

Гыйбадулла Хәбибулла улы Алпаров
1888—1936

# ГЫЙБАДУЛЛА АЛПАРОВ

## САЙЛАНМА ХЕЗМӘТЛӘР

ФОНЕТИКА. ГРАФИКА. ОРФОГРАФИЯ.
ГРАММАТИКА МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Казан • «Мәгариф» нәшрияты • 2008

УДК 811.512.145.34/36
ББК 81.2-2/8
А54

*Җыентыкның фәнни редакторы —
филология фәннәре докторы, профессор И. Б. Бәширова*

*Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

**Алпаров Г. Х.**

А54 Сайланма хезмәтләр / Гыйбадулла Алпаров. – Казан : Мәгариф, 2008. – 287 б.: рәс. б-н.
ISBN 978-5-7761-1879-1

ISBN 978-5-7761-1879-1

© Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2008
© «Мәгариф» нәшрияты, 2008

## Г. АЛПАРОВНЫҢ ТОРМЫШЫ
## ҺӘМ ГЫЙЛЬМИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

2008 елның декабрь аенда мәшһүр тел белгече, тюрколог, педагог, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Гыйбадулла Алпаровның тууына 120 ел тула. Аның тормышын һәм күпкырлы эшчәнлеген Х.Бәдигый, Ш.Рамазанов, Л.Җәләй, В.Хангилдин, Л.Яфаров, Г.Әхәтов, Ф.Ганиев, Г.Якупова, М.Сәгыйтов, Ф.Фаткуллин, Р.Үтәбаев кебек күренекле тел галимнәре, танылган педагог һәм журналистлар тирәнтен өйрәнеп анализлаганнар һәм үзләренең фикер-нәтиҗәләрен хезмәтләрендә, Татарстан, Башкортстан республикалары матбугат битләрендә бәян иткәннәр.

Г.Алпаров кебек шәхеснең җәмгыятьтә тоткан урыны һәм роле турында сөйләгәндә, аның нинди гаиләдән чыгуын, әтисе-әнисе һәм әби-бабаларының кем булуын белү, нинди эш белән шөгыльләнүләрен дә истә тоту кирәктер.

Гыйбадулла Хәбибулла улы Алпаров 1888 елның иске стиль белән 20 ноябрендә (яңача 2 декабрендә) Уфа губернасы Стәрлетамак өязе хәзерге Авыргазы районының Корманай авылында тугыз балалы гаиләдә, әти-әнисен сөендереп, икенче бала булып дөньяга килә. Гыйбадулланың әтисе Хәбибулла абзый – алдынгы карашлы мөселман руханилар вәкиле, бай тормышлы булган. Аның дөньяга нинди караште булуын күрсәтү өчен түбәндәге фактларны китерү дә җитә. 1911–1912 елларда Хәбибулла Алпаров авылда больница ачу хәстәрен күрә башлый. Әмма аның бу изге нияте тормышка ашмый кала. Чөнки иске карашлы кешеләр, мөселман руханилары «Авылга руслар җыярга телисеңме»,– дип аңа каршы төшәләр. Инде бу нияте барып чыкмагач, Хәбибулла абзый, төрле янауларга, куркытуларга карамастан, үз йортында мәктәп ачуга ирешә. Ул үз акчасына мәктәп өчен парталар, класс такталары, урындыклар, уку китаплары сатып ала, аларны Стәрлетамактан үз аты белән ташый. «Мәктәп бинасын бөтен гаиләбез белән җыештыра идек, идәнен юабыз, әти мичне үзе яга иде. Якты киләчәккә ул нык ышанды. Бу тойгылар безгә – балаларга да күчте. Нәкъ менә шуңа күрә дә барысы да (алты малай, өч кыз) илебез һәм халкыбыз өчен файдалы кешеләр булып үстеләр, партия һәм совет работниклары дәрәҗәсенә җиттеләр»,– дип искә алалар



Гыйбадулла Алпаров «Галия» мәдрәсәсе шәкертләре арасында. 1908 ел

Алпаровның кече балалары Мәхмүт белән Мәрьям. («Ватан юлы», 29 май, 1973, № 64)

Башлангыч белемне Гыйбадулла Алпаров үз авылы мәктәбендә ала, аннан соң Уфа шәһәрендә «Госмания» һәм «Галия» мәдрәсәләрендә укый, 1910 елда Казанга килеп «Татарская учительская школа» шәкерте була һәм бу уку йортын 1913 елда тәмамлый. «Госмания» мәдрәсәсендә укыган елларын галим болай дип искә ала: «1904–1905 елларда инде мин газета аркылы бөтен дөнья әхвәле белән танышып баручы идем. Якыннан катнашмасам да, 1905 ел революция хәрәкәтләрен беркадәр аңлап, эчемнән аның яклы булып үткәрдем. Мәдрәсәдә мантыйк укуга каршы забастовкаларда катнаштым. 1907 елны, хәзрәтнең «бәддогасына» карамыйча, «Галия» мәдрәсәсенә күчеп киттем. Атам мине тәрбияләүдән кул селтәде» (5, 168б.). Шуңа күрәдер, булачак тел белгече «Галия» мәдрәсәсендә укыганда каникул вакытларында, Галимҗан Ибраһимов белән бергәләп, Урта Азия якларына барып, үзбәкләр, казахлар, кыргызлар, таҗиклар арасында укытучылык хезмәте белән шөгыльләнә, аларның телләрен, йолаларын, гореф-гадәтләрен өйрәнә, шул рәвешле ул өч



Гыйбадулла Алпаров, Галимҗан Ибраһимов

ел дәвамында эшли дә, укый да. Гыйбадулла Алпаров 18 яшеннән үз көнен үзе күрә башлый. 1910–1911 елларда Казанда, 1913–1914 елларда Оренбург губернасының Троицк шәһәрендә балалар укыта. 1914–1918 елларда Г.Алпаров кабат Стәрлетамак өязенә кайта, Карамалыда культура-агарту өлкәсендә хезмәт итә.

Октябрь инкыйлабын яшь белгеч күтәренке рух белән каршы ала һәм халкыбызның рухи-мәдәни дәрәҗәсен күтәрү юлында зур тырышлык куя. 1918 елда Уфада «Авыл халкы», «Көрәш», «Кызыл яу» газеталарын чыгаруда актив катнаша, 1920 елда Уфадагы халык мәгарифе институтында белемен күтәрә, төрле уку йортларында, укытучылар өчен ачылган курсларда тел гыйлеме укыта, Кызыл гаскәрләр өчен ачылган курсларда дәресләр бирә. Шул ук вакытта Башкортстан китап нәшриятында бүлек мөдире, «Кызыл юл», «Шәрык ярлылары», «Урал» газеталарында әдәби хезмәткәр, секретарь, редактор булып эшли. Әйтергә кирәк, әлеге газета битләрендә галимнең күп санлы мәкаләләре дөнья күрә һәм алар татар, башкорт хезмәт ияләренең милли-сәяси аңын үстерүдә әһәмиятле роль уйныйлар.



Гыйбадулла һәм Гайшә Алпаровлар. 1914 ел



Гыйбадулла Алпаровның әнисе Мәрфуга, әтисе Хәбибулла Алпаровлар. Уфа. 1925 ел

Инде югарыда язылганча, Г.Алпаров «Галия» мәдрәсәсендә укыган чорда да, Казанда «Татарская учительская школа»ны тәмамлаганнан соң да балалар укыту белән шөгыльләнә һәм гарәп хәрефләренә нигезләнгән алфавит белән балаларны укырга-язарга өйрәтүнең авырлыгын һәм кыенлыгын үз җилкәсендә татый. Уку-укыту практикасы, әлифба һәм орфография тарихын өйрәнү нәтиҗәсендә ул татар хәрефләренең формасын үзгәртү, аларның санын азайту фикеренә килә һәм үз практикасында боларны эшләп тә, сынап та карый. Бу урында авторның үзен тыңлап карау яхшырак булыр: «Без ике кыш, балаларга берәр баш хәрефне күрсәтеп кенә укырга һәм язарга өйрәтеп карадык: балалар аңарга бик тиз төшенә, берәр баш хәрефләрне генә кушып язудан хәзерге кеби гүзәл язу чыга. Хәрефләребез берәр генә калдырылса, балаларга ике-өч айда белдерелә торган нәрсәләрне бер айда белдереп, калган вакытларда башка файдалы гыйлемнәр өйрәтергә мөмкин булыр иде. Аларның газиз гомерләре әллә ничә катлаулы хәрефләр белән саташып үтмәс иде». (1, 17). Галим үзенең бу идеясен 1912, 1913 елларда Казанда нәшер ителгән «Хәреф вә имлямыз», «Татар әлифбасы» китаплары аша киң массага таратырга тырыша. Бу хезмәтләрдә хәреф,



Гыйбадулла Алпаров (өстәге рәттә, сулдан өченче) тел-әдәбият галимнәре, язучылар Гомәр Әлмөхәммәтов, Гомәр Гали, ?, Сафа Борһан, Сәгыйть Фәйзуллин, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Гадел Кутуй, Зәки Гыймранов, Исмәгыйль Рәмиев, Гомәр Толымбайский, Кәрим Әмири, Исхак Рәхмәтуллин һ. б. арасында

сүзнең кайсы урынында килүенә карамастан, һәрвакыт бер генә шәкелдә күрсәтелә. Шулай итеп, язуда татар хәрефләренең саны өч тапкыр кими. Ни кызганыч, Г.Алпаровның бу теләге К.Насыйри һәм Ш.Иманаевларның идеяләре кебек тормышка ашмый кала. Татар язуында бер авазны өч-дүрт хәреф белән күрсәтү гарәп графикасын латинга алыштырганчы дәвам итә. Шуны да искәртергә кирәк, галим «Хәреф вә имлямыз» хезмәтендә, беренчеләрдән буларак, әлифба тарихын шактый киң яктырта. Җыеп әйткәндә, галим, Октябрь революциясенә кадәр үк хәреф-имля, язу тарихы, әлифба, сүзлекләр төзү өлкәсендә шактый зур нәтиҗәләргә ирешә.

Г.Алпаров мөстәкыйль эшчәнлеген тәрҗемәләрдән башлап җибәрә. Ул, Г.Ибраһимов белән берлектә, рус теленнән «Бичара колның тормышы» (1908), «Миллионнар табу» (1909) исемле хикәяләрнең, 1910 елда төрекчәдән «Бичара хатын» әсәренең тәрҗемәләрен һәм «Кесәлек мәңгелек календарь» (2 нче кисәк) дигән хезмәтен бастыра.

Гражданнар сугышы барган авыр еллардагы киеренке хезмәт Г.Алпаровның сәламәтлеген шактый какшата. 1921 елда ул Урта Азиягә дәваланырга җибәрелә. Авыру булуы-

на карамастан, эшен дәвам иттерә. Башта Әүлията өязендә гомуми белем мәктәбендә сабак бирә, аннары совет-партия мәктәбендә лекцияләр укый. 1922–1924 елларда Ташкентта «Чулпан» журналында җаваплы сәркатип, казах телендә чыга торган «Ак юл» газетасында хезмәткәр вазифаларын башкара. Төрекмәнстан Мәгариф халык комиссариатының дәүләт гыйльми советында эшли. Үзбәк, казах, кыргыз, уйгур, төрекмән телләрен яхшы белүче буларак, Г.Алпаров шушы милләт халыкларына фәнни-практик ярдәм дә күрсәтә. Галим бу телләрнең өзлексез баюын, камилләшә баруын күреп, халыкларны бай сүзлек хәзинәләреннән, телләрнең сүз ясау мөмкинлекләреннән, җанлы сөйләшү теленнән, җирле сөйләшләрдән тулы һәм нәтиҗәлерәк файдаланырга өнди, телгә игътибарлы булырга, тел үсешен тәртипкә салырга үгетли. Шушы елларда Г.Алпаров байтак кына төрки телләрнең дәреслекләрен төзүдә дә катнаша. Аның, төрекмән галиме Мөхәммәд Гилдиев белән берлектә, 1924 елда төзегән әлифбасы төрекмән мәктәпләрендә 15 ел буена дәреслек буларак хезмәт итә. Моннан тыш ул төрекмәнчә «Олыларга уку-язу өйрәтү өчен сабаклык», «Тел сабаклыгы», «Төрекмән теленең грамматикасы»н язган, каракалпак халкы теле грамматикасы нигезләрен эшләүдә катнашкан. Болар, үз нәүбәтендә, күпьяк төрки телләрнең әлифба һәм орфографияләрен эшләүдә һәм эшкәртүдә актив катнашырга мөмкинлек бирсә, киләчәктә үзенең гыйльми эшләрендә бу телләрне чагыштырма-тарихи метод белән өйрәнүгә бик нык ярдәм итә.

1924 елда Г.Алпаров яңадан Уфага кайта һәм Башкортстан Мәгариф комиссариаты каршындагы Гыйльми үзәкнең һәм Академүзәкнең органы – «Белем» журналының сәркатибе булып эшли. 1925 елда ул Казанга килә, анда Татарстан Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Гыйльми үзәккә сәркатип булып эшкә урнаша, Татарстан Мәгариф комиссариатының Татарстан делегаты буларак, 1926 елда Баку шәһәрендә үткән Беренче тюркологик съезд эшендә катнаша. Съездга әзерлек уңае белән «Мәгариф» журналында, «Кызыл Татарстан» газетасында «Бездә хәреф мәсьәләсе» исемле мәкаләсен бастыра.

1926 елның җәендә, Гыйльми үзәк җитәкчесе Г.Ибраһимов тарафыннан сайланып, өч кеше – Г.Алпаров, Х.Бәдигый, Н.Хәким Ленинградка укырга җибәрелә. Андагы Көнчыгыш институты студентлары Н.Н. Поппе, И.И. Мещанинов, Н.Я.Марр, С.Е. Малов, В.Н. Самойлович, Л.В. Щерба кебек танылган галимнәренең дә лекцияләрен тыңлыйлар. Татар егетләре башта Ленинград Көнчыгыш институтының төрки телләр бүлеген (1928



Беренче төрекмән дәреслекләрен төзү.
Гыйбадулла Алпаров һәм Мөхәммәд Гилдиев. 1923–1925 еллар

ел), аннары шунда ук аспирантура (1930) тәмамлыйлар. 1930 елда өчесе дә зур белгеч булып Казанга әйләнеп кайталар. Бу турыда Казан дәүләт педагогия институты профессоры Мөхәммәтхан ага Фазлуллин бер истәлегендә болай дип яза: «... 1930 елның язында алар аспирантураны тәмамлап кайтканда инде безгә, Казан педагогия институтында, татар теле кафедрасы оештырырга рөхсәт ителгән иде. Без аларның өчесен дә шул кафедрага укытучы итеп чакырдык, доцентлар итеп билгеләдек. Кафедраны юлга салу эшендә Гыйбад ага зур булышлык итте. Татар теле буенча синтаксис курсын укытып барды. Студентларны тәрбияләү эшендә актив катнашты». (М.Фазлуллин. Кульязма истәлек. 19 декабрь, 1958 ел.)

Казанга кайткач, Г.Алпаров педагогия институтында һәм башка югары уку йортларында укыта, гыйльми эш алып бара, гыйльми кадрлар әзерләү өлкәсендә зур эшчәнлек күрсәтә. 1931 елда кафедрада аспирантура ачылгач, Ш.Рамазанов, В.Хангилдин, Л.Җәләй, Ф.Хәмидуллин, Г.Хәбиб кебек яшь белгечләр, Г.Алпаров җитәкчелегендә аспирантура курсын үтәләр, мәшһүр тел белгечләре, зур галим булып җитешәләр. Гомумән, педагогия институтында эшләгәндә Г.Алпаров җитәкчелегендә йөзләрчә укытучылар, дистәләрчә гыйльми хезмәткәрләр әзерләнеп чыга. 1930–1931 елларда галим Татарстан фәнни-тикшерену экономика институтының гыйльми хезмәткәре булып та эшли. Тел белеме өлкәсендә җитди

хезмәтләре белән танылган профессор Х.Бәдигый, Г.Шәрәф һәм М.Фазлуллиннар белән бергә, ул 1934 елда татар эшче һәм колхозчыларының сөйләм телен өйрәнү өчен төзелгән 20 кешелек экспедициягә җитәкчелек итә. Шул ук елны Урал педагогия фәнни-тикшеренү институты тарафыннан Свердловск шәһәренә татарлардан тел-әдәбият укытучылары әзерләү буенча оештырылган курсларда лекцияләр укырга чакырыла. Г.Алпаров әдәбият галимнәре һәм классик язучыларыбыз Г.Ибраһимов, М.Гафури һәм башкалар белән иҗади бәйләнештә тора. Мәсәлән, М.Гафури юбилеен котлап, Ташкенттан «Мәҗит абый кем?» дип язган хаты «Башкортстан» газетасында басыла. Укытучылык хезмәтен башкару белән бер рәттән ул тел мәсьәләләрен тикшерү буенча да нәтиҗәле эш алып бара.

Галим бик иртә, 48 яшендә, педагогик һәм гыйльми эшчәнлегенең киң җәелеп үскән чагында, 1936 елның 31 июлендә фани дөньяны калдырып мәңгелеккә күчә. Җәсәде Казанда Арча зиратында күмелгән. Ләкин дөньядан иртә китүенә карамастан, ул тел белеменә караган 30 лап китап, 40 тан артык фәнни хезмәт, 100 гә якын иҗтимагый-публицистик һәм фәнни-популяр мәкалә калдыра. Аларның күбесе, инде алда язылганча, татар, башкорт, төрекмән, үзбәк телләренең әлифба, орфография мәсьәләләренә багышланган. Татар теленең грамматик төзелешенә караган хезмәтләре түбәндәгеләр: «Телебездә падеж мәсьәләсе», «Грамматика нигезләре турысында», «Татар теленең ялганмалык табигате турында», «Татар телендә кушма төрләр», «Функциональ сүзләр», «Татар телендә иярчен җөмләләр бармы?» Г.Алпаровны тел галиме буларак дөньяга таныткан хезмәте – беренче басмасы 1926 елда, икенче басмасы 1927 елда дөнья күргән «Шәкли нигездә татар грамматикасы» дигән монографиясе. Бу хезмәт шул чорда ук фән, мәдәният җәмәгатьчелегендә зур кызыксыну уята һәм тел белгечләренең төрле бәясен ала. «Телебезне гыйльми тикшерү юлында бер тәҗрибә» буларак язылган зур күләмле бу хезмәт татар теле фәне үсешенең яңа этабын башлап җибәрә. Ләкин авторга бу кыю адымы өчен шактый тәнкыйть сүзләре дә ишетергә туры килә. Тәнкыйтьнең төп юнәлеше, әлеге грамматикада телнең тик тышкы, ягъни шәкли ягы гына алынып, эчке – мәгънә ягы читләтелгән диюдән гыйбарәт була. Болай бәяләү тәнкыйтьнең берьяклы булуыннан килә. Шуны ассызыклап әйтергә кирәк: Г.Алпаров телнең мәгънә ягына игътибар итмәүчеләр тарафдары түгел иде. Аның өчен телнең шәкли ягын, формаль факторларын өйрәнү үзмаксат булмады. Тел күренешләренең башта шәкли ягын,



Аста, уңнан беренче — Гыйбадулла Алпаров, өченче — Галимҗан Нигъмәти

формаль якларын өйрәнү аңа соңыннан бу күренешләрнең мәгънәсенә тагын да тирәнрәк, тагын да тулырак төшенү өчен кирәк иде. Аңлашылганча, формаль нигезгә корылган грамматика телнең тышкы ягы белән эш итми булдыра алмый, югыйсә ул шәкли (формаль) грамматика да булмас иде. Әнә бит автор үзе үк: «Дөрес, кайбер урыннарда мәгънә ягына да кагылмый булмас. Чөнки телнең тышкы әйтелеш ягы белән эчке мәгънә ягы бер-берсенә бик нык бәйләнештә була» (3, 28), – дип яза. Аның, мәсәлән, сүз төркемнәрен эчке һәм тышкы яклардан карап классификацияләве, сүзләр ясалышын фонетик, морфологик, синтаксик төрләргә бүлеп каравы нәкъ әнә шул принципка корылган.

Хезмәт тел материалына гаять дәрәҗәдә бай булып, дүрт бүлектән гыйбарәт: кереш, фонетика, морфология һәм синтаксис. Монда телебезнең грамматик төзелеше үзенчәлекле һәм шактый тулы яктыртыла, анык мәгълүмат билгеле бер калыпка салып бирелә. Галим бу хезмәтен татар, башкорт, казах, кыргыз, төрекмән, үзбәк, уйгур телләрен янәшә куеп, чагыштырып яза һәм ул гомуми тюркология куләмендә фәнни грамматика тудыруда иң уңышлы тәҗрибә була.

«Шәкли нигездә татар грамматикасы» дүрт бүлектән гыйбарәт дидек. Боларның дүртесе дә оригиналь хезмәтләр. Г.Алпаров,



Г.Алпаров, Х.Бәдигый, Н.Хәким *Ленинград* Көнчыгыш *телләр* институтында укыган вакытта. *Ленинград*. 1928–1929 *еллар*

гомумән, әзер материал белән эш итми торган, үзе тикшереп ышанган фактларны гына фәнни эшкәртә торган галим була. Моны фонетика бүлегенә караган материаллар да дәлилләп тора. Г.Алпаров экспериментал фонетика белән шөгыльләнгән галим түгел. Шуңа да карамастан, аның грамматикасында татар теленең фонетик төзелеше тирәнтен тикшерелгән һәм үзенчәлекле яклары тулысынча ачылган. Мәсәлән, татар сөйләмендә «а» авазының (басымсыз иҗектә) иренләшү үзенчәлеген беренче башлап ачучы, дәлилләүче Г.Алпаров була. Аның бу ачышының дөреслеге экспериментал юл белән дә раслана. О–ө сузыкларының сүз эчендә әйтелеш үзенчәлекләрен билгеләүдә дә аның фикере аксиома булып тора. Төрки телләргә хас сингармонизм күренеше дә, беренче буларак, Г.Алпаров тарафыннан җитди тикшерелә һәм аңа «авазлар гармониясе» дигән гаять төгәл фәнни билгеләмә бирелә. Татар телендә фонетик чаралар белән сүз ясалу фактына башлап игътибар итүче һәм аны фәнни нигезләүче шулай ук профессор Г.Алпаров була.

«Шәкли нигездә татар грамматикасы» китабында татар теленең фонетик төзелеше тирән һәм тулы яктыртылган. Монда автор татар теленеке дип танылырга тиешле авазларның санын ачыклый: «Димәк, – дип яза ул, – безнең телебездә,

калын һәм нечкә әйтелүләрне игътибарга алмаганда, барлыгы 28 аваз бар. Аларның һәрберсенең калын да, нечкә дә әйтелүләрен игътибарга алганда, безнең телебездә барысы 56 аваз булырга туры килә (сузыклар – 10, тартыклар – 46).

Узган гасырның 20 нче елларында гыйльми һәм мәктәп грамматикаларын шәкли нигездә кору юлында кызу эш башлана. Бу өлкәдә рус галимнәреннән А.М. Пешковский, М.К. Петерсон, Гуппиус һәм башкалар грамматикада шәкли принципны бик нык яклап чыгалар.

Яңа эш мәктәпләре өчен Дәүләт гыйльми советы (ГУС) тарафыннан тел буенча төзелгән программаларда да телнең шәкли ягы нигез итеп алынган була. Ягъни грамматика дәресләрендә сүзләрнең тышкы күренешләрен, аларның формаль үзгәрешләрен тикшерү, җөмләләрне дә сүз тезмәләре дип тикшерү һәм өйрәнү төп максат итеп куела. Грамматикаларны шәкли нигездә төзү яки төземәү мәсьәләсе төрки тел фәнендә дә кызу бәхәсләр тудыра. Бу бәхәс, Г.Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» чыкканга кадәр үк, Ташкентта 1922–1923 елларда үзбәк телендәге «Инкыйлаб» журналында күтәрелә. Монда үткәрелгән җаваплы бер киңәшмәдә профессор Е.Д. Поливанов «Төрки телләрдә тар шәкли грамматика нигезе»н алу турында доклад сөйли. Телче һәм әдәбият белгече Г.Сәгъди моңа каршы төшә. Ул төрки телләрдә саф шәкли нигезне алу мөмкин түгел дип чыга. Ләкин фәнни бәхәс киңәшмәдә сөйләнгән сүзләр белән генә бетми, ул «Инкыйлаб» журналы битләрендә дәвам итә, соңыннан «Мәгариф» (Казан) журналы битләренә дә күчә. Димәк, Г.Алпаров бөтен ил тел белгечләре, мәгариф һәм гыйльми учреждение эшчеләре арасында күп санда үзенең яклаучыларын тапкан, мәктәп практикасында кулланылган шәкли нигездәге грамматикаларны читтән күзәтүче генә булмаган. Ул «Шәкли нигездә татар грамматикасы»н практик рәвештә төзеп күрсәтүне көн тәртибенә куя һәм, кичекмәстән аны башкарып, китап итеп бастырып та чыгара.

1927 елның 15–22 июнь көннәрендә Казанда үткәрелгән тел-әдәбият конференциясендә Г.Алпаров «Шәкли грамматика агымы һәм шәкли грамматика нигезләре» темасына доклад ясый. Докладында, грамматикада шәкли агымның тарихын һәм асылын аңлатуга зур урын бирсә дә, аның мәгънә ягын да игътибарсыз калдырмый. «... шулай да, – ди ул, – телнең шәкли ягын бөтенләй саф көенчә, бер дә мәгънә ягына кермичә өйрәнү кыен һәм артык җансыз, файдасыз да бер нәрсә булыр иде. Шуңа күрә, шәкли ягы грамматикада нигез, төп итеп кенә алына, телнең мәгънә ягы ташланмый, бәлки аны шәкелгә иартеп, тагы да ачыклабрак өйрәнергә



Казах телендәге «Ак жул» газетасы редколлегиясе, Г.Алпаров арттагы рәттә, уңнан икенче. 1924 ел

юл ачыла». Шул ук докладында галим шәкелне өйрәнүнең тел законнарын ачыклауга, һәр аерым телгә хас булган фактларның бүтән тел тәэсиренә бирелүләренә юл куймауга хезмәт итүен дә әйтә. Конференция, грамматикада шәкли нигезне уңай күренеш, дип таба һәм киләчәктә шул нигезгә күчәргә кирәклек турында махсус карар да кабул ителә.

«Шәкли нигездә татар грамматикасы»ның 1927 елда бераз төзәтелгән 2 нче басмасы чыккач, «Мәгариф» журналы битләрендә аңа карата тел белгечләре Х.Бәдигый, Ф.Туйкә, И.Гобәйдуллин һәм башкаларның рецензияләре басыла. Хуҗа Бәдигый журналның өч санына сузылган, җентекле һәм тирән фәнни тикшеренү нәтиҗәсе булган озын мәкаләсендә, галимнең «Шәкли нигездә татар грамматикасы» хезмәтенә югары бәя бирә. Ул Г.Алпаров китабында телебездәге моңа кадәр таркау, томанлы хәлдә булган тышкы фактларның ачык гәүдәләндерелүе, бу юнәлештәге тикшеренүләргә киң юл ачылуы һәм тикшеренү, тәҗрибәләрне уртаклашу кирәклеге турында теләк белдерә.

Галимнең «Шәкли нигездә татар грамматикасы» монографиясе һәм күпләгән башка хезмәтләреннән югары уку йортларының татар теле һәм әдәбияты бүлеге укытучылары һәм студентлары уннарча еллар буена файдаланып килделәр һәм киләчәктә дә файдаланырлар.

Профессор Г.Алпаров телебезнең аваз-хәреф, имля һәм грамматикасы мәсьәләләрен тикшерү белән генә чикләнми. Аның гомуми тел гыйлеменә, тел фәлсәфәсенә караган хезмәтләре («Тел гыйлемендә марксизм хәрәкәте», «Тел гыйлемендә марксизмга таба», «Тел гыйлемендә диалектик материализм нигезләре») дә байтак. Аның «Тел гыйлеменең кыскача тарихы» хезмәтендә грамматика һәм тел белеме тарихында үтелгән юллар, тел белеменең үсеш баскычлары, үсеш юнәлеше шактый тулы яктыртылган. Г.Алпаров үзенең бик күп хезмәтләре белән тел гыйлемебезне тагын да үстерү, күп милләтле илебез чикләреннән читкә – башка халыкларга да җиткерү эшенә билгеле бер өлеш керткән галим.

Миңа калса, хәзерге укучы галимнең әлифба алыштыру кебек четерекле мәсьәләгә карата булган фикерен дә белеп торырга тиеш. Г.Алпаровның 1926 елда Бакуда узган Беренче тюркологик съездда делегат булып катнашуын язган идек инде. Анда төрки халыкларының гарәп әлифбасына нигезләнгән язуын латин графикасына күчерү мәсьәләсе дә карала. Татар зыялыларының күпчелеге, шул исәптән Г.Алпаров та, моңа




Шиһаб Рамазанов (өстә, сулдан өченче), Гыйбадулла Алпаров (өстә, сулдан дүртенче)

каршы була. Ул үз фикерен «Латин түгел, гарәп» дигән мәкаләсендә түбәндәгечә дәлилли: «Хәреф алмаштыру бар, хәреф алу бар – болар икәве ике нәрсә. Элгәредән үзенең әлифбасы, язуы, мәдәнияте булмаган халык кына «Әлифба ала». Бу дөньяда бар эш, иректе эш. Ул аны «мәдәниятле»дән сайлап ала, чагыштырып, карап ала.

Ләкин электән әлифбалы, язулы бер халыкның, бер фаҗигале хәл булмаганда, үз ирекe белән әлифба алыштыруы, яңаны сайлап алуы – булмый торган нәрсә. Бер халык үзенең ана телен үз ирекe белән алмаштыра алмаган кебек, тел кебек үк үзләшкән язуын да алмаштыра алмый...

Яңа әлифбага күчү өчен, элгәреге әлифбаның 90% ы укырга да, язарга да яраксыз булуы, техникага бөтенләй уңайсыз булуы кирәк. Яңадан алмаштырып алына торган әлифбаның халык арасында күптән, яртылаш таныш булуы, үзе көн-төн катнашып бергә аралашып яшәгән халыкның әлифбасы булуы шарт.

Бу шартлар табылмаганда, яңа әлифбага күчәбез, дип булышу – тирәнлеге, киңлеге беленмәгән диңгезгә кереп йөзәргә тотыну белән бер булачагына шик юк». (2, «Безнең юл», 1926.– № 4.). Галимнең сүзләре, фикере Ж.Вәлидинеке белән аваздаш. Ул да бит: «Яңа әлифба кертү – милли мәдәният өчен фаҗига, чөнки бу традицияләрнең тулысынча өзелүе дигән сүз. Бөтен халык кинәт кенә, бер мизгел эчендә наданга әверелә», – дип әйткән. Бу ике олпат зыялыбызның әлифба алыштыруга каршы булулары, аларның яңалыкны аңламавыннан түгел, бәлки үз халкын укымышлы, мәдәниятле итеп саклау ниятеннән туган.

Гыйбадулла Алпаровның гаиләсе этисенеке кебек ишле булмый. Ул Кырмыскалыда эшләүче, Мирсәет Солтангалиевнең туганы, Гайшә исемле кызга өйләнә. 1914 елда аларның уллары туа, аңа Үзбәк дип исем кушалар.

Үзбәк кече яшьтән үк тырыш, эш сөючән була, әти-әнисенең йөзенә кызыллык китерми, 35 ел «Татгражданпроект» институты директоры булып эшли. Хезмәттә ирешкән уңышлары өчен ул республика һәм ил күләмендәге мактаулы исемнәргә лаек була, күкрәген «Хезмәт Кызыл Байрагы», ике «Почёт билгесе», «Халыклар дуслыгы» орденнары бизи.

Үзбәк аганың әтисенә булган җылы мөнәсәбәте аның «Кызыл таң» газетасы хезмәткәре Ф.Фаткуллинга биргән җавабында ачык чагыла. Әтиегезне ничегрәк хәтерлисез?– дигән сорауга ул: «Идеаль кеше булмый диләр. Әти минә шул идеалга якын кеше иде. «Итагатьле Гыйбадулла хәзрәт» дип йөртәләр иде аны. Бик иҗади кеше, башында яңадан-яңа идеяләр туып кына тора иде...» – дип җавап бирә.



Гыйбадулла Алпаров гаиләсе белән. 1935 ел

Г.Алпаровның башка балалары булмаган. Казан шәһәрендә ике оныгы – Әскәр, Фәридә (Галия белән Үзбәкнең балалары) яши.

Чыганаклар:

1. *Алпаров Г.* Хәреф вә имлямыз.– Казань: Лито-типография Т-го Д-ма «Бр.Касимовы», 1912. – 29 б.

2. *Алпаров Г.* Латин түгел, гарәп // Безнең юл. – 1926.– № 4.

3. *Алпаров Г.* Сайланма хезмәтләр.– Казан: Татгосиздат, 1945.

4. *Вәлиди Җ.* Сайланма хезмәтләр.– Казан: Мәгариф, 2007.

5. *Җәләй Л.* Фәнни кыюлык // Казан утлары.– 1978.– № 12.

6. *Якупова Г., Фаткуллин Ф.* Бертуган Алпаровлар // Ватан юлы. – 1973. – 29 май. – № 64.

7. Беренче тел-әдәбият конференциясе материаллары. – Казан, 1927.

8. *Фаткуллин Ф.* Йөз елларга торырлык дәвернең бер батыры // Кызыл таң. – 1998. – 18 ноябрь.

*Ш. Асылгәрәев*

## ТӨЗҮЧЕЛӘРДӘН

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, «Мәгариф» нәшрияты белән берлектә, татар теле һәм әдәбиятының төрле аспектларын яктырткан фәнни-гамәли хезмәтләре белән тирән эз калдырган олуг галимнәребезнең һәм әдипләребезнең мирасларына кире кайтып, алар арасыннан бүгенге көндә дә актуальлелеген саклап килгәннәрен махсус серия рәвешендә бастыруны дәвам итә.

Мәгълүм булганча, Галимҗан Ибраһимовның «Милләт, тел, әдәбият», Җамал Вәлидинең «Сайланма хезмәтләре» укучылар хөкеменә барып иреште дә инде.

Бу томга Г.Алпаровның 1912 елда гарәп графикасында басылып чыккан «Хәреф вә имлямыз» һәм 1945 елда хәзерге татар әлифбасында (кирилл хәрефләре белән) нәшер ителгән «Сайланма хезмәтләре»ндәге «Шәкли нигездә татар грамматикасы», «Татар грамматикасына караган өстәмә материаллар»ы һәм, шуларга өстәп, заманында газета-журналларда дөнья күргән 6 мәкаләсе кертелде. Әлеге материаллар хронологик тәртиптә урнаштырылды:

1) Хәреф вә имлямыз (1912).

2) Грамматика нигезләре турысында (1925).

3) Латин түгел, гарәп (1926).

4) Шәкли нигездә татар грамматикасы (1926, 1927, 1945).

5) Татар грамматикасына караган өстәмә материаллар (1927–1936).

6) Ун ел эчендә татар теле (1927).

7) Фонетик транскрипцияме, гамәли язумы? (1928).

8) Татар грамматикасы турындагы тәнкыйтьләргә җавап (1928).

9) Татар грамматикасы турындагы тәнкыйтьләргә җавап (1929).

Күпчелек хезмәтләр авторның үзе исән чагында гарәп графикасында басылган. Алда әйтелгән «Сайланма хезмәтләр» җыентыгы гына (фәнни редакторы Ш.Г.Рамазанов) Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты (хәзерге Г.Ибраһимов исемендәге ТӘҺСИ) галимнәре тарафыннан әзерләнеп, татар алфавитында нәшер ителгән. Гарәп язуындагы хезмәтләрнең текстларын рус графикасына нигезләнгән гамәлдәге әлифбабызга күчерү эшен Ш.Н. Асылгәрәев җитәкчелегендәге бүлек хезмәткәрләре (М.З. Вәлиева, Р.Н. Дәүләтшина, Л.И. Яруллина, Э.И. Яруллин) башкарды. «Шәкли нигездә татар грамматикасы» текстын басмага Г.М. Сөнгатев әзерләде. Махсус сүзлекләрдән файдаланып, тексттагы һәр сүз, аларның мәгънәсе һәм язылышы ачыкланды. Гарәп-фарсы телләреннән алынмалар (нәху, муафикъ, тәсаувыр, матлуб һ. б.), шулай ук башка кайбер сүзләрнең охшаш язылышы оригиналдагыча калдырылды. Төрек сүзенең автор тарафыннан төрки мәгънәсендә кулланылуын да искәртергә кирәк.

Китапта бирелгән фотолар Алпаровларның шәхси архивыннан алынды.

# АЛПАРОВЛАР НӘСЕЛЕ ШӘҖӘРӘСЕ



# ХӘРЕФ ВӘ ИМЛЯМЫЗ[1]

Әлифба тарихы, иске язулар, хәрефләребезнең
күплеге, үз тавышыбызга хәрефләр, имлямыз...

## Башлангыч

Мин кечкенә шәкерт чагымда, русларның «кесә матбагасы»н күп истигъмаль иткәнгә күрә, үз хәрефләребезгә дә шундый «кесә матбагасы» ясалуын тели идем. Андый татарча матбаганы бер җирдән дә тапмагач, резинкадан кисеп үзем эшләп тә карадым. Ләкин хәрефләребезнең гаять күп булуы миңа кискә булды. Мин шул чакта ук хәрефләребезне азайту турысында уй йөртә башладым. Күп уйлый торгач, аңарга бер төрле чара да таптым: нокталарга, хәреф койрыкларына үзләренә башка шрифтлар кистем.

Шундый «кесә матбагасы»ның халкыбыз арасына таралуын теләп, резинкадан хәреф кою мәсьәләсе белән дә күп вакыт баш ватып йөрдем.

Соңра, шундый ук хәрефләр белән, татарча «язу машинасы» ясап чыгарырга да хыялланып йөрдем. Мин кая барсам да, шуны гына уйлый, иптәшләремә дә шуны сөйли идем.

Ахырда чын матбага эшләре белән танышкач, мин матбагаларыбызда хәреф күплегеннән килгән зарарларны аңладым. Нокталарны аермыйча, баш хәрефләргә коерыклар ялгап, бик аз хәрефләр белән дә китаплар басарга мөмкин булачагын төшендем. Хосусый кешеләргә, матбагачыларга аны кабул иттерергә тырыша башладым. Үзем уйлаган баш хәрефләрне бервакыт Казандагы Харитонов матбагасы идарәсенә дә тәкъдим иткән идем.

Мәгълүм булгач мин, хәрефләребезнең күплегеннән тәгълим (уку, өйрәтү) эшенә килгән зарарны да аңлаганга күрә, балаларга үзем бирәр хәрефле әлифба язып укыттым.

1909 ел Уфада, иптәшләремә ул фикерне вә әлифбаны гарыз иткәли йөрдем. Гата Исхакый әфәнде шул фикергә кушылып, үзенең «Мөҗәссәм әлифба»сын эшләде.

Мин көне-төне хәреф вә имля мәсьәләсе турысында уй йөртә идем. Бәгъзы иптәшләрем минем артык хыяллануымнан көләләр дә иде. Ләкин

[1] Гыйбадулла (Гыйбад) Алпаровның шушы исемдәге китабы 1912 елда гарәп хәрефләре белән Казандагы бертуган Кәримовлар тарафыннан нәшер ителгән булган.




«Һәреф вә имлямыз» дигән китапның тышлыгы

мин милләтебезнең ул дүртәр калыплы хәрефләрне, әлбәттә, бервакыт ташлаячакларына, баш хәрефләрне кабул итәчәкләренә ныклап ышана идем. Минем эчемдә ут кайный, ләкин аны ничек матбугатка гарыз итәргә генә белми йөри идем.

1910 елда Эстәрлетамакта мәгълүм булгач, Мөхәммәдгариф Рәмиев җәнабларына, мөгаллим рәфикъларыма фикеремне вә әлифбамны гарыз иттем. Алар минем фикеремне кабул итеп, баш хәрефләр белән язылган «Әлифба»мны тизрәк бастыруымны үтенделәр. Мин андагы «Нур» матбагасы мөдиренә баш хәрефләр эшләргә кирәклеген һәрвакыт сөйли йөрдем.

Быел Вәсим Солтанов әфәнде минем фикеремә артык әһәмият биргәнгә күрә, аның белән кушылып, 1911 сәнә июньдә «Шура» 12 нче санындагы мәкаләбез белән ул фикерне мәйданга куярга булдык.

«Шура» 16 нчы санында безнең мәкаләбезгә күп тәкъризлар (мактаулар) язылды. Без ул турыда күп могътәбәр[1] затлардан рәхмәт хатлары да алдык.

Бер эшнең дөньяга чыгар вакыты җитсә, ул турыда уй йөртүчеләр дә күбәя. Шунлыктан бу мәсьәлә турысында да фикер әйтүчеләр күп булырга кирәк. Ләкин мин читтән һич бер фикер вә ярдәм ала алмадым. Мин хәрефләребезне азайтырга тырышкан кешеләрнең күбәюен генә телимен.

Минем өчен тик хәрефләр азайсын да, укучы, басмаханәчеләребезнең өстеннән авырлык төшсен. Мин хәрефләребезнең азайтылуыннан чиксез күп файдалар булачагын сизәм. Мин тик милләтебезнең «чын үз тавышларыбызны бирәр хәреф белән генә» тәрҗемә итүләрен күрәсем килә. Быел уку нияте белән Казанга килгәч, төрле кешеләр – хәрефче вә имлячылар белән киңәшеп, күп тикшергәннең соңында гына «Хәреф вә имлябыз» турысындагы бу китапны мәйданга чыгарырга батырчылык иттем. Озакламый «Әлифба» да басылып чыгар.

*1911 ел. Гыйбадулла Алпаров.*

Искәрмә. Бу китапны язып бетереп басылырга биргәннән соң, моннан 4–5 еллар элек, Матбагаи Кәримиянең мөдире мәрхүм Габделмәннән Рахманкулов дигән бер затның хәрефләребезне азайтырга тырышып йөргәне, шул чакта ук, шул матбагада баш хәрефләрдән генә булган шрифтлар эшләнгәне хакында мәгълүмат алдым. Ләкин ул чакта аңарга игътибар итүче булмаганга күрә, шул көе ятып калган, быел ул мәсьәлә тагын күтәрелгәч, «Бораддәран Кәримевлар» матбагасының идарәсе шул хәрефләрне яңадан эшләтеп чыгарган икән. Бу китап шул хәрефләр белән басылды. Г.А.

[1] Могътәбәр — игътибарлы, хөрмәтле.

# 1 – Әлифба тарихы

Борын заманда адәм балалары үзләренең максудларын бүтән кешеләргә болай, безнең кебек, кәгазьләргә сызгалап аңлата белмәгән. Ул чакта бераз аңлы кешеләр такталарга, ташларга төрле сурәтләр төшереп үзләренең эшләрен, уйларын аңлата алганнар. Мәсәлән, бер гаскәр йортының ишек тактасына, ташка, ат белән китеп барган кеше сурәте, сугышып торган кешеләр сурәте, егылып яткан кеше, ахырда җәрәхәтләнеп кайтып килгән кеше сурәте ясалган булган. Башкалар, шуңа карап, аның «сугышка барып җәрәхәтләнеп кайтканын» аңлый торган булганнар... Соңра ул сурәтне кечкенәрәк вә күп итеп төшереп, озынрак максатларны да аңлата башлаганнар. (Телсез кешеләрнең ишарә белән сөйләшүләре кебек).

Ахырда авыздан чыккан тавышларга да аерым «тамга»лар ясап чыгарганнар. Кеше, үзенең авызыннан чыккан тавышларны алмаштырып, төрле сүзләр чыгарган кебек, шул тамгаларны алмаштырып тезеп, төрле сүзләрне язып аңлата алган. Менә шуннан дөньяга «язу – әлифба» дигән нәрсә килеп чыккан.

Җир йөзендә иң элек язу язган кеше Идрис (галәйһиәссаләм) дип риваять кылалар. Безгә тарих гыйлеме белән беленүенә караганда, ташларга, такталарга төрле сурәтләр, ишарәтләр белән язып максуд аңлату, иң элек Мисыр җирендә башланган булырга кирәк. Аларның язган язулары «иероглиф = Іероглифь» язуы дип аталган.

Иероглиф язуының ишарәтләре бик чубалчык (чуалчык), гаять күп булып, берәр тавышка бер ишарәт йөртелгән кебек, бер сүз хәтта бер эшне аңлату өчен дә бер ишарәт йөртелгән. Аларның ишарәтләре кош, ат, аяк вә пычак кебек шәкелләрдән гыйбарәт булган. Соңга таба ул шәкелләрне азайтып, берәр хәреф итеп кенә калдырганнар.

Хәзерге кебек китаплар язарлык хәрефләр (әлифба), мисыр халкының мәдәниятеннән соңрак, финикия (Кәнган) халкы тарафыннан чыгарылган. Финикия халкы бик үткен-зирәк һәм сәүдәгәр халык булганга, алыш-биреш, хисап эшләрендә максатны ачык аңлатырга, тизрәк язарга кирәклекне сизгәннәр, шунлыктан алар иероглиф язуын ислях итеп авыздан чыккан һәр тавышка берәр хәреф вазыйг иткәннәр... Аларның хәрефләре бары (22) булып, язуны гарәпләр кебек уңнан сулга таба язганнар. Шул иҗатлары сәясендә финикия халкы «Әлифба» иҗат итүче, бөтен дөньяга башлап «язу» өйрәтүче саналалар. Финикиялеләрдән соң күп заманнар үткәч, юнан халкы мәдәният кәсеп иткән. Алар финикия язуын тагын да ансатрак, матуррак шәкелләргә үзгәртеп алганнар. Аларның язуы «юнан хәрефләре» дип мәшһүр булган. Юнанилардан румалилар алып, тагын бераз үзгәрткәннән соң, хәзерге «латин әлифбасы» дип аталган хәрефләр белән язганнар. Румалилар хәрефләрнең санын да бераз кубәйткәннәр.

Руслар элгәре заманда «церковно-славянский» хәрефләре белән язган-




بو یازولار مصرلی احمد افندی نجیب حضرتلرینك «کتاب الاثر الجلیل لقدماء وادی النیل» اسملی کتابندان عینا آلندی .

нар икән; Петр великий падишаһ заманында, латин әлифбасыннан күчереп, хәзерге «рус» хәрефләрен чыгарганнар.

Боларның финикиялеләрдән башкасы бары да сулдан уңга таба яза баруны алда тотканнар[1].

Бу язулар мисырлы Әхмәд әфәнде Нәҗиб хәзрәтләренең «كيتاب الاثر الجليل لقدماء وادى النيل» исемле китабыннан алынды (26 биттәге таблица).

**«Хаты михый»дән бәгъзы хәрефләр**



Икенче яктан финикә язуыннан үзгәртеп, Хиҗаз тарафында булган гарәпләр, «хиҗазия» дип аталган язуны чыгарганнар; шул «хаты хиҗазия»дән «хаты куфи» үзгәртелгән. Гарәпләр финикиялеләрдән алынган 22 хәреф өстенә үз тавышлары өчен тагын 6 хәреф (ث، خ، ذ، ض، ظ، غ) арттырганнар. Финикиялеләр белән бер гасырдарак, Ассирия, Каледония дәүләтләре заманында, шәрыкта «Хаты михый яхуд хаты масмари» диелгән, кадак шәкелендәге язу йөртелгән. Ләкин хәзерге франк вә гарәп хәрефләре аннан алынмаган. Бәлки, иероглиф вә финикия әлифбасыннан үзгәртелгән.

Борынгы төрки-орхон әлифбасы

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ж | ج – |  | дъ | ض – |  | а, ә | آ،ئه – |  |
| иж | يج – | | д | د – | | и | اى – | |
| съ | ص – | | п | ب – | | ү | او – | |
| с | س – | | б | ب – | | ө | ۆ – | |
| ш | ش – | | и | ى – | | къ | ق – | |
| з | ز – | | и | يى – | | къ | ق – | |
| нд | ند – | | ң | ڭ – | | гъ | غ – | |
| нж | نج – | | н | ن – | | к | ك – | |
| лд | لد – | | м | م – | | г | گ – | |
| Кәлимә ахырында | كلمه آخرنده | | р | ر – | | тъ | ط – | |
| | | | л | ل – | | т | ت – | |

Бу хәрефләрне мөхтәрәм مؤرخ шаһир Нәҗип Гасыйм хәзрәтләренең «Иң иске төрк язысы» нам рисаләсеннән алынды.

[1] «Тарих мәдәният» Әхмәд Рафикъ.

Моннан 1300 еллар элек безнең төрек вә татар халкының да үзләренә башка «әлифба» хәрефләре булган. Алар язуны өстән аска таба барып яза торган булганнар.

Халкыбыз моннан мең ел әүвәл мөселман булып, гарәп хәрефләрен кабул иткәч, үз язуыбыз бөтенләй онытылып калган.

Безнең борынгы язуларыбыз ике төрле булган: орхон язуы, уйгур язуы. Монда орхон язуының әлифбасы күрсәтелде. Уйгур язуының әлифбасын да дәрҗ итәргә теләсәм дә, муаффәкъ була алмадым.

## 2 – Гарәп хәрефләре ничек үзгәргән?

Бөтен җир йөзендә булган мөселманнарның телләре, сөйләшүләре төрлечә булса да, язулары барысының да бертөсле: уң яктан башлап сулга таба языла торган «гарәп хәрефләре»дер. Гарәпләр мөселман булгач, көннән-көн мәдәният кәсеп итеп, язу-уку эшләрен дә бик алга җибәргәннәр.

Элегерәк гарәп хәрефләре латин, рус хәрефләре кеби ноктасыз һәм бер-беренә кушылмыйча языла торган булган. Гарәп хәрефләрендәге ноктлар вә башка бәгъзы бер ишарәтләр, امويه (өмәвия) хәлифәләреннән Габделмәлик заманында, Гыйрак вәлисе Хиҗаҗ бине Йосыф әмере белән чыгарылган.

Заман үтә-үтә мөселманнар язу-уку эшләрендә тагын да алгарак киткәннәр. Ул чакта тәбагать һөнәре мәйданга килеп җитмәгәнгә күрә, китапларны, бүтән язуларны барын да кул белән язганнар, әнә шул чакта гарәп хәрефләре бер-беренә кушылып, бер сүз бер тоташтан языла башлаган.

Ул чакта китапларга язу эше бик күп булганга күрә, алар, күп язарга тырышып, шәп язу өчен, каләмне алмыйча хәрефләрне кушып язганнар. Шул сайәдә гарәп хәрефләре кул белән бик шәп язарга да уңайлы булып үзгәргән. Соңрак элекеге «хаты куфи» урынына, «нәсех», «сөлес», «тәгъликъ», «рокга» кеби гүзәл хатлар мәйданга килгән.

Язулар үзгәрмәс борын гарәп хәрефләре хәзерге баш хәрефләр шәкелендә булган. Китапларның язуында (ا) хәрефе ялгыз язылганда (ا) шәкелендә булса да, кушып язганда – ахырда (ـا) шәкеленә кергән.

ﺑ، ﺗ، ﺛ хәрефләре сүз уртасында ﺒ، ﺘ، ﺜ шәкеленә, сүз ахырында, фәкать сузып җибәрүдән ب، ت، ث шәкеленә әйләнгән.

ﺟ، ﺣ، ﺧ хәрефләре уртада, өстән килеп кушылганда, астан кушылганда ـحـ шәкеленә, ахырда фәкать боргалап җибәрүдән ج – ح шәкелләренә кергән. Башка хәрефләрнең үзгәрүе дә шулай ук.

Гарәп хәрефләренең баш, урта, ахыр вә ялгыз дип аталган дүртәр төрле шәкелгә әйләнүе менә шуннан килгән.

Хаты нәсехкә нәмунә:

تەن ئوسدرسەلڭ جهانده، بردەشكسز، فيل بولو ممكن.

اوقوب روحكنى عالى ئەيلەسەلڭ، جبريل بولو ممكن.

استانبول مطبعەلرندەگى حرفلر، عموما، نسخ يازووندان آلونغان.

Хаты сөлесдән нәмунә:




Хаты тәгъликъка мисал:

برادر بزلرنگ سعى علكمه اجتهادا تيومزده سزلرنگ مادى معنوى
جهتدن همتكزا وچون اخلاص قلبدن تشكر ايده من...

Хаты рокгага мисал:

انسانه آكا ديرلركه، ايده قلب رفيقى، آلام بنى نوعيله كسب
ملالت. انسانه كندو خدمتنده كندوسى فائده كورماى در.

Болардан башка хатлар күрсәтелмәде.

Бәгъзы хәрефләрнең төрле шәкелдәгеләре хәтта бер-беренә охшамаслык булып та үзгәргән.

Мәсәлән (ک) хәрефе, ک - ک - گ - ك шәкелләренә,

(ه) хәрефе, ه - الله - ـهـ - ـه – шәкелләренә кергән.

(ل) хәрефе, (ا) белән кушылганда لا - لا шәкелләренә кергән.

(ي) хәрефе ахырда бөтенләй үзгәреп – ى шәкеленә кереп калган.

Бәгъзы хәрефләр икенче хәрефләргә кушылып язылуына карап, дүрттән артыграк шәкелләргә дә үзгәргән: لم، کلا، کا، لـ، مح، مخ، مجـ، مـ кебек.

## 3 – Тәбагать (басмаханә) мәйданга килгәндә

Гасырлар үтеп, әдам балалары көннән-көн һөнәрләрен арттырып, чын мәдәният юлына аяк баскач, язу кебек иң мөкаддәс вә кирәкле бер эшне тагын да җиңеләйттеләр: германияле «Жан Гутенберг» нам бер зат, дөньяда беренче мәртәбә буларак, «тәбагать» һөнәрен мәйданга куйды.

Бу зат Германиянең «Маянс» шәһәрендә 1450 нче сәнә миладиядә иң элек матбага ачып, латин хәрефе белән Инҗил шәриф табыгъ итте.

Шул чактан башлап, басу (китап басу) эше күп әтрафка таралып, бөтен җир йөзендә булган мәдәни халыклар китапларны кул белән язу мәшәкатеннән котылган. Чөнки матбагаларда, машинага тезгән хәрефләр белән басып, бик әз вакыт эчендә әллә ни чаклы күп китапларны өлгертеп чыгарганнар. Шуннан соң китаплар күбәеп, арзанаеп халык арасына гыйлем вә мәгариф таралганнан-тарала барган...

Басмаханә мәйданга килгәндә, Жан Гутенберг җәнаблары латин хәрефләре өчен һәр тавышка берәр генә хәреф кискән; ул чакта латин хәрефләре дә гарәп хәрефләре кебек кушылып, төрлечә язылa торган булса да, ул матбага хәрефләрен кул язмасына охшатып ясамаган. Иске латин кульязмасы белән иң элек басылган инҗил сәхифәсен тикшереп караганда, моны бик ачык аңларга була. Аннан соң эшләнгән хәрефләр дә шул юл белән бара биргән...

Элегерәк басу өчен йөртелгән хәрефләр бигүк ачык вә матур булмаса да, бара-бара ислях итеп хәзерге дәрәҗәгәчә тәраккый иткән.

Матбагалар күбәя башлагач, гарәп хәрефләре белән дә китаплар басарга хаҗәт төште; 1510 нчы сәнәи миладиядә Италия мәмләкәтендә беренче мәртәбә гарәп хәрефләре белән китап басылды.

Истамбулда исә 1730 сәнәдә, Русиядә 1787 сәнәдә башлап гарәп хәрефләре белән китаплар басылган[1].

Гарәп хәрефләренә беренче мәртәбә башлап клише кискәндә, матбагачылар һәр хәрефне берәр шәкелдә генә алмыйча бик зур хаталык иткәннәр. Югарыда әйтелгәнчә, шәп язу өчен генә баш, урта, ахыр, ялгыз вә башка шәкелләргә үзгәртелгән бер гарәп хәрефен асыл булган бер шәкелдә генә ясап алмыйча, шул чактагы кульязмадан күчереп, дүрт-биш төрле шәкелдә итеп алганнар. Шул чакта, гарәп хәрефләре дә асылда бер генә шәкелдә булырга тиешле икәнен уйлап та карамаганнар. Хәтта басылган китаплар, тәмам кульязмага охшап чыксын өчен, Истамбул матбагаларында бергә кушылган ике, хәтта өч хәреф өчен дә аерым берәр шрифт ясаганнар.

Мәсәлән:  вә башкалар кебек[1].

---

1 «Матбагачылык тарихы» исемле китапка карагыз!

2 عثما نليچه "صنعت طباعت ياخود مر تبلك" نام رسله يه باقگز!

Шуның өчен дә матбагалардагы гарәп хәрефләренең саны, бар шәкелләре белән бергә, ике йөз, хәтта өч йөзгә җитеп, шул хаталык хәзергәчә төзәтелмичә дәвам иткән.

Хәрефләребезнең бу сурәттә күбәйтелеп йөртелүеннән нинди авырлык вә нинди зарарлар килгәнен кыска гына булса да әйтеп китим әле.

## 4 – Хәреф күплекнең уку эшенә тәэсире

Ун-унбиш еллар элек, ысулы җәдидә мәйдан алмас борын, безнең халык арасында, балаларны укырга өйрәтү гаять тә авыр вә кыен иде: иң элек балаларга хәрефләрнең исемен белдерәләр, соңра туп-туры китапка төшерәләр иде. Шунлыктан балалар берничә ел буена, үзлекләреннән, хәрефләрне танып китап укый алмый, өйрәтүчегә генә ияреп йөриләр иде. Бу ысулның начарлыгы хакында сөйләп торырга да ярамый инде.

Ысулы җәдидә мәйдан алгач кына, без бу авырлыктан котылдык. Шул чакта гына балалар хәрефләрне үзләре танып укый ала башладылар.

Хәзергәчә безнең халык арасында, балаларга хәрефләрне танытып укыту өчен, ике ысул тотылды: ысулы саутия, ысулы мәддия. Бездә ысулы саутия белән укытканда, балаларга бер тавышта дүртәр төрле хәреф күрсәтелде. Ягъни бер (ﺑ) хәрефен баш (ﺑ), урта (ﺒ), ахыр (ﺐ), ялгыз (ب) дип, дүрт-бишкә арттырып өйрәтелде. Язганда да шулай ук бер хәрефне дүрт, биш төрле иттереп язылa иде. Бу төрле укытуның да авырлыгыннан зарланмаган мөгаллимнәр юктыр дип уйлыйм.

Шунлыктан, ысулы саутия, гәрчә башка милләт арасында иң мәкъбүл ысул булса да[1], хәрефләребезнең күплеге сәбәпле, безнең халкыбызга авыр йөк булудан артмады.

Холясә, бу ысул, иҗек ысулына караганда ничә мәртәбә яхшы булса да, һаман да тиешле дәрәҗәсеннән авыр итеп йөртелде.

Ихтимал, халкыбызның ысулы җәдидәдән бизүенә, хәрефләребезнең күбәйтелеп йөртелүе дә сәбәп булгандыр.

Ысулы мәддия исә, безнең халык арасында ысулы саутиягә караганда мәкъбүлрәк булып чыкты. Чөнки ысулы мәддия белән укытканда, балаларга бер урында ук дүртәр төрле хәреф күрсәтелми, бәлки имля (мәд) хәрефләренә кушылып, башка җирләрдә күрсәтелә. Шуңа күрә ул, балаларга хәтергә алу өчен, җиңелрәк була. Ләкин ул ысулның да педагогиягә муафикъ булмаган җирен аңлаган кешеләр бар. Андый әлифбалар белән баштарак хәреф тану җиңел булса да, соңга табарак чуалып калырга, яки яңадан хәрефләрнең тавышы белән башлап укытырга туры килә...

Бу ысулдан да асыл максат хәрефләрнең күп төрле шәкелдә күрсәтелүеннән качу икәнен бик тиз аңларга мөмкин.

[1] «Әлифба китапларына тәнкыйть» мәрхүм Гайнетдин Әхмәровныкы.

Шуның өчен без бу гарәп хәрефләрен һәр тавышка берәр генә шәкел итеп калдырырга тиешле. Юкса, без яңадан әллә ничә төрле ысул чыгарсак та, авырлыктан котыла алмабыз.

Бөтен дөньяда хәрефләр таныту өчен иң ансат ысул «ысулы саутия» булганга күрә, хәрефләребез берәргә генә калса, халкыбыз арасында тагын да ысулы саутия белән укыту мәйдан алачак. Чөнки бер тавышка дүртәр хәреф күрсәтеп укытыла торган ысулы саутия, ысулы мәддиядән авыррак булса да, чын ысулы саутия, бер тавышка берәр хәреф кенә күрсәтелсә, бөтен ысулылардан да яхшы вә җиңел булачагы билгеле.

Без ике кыш, балаларга берәр баш хәрефне күрсәтеп кенә укырга һәм язарга өйрәтеп карадык: балалар анарга бик тиз төшенә, берәр баш хәрефләрне генә кушып язудан хәзерге кеби гүзәл язу чыга.

Хәрефләребез берәргә генә калдырылса, балаларга ике-өч айда белдерә торган нәрсәләрне бер айда белдереп, калган вакытларда башка файдалы гыйлемнәр өйрәтергә мөмкин булыр иде. Аларның газиз гомерләре әллә ничә катлаулы хәрефләр белән саташып үтмәс иде.

Мөгаллим әфәнделәр! Моңа яхшы дикъкать итегез!

## 5 – Матбагаларда хәреф күплеге

Безнең мөселман басмаханәләрендә йөртелгән бер төрле генә хәрефләрнең саны өч йөзгә җитә. Гәрчә бөтен хәрефләр кырыклаптан артмаска тиеш булса да, хәрефләрнең күбесе дүрт төрле йөртелгәнгә күрә, басмаханәләрдәге хәрефләр дә шул чикле күбәеп киткән. Шуңа күрә басмаханә хуҗасына хәрефләр бик кыйммәткә төшә. Өч мең расход тота. Әгәр дә хәрефләр берәр генә булса, ул артык акчасын төрле матур хәрефләр алырга, матбагасын зурайтырга сарыф итәр иде...

Башка милләтләрнең хәрефе белән басылган кечкенә бер игъланда да уннан да артык төрле, берсе-берсеннән матур хәрефләр була.

Бездә иң күп булганда, бөтен матбагадагы хәрефләрнең нәүгысы 5–10 нан артмый. Бездә бер хәреф урынына 4–5 төрле хәреф йөртелгәнгә күрә, төрле матур хәрефләрнең урынын шул бер төрле күп хәрефләр тутыра. Русларда исә бертөрле хәрефләрнең саны аз булганга, төрле-төрле хәрефләргә урын күп кала. Гарәп хәрефләреннән бер төрлеләрен генә алган акчага, русчадан 3–4 төрле җитәрлек хәреф алырга була. Безнең хәрефләребез дә шулай берәргә генә калса, төрле шәкелдә төрле зурлыктагы хәрефләребез күбәеп, мөселманнарда да сәнгати тәбагать сәнаигы нәфисә җөмләсенә тезелер иде.

Матбагаларыбызда хәреф кассалары күплектән, хәреф җыю өчен кирәгеннән артык күп вакыт сарыф ителә. Чөнки бездә бер тавыштагы

хәрефне җыяр өчен дүрт якка кул сузарга, кассаның бер башыннан икенче башына бер туктамый йөгереп торырга туры килә. Әгәр дә хәрефләребез азайса, хәреф җыючыларга күп җиңеллек булыр, заказларның аз гына вакыт эчендә, аз расход белән өлгереп чыгуына сәбәп булыр иде.

Инде үзегез уйлап карагыз: басмаханә өчен җитәрлек хәрефләр, башкаларга караганда 3–4 мәртәбә артык кыйммәт булса, заказларның әзерләнеп чыгуына күп вакыт сарыф ителсә, шул расходларны өстенә күтәреп басылып чыккан китапның хакы ничек булырга кирәк? Әлбәттә, башкаларның китапларына караганда 3–4 өлеш кыйммәт булачагы билгеле.

Үткән ел «Вакыт» гәзитәсендә берәү: «Асылган җиде кешеләр» китабының русчасы 10 тиен булган хәлдә, татарчасы 35 тиен... Нигә бездә болай китаплар кыйммәт?..» дип язган иде. Ул чакта «Вакыт» гәзитәсе аңарга: «Бездә наборщиклар русларга караганда кыйммәт хак алалар; бездә китаплар аз басыла... Шунлыктан кыйммәт төшә...» дип җавап биргән иде.

Ләкин, боларның барсына да хәреф күплеге сәбәп була! дип җавап биргәндә ялгыш булмаса кирәк. Басмаханәләребездә хәрефләр азаеп, хәреф төзүчеләргә эш ансатлашса, китап та матур басылган булса, аның хакы да арзан булыр, алучы да күбәер иде.

Басмаханәләрдә хәрефләр азайса, яңа иҗат ителгән «хәреф тезү» машинасының истигъмале мөмкин булып, матбугат вә заказларның тагын да тизрәк өлгерүенә сәбәп булачак.

Тагын болардан башка, «язу машинасы» дигән нәрсә бар. Зур фирмалар, докторлар, идарә вә канторалар берәр җиргә хат яки башка нәрсә язсалар, һәр вакыт «язу машинасы» белән язып җибәрәләр. Чөнки анда язу ачык, чиста чыкканга күрә, танырга ансат, халык яратып укый, укып бетермичә туктамый.

Русларда бу машина бик күп йөртелә. Аның 40 сумлыклары да бар. Игъланнарда 15, хәтта 7 сумлыклары да күренә.

Бу көнгә чаклы, безнең гарәп хәрефләре өчен ясалган машиналар булса да, гаять кыйммәт булган, яхшы матур булып чыкмаган. Чөнки безнең язуларны язар өчен аз булганда 150 хәреф кирәк булган; аны өйрәнү-басу да яхшы ук кыен булган.

Азайтылган хәрефләрнең шул «язу машинасы»нда истигъмале бик мөмкин булып, бездә дә аларның хакы арзанаеп күп файдалануыбызга сәбәп булыр; өйрәнергә дә җиңел булыр, матур да чыгар иде.

Һәр тавышка берәр генә хәреф ясалганда, балаларның хәреф тануларын, зиһеннәрен арттырырга сәбәп булган «кесә матбагасе»да эшләтергә мөмкин булыр иде. Башка милләтләрдә моңарга бик игътибар итәләр. Кесә матбагасенең русларда бер сум, хәтта 25 тиенлекләре дә бар.

## 6 – Тавыш вә хәреф

Язу – ерактагы кешеләргә махсус ишарәтләр белән сөйләү булганга күрә, аның ишарәтләре дә сүздәге тавышларга муафикъ булырга тиешле. «Фонетика»ның иң баш кагыйдәсе буенча: **«Бер тел белән сөйләшкәндә, ни чикле (вә нинди) тавыш булса, аның язуында да шул чикле (вә шундый) хәреф булырга кирәк».**

Монда бу кагыйдә, бөтен телләрнең әлифбасы өчен иң зур, иң кирәкле бер кагыйдә булса да, безнең хәзерге әлифбабызда бу кагыйдә һич тә ригая ителмәгән, чөнки бездә бәгъзән бер тавышка әллә ничә хәреф йөри; яки бер хәреф әллә ничә тавышны күрсәтә.

Безнең борынгы саф үзебезнең әлифбабыз «фонетика» кагыйдәсенә, ихтимал, муафикъ булгандыр. Ләкин без аны ташлап, чит бер милләтнең (гарәпләрнең) үз тавышларына муафикъ ясалган әлифбасын, үзебезгә күчереп алганбыз; шунлыктан аларда, безнең тавышыбызга туры килгән хәрефләрнең булмаячагы билгеле.

Гарәп әлифбасында безгә кирәкмәгән артык хәрефләр менә шулар: ث, ح, ذ, ض, ظ, ع (татарча сүзне бу хәрефләр белән язарга бер дә ярамый).

خ – тавышы да элек безнең телдә булмаган. Бу көндә *хатын, охшый, хан, яхшы* кеби берничә сүзләрдә генә йөртелә. (Боларда, асылда ق хәрефе булган).

ف – бу тавыш та безнең телдә юк. *Яфрак, туфрак* кебек сүзләр урынына *япрак, тупрак* язарга кирәк.

ه – хәрефе дә элек бездә булмаган; читтән кергән, *һәр, һаман, һич* кебек сүзләрдә йөри.

ط، ص – хәрефләре дә артык. Алар урынына ت، س йөртергә тиеш. (Алда сөйләячәгебез буенча, ахырларына калын тавыш хәрефләре куйгач, алар да калын укылалар).

Гарәп хәрефләрендә безнең тавышыбызга кирәкле булган ڭ، گ، چ، پ хәрефләре юк. Аның өстенә телебездәге ун тавыш (имля-мәд) хәрефләренә бары өч-дүрт хәреф йөри. Шунлыктан, без татарча сүзләрне дөрес язуда бик мөшкеллек чигәбез.

Бездә бер (ا) тавышына (ا-ا) хәрефләре, (ە) тавышына да шулай ук (ا) хәрефе йөртелә, бәгъзән (ه) тавышына (ا) хәрефе, яки киресенчә языла. Шуның өчен яңа укырга өйрәнеп килгән балалар, боларны кайсы тавышка йөртергә аптырап кала. (Мәсәлән: اتكايم انكايم – يولده اولان اوسكان – اتچ – پار – امچ – اول اشكه باره ... آلار اشكه بارالار кеби сүзләрдә).

Бер (و) хәрефе дүрт-биш тавышка йөри. (Мәсәлән: ياخشى كشى – يازدى – كيلدى، گل اوسه – سوز سويلى – قول توتارغا – خداى قولى – بارمو؟ هو اغه اوچدى – اوچ تيين – اوچلاب آلدى – اوچ آلدى – نو – ... кебек сүзләрдә).

Бер (ي) хәрефе әллә ничә тавышка йөри. (Мәсәлән: ياخشى كشى – يازدى – كيلدى، كيلديلر، بارديلر، باردگى؟ يازيلغان – بير – اوق – كوزگى – يازغى... кебек сүзләрдә.) Боларның берсендә дә язуга карап әйткәндә, сөйләшкәндәгечә булып чыкмый.

Димәк, безнең язуыбыз чын үз тавышыбызны тәрҗемә итми. Бер төрле хәрефнең 3–4 тавышка йөрүе, өйрәнгән олуглар өчен кыен булмас та, балалар өчен ул бик зур авырлык була. Шуның өчен дә фән, һәр тавышның үзенә махсус хәрефе булуын тели. **Болай үз тавышыбызга хәрефләр куймыйча йөртсәк, милли телебезнең тиздән мөнкариз (юкка чыгу) булуы да ихтимал.**

Шуның өчен безгә әлифбабызны тәмам үз тавышыбызга муафикъ итеп ислях итәргә бик тиешле. Аның өчен безгә кулыбыздагы гарәп хәрефләрен генә ислях итәргә кирәк. Бүген тотынып кына, яңадан үзебезгә башка, хәрефләр чыгару бер дә мөмкин түгел... Рус яки латин хәрефләрен алганда да, барыбер, аларның хәрефләре безнең тавышка килми. Безгә кирәкмәгән яки җитмәгән хәрефләр аларда да бик күп. Аларның хәрефе безгә бөтенләй ят булуы өстенә, тагын артык галәмәтләр дә кушсак, әлифбабыз бөтенләй эштән чыгар... гарәп хәрефләренең исә, кыскалыгы, язарга укырга уңайлыгы да башкалардан күп дәрәҗә артык. Холяса, кулымызда булган китаплар истигъмальдән төшмәсен, элеккечә укый яза белгәннәр, хәзергечә дә укый яза белсен дисәк, безгә шул кулыбыздагы гарәп хәрефләрен үз тавышыбызга (тәгълим вә табгы эшендә дә) муафикъ итеп ислях итәргә генә кирәк.

## 7 – Әлифбабызны ничек төзәтергә

Хәрефләрнең шәкелләре хакында сүз башлаудан элек, телебездә йөртелгән тавыш (мәд) хәрефләре турысында бераз әйтеп китим әле. Фонетика кагыйдәсе буенча, тавышлы *Согласн.* хәрефләрнең калыны, нечкәсе өчен бер генә хәреф булырга тиеш. Әмма тавыш хәрефләре *Гласн.*ның нечкәсенә һәм калынына аерым хәрефләр булырга кирәк.

**«Тавыш хәрефләре»**, һәр телдә, асыл өч хәреф (ى - ا - و) тән туып чыгалар. Безнең телебездә төгәл ун тавыш хәрефе булып, аларның бишесе калын, бишесе нечкә укыла. Госманлы انجمن (инҗәмән) мәгарифе тарафыннан телебездә ун тавыш хәрефе барлыгы тасдыйк ителгән. Бездә иң элек Каюм Насыйри җәнаблары бу турыда каләм тоткан.

**Калын тавышлар менә шулар:**

**Беренче, (ٵ) хәрефе.** Безнең бу хәреф русларның (а) белән (о) хәрефләре арасында ишетелә. Безнең элекке (ا) хәрефе (ئـ) белән (ٵ) дән җыелганга күрә, һәм (ا) хәрефе бер шәкелдә генә йөрсен өчен аны (ئا) шәкелендә язып өйрәтү бик мөнасиб[1]. Сүз башында тавыш хәрефләренең алдыннан бездә һәр вакыт (ئـ) хәрефе языла.

**2 – калын (و) хәрефе.** Русларның (у) хәрефе белән бер тавышта. Өстенә бер галәмәт тә куелмаса, саф шул тавышта чыгарга тиеш.

[1] Бу шәкел матбагалар өчен һәм балаларга тавыш аерту өчен дә файдалы.




(ئول ، ئوچ، يوق، سوق، توڭ،
قولڭ-سوز ... كبك سوزلەردە.)

(*ул, уч, юк; сук, туң*
*кулың суз* кебек сүзләрдә)

3 – **калын (ى) хәрефе.** Бу тавышны русларның (ый) хәрефләре белән тәрҗемә итәргә мөмкин. Бу калын (ى)не нечкә (ي)дән аеру өчен, (ـٍ) шәкелендә алу муафыйк күренә. (ئوقىـ - بارمىـ - سىغان - ئىجاق - تابزى - سىعلا - تابىـ - باسىق - سالىق - سىبر - مىبق - قارىـ بارىـق - سا :ىم - جىما ... кебек сүзләрдә).

4 – бу өч хәрефтән башка, бездә (ا) белән (و) арасында ишетелгән, русларның (о) хәрефенә якынрак бер тавыш бар. Шуның өчен аны (ۉ) шәкелендә алу бик мәгъкуль. Бу тавыш фарсыйда (او) язылa (خواجه – دسترخوان). Башлап Каюм Насыйри (ۉ) шәкелендә алган (انموذج) ... (قلم نۉچن، ناش تۉزى، تۉر، قۉر، يۉلدۉز، قۉندۉز، قۉل، قۉش نۉچدى... кебек сүзләрдә).

5 – тагын (ـٍ) белән (و) арасында ишетелгән бер тавыш бар[1]; русларның (ы) хәрефен йомшаграк әйткәндә аларга туры килә. Бу тавышка (ۊ) хәрефен алу мәгъкуль. Бер яктан караганда, язарга, укырга да уңайлы, табигый хәреф. ( نوروم = قوروب نورغوتدم – نالوب قوى – مولتوق – توروش توغانوم – قونا گول – توش جولو – قوزوق – قول – بولوى – قوموز قورغوزدا – ياخشو - نوقو ياز... ... кебек сүзләр).

Нечкә тавыш хәрефләре исә шул ук биш калын хәрефнең нечкә әйтелүеннән хасыйль булалар.

6 – (ا)нең нечкәсе (ە).




٦ – (ا) نڭ نچكەسى (ە)· عربى
فتحەگە تورى كيلە· (ئەلى - بەيرەم -
كەجە - نەرسە - پەرەمەچ - ئەمەل - ئشلە-
سەلمەك... كبك سوزلەردە.)

Гарәби фәтхәгә туры килә.
(*Әле, бәйрәм, кәҗә, нәрсә, пәрәмәч, әмәл,*
*эшлә, сәлмәк* кебек сүзләрдә)

7 – **(و)ның нечкәсе (ۆ).** Русларның (ю) хәрефен йомшаграк әйткәндә бу тавышка туры килә. Өстенә нокта төртелгән (ۆ) белән шул тавышта йөртелергә тиеш. (سۆز - كۆل - تۆز - كۆردم - ئۆچ - ئۆز - بۆلمە - جۆكە - سۆندك كۆك - كۆز - كۆب ... кебек сүзләрдә).

8 – **(ـٍ) хәрефенең нечкәсе (ي = и).** Аска батырып әйтелгән нечкә сүзләрдә генә йөртелә. (- بير – نه بز سه بز سوُ يلز نيكه ن – كيم – مين – شين – تيمه – نير – جير – بيلز نيت ... кебек сүзләрдә).

9 – (ە) белән (ۆ) арасында, ягъни (و)нең нечкәсе (ۉ) хәрефе. Авызны

[1] (ا) белән (ى) арасында ишетелгән хәреф бездә юк. (Русларда бар ѣ – э – е) хәрефләре. Академик Я.К. Гротның «Русское правописание»сенә карагыз).

очлайтып өтер белән әйтелә. Бу хәреф бездә күптән йөртелә. Фәкать аны урынына истигъмаль итәргә генә кирәк. (– كوُلمه – نوُچ – كوُچلى – بوُرمه – سوُزمه – كوُز قوُنى – يوُزوُم كوُزگوُ بوُركوُت – بوُتوُن ... кебек сүзләрдә).

10 – (يِ) белән (وٖ) арасында, (و) аның нечкәсе (ـٗ) хәрефе. Бу хәреф өтер белән укылмый. Нечкә хәрефнең калькаланеп әйтелгән урынында гына була (– تـُنش – ثوُلـُم – بوُلـُم – كـَنـدُ – كـِلـدُ – كـُرگـُز – پهكـُز – ثهلـُز – كـُنـُر – بـُلـُم – كـُثـُز ... تـِلـدُ – جـُنـلـُز – تـُرنـُاه кебек сүзләрдә). Язарга уңай булсын өчен бу хәрефнең өтерен калдырып йөртергә дә ярый. (Бу 10 нче һәм 5 нче хәрефләрнең языла торган урыннары хакында киләсе фасылда да язылды)[1].

Әлегә тикле бу хәрефләр бездә ی - و сурәтләрендә йөртелә иде. Бу өйрәнгән кешеләр өчен авыр булмаса да, балаларга һәм безнең телебезне белергә теләгән чит милләт кешеләренә бик зур мәшәкатьләргә сәбәп була.

Менә шул хәрефләрне үз тавышлары турысына, тиешле урынына куеп язганда гына, безнең язуыбызга карап телебезгә төшенергә мөмкин булыр. Шул чакта гына язуыбыз телебезнең тәрҗемәне булыр.

Сәкенле (يِ) һәм (وٖ)хәрефләре, мәд хәрефләре булган (يِ, وٖ) белән бер тавыштарак булганга күрә, җиңеллек өчен, аларның үзләренә башка – аерым хәреф йөртмәскә дә ярый. Аларны әйтелгәнчә укырга була.

(يِ) белән башланган сүзләрне сөйләнгәнчә (جِ) белән язарга мөмкин. Бигрәк ике (يِ) җыелып килгәндә.

Мәсәлән: - ناي - باي - تاي - ناو - باو - تاو - ناوز – تاوق - (моны төрекләр تااوق дип язалар) نه په ي - كيلمه و – بارماو – بيله و – جير – جيله ك – جيگرمي – جه – جيته ر... кебек сүзләрдә.

Тавыш хәрефләренең нечкә һәм калыннарына аерым хәрефләр булганда бары 5 кенә хәреф арта. Әмма тавышлы хәрефләрне икешәр төрле йөрткәндә яңадан 23 хәреф кирәк була.

Холясә, басма вә язма өчен, бу берәр, баш (асыл) хәрефләрне генә алырга бурычлыбыз:



[1] Бу тавыш хәрефләре хакында тагын да озынрак мәгълүмат алырга теләгән кеше, Гыймәд әфәнде Нугайбәк җәнабларының «Башлангыч», «Үрнәкләр» дигән әсәрләрен карасын.

Болардан башка, русча сүзләр өчен ۋ - ٯ хәрефләрен дә истигъмаль итү мәгъкуль күренә.

Шул хәлдә безгә, уку һәм язу өчен тәмам муафыйк булган, «**кырык өч**» хәреф җитәчәк.

## 8 – Имля кагыйдәләре

Югарыда сөйләгәнебезчә, кирәкле тавышларыбызга аерым хәрефләр арттырылгач, татарча имля мәсьәләсе тәмам ансат хәл ителәдер. Чөнки ул чакта, сарыф кагыйдәсе буенча тиешле булган бер-ике истиснадан (искәрмә, чыгарма) башка, безнең бөтен сүзләребез, **ничек ишетелсә шулай** язылырга кала. Сарыф кагыйдәсе буенча:

**1 – сәкенле ک، ق، ش، س، چ، ت، پ، ب хәрефләре сөкүндә (ت) тавышы ишетелсә дә (د) хәрефе язарга кирәк.** (كيتتك، قاچتم، كيستك، شاشتق، يوقتر، تاشتان، نيشتله؛ كوبده ن، كيتدك، قاچدم، كيسدك، شاشدق، يوقدر، تاشدان، كوكده، ياقداش، نيبده ش يازيلا كوبته كوكته، ياقتاش، نيپته ش...)

**2 – сәкенле ڭ، ن، م хәрефләреннән соң, (ا) белән башланган иярчennәр һәм ( دان – ده ن ) иярчennәре (ن) белән ишетелсәләр дә (دل) белән язылырга тиеш.**

«قۇمنق، چبننک، جیڭننک ، ـ ئیگننه ر، قازاننار، ـ توننه ،
جۇننڭ، میڭننڭ ، جهمنڭ، ـ طڭنا، دیمنه، ـ بۇتۇننه ی، ئاڭنای ، ـ
ئوڭناب، ئیمنهب ، ـ طڭنلش ، ئاڭنهانا، ـ جانناندی، جه منهندی، ـ
تیڭنهو ، جامانناو ، ـ ئالامناباسا، کیلدمناسا ، ـ قازاننان ،
میننه ن...» ئورننا، «قۇملق، چبنلک، جیڭلک، ـ ئیگنلهر، قازانلار ،
تونلو ، جۇنلڭ ، میڭلڭ ، جهملڭ ، ـ توڭلا ، دیمله ، ـ بۇتۇنله ی ،
ئاڭلای ، ـ ئوڭلاب ، ئیمله ب ، ـ توڭلاش ، ئاڭلانا ، ـ جانلاندو ،
جهملهندڭ ، ـ تیڭلهو ، جامانلاو ، ـ ئالاملاباسا ، کیلدملاسا ، ـ
قازاندان، میندهن...»

язылырга кирәк. “ تۆنله (تۆنده)، نالدندا ” сүзләре дә шулай языла.

(Укыганда боларны, ишетелгәнчә – (ت), (ن) белән – укырга кирәк). Бу ике истиснадан (искәрмә, чыгарма) башка, безнең сүзләребез һәрвакыт, ничек ишетелсә, шулай язылырга тиеш. Фән теле ишетелгән хәрефнең һич тә калмыйча язылуын, ишетелгән хәрефне калдыру, яки берсе урынына икенчесен язу фәнгә хилаф була.

Инде элекке

« اشـ ، اوزم – پـارامچ، یـولده ، آنـدنـ بـونـدنـ ،
بـازارغه،، آزغـنه، اوتـنـدم ، اوطـنـ، آغز، طاغ ، آنلر، طاشلر ، ایـرلـر ،
طرشـ، اوقو! آلـوبـ ، یـخشی ، کـشی، آطه ، بـازغه ، آطقه ، کـیلـگـانـ ،
اوزگـاردی...» урыннарына,

«ئشـ، ئۆزم، پەرەمەچ ، یـولـدا ، ئـاندانـ،
مۆنـدانـ ، بـازارغا ، ئـازغـنـا ، ئۆتـنـدم ، ئـوتـونـ ، ئـاوز ، تـاو ، ئـالار ،
تـاشلار، ئـیرلەر ، تـوروشـ، ئـوقـو ، ئـالـوبـ ، یاخشو ، کـشـۆ ، ئـوتـراو ،
بـازغا ، ئـاتقـا ، کـیلـگەنـ ، ئۆزگەردۆ ...» язарга кирәк

---

Искәрмә: бу сүзләр «دۆرۆس، ئاس ، ئۆس ، ئیـۆ ، ئیك ، ئیگز ، ئیم ، ئیك» ишетелсәләр дә «دۆرۆست، ئاست، ئۆست (دیب (ت) بەلەن) ، ئیدۆ ، ئیدك ، ئیدۆگز، ئیدم، ئیدك (دیب (د) بەلەن)» язылалар.

Бу үзгәреш шул берничә сүзләрдә генә булганга күрә, аларга аерым кагыйдә куелмады.

**«Бер телдә ике имля булмаска тиеш»** булганга күрә, үз имлябыз төзәтелгәннән соң, телебездә йөртелә торган гарәби, фарси сүзләрне дә **«татар имлясы»** белән язарга тиешле.

Шулай булгач безгә, элекке «بلکه، حتی، هم، هر، قلم، کتاب،سبق، ساعت، هفته، افندی، کاغد» урынына, күптән, « یاکی، حه تته، هه م، هه ر، قه له م، کیتاب، ساباق، سه عه ت، هه فته، عا ر ف...» урынына, күптән, «ئه فه ندێ، که غه ز، عاریف. یاکی،» дип язарга ярый.

Башка телдәге кебек бездә дә сүзләр **«төп сүз», «иярчен сүз»**ләрдән җыелып ясала. Бездә ялгыз бер нәрсәнең исеме, мәсәлән, کشی، مال، نوسته ل، قۆش، тавыш... фигыльләрнең әмер сыйгасы, мәсәлән, بار، کیل، چق، سوق، یاز... «төп сүз» булалар. Икенче сүзгә кушылып кына йөри торган сүзләр, мәсәлән: لق، نگ، غنا، م، دم، دك، دگ، گز، ش... در، دان، لار، кебекләр «иярчен» булалар.

Бездә иярченнәр, төп сүзләрне һич үзгәртмичә, ахырга тоташып йөриләр.

Безнең татар телендә бер сүзнең, бөтен иярченнәре белән бергә, бар хәрефләре дә **я калын гына, я нечкә генә була**. Бездә бер сүз эчендә, калын һәм нечкә хәрефләр җыелып килми. Бер сүзнең калын яки нечкә укылуына, ул сүзнең башында (яки икенче хәрефендә) килгән бер калын яки нечкә хәреф кенә сәбәп була.

Без татар сүзләренең бу хасыяте белән азрак файдалану өчен, ٔ (ы) – ـٔ (э-е) хәрефләре хакында түбәнге ике кагыйдәне генә хәтердә тотарга кушабыз:

**1 – калын ٔ (ы) хәрефе иярчен сүзләрнең уртасында гына язылмый.**

**2 – нечкә ـٔ (э–е) хәрефе, иярчен сүзләрнең дә, төп сүзләрнең дә уртасында язылмый.**

Димәк, калын (ы) хәрефе, иярчен сүзләрдән һәр ишетелгән урында языла: төп сүзнең уртасында, ахырында, төп сүз белән иярчен кушылган җирдә, ике иярчен арасында. Нечкә (э–е) хәрефе сүз ахырында, төп сүз белән иярчен кушылган җирдә ишетелсә генә языла. Иярчен сүзләрнең уртасында боларның берсе дә язылмый, чөнки иярчен сүзләр, калынлык-нечкәлектә, төп сүзләргә ияреп йөриләр. Бер иҗек (слог) эчендә тавыш хәрефләренең берсе дә булмаса, анда (э) хәрефе укыла.

## ئۆرنەك.

مينئم ئوقورغا كيلگەنئمە كۆبدەن بر ئاي تولوب ئوزغان بولسادا، هامان ساباق باشلانماغانغا كۆرە، ئيبدەشلەرئم بلەن مين، كۆن تۆن ئويينابقنا واقتنو ئوزدرا ئيدك. كۆندە بر بازارغا چوغوب، تاناو ئۆچلاروبزنو قوزارتوب - ئۆشۆب كرەبز؛ كۆبرەك واقتوبزنو، ئۆي ئارتوندا، قاردان پيچلەر ياساب، بۆز توگدروب، شووب ئويناب ئۆتكەرەبز.

بزگە، ئەللە نيشلەب، خەلفەدە بردە ئاچولانمي، ئۆرشمي، «ئەي بالالار! كوب شايارماغز، كرئگز ئۆيگە! ئۆشۆب بتكەنسزلاباسا...» ديەدە قويا ئيدئ. خەلفە - ياخشو كشئ شول ئول...

شولاي ئيتئب عيدكە چيكلئ بر ئاينو، ساباق ئوقومىچا، بوشقا ئوزدردق. ئەتكەي، مينئ قوناققا ئالوب قايتورغا ديب، كيلئبدە جيتدئ.

— ئولوم! ساباقنو بيك شەب ئوقودڭمو؟ قايدا چيكلئ ئوقودوغز نە حونئ؟ دي، ئەتي سۆرى... مين ئانارغا نيچك ديب جاواب بيرئرگەدە بلميچە ئابتوراب قالدم: مۆندا چيكلئ ئوقودق ديسەم، توگلاتوب قارار ديب قورقام؛ بردە ئوقومادق ديسەم، خەلفەنڭ عەيبئ چوغا.....

١٩٠٦ نچو جول - نۆيابردە.

## Өйрәндек

Минем укырга килгәнемә күптән бер ай тулып узган булса да, һаман сабак башланмаганга күрә, иптәшләрем белән мин, көн-төн уйнап кына вакытны уздыра идек. Көн дә бер базарга чыгып, танау очларыбызны кызартып – эчеп керәбез; күбрәк вакытыбызны, өй артында пичләр ясап, боз туңдырып, шуып уйнап үткәрәбез.

Безгә, аллә нишләп, хәлфә дә бер дә ачуланмый, орышмый, «Әй балалар! Күп шаярмагыз, керегез өйгә! Өшеп беткәнсез ләбаса...» дия дә куя иде. Хәлфә – яхшы кеше шул ул...

Шулай итеп гаеткә чаклы бер айны, сабак укымыйча, бушка уздырдык. Әткәй мине кунакка алып кайтырга дип, килеп тә җитте.

– Улым! Сабакны бик шәп укыдыңмы? Кайда чаклы укыдыгыз нәхүне?– дип, әти сорый... Мин анарга ничек дип җавап бирергә дә белмичә аптырап калдым: монда чаклы укыдык дисәм, тыңлатып карар дип куркам; бер дә укымадык дисәм, хәлфәнең гаебе чыга...

*1906 ел, ноябрь.*

# ГРАММАТИКА НИГЕЗЛӘРЕ ТУРЫСЫНДА[1]

Үз арабыздан телебезне башлап тикшергән, татар теленең сарыф-нәхүләрен баблап төзегән кеше – Каюм бабай. Ул телебезнең кушылмак табигатен тикшерү өчен кирәкле бик күп материаллар табып күрсәтте. Фигыль бабларының бездә ничек ясалганлыкларын ачты.

Каюм бабайдан соң тел тикшерү хәрәкәте байтак еллар тукталып торды да 1911 елларда Галимҗан Ибраһимовның «Татар сарыфы» белән башлап яңадан кузгалды; «Татар сарыфы» безгә телебезнең кушылмалык табигатен, сингармонизм канунын җиңел итеп аңлатып бирде.

Бездә «падеж» мәсьәләсен башлап күтәрүче «татар сарыфы» булды. Шуның белән, ул яшьләрне тел тикшерүгә кызыктырды.

«Татар сарыфы» өчен күрсәткән фактлар, аның ысулы хәзергә кадәр тел сабакларына нигез булып килде. Башкалар шуны төрләндерделәр, тирәнәйттеләр генә.

Октябрь революциясеннән соң телчеләребездә иҗади хәрәкәт яңадан уянды.

1922 елда Ташкентта чыккан «Инкыйлаб» журналында Н.Хәким белән Габдрахман Сәгъди иптәшләр арасында сарыф-нәхүләребезне нинди әсаста төзәргә дигән гыйльми бәхәсләр кузгалды. Шуңа ияртелеп, элгәре тикшерелгән нәрсәләр яңадан иләктән үткәрелә башлады.

Н.Хәким, сарыф-нәхүләребезне саф шәкел (формальный) әсаста төзергә кирәк, дип; Г.Сәгъди, телебезнең табигате саф шәкел әсасны күтәрә алмый, бездә телнең мәгънә, мантыйк ягы көчле, шуңа күрә мантыйкый (яки катнаш) әсасны алырга тиеш, дип бардылар.

Бу бәхәсләр соңыннан Казанга күчте. Шул уңай белән «Мәгариф», «Безнең юл» журналларында Н.Хәкимнең берәр мәкаләсе, Уфадагы «Белем» журналында (4 сан) Г.Алпаровның «Падеж мәсьәләсе» хакында бер мәкаләсе басылды.

Соңгы вакытта «Мәгариф»нең 4–5 саннарында Г.Сәгъдинең «Сарыф-нәхү әсаслары» хакында озын гыйльми мәкаләсе басылып чыкты. Бу мәкаләдә югарыда әйтелгән мантыйкый яки шәкли әсасларның төрек-татар телләре өчен кайсын алу мәсьәләсе тикшерелеп, шуңа бәйләнешле сүз тәгъриде, сүз төркемнәре, фигыль баблары, падеж мәсьәләсе кебек нәрсәләр дә телгә

---

[1] Мәгариф. – 1925. – № 10–11. – 100–112 б.

алынып үтәләр. Гомумән, грамматиканың нигезләрен билгеләү мәсьәләсе – телнең табигатен бик нечкәләп тикшергәннән соң гына чишелүе мөмкин булган яхшы ук тирән, гыйльми бер мәсьәлә. Бу турыда әле рус теле галимнәре дә катгый бер фикергә килеп тукталганнары юк.

Сарыф-нәхүләрне төзүдә мантыйкый як нигез итеп алынса, анда сүзләрне, сүз төркемнәрен, сүз кисәкләрен, аларның төрләнүләрен аңлатканда, аерганда, һәрвакыт аларның эчке мәгънәләре ягыннан булган аерымлыклары гына дикъкать ителеп, шул мәгънә һәм тасаурларның бер-берсенә мөнәсәбәтләре генә тикшерелә; тышкы авазлар, кушымталар белән төрләнеп әйтелү ягы шул эчке якка ияртелеп, мәгънә ягын аңлауга ярдәмче булып кына аерым өйрәтелә торган була.

Моңа каршы, грамматикаларда фәкать телнең тышкы әйтелеше ягыннан булган күренешләренә, авазлардан гыйбарәт формаларына гына дикъкать итеп, шушы тышкы фактлар буенча гына эш итү шәкеле (фармалны) якны әсас итү була. Боларны саф шәкелчеләр дип атыйлар.

Телнең әйтелеше ягыннан булган тышкы факторларын нигез итү белән бергә, шуңа бәйләп, аның мәгънә ягыннан булган аерымлыкларын да күрсәтә бару шәкли-рухи әсас булып чыга.

Төрек-татар телләренең грамматикаларын төзүдә бу әсасларның кайсысы белән эш итәргә? Аларның кайсысы безнең телебезнең табигатенә муафыйграк? Менә хәзерге көндә матбугатта тикшерелгән нәрсәләр шулар.

Сарыф-нәхүләрне төзүдә саф мантыйкый җиһатне генә игътибарга алып эш итү ярамаганлыгы инде ачык исбат ителде, аңлашылды булса кирәк. Хәзерге бәхәсләр саф шәкелчәләр белән, шәкеле-рухы (яки шәкеле-мантыйкый) якны әсас итүчеләр арасында шул ике нигезнең кайсын алу мәсьәләсе тирәсендә бара.

Г. Сәгъди соңгы мәкаләсендә шәкелчәләр ягын куәтләсә дә: «Төрек татар телләрендә мантыйкый җәһәт көчле, сарыф шәкеле әсасны телебезнең табигате күтәрә алмас», – дип шөбһәләнә. Бездә сарыф-нәхүләрнең шәкеле-мантыйкый (катнаш) әсасда төзелүен муафыйграк күрә.

Минемчә, саф шәкеле әсасдан да артык куркырга урын юк. Бердән, грамматика үзе телнең авазлардан гыйбарәт булган шәкелләрендә күрелгән фактларын тикшерә торган бер фән. Телнең мәгънә ягын тикшерсәк, ул грамматика түгел, семасиология булып китәргә тиеш. Икенчедән, «телебезнең табигате шәкеле әсасны күтәрә алмас» дигән сүз телебезне хаксыз кимсетү генә. Бу сүз «безнең башыбызда мәгънә күп, ләкин әйтеп бирергә телебез кыска» дигән сүз булачак. Авазлардан гыйбарәт шәкелләр, тышкы фактлар белән аңлатылмаган бер мәгънәнең телдә булуы да мөмкин түгел, алай булганда телләр уяну аңлатуга хезмәт итә торган корал була алмаслар иде. Тышкы фактлар телгә читтән килеп йөкләнгән, мәгънәгә мөнәсәбәтсез нәрсәләр түгел, тел башта ук шуның

белән тулган, шулар белән яшәп килә, безгә тик телебезнең нинди тышкы фактлары барлыгын ачык аңларга, аларны тикшереп табарга, аннары грамматикабызны (сарыф-нәхүләребезне) шул фактларга каратып төзи белергә кирәк.

Тышкы фактлары белән бер уңайдан телнең эчке мәгънә аерымлыкларын да өйрәтә бару – анысы метод мәсьәләсе булса кирәк.

Грамматика фактларының төзеклеге, ачык һәм җиңеллеге, тышкы төрләнешләренең кыска һәм ныклы кануннарга ияргән булуы белән безнең төрек-татар телләре Европа тел галимнәрен – тюркологларны гаҗәпкә калдыра түгелме? Шулай булгач нигә безгә шәкеле әсастан качарга?

Кыскасы, сарыф-нәхүләрне төзүдә иң беренче планда торган нигез телнең тышкы әйтелеш ягыннан күренгән фактлары формалы ягы булырга тиеш. Телебезнең табигате саф шәкли (формаль) әсасны күтәрә алачак, әлбәттә. Моны аңлар өчен, иң элгәре, төрек-татар телләренең шәкеле җиһәте – тышкы фактлары нәрсәләрдән гыйбарәт икәнен ачып күрсәтергә, шәкли якны нигез итеп алганда, грамматикабызның мөндәриҗәсе ни рәвешкә керәчәге хакында гомуми бер тәсаур ясарга кирәк була. Шунсыз һаман да мәсьәлә томаналы көенчә калып, ихтилаф (каршылык) дәвам итәргә мөмкин.

Безнең төрек-татар телләренең тышкы әйтелеш ягыннан булган фактлары түбәндәге күренешләрдән гыйбарәт:

1) Сингармонизм – аерым-аерым сүзләрнең авазлары бер төсле – ибәредә калын гына, ибәредә нечкә генә булу – табигате. Күп сүзләрне бер-береннән шушы калынлык, йә нечкәлекләренә карап танырга була. (*Ул, ул, туз, түз, шуз, шүз,...* кебек).

2) Кушылмалык – аерым сүзләрнең төп (тамыр) һәм кушымта дигән вак кисәкләрдән кушылып, бездә бөтен сүз төрләренең шул кисәкләр белән аларның авазлары үзгәрмичә янәшә килеп төзелүләре белән ясалу табигате. (*кешеләрегезнең = кеше +ләр+егез+нең, тырышмаганлыкларыннан гына = тырыш+ма+ган+лык+лар+ыннан+гына*).

3) Басым – бер сүздәге сузынкы авазларның арадан берсе көчлерәк сузылып әйтелү табигате. Бездә басым урыннары катгый кануннар буенча алдан билгеле була.

4) Тартыб – бер сүздәге төрле кушымталарның бер җөмләдәге аерым төрек-татар телләрендә ныгып урнашкан мәгълүм бер тәртибтә генә тезелеп әйтелү табигате. Бездә бер сүзнең кушымталары саннар (цифрлар) шикелле тезелеп, җөмлә әгъзалары бер-беренә йәбәрешеп, башкарган сүзләр башкаручыдан (иң кирәкле сүз иң соң) тезелеп әйтеләләр.

5) Аһәң тавыш үзгәреше шулай ук телнең тышкы күренешләреннән санала. Җөмлә әгъзаларын, җөмлә төрләрен күп вакыт шушы аһәң (интонация) тынышларының торуына карап белергә була.

Төрек-татар телләренең шушы күрсәтелгән табигатьләре бөтен төр, тармаклары белән бездә грамматика фактлары булалар. Телебезнең шәкли грамматикасы шушы тышкы фактларга таянып эш итәргә, шуларны тикшереп, бер системага салып күрсәтергә тиеш була.

Грамматиканың морфология (сарыф) бүлеге – телебезнең кушылмалык табигатен, аерым сүзләрнең нинди кушымталар белән, ничек төрләнүләрен тикшерергә; нәхү бүлеге – җөмләләрнең бездә ничек төзелүен, сүз тәртипләрен, бәйләнешләрен, тавыш, тыныш үзгәрешләрен өйрәтергә; фонетика бүлеге – телебездәге авазларның табигате, аларның үзгәрешләре, сингармонизм, басым кануннары белән таныштырырга тиеш.

Бу өч бүлек бер-береннән аерым нәрсәләр түгел, болар – тышкы һәм эчке яктан бер-берсенә бәйләнешеп, бер комплекс булып әверелгән нәрсәләр. Чөнки сүз төрләнешенә бәйләнмәгән аваз үзгәреше, җөмлә әгъзасы булмаган сүз төрләнеше юк. Шуңа күрә мәктәпләр дә боларны аермыйча бер бөтен комплекс итеп өйрәтергә тиеш була. Телебезнең мәгънә ягыннан булган табигатьләре дә шушы тышкы фактларга бәйләнешле булганлыктан, мәктәпләрдә аларда кушып аңлата бару муафыйк булса кирәк.

Инде килик мәсьәләләрнең гамәли ягына. Шәкли нигезне алганда, грамматикаларыбызның мөндәриҗәсе ничек булачак? Сүзне ничек тәгъриф итәргә? Сүз төркемнәре, фигыль баблары, башка төркемчәләр ничә һәмниләр булып чыгалар? «Падеж»лар тагын башка бик күп нәрсәләр бар буламы, әллә юкмы?

Сәгъди иптәш күбрәк мантыйкый җиһәдне игътибар иткәнгә күрә, сүзне үзенә башка бер тәсаувыр аңлаткан авазлар тезмәсе дип аңлаткан авазлар тезмәсе дип тәгъриф итә. Шунлыктан, ул бер сүзнең фармалны кисәкләре булган кушымталарны да сүзлектән чыгарып бетерми, вак сүзләр дип таный. Мантыйкый яктан бу шулай булса булыр, ләкин шәкли грамматикада сүзне болай аңлату, әлбәттә, дөрес булып чыкмый. Шәкли якны нигез иткәндә, безнең төрек-татар телләрендә сүзне, югарыда әйтелгән тышкы табигатьләренә карап: «Сөйләшкәндә үзенә аерым гармония һәм мөстәкыйль басым белән әйтелгән авазлар тезмәсе» дип кенә аңлатырга тиеш була. Бу тәгъриф буенча басмадагы калынлык, нечкәлек, нечкәлектән төп сүзгә ияргән кушымталар аерым сүз була алмыйлар, бәлки шул сүзнең кисәге булып кына саналалар.

Сүзләрне төркемнәргә (төрләргә түгел) аерганда да безгә югарыда күрсәтелгән тышкы фактларга, бигрәк тә сүзләрнең кушылмалык табигатендә күренгән аерымлыкларына карап эш итәргә кирәк була. Чөнки бездә тамыр кисәкләрнең аерым көенчә үзләрендә генә, сингармонизм табигатеннән башка, тышкы аермалык юк (сүзләрне төркемләгәндә: «эш яки хәлне белдергән сүз – фигыль, бер әйберне белдергән сүз – исем»... дип аеру мәгънә ягыннан карап эш итү була. Шәкли грамматикада ул

ярамый). Димәк, элгәре безгә төрек-татар телендәге сүзләрнең кушымталары белән, кушымталарның үз төркемнәре белән таныш булырга кирәк була.

Төрек-татар телендә кушымталар өч зур төркемгә аерылалар:

1) Ялгаулар (сарыф яки нигезлек кушымталар – суффиксы).
2) Бетемнәр (нәху яки бәйлек кушымталар – окончания).
3) Өстәмәләр (яки уртак кушымталар).

Бу кушымталар тамыр кисәкләргә ныгып урнашкан бер тәртип белән: иң элгәре ялгаулар, аннары бетемнәр, иң соңыннан өстәмәләр килеп кушылалар; ялгаулар бер сүздән икенче сүз ясау, сүзнең мәгънәсен күбәйтү, төрләндерү өчен тамыр кисәкләргә иң беренче килеп кушылалар. Болар үзләре өч рәт булалар: беренче рәттә сүз ясаучы ялгаулар килә. (Болар фигыль, исем, сыйфат, рәвеш ясау белән дүрт төргә аерылалар. Безнең телебездә болар күп кенә. Теләсә нинди тамыр кисәкләргә, теләсә кайсы ялгаулар кушылып сүз ясала алмый, аларның төрлесе төрле кушылу белән аерылалар. *Эшлә, сугыш, казгыч, язгы, беренче, язучы, алай, болай, акчалата* дигән сүзләрнең ялгаулары кебек.) Икенче рәттә дәрәҗәлек ялгаулары килә. (Болар фигыль дәрәҗәләре (баблар), исем дәрәҗәләре (иркәлек, кечелек), сыйфат дәрәҗәлекләре ясау белән өч төрле булалар: эшләттерт, язызтыргалау, картчык, казгычкай, акыл, күгелҗем, язучыкай, беренчерәк сүзләренең ахыргы кушымталары кебек. Өченче рәттә фигыльләрдә бүлмәү (ма-мә) ялгаулары килә (*эшләттермә, эрелдәнмә, язышма* кебек. Өченче рәт ялгавы башка сүзләрдә булмый).

Бу ялгау яки нигезлек кушымталарының бер рәттәгеләре үзләре берничә төрле булып, бер үк сүзгә, кайберәүләрнең берничәсе янәшә килеп кушылулары да мөмкин (мәсәлән, фигыль дәрәҗәлекләре: *эшләттерт, язызтыргалау, күрсәтеңкерә, яздырткалаш....* кебек). Бер сүздә һәр рәттәге кушымталарның калмыйча килүе ләзем түгел. Монда рәт билгеләү, аларның кирәк булганда шул урынны шигал итүләренә карап эшләнгән.

Шушы өч рәт ялгаулар кушылып әйтелгән сүз кисәге ахырдан килеп кушылачак нәхәви бетемнәргә нигез (основа) булып саналу. (Бу нигезләргә яңадан ялгаулар кушылып, яңадан бер мәртәбә башка сүзләр ясалуы да мөмкин).

Бетемнәр ялгаулардан соң ясалган нигез кисәкләргә икенче чиратта килеп кушылалар. Болар җөмлә эчендә сүзләрнең бер-беренә бәйләнешләрен билгеләргә хезмәт итәләр.

Болар үзләре ике төрле: 1) фигыль бетемнәре, 2) исем бетемнәре булып, һәрберсе ялгаулар кебек 2–3 рәткә бүленәләр.

Фигыльләрдә беренче рәттә заман бетемнәре (*ди, ган, чак, ар, п, эшле, мас, мича...*) икенче рәттә япсару (якы хәбәрлек) бетемнәре (*м, н, къ, к, гыз-гез, сын*) килә.

Искәрмә. Заман бетемнәре төрләнеш ягыннан өчкә бүленәләр:

1) үзләреннән соң япсару (яки хәбәрлек) бетемнәрен катгый теләүчеләр (боерык, үткән, шарт, хәзер);

2) япсару бетемнәрен бөтенләй теләмәүчеләр (рәвеш, вакыт);

3) фигыльнең яңадан сыйфатка әйләнүенә хезмәт итүчеләр. Болары үзләреннән соң фәкать исем бетемнәре генә телиләр (*ган-гән, чак-чәк, ар-әр, макчы, асыәсе*): килештермәдек, язгаласагыз, үкенсеннәр, килеп, барышлы, күренмәгәч, киләчәкләрдән, алганнар, үгезне, ашарларына, килгәнмен, барачаклардан... кебек.

Исемнәрдә беренче рәттә сан (*лар-ләр*), икенче рәттә япсару (*м, ң, ы, (сы) быз, гыз-гез*), өченче рәттә төшем бетемнәре (*ның, дан-дән, га-гә, ка-кә, ны, н, да-дә, ча-чә, ди*) килә. Боларның бер рәттәгеләрдән берәүсе кушылган сүзгә шул рәттән башкалары кушылмый. Бер сүздә боларның һәр рәттән берәүсе калмый килүе ләзем түгел, ләкин килсә, урыны шул рәттә була.

Искәрмә. Кайбер төшем бетемнәреннән соң яңадан сыйфат ясаучы ялгаулар кушылып, яңадан исем бетемнәре белән төрләнү мөмкин була. Базардагылардан, күптәнгеләр, күршеләрегезнеке, ягъни -ның, -ке, -лардан кебек өстәмәләр теләсә нинди тамыр һәм нигез кисәкләргә, бетемнәр белән төрләнгән бөтен сүзләргә кушыла алалар. Уртак кушымталар белән төрләнешкән сүзләр бездә юк диярлек. Болар үзләре нинди тәртиптә килеп кушылуларына карап, ялгаулар һәм бетемнәр кебек, өч рәткә бүленәләр:

Беренче рәттә чикләүче өстәмәләр (*гына-генә, ук-үк, рак-рәк*) килә.

Искәрмә. Исемнәрдә чикләү кушымталарыннан соң яңадан исем бетемнәре белән төрләнү табигате дә бар.

Икенче рәттә хәбәрлек өстәмәләре (*мын, сың, без, сез, (сыңз), лар-ләр*) килә, бу кушымталар япсару бетемнәре белән төрләнгән фигыльләргә генә кушылмыйлар. *Барамын, адәмсең, түгелбез, килгәнсез, йуклар* кебек.

Өченче рәттә ныгытучы өстәмәләр (*мы, мени, ла-лә, да-дә, сана-сәнә, ләбаса, чы, дыр*) килә.

Бу өстәмәләрнең бер рәттәгеләрдән берәрсе кушылган төргә икенчеләре кушылу гадәте юк диярлек. Өстәмәләрнең тәртибендә аз-маз башкалыклар очрарга мөмкин. Чөнки болар аерым сүзлектән чыгып кушымтага бөтенләй әйләнеп бетмәгәннәр әле. Өстәмә кушымталар төп сүзнең гармониясенә иярүдә башкалар белән бер табигатьтә булсалар да, басымны үзләренә үткәрмәү белән башкалардан аерылалар.

Төрек-татар телләренең кушылмалык табигате шушы өч төркем кушымталар белән механик рәвештә төрләнүдән гыйбарәт. Телебезнең морфология төзелешенә берничә мисал:

| Нигез кисәк | | | |
|---|---|---|---|
| Тамыр (төп) кисәк | Ялгаулар: ясаучы, дәрәҗәлек, бүлмәү | Бетемнәр: заман, сан, япсару, төшем | Өстәмәләр: чикләү, хәбәрлек, ныгыту |
| Эш | *лә + т +*<br>*дер + мә* | *– де + гез –* | *– – мый?* |
| Кил | *– гәлә +*<br>*штер + –* | *сә + н –* | *– – че* |
| Ярдәм | *лә + ш + мә*<br>*лек + – –* | *гән +*<br>*ләр + егез + не* | *генә – –* |
| Юл | *даш +*<br>*лык + – –* | *лар + ы +ндан* | *рак – –* |
| Иб<br>Авыл | *дәш + кәй –*<br>*даш + – –*<br>*гы – –* | *ләр + егез + дән*<br>*лар + ыгыз +да*<br>*лар – ны* | *– мен +ласа*<br><br>*гына – моны* |

Инде бу кушымталар белән төрләнүләрендәге аерымлыкларына карап, сүзләрне төркемнәргә аеру мәсьәләсенә кайтыйк.

Өстәмә кушымталар белән телебездәге бөтен сүзләр төрләнә алганлыктан, аларга карап, сүзләрне төркемнәргә аеру мөмкин түгел. Кала бетемнәр һәм ялгауларга карап төркемләү.

Нәхәви бетемнәр белән төрләнүдәге аерымлыкларына карап, бездә бетемләнүчән сүзләр һәм бөтенләй бетемләнмәгән сүзләр бар. Боларны 1) төрләнүче, 2) төрләнмәүче сүзләр дип икегә аерырга мөмкин. Төрләнүче сүзләр үзләре ике төркем: 1) фигыль бетемнәре белән төрләнүчеләр; 2) исем бетемнәре белән төрләнүчеләр (ике фигыльле исемнәр).

Сарфи ялгаулар белән төрләнүдәге аерымлыкларына карап, сүзләрне тагы берничә төрле төркемнәргә аерырга була (ялгаулар кушылып ясалу-ясалмауларына карап): 1) ясалган сүзләр, 2) ясалмаган сүзләр бар. Ясалган сүзләр үзләре дүрт төркем: 1) фигыльләр, 2) исемнәр, 3) сыйфатлар, 4) рәвешләр, 5) саннар, 6) алмашлыклар, 7) вакыт-урыннар, 8) ярдәмлекләр, 9) ымлыклар.

Менә бездә сүзләрне тышкы төрләнешләрендәге аерымлыкларына карап, төрле рәвештә төркемнәргә аеру шулай булып чыга.

Безнең төрек-татар телләрендә сүзләрне һәр җәһәттән үзенә аерым тышкы табигате тулы булган төркемнәргә аеру мөмкин түгел. Бездә бер төркемдәге сүз төрле ялгаулар кушылу белән башка төркемнәргә әйләнеп, алмашып тора. Шунлыктан бездә сүзләрне ачык төркемнәргә аерып өйрәнүнең әһәмияте дә аз булса кирәк.

Сүз ясаучы ялгауларның төрлесе кушылганда, бездә аларның иң

соңгысы сүз төрен билгели. Баб булмау төрләре генә сүзләрнең фигыль булып очлануларын тәэмин итә алмый. Заман бетемнәреннән берничәсе генә фигыль булып бөтенне тәэмин итә ала.

Монда да күбрәк иң соңгы бетемнәргә дикъкать итәргә кирәк.

Нигъмәт Хәким иптәшнең нәхәви бетемнәр белән төрләнгән сүзләрне генә төркемнәргә аеруы, сарыфта шул ике төркем сүзләрне генә тикшерүе дөрес һәм тулы булып чыкмый. Төркемнәргә аерганда, телебездә булган бөтен сүзләр үзләренең хакын алмый калмаска тиеш. Аннары өстәмә кушымталар белән төрләнми торган сүзләр бездә юк та. Шунлыктан аларны нәхүгә калдыру да урынсыз. Сәгъди иптәшнең төрләнмәүче сүзләрне вак төркемчәләргә аеруы аларның мәгънәләренә карап эшләнгән. Тышкы яктан исә, аларда аерма юк. Араларында төрләнә торган сүзләр дә бар.

Телебезнең кушымталану механикасын игътибарга алып җиткермәгәнлекләреннән, Нигъмәт һәм Сәгъди иптәшләр бер рәткә бер җенес төрләрне билгеләүдә бераз ялгышалар. Мәсәлән, Нигъмәт Хәким исемнәрдә тартым (*ныкы*), пошыну (*ла-лә*), ялгызлык (*гына-генә*), сорау (*мы*) дигән аерым төрләр күрсәтә. Сәгъди иптәш шуларга тагын охшату (*дай-дәй*), төбәү (*генә*), икеләнү (*дыр*), (*ук-үк*), сәбәпләнү (*курә*) дигән төрләр өсти. («Күрә» шәкеле грамматикада бөтенләй мөстәкыйль аерым сүз, ул кушымта түгел. Димәк аерым бер төр дә була алмый. Нигъмәт Хәкимнең «торган» дигән сүзне аерым бер төрдән санап таратуы да шулай ук дөрес түгел.)

Сәгъди иптәш, «фигыльләрнең хәрәкәти хосусиятләре шәхси яки нисбәт, юклык, баб, заман белән үзгәрүләрендәдер», ди. «Исемнәр арасында иң характерлы якларның *кә-гә, ка-га, дән-дан, дә-да, ның, белән, хакында (турысында)* дигән килеш яки тәмамлык кушымталары булган вак сүзләр белән төрләнеп күренүләрендәдер» ди.

Бу сүзләрдә берничә төзәтәсе урын бар:

1) Фигыльләрдә үзгәрү, исемнәрдә төрләнү сүзен куллана, боларны икәүен бер төрле генә йөртү кирәк.

2) Нисбәт (япсару) белән төрләнү фигыльдә генә түгел, исемнәрдә дә бар. Икенче рәт исем бетемнәре, өстәмә хәбәрлекләр шулар).

3) *Белән, хакында, турысында* дигән сүзләрне кушымталардан килеш (төшем) төрләреннән саный. (Шәкли грамматикада болар аерым сүзләр булып саналалар, әлбәттә).

Сәгъди иптәш: «Нигъмәт Хәкимнең низагсыз торуы фикерләре фигыльләрнең баб белән булынуларындадыр», – ди. Минемчә, Н. Хәким иптәшнең бабларны билгеләүдә байтак хаталары бар:

1) Бабны «ия белән эш вә хәл арасындагы мөнәсәбәтне аңлата торган төрләнеш» дип (тәгърифый – мантыйкый), шәкли грамматикача: «фигыльләрнең икенче рәт ялгаулары белән төрләнешүе» дияргә кирәк.

2) Н. Х. Туктар авазның теләве белән генә төрлечә әйтелгән бер үк

йөкләтүне икегә аерып, *т* ялгавы кушылганын «үтем бабы», *дыр* ялгавы кушылганын «васита бабы» дип йөретә.

3) Н. Х. Туктар бер үк кабатлау белән «тәкърарлау» (*гала-гәлә*) «сирәклек» (штыр) дигән ике бабка аера. Боларда бер үк бабның ахыргы авазларга карап, төрлечә әйтелгән төрләре (тартынкы авазга беткән фигыльләрдә *гала-гәлә*, сузынкы авазга беткән фигыльләрдә «штыр» ялгавы белән) бар.

4) Н. Х. Туктар баб ялгавы кушылмаган фигыль төрен аерым бер баб итеп санамый, хәлбуки, шәкли грамматикада бер рәттәге сүзләрнең кушымтасыз әйтелеше дә бер төр саналырга тиеш (күплек янында берлек, булмау янында булу төрен йөретүебез кебек).

«Падеж мәсьәләсе» хакында безнең арабыздагы тартышлар бары да «лафыз бәхәсеннән» гыйбарәт булырга ошый. Минемчә, «падеж» сүзе бер истилях дип кенә каралырга тиеш. Аны «килеш» дип йөртсәң дә, «төшем» дип атасаң да – барыбер. Истилях дип атау, телдәге фактны үзгәртә алмый, әлбәттә.

Нәрсә соң ул «падеж»?

Мантыйкый яктан ул – исемнәрнең фигыльгә бәйләнеше дигән сүз; шәкли яктан – исемнәргә шул бәйләнешне күрсәткән өченче рәт нәхәви бетемнәр кушылып әйтелүе дигән сүз. Димәк, ул, мантыйкый яктан карaганда да, фармалны игътибарга алганда да бездә бар булып чыга.

Югарыда күрсәтелгәнчә, телебезнең кушылмалык табигате сүзләрнең нинди кушымталар белән, ни тәртиптә төрләнүләре ачык аңлашылганнан соң бу мәсьәлә үзеннән-үзе чишелә торгандыр дип беләм.

Грамматиканың нәху бүлегендә дә шулай ук югарыда күрсәтелгән тышкы фактлар белән эш итәлергә тиеш була. Җөмләне: «атау төшемендәге иягә бәйләнеп аның белән ярашып әйтелгән хәбәрдән гыйбарәт сүзләр тезмәсе» дип, ияне «үзенә ярашкан хәбәр атау төшемендәге сүз» дип, хәбәрне – «атау төшемендәге иягә ярашып әйтелгән азаккы сүз» дип, тәгъриф итәргә туры килә.

Тәмамлыклар – фигыльдән элек әйтелеп, тышкы бер төр белән аңа бәйләнгән сүзләр; аергычлар – исемнән элек әйтелеп, тышкы төр белән аңа бәйләнгән сүзләр була.

Җөмлә әгъзаларын, аның төрләрен сүзләрнең нәхәви бетемнәр белән төрләнүләренә, җөмләдә торган урыннарына нинди басым һәм нинди тавыш (тон) белән әйтелүләренә карап та аерып танырга була. Монда күбрәк тәртип роль уйный: безнең төрек-татар телләрендә җөмләдәге сүзләр бер-беренә иярешү-буйсыну рәвешендә, морфология төзелешенә кире тәртиптә, тезелеп әйтеләләр. Морфологиядә тамыр кисәк, элгәре, кушымталардан соң килә иде; җөмләдә иң элек ияргәнгә, иягә генә ияргән сүзләр, аннары ияргәнгә ияргән сүзләр, соңра беренче ияргән сүзләр, иң ахырдан үзе ияртүче (башкаручы) сүзләр әйтеләләр (шигырьләрдә, кайбер кирәкле урыннарда гына бу тәртипнең үзгәрүе мөмкин).

Бездә таркалу җөмләнең болай төзелешен түбәндәге схема белән күрсәтергә мөмкин (уклар белән әгъзаларның нинди тәртиптә әйтелеше күрсәтелгән):




Мәсәлән: «Татар теленең грамматикасы моннан соң шәкли нигездә төзелергә тиеш». «Россия коммуниситлар партиясенең юлбашчылыгы белән күтәрелгән Октябрь революциясе әрәмтамакларны эш башыннан тимер себерке белән себереп ташлады» дигән җөмләләрдәге әгъзаларның төзелүе кебек.

Кыскасы, шәкли якны әсас иткәндә, сарыф-нәхүнең бөтен матдәләрен телебезнең тышкы фактлары буенча бик ачык итеп аңлата барырга һәм ныклы системага куярга мөмкин булачак. Журнал битләре артык җәелергә ирек бирмәгәнлектән, хәзергә шуның белән туктатырга туры килә.

Монда сөйләнгән мәсьәләләр хакында тулырак карашымны озакламый басылып чыгачак «Татар грамматикасында» күрергә булыр.

# ЛАТИН ТҮГЕЛ, ГАРӘП[1]

## 1. «Бөтен фронт буенча...»

Бу чорларда безнең арада «Латинмы, әллә гарәпме?» дигән бер мәсьәлә турысында үзара әрепләшү, шул сылтау белән бер-берен чәйнәшү кызып барганлыгы күренә.

«Гарәп хәрефе» яклы иптәшләр яудан саклану юлын тоткан хәлдә, латинчы иптәшләр «Европа ысуллары» белән коралланып, «бөтен фронт буенча» аларга каршы һөҗүм итә башладылар; кот очырып, бик кызулап, ил өстенә томан җибәрергә тотындылар.

– Башкалар латинга күчеп бетә инде... Тизрәк булыгыз... Гарәп хәрефенә ышанып, төтен тавы тотып калабыз инде, – дип ашыктыралар, «мәхрүм калу» төтеннәре җибәрәләр.

– Гарәп хәрефен 50 ел буена төзәттек – булмады, ул һаман бозыла гына бара; аны төзәтеп бетергәнче тагы 50 ел вакыт кирәк булыр, – дип, юри чынлыкны бозалар. Гүя 50 ел буенча бөтен татар, аның төзәлеп беткәнен көтеп, кашык тотып карап утырыр төсле итеп күрсәтергә тырышалар.

– Яңлыштан курыкмаска кирәк: латиннан файда булмаса, кире гарәпкә кайта алырбыз...,– дип, Коръән әйткәнчә, тәвәккәл булырга димли берәүсе. «Булса – булыр, булмаса – юк, әйдә валяй! Тәвәккәл Ходa!..» – дип кыздырмакчы итә.

– 4, 6 кегль гарәп хәрефләрен эшләткәндә, аларны укыр өчен берәр микроскоп та ясатырга кирәк булачак, – дип, – гарәп хәрефен ташламаса, татар халкына Европаның су астыннан байлык эзләүче водолазы, газдан саклану өчен битлек, борынчык кигән солдаты кебек коралланып укырга туры килер, – дип бала-чаганы куркыта берсе.

Куркыту, тилертүләр белән аралаш әрләшү, тиргәнүләр дә катыша:

– Теге болай дип әйтә, мин алай дип әйтеп әйтмәгән идем, аның фәлән дигәне төгән була... фәлән-фәсмәтән..., – дип сүз көрәштерәләр, «күршенең аты узганчы, үземнең таем узсын» дип маташалар.

Ике яктан ду килеп чәкәләшкән арада төп мәсьәлә чишелми, томан арасында буталып йөри. Шул шау-шуларны ишеткән беркатлы халыкның кайсы:

[1] Безнең юл. – 1926. – № 4. – 10–17 б.

– Иртәгә латин булабыз икән! – дип чәчләре үрә тора, кайсылары шатланып үзе үрә сикерә.

Мин бу хәреф мәсьәләсе өстендә башыннан бирле чокчынып килгән, уйланып яткан берәү булуым уңае белән, әрепләшү өчен түгел, аңлашу уе белән бу турыда карашымны әйтеп калырга телим. Мәсьәләне, көчем җиткән кадәр томаннардан әрчеп, өстән генә түгел, астан да, баштан, аяктан, кабыргадан да аңа җентекләбрәк карамакчы булам...

## 2. Әлифба белән тел бер

Хәреф – билге ул. Үзара бер телдә сөйләшә торган халыкларның язып аңлаша торган билгеләре ул. Бер телдә сөйләшкән халыкларның эш мөнәсәбәтләре вакытында үзара аңлашуларына, бер-беренең тәҗрибәләреннән файдалануларына ярдәм итә торган ишарәләр алар. Ул билгеләр мәгълүм бер телдә сөйләшкән халыкларның мөмкин кадәр күпчелегенә таныш, нык таралган булса, файдаланырга яраса – булды. Шуннан артыгы кирәк түгел. Хәрефләрнең төрткесез, тешсез булуы, бакча рәшәткәсе кебек тезелеп торуы, кирпеч кебек дүрт почмаклы булып утыруы, бөтен дөнья халкында бер төсле булуы лязим дә түгел, нигез дә түгел...

Әлифбасы бер төсле булып та, теле, сөйләшүе башка булган халык бер-беренең язуыннан һич тә файдалана алмый, чөнки ул язуларның нинди сүзгә, нинди мәгънәгә йөргәне аңлашылмый. Теле үзенчә булса гына аңларга була. Әлифба берлеге бер телдә сөйләгән халыклар өчен, аларның мәдәни мөнәсәбәтләрен көчәйтү өчен генә файдалы. Шуңа күрә бер телдә сөйләгән халыклар үзара мөмкин кадәр бер төрле хәреф белән язарга, бер әлифба, бер имля кулланырга тырышалар. Тел ерак булганда, әлифба берлегенең үзара аңлашуга бер тиенлек тә ярдәме тиячәк түгел.

Язу белән тел арасында һәр җәһәттән бик якын мөнәсәбәт, бик нык бәйләнеш бар. Язуның тарихы да тел тарихы белән янәшә бара.

Кешеләр борын заманда, ярым хайван булып яшәгән чагында, аларның телләре дә булмаган, язулары да. Сөйләшеп аңлаша башлагач, язып (ишарә белән) аңлашу да башланган. Тел үсеп төрләнә барган саен, халыкның тел хакында аңы (тәсаувыры) үскән саен язу да төрләнә, үсә, дөресләнә бара.

Бер төптән чыккан тел, бара-бара тормыш законнары буенча төрле телләргә, шивәләргә аерылган кебек, төбендә бер финикә-еврей әлифбасыннан башланган язу һәм хәрефләр дә төрле халыкта, төрле шартлар астында төрле якка таба үсеп, тармакланып киткән, төрлесе төрле якка каратып яза башлаган.

Шуны да әйтергә кирәк: латин, юнан хәрефләре моннан өч мең ел элгәре финикә әлифбасыннан ни сурәттә алынган булса, шул төп сурәтенә

якын көенчә, үзгәртелмичә, изге итеп саклanган, тормышка яраклашып төзәлә бармаган (латин хәрефләрен финикә хәрефләре белән чагыштырып каравыгызны үтенәм). Гарәп хәрефләре исә, төп шәкелдә калмыйча, эш өстендә уңайлыкка карап үзгәрә, табигый юл белән үсә, төзәлә килгән. Шул арада ул җитез укыначлы, тиз язылмалы, комбинацияле нәфис бер язуга әйләнгән. Гарәп хәрефләренең чиксез күп комбинацияләр белән бер-береннән аерыла торган, сүзләрне күренекле, аерым фигуралы итеп күрсәтә торган керенде-чыгындылары бары да тиз күреп уку, тиз язуга уңайлык бирү юлында табигый рәвештә үсеп килеп чыкканнар.

## 3. Элек тел, аннары язу...

Язулар берләшү өчен иң элгәре телләрнең берләшүе кирәк. Телләрнең берләшүе исә, халыкларның үзара катнашып яшәүләренә, икътисади берләшүләренә бәйләнгән.

Телләрнең бер төптән әллә ничә тармакларга аерылып китүе бик тиз генә хасил булмаган кебек, аларның якынлашу, берләшүләре дә тиз генә була алмый. Әле бер яктан телләр үзара якынлаша барган кебек булса, икенче яктан ераклаша, аерылыша да бара. Ерак киләчәк бер заманда бөтен дөнья халкының теле бер булачак дигән өмет бар. Бу берләшүнең, ләкин, ни рәвешле булачагы, хәзерге Европа яки Азия телләренең берсендәме, әллә бөтенләй яңа бер телдәме, хәзергә атап күрсәтү – мөшкел эш.

Телләрнең берләшү процессы иң элгәре аз санлы, үзара якынрак телле халыклар арасында ваклап, бик акрынлап, үзара аерымлыкларның шомаруы рәвешендә табигый юл белән генә барачак. Аннары зур группалар үзара бик озак еллар буенча көчле катнашып яшәгәннән соң гына берләшә алачаклар. Шул вакыт аларның язулары да бик озак янәшә барганнан соң көчсезрәге кирәксез булып ташланырга, үз-үзеннән берләшергә мәҗбүр булачак. Димәк кешеләрнең телләре берләшүгә аларның тормышлары бик зур ярдәм итәчәк. Ләкин хәреф-язу берлеге моңа хезмәт итә алмый, чөнки тормышы аерым булган халыкны язу гына көчләп берләштерә алмый, алар язуга карамыйча ераклаша гына барачаклар. Урыслар белән Анатулы төрекләренең безгә мөнәсәбәтен чагыштырып карагыз: безнең татар массасы кемнең язуын күбрәк таный? Кемнең телен күбрәк аңлый? Боларның кайсына якынлашып, кайсыннан ераклаша бара? Монда язуның «зәррә мыскал» хезмәте бармы?

Кыскасы, элгәре тормыш, аннары тел, иң соңыннан язу бүлешергә мөмкин. Элек үзара якыннар, аннары ераграклар. Киресенчә түгел.

## 4. Өметләнергә дә, куркырга да ярамый

Әлифба – бер билге булу ягыннан, әлбәттә, изге бер нәрсә итеп каралмый. Аны үзгәртергә дә, алмаштырырга да ярый, әлбәттә.

Хәреф алмаштыру бар, хәреф алу бар – болар икәве ике нәрсә.

Элгәредән үзенең әлифбасы, язуы, мәдәнияте булмаган халык кына «әлифба ала». Бу – дөньяда бар эш, ирекле эш. Ул аны «мәдәниятле»дән сайлап, чагыштырып, карап ала.

Ләкин электән әлифбалы, язулы бер халыкның, бер зур фаҗигале хәл булмаганда, үз иреге белән әлифба алмаштыруы, яңаны сайлап алуы – булмый торган нәрсә. Бер халык үзенең ана телен үз иреге белән алмаштыра алмаган кебек, тел кебек үк үзләшкән язуын да алмаштыра алмый. Аны соңгы рәвештә алмаштыру бик кыен, күп көч, озак вакыт сорый.

Язу алмашуга караганда, хәтта тел алмашу җиңелрәк. Чөнки ул берәр сүзләп-берәр сүзләп ана теленә аралаша барып, сизелми генә алмаша ала. Язуны берәр сүзләп, берәр хәрефләп аралаштырып йоттырырга мөмкин түгел. Аны элгәреге язу белән янәшә өйрәтә бару белән генә, яки яңа белән язган кешеләрне искечә язганнарга аралаштырмый аерып тоту белән генә кертергә булса булыр.

Яңа әлифбага алмашу өчен бөтен илнең азында 100 еллар буенча сугыш, кыйралыш кебек, тормыш үзгәртү кебек комачаулардан тыныч булуы кирәк. Яңа әлифбага күчү өчен, элгәреге әлифбаның 90% укырга да, язарга да яраксыз булуы, техникага бөтенләй уңайсыз булуы кирәк. Яңадан алмаштырып алына торган әлифбаның халык арасында күптән, яртылаш таныш булуы, үзе көн-төн катнашып бергә аралашып яшәгән халыкның әлифбасы булуы шарт.

Яңа әлифбага күчәргә булганда иске белән бәйләнешне бөтенләй өзәргә кирәк.

Бу шартлар табылмаганда, яңа әлифбага күчәбез дип булашу – тирәнлеге, киңлеге беленмәгән диңгезгә кереп йөзәргә тотыну белән бер булачагында шик юк. Тарих безгә моны ачык күрсәтә.

Борынгы төрекләрнең (*төркиләрнең*) уйгур әлифбасын ташлап, гарәп хәрефләренә күчүе VIII йөздән башлап XVI–XVIII йөзләргәчә дәвам иткән. Нимесләр үзләренең иске готик хәрефләрен латин әлифбасына алмаштырмакчы булып инде 100 еллар буе янәшә ике әлифба белән китаплар басып киләләр. Үзләре Европа уртасында яшәүгә, хәрефләре, телләре якын булуга карамастан, 100 ел параллелизм! Японнар әллә никадәр чыгыннардан (*чыгымнардан*) соң, латинга күчә алмый кире кайтырга мәҗбүр булганнар.

– Параллелизм нигә кирәк, бүгеннән кырт кисеп, иске язуны, иске укуны туктатабыз да, гелән яңа «татар» әлифбасы белән генә эш итә башлыйбыз,– диярләр.

Юк, иске әлифба белән укыганнарга да гәзит, китап бирергә кирәк. Алар яңаның хәрефен таныса да бөтен сүзне тиз таныл, тиз укуга күнегә алмыйлар. Озаклап, иҗекләп утырырга чыдамнары җитми. Яңа белән өйрәнгән яшьләр дә үз яннарында су кебек агып торган икенче

бер әлифба белән мөгамәлә барганда, үзләре дә шуңа катнашып агарга мәҗбүр булалар. Син өйрәтмәсәң дә алар аны өйрәнәчәкләр, күбесе аны шәп укырга да күнегәчәк.

Шулай итеп берничә буыннар, берничә йөз еллар үтми торып, яңа әлифба ягы басып китә алмый, массаның укырга-язарга җитезлеге яңа әлифба ягына авышып китә алмый. Менә шул хәл озак параллель ясауга сәбәп була.

Хәзергә безнең параллелизм белән маташырга запас вакытыбыз да, артык байлыгыбыз да юк. Әле без шулкадәр ярлы, шулкадәр икътисади яктан түбән, әле ул андый зиннәтләргә кабагын да күтәреп карый алмый.

Хәер «читтән» берәр ярдәм булмаса.

Тюркология съездында төп докладчы профессор:

– Акча юклыктан зарлансагыз,... җәгез, ул акчаны табарбыз,...– дигән иде диюен.

Параллель ясамас өчен, латинлаштырылганнарны – Башкортстанга я Кавказга, гарәп хәрефендә калганнарны Казахстанга күчереп, бер-береннән аерсалар, гаҗәп түгел... Ләкин ул да бик кыен.

Шулай итеп, безгә латин хәрефләрен кертеп бетергәнче әле 99 томлы энциклопедияләрне генә түгел, бөтен әдәбиятыбызны, хәтта бөтен Европа әдәбиятын үз телебезгә әйләндереп, басып өлгертеп чыгарырга мөмкин булыр. Әллә, бәлкем, ул чакта берьюлы 2–3 хәреф белән янәшә басарлык һөнәрле һәм бай булырбыз, белер хәл юк. Ләкин ул ерак әле.

Шуңа күрә:

– Иртәгә латин булабыз икән, – дип өметләнергә дә, аннан куркырга да урын юк әле, минемчә.

## 5. Латин – мәдәният гамилеме (*билгесеме*)?

Соң латин безгә шул хәтле кирәк бер нәрсәмени? Әллә латин алганга бер нәрсә өләшәләрме? Нигә ул чаклы үлешәләр?

Ислам гашыйклары бервакыт шулай: «Безне чын ислам дине генә тәрәккый иттерәчәк... Киләчәктә ислам мәдәнияте... Без әле чын мөселман булмаганга күрә генә болай хур вә хәкыйрь (*фәкыйрь*) булып...» дигән идеализм белән саташалар иде.

Шуның кебек безнең латинчыларыбыз да, гарәп хәрефенә ышанып, мәдәнияттән мәхрүм калабыз инде дип куркалар. Алар латин хәрефен алсак, Европа, Америка кебек бай да, көчле дә, гаҗәп шәп мәдәниятле дә булып китәбез дигән идеализм белән хыялланалар. Иртәгәдән 99 томлы энциклопедияләр, радиолар, үз телебездә аэропланнар, «яңа татар хәрефе» белән трактор – Фордзоннар, тагын әллә нинди әкәмәт нәрсәләр булдырмакчы булалар.

Хәреф-әлифба мәдәниятнең төп гамиле булмаганлыгын советлар илендә хәзер мәктәп балалары да белә инде. Мәдәният – ул тормышка кирәк нәрсәләрне эшләп чыгару, аны тарату көчләренә тулы рәвештә ия булырга, икътисади яктан көчле булуга карап; юри хәреф, имля (*орфография*), өтер, билге кебек нәрсәләр алар мәдәният тудырмыйлар. Икътисади ягы көчле булгач, әнә Япония бик начар, кашаяк мунчаласы кебек хәрефләр белән язып та алдырта. Бер дә мәдәниятсез түгел. Якутлар, эскимослар шәп хәреф белән язсалар да, ерак китә алмыйлар.

Илендә нефть, күмер коелары кебек табигый байлыклар агып тормаса, яки фабрик-завод, электрификацияләр корылып, машиналар гөрләп, эшләп тормаса, берничә ун елдан түгел, берничә йөз елдан соң да, 99 әлифба алмаштырсаң да, мәдәният юк сиңа.

Нигә соң латин шәп күренә?

Шулай инде, икътисади яктан көчле, өстен халыкның теле дә, сүзе дә өстен, кыяфәте дә, язуы да шәп күренә: үзе ярлы халыкның теле дә ярлы, әлифбасы да ямьсез күренә. Гарәпләр сәясәт, байлык ягыннан өстен чагында аның дине дә, язуы да шәп иде – ул вакыт төрекләр (*төркиләр*) үз әлифбаларын гарәп хәрефенә алмаштырдылар. Соңгы гасырларда латин хәрефе белән язучы европалылар, бөтен көнчыгыш иленең байлыгын суырып көчәйделәр дә, инде аларның дине, теле, кием-салымы, хәреф, язулары да шәп булып китте. Элгәреге матурлар ямьсезгә әйләнде, читләнде. Шулай булырга да тиеш иде ул. «Байның авызы кыеш булса да, сүзе туры» дигән борынгы тәҗрибә дә шуны күрсәтә ич.

Ләкин ул мәңге шулай бара алмый.

Мәсьәлә шунда. Элек Орхон хәрефе иде, аннары уйгур, аннары гарәп булдык, кайсыларыбыз рус хәрефен алды. Инде тагын латин булып чобарлансак, моннан нинди файда чыгар? Ихтимал, озак үтмәс, коммунизм идеясе өстен чыгу белән СССР пролетариаты бөтен эштә үзәк урынны тотар, латинчы Европа империализмы канлы капиталы, черек мәдәнияте белән юкка чыгар, коммунизм теләге белән бергә урыс хәрефе өстен булыр – ул чакны без тагы рус хәрефенә күчәрбезме? Әллә латинда торып калырбызмы? Күчә бирсәк, мәдәнияткә тиз ирешербезме? Ул чакта «Тришка чикмәне»нә түгел, Крыловның «Квартет»ындагы каһарманнарга охшап калмабызмы икән?

Хәзергә әле рус, гарәп әлифбалары азатлык ягында, революция ягында. Латин хәрефләре әле капитал коралы. Капиталга, империализмга каршы көрәшкән бер генә илдә дә бүген латин хуҗа түгел әле. Киләчәген дә беркем тәэмин итә алмый.

Ислам утопистлары көчле заманнарында: «Ахирәттә сөаль-хисап сөрйани телендә, пәһләви язуы белән булачак...»– дип хыял итәләр иде. Әллә тагы шуның кебек, безнең латинчылар да киләчәк коммунизм дәверендә бөтен халыкларның уртак теле (Европа телләреннән генә оештырып ясалган)

эсперанто, язулары латин хәрефе булачак дип пигамбәрлек итәләрме? Бу нинди идеализм?

Социализм Европа телендә латин хәрефендә генә төзеләчәк, тискәрегә язу гына безне империализм тырнагыннан коткарып, коммунизм тормышына илтәчәк» дигән берәр гипотеза булса, аны исбат итүне, шуңа мине ышандыруны сорыйм мин латинчы иптәшләрдән.

Әллә тагы безгә мәгълүм булмаган башка берәр төрле пролетариат мәнфәгате шуны телиме икән?

Тәҗрибә дисәң, нигә безнең белән ясала? Дөньяда иң бәйнәлмиләл (*интернациональ*) халык яһүдләр булса кирәк. Алар нигә үзләренең шайтан ботагы, Муса пигамбәр таягы кебек әлифбаларын ташламыйлар? Хәреф алмаштыру, бәйнәлмиләлләштерү тәҗрибәсен алардан башлап караганда, уңаерак булмас идеме? Нигә бер учтай әрмән халкы да, дөньяда башка һичбер халыкта күренмәгән мөгезле, ботаклы-ботаклы хәрефләр белән язса да: «Әлифбамны алмаштырмыйм!» – дип аяк терәп тора тюркология съездында әрмән вәкиленең сүзеннән)? Аңа димләмиләр дә. Әллә аларның Европа кебек мәдәни булулары матлуб (*кулай*) түгелме?..

## 6. Кем ышаныр икән?

Латинчы иптәшләр: «гарәп хәрефен 50 ел буе төзәттек, ул һаман бозыла гына бара. Аны төзәтергә яңадан 50 ел вакыт кирәк...»– диләр. Мәсьәләне томаннан аерып карый белмәгән яшьләр моңа ышанырга мөмкин шул.

Дөрес, гарәп хәрефе әлегә чаклы берничә катлаулы шәкелдә йөртелү сәбәпле, басма техникасы өчен уңайсызрак иде. Ләкин аны төзәтергә керешүче, аңа бер тиен чыгым бирүче юк иде. Татар бае андый нәрсәгә акча түгәсе урынга, тәҗрибә белән сыналган толчок әйберенә, шәргый пивога акча бирүне артык күрә иде. Революциядән соң да әле күпләр аны бик җиңел төзәтеп булганлыгын, аның инде ничә тәҗрибә белән исбат ителгәнен аңларга теләмиләр, күрмәмешкә салыналар. Нух заманындагы хәрефләргә карап күзгә томан җибәрәләр.

Әле безгә ул хәрефләрне 50 ел төзәтү кая? Аңа бармак тыккан кеше дә булмады дисәң, дөресрәк булыр.

Хәреф төзәтү мәсьәләсе бездә 1911 елда гына (моннан 15 ел элек кенә) башлап күтәрелгән иде. Революциягәчә матбагадан матбагага йөреп, төзәтүгә берәүне дә күндерә алмый, пропаганда белән үтте.

Элгәрегене яртылаш киметкән хәрефләр 1925 ел (былтыр гына) Бурнашев үрнәге буенча гамәлгә куелды һәм шунда ук эшкә дә кереп киттеләр... Элгәрегене дүрт мәртәбә кыскартып, латин, рус хәрефләреннән ике өлеш уңайрак булачак баш хәрефләр бары 1921 елда гына (биш ел элек) тәҗрибәгә куеп каралдылар.

Яртылаш төзәтү – элгәреге дүрт катлаулы басма хәрефләр арасыннан урта, ахыр шәкелләрне ташлап, баш, ялгыз шәкелләрне генә алу (хәреф аралыкларын дөресләү) белән табыла. Язуның шәкеле бер дә үзгәрми, төзәлгәне дә сизелми, гарәп хәрефе белән басма эше ике өлеш җиңеләя. Гарәп хәрефләрен тулы рәвештә аңлап төзәтү, басмада фәкать баш хәрефләрне генә алу белән табыла. Монда элгәргеләрнең хәреф аралыгын билгеләүдә, хаталарын төзәтү белән бергә, кулъязма эше булган койрыклар гына ташлана. Болай иткәндә дә язуның (басылган сүзнең) таныш күренеше әллә ни үзгәрми, иялә шкәнче сирәк сүзләр дә сүз азагы гына койрыксыз кебек сизелергә мөмкин.

Бу ел баш хәрефләрне тагы да уңайлабрак гамәлгә куеп карау тәҗрибәсе булачак. Бу соңгылары техника ягыннан латин хәрефенә караганда, әлбәттә, ике мәртәбә яхшырак булачак. Аларның саны телебездәге авазлар санынча гына булачак. Булачак түгел, ул шулай булган инде. Бу үзе дә зур революция!

Шулай булгач, кая монда 50 ел төзәтү? Катлаулыны катлаусызлау, күпне азайту, авырны җиңеләйтү, яңлышны дөресләүне кем «бозу» дип әйтергә батырлык итәр икән? Әйтсә, аңа кем ышаныр икән?

## 7. Имляда революция

«50 ел» дигән сүз – хәреф мәсьәләсен имля (*орфография*) мәсьәләсе белән бутап йөретүдән килеп чыккан булса кирәк.

Хәреф, әлифба – бер телдәге авазларның язып аңлашканда күрсәтелгән билгесе дидек.

Имля – шул хәрефләрдән ничек файдалану, кайда калдырып, кайда алмаштырып, ничек тезеп язу юлы. Имля хәрефкә бәйләнмәгән. Әлифба шәп булса да – имля начар булырга, хәрефләрең начар булса да – имляң дөрес булырга мөмкин.

Әле бездә имляны чынлап бер юлга куя башлаганга да, Насыйриның «Әнмүзәҗ»ен башлангыч дип әйтсәк, бары 30 еллар гына гомер үткән. Имля хакында Уфада булган «голяма» киңәшен алсак, аңа 25 ел гына. Хәлфин, Фәезхановлар, ихтимал, имля, тел турында 50 ел борын уйлана һәм сөйләнә башлаганнардыр, ул безгә яшерен (*билгесез*).

Бездә хәреф төзәтү хәрәкәте имля төзәтү хәрәкәтеннән күпкә яшь әле. Имля мәсьәләсендә, вакыйган (*чынлыкта*), казакълар белән татарлар арасында аз гына еллар эчендә бик олы тарихи бер эш эшләнгән, зур бер революция ясалган икән!

Үзең шуның эчендә булгач белмисең. Көньяк төрекләре (*төркиләре*) безнең имля мәсьәләсендәге уңышларыбызны, нәтиҗәләрне аңлаудан да ерак торалар. Әзәрбәйҗан латинчыларының Тюркология съездында латин әлифбасына күчүгә иң зур дәлил итеп китергән нәрсәләре «млк», «хрмн» сурәтендә язылган гарәпчә сүзләр булды.

– Боларны ничек укыйбыз: «мәлик»ме, «милек»ме, «мөлек»ме, «мәләк»ме? «Хәрмән»ме, «хирмән»ме?

Алар бу сүзләрнең югарыда язылган шәкелләрендә катып калганнар. Алар бу сүзләрне үзләре сөйләгәнчә яза алудан мәхрүмнәр. Хәрефләре бар булса да, аны ишетелгән җиренә (*ишетелгәнчә*) язуны кабил түгелләр (*кабул итә алмыйлар*). Шуңа күрә алар: «Гарәп хәрефе белән дөрес имля мөмкин түгел, латинга күчәргә кирәк,»– диләр.

Бездә бу сүзләрне ишетелгәнчә яза алмаган кеше таба алмассың, казакъ, татар, үзбәк, башкорт имляларында хәзер мондый башваткыч нәрсәләр юк. Без алар килеп терәлгән күперне үтеп чыкканбыз. Без мондый сүзләрне әйтелгәнчә рәхәтләнеп яза алабыз, укый алабыз. Бездә имляда революция булып үткән.

Моннан чыккан нәтиҗә шул: «Хәреф алмаштыру мәсьәләсендә аларның позицияләре башка, төньяк төрекләренең (*төркиләрнең, ягъни татарларның*) позициясе башка.

Аларда, дөрес, имля мәсьәләсендә революция ясарга хаҗәт бар. Алар шуны эшләргә тиешләр. Алар, кыен булса да, үз туганнары булган шималь төрекләреннән (*төньяк төркиләрдән, ягъни татарлардан*) өлге алып «хрмн» сүзен ишетелгәнчә «хәрмән» яки «хирмән» сурәтендә язарга тиешләр.

Алар үз бәлаләрен безгә тагарга тиеш түгелләр. Аларга хәрефтә түгел, имляда революция кирәк.

Бу революция 30 миллионлы төрек (*төрки*) дөньясын яңадан VIII гасырга кайтып, тарихын башларга мәҗбүр итәчәк түгел.

Иртәгәдән кулда бар гарәп хәрефе белән һәр сүзне ишетелгәнчә яза башларга гына кирәк.

Атың начар булса – ашат, тәрбиялә; җирең начар булса – тиреслә, яңарт! Илең начар булса – баетырга тырыш! Аны ташлап, Америкага китмә! Хәрефең начар булса – төзәт, машинага куймаган булса – куй! Имляң начар булса, дөрес яз! «Әзергә хәзер» булып ятма!

## 8. «Метр аршинга караганда озын килә...»

Латинчы иптәшләрнең иң зур игътиразы (*дәгъвасы*) «Гарәп хәрефләре латин хәрефләренә караганда ике өлеш күбрәк урын ала. Гарәпчә белән 4–6 кегль шрифтлар ясап булмый, ясасаң – аны укырга микроскоп кирәк булачак» дигән сүзләре булыр төсле. Ләкин бу сүз дә басма эшеннән хәбәре булмаган бала-чаганы гына ышандырырга яраса ярар...

Дөресе: русчасы 10 нчы кегль, татарчасы 16 нчы кегль хәреф белән тезелгән булса, безнең хәрефләр күбрәк урын алыр. Безнең хәрефләр урыс-латин хәрефләренә караганда таррак булганга, 2–3 кегль эрерәктән җыелган булса да, икәве бер чамада урын алачак. Моңа ышаныр өчен, матбагада бер үк сүзләрне бер үк кегльдәге гарәп хәрефләре белән дә,

рус хәрефләре белән дә җыйдырып карарга мөмкин. Шулай булгач, кем хәрефе күбрәк урын ала була инде?

Мәсьәләне алай:

– Метр аршинга караганда озын килә, бәрәкәтле була, шуңар күрә мин метрлап алам... – дигән сүзләр белән бутап, укучыларны ахмак кылу ярый торган эш түгел.

Русчада ярлы студентлар игъланын гәзитәдә басып чыгара торган 4–6 нчы кегль хәрефләрне бездә дә ясарга мөмкин. Ләкин безнең хәрефләр 3–4 нче кегль эрерәктән булса да, материал бертигез керәчәк булганга, аның кирәге юк. 4–6 нчы кегль гарәп хәрефләренең төрткеләрен «борча тәпиләрен, кырмыска табаннарын» күрү өчен микроскоп кирәк булса, урыс, латин әлифбасында ике сызык уртасындагы ярыкка кысылган кандала мыекларын, үрмәкүч ауларын күрү өчен дә, әлбәттә, ике өлеш көчлерәк микроскоп кирәк булачак. Чөнки «п, и, н, ц» кебек хәрефләр ике уртага кысылган, яшерен сызыклар белән генә бер-береннән аерылалар.

Ләкин боларны күрергә хаҗәт юк. Русча да, татарча да бөтен сүз берьюлы, күрү белән укыла. Бер тоташ, бер фигура булып күренү ягыннан, әлбәттә, гарәпчә язулар өстен. Моны вак хәрефләр белән начар кәгазьгә басылган русча һәм татарча басмаларны укып карау белән аңларга мөмкин.

Кирәк булса, әлбәттә, гарәп хәрефенең төрткеләрен дә бетерергә, киметергә мөмкин булыр. Дөньяда үзгәрмәгән, төзәлмәгән бер нәрсә дә юк. Ләкин ул төзәтүләр халыкның укымышын, тиз язу, тиз укуга күнегүен югалтмыйча, сизелмичә генә гамәлгә кереп китәләр, аны 100 еллар буенча туктатып торуга сәбәп булмас. Без моны имля төзәтү тәҗрибәләрендә гамәлдә күреп уздырдык.

Әле безнең нинди эшләребез хәрефкә терәлеп тора?

Әллә язучыларыбыз гарәп хәрефе белән китапларны, мәкаләләрне вакытында язып өлгертә алмыйлармы? Әллә язылганны тезәргә, тезгәнне басарга өлгерә алмый аптырыйлармы? Татар телен ныклап гамәлгә куюга шул гарәп хәрефләре җайсызлап торамы әллә? «Кырмыска тәпиләре» күплектән әллә китапларны укый алмый утырган кешеләр бармы? Әллә кеше тавык сукыры булган кебек, инә төртерлек бер урынны гына күреп укыймы?

Әллә Шәрыктә революция ясау шуңа терәлеп торамы? Без латин хәрефен алсак, Иран, Төркия, Әфган, Һинд, Кашгар, Җунгар, Мисыр, Гарәбстан, Сүрия... илләре шуны күреп тизрәк кузгалачакларммы?

Җә, әйтегез! Әллә тагы башкалар «Совет власте + электрификация = коммунизм!» лозунгысы белән эшләп ятканда, безгә «самоопределение + латинизация = Америка» булу, төрек (*төрки*) халкының берләшүе дип саташып, үзара пычакка-пычак килеп, кыйралышып бетү яхшыракмы?

Боларның кайсысы тизрәк мәдәнияткә илтәчәк?

## 9. Латин хәрефе нигә кирәк?

Латинчы иптәшләр гарәп хәрефен каян тотып яманларга белмәсәләр дә, латин әлифбасының җитмәгән ягын бер дә телгә алмыйлар. Латин хәрефләре гүя «пешкән дә төшкән. Төрткесе дә юк аның, иртәгәдән шатырдатып язарга да, шаулатып укырга тотынырга...» кебек.

Минем тикшерүемчә, гарәп әлифбасын латин әлифбасы белән чагыштырып караудан шул нәтиҗәне алырга туры килде:

Латинда *җ, ч, х, ж, ш, щ, ө, ә, ы–э* хәрефләре бөтенләй юк.

Шулай булгач үз хәрефләребезне ташлап, латин хәрефләрен алуның ни кирәге бар?

– Съезд шулай карар иткән бит, – диләр.

Съездда мин дә булдым. Ләкин анда алай «латинга күчәргә» дигән карар чыгарылмады, бәлки: «латин хәрефләре техника ягыннан уңаерак. Бакулыларның латинны тырыштырулары бик шәп эш, ләкин аерым төрек (*төрки*) җөмһүриятләре латинны алса да, гарәпне төзәтсә дә – ирекле» дигән мәгънәдә карар чыгарылды.

Ләкин ул карарны да әле, бөтен тюркологлар, чукындырылган вак төрек (*төрки*) кабиләләреннән (чуаш, ойрат, хакас, калмык... кебекләрдән), әрмән, грузин кебек чит халыклардан килгән вәкилләр, махсус чакырылган латинчылар, 30 лап бакулылар, бергәләп, 30 миллионлы төрек (*төрки*) халкының 29 миллионы булган гарәп хәрефе белән язучыларның вәкилләренә караганда, «күпчелек» булып, көч-хәл белән генә «кабул» иттерделәр.

Безнең мең бәла белән имкян (*рөхсәт*) алып сөйләгән сүзләребезне дә газитәгә хәбәр итеп тә басып чыгармадылар. Шуңа күрә мин:

– Бик зур тарихи съезд булды. Күп гыйбрәтләр күрдек,– дисәм дә, дөмбәсләсәләр дә,– гадәләтле съезд булды,– дип әйтеп әйтә алмыйм.

Безнең татар пролетариатына хәреф алмаштыру чынлап та кирәк булган булса, ул әллә кайда, 7 диңгез, 70 дәрья аръягындагы халыкның әлифбасын түгел, үз янындагы урыс хәрефен алыр иде. Чөнки ул аны яртылаш хәзердән белә, таный; ул үзе көн-төн завод-фабрик, шахталарда урыс пролетариаты белән бергә яши. Ул белмәгәнен Иваннан да сорый алачак. Иптәше Василий да аны өйрәтә алыр. Ул инде чукындырырлар дип курыкмыйдыр, ул миссионерның кире кайтмавына ышангандыр. Тюркология съездында да профессорлары урыс хәрефенең латиннан яхшырак булуын, миссионерлар куркытмаган булса, төрек (*төрки*) халкының урыс хәрефен алу шәберәк булачак булганын ачык әйттеләр.

Шуңа күрә хәреф алмаштырырга бик теләүчеләр:

– Латинмы, урысмы? – дигән мәсьәлә турысында гына сөйләшергә тиешләр иде.

Мәсьәләне куертып, халыкның башын әйләндерергә теләмәгәндә, сал-

кын кан белән бер әмләп барын да тикшерергә, чынлап аңлашырга кирәк иде.

Гарәп хәрефе нишләп ярамый? Ярамавы ни дәрәҗәдә? Төзәлә аламы? Ничек төзәлә? Төзәлмәсә, нишләргә? Яңа әлифбага күчәргәме? Әллә бөтенләй хаҗәте юкмы? Кулда бар әлифбаны төзәтү уңаймы, яңаны алумы? Берләшәбезме, аерылабызмы? Кайсыбыз кем белән берләшәбез? Бөтен төрек (төрки) халкы бергә күчә аламы? Күчмәсә, нишлибез? Күчәргә булса, нинди әлифбага? Латинмы, урысмы?

Элгәре менә шул сөальләрнең барын да бик тирәнләп җентекләргә, аннары бергәләшеп өзәргә, шуннан соң гына бала-чаганың башын катыра башларга кирәк.

# ШӘКЛИ НИГЕЗДӘ ТАТАР ГРАММАТИКАСЫ[1]

*(Телебезне гыйльми тикшерү юлында бер тәҗрибә)*




[1] Г.Алпаровның татар телен, аның грамматикасын үстерүгә һәм камилләштерүгә юнәлдерелгән зур күләмле бу хезмәте авторның 1945 елда басылып чыккан «Сайланма хезмәтләр» (Татгосиздат, Казан) китабында тулы килеш бирелгән. Бу китапка ул үзгәрешсез кертелде. — *Ред.*

## Сүз башы

Соңгы вакытларда тел галимнәре сарыф-нәхүләрне[1] төзүдә телнең әйтелеш ягыннан күренгән тышкы фактларын гына игътибарга алып, күбрәк формаль якны нигез итеп эш күрү кирәклеген исбат итәләр. Мәктәптә тел сабакларын өйрәткәндә, телнең шәкли ягын нигез итеп алырга тиешлеге ГУС[3] программасында да әйтелгән. Урысларда шәкли нигезгә таянып төзелгән грамматикалар берсе артыннан берсе чыгып тора башлады. Татар теленең сарыф-нәхүләрен шәкли яктан карап тикшерү юлында әлегә кадәр бездә журнал битләрендә күренгән берничә мәкаләдән башка бернәрсә дә юк иде. Әлегә чаклы чыккан сарыф-нәхүләребездә телебезнең тышкы әйтелеш ягыннан булган фактлары белән эчке мәгънә ягы бер-беренә катнаштырып йөртелә иде.

Бездә сарыф-нәхүләрне тышкы фактларга гына нигезләп төзү мөмкинме? Шәкли якны нигез иткәндә, грамматикабыз ничек булачак?

Бу мәсьәләгә җавап бирү өчен, телебезнең грамматикасын гамәли рәвештә шәкли нигезгә каратып төзеп күрергә кирәк була. Менә шул кирәкне игътибарга алып, кыскача бер конспект рәвешендә, шәкли нигездә татар теленең грамматикасын төзеп күрсәтергә булдым.

1924 елда шәкли нигез буенча минем якын катнашым белән «Төрекмән теленең грамматикасы» төзелгән һәм быел Уфада «төрек телләренең грамматика нигезләре» турында бер доклад укылган иде. Шул тәҗрибәләргә таянып, әзерлек сай, каләм кытыршы булуга карамастан, телебезне тикшерүчеләргә, укытучыларга бирәр эшкә ярар дип, җыелган материалларны китап итеп чыгарырга уйладым. Тикшереп табылган нәрсәләрнең барын да бер тәртипкә салып, оештырып бетерә дә алмадым. Шуңа күрә, аңланып һәм әйтелеп җитмәгән урыннары күп булыр.

Шәкли грамматикабыз бабында татар дөньясында бу китап әле беренче тәҗрибә генә булганлыктан, бу турыда телчеләребезнең фикерен ишетү бик матлуп (кирәк), әлбәттә.

*Гыйбадулла Алпаров, 1925 ел, Уфа*

## 2 НЧЕ БАСМАГА

Беренче басмасы чыкканнан соң, бер еллык тәҗрибә нәтиҗәсендә бу китап яңадан төзәтелде. Грамматикага турыдан-туры бәйләнеше булмаган урыннары төшерелде. Бераз сипләштереп, атамалары Гыйльми үзәк тарафыннан кабул ителгәнчә үзгәртелеп, икенче мәртәбә басарга бирелде.

*Г.Алпаров, 1926 ел, Казан*

---

[1] Сарыф-нәху — грамматика (*сарыф* — морфология; *нәху* — синтаксис).

[2] ГУС — Государств. Ученый Совет = Дәүләт Гыйльми Советы (ул елларда РСФСР Наркомпросы каршында шундый бер учреждение бар иде).

## Беренче бүлек

# КЕРЕШ

### 1. ТЕЛ ҺӘМ СӨЙЛӘШҮ

Кешеләрнең, сөйләү әгъзалары[1] аркылы үз ирекләре белән төрле авазлар чыгарып, аңлашуларына «тел» дип, «сөйләшү» дип әйтелә. Тел аркасында кешеләр бер-берсе белән аңлаша, белмәгәнен өйрәнә, хәтта шул тел белән уйлый да.

Кешеләрдә тел иҗтимагый сәбәпләр аркылы туып, аларның эш мөнәсәбәтләре вакытында бер-берсе белән аңлашу коралы булып хезмәт итә. Тел – ул, һәркемнең үзе белән бергә үсеп, бергә яши торган аерылмас бер сыйфаты. Тел безгә һәртөрле авазлар, сүзләр, җөмләләр рәвешендә һәм шулардан аңланган мәгънәләр рәвешендә атадан балага, буыннан буынга күчеп килә. Кешеләр бала чагында ук сөйләшергә өйрәнә башлыйлар. Шуңа күрә һәркем, һәр халык үз телен якын күреп «ана теле» дип атый.

Бер халыкның ана теле шул халыкның бөтен тарихы, бөтен тормышы, аңы һәм дөньяга карашы белән бик нык бәйләнгән. Тормыш, аң үзгәрү белән бергә тел дә үзгәрә: аның авазлары да, сүзләре дә, сүзләрнең төрләнүләре, мәгънәләре дә бер туктамый үзгәреп, алмашып, артып, кимеп, яңарып тора.

Шушы үзгәрүләр аркасында, борын бер тел белән сөйләшкән кешеләрнең сөйләшүләрендә аерымлыклар туа, бу аерымлыклар тормыш үзгәргән саен, заман үткән саен артып бара-бара, бер телдән төрле шиваләр[1], алардан аерым телләр мәйданга килә.

Мәсәлән, бер Урал-Алтай тамырыннан чыгып, төрле үзгәрешләр нәтиҗәсендә төрек, монгол, манжур, фин, самоед[1] телләре туган. Шулардан, ялгыз бер төрек тармагыннан үсеп, хәзерге уйгур, үзбәк, кыргыз, казах, төрекмән, анатули (госманлы), татар, башкорт, чуваш һәм башка бик күп аерым төрек телләре килеп чыккан. Боларның һәрберсе тагы әллә ничәшәр аерым шиваләргә, аерым сөйләшләргә бүленеп беткән. Бу аерылышларга, әлбәттә, бу халыкларның үз тормышлары, аларның элгәре бергә катнашып торган җирләреннән ерак китеп, бер-береннән аерым тора башлаулары сәбәп булган.

Киләчәк заманда, кешеләрнең үзара катнашулары, алыш-бирешләре, бергәләп эшләүләре көчәйгән, арткан саен, аларның телләре дә яңадан

---

[1] Сөйләү әгъзалары — сөйләү органнары.
[2] Шиваләр — диалектлар.
[3] Самоедлар — ненецлар.

берләшүгә, якынлашуга таба барачак. Мәдәният[1], гыйлем, һөнәр аркасында уртак сүзләр көннән-көн күбәеп, бөтен телләр үзара берләшүгә таба хәрәкәт итәчәк.

Кыскасы, тел, тормышның үзе кебек, бер туктамый үзгәреп тора торган җанлы бер хадисәдән[2] санала. Һәр тел үзгәреп, яшәп торган тарихи бер телнең хәзерге дәвергә килеп ирешкән вакытлы бер күренешеннән гыйбарәт. Шулай да, ул тел бөтенләй үк тормыш артыннан калышмыйча, аның белән янәшә, тигез үзгәреп бара алмый. Телнең һәрбер күренешендә, әйтелешендә һәм мәгънәсендә борынгылык, тарихи эз, тарихи фактлар сакланып килә. Мәсәлән, безнең телебездә тышкы әйтелеш ягыннан сүзләребезнең калын яки нечкә булулары, ялганмалык табигате, тезмәләрендәге тәртип кебек күренешләре борыннан бирле сакланып килгән, ныгып урнашкан фактлардан санала. Мәгънә ягыннан, мәсәлән, *йокы килә, кояш бата, ычкылык тота, томау төште, бизгәк тотты, бумасы тота, ут алды, теле ачылды, казан аскан, котым очты...* кебек тәгъбирләр, әлбәттә, борынгы карашлар, иске идеологияләрне күрсәтеп торалар.

Бу сүзләргә карап, борынгы бабаларыбызның йокыны килә торган бер нәрсә итеп, кояшны бата дип, очкылык, томау, бизгәк, бума кебек нәрсәләрне кешегә кайдандыр килеп төшә торган, аны тота, буа торган бер көч итеп таныганлыкларын, утны исә янган әйберне алып китә торган алла дип, баланың теле югары бер көч тарафыннан ачыла дип ышанганлыкларын, борын заманда казанны югары асып аш пешергәнлекләрен, кеше эчендә ниндидер «кот» дигән һәм очып йөри торган бер нәрсә (җан) бар дип ышанганлыкларын аңлавы кыен түгел. Без хәзер бу сүзләрне ата-анабыздан өйрәнгәнчә, ләкин борынгы мәгънәләрен уйламастан сөйлибез.

Сөйләшү төрлечә булырга мөмкин. Кул, аяк, йөз хәрәкәтләре белән (мәсәлән, телсезләрдәге кебек) аңлашуны да сөйләшү дип әйтәләр. Шагыйрьләр, әдипләр[3] завод кычкыртуын, шау-шулы тормышны, төрле табигать күренешләрен дә нәрсәдер сөйли дип йөртәләр. Ләкин без монда авыздан чыккан төрле тавышлар белән төрле сүзләр әйтеп аңлашуны, тел белән сөйләшүне генә тикшерәбез.

Соң без ничек сөйләшәбез?

Сөйләшкән чакта кеше үпкәсенә тын алып, шул тынны авыз аркылы үткәрә. Тын бугаздан үтешли, тавыш коралын дерелдәтеп, тавыш чыгарта. Авыз эчендә тел, кешенең үз теләге белән, бик җитез эшләргә күнеккән төрле хәрәкәтләр ясап, иреннәр бер-беренә тиеп я башкача рәвешләргә кереп, бугаздан чыккан тавышны төрләндерә, аерым авазлар хасил итә; шул авазларны бер-беренә төрлечә кушып, мәгънәле сүзләр ясый, төрле сүзләрне бергә тезеп, уй-фикерләрне сөйләп бирә. Авыздан чыккан авазлар

[1] Мәдәният — культура.
[2] Хадисә — күренеш (явление).
[3] Әдипләр — әдәбиятчылар, язучылар.

һава дулкыннары аркылы тыңлаучының колак барабанын селкетә. Аның миенә төрлечә тәэсир итеп, ишетеп аңлавына сәбәп була. Сөйләгәндә кешенең әллә никадәр нервлары, әллә нихәтле мускуллары эшли.

Тел – табигатьтә булган күренешләрнең иң гаҗәп, иң тирән, иң катлаулы булганы. Ләкин кеше, гадәттә, үз ана телендә ничек сөйләшкәнен бөтен тулылыгы белән сизеп аңлап бетерә алмый, үз теленең табигатен төшенеп сөйләми. Чит бер телдә сөйләргә туры килсә генә, кеше авазларны ничек үзгәртеп, сүзләрне ничек төрләндереп, аларны бер-берсенә ничек бәйләнештереп әйткәнен төшенә, ул аңа дикъкать итә, шул турыдагы тәҗрибәләрен башкаларга сөйли, аны үз ана теленә чагыштырып карый башлый. Шушы тәҗрибә, шушы чагыштырып караулардан бара-бара тел гыйлеме – лингвистика дигән зур бер гыйлем вөҗүткә килгән[1] дә.

## 2. ТЕЛ ГЫЙЛЕМНӘРЕ[2]

Гомумән тел гыйлеме бик борынгы гыйлемнәрдән санала. Кытай, юнан[3], гарәп, латин телләре элек-электән үк тикшерелеп, китапларга язылган. Соңгы гасырларда телләрне тикшерү, аларның табигатен өйрәнү тагы да ныграк көчәеп киткән. Тел гыйлеменең фәнни бер төскә керүенә йөз елдан артык гомер үтмәгән әле. Шулай булса да, ул инде артык киңәеп, әллә ничаклы аерым фәннәргә дә бүленеп өлгергән.

Тел гыйлеменең иң иртә мәйданга килгән бер бүлеге – грамматика, гарәпчә әйткәндә, «сарыф-нәху» .

Моннан башка тагын тел гыйлеменең телдәге сүзләрнең мәгънә үзгәрешләрен, эчке аңлашу ягын тикшергән бүлеге – семасиология, телдәге сүз байлыгын җыйнап, һәр сүзнең аерым мәгънәләрен ачып күрсәткән бүлеге – лексикология, сүз һәм сүз кисәкләренең тарихи килеп чыгышларын тикшергән бүлеге – этимология бар.

Грамматика үзе берничә төрле була. Бер телнең үткән бер заманда булган хәлен өйрәткәне – тарихи грамматика, төрле тел һәм шивәләрне тикшереп, бер телнең башка телләргә, шивәләргә якынлык һәм ераклыкларын ачып күрсәткәне – чагыштырмалы грамматика дип атала. Билгесез әйтелгән грамматикадан бер телнең соңгы, хәзерге көндә сөйләнеп торган хәлен өйрәтә торган фәнне аңларга кирәк.

## 3. ГРАММАТИКАНЫҢ БҮЛЕКЛӘРЕ

Грамматика үзе өч зур бүлеккә аерылып өйрәнелә: 1) фонетика (аваз гыйлеме), 2) морфология (сарыф), 3) синтаксис (нәху).

---

[1] Вөҗүткә килгән — барлыкка килгән, туган.
[2] Тел гыйлемнәре — лингвистик фәннәр.
[3] Юнан — грек.

Грамматиканың фәкать авазларны, аларның телебездә үзгәреп, нинди кануннар белән тезелеп әйтелүләрен тикшерә торган бүлеге – фонетика; аерым сүзләрнең нинди кушымчалар белән ничек төрләнешләрен тикшергән бүлеге – морфология (сарыф); ниһаять, сүзләрнең бергә тезелеп сөйләнгән чагындагы тышкы күренешләрен өйрәткән бүлеге – синтаксис (нәху) дип атала.

Бу өч бүлек үзара бер-берсенә бик нык бәйләнешкән; аларны бер-берсенә катнаштырмыйча, аерым көйләренчә, тикшерүе дә, өйрәнүе дә кыен. Чөнки телдә җөмлә кисәге булмаган бер сүзнең төрләнүе, төрләнүгә бәйләнмәгән аваз үзгәреше юк диярлек. Шуңа күрә грамматикада бу өч бүлекнең кайсын элгәре өйрәнергә, аларны аерым-аерыммы, әллә барын да бергә катнаштырып тикшерергәме – дигән сөальләрнең (сорауларның) тууы бик табигый.

Аерым сүзне үсеп утырган бер агачка охшатсак, сүз тезмәләре булган җөмләләрне бакчага я урманга, авазларны исә шул агачның яфракларына охшатырга мөмкин. Аерым сүз, мәгънәсе ягыннан, кешегә ачык мәгълүм булган аерым әйберләр, аерым билгеләр белән дә бәйләнгән. Сөйләүченең аңында иң элек сурәтләнгән, барлыгы иң ачык сизелгән нәрсә – сүз, аннары сүз тезмәләре булып, сизелүе иң ерак булганы – авазлар.

Аерым сүз – телнең мәгънә бирәмлеге, җөмлә – шул сүзнең җыентыгы, авазлар – аның иң вак элементы. Шуңа күрә югары мәктәпләрдә грамматиканы авазлардан башлап – сүзләргә, аннары сүз тезмәләренә күчү тәртибендә өйрәтү уңайлы дип танылган булса да, мәктәпләрдә иң элек сүзләрдән башлау, аннары сөйләмнәргә, иң соңыннан авазларга күчү яки, телнең табигый төзелешенә ияртеп, барын бергә кушып, бер-беренә бәйләнешле итеп өйрәтү артыграк булса кирәк.

## 4. ГРАММАТИКА НИГЕЗЛӘРЕ ТУРЫНДА

Һәрбер сөйләнгән нәрсәнең ике ягы бар: 1) тышкы ягы, 2) эчке ягы. Сөйләшкәндә, тел белән әйтелеп, колакка ишетелгән авазлар, сүзләр, аларның төрләре, тәртипләре, үзгәрешләре телнең тышкы ягы санала; шул авазлар тезмәсеннән аңланган мәгънә, уй һәм төшенчәләр аның эчке ягы була.

Грамматика телнең кайсы ягын өйрәтә? Ул тышкы як белән эчке якның кайсына нигезләнеп төзелергә тиеш? Бу турыда тел галимнәре арасында беркадәр бәхәсләр бара. Аларның кайсы берәүләре, сарыф-нәхүләрне эчке мәгънә ягына нигезләп, мантыйкый әсаста[1] төзергә кирәк, ди. Кайсылары, киресенчә, фәкать телнең тышкы күренешләрен генә өйрәтергә, икенче төрле әйткәндә, грамматикаларны саф шәкли нигездә генә төзергә тиеш,

[1] Мантыйкый әсаста — логик принципта, мәгънәне нигез итеп.

ди. Кайберәүләре икәвен дә бергә кушып өйрәтүне мәгъкуль күрә. Бусын шәкли-мантыйкый әсас[1] дип йөртәләр.

Гомумән, грамматиканың нигезләрен билгеләү мәсьәләсе – телнең табигатен ныклап тикшергәннең соңында гына чишелүе мөмкин булган яхшы ук тирән гыйльми бер мәсьәлә. Шулай да, хәзер инде грамматикаларны төзүдә мантыйкый җәһәтне генә нигез итеп эш күрүнең ярамаганлыгы ачык аңлашылды. Хәзерге көндә телчеләр арасында мозакәрәләр[2] саф шәкли җәһәт белән, шәкли-мантыйкый әсасның кайсын алу тирәсендәрәк бара.

Телнең мәгънә ягы катгый кануннар астына алынуы бик кыен, артык тирән. Күп вакыт сөйләүченең үзенә, аның аңына, табигатенә карап үзгәреп, төрләнеп тора торган була. Бер үк сүз төрле кешенең телендә, төрле урында әйтелүенә карап, төрле мәгънәләр аңлатырга мөмкин. Шуңа күрә катгый бер фән төсен алган грамматика аны тикшереп тора алмый. Ул күбрәк матди якка таяна, телдә ныгып урнашкан тышкы фактлар белән эш күрә. Телнең мәгънә ягыннан булган табигатен тикшерү – семасиология эше.

Икенче яктан, телнең тышкы фактлары аңа читтән килеп йөкләнгән бер нәрсә түгел. Тел башта ук шуның белән туган, шулар белән яшәп килә. Телдә тышкы бер төр белән билгеләнмәгән эчке бер мәгънә юк булса кирәк. Чөнки башында ничә төрле уй булса, аларны сөйләп, әйтеп бирергә шундый ук тел дә булырга тиеш. Шуңа күрә грамматикаларны тышкы шәкли якка нигезләп төзү бик мөмкин, тиеше дә шул булса кирәк.

Шуңа күрә безгә дә телебезнең грамматикасын (сарыф-нәхүен) төзегәндә, аның табигать һәм кануннарын өйрәнгәндә, фәкать тышкы әйтелеш ягын – матди, шәкли якны гына күз уңында тотып эш күрергә, грамматиканы телнең мәгънә ягы белән бутамаска тиеш булып чыга.

Телебезнең тышкы әйтелеше ягыннан тикшерерлек берәр факт, бер хәл бар икән – сарыф-нәхүләребездә аны калдырмый тикшерергә, шундый тышкы бер күренеш юк икән – аны грамматикабыздан чыгарып ташларга тиеш була.

Дөрес, кайбер урыннарга мәгънә ягына да кагылмый булмас. Чөнки телнең тышкы әйтелеш ягы белән эчке мәгънә ягы бер-берсенә бик нык бәйләнешкән була. Шулай да аны сарыф-нәхүнең мөндәриҗәсеннән[3] гыйбарәт бер нәрсә итеп карамаска, аны тышкы – матди якка ияртеп кенә өйрәтергә тиеш була.

Шуңа күрә без грамматиканы «бер телнең авазлар тезмәсеннән гыйбарәт булган тышкы күренешләрен, аваз һәм сүзләрнең сөйләшкән чакта ничек

---

[1] Шәкли-мантыйкый әсас — формаль-логик принцип.
[2] Мозакәрәләр — аңлашулар.
[3] Мөндәриҗә — эчтәлек.

үзгәреп, ни рәвешле төзелешләрен тикшерә торган фән» дип тәгъриф итәбез[1].

## 5. ТЕЛЕБЕЗНЕҢ ТЫШКЫ ФАКТЛАРЫ

Грамматиканың эченә кермәстән, элгәре бу урында телебезнең тышкы фактлары – шәкли җәһәте нәрсәләрдән гыйбарәт булганлыгын кыскача гына күрсәтеп үтәргә туры килә.

Төрек телләренең, шул җөмләдән һәм безнең телебезнең, шәкли ягы, әйтелеш ягыннан булган фактлары, түбәндәге нәрсәләрдән гыйбарәт: 1) ялганмалык, 2) тәртип, 3) кабатлау, 4) сингармонизм, 5) басым, 6) аһәң – тон.

1. **Ялганмалык.** Бөтен төрек телләрендә булган сүзләргә дикъкать белән карасак, без аларның берничә кисәктән кушылып ясалганын күрәбез. Мәсәлән: *эшче, юлчы, тимерче* дигән сүзләрнең азагында бер-беренә охшаган *чы–че* кисәкләре, башында *эш, юл, тимер* дигән кисәкләре бар. *Алган, барган, булган..., юллык, башлык, тимерлек, алдым, булдым, килдем, юлдан, авылдан...* кебек сүзләрнең *дә ган, лык-лек, дым-дем, дан* кисәкләрен кушып ясалганлыгы аерым-ачык күренеп тора.

Шул кисәкләргә карап, без сүзләрне иң элек ике кисәккә аерабыз: 1) тамыр (төп), 2) кушымча.

Тамыр кисәк (корень) – сүзнең һәрвакыт алдан әйтелә торган һәм кушымчасыннан башка әйтелгәндә дә куелган мәгънәсен югалтмый торган өлеше: *эш, юл, тимер, ал, бул...* кебекләр.

Кушымча (аффикс) – һәрвакыт тамырның азагына кушылып, аңа ияртеп әйтелә торган, үз башына аерым торганда мәгънәсе булмаган кисәк: *че-чы, ла-лә, лык, лык-лек, ды-де, дан-дән, дыр-дер, са-сә...* кебекләр.

Безнең телебездә сүзләр күп вакыт шулай төрле кисәкләрдән ялганып ясалган була. Ялганган чакта сүзнең тамыр кисәге дә, кушымчалары да үзгәрмиләр, бәлки төрле кисәкләр бер-беренә янәшә килеп тезеләләр генә. Кушымчаларның тамырга килеп ябышканлыгы аерым-ачык беленеп тора. Аларны аерым алып күрсәтергә дә уңай була. Мәсәлән: *килештерде – кил + еш + тер + де, аерылмаганлыкларыннан – аер + ыл + ма + ган + лык + лар + ын + нан.*

Дөньяда бер дә кушымчаланмый торган (мәсәлән, кытай теле) яки тамыр сүзгә авазлар аралаштырып кына (мәсәлән, гарәп теле) сөйләнә торган телләр дә бар.

Бездә сүзләрнең шулай кушымчаланып әйтелү табигатенә ялганмалык дип әйтәләр. Менә шул ялганмалык табигате телебезнең әйтелеш ягыннан булган бер төре, тышкы бер күренеше була. Бер тамыр сүз

[1]Тәгъриф итәбез — билгелибез.

ничә төрле кушымча белән әйтелсә, шул хәтле төрдә килгән була. Шуның белән бергә, грамматикада аның кушымчасыз әйтелгән төре дә үзенә аерым бер күренеш итеп саналырга тиеш.

Искәрмә. Бездә сүзләрнең кушымчалар рәтендә йөргән ярдәмлекләр белән кушылып яки ярдәмлексез әйтелүләре дә аерым бер тышкы күренештән саналырга мөмкин. Чөнки ярдәмлекләр дә, бер яктан караганда, тамыр (төп) сүзләрнең гармониясенә ияреп өлгермәгән кушымчалардан гыйбарәт. Һәм киресенчә, кушымчаларның үзләренә дә, төп сүзнең гармониясенә ияреп, аерым сүз булу табигатен югалткан ярдәмлекләр дип карарга мөмкин. Мәсәлән: *ат белән килде, атсыз килде, ул безгә киләчәк, ул безгә киләчәк түгел*... дигәндә *белән, түгел* ярдәмлекләрен кушып яки кушмый әйтелгән сүзләр дә үзенә күрә тышкы бер төрләрдән саналалар.

**2. Тәртип.** Сүзләрне кушымчалану төрләренә карап кына белү дә җитешми. Бездә сүзләрнең кушымчалы төрләре бик аз. Руслардагы кебек, бездә сүзләрнең җенес аермасы белән (ирлек, хатынлык, урталык булып) төрләнүләре дә юк. Шуңа күрә кайвакыт безнең телебездә сүзләрнең мәгънәгә бәйләнгән тышкы төре кушымча белән дә, ярдәмлекләр белән дә беленмәскә мөмкин. Бу вакыт аны без сүз тезмәсендәге тәртибенә, җөмләдә торган урыннарына карап танырга тиеш булабыз. Шуңа күрә безнең җөмләләребездә сүзләрнең нинди тәртиптә тезелеп әйтелүләре дә бик әһәмиятле урын тота, чөнки җөмләдә сүзнең тәртибен үзгәртү белән күп вакыт әйтергә теләнгән мәгънә дә үзгәреп китүчән була. Мәсәлән: *аю адәм ашаган* яки *адәм аю ашаган* дигән җөмләләрнең беренчесендә без, сүзләрнең тәртибенә карап, ашаучы аю, ашалган нәрсә адәм икәнне, икенчесендә моның киресе булганын аңлыйбыз. Сүз тәртибе әһәмиятле бер нәрсә булмаса, без боларда мәгънә аермасын да сизмәс идек.

Димәк, җөмләләрдә аерым сүзнең торган урыны, тәртибе дә бездә үзенә башка тышкы бер төр, бер күренеш саналырга, бөтенләй кушымчаланмый әйтелгән сүзләрдә дә шушы төр бар дип каралырга тиеш була.

**3. Кабатлау.** Сүзләрнең тышкы төре бездә, кушымчалардан һәм тәртиптән башка, бер сүзне бөтен көенчә я аның бер кисәген тәкрар әйтү-кабатлау белән дә ясалырга мөмкин. Мәсәлән, сыйфат һәм рәвеш сүзләре күп вакыт шулай тәкрар әйтү белән ясалалар: *укый-укый, килә-килә, тора-тора, күп-күп, озын-озын*... кебек.

Сүзнең бер кисәген кайталап, аерым төр ясау бездә артыклык сыйфатларында очрый. Мәсәлән: *кып-кызыл, ап-ак, кум-кук, туп-туры*... Болар да төбендә бөтен сүзне тәкрар әйтүдән үзгәреп килеп чыкканнар. Аларның мәгънәсе, истигъмалы[1] да шуны күрсәтеп тора. Аларның бездә тулы кайталау төрендә йөртелүләре дә бар. Мәсәлән: *күп-күп кабып ашый, чын-чын күңелемнән.., озын-озын бүрәнәләр*...

**4. Сингармонизм.** Бездә күп вакыт аваздаш сүзләр бер-берсеннән ка-

---

[1]Истигъмалы — кулланылышы.

лынлык-нечкәлек белән генә дә аерылалар. Бездә бер сүзнең бөтен авазлары, кушымчалары белән бергә үк, я бөтенләй калын гына, я бөтенләй нечкә генә әйтелү гадәте бар. Башка телләрдәге кебек, бездә бер сүзнең эчендәге авазларның бер калын, бер нечкә булып, боргаланып әйтелүләре юк. Мәсәлән: *кеше, кешедән, кешеләргә* (бу сүзләр бөтенләй нечкә генә әйтелә); *ал, алам, алырлар, алганлыктан* (болары бөтенләй калын гына әйтеләләр).

*Бул* (калын), *бүл* (нечкә), *оч, өч, тоз, төз, кыр, кер...* кебек сүзләр бер-берсеннән бары шул калынлык, нечкәлекләре белән генә аерылалар.

Менә шушы сингармонизм табигате дә бездә сүзләрнең тышкы әйтелеш ягыннан булган аерым бер төре дип каралырга тиеш.

5. **Басым.** Бер үк авазлар, бер үк гармония белән әйтелгән сүзләр күп вакыт бездә үзләренең басымнары (ударение) белән аерылалар. Басым сүзнең мәгълүм урыннардагы сузык бер авазын көчлерәк чыгарып әйтүдән гыйбарәт. Мәсәлән: *ба́тыр, баты́р, а́лма, алма́, ка́ра, кара́...* Бу икешәр иҗекле аваздаш һәм барсы да калын әйтелә торган сүзләрнең беренчеләрендә басым беренче иҗектә, алар – фигыльләр. Икенчеләрендә басым икенче иҗектәге сузык авазда, болары – исемнәр.

Бер иҗекле аваздаш сүзләр дә, ялгыз әйтелгән чакларында, күбрәк шушы басым белән бер-береннән аерылалар. Мәсәлән: *а́л, ал, о́ч, оч, тө́ш, төш, кү́й, куй, кү́н, кун, кы́з, кыз...* Боларның беренчеләре басым белән, икенчеләре басымсыз (яки аз басым белән) әйтеләләр. Басым белән әйтелгәннәре – фигыльләр, басымсызлары – исемнәр. Мондый сүзләр безнең телебездә байтак күп кенә. Аларны җөмлә эчендә без тәртипләре белән дә аера алабыз.

6. **Аһәң, тыныш.** Җөмләдә сүзләрнең нинди көй, нинди аһәң белән әйтелүләре, сүзне туктатып, тыныш ясалулар да телебезнең тышкы күренешләреннән бер төре дип саналырга тиеш. Күп вакыт без җөмләнең кисәкләрен, сорау, өндәү, хәбәр, боерык җөмләләрен, оешма, кушма җөмләләрне, аларның баш һәм иярчен булуларын нинди аһәң (тон) һәм нинди тыныш (пауза) белән әйтелүләренә карап аера алабыз.

Югарыда әйтелгән шушы һәртөрле тышкы күренешләр телебезнең грамматика фактлары дип әйтеләләр.

Телне төрле тарихи тәэсирләрдән, башка телләргә йотылып, тиз генә үзгәреп китүдән саклап тоткан көч һәм факторларның иң зурысы да шушы телебездә ныгып урнашкан грамматика фактларыдыр.

Менә грамматика (сарыф-нәхү) дигән фән шушы тышкы фактлар белән эш күрергә, шуларның канун һәм табигатьләрен ачып күрсәтергә тиеш.

## Икенче бүлек

# ТЕЛЕБЕЗНЕҢ ФОНЕТИКАСЫ

---

## ФОНЕТИКА, ХӘРЕФ, ИМЛЯ[1]

Грамматиканың сөйләшкән чакта авыздан чыгарылган авазларны, аларның әйтелеш ягыннан булган табигать һәм үзгәрешләрен, кыскасы, сүзләрнең нинди вак элементлардан гыйбарәт булганлыгын тикшерә торган бүлеге ф о н е т и к а (аваз гыйлеме) дип атала.

Фонетиканың мәгънәгә бөтенләй катнашы юк. Ул – грамматиканың саф шәкли бер бүлеге. Шуңа күрә фонетикада тышкы якны нигез итәргәме, әллә эчке якнымы дигән бәхәсләр булырга да мөмкин түгел.

Фонетикада аңлашылмау ике нәрсәдән чыгарга мөмкин: берсе авазларның тарихын, борынгы үзгәрешләрен тикшерүдән, икенчесе аваз белән хәрефне, әйтелеш белән язылышны бер-берсе белән саташтырудан.

Хәзерге грамматиканың бер бүлеге булган фонетикада авазларның бары хәзерге дәвердәге, җанлы телдәге хәлләре, җанлы сүз эчендәге авазларның табигате, кушымчалар белән төрләнгән чактагы аваз үзгәрешләре генә тикшерелергә тиеш.

Фонетиканы хәреф, язу, имля дигән нәрсә белән саташтырырга ярамый, чөнки хәреф, язу, имля – ул, авазның, сүз һәм сөйләшүнең кәгазьгә төшерелгән тупас сурәтләре генә. Начар сурәт белән әйбернең чын үзе арасында байтак кына аермалар булырга мөмкин.

Хәреф – телдәге авазның язудагы билгесе.

Әлифба – бер телдәге авазларга куелган бөтен хәрефләр тезмәсе.

Имля – язганда әлифбадан ничек файдалану юллары.

## 1. АВАЗЛАРНЫҢ ТАБИГАТЕ

### Сөйләү әгъзалары

Безнең телебездә нинди һәм ничә аваз бар? Алар ничек әйтеләләр? Гомумән авазларны, аларның табигатен өйрәнү, аңлау өчен, иң элгәре сөйләү әгъзаларының эшләре белән таныш булырга кирәк була. Чөнки телдәге авазлар сөйләү әгъзаларының катлаулы хезмәтләре һәм төрле хәрәкәтләре аркылы хасил булалар.

Авазларның ясалу урыны, ясалу рәвеше һәм ишетелү рәвеше бар. Сөйләү әгъзаларының төзелеше һәм аларның эшләре белән таныш булмый торып, авазларның табигатен өйрәнү мөмкин түгел.

---

[1] И м л я — орфография.

Сөйләү әгъзалары ике төрле: актив әгъзалар, пассив әгъзалар. Актив әгъзалар: 1) сулыш коралы, 2) тавыш коралы, 3) кече тел (йомшак аңкау), 4) ияк, 5) тел, 6) иреннәр.

Пассив әгъзалар: борын, каты аңкау, урт һәм тешләр.

1. **Сулыш коралы** булып, күкрәк читләре эченә урнашкан үпкәләр һәм күкрәк пәрдәсе, кабырга итләре хезмәт итә. Үпкәләр сөйләү, әйтү өчен кирәк булган һава хәрәкәтен ясый. Сөйләшкән чактагы сулыш белән сөйләшми торгандагы сулыш алуны бер-береннән аерып белергә кирәк: сөйләшмәгәндә сулыш алу белән сулыш бирү икәве бертигез вакыт эчендәрәк ясала; сөйләшкән чакта исә сулыш алу тиз һәм берьюлырак булып, сулыш бирү озаграк һәм үпкәләрдән килгән һава, әйтелгән нәрсәләрне аерым сүзләргә, сүзләрне аерым иҗекләргә бүлеп әйтү өчен, бүленеп-бүленеп чыга. Аерым сүз һәм иҗекләренең басым белән яки басымсыз әйтелүләренә карап, һаваның чыгу көче һәм дәвамы да төрлечә була. Төрле телдә сүзләрнең басымы төрле урында булганга, һаваның бүленеп чыгарылуы төрлечәрәк була. Һава хәрәкәте – сөйләүнең иң төп шарты. Сөйләү күбесенчә сулыш биргәндә хасил була.

2. **Бугазда тавыш коралы** дигән бер әгъза бар. Тавыш коралы – тын юлының югарыгы башында урнашкан, сыбызгы яки гармонь теле кебек, ике яктан килеп кысылган ярылар. Болар, һава үткәндә, калтырап тавыш бирәләр.

Тавыш коралы ике хәлдә була: 1) сөйләшмәгән чакта яки *ш, т, ф* кебек, яңгыравыксыз авазларны әйткәндә, тавыш ярылары бер-береннән ераклашып, ачылып тора. Шуңа күрә үпкәләрдән килгән һава аларны калтыратмыйча иркен үтә. Тавыш чыкмый. Бу вакыт колакка ишетелгән тавыш бугаздан түгел, бәлки тел, иреннәр арасыннан шуып үткән һавадан килә; 2) *а, у, з, л, м* кебек яңгыравыклы авазларны әйткәндә, тавыш ярылары бер-беренә якынлашып, тартылып тора. Шуңа күрә үпкәләрдән килгән һава аларга басып, гармонь теле кебек калтырарга, тавыш чыгарырга сәбәп була.

Сузык авазлар бары да яңгыравыклы була, чөнки алар һәрвакыт тавыш коралының калтыравы белән, бугаздан килгән ачык тавыш белән генә әйтеләләр. Башка әгъзалар берсе дә эшләми диярлек. Тартык авазларда исә башка әгъзалар да катнаша. Алар төрлечә: *р, л, м, н, ң, й* авазлары һәрвакыт тавыш белән, башкалары тавышлы да, тавышсыз да әйтеләләр. Шуңа карап, болары пар-пар киләләр.

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Тавышлы, яки яңгыравыклы авазлар | б | д | з | җ | ж | г | ع[1] | в | һ |
| Тавышсыз, яки яңгыравыксыз авазлар | т | т | с | ш | ч | к | ق | ф | х |

ع, ق — *дага, багана, игътибар, мәгънә, кул, аяк, нәкъ, тәкъдим* сүзләрендәге кебек, калын әйтелешле *г, к* авазларының гарәп алифбасындагы билгеләре — хәрефләре. — *Ред.*

Сүз арасында яңгыравыклы авазлар белән яңгыравыксызлар янәшә килгәндә, күп вакыт бу парлы авазлар бер-берсенә үзгәрәләр. Моңа фонетикада «йотылу» дип әйтелә.

3. **Кече тел.** Тавыш коралыннан өстә бугаз куышлыгы бар. Бу куышлык алдан авыз куышлыгына, өстән борын куышлыгына тоташа. Борын белән авыз куышлы арасында югарыдан түбәнгә кече тел (йомшак аңкау) асылынып тора. Кече тел, теләгән очракта, күтәрелеп, борын юлын каплый да үпкәләрдән килгән һаваны авыздан үткәрә яки, түбән төшеп, һаваны борыннан чыгара. Күп авазлар үзара шушы кече тел хезмәте белән генә бер-береннән аерылалар. Мәсәлән:

1 { иреннәрне кысып, һава борыннан үткәрелгәндә – *м* авазы,
иреннәрне кысып, һава авыздан үткәрелгәндә – *б* авазы,

2 { тел очын аңкауга кысып, һава борыннан үткәрелгәндә – *н* авазы,
тел очын аңкауга кысып, һава авыздан үткәрелгәндә – *д* авазы,

3 { тел уртасын аңкауга кысып, һава борыннан үткәрелгәндә – *ң* авазы,
тел уртасын аңкауга кысып, һава авыздан үткәрелгәндә – *к* авазы

хасил була. Димәк, бу авазлар, кече тел хезмәтенә карап, кушар авазлар булып чыгалар.

Бу авазларны борын яки авыз авазлары дип йөртү аларның ишетү ягына карап әйтелгән. Физиология ягыннан алар кече тел төшеп яки күтәрелеп әйтелгән авазлар була.

4. **Ияк** сузык авазларны әйткәндә, түбәнрәк төшеп, авыз ачыклыгын киңәйтә. Тартык авазларны әйткәндә күтәрелеп, авыз ачыклыгын киметә. Иякнең ачылу дәрәҗәсе, сузык авазларның төренә карап, төрлечәрәк була:

*а* авазын әйткәндә, ияк күбрәк ачыла, *о, ә, ө* авазларын әйткәндә уртачарак, *у, ү, и, ы, э* авазларын әйткәндә азрак ачыла. Сузыклар басым белән әйтелгән чагында басымсыз әйтелүләреннән күбрәк ачыла. Калын авазларны әйткәндә дә ияк, нечкә авазларга караганда, күбрәк ачыла. Шулай итеп, сөйләшкән чакта ияк, чәйнәгәндәге кебек һәрвакыт хәрәкәтләнеп тора.

5. **Тел** – әйтү әгъзаларының иң хәрәкәтлесе. Телнең, төбенә караганда, алгы очы сөйләшкәндә тагы да күбрәк хәрәкәтләр ясый. Тел үзенең хәрәкәте белән, пассив әгъзалардан аңкау, теш ите һәм югарыгы тешләргә тиеп, әйтергә теләнгән авазларны бөтенләй эшләп житкереп чыгара. Мәсәлән:

– тел очы, өске тешләргә тиеп, *т, д* авазлары ясый;

– тел очы, өске теш итләренә тиеп, *с, з, р, л, н* авазларын ясый;

– тел очы аңкауга тиюдән *җ, ч, ш, ж* авазлары ясала;

– тел уртасы аңкауга якынлашудан *й, г, ң* авазлары хасил була;

– тел төбе йомшак аңкауга якынлашканда, ق, ع (*кул, дага* сүзләрендәге кебек, калын *к*, калын *г*), *х* авазлары чыга.

Авазларның калын яки нечкә әйтелүләре дә телнең хәрәкәте белән була. Калын авазларны әйткәндә, телнең очы түбәнрәк төшеп, тел төбе йомшак аңкауга якынлашып күтәрелгән була. Нечкә авазларда тел төбе түбән төшеп, тел уртасы һәм очы алга, каты аңкауга күтәрелгән була. Төрек телләрендәге сингармонизм табигате буенча, бөтен сүзләрнең я калын гына, я нечкә генә авазлар белән әйтелүе телнең шушы әйтелгән торышны, сүз әйтеп беткәнче, үзгәртергә теләмәвеннән, ялкаулыгыннан килә.

**6. Иреннәр** үзләренең хәрәкәте белән бер-беренә тиеп, якынлашып, бөрешеп яки төрлечә ачылып, *м, б, п, ф, в, у, ү, о, ө* авазларының эшләнеп чыгуына сәбәп булалар. Шуңа күрә бу авазларга ирен авазлары дип әйтәләр.

Тел һәм ирен авазлары арасындагы аерымлыклар, тавыш коралы һәм рече телнең катнашыннан башка, аларның кысылу, тию, якынлашуларында булган аермалардан, әйтелү рәвешендәге төрлелектән дә килә.

Бу әгъзалар бик нык кысылып, һаваның (тавышның) авыздан үтмичә, борыннан үтүе белән әйтелгәннәре (*м, н, ң*) «борын авазлары» дип, әйтү әгъзаларының кинәт кысылуы яки кинәт ачылуы белән әйтелгәннәре (ق, *к, д, т, б, п*) «шартлаулы авазлар» дип, әйтү әгъзаларының якынлашуы белән, ике арадан һава ышкылып үтәрлек кенә юл калдырып әйтелгәннәре (*h, х,* ڽ, *г, ж, ш, й, җ, ч, з, с, ф, в*) «өрелмәле авазлар» дип аталалар (1 табл.)[1].

**Авазларның чыганаклары (артикуляциясе)**

*1 таблица*

| Аваз билгесе | Тавыш коралы | Рече тел | Ияк | Тел төбе | Тел уртасы | Тел очы | | | Иреннәр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | *аңкауга* | *уртка* | *тешкә* | |
| ء (һәмзә[2]) | *калтырый* | *күтәрелә* | – | – | – | – | – | – | *ачык* |
| *а* | ” | ” | *төшә* | *күтәрелә* | *төшә* | – | – | – | *ачыла* |
| *ә* | ” | ” | *аз* ” | *төшә* | *күтәрелә* | – | – | – | *аз* |
| *у* | ” | ” | ” | *күтәрелә* | *төшә* | – | – | – | *бөрелә* |
| *ү* | ” | ” | ” | *төшә* | *күтәрелә* | – | – | – | ” |

*(дәвамы алдагы биттә)*

[1] *Таблица* сүзе һәм аның тәртип саны редактор тарафыннан кертелде.

[2] (һәмзә) — تأمین тәэмин, تأثیر (тәэсир), مائمای (маэмай), مأیوس (мәэюс) сүзләрендәге өченче авазның гарәп әлифбасындагы билгесе һәм исеме.— *Ред.*

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| о | ” | ” | ” | күтә-релә | төшә | – | – | – | бүл-тәя |
| ө | ” | ” | ” | төшә | күтә-релә | – | – | – | ” |
| и | ” | ” | ” | ” | якын-лаша | – | – | – | җәе-лә |
| э | ” | ” | ” | – | – | – | – | – | – |
| ы | ” | ” | ” | – | – | – | – | – | – |
| б | ” | ” | күтә-релә | – | – | – | – | – | тиешә |
| п | калты-рамый | ” | ” | – | төр-лечә | – | – | тия | ” |
| т | ” | ” | ” | – | ” | – | – | – | ачык |
| җ | калты-рый | ” | ” | – | ” | тия | – | – | ” |
| ч | калты-рамый | ” | ” | – | ” | – | – | – | ” |
| х | ” | ” | ” | якын-лаша | ” | – | – | – | ” |
| д | калты-рый | ” | ” | – | ” | – | – | тия | ” |
| р | ” | ” | ” | – | ” | – | тигә-ли | – | ” |
| з | ” | ” | ” | – | ” | – | тия | – | ” |
| ж | ” | ” | ” | – | ” | якын-лаша | – | – | ” |
| с | калты-рамый | ” | ” | – | ” | – | тия | – | ” |
| ш | ” | ” | ” | – | ” | якын-лаша | – | – | ” |
| ф | ” | ” | ” | – | – | – | – | – | якын-лаша |
| ع | калты-рый | ” | ” | якын-лаша | төшә | – | – | – | ачык |
| ق | калты-рамый | ” | ” | тия | ” | – | – | – | ” |
| к | калты-рамый | күтә-релә | күтә-релә | – | тия | – | – | – | ачык |
| г | калты-рый | ” | ” | – | якын-лаша | – | – | – | ” |

(Ахыры алдагы биттә)

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *ң* | ” | *төшә* | ” | *кысыла* | *тәрләчә* | – | – | – | ” |
| *л* | ” | *күтәреләә* | ” | – | – | – | *тия* | – | ” |
| *м* | ” | ” | ” | – | – | – | – | – | *кысыла* |
| *н* | ” | ” | ” | – | – | – | *кысыла* | – | *ачык* |
| *в* | ” | *күтәреләә* | ” | – | – | – | – | – | *якынлаша* |
| *һ* | ” | ” | ” | – | – | – | – | – | *ачык* |
| *й* | ” | ” | ” | – | – | *якынлаша* | – | – | ” |

## Телебездәге авазларның төркемнәре

Телебездәге авазларны, әйтелешләрендәге аермаларына карап, түбәндәге төркемнәргә аерырга мөмкин.

Иякнең ачылу һәм ябылуына карап, бездә барлык авазлар ике төркем була.

1) **сузык авазлар**: *ا (а), ە (ә), ۇ (ы, э), ێ (и, ый), و (у, ү), ۇ (о, ө)*[1].

2) **тартык авазлар**: ء (һәмзә), *һ, х, г, к, ع, ق, ң, й ж, җ, ч, р, л, н, з, с, т, д, м, б, п, ф, в.* Тавыш коралының калтырау, калтырамавына карап:

1) **яңгыравыклы авазлар**: *а (э), ы (э), и, у (ү), о (ө),* ء (һәмзә), *һ, г,* (ع), *ң, ж, й, җ, р, л, н, з, д, м, б, в;*

2) **яңгыравыксыз авазлар**: *х, к* (ق), *ш, ч, с, т, п, ф.*

Кече телнең күтәрелү, төшүенә карап:

**борын авазлары**: *м, н, ң;*

**авыз авазлары**: *н, м, ң* авазларыннан башкалары – бары да.

Телнең аңкауга, тешләргә, иреннең иренгә якынлашу, тию, кысылуларына карап:

**өрелмәле авазлар** (якынлашу белән): *һ, х, г* (ع), *й, ж, ш, җ, ч, з, с, ф, в;*

**шартлаулы авазлар** (тиеп алу белән): *к* (ق), *т, д, б, п;*

**йөзмәле авазлар**: *р, л* (*р* авазы телнең теш итенә бер тиеп, бер тимичә, кабат-кабат әйтелүеннән, *л* авазы тел очы тиеп, ике як чите тимичә, шуннан һава үткәрелү белән ясала).

Иреннәр, тел очы, тел уртасы нык кысылып, һава борыннан үткәрелү белән борын авазлары – *м, н, ң* – ясалалар.

---

[1] Яңалифкә күчкәнче, татар телендәге барлык сузыклар шушы алты хәреф (ا, ە, , ۇ,ێ, و) белән генә күрсәтелә иде: *а-ә* дән башка сузыклар калын һәм нечкә парлары өчен берәр генә кулланыла иде. Мәсәлән: بولنشه (бүлешә), بولنشا (булыша), تورا (төрә), كيله (килә), سيلا (сыйла).

Болардан башка, тел уртасының аңкауга якынлашу яки ераклашуына карап, бөтен авазлар нечкә яисә калын булып, икешәр төрле әйтеләләр.

Димәк, безнең телебездә, калын һәм нечкә әйтелүләрен игътибарга алмаганда, барлыгы 28 аваз бар. Аларны авыздан чыгышларына карап тезгәндә, түбәндәгечә булып чыгалар: *а (ә), ы (э), и, у (ү), о (ө),* ء (һәмзә), *һ, х, г* (ع), *к* (ق), *ң, й, ж, ш, җ, ч, р, л, к, з, с, д, т, м, б, п, ф, в.* Боларның баштагы бишәве – сузыклар, калганнары – тартык авазлар.

Боларның һәрберсе калын да, нечкә *дә* булып әйтелүләрен игътибарга алганда, безнең телебездә барсы 56 аваз булырга туры килә (сузыклар 10, тартыклар 46 аваз)[1]. (2 табл.)

### Тартык авазлар чыганагы

*2 таблица*

| Авазларның чыккан урыннары | Яңгыравыклы авазлар | | | | Яңгыравыксыз авазлар | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | борын авазлары | шума авазлар | өрелмәле | шартлаулы | өрелмәле | шартлаулы |
| бугаздан | – | – | *һ* | *(һәмзә)* | – | – |
| тел артыннан | *ң* | – | *г* (ع) | – | *х* | *к*(ق) |
| тел уртасыннан | – | – | *й, ж, җ* | – | *ш, ч* | – |
| тел очыннан | *н* | *р, л* | *з* | *д* | *с* | *т* |
| иреннән | *м* | – | *в* | *б* | *ф* | *п* |

### Сузык авазларның табигате

Татар телендә төп сузык авазлар бишәү: ا, ىٖ, ىٔ, و, ۇ. Болар, калын һәм нечкә әйтелүләренә карап, һәрберсе икешәр төрле була.

**Калын сузыклар**: *а, ы, (ый), у, о,* (ا, ىٖ, ىٔ, و, ۇ).

**Нечкә сузыклар**: *ә, э, и, ү, ө* (ە, ىٖ, ىٔ, و, ۇ).

Боларны авыздан чыккан урыннарына, әйтелешләренә карап, түбәндәгечә тезеп күрсәтергә мөмкин (3 табл.):

*3 таблица*

| | Авыздан | | | Иреннән | |
|---|---|---|---|---|---|
| | авызны нык ачып | тел иректе | телне аңкауга якынлаштырып | иреннәрне бүлтәйтеп | иреннәрне бөреп |
| тел төбеннән (калыннар) | *а* | *ы* | *(ый)* | *о* | *у* |
| тел очыннан (нечкәләр) | *ә* | *э* | *и* | *ө* | *ү* |

[1] *Тонна, фронт, эра, эпоха, цех, цирк* сүзләрендәге кебек, хәзерге татар теленә кереп һәм урнашып бара торган кинрәк әйтелешле *о, э,* шулай ук африкат *ц* авазлары бу исәпкә кертелмәгән. Боларны да санаганда, хәзерге татар әдәби телендәге авазлар саны 60 ка җитә. — *Ред.*

Болар арасыннан бөтен төрек телләрендә уртак булганнары *а, э, (е), о.*

*О–ө* авазлары төп сүзнең беренче иҗегендә генә булып, үзеннән соң килгән *а, ы, э* авазларына да тәэсир итә, аларны «ө»ләндерә.

*У, и* сузыклары татар һәм башкортлардан башка төреклэрдә, *О, э* авазларына якынрак әйтелә. (Бездә дә алар, ачык *у, и* гә караганда, аз гына *о, э* гә авышлырак.)

*О–ө, у–ү, и* сузыклары кушымчаларда булмыйлар.

Кушымчаларда *а–э, ы–э* авазлары (калын һәм нечкәләре) калмый йөри.

Димәк, бездә иң күп йөргән сузыклар *а–ә, и–э* була.

*А* авазы сүз башында бездә *о* га авышыбрак әйтелә. *У (ү), ә, о (ө)* авазлары – арткы авазлар, *а, ы* – уртангы авазлар, *и, э* – алгы авазлар санала.

*А, и, у, ү* авазлары, башкаларга караганда озаграк сузып әйтелгәнгә күрә, «озын авазлар»дан, *о, ө, ы, э* авазлары «кыска авазлар»дан саналалар.

Сузык авазлар, иҗекнең азагында килгәндә, басымлы урыннарда тагын да ныграк сузып әйтеләләр. Иҗек уртасында һәм басымсыз булганда, бары да бераз кыскара төшәләр. Бигрәк тә *ы–э* авазлары ябык иҗектә һәм басымсыз булганда бөтенләй кыскарып, юк диярлек дәрәҗәгә киләләр.

Татар телендә гомумән бөтен авазлар ялкаурак әйтеләләр. Сузык авазлардан, мәсәлән, *а, у, и* авазлары рус телендәге *а, у, и* авазлары кадәр ачык итеп, көч белән әйтелмиләр. Шуңа күрә, русча сөйләшкәндә, без бу авазларны русча итеп җиткереп әйтә алмыйчарак мәшәкатьләнәбез.

## Кайбер тартык авазларның табигате

Тартык авазлардан *б, п, ж, ч, д, т, з, с* авазлары бездә рус телендәгеләргә караганда, ялкаурак, йомшаграк әйтеләләр. Мәсәлән, русларда *ч* авазы *тьшь* кебек, бездә исә ялгыз *шь* кебек әйтелә. Шуның өчен руслар безнең авыздан әйтелгән *пычак, печән* кебек сүзләрне *пысак, песән* рәвешендәрәк ишетәләр. Безгә бу сүзләрне алардан *ч* белән әйттерү өчен *пытчак, петчән* дип әйтеп бирергә туры килә.

Сүз башындагы *й* авазы *җ* һәм *й* авазларының уртасындарак әйтелгән бер аваз булып чыга. *Юк* сүзе *җук, юк* булып ишетелергә мөмкин. Җөмлә эчендә *й* белән башланган сүзләр янәшә килгәндә, без аларның берсен *җ*, берсен *й* авазына алмаштырыбрак әйтәбез: *җир йиләге, йир җиләге; җакын йиргә, якын җиргә; җаңгыр ява, яңгыр җава...* кебек[1].

Русларда нечкә *д*, нечкә *т* авазлары *дзь, тсь* булыбрак әйтеләләр; бездә исә алар калында да, нечкәдә дә ялгыз *д, т* булып кына әйтеләләр.

---

[1] Хәзерге орфографиядә болар *җир җиләге, якын җиргә, яңгыр ява* рәвешендә биреләләр һәм язылганча ук әйтелүләре дә орфоэпик норма итеп санала. — *Ред.*

Иҗек азакларында *р, л, с* авазлары *т, д* белән кушылып, икәве берьюлы әйтелә алалар: *арт, корт, ялт, балк, аст – өст, көртлек, алтмыш...* кебек.

## СИНГАРМОНИЗМ

Телебезнең иң төп табигатеннән берсе, авазлар янәшә тезелеп сүзләр хасил иткән чагында, аларның бары да калынлык, нечкәлектә бер-берсенә ярашып әйтелүләредер. Авазларның калынлык һәм нечкәлеге, тамыр кисәкләрдә, төп сүзләрдә генә калмыйча, кушымчаларга да күчә. Төп сүзнең азагына ничаклы, ничә рәт кушымча тоташса да, алар бары да калынлык, нечкәлектә төп сүзнең әйтелешенә ияраләр. Мәсәлән: *ал, алды, алдылар, алдыгызмы, алганнарыгыздан; кил, килде, килделәр, килдегезме, килгәннәрегездән...* кебек.

Бер сүздәге авазларның калынлык, нечкәлектә бер-беренә ярашып әйтелүенә «сингармонизм кануны» дип әйтәләр.

Сингармонизм нәрсә ул? Бу канун буенча сүзләрнең калын яки нечкә әйтелүләре берәр төрле авазга иярүдән киләме, әллә ул бөтен сүзнең бер табигатеме? Бу мәсьәләне ачу өчен бу урында беркадәр аңлатма ясап китәргә туры килә.

Сүзләрнең калынлык, нечкәлекләре, бер сүзне әйткән чакта тел ни рәвештә торса, сүзне әйтеп бетергәнгә чаклы шул торышын үзгәртми саклавыннан –ялкаулыгыннан килә.

Калын сүзне әйткәндә, ияк аз гына ачыла төшеп, тел арткарак тартыла. Тел очы турысында бушлык күбрәк калдырылып әйтелә. Нечкә сүзне әйткәндә, ияк ябыла төшеп, тел алгарак килә. Тел төбе белән йомшак аңкау арасында ачыклык күбрәк калдырылып әйтелә. Бөтен кушымчалары белән бөтен сүзне әйтеп бетерми торып, тел үзенең шул торышын үзгәртми. Менә бездә сингармонизм табигате шуннан гыйбарәт.

### Сингармонизмда телнең торышы

Бездә сингармонизм – бөтен сүзнең бөтен торышынча алынгандагы бер табигате ул. Сүзләрнең калынлык, нечкәлек табигате бездә аның мәгънәсе белән, сөйләүченең башындагы тәсаувыр белән бәйләнгән. Чөнки зур һәм эре нәрсәләр бездә күбрәк вакыт калын әйтелүчән, кечкенә һәм вак нәрсәләр күбрәк нечкә әйтелүчән була. Калынлык, нечкәлек сүзнең башындагы яки тамырындагы бер авазга (я бер хәрефкә) карап йөрми. Сөйләүче, бер сүзне әйтергә теләп, авызын ача башлаганда ук (экскурсия чагында), авыз эчендә үзенең телен, үзенең тәсаувырына мовафыйк рәвештә, я калынга, я нечкәгә иpләп куйган була; гүя телгә: «Син, тел, бу сүзне менә шул көе торып кына әйт, урыныңнан күп кузгалма!» – дип, боерык бирелә.

Бу табигать төрек телләреннән башка телләрдә күренми. Гарәп, рус һәм башкаларда сингармонизм юк. Аларда бер сүзне әйтеп бетергәнче, тел әллә ничә төрле хәлгә кереп, үзгәреп тора. Шуңа күрә аларда бер сүзнең бераз авазы калын, бераз авазы нечкә булып әйтелергә мөмкин, һәм ул аларда шулай да.

Төрек телләрен тикшерүче кайбер рус, Европа галимнәре (тюркологлар) бу сингармонизм табигатен, «төрек телләрендә сузык авазлар гармониясеннән (гармония гласных) гыйбарәт» дип аңлаганнар, шулай дип язалар да. Хәлбуки, бездә сузык авазлар гына түгел, тартык авазлар да калынлык, нечкәлектә бер-беренә охшашалар, барсы бергә гармония хасил итәләр. Дөресе, бездә бу канунны «гармония звуков в прогрессивном порядке – бөтен авазларның уңайга таба бер-беренә ярашуы» дип әйтергә, шул мәгънәдә генә аңларга тиеш була.

*Билбау, китап, калəм, бәгърем...* кебек, берничә сүзләргә карап, бездә сингармонизм юк икән, дип куярга ярамый. Дөрес, бездә кушма сүзләрдә тулы гармония булып җитә алмый. Ләкин бу вакытта да ул бер иҗектән дә кими алмый, ягъни гармония иң кимендә бер иҗектә тулы көенчә кала. Читтән кергән *калəм, китап, кадер...* кебек сүзләрне без иске мәдрәсәләрдә өйрәнү, махсус күнегү сәбәпле генә әйтергә өйрәнгәнбез; югыйсә аларны авыл кешеләре һәм балалар *кәләм, китәп, кәдер...* яки *калам, кыйтап, кадыр...* дип әйтәләр.

*Билбау, актирәк, Гөлбану...* кебек үз сүзләребезне без, гармония ягыннан *бил + бау, ак + тирәк, Гөл + бану...* дигән аерым сүзләргә караган кебек карарга тиеш булабыз. Әйтелеш ягыннан тел аларны бер сүз дип белми, алар тел өчен *син бар, мә ал, тор эшлә...* дигән сүзләрне әйтү белән бер.

Ләкин без, руслардагы кебек, бер иҗектәге авазларның берсен калын, берсен нечкә итеп әйтә алмыйбыз, *пыль, пил, мать, мят...* кебек бөгелешләр бездә юк. Димәк, бездә сингармонизмның киме бер иҗектә, күбе бөтен кушымчалары белән бергә бөтен сүздә була дип аңларга тиеш.

Искәрмә. Телчеләребез арасында калынлык, нечкәлектә сузык авазлар асыл булып, тартык авазлар фәкать шуларга ияреп кенә калын, я нечкә булып әйтеләләр, дигән бер караш бар. Бу фикер безгә бүтән халыклардан килеп кергән бер аңлашылмаудан гыйбарәт. Рус, Европа телләрендәге сүзләр иҗек саен бер калынаеп, бер нечкәреп әйтелү гадәте булганга күрә, алар саннары аз булган сузык авазларның калын, нечкәләренә аерым хәрефләр алып, тартык авазларны шуңа ияртергә мәҗбүр булганнар. Хәлбуки, аларда да моны табигый дип булмый. Чөнки бер иҗектәге бөтен тартык авазлар сузык авазга ияреп бетә алмый. Мәсәлән, русчада *няня, дядю* сурәтендә язылган сүзләр рус фонетикасында *ньанья, дьадьу* дан гыйбарәт икәнлеге күрсәтелеп тора; *пыль, пил* сүзләрендәге *л* авазлары да сузык авазларның гармониясенә бөтенләй каршы әйтелгән.

Бездә гармония бөтен сүздә булып, аерым – ялгыз авазлар үз торышынча калын да, нечкә дә була алмаганга, бу ияреш дигән фикер безнең телебезгә бигрәк

тә туры килми. Бездә мәгълүм бер мәгънәгә куелган бер сүзнең гармониясенә ул сүзнең бөтен авазлары иярә – дисәң, дөресрәк булачак.

Кушымчаларның төп сүз гармониясенә ияреп-иярмәвендә башка төрек телләрендә азмы-күпме аерымлыклар булырга мөмкин. Кушымчаның төп гармониягә ияреп бетмәве аның бөтенләй кушымчага әйләнеп житмәгәнлеген күрсәтә. Мәсәлән, кыргыз телендә үткән заман исем фигыльләренең юклык төре *ләк* кисәге кушып әйтелә. Бу кисәк һәрвакыт нечкә генә әйтелә, төп сүзнең гармониясенә иярми: *киләләк, алаләк, булаләк (килмәгән, алмаган, булмаган)* кебек.

Көньяк төрек телләрендә хәзерге заман хәбәр фигыльләренең беренче рәттәге заман төрлекләре (*юр, яр, я, дур*...), төп сүзнең гармониясенә иярмичә, һәрвакыт калын гына әйтеләләр: *алыюр, гәлеюрыз, гәлеярын, белеярләр*[1]... кебек.

Казах телендә *гана (гына)* кушымчасы һәрвакыт калын, *неке, деке* кушымчасы һәрвакыт нечкә булып әйтеләләр. Татар, башкорт телләрендә андый аерымлыклар юк.

## Бездә сузык авазлар ничә?

Авазлардагы калынлык, нечкәлек бер ялгыз авазның ике төрле әйтелешле генәме, әллә ике авазның бер-берсенә охшашуымы? Әлбәттә, бер авазның ике төрле әйтелеше генә.

Бездә сөйләүченең психологиясендә, телебезнең морфологиясендә нигез булган авазлар төбендә калын да, нечкә дә булмаган берәр генә аваз булып, аларның һәрберсе, сингармонизм табигатенә ияреп, я калын, я нечкә – икешәр төрдә әйтеләләр, ягъни бер төп аваз ике оттенокта йөри. Бу табигать – бөтен авазлар өчен дә уртак, ныклы бер канун. Тартык авазлар да, сузык авазлар да шул канунга буйсыналар.

Сүзләрнең сингармонизм һәм кушылмалык табигате бездә авазларның төбендә калын да, нечкә дә булмаган берәр төрдә генә булуын мәҗбүри итә. Шунлыктан сузык авазларны да бездә ун түгел, бәлки биш дип белергә һәм шул биш сузык аваз, сүзләрнең гармониясенә ияреп, калын да, нечкә дә әйтелергә мөмкин дип карарга тиеш була.

## Сузыклар башында «ء» (һәмзә) бармы?

Сүз башында сузык авазлар алдыннан «ء» (борынрак – «ا») хәрефенең язылып йөрүе күп телчеләребезнең, сузык авазлар башында бер «ء» (һәмзә) авазы бар, дигән бер фикердә булуларына сәбәп булган.

[1] Бу сүзләрнең биредә күрсәтелгән язылышы ул халыкларның хәзерге орфографиясен һәм хәзерге орфоэпиясен якынча гына чагылдыра. Китапның башка урыннарында да төрки телләргә карата ясалган чагыштыруларда сүзләрнең хәзерге орфография һәи орфоэпиясе күп очракларда якынча гына бирелә.— *Ред.*

Тик торган җирдән сүз башлап әйткәндә, сузыклар алдыннан бу «ء» (һәмзә) ишетелгән кебек булса да, ике сүз уртасында аның юклыгы ачык билгеле. Мәсәлән:

مین ئول کشئنی کوره ئالمادم (мин ул кешене күрә алмадым);

ئیرته ئیسمده . کیج ئیسمده (иртә исемдә, кич исемдә);

ئول بر ئایٔ ئوچن ئاقچا توله مهگه ن (ул бер ай өчен акча түләмәгән) сурәтендә язылган сүзләр «مینول کشئنی کورالمادم، ئیرتیسمده کچیسمده. ئول برایوچنئاقجا توله مهگه ن» рәвешендә «ء» (һәмзә)сез сөйләнәләр.

Сузыклар алдыннан сүз башында «ء» (һәмзә) авазы бар дип карау – безгә язу белән бергә гарәпләрдән килеп кергән бер нәрсә генә. Язуда йөртелүгә карап, аны бездә бар дип әйтергә юл юк[1].

## Сузык *у(ү), и* авазлары турында

Бездә бервакыт сузык *у(ү), и* авазлары кушмамы (дифтонгмы), гадиме? дигән бер мәсьәлә күтәрелеп үткән иде. Яңарак укучыларга мәсьәләне аңлатыр өчен бу турыда бераз тукталып китәргә туры килә.

*Су, бу, алу, ки, ти* кебек, *у, и* авазына беткән сүзләрнең азагына *э (е) – ы* белән башланган кушымчалар килгәндә, *сувы, алувына, кием (кийэм), тиеш (тийэш)* кебек, берәр *в, й* авазы арттырып әйтелгән кебек була. Башка авазлардан соң *ә (е) – ы* кушымчалары килгәндә, мондый яңа аваз арту юк. Мәсәлән: *ат – аты, кирәк – кирәге...*

Моның сәбәбен тикшереп караганда, югарыдагы сүзләрнең борынгы телебездә *суб, буг, алгу, тиг* булып әйтелгәнлеге, соңыннан бу авазларның *в, й* гә әйләнеп, андагы *у, и* авазларының *ы–э (е)* авазларына әйләнеп киткәнлеге мәгълүм була. Ябык иҗек булганда, бу *ы–э (е)* авазларының барлыгы ачык сизелми; азагына сузык аваз кушылганда, иҗек ачылу белән, ул *ы–э (е)* нең барлыгы бик ачык беленә. Шуңа күрә боларның дөрес әйтелеше *у(ү)+в*, яки *и+й* белән түгел, бәлки *сывы, алывына, тэйэш* рәвешендә була.

*Димәк, су, ти* сүзләренең азагындагы *у, и* асылда сузык түгел, бәлки тартык *в, й* дән гыйбарәт, *ыв, эй* дән кыскарган катлаулы аваз була.

*Ләкин кул, куй, йук (юк), тик, кил, син* кебек, сүз уртасындагы *у, и* авазлары бездә ялгыз авазлар – сузык авазлар. Бу соңгылары – башка төрек телләрендә *о, э (е)* тавышы белән әйтелгән сузык авазлар. Алар татар, башкорт телләрендә *дә*, рус телендәге кебек, саф *у, и* авазы белән

---

[1] Сүз башында килгән сузыклар 1921 нче елларга кадәр آ, او, او, ایٖ рәвешендә, 1921 елдан соң, яңалифкә күчкәнче , ئه, ئن, ئو, ئو, ئي рәвешендә язылып килделәр. Мәсәлән: آل – ئال (ал), ار – ئنر – ئه‌ر (р-ыр әр), اوقا – ئوقا (ука), اوته – ئوته (үтә), اوتا – ئوتا (ота), اوره – ئوره (өрә), ایر – ئیر (ир). Шунлыктан бу сузыклар гади сузыклар түгел, бәлки ике аваздан торган сузыклар (дифтонг) дип уйлаучылар бар иде. Шулай итеп, сүз башындагы бер сузык аваз ике билге белән күрсәтелә иде. Алпаров бу карашның бары тик гарәп хәрефләре йогынтысы, язудагы күренеш белән генә туганлыгын һәм ялгыш караш икәнлеген күрсәтә.— *Ред.*

әйтелмиләр, *о, э (е)* гә якын әйтеләләр. Чын *у, и* бездә саннары бик аз гына булган *су, бу, ти, ки, и...* кебек сүз азакларында гына, *алу, бирү, бирми..* кебек кушымчаларда гына очрыйлар. Алар да булса, асылда бәсит *у-и* булмыйча, *ыв-эв (ев), эй (ей)* дигән катлаулы авазлардан гыйбарәт. Моны телебезнең морфология төзелеше (кушымчалар җәдвәлен, аларның калыпларын карагыз,) бик ачык күрсәтеп тора. Димәк, татар телендәге *мый-ми, лый-ли, дый-ди ...* кушымчалары башка шивәләрдәге *май-мәй, вай-дәй, лай-ләй* кушымчаларындагы *а-ә* авазы урынына *ы-э (е)* белән әйтелгән *мый-мей, дый-дей, лый-лей ...* төреннән; *көри, төзи, бирми, эшли сүзләре, укый, ашый, карый, бармый* сүзләре кебек *ук, көрей, төзей, бирмей, эшлей ...* дән гыйбарәт була.

Кыскасы, бездә тулы *у (ү), и* авазлары юк. Сүз азагында тулы *у (ү), и* булып ишетелгән авазлар ябык иҗектәге *ыв-эв (ев), эй (ей)* дән гыйбарәт. Иҗек ачылганда, аларның барлыгы ачык беленә. Әмма төп сүз уртасында *у-ү, и* гә якын авазлар бездә бар, алар катлаулы түгел, ялгыз сузыклар.

## А - ә, ق - ک (к) һәм ع - گ (г) авазлары турында

Сингармонизм кануны буенча төрек телләрендә бөтен авазлар һичбер аермасыз һәрберсе калын да, нечкә дә әйтелеп йөри. Шуңа күрә бездә һәр аваз төп әйтелештә булып, ялгыз нечкә генә яки фәкать калын гына әйтелеп йөргән авазлар бездә булмый[1].

*А* белән *ә*, ق белән ک, ع белән گ[2] авазларының калын һәм нечкәләренә аерым хәрефләр куелып, башкаларның икәвенә бер генә хәреф йөртелүе – безгә гарәптән килеп кергән бер гадәт кенә.

Шуңа күрә күп телчеләребез аларны бездә икешәр мөстәкыйль авазлар дип уйлыйлар. Ләкин телебезнең морфология төзелешенә игътибар күзен төшергәндә, без аларның икәве дә бер үк канунга ияргән торган, бер үк хезмәтне үти торган, тик калынлык, нечкәлек белән генә алмашып әйтелә торган төп бер аваз икәнен күрәчәкбез. Бу төп авазларның, арадан берничәсен генә аерып, икешәр хәреф белән йөртү телебезнең механикасына зыян китереп, авыр бер йөк булып тора. *А* белән *ә*, ق белән ک, ع белән گ авазларының да калын, нечкә әйтелгәненә язуларыбызда икәвенә бер генә хәреф булырга тиеш иде. Телебезнең табигате, әлбәттә, шуны тели. Дөрес, боларның әйтелгән урыннарында аз гына аерымлык бар, ләкин алар сөйләүче аңында, телнең психологиясендә икәве бер аваз. Бездә бөтен авазларның да калынлык, нечкәлекләрендә (мәхрәҗләрендә) азрак аерма булырга мөмкин. Мәсәлән, *ң-нь, ш-шь,*

---

[1] Татар, башкорт телләреннән башкаларда бу канунга иярмәгән бер аермалык бар. Ул да булса — алардагы *е* авазы. Аларда бу аваз фәкать нечкә генә булып йөри. Бездә бу аваз юк, аның урынына без сузык *и* йөртәбез: *кил, мин...* . — *Автор.*

[2] ق–ک кул, кил сүзләрендәге калын һәм нечкә к, ع,گ – *богау, игәү* сүзләрендәге калын һәм нечкә *г* авазларының гарәп алфавитындагы билгеләре. — *Ред.*

*з-зь, р-рь*... авазларының калыннарын нечкәләренә чагыштырып карагыз. Игътибарга алынган нәрсә телебезнең морфология төзелешендә берлек булырга тиеш. Бу берлек аларның төп бер аваз булуын күрсәтә.

Бу мәсьәләдә аңлашылмау хәреф-имля мәсьәләсен һәм фонетиканы бер-берсе белән буташтырудан килеп чыккан булса кирәк.Ләкин бездә, рус телендәге кебек, ике уртада әйтелгән *к, г* авазлары юк. Руслардан кергән сүзләрдә без бу авазларны калын иҗектә ق, ع авазы белән, нечкә иҗекләрдәгеләрен *к, г* авазы белән әйтәбез. Әлифбабызда ق, ع хәрефләре ташланмаса, әлбәттә, чит сүзләрдә дә аларны йөртү тиешле[1].

## 2. АВАЗЛАРНЫҢ ҮЗГӘРЕШЕ

Телдә һичбер аваз аерым әйтелми, башка авазлар белән бергә кушылып йөри. Шуңа күрә авазлар һәрвакыт бер генә төсле әйтелмиләр, күршесенә ияреп, бераз үзгәрәләр.

Сүз эчендә авазлар бер-беренә янәшә килгәндә, төп сүзгә кушымчалар тоташкан чакта, фонетика кануннары буенча, бер-беренә төрлечә тәэсир итеп үзгәрешүләр була.

Янәшә авазларның бер-беренә тәэсире «йотылу» – ассимиляция дип атала. Авазларның йотылуы күбрәк сөйләү әгъзаларының ялкаулыгыннан, югарыгы авазны әйткән чакта сөйләү әгъзасы ни хәлдә булса, соңгы авазны әйткәндә дә шул торышын саклап, үзгәртергә теләмәвеннән килә. Шунлыктан югарыгы аваз түбәнге авазның үзгәреп әйтелүенә сәбәп була. Мондый йотылышка уңайга таба йотылу дип әйтелә. Мәсәлән, *китде, шундан, аңла*... сүзләрендә *д, л* авазлары уңайга йотылып әйтелә: *китте, шуннан, аңна.*

Кайвакыт йотылу сөйләү әгъзаларының түбәндәге авазларны әйтергә алдан хәзерләнеп торуыннан да килә. Бу вакыт соң килгән авазлар югарыгы авазның үзгәреп әйтелүенә сәбәп була. Мондый үзгәрешкә кирегә таба йотылу дип әйтелә: *бу+көн – бөген (бүген), бу+ел – быел, килгәнләр – килгәлләр (килгәннәр)*... Бу мисалларда *у, н* авазлары түбәнге аваздан йотылганнар.

Авазларның йотылуы актив сөйләү әгъзаларының тартуы белән була:

1) тавыш коралы тартуы,
2) кече тел тартуы,
3) тел төбе тартуы,
4) тел очы тартуы (палатализация – нечкәртү),
5) ирен тартуы (лабиализация – иренләштерү).

---

[1] Хәзерге әдәби сөйләшебез Алпаров өйрәткән юл белән бармый. *Колхоз, доктор, банк, газ агроном, лозунг* кебек сүзләрдәге *к, г* авазларын хәзерге әдәби сөйләшебездә татарча *карга, козгын* сүзләрендәгечә артык калын итеп, тел артыннан түгел, бәлки рус әдәби әйтелешендәгечә, йомшаграк итеп, чыгарырга тырышабыз, һәм мәктәп тә шулай өйрәтергә тиеш.— *Ред.*

Телдә авазларның бер-беренә йотылулары гына түгел, төрле сәбәпләр белән төшүе, алмашуы, яңа бер аваз килеп чыгуы да бар. Түбәндә без бу үзгәрешләрнең зурракларын тикшереп чыгабыз.

## Сузык авазлар үзгәреше

***А* авазының үзгәрүе.** Татар телендә төп сүзләрнең беренче иҗегендә рус телендәге кебек саф *а* авазы булмый. Бездә беренче иҗектәге а авазы һәрвакыт ирен тартуы белән, *о* га якын бер аваз белән әйтелә. А авазының шул табигатенә карап, кайбер телчеләребез, бездә бөтенләй саф *а* авазы юк, бездә *а* белән *о* уртасындарак әйтелгән бер аваз гына бар дип, әйтәләр. *Ләкин* бу караш дөрес түгел, чөнки бездә сүзләрнең беренче иҗегендә саф ачык а авазы булмаса да, сүзнең азаккы иҗекләрендә ул бар. *А* авазының ирен тартуы белән «олашуы» 2 нче, 3 нче иҗекләргә таба киткән саен кими барып, азаккы иҗекләрдә бөтенләй ачылып җитә, саф *а* га әйләнә. Мәсәлән, *кара, балаларга, ташламаганнар* дигән сүзләрнең әйтелеше түбәндәгечәрәк була:

*Кора, бололарга, тошламаганнар.*

Татар телендә *а* авазының үзгәрешен, *о* хәленнән *а* хәленә акрынлап көчәюен түбәндәге схема белән күрсәтергә мөмкин:

***О (ө)* авазының тартуы.** Бу *о (ө)* авазы безнең төрек телләренә хас бер аваз дияргә ярый. Ул төбендә сүзләрнең беренче иҗегендә генә була торган аваз. Бездә бу *о (ө)* авазы иреннәрнең тешкә тиеп торган йөзендәге мускулларын бөреп, тышкы йөзен, киресенчә, читкә җәеп (боргы ясап) әйтелә. *У (ү)* авазы булса, бөтенләй моның киресенчә, иреннәрнең тышкы йөзен бөреп әйтелә.

Гадәттә, күп эшләмәгән мускуллар тартылган өчен булса кирәк, *о (ө)* авазы безнең телебездә иң ялкау авазлардан. Аның төп урыны сүзләрнең беренче иҗеге булса да, ул үзеннән соңгы 2 нче, 3 нче иҗектәге авазларның да «оланып» яки «өләнеп» әйтелүенә сәбәп була. Үзеннән соңгы иҗекләрдәге *ы–э* авазларына, хәтта 3–4 буынга җиткәнче, тәэсир итә ала. Кыргыз, башкорт телләрендә бу *о-ө* ләрнең түбәнге авазларга тәэсире бик көчле. Мәсәлән, *бөтенесе, томан, көләм, төрле, озынлыгы, төзелеше, көлдердеме* дигән сүзләр шушы беренче буындагы *о-ө* тәэсире белән *бөтөнөсө, томоан, көлөәм, озонлого, төзөлөшө, көлдөрдөмө* кебегрәк әйтеләләр.

Бездә бу авазның түбәнгә тәэсире 2–3 иҗектән артык еракка китми. Сүз ахырына таба киткән саен ирен тартуы кими барып, 4–5 буынга киткәч, бөтенләй югала. Ирен авазлары туры килгәндә, аның түбәнгә тәэсире тагы да элегрәк кимергә мөмкин.

*Ө* авазының үзеннән югарыгы авазга тәэсире дә бар. Мәсәлән, *бу+көн* дигән сүз шул *ө* нең югарыга тәэсире белән *бөгөн* булып әйтелә.

Татар, башкорт телләреннән башка төрек телләрендә *у-ү* авазларының

да түбәнгә тәэсире бар. Мәсәлән, көньяк төрекләрдә *булып, күрде* сүзләре, *(б)улуп, күрдү* кебек әйтеләләр.

### Ике сузык янәшә килгәндә

Сүз кисәкләре арасында ике сузык янәшә килә алмый. Боларның икесе арасына иҗек тотыручы бер өстәмә аваз килеп керә. Мәсәлән: *күз + е = күзе, әмма бала + ы = баласы, кил + әчәк = киләчәк, кара + ачак = карайачак (караячак), бел + әчәк = беләчәк, белмә + әчәк = белмәйәчәк (бәлмәячәк), атым + а = атыма, аты + а =атына.*

Ике сүз арасында сузык авазлар янәшә килгәндә, алар берләшергә, көчсезрәге төшеп калырга яки үзгәрергә мәҗбүр була.

Очрашучы сузыкларның берсе *а* яки *ә* авазы булса, башкалары төшеп кала:

*бара алмый – баралмый, килә алмадым – киләлмадым,*
*бала өчен – балачөн, кала эчендә – калачендә,*
*килә әле – киләле, башы авырта – башавырта,*
*йокы ачылды – йокачылды,*
*төрле әйбер – төрләйбер,*
*бүлмә эче – бүлмәче,*
*коры имән – коримән.*

Очрашучы авазларның берсе *ы–е* авазлары булса, һәрвакыт үзләре төшеп кала: *сары ат – сарат, чөйгә элеп – чөйгәлеп, яхшы әйбер – яхшәйбер, майлы ит – майлит, яхшы эш – яхшеш, сине эзләп – синезләп.*

Очрашучыларның берсе *у – и* булса, болар тартык *в – й* гә әйләнәләр: *бара икән – барайкән, бара ул – баравыл, ачу ала – ачывала, иртә исемдә – иртисемдә* (*карурман, иртисемдә* төрендә әйтелгән сүзләр сирәк).

Искәрмә. Ике сүз арасында янәшә килгән сузыкларның берсе төшеп калу белән сүзләрнең калынлык, нечкәлекләре үзгәрми саклана. *О–ө* авазларының төшеп калуы белән боларның түбәнге авазга тәэсире бетми (югарыгы мисалларны кара).

Кайбер сүзләрнең сузык авазы әйтергә җиңелрәк икенче бер сузыкка үзгәрүе бар:

*Бу + ел – быел, бу – боны – моны, моннан – мыннан, булды – болды – былды.*

## Тартык авазларның үзгәрешләре

Төп сүзгә кушымчалар тоташкан чагында, авазларның бер-беренә йотылуларын аңлар өчен, иң элгәре, төп сүзнең азакка туктар авазы белән кушымчаларның башлар авазын игътибарга алырга кирәк.

Туктар авазлар белән башлар авазларның нинди төркемнән булып, ничек әйтелүләренә карап, бу авазларның бер-беренә йотылуы да төрлечә

була. Югарыда әйтелгәнчә, бу урында йотылыш уңайга таба да, кирегә таба да булырга мөмкин. Татар телендә бу йотылышлар түбәндәге урыннарда очрый:

1) төп сүзгә кушымчалар тоташканда, тавыш коралы тартуы сәбәпле, яңгыравыксыз яки яңгыравыклы аваздан гыйбарәт булган туктар яки башлар авазларның берсе үзенең янәшәсендәге яңгыравыксыз яки яңгыравыклы авазга йотыла:

а) туктар яңгыравыксыз авазлар (*п, т, ч, с, ш, к, ф*) яңгыравыклы башлар *г, д* авазларын йотып, үз тиндәшләре булган яңгыравыксыз *к, т* авазларына үзгәртәләр (уңайга таба йотылу). Мәсәлән: *ат + га = атка, кит + де = китте, ач + ды = ачты, ус + гән = ускән, баш +дан = баштан, юк+дан = юктан, чик + дән = чиктән, юк + дыр = юктыр*;

б) туктар яңгыравыксыз авазлардан, *п, к* авазлары башлар сузык (яңгыравыклы) авазлар белән янәшә килгәндә, юлдашлары булган яңгыравыклы *б, г* авазларына әйләнәләр (кирегә таба йотылу). Мәсәлән: *куп – кубе, тап – таба, юк – югы, кирәк – кирәге, сук – суга, тук – туга...* кебек. Бу йотылыш ике сүз арасындагы очрауда да була.

Искәрмә. Көньяк төрек телләрендә туктар *т, ч* авазлары да яңгыравыклы *д, җ* авазларына үзгәрә: *ач – аҗы, ат – ады* кебек.

2) Кече тел тартуы белән янәшә авазларның бер-беренә йотылулары бездә түбәндәге урыннарда очрый:

а) *дан–дән* кушымчалары һәм *л* авазы белән башланган 2–3 авазлы кушымчалар, туктар *м, н, ң* авазларыннан соң килгәндә, бу авазларның уңайга таба тәэсире белән, *н* авазы белән башланып әйтеләләр. Мәсәлән: *Казандан – Казаннан, үзендән – үзеннән, урамдан – урамнан, берәмләп – берәмнәп, комлы – комны, утынлык – утынныk, тыңла – тыңна, миңле – миңне, җанлы – җанны, килгәнләр – килгәннәр...* кебек.

б) туктар *н* авазы, башлар *к* һәм *г* авазларына очраганда, *ң* авазына үзгәрә (тел төбенең кирегә тәэсире белән). Мәсәлән: *иртән – иртәнге – иртәңге, борын – борынгы – борыңгы, күтәрен – күтәренке – күтәреңке, мин – миң генә, сүн – сүңгән, сузын – сузыңкы...* кебек.

Искәрмә. *Н* авазының *ң* авазына үзгәрүе, башлар *к, г* авазлары икенче сүз башында булганда да мөмкин: *син килдең – сиң килдең, ун кат – уң кат, мин күрәм – миң күрәм...* кебек.

в) кайбер урыннарда башлар *г* авазы туктар *м, л, ң* авазларының түбәнгә тәэсире белән *ң* авазына үзгәреп әйтелә. Мәсәлән: *туң – туңган = туңңан, уң – уңган = уңңан, үзем генә = үзем ңенә, син генә = сиң ңенә, соң гына = соң ңына...* кебек.

3) Туктар *з, с* авазлары кушымчадагы яки икенче сүздәге башлар *с, ч, ш, җ, й* авазларына очраганда, тел һәм тавыш коралы тартуы белән, соңгыларына әйләнеп әйтеләләр (кирегә тәэсир): *кыз + са = кысса, сүз + чән = сүсчән яки – сүччән, кыз + чык = кысчык яки кыччык, йөз шәм =*

*йөш шәм, сүз юк = сүҗ җук, каз йолкырга = каҗ җолкырга, тоз чиләге = точ чиләге, сез шундагымы = сеш шундагымы...* кебек.

4) Туктар *н, ң* авазлары икенче сүздәге башлар ирен авазларына (*м, б, п, ф*) очраганда, ирен тартуы белән, юлдашлары булган *м* авазына үзгәрәләр: *син бар = сим бар, мин барыйм = мин барыйм, таң белән = там белән, ун пар = ум пар, ун пот = ум пот, үзең беләсең = үзем беләсең...* кебек.

5) туктар *б* авазы кайбер сүзләрдә тартык *в* авазына үзгәрә: *Каб – кавып, таб – тавып, чаб – чавып...*

Бу сөйләнгән аваз үзгәрешләрен түбәндәге җәдвәлгә җыеп күрсәтергә мөмкин (4 табл.):

*4 таблица*

| Туктар аваз | Башлар аваз | Кайсы нинди авазга үзгәрә |
|---|---|---|
| 1) *п, т, ч, с, ш, ф, к* | *г, д* | башлар аваз *к, м* авазына үзгәрә, |
| 2) *п, к* | *а, ә, э, (е), ы* | |
| 3) *м, н, ң* | *дан–дән, л, м* | туктар аваз *б, г* авазына үзгәрә, |
| 4) *н* | *г, к* | башлар аваз *н* авазына үзгәрә, |
| 5) *з, с* | *с, ш, ч, җ, й* | башлар аваз *ң* авазына үзгәрә,<br>туктар аваз *м* авазына үзгәрә,<br>туктар аваз *ң* авазына үзгәрә,<br>туктар аваз соңгыларга үзгәрә |

Кайбер алмашлыкларга кушымчалар тоташкан чагында, туктар авазның бөтенләй югалу гадәте дә бар: *мин + гә = миңа (миңә); син + гә = сиңа; шул + ны = шуны, шул + лар = шулар; ул + лар = унлар – улар – олар – алар...*

Сирәк сүзләрдә, кушымча тоташканда, *л* авазының төшеп калуы да бар: *кил+тер = китер, үл+дер = үтер...*

Кайвакыт төшеп калган аваз үзе яки шуңа якын башка бер аваз яңадан килеп чыга: *шул+ да = шунда; ул+да = уда – ода – анда...* кебек.

Тартык авазның икенче бер якын авазга үзгәреп әйтелүен бу – *моны, моннан* сүзләрендә күрергә мөмкин.

Казах, төрекмән, башкорт телләрендә *к* авазы белән башланган сүзләрнең, сузык авазга беткән сүзләр артыннан килгәндә, *г* авазына үзгәреп әйтелүләре бар: *ала карга – ала гарга, бире кил – бире гел, ары карап – ары гарап, ни кирәк – ни гирәк...* кебек.

## Төрек телләрендә аваз аермалары

Төрек телләренең үзара бер-береннән аерымлыклары күбрәк авазларда күренә. Түбәндә мин аларның аваз ягыннан зуррак аермаларын кыскача күрсәтеп үтмәкче булам.

Сузык авазларда татар теле белән башкорт теле арасында аерма юк. Татар һәм башкортлардан башка төрекләрдә сүз уртасындагы сузык *у, и* авазлары *о, э (е)* авазларына якынрак әйтеләләр. Мәсәлән, бездәге *кул, бул, юк, кил, бир, син* сүзләре аларда *кол, бол, йок, кел, бер, сен* рәвешендә әйтеләләр.

Күньяк төрекләрдә бездәге *ы–э (е), о–ө* авазлары да *и, у* авазларына авышыбрак әйтеләләр: *ары – ари, килде – гелди, бөтен – будун...*

Уйгур (таранчы) телендә кайбер сүзләрдәге *а–ә* авазлары *ы–э (е)* авазларына алмашып әйтелә. Мәсәлән, б*асып, алып, күзләре, юлдан, берләшегез сүзләре бысып, элеп – илеп, күзлери, юлден, берлешеңлә* рәвешендә әйтеләләр.

Башкорт телендә сүз башында *п* авазы урынына һәрвакыт *б* авазы килә. Мәсәлән, *печән, пешерде, пыяла* кебек сүзләр *бесән, бешерде, бияла* дип әйтеләләр.

Госманлы төрек телендә сүз башындагы *б* авазы урынына *в* авазы килгәли. Мәсәлән, *бар, бир* сүзләре *вар, вир* дип әйтелә.

Сүз башындагы *т* авазы госманлы төрек һәм төрекмән телләрендә күбрәк *д* авазына алмашып йөри. Мәсәлән, *тел, таш, туйды* сүзләре *дел, даш, дуйду* булып әйтеләләр.

*Җ* авазы башкорт телендә бөтенләй юк. Башкорт телендә бу аваз урынына сүз башында һәрвакыт *й* авазы, ә башка, урыннарда *ж* авазы килә. Мәсәлән, *җил, җан, җыелды, хуҗа, киҗе* сүзләре башкортчада *йил, ян, еелды, хужа, кижe* рәвешендә әйтеләләр.

Уйгур телендә сүз башындагы *й, җ* авазлары күбрәк *ж* белән әйтеләләр. Мәсәлән, *ел, елады, йөкләп* сүзләре *жыл, жыглады, жөкләп* рәвешендә әйтеләләр.

Казах, кыргыз телләрендә сүз башында һәрвакыт *ж* га якын *җ* авазы гына килә. Мәсәлән, *ел, юк, җитәр* сүзләре аларда *җыл, җук, җитәр* (дөресрәге – *жыл, жук, житәр*) булыр әйтеләләр.

*Ч* авазы башкорт телендә бөтенләй юк. Башкорт телендә бу аваз һәрвакыт *с* авазына алмашып әйтелә. Мәсәлән, *чак, чиләк, эшче, кичә, киләчәк, һич* сүзләре *сак, силәк, эшсе, кисә, киләсәк, һис* булып әйтеләләр.

Шул ук *ч* авазы казах телендә дә юк. Казах телендә бу аваз *ш* авазына алмаша. Мәсәлән, *чама, чәй, чулпан, булгач, кучерде* сүзләре *шама, шәй, шулпан, булгаш, кушерде* булып әйтеләләр (ләкин *ш* авазының әйтелешендә беркадәр *ч* гә якынлык бар).

Кушымчалардагы *д, л* авазлары казах, кыргыз телләрендә, туктар авазларның табигатенә карап, өчәр төрле, ә башкорт телендә дүртәр төрле киләләр (бу турыда морфология бүлегендә мисаллар күрсәтеләчәк).

*Р* авазы сүз азагында уйгур һәм үзбәк телләрендә күбрәк төшеп калучан: *бар, киләләр* кебек сүзләр аларда ба, киләлә булып әйтеләләр.

*З* авазы һәм төп сүздәге *д* авазы башкорт телендә интердентал *з*

авазына алмашынып йөри. Мәсәлән, бездәге *йөз, күзем, кызыл, идел, бодай* кебек сүзләр аларда интерденталь (сакау) *з* белән әйтеләләр.

*З* һәм *с* авазлары төрекмән телендә бөтенләй юк. Бу авазлар урынына төрекмәннәрдә интерденталь (сакау) з, с (ث, ذ[1]) авазлары алмашынып йөри. Мәсәлән, татар телендәге *сүз, үзе, язылса, юксыл* сүзләре аларда интерденталь (сакау) *з, с* авазлары белән әйтеләләр.

Сүз һәм кушымчаларның башында килгән с авазы башкорт телендә *һ* авазына алмашынып, башка урындагы *с* авазы, төрекмән телендәге шикелле, интерденталь (сакау) *с* авазына алмашынып әйтеләләр. Мәсәлән, *сук, син, сакал, сөйлә, баласы, килсә...* кебек сүзләр аларда *һук, һин, һакал, һөйлә, балаһы, килһә* рәвешендә, ә *кысылды, кис, булмас...* кебек сүзләрдәге *с* авазы интерденталь (сакау) *с* белән алмашынып әйтеләләр.

*Ш* авазы казах телендә һәрвакыт *с* авазына алмашынып йөри. Мәсәлән, *эш, кеше, сөйләшеп, кошлар* дигән сүзләр *эс, кесе, сөйләсеп, костар* рәвешендә әйтеләләр.

Кайбер кушымчалар башында килә торган *к, г, н* авазлары төрекмән һәм госманлы төрек телләрендә төшеп калалар. Мәсәлән, *юлга, айга, килгән, барган, кайткан, кемне, сүзнең...* кебек сүзләр аларда *юла, ая, гелән, варан, кайдан, геме, сүзең* булып әйтеләләр.

*К* авазы бу ике телдә сүз башында күбрәк *г* авазына үзгәреп әйтелә: *гелде, герек, гүрдем...* кебек.

Госманлы һәм кыргыз телләрендә *ң* авазы күбрәк *н* авазы белән алмаштырып сөйләнә. Мәсәлән, *синең, юлың, китапның* урынына *сенен, юлын, китабын, китаптын* дип әйтелә.

*Л* авазы казах, башкорт, уйгур телләрендә сүз уртасында төшеп калгалый. Мәсәлән, *булган, килгән, алып...* урынына *буган, кигән, ап* әйтелә.

*М* авазы госманлы телендә кайбер сүз башында *б* авазына алмашып әйтелә. Мәсәлән, *мин, менде, мул* урынына *бен, бенде, бул* дип әйтелә. Казах, кыргыз телләрендә *ма – мә* кушымчалары кайбер урында *ба – бә, па – пә* булып әйтеләләр. Мәсәлән: *китмәде – кетпәде, чыкмаган – шыкпаган, шыкбайт, булбайт, айтпадым...* кебек.

Тартык *в (у)* авазы төрекмән һәм госманлы телләрендә *г* авазына алмашынып йөри. Мәсәлән, *тау, сау, авыз, авыр* сүзләре *даг, саг, агыз, агыр* булып әйтеләләр.

Сүзләрнең кушымчалар белән төрләнешендәге аерымлыклар морфология бүлегендә беркадәр күрсәтеләчәк. Төрек телләренең үзара аерымлыкларын озынлап тикшерү «чагыштырмалы грамматика»ның вазыйфасы булганга, бу урында шул кадәр белән канәгатьләндек.

[1] ذ һәм ث хәрефләре башкорт, төрекмән һәм гарәп телләрендәге интерденталь [*з*] һәм [*с*] авазларын күрсәтәләр. Бу авазлар телнең очын өске һәм аскы тешләр арасына куеп әйтеләләр. Татар телендә бу авазлар юк. Татарларда бу авазларның беренчесен сакау *з*, икенчесен сакау с дип атыйлар. — *Ред.*

## 3. ИҖЕКЛӘР

Сүз әйтергә булганда, без үпкәбезгә күп итеп тын алабыз да, сөйләшкәндә шул тынны бүлеп-бүлеп кенә чыгарабыз. Һәрбер бүлеп тын биргәндә, сүзнең берьюлы әйтергә уңай булган бер кисәген әйтеп калабыз. Сүзнең бер тын белән, берьюлырак әйтелеп калган өлешенә иҗек (буын) дип әйтәләр. Һәр иҗектә бер яки берничә аваз булырга мөмкин. Боларның берсе, әлбәттә, сузык аваз булырга тиеш. Сузык аваз ул – иҗекнең төп хуҗасы, ансыз иҗек була алмый.

Иҗекнең ачык яки ябык дип аталуы шушы сузык аваз (а, ә, ы...) ның торган урынына карап йөри; сузык аваз иҗекнең азагында килсә, ул иҗек ачык дип, иҗекнең азагында тартык аваз килсә, ул иҗек ябык дип атала.

Ачык иҗекле сүзләр: ба-ла-ла-ры, ке-ше-се, я-кы-ны; ябык иҗекле сүзләр: бул-дым, бел-дер-дең, яз-мыш, а-лып (имля кагыйдәсе буенча ябык иҗектә ы-е язылмый, ачыкта языла)[1].

### Иҗек калыплары

Авазларның санына, сузык авазның торган урынына карап, бездә иҗекләр түбәндәге алты калыпта киләләр:

1) ялгыз бер сузык аваздан гыйбарәт иҗек: *а, ә, у, и*... кебек,

2) алдан тартык, ахырында сузык – ике авазлы иҗек: *ба–ла, и–лә*... кебек,

3) алдан сузык, ахырдан тартык – ике авазлы иҗек: *ал, эш*...

4) уртада сузык, ике яктан берәр тартык – өч авазлы иҗек: *бул, кал–дым*...

5) алдан сузык, ахырдан янәшә ике тартык – барсы өч авазлы иҗек: *әйт, урт, арт*...

6) уртада сузык, алдан бер, ахырдан ике янәшә тартык – барсы дүрт авазлы иҗек: *тарт, дүрт, сырт*...

Бу иҗек калыпларын түбәндәге таблица белән күрсәтергә мөмкин (сузык аваз ятык сызык белән (➻), тартык аваз текә сызык (|) белән күрсәтелгән) (5 табл.):

---

[1] Яңалифкә күчкәнче, татар орфографиясендә сүзнең беренче иҗегендә һәм барлык ябык иҗекләрендә иҗекнең икенче авазы булыл килгән *ы – е* язуда күрсәтелми иде. Мәсәлән, хәзерге орфографиядә *бел, белем, белдердек, тынычлансын* рәвешендә языла торган сүзләр ул чакта بل بلم بلدرك تنچلانسن рәвешендә языла иде.

1929 нче елдан соң яңалиф орфографиясендә дә *ы–е* авазларының язылышы шактый чикләнгән иде. Мәсәлән, хәзерге орфографиядә *ындыр, энҗе, белем, тынычлык* рәвешендә языла торган сүзләр 1933 нче елга чаклы *ндыр, нҗе, блем, тнчлык* рәвешендә язылып килде. 1933 нче елда орфографиягә кертелгән төзәтмәләр *ы–е* авазларының язылышын киңәйтеп җибәрде, татарча сүзләрдә бу авазларны язу фонетик принцип буенча кагыйдәләштерелде. – *Ред.*

*5 таблица*

<table>
<tr><td>Нинди иҗек</td><td colspan="2">Ачык иҗек</td><td colspan="4">Ябык яки тартык иҗек</td></tr>
<tr><td>Ничәнче калып</td><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td></tr>
<tr><td>Билгесе</td><td>➽</td><td>|➽</td><td>➽|</td><td>|➽|</td><td>➽||</td><td>|➽||</td></tr>
<tr><td>Ничә авазлы иҗек</td><td>сузык, бер генә авазлы</td><td colspan="2">бер сузык, бер тартык – ике авазлы иҗекләр</td><td colspan="2">бер сузык, ике тартык – өч авазлы иҗекләр</td><td>дүрт авазлы иҗек</td></tr>
</table>

Безнең төрек телләрендә теләсә нинди иҗекләр (сүз буыннары) шушы алты калыпның берсенә туры килергә тиешләр. Башка төрле иҗекләр безнең телебездә булмый. Уң яктан ачык иҗекләр сүз башында гына булырга мөмкин. Сүз уртасында иҗекләрнең һәрвакыт тартык аваз белән башланганнары гына килә.

Искәрмә. Чит телләрдә баштан ике, азактан өч янәшә тартык авазлы иҗекләр дә бар. Мәсәлән: *схема, школа, Шмидт, Александр, грамм, Чарльз.* Без татарчада бу авыр иҗекләрне икегә бүлеп кенә әйтә алабыз: *А-лек-сан-дыр, Чар-лез, гы-рам, эс-хи-ма, ыш-ку-ла*[1].

## Иҗекнең ачылуы һәм ябылуы

Кушымчалар ялганып, сүзләр төрләнгән чагында, сүз азагындагы ачык иҗекләр ябыкка, ябык иҗекләр ачыкка әйләнергә мөмкин. Мәсәлән: *тел* (ябык), *теле* (ачык), *телем* (ябык), *телемә* (ачык), *теленнән* (ябык), *телендәге* (ачык).

Сүз азагындагы ябык иҗекнең ахырына ялгыз сузык аваздан гыйбарәт кушымчалар ялганганда, ябык иҗекнең соңгы тартык авазы әлеге кушымча белән берләшеп, яңадан бер ачык иҗек ясала: *ал – а-ла, сүз – сү-зе, тарт – тар-та...*

Сүз азагындагы ябык иҗеккә ялгыз тартык аваздан гыйбарәт кушымча килгәндә, ябык иҗекнең соңгы авазы өстәмә *ы-э (е)* авазы аркылы әлеге кушымчага тоташып, 4 нче калыптагы бер ябык иҗек ясый. Элгәреге иҗек күбрәк ачык булып калырга мәҗбүр була: *Яу – я-вым, тарт – тар-тыл.*

---

[1] Татар сүзләренең иҗек калыплары бик гади. Иҗек башында бер генә тартык, иҗек азагында ике генә тартык аваз була ала. Татар теленә рус теленнән һәм рус теле аркылы Европа телләреннән кергән сүзләрдәге катлаулы иҗекләрне дә, менә шушы законга ияртеп, *эс-хи-ма, пы-лан, ыш-каф, ыш-ты-раф, ти-а-тыр* рәвешендә гадиләштерелгән иде. Яңалифкә күчкәнче, хәтта яңалифнең беренче елларында да, шулай кагыйдәләштерелгән иде. Хәзерге татар орфографиясендә мондый сүзләрнең язылышы һәм әйтелеше рус телендәге кебек итеп алына, орфография һәм орфоэпия нормалары шулай билгеләнә: *схема, план, шкаф, штраф, грамм, театр, шрифт...* Шулай итеп, хәзерге татар әдәби теле орфографиясендә һәм орфоэпиясендә яңа нормалар туды. Хәзерге татар әдәби телендә иҗек калыплары алты гына түгел, бәлки уннан артык санала. – *Ред.*

Сүз азагындагы ачык иҗекләргә ялгыз тартык аваздан гыйбарәт кушымчалар ялганганда, алар ябык иҗеккә әйләнәләр: *кара – каран, кеше – кешем, үзе – ү-зен.*

Ачык иҗекләрнең азагына сузык аваз белән башланган кушымчалар килгәндә, ике арага читтән бер өстәмә аваз килеп керә: *бала – баласы, булачак – булмайачак (булмаячак)*... кебек.

Башка хәлләрдә сүз кисәкләре бер-беренә иҗек калыпларын үзгәртми генә килеп ялганалар.

## 4. БАСЫМНАР

«Басым» дип, иҗек эчендәге сузык авазны күбрәк тын биреп, көчлерәк итеп чыгаруга әйтәләр. Һәр сүз, ничә иҗекле булса да, бер басым белән әйтелмичә булмый. Басым күп иҗекле сүзләрнең һәр иҗегендә булмыйча, мәгълүм бер иҗегендә генә була. Бу басымның кайсы иҗектә, тамырдамы яки кушымчадамы һәм кайсы кушымчада булуы аерым сүз төркеменә, кушымчаларның кайсы төркемнән булуына карап билгеләнергә мөмкин. Чөнки бездә басым сүзләрнең ялганмалык табигате белән бәйләнгән була. Безнең телебездәге басымнарның урыннары түбәндәгечә булып чыга:

1) бездә бер иҗекле тамыр сүзләрнең фигыль төркеменә кергәннәре көчле басым белән, башка төркемдәге бер иҗекле тамыр сүзләр аз басым белән яки бер дә басымсыз әйтеләләр. Аваздаш сүзләрнең фигыльме, түгелме икәнен без шушы басымнарның көченә карап аера алабыз: *а̀л – ал, кы̀л – кыл, тө̀ш – төш, кү̀н – кун, о̀ч – оч, кы̀р – кыр*...

2) ике иҗекле тамыр сүзләрдән фигыль төркеменә (боерык фигыль төркемчәсенә) кергән сүзләр һәм сорау алмашлыклар беренче иҗектә басым белән әйтеләләр. Башка төркемдәге ике иҗекле сүзләрдә исә, басым һәрвакыт ахыргы – икенче иҗектә була (күп иҗекле, кушма яки тагылмалы сүзләрдә дә шулай).

Мәсәлән: *а́лма, ба́тыр, ни́чек, ка́йчан, ба́кыр, ка́ра* (басым беренче иҗектә);

*алма́, баты́р, өзе́к, бакы́р, кыска́, кара́* (басым икенче иҗектә).

3) кушымчалар тоташып, сүз озайганда, бер озын сүзнең эчендә төрле дәрәҗәдә 2, хәтта 3 басым да булырга мөмкин. Бу вакытта аларның арасыннан көчлерәк булганы төп басым булып, башкалары икенче дәрәҗәдәге басымнар була. Мәсәлән: *ки́лмәделә́р, пеше́рмәгәнлекләреннә́н, китергәннә́рмени́* (икешәр басымлылар булып, беренче басымнары көчлерәк).

4) ясаучы кушымчалар тоташу белән, фигыльләрнең басымнары беренче иҗектән күчми, элгәреге урында саклана, исемнәрдә исә, ясагычлар кушылу белән, басым элгәреге урыннан ахыргы буынга – кушымчага таба күчә, мәсәлән: *а́л – а́лдыр – а́лдырт, ка́ра – ка́раштыр, ки́л –*

*кйлгәлә...* (фигыльләр); *кешé – кешелéк, кешелеклé, кешекәй, яхшылыклы́...* (исемнәр).

5) Фигыльләргә 3 нче рәттәге *ма-мә-мый-ми* кушымчалары тоташканда басым беренче иҗектән шушы ма–мә кушымчаларының алдындагы иҗеккә күчә. Мәсәлән:

*а́лдыр – алды́рма, я́зыл – язы́лма, э́шләт – эшлә́тмә,*

*ка́ра – кара́ма, кү́рсәт – күрсә́тмә, килешкәлә́мә, йокымсыра́ма...*

6) сүз төрләндерүче кушымчалар белән төрләнгән боерык фигыльләрендә һәм юклык нигезенә төзелгән бөтен фигыльләрдә басым нигез төрдәге урыныннан үзгәрми: *ки́легез, язы́шмасын, ба́рмасыннар...* кебек. Бу вакытта иң ахыргы иҗектә икенче дәрәҗәдәге басым булырга мөмкин.

7) барлык төрендәге хәбәр фигыльләренең басымнары иң ахыргы иҗеккә күчә: *килдé, килделә́р, килсәгéз, килсәлә́р...* кебек.

8) рәвеш ясагычлары булган *лата-ләтә* һәм исемнәрнең 3 нче рәттәге *ча-чә, дай-дәй, дый-ди, тай-тәй* төрлекләре басымны үзләренә чыгармыйча, алларындагы иҗектә тоталар: *күрә́ләтә, акча́лата, тата́рча, безнéңчә, аю́дай, килгә́ндәй ...*

9) җиткерү рәвеше фигыльләрендә басым беренче иҗектә була: *у́тергәнче, ту́йганчы, а́рганчы, бéткәнче...*

10) өстәмә кушымчаларның *рак–рәк* тән башкалары, шулар җөмләсеннән уртак хәбәрлекләр дә, басымны үзләренә үткәрмиләр, бәлки үзләренең алдындагы янәшә буынга тартып китерәләр: *бая́ гына, ару́ гына, шула́й ук, килгә́ч ук, күргә́нмен;*

*белмә́ссең, алмакчы́мын, киләчә́кбез, алма́ссыз* (әмма килмәсләр, булмаслар төрендәге фигыльләрдә басым ахырга чыга).

Өстәмә кушымчаларның берничәсе янәшә килгәндә, төп басым аларның барыннан да алдагы иҗектә кала: *килéрсеңме, барга́нсың да...*

Искәрмә. Басымны үзенә алмаган кушымчаларның үзләренә аерым 2 нче дәрәҗәдә кечерәк басымнары була.

11) бер кешенең әйткән сүзен яңадан әйтеп, тавышны үзгәртеп сорау ясаганда, югарыгы кагыйдәләргә карамастан, ул сүзнең көчле басымы һәрвакыт ахыргы иҗектә була.

Мәсәлән: – *килдéңмени. – килдеңмени́? – кычкы́рма.– кычкырма́?*

Исемнәрдә басымнарның ахырга күчеп, фигыльләрдә беренче иҗектәрәк саклануы бездә җөмлә кисәкләренең билгеле бер тәртиптә әйтелеп йөрүеннән килә. Җөмләдә исемнәрнең үзеннән соңгы фигыльгә, сыйфатларның үзеннән соңгы исемгә бәйләнеп әйтелүләре алардагы басымның да сүз азагында булуын, үзе бәйләнгән – ахырдан әйтеләчәк сүзгә таба тартып, аның барлыгын белдереп торуын тели. Фигыльләр, күп вакытта җөмләнең хәбәре булып, азактанрак әйтелүчән булганлыктан, аның басымы да алдарак килеп, югарыгы сүзләргә тартып торса кирәк.

## Өченче бүлек

# ТЕЛЕБЕЗНЕҢ САРЫФЫ

## МОРФОЛОГИЯ НӘРСӘ?

Грамматиканың аерым сүзләрне генә алып тикшерә торган бүлеге морфология (сарыф) дигән идек. Морфология грамматиканың бер бүлеге булганлыктан, әлбәттә, аерым сүзләрнең эчке якларын түгел, бәлки тышкы әйтелеш ягыннан булган күренешләрен генә тикшерергә тиеш. Безнең телебездә сүзләрнең тышкы күренешләреннән бер төре ялганмалык булганлыгын да күреп үткән идек. Менә морфология – аерым сүзләрнең шушы ялганмалык табигатен, безнең сүзләребезнең нинди тамыр, нинди кушымча кисәкләрдән төзелешен, тамыр һәм кушымчаларның урыннарын, тәртипләрен тикшерә торган, аларны бер системага салып күрсәтә торган гыйлем. Шунлыктан морфологиянең саф тышкы шәкел ягын гына күзәтеп эш итәргә тиеш икәнлеге үзеннән-үзе күренеп тора.

Кыскасы, бездә сарыфны «аерым сүзләрнең нинди кисәкләрдән төзелешен тикшереп, шуларны бер системага салып күрсәтә торган фән» дип тәгъриф итәргә тиеш була.

## АЕРЫМ СҮЗ

Иң элек сүз үзе нәрсә? Шуны телебезнең табигатенә, грамматика нигезләренә мовафыйк рәвештә тәгъриф итеп, ачык аңлатып үтәргә кирәк була.

Аерым сүз дигәннән, без сүз кисәген түгел, бәлки бер бөтен сүзне һәм, сүз тезмәсен түгел, ялгыз бер сүзне аңлыйбыз.

Шуңа күрә безнең телебездә сүзне «үзенә аерым гармония һәм мөстәкыйль басым белән әйтелгән, мәгънә ягыннан да бербөтен булып тәсаувыр ителгән авазлар җыелтыгы» дип тәгъриф итәргә тиеш була. Аерым сүз бөтен кушымчалары белән бергә сөйләүченең психологиясендә дә мөстәкыйль бер бөтен булып сизелә. Менә бу тәгъриф, бер яктан, телебезнең табигатенә мовафыйк булса, икенче яктан, телнең тышкы әйтелеш ягын гына тикшерә торган грамматика карашына да мовафыйк булып чыга. Калынлык, нечкәлектә, тамыр кисәкләргә ияреп йөри торган кушымчалар, бу тәгъриф буенча, грамматикада аерым сүз булып санала алмыйлар. Мәгънә ягыннан да алар сөйләүченең аңында, бербөтен булып түгел, төп сүзнең бер кисәге булып кына тәсаувыр ителәләр. Хәзер без шул сүзләрнең төзелешен, төрләрен, ясалу һәм төрләнүләрен тикшерә башлыйбыз.

## 1. СҮЗ КИСӘКЛӘРЕ

Ялганмалык табигатен сөйләгәндә, телебездәге сүзләрнең тамыр, кушымча дигән кисәкләре булганлыгын кыскача әйтеп киткән идек. Инде без монда аларны ныклап тикшерәбез. Сүзләрнең тамыр кушымча кисәкләрен дөрес билгеләү өчен түбәндәге өч шартны игътибарга алырга тиеш була:

1) Кушымча кисәкләр башка сүзләрнең, бүтән тамыр кисәкләрнең дә азагында үзгәртелмәгән көенчә очрарга тиеш. Мәсәлән: *че–чы* кушымчасы *эшче, язучы, игенче, укучы, сугышучы*... кебек һәртөрле сүзләрнең азагына кушыла ала.

2) Тамыр кисәк, үзгәртелмәгән көенчә, башка бик күп төрле кушымчалар белән дә йөртелә алырга тиеш; мәсәлән, *эш* дигән тамырны без *эшлә, эшсез, эшчән, эшлекле, эшләткән, эштән*... кебек һәртөрле кушымчалар белән дә әйтелә алганлыгын күрәбез.

3) Тамыр кисәкнең кушымча белән бергә әйтелгән чагында аңлаткан төп мәгънәсе ялгыз гына әйтелгән чагында да югалмаска һәм үзгәрмәскә тиеш. Югыйсә ул шул сүзнең, үз тамыры булып саналмаячак. Мәсәлән, *кара, бара, тора һәм утыр, сукыр, тимер*... кебек сүзләрнең азагында ра һәм *ыр–ер* кисәкләре кушымча булып санала алмыйлар. Чөнки монда югарыгы шартлар табылып бетми: бу кисәкләрне алгач, югарыда калган кисәкләрнең элгәреге мәгънәләре калмый яки бөтенләй икенче сүзгә әйләнә; *бара, тора* сүзләренең азагындагы *а* кисәге кушымча булса да, *кара* сүзендәге *а* кушымча түгел, чөнки бу кисәкне алгач, *кар* кисәгендә элгәреге *карау* мәгънәсе бөтенләй югалып китә, *сукыр, утыр, тимер* дигән сүзләрдә дә шул ук хәл. Шуңа күрә бу соңгылар бөтен көенчә тамыр кисәк булып саналалар.

## Тамыр кисәкләр

Телебездәге тамыр сүзләрнең төзелешен иҗекләренең санына һәм иҗек калыпларына карап, ягъни бер иҗектәге авазларның санына һәм сузык авазларның торткан урыннарына карап, тикшерергә мөмкин. Безнең телебездә тамыр кисәкләр күбрәк бер я ике иҗекле булалар. Өч иҗекле тамыр сүзләр – бездә юк диярлек, аз. Булганнары да, ныклап тикшереп караганда, я ике сүздән кыскартылган, я ниндидер бер кушымча ялгап ясалган булып чыгалар (6 табл.).

Тамыр кисәкләрнең нинди авазлардан төзелеше турында кыскача шуны әйтергә мөмкин:

беренче иҗектә сузык авазларның һәрберсе килергә мөмкин. Башка иҗекләрдә сузык авазлардан *и, у–ү* авазлары белән әйтелгән сүзләр бик сирәк. *О–ө* авазлары фәкать беренче иҗектә генә була, башка иҗекләрдә *о–ө* авазлары бөтенләй килми. *А–ә, ы–э(е)* авазлары – беренче иҗектә дә, 2 нче, 3 нче иҗекләрдә дә иң күп очрый торган сузыклар. (Бу

## Өч иҗекле тамыр сүзләрнең калыплары

*6 таблица*

| Сузыклар | Алты авазлы | Жиде авазлы | | | Сигез авазлы | | | Тугыз авазлы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| чираты | 2+2+2 | 2+2+3 | 2+3+2 | 3+2+2 | 2+3+3 | 3+2+3 | 3+3+2 | 3+3+3 |
| *а – а – а* | *багана* | *йабалак* | – | *кандала* | *йалангач* | *йарканат* | – | – |
| *а – а – ы* | – | *балавыз* | *караңгы* | – | – | – | – | – |
| *а – ы – а* | – | – | *кайызла* | *карчыга* | *арыслан* | *карлыган* | – | *балтырган* |
| *ә – ә – ә* | *тәрәзә* | *перәмәч* | – | – | *тәгәрмәч* | – | – | – |
| *ә – ә – э(е)* | – | – | *бәрәңге* | – | – | – | – | – |
| *о – а – а* | *шобага* | – | *көйәнтә* | *гөрләпә* | – | – | *корчаңгы* | – |
| *о – ы – а* | – | *йомышак* | *йомырка* | – | *корылтай* | – | – | – |
| *ө – э(е) – ә* | – | – | *бөтеркә* | – | – | *бөрлегән* | – | – |
| *у – а – а* | *бусага* | – | *умарта* | – | – | *кузгалак* | – | – |
| *ү – ә – ә* | *бүдәнә* | *күбәләк* | – | – | – | – | – | – |
| *ү – ә – э(е)* | *шүрәле* | – | – | – | *күгәрчен* | – | – | – |
| *у – ы – а* | – | – | – | *думбыра* | – | – | – | – |
| *у – ы – ы* | – | – | *тубылгы* | – | – | – | – | – |
| *э(е) – ә – э(е)* | – | *беләзек* | – | – | – | – | – | – |
| *ы – ы – а* | – | – | – | – | *чытырман* | – | *кырмыска* | – |
| *ы – ы – ы* | – | – | – | | *сыйырчык* | – | – | *бытбыл-дык* |
| *и – ә – ә* | *тигәнә* | – | *миләүшә* | – | – | – | – | – |
| *и – ә – э(е)* | – | *кигәвен* | – | *тискәре* | – | *чикләвек* | – | – |
| *и – э(е) – ә* | – | *тилегән* | – | *дилбегә* | *тигермән* | – | – | – |
| *и – э(е) – э(е)* | – | – | *шикелле* | – | – | – | – | – |

соңгыларның, *о–ө* артыннан килгәндә, беркадәр иренләшеп әйтелүе турында фонетика бүлегендә әйтелгән иде.)

Сингармонизм табигате буенча, безнең телебездә бер сүзнең беренче иҗегендә калын сузыклар килсә, башкаларында да һәрвакыт калыннар гына килә, беренче иҗектә сузыкларның нечкәсе булса, калганнарында да нечкә сузыклар килә.

Бер сүз эчендә янәшә ике сузык аваз килергә мөмкин түгел. Иҗек башларында сузык аваз беренче иҗектә генә була.

Бездә сузыкларның чиратлашуларын түбәндәге сүз калыплары җәдвәленнән күрергә мөмкин.

Тартык авазлардан *х, һ* авазлары саф татар сүзләрендә бөтенләй очрамый диярлек, хатын, яхшы рәвешендә йөртелгән берничә сүз булса да, алар да түбәндә *к* дан үзгәргәннәр, халык телендә *катын, якшы* дип сөйләнәләр.

*Ф, ж* авазлары да бездә бик сирәк сүзләрдә генә. Сүз башында татарча *р, л, ң* авазлары бер дә булмыйлар, *д, з, г, н, в* тартыклары да сүз башында, бик сирәк килә. Сүз башында иң күп очрый торган тартыклар – *б, т, с, к, й* авазлары. Сүз азагында *б, җ, г, д* авазлары бөтенләй килми.

Ике тартык аваз иҗек башында янәшә килергә мөмкин түгел, иҗек азагында да янәшә ике тартык аваз бик сирәк; булганы да – ярым сузык саналган *р, л, с* авазлары белән *т, к* авазларыннан кушылган *рт, лт, рк, лк, ст* дифтонглары гына.

**Бер иҗекле тамыр сүзләрнең калыплары** (7 табл.):

*7 таблица*

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| ➻ | │➻ | ➻│ | │➻│ | ➻││ | │➻││ |
| *а* | _ | *ал* | *баш* | *арт* | *тарт* |
| *ә* | *йә (я)* | *әй* | *йәм (ямь)* | *әйт* | *чәлт* |
| _ | – | *өч* | *төз* | *өст (өс)* | *йорт* |
| – | – | *эш* | *бер* | – | *сырт* |
| *у(ү)* | *бу* | *ур* | *бүл* | *үрт* | *дүрт* |
| *и* | *ки* | *ил* | *чит* | *илт* | *чирт* |

Искәрмә. Бер иҗекле тамыр сүзләрнең безнең телебездә иң күп очраганнары – 3 нче һәм 4 нче калыптагылар, башка калыпларда тамыр сүзләр сирәк була. (Бу урында тамырларның нинди авазлардан төзелеше ачык күренсен өчен, мисалларда гади имля кагыйдәсе игътибарга алынмады.)

**Ике иҗекле тамыр сүзләрнең калыплары** (8 табл.):

(Сузык аваз → билгесе белән, тартык аваз | билгесе белән күрсәтелгән. Беренче иҗек билгесе өске юлда, икенче иҗек – аскы юлда.)

Мисаллар фонетик имля белән күрсәтеләләр.

*8 таблица*

| Сузыклар чираты | 1) →<br>2) → | \|→<br>\|→\| | \|→<br>\|→ | \|→<br>\|→\| | →\|<br>\|→ | →\|<br>\|→\| | \|→\|<br>\|→ | \|→\|<br>\|→\| |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *а – а* | *ата* | *азак* | *кара* | *татар* | *алка* | *аркан* | *карга* | *шалкан* |
| *а – ы* | *ары* | *айыр* | *казы* | *алык* | *алты* | *алтын* | *йакты* | *салкын* |
| *ә – ә* | – | *әтәч* | *кәҗә* | *сәнәк* | *әрҗә* | *әйрән* | *нәрсә* | *бәйрәм* |
| *ә – е* | *әле* | *әрем* | *сәке* | *йәшел* | *әйие* | *әйбер* | *тәңре* | *челтәр* |
| *о – а* | *ойа* | *осак* | *кода* | *койаш* | *оста* | *олтан* | *торна* | *борчак* |
| *о – ы* | *олы* | *озын* | *йокы* | *колын* | *опты* | – | *боргы* | *йолдыз* |
| *ө – ә* | *өмә* | *өрәк* | *төйә* | *сөйәк* | *өлкә* | *өстәл* | *көлтә* | – |
| *ө – э(е)* | – | *өмет* | *төзе* | *көмеш* | *өлге* | – | *төлке* | *төркем* |
| *ы – а* | *ыра* | *ышан* | *сына* | *пычак* | – | *ыргак* | *кыска* | *кылган* |
| *ы – ы* | – | *ырым* | *кыны* | *кыйын* | *ыргы* | *ычкын* | *шырпы* | *кычкыр* |
| *у – а* | *ука* | *учак* | *сука* | *куйан* | *урта* | *урман* | *бутка* | *чулпан* |
| *у – ы* | *укы* | *утын* | *туры* | *кубыз* | – | – | *чулпы* | *бурсык* |
| *ү – ә* | *үтә* | *үлән* | *түрә* | *йүтәл* | *үзгә* | *үрнәк* | *күркә* | *сүлпән* |
| *ү – э (е)* | – | *үгез* | *бүре* | *күнел* | *үксе* | – | – | – |
| *– ә* | *илә* | *ишәк* | *тирә* | *шикәр* | *иртә* | *икмәк* | *тирмә* | *билчән* |
| *и – э(е)* | *ике* | *идел* | *тиле* | *тигез* | *изге* | *иркен* | *билге* | *тилмер* |

Искәрмә. Бу җәдвәлгә ике иҗекле тамыр сүзләрнең иң күп йөргән калыпларына гына мисаллар күрсәтелде. Икенче иҗектә *и–у* сузык авазлары белән әйтелгән тамыр сүзләр бездә бик сирәк очрый. Шуңа күрә бу җәдвәлгә мин аларны кертмәдем. Бездә алар бик аз. Булганнарының да катлаулы *ыв, эй* авазларыннан төзелгән булулары бик мөмкин. Шулай ук бездә беренче иҗектә калын *и (ый)* белән әйтелгән сүзләр бик сирәк булганга күрә, җәдвәлдә күрсәтелмәде.

Мәсәлән: *айу (аю), абый, әти, ыру, дару, сылу, матур, кыйу (кыю), уйсу, чылгый, калку, черки, кыйна, кыйгач, кыйрат* кебек сүзләр.

Җәдвәлдә мисаллары табылмыйча, урыннары ачык калган калыпларда да телебездә тамыр сүзләр булырга тиеш.

5 нче һәм 6 нчы калыптагы ябык иҗекләрдән төзелгән ике иҗекле тамыр сүзләр дә бездә бик сирәк очрый. Мәсәлән: *алтмыш, кортка, көртлек, шалдырт...* кебекләр. Шуңа күрә болар да җәдвәлгә кертелмәде.

## Кушымчалар

Кушымчалар күбрәк 2–3 авазлы, бер иҗекле булалар. Дүрт-биш авазлы, икешәр иҗекле кушымчалар бик аз.

Кушымчаларда сузык авазлардан *а, ә, ы, э (е)* авазлары гына була, *о, ө, у, ү, и* сузыклары кушымчада булмыйлар. (Татар телендә кушымчаларда очрый торган *у-ү, и,* авазлары түбендә тартык авазлар булып, *ыв-эв, әй* дән кыскартылган булалар.)

Тартык авазлардан кушымчаларның башында *б, п, р, з, ш, ң, н, в, й* авазлары, кушымчаларның азагында *д, с, г* авазлары килмиләр; *б, җ, х, ж, ф, һ* тартык авазлары кушымчаларда бөтенләй булмыйлар. (Көньяк төрек телләрендә кушымчаларда *җ* йөри. Татар телендәге без, *рак–рәк* һәм *мас–мәс* кушымчалары – бу әйтелгән гадәттән тыш ялгыз кушымчалар гына.)

*А, ә, ы, э (е), т, ч, к, л, м* авазлары исә, кушымчаларда иң күп йөргән, кушымчалар эчендә һәркайда була ала торган авазлар.

Кушымчалар шушы күрсәтелгән авазлардан я берәр генә авазлы, я 2–3 авазлы булып төзеләләр. Аларны түбәндәге җәдвәлләрдә авазлары санынча барын да күрсәтеп үтәбез (9,10,11 табл.).

Һәрбер кушымча төбендә бер генә булса да, калынлык, нечкәлектә тамыр кисәкнең әйтелешенә ияреп, икешәр төрле гармония белән әйтелә. Кайбер кушымчалар, авазлар үзгәрү канунына ияреп, дүртәр, алтышар төрле булалар.

**Бер һәм ике авазлы кушымчалар**

*9 таблица*

| Бер авазлылар | а-ә | ы-э (е) | а-ә | ы-э (е) | (у-ү, п) |
|---|---|---|---|---|---|
| *п* | – | – | – | *ып-эп* | – |
| *т* | *та-тә* | *ты-те* | *ат-әт* | *ыт-эт* | – |
| *ч* | *ча-чә* | *чы-че* | *ач-әч* | *ыч-эч* | – |
| *д* | *да-дә* | *ды-де* | – | – | *(ди)* |
| *р* | *ра-рә* | – | *ар-әр* | *ыр-эр* | – |
| *з* | – | – | *аз-әз* | *ыз-эз* | – |
| *с* | *са-сә* | *сы-се* | – | – | *(су-сү)* |
| *ш* | – | *шы-ше* | *аш-әш* | *ыш-эш* | *уш-үш* |
| *к* | *ка-кә* | *кы-ке* | *ак-әк* | *ык-эк* | *ик, ук-үк* |
| *г* | *га-гә* | *гы-ге* | – | – | – |
| *ң* | *(ңа-ңә)* | – | – | *ың-эң* | – |
| *л* | *ла-лә* | *лы-ле* | *ал-әл* | *ыл-эл* | *(ли)* |
| *м* | *ма-мә* | *мы-ме* | *ам-әм* | *ым-эм* | *(ми)* |
| *н* | *(на-нә)* | *ны-не* | *ан-ән* | *ын-эн* | – |
| *в (у-ү)* | – | – | *ав-әв (ау-әү)* | *ыв-эв (ев)* | – |
| *й* | – | – | *ай-әй* | *ый-(эй)* | |

*Дый-ди, лый-ли, мый-ми* кушымчалары башка төрекләрдә *дай-дәй, лай-ләй, май-мәй* калыбында киләләр. Бездә дә төбендә шул калыпларда дип каралырга мөмкин.

Бу җәдвәлдә күрсәтелгән берәр авазлы кисәкләр дә, икешәр авазлы кисәкләр дә – кушымчалар.

## Өч авазлы кушымчалар (уртада а–ә сузыклары белән)

*10 таблица*

| Башта / азакта | п, т | - ч | - р | с - ш | к | ң, м | -н | й |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *т* | – – | – | – | – – | – | – – | *тан-тән* | *тай-тәй* |
| *ч* | – – | – | – | – – | *чак-чәк* | – – | *чан-чән* | – |
| *д* | – | – | *дар-дәр* | - *даш-дәш* | *-дак-дәк* | - *дам-дәм* | *дан-дән* | *дай-дәй* |
| *р* | – – | – | – | – | *рак-рәк* | – – | – | – |
| *с* | *-сәт* | – | *сар-сәр* | - *сак-сәк* | | *саң-сәң*<br>*сам-сәм* | | *сай-сәй* |
| *ш* | – | – | *шар-шәр* | – – | – | – – | – | – |
| *к* | – | *кач-кәч* | *кар-кәр*<br>*каз-кәз* | - *кәш* | *как-кәк* | – – | *кан-кән* | *кай-кәй* |
| *г* | – | *гач-гәч* | *гар-гәр-гәз* | – | *гак-гәк* | – – | *ган-гән* | *гай-гәй* |
| *л* | *лап-ләп* | *лач-ләч* | *лар-ләр* | - *лаш-ләш* | *лак-ләк* | – – | *лан-лән* | *лай-ләй* |
| *м* | – | *мач-мәч* | – | - *мас-мәс* | *мак-мәк* | – – | – | *май-мәй* |
| *н* | *нап-нәп* | – | *(нар-нәр)* | – | *нак-нәк* | – | *(нан-нән)* | – |

## Өч авазлы кушымчалар (уртада *ы, э (е)* сузыклары белән)

*11 таблица*

| | т, ч | р | з | к | ң, л | м, н | в, й |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *б* | – | – | *быз-без* | – | – – | – | – |
| *т* | – | *тыр-тер* | – | *тык-тек* | *тың-тең* | *тым-тем тын-тен* | – |
| *ч* | – | – | – | *чык-чек* | *чыл-чел* | *чым-чем чын-чен* | – |
| *д* | – | *дыр-дер* | – | *дык-дек* | *дың-дең* | *дым-дем* | *дый* |
| *с* | *сым-сем* | – | *сыз-сез* | – | *сың-сең сың-сел* | *сым-сем сын-сен* | – |
| *ш* | – | *шыр-шер* | – | *(шык-шек)* | *(шыл-шел)* | – | – |
| *к* | *кыч-кеч* | *кыр-кер* | *кыз-кез* | – | *кыл-кел* | *кым-кем кын-кен* | – |
| *г* | *гыч-геч* | *гыр-гер* | *гыз-гез* | – | – | *гым-гем гын-ген* | – |
| *л* | – | – | – | *лык-лек* | – | – | *лый* |
| *м* | – | *мыр-мер* | *мыз-мез* | *мык-мек* | – | *мын-мен* | *мый* |
| *н* | *ныч-неч* | – | – | *нык-нек* | *ның-нең* | – | – |
| *в* | *выч-веч* | – | – | *вык-век* | – | – | – |
| *и-ый* | – | – | – | *ик(ыйк)* | – | *им(ыйм)* | – |

## Кушма һәм күп авазлы кушымчалар

*Ачак-әчәк (ячак-ячәк), арга-әргә (ырга-ергә, рга-ргә), арлык–әрлек (ырлык-ерлек, рлык-рлек), маслык-мәслек,*

*асы-әсе-ыйсы-исе, алак-әләк, анак-әнәк,*

*дагы-дәге-тагы-тәге (дәнге-дангы...), дыра-дерә (тыра-терә), дырык-дерек-тырык-терек,*

*сана-сәнә, сыра-серә (ымсыра-емсерә-мсыра-мсерә),*

*штыр-штер (ыштыр-ештер), шлый-шли (ышлый-ешли-ышлай-ешләй),*

*гала-гәлә, кала-кәлә, гача-гәчә, кача-кәчә (нача-нәчә),*

*ганчы-гәнче, канчы-кәнче, ганда-гәндә, канда-кәндә,*

*ганлыктан-гәнлектән, канлыктан-кәнлектән,*

*гыра-герә, гыры-гере, кыра-керә, кыры-кере, гырау-герәү,*

*гына-генә, кына-кенә, гылт-гелт, кылт-келт, кылтым-келтем (лҗым-елҗем),*

*лата-ләтә, ласа-ләсә (лабаса-ләбаса), лавык-ләвек,*

*ылда-елдә (елта-елтә), ылдырак-елдерәк,*

*макчы-мәкче,*

*ымта-емтә, мса-ымса-емсә-әмсә-мсә, әксә, мешәк,*

*мсак-ымсак, мыный-мени, мыйча-мичә (мыйчы-миче),*

*ытны-енте, (ынта-ентә), ында-ендә, ндый-нди (ндай-ндәй), нча-нчә-нчы-нче,*

*ынкы-енке (ңгы-ңге), ныкы-неке,*

*ынкыра-енкерә.*

## Кушымчаларның тарихы

Тамыр кисәкләрнең азагына кушылып йөргән кисәкләр нәрсәләр? Алар кайдан килеп чыкканнар? Бу турыда да бер-ике сүз әйтеп киту файдасыз булмас дип уйлыйм.

Кушымчалар бик борын заманда безнең борынгы телебездә үзенә аерым мәгънәле бөтен сүзләр булган булса кирәк. Алар телнең үсүе, бер туктамый үзгәреп торуы нәтиҗәсендә акрынлап килеп – эволюция буенча, башта мөстәкыйль мәгънәләрен югалтканнар, соңра әйтелешләре ягыннан да бик нык кыскарып, кушымчага әйләнгәннәр. Сингармонизм кануны теләвенчә, калынлык, нечкәлектә тамыр кисәккә ияргәннәр.

Мәсәлән: *киләмен, барамын, киләсең, күрәбез...* кебек сүзләрнең азагындагы кушымчаларның *мин, син, без* сүзләреннән үзгәреп киткәнлеге ачыктан-ачык беленеп тора.

Телдә бу процесс хәзерге көндә дә бара. Мәсәлән, госманлы телендә *белән, өчен сүзләре, анынлә, улмаклә, шунынлә, анынчөн, ничөн* сүзләрендә кушымчага әйләнеп киткәннәр.

Шуның белән бергә бик борынгы кушымчалар үзләре дә бара-бара бик нык кыскарып, тамыр сүзнең аерылмас бер авазы булып китүләре дә мөмкин.

Мәсәлән: *елан, таган, пычак, чәчәк, якын, бөтен...* сүзләренең азагындагы *ан, ак, әк, ын-ен* кисәкләренең борын кушымча булулары сизелә. Бу сүзләр төбендә *ел+ган, так+кан, пыч+ак, чәч+әк, як+ын, бөт+ен* кисәкләреннән төзелгәннәр. Ләкин хәзерге көндә бу сүзләр ялгыз тамыр кисәкләр итеп каралалар.

Хәзерге җанлы телне тикшерүче грамматиканың мондый сүзләрне тамыр кисәкләр итеп каравы ялгыш түгел, чөнки грамматикаларда хәзерге җанлы телдә барлыгы ачыктан-ачык сизелеп торган кушымчалар гына тикшерелергә тиеш. Тамыр сүзгә берегеп киткән кушымчаларны тикшереп, казып чыгару – тарихи грамматика эше.

Димәк, тарихи якларына карап, кушымчалар ике төрле була: 1) җанлы кушымчалар, 2) җансыз кушымчалар.

**Җанлы кушымчалар** – хәзерге көндә тамыр көенчә җанлы телдә йөргән сүзләрнең азагында барлыгы ачык беленеп торган кисәкләр:

*кил, килә, киләләр, киләләрме* сүзләрендәге *ә, ләр, ме* кисәкләре кебек.

**Җансыз кушымчалар** – хәзерге жанлы телдә тамыр көенчә аерым

йөртелмәгән сүзләрнең азагындагы кисәкләр: *ыкчым, өчен, элгәре, елан, багана, кубәләк*... кебек сүзләр азагында тикшереп табылган *чым, ен, гәре, ан, ана, әләк* кушымчалары кебек.

Төрек телләренең тарихи грамматикалары эшләнмәгән, сүзләре төпчекләп тикшерелмәгән әле дияргә ярый.

Шуңа күрә хәзерге грамматикаларда, мондый җансыз кушымчалы сүзләрнең тамыр кисәкләр итеп каралуы бер дә гаҗәп түгел.

## 2. СҮЗ ТӨРКЕМНӘРЕ

Аерым сүзләрнең һәртөрле табигатен, төрләрен, кисәкләрен, аларның ничек ялгануларын өйрәнүдән килеп чыккан канүннарны бер-берсе белән чуалтмый аңлау өчен, гомумән телебезнең морфология ягыннан булган төзелешен ачык бер системага салып күрсәтү өчен, сүзләрне һәртөрле бүлекләргә, төркемнәргә аергалап өйрәнергә кирәк була.

Сүзләрне төркемнәргә бүлгәләүдә без түбәндәге шартларны игътибарга алырга тиеш:

1) төркемнәргә бүлүдә сүзләрнең тышкы – шәкли ягы нигез итеп алынырга,

2) мәгълүм бер тышкы табигате белән төркемләнгән сүзләр арасына башка табигате белән аерылган төркемнәрне аралаштырмаска,

3) һәр төркемнең башкаларыннан аерыла торган нинди булса да үзенә хас, ачык тышкы бер билгесе, үзенә махсус табигате булырга тиеш,

4) шуның өстенә, әлбәттә, сүзләрне төркемнәргә бүлүдә чит тел кагыйдәләренә дә иярмәскә, саф үз телебезнең табигатен күзәтеп эш итәргә тиеш була.

Сүз төркемнәренең шәкли ягы белән мәгънә ягын бер-беренә чагыштырып карау өчен, бу урында мин сүзләрне эчке мәгънәләре ягыннан карап, нинди төркемнәргә аерылуларын да күрсәтеп китәм.

### Эчке яктан сүз төркемнәре

Саф эчке мәгънәләре ягыннан карап төркемләгәндә, безнең телебездә сүзләр иң элек шушы өч зур төркемгә аерылалар:

1) тулы мәгънәле сүзләр, 2) ким мәгънәле сүзләр, 3) ымлыклар.

**Тулы мәгънәле** сүзләр, башка сүзләргә кушылмыйча, үзләре генә дә аерым бер мәгънә аңлата, бер тәсаувыр бирә алалар.

Тулы мәгънәле сүзләр үзләре, мәгънәләрендәге аерымлыкларына карап, 9 төркемгә аерылалар:

1) фигыльләр, 2) исемнәр, 3) сыйфатлар, 4) рәвешләр, 5) саннар, 6) вакытлар, 7) урыннар, 8) алмашлыклар, 9) сораулар. Мәсәлән: *кил, кеше, кызыл, тиз, ике, былтыр, ас(т), бу, ничек*... кебекләр. Исем, сыйфат һәм алмашлыкларның үзләрен, мәгънәләрендәге аерымлыкларына карап, тагы

да берничә төркемнәргә аергаларга мөмкин (ялгызлык, күмәклек исеме, төс сыйфаты, башка сыйфатлар... кебек).

**Ким мәгънәле** сүзләрдән, башка сүзләр белән кушылмыйча, үзләреннән генә аерым бер мәгънә аңланмый. Болар үзләре кушылган сүзләргә махсус бер өстәмә мәгънә кушу белән генә аерылалар. Боларны да, кушылган сүзләренә, нинди өстәмә мәгънә бирүләренә карап, әллә ничә вак төркемнәргә аерырга мөмкин. Мәсәлән: *белән, өчен, һәр, иң, әгәр, бәлки*... кебекләр.

**Ымлыклар** булса, аерым мәгънә түгел, бәлки эчке тойгы, сизенүләрне генә аңлата торган сүзләр. Боларны да, нинди тойгы аңлатуларына карап, байтак кына вак төркемнәргә аерырга була: *аһ, уф, әй, эм, мә, тс!* кебекләр...

Болардан башка тагын эчке мәгънәләре ягыннан сүзләрне бер мәгънәле, күп мәгънәле дип тә, туры мәгънәле, кинаяле сүзләр[1] дип тә икенче төрле төркемнәргә аерырга мөмкин.

Менә мәгънә ягыннан күзәтеп төркемләгәндә, нәтиҗә шулай булып чыгарга тиеш. Ләкин шәкли грамматикада безгә сүзләрнең мәгънә ягыннан түгел, бәлки тышкы әйтелешләре ягыннан булган төркемнәренә ныграк игътибар итәргә тиеш була.

## Тышкы яктан сүз төркемнәре

Сүзләрне, тышкы әйтелешләре ягыннан булган аерымлыкларына карап, төркемнәргә аеру бездә өч төрле эшләнергә мөмкин:

1) фонетика ягыннан,
2) тамыр кисәкләренең төзелеше ягыннан,
3) морфология ягыннан.

**Фонетика** ягыннан, ягъни сүзләрнең авазларында күренгән табигатенә, аваз аерымлыкларына карап, бездә сүзләрне ике төркемгә бүләргә туры килә:

1) калын сүзләр, 2) нечкә сүзләр.

Бөтен авазлары, кушымчалары белән бергә һәрвакыт калын гына әйтелеп йөри торган сүзләр «калын сүзләр», бөтен кушымчалары белән бергә һәрвакыт бөтен авазы нечкә генә әйтелгән сүзләр «нечкә сүзләр» була.

Калын сүзләр: *кал, калды, калдылар, калдыгызмы, урман, урманда, урмандагы, урмандагыларныкы*... кебек.

Нечкә сүзләр: *кил, килде, килделәр, килдегезме, бүре, бүреләр, бүреләрдән*... кебек.

Безнең төрек телләрендә сүзләрнең авазлары шушы рәвешле үзара ярашып, охшашып әйтелү табигатенә «сингармонизм» кануны дип әйтәләр. (Сингармонизм турында фонетика бүлегендә сүз булган иде.)

---

[1] Кинаяле сүзләр — читләтеп әйтелгән сүзләр, күчерелмә мәгънәле сүзләр, аллегория.

Тамыр кисәкләренең төзелеше ягыннан бездә сүзләрне өч төркемгә бүләргә мөмкин:

1) ялгыз сүз, 2) кушма сүз, 3) тагылмалы сүз.

**Ялгыз сүзләр** – яңадан аерым кисәкләргә бүленә алмый торган, күбрәк вакыт бер яки ике иҗекле, мәгънәле сүзләр. Тамыр сүзләрнең бу төре безнең телебездә бик күп кулланыла. Мәсәлән: *ал, кил, кеше, тор, өй, зур, белән, агач...* кебекләр. Кайбер ялгыз сүзләрнең бер үк калыпта, бер үк авазлар белән әйтелгәннәре, мәгънә ягыннан һәм морфология ягыннан берничә төрле хезмәтне үти: *ак, куш, бар, куй, ага, кара...* кебек аваздаш сүзләр. Без аларны нинди кушымчалар белән төрләнүләренә карап аерган кебек, басымнарына, аһәңнәренә, җөмләдә торткан урыннарына карап та нинди мәгънәдә булуларын бик җиңел аера алабыз.

**Кушма сүзләр** – кушымчалардан алда әйтелеп тә, яңадан ике тамыр кисәккә аерылуы мөмкин булган, ике тамырдан кушып бер нәрсәгә исем итеп йөртелгән сүзләр: *билбау, ташаяк, иңбаш, Биктимер, Сөембикә, табагач, алъяпкыч, Айсылу, аккош, ташбака...* сүзләре кебек.

**Тагылмалы сүзләр** – әйтелешләре яки мәгънәләре ягыннан бер-беренә якынлыгы булган ике сүзне янәшә китереп, бер-беренә ияртеп әйтелгән куш сүзләр. Боларның беренчесе төп, икенчесе тагылма була. Тагылма сүзнең күп вакыт аерым көенчә телдә йөртелүе дә, аерым мәгънәсе дә булмый.

*Бала-чага, сөяк-саяк, шау-шу, агач-богач, мал-туар, кием-салым, килде-китте, алай-болай, әтәм-сәтәм, шатыр-шотыр...* кебек сүзләр.

Искәрмә. Чит телләрдән кергән сүзләр, үз телләрендә теләсә нинди кисәкләрдән төзелгән булсалар да, телебездә ялгыз тамыр сүзләр кебек кулланылалар. Шуңа күрә аларны түбәндә кушымча белән яки ике-өч сүздән ясалган булуларына карамастан, бездә ялгыз тамырлар рәтендә санарга тиеш. Мәсәлән: *мәгълүмат, матбугат, коммунист, комиссариат, таныкнамә, телеграмма, социализм, комсомол, исполком, хөкүмәт, Коминтерн, Ленинград, Татарстан...* кебек сүзләр.

## Морфология ягыннан

Морфология ягыннан карап, сүзләрне төркемнәргә аеру, башка яктан карап төркемләүләргә караганда, иң катлаулы һәм безнең өчен иң әһәмиятлесе.

Бу яктан карап, сүзләрне төркемнәргә аеру өчен, аларның ялгыз авазларына, яки фәкать тамыр кисәкләренә генә карау җитми, аларның тамыр кисәкләре белән бергә кушымча кисәкләренә дә, ягъни аларның ничек ясалу, ничек төрләнүләренә дә, игътибар итәргә, сүзләрнең шушы яктан булган аерымлыкларын күзәтеп эш итәргә кирәк була. Чөнки шәкли яктан тамырларга гына карап ялгыз сүзләрне төркемнәргә бүләргә мөмкин түгел. Шуңа күрә ул яхшы ук катлаулы гына бер эш.

Икенче яктан, морфология бүлегенең эше бөтенесе белән сүзләрнең

шушы кушымчалану табигатьләрен өйрәнү, аларны бер системага салып күрсәтүдән гыйбарәт. Шуңа күрә ул безнең өчен башкалардан әһәмиятлерәк тә.

Бу яктан карап төркемләгәндә, иң элгәре безгә телебездә булган сүзләрнең тамыр көенчә төрләндерүче кушымчаларны алып-алмауларына дикъкать итәргә туры килә. (Төрләндерүче, ясаучы кушымчалар турында «кушымчалар төркеме» дигән бүлекне карагыз.) Менә шул яктан бездә сүзләр түбәндәге ике төркемгә бүленәләр:

1) төрләнүче сүзләр, 2) төрләнмәүче сүзләр.

Төрләнүче сүзләр турыдан-туры тамыр хәлендә җанлы телдә, төрләндерүче кушымчалар (төрлекләр) белән әйтелә алалар. Төрләнмәүче сүзләр, туры мәгънәләрендә алынганда, тамыр хәлендә төрлекләр белән әйтелмиләр.

Нинди төрлекләр белән әйтелә алуларына карап, төрләнүче сүзләрне без тагы ике төркемгә аера алабыз: 1) фигыльләр, 2) исемнәр.

**Фигыльләр** үзләренең азагына турыдан-туры дәрәҗәлек *(баб)*[1] һәм юклык *(ма-мә)* кушымчалары алу белән исемнәрдән аерылалар: *яз, укы, кил, бул, тор...* сүзләре кебек. Болар:

*яздыр, язма, яздырма,*
*укыт, укыма, укытма,*
*килгәлә, килмә, килешмә,*
*бүлдер, бүлмә, бүлгәләмә,*
*торгыз, торма, торгалама...*
булып әйтелә алалар.

**Исемнәр** гомумән үзләренең азагына, туры мәгънәләрендә, тамыр хәленчә килеш төрлекләрен (*ны, дан, га, гә, нең...*) кабул итә алу белән аерылалар. Мәсәлән:

*ат – атны, аттан, атка...*
*тавыш – тавышны, тавыштан, тавышка,*
*кызыл – кызылны, кызылдан, кызылның,*
*биек – биектән, биеккә, биекне,*
*ике – икедән, икегә, икене,*
*уң – уңнан, уңга, уңны,*
*югары – югарыдан, югарыга, югарыда,*
*мин – миннән, мине, миндә,*
*шул – шуннан, шуны, шуның...* кебек...

**Исемнәр** үз эчләрендә тагын берничә төркемгә бүленәләр. Бу вакыт без аларны килеш кушымчаларын кабул итүләренә карап түгел, бәлки фәкать үзләренә махсус нинди булса да берәр төрле кушымча алу-алмауларына карап аера алабыз. Бу яктан исемнәр үзләре биш төркем булалар: 1) зат исеме, 2) сыйфат исеме, 3) сан исеме, 4) вакыт-урын исеме, 5) алмашлык.

[1] Дәрәҗәлек (баб) кушымчалары – фигыль юнәлеше кушымчалары.

**Зат исеме** (яки фәкать «исем») башкалардан күбрәк тамыр хәлендә турыдан-туры «*даш-дәш, таш-тәш, сыз-сез, чы-че*» кушымчаларын кабул итә алу белән аерыла:

*юл – юлдаш, юлсыз, юлчы,*

*тавыш – тавышсыз, тавышчы,*

*акыл – акылсыз, акылчы,*

*эш – эшсез, эшче,*

*таш – ташсыз, ташчы*... кебек.

**Сыйфат исеме** (сыйфат) башка исемнәрдән артыклык төрендә (сүз башыннан берничә авазын кабатлап) әйтелә алу белән аерыла. Бу төр башка исемнәрдә булмый. Мәсәлән:

*кызыл – кып-кызыл,*

*биек – биб-биек,*

*зур – зуп-зур,*

*аз – ап-аз,*

*авыр – ап-авыр,*

*тигез – тип-тигез*... кебек.

**Сан исеме** башка исемнәрдән үзенең азагына *ынчы-енче, нчы-нче* кушымчалары кабул итүе белән аерыла:

*бер – беренче,*

*биш – бишенче,*

*кырык – кырыгынчы, бер йөз ун – бер йөз унынчы*...

**Вакыт-урын** сүзләре башкалардан *кы-гы, ке-ге* кушымчалары ялганып әйтелүләренә карап аерылалар. Мәсәлән:

*кыш – кышкы,*

*иртән – иртәнге,*

*яз – язгы,*

*өс – өске,*

*бире – бирегe*... кебек.

**Алмашлыклар** үзләрендә башка исемнәрдә табылган табигатьләрнең юклыгы белән, гомумән, ясаучы кушымчалар белән әйтелмәүләре һәм төрлекләр белән төрләнүдә дә беркадәр аерымлыклары булу белән аерылалар. (Без боларның һәрберсенең табигатьләрен алда озынлап өйрәнәчәкбез.)

Төрләнмәүче сүзләрне үзара тагы – өч төркем итеп аерырга туры килә:

1) рәвешләр, 2) ымлыклар, 3) ярдәмлекләр.

**Рәвешләр** үзләре сүз төрләндерүче кушымчалар белән төрләнмәсәләр дә, *лата-ләтә, тын-тен* кебек ясаучы кушымчалар белән исемнәрдән ясалып әйтелә торган сүзләр: *акчалата, эсселәтә, яшертен, астыртын*... кебек сүзләр.

**Ымлыклар** *-ылда-елдә, да-дә, ыра-ерә* кушымчалары белән фигыль булып ясала торган сүзләр. Мәсәлән:

*ырылда, чәрелдә, чатырда, кетердә, ялтыра*... кебек.

Төрләнми дә, ясалмый да торганнары – ярдәмлекләр: *һәм, һәр, бик, иң, белән, саен, өчен, әгәр...* кебекләр.

Шулай итеп, безнең телебездәге сүзләр, морфология төзелешләрендәге тышкы аерымлыкларына карап, нәтиҗә игътибары белән барсы тугыз төркем булып чыгалар:

1) фигыльләр, 2) исемнәр, 3) сыйфатлар, 4) саннар, 5) вакыт-урыннар, 6) алмашлыклар, 7) рәвешләр, 8) ымлыклар, 9) ярдәмлекләр.

Боларның эченнән **фигыль, исем, сыйфат, рәвеш** төркеменә кергән сүзләр башка сүз төркемнәреннән дә ясала алалар. Калганнары башка төркемнән ясалмыйлар, ләкин ярдәмлекләрдән башкалары, үзләре югарыгы дүрт төркем сүз булып ясала алалар (12 табл.).

**Сүз төркемнәре схемасы**

*12 таблица*

| | Төрләнүче сүзләр | | | | | | Төрләнмәүчеләр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «килеш» белән төрләнүчеләр | | | | | | | |
| | *ма-мә* белән төрләнүчеләр | *чы-че, сыз-сез* ялганучылар | *кып-ап...* алучылар | *ынчы-енче, нчы-нче* ялганучылар | *кы-ке, гы-ге* ялганучылар | фәкать «килеш»челәр | *ылда-елдә* ялганучылар | *лата-ләтә ле* сүзләр | ясалмаучы сүзләр |
| Ясалма да була торганнар: | фи-гыль-ләр | исем-нәр | сый-фат-лар | – | – | – | – | рә-веш-ләр | – |
| Ясалма булма-ганнар Үзләре ясау-чылар: | – | – | – | сан-нар | ва-кыт урын-нар | ал-маш-лар | ым-лык-лар | – | – |
| Ясалмаучылар: | – | – | – | – | – | – | – | – | яр-дәм-лек-ләр |

## Кушымчаларның төркемнәре

Тамыр сүзләрнең азагына кушылып, калынлык, нечкәлектә тамырның әйтелешенә ияреп йөргән сүз кисәкләрен – барын бергә без «кушымчалар» дип атаган идек.

Бу кушымчалар безнең төрек телләрендә бик зур урын тоталар. Морфология бүлеге, тоташы белән диярлек, шушы кушымчаларның табигате белән танышудан гыйбарәт. Алар бездә байтак бар. Аларның, бер

тамырга ялгыз берәве генә кушылганы кебек, берничәсе янәшә килеп кушылулары да бар. Кушымчаларның табигатен ныклап өйрәнми торып, аларның кануннарын ачарга мөмкин түгел. Шуңа күрә бездә тамыр сүзләрне генә түгел, кушымчаларны да төрле-төрле төркемнәргә аерып тикшерергә тиеш була. Шул чакта гына безгә телебезнең кушылмалык табигате нидән гыйбарәт булганлыгы хакында ачык бер тәсаувыр алып, телебезнең механикасын төшенергә, чит телләрнең морфологиясенә ияреп эш итүдән котылырга мөмкин булачак. Әлегә хәтле бездә кушымчаларны төркемнәргә аерып күрсәтүче юк иде.

Кушымчаларны эчке мәгънәләре ягыннан төркемнәргә аерып бетәрлек түгел, аларның берәүсе генә дә, урынына карап, әллә ничәшәр мәгънәдә йөри. Шуңа күрә аларны фәкать тышкы яктан карап кына төркемнәргә аерырга була.

Безнең телебездә кушымчалар, үзләренең тоткан урынnарына, хезмәтләренә карап, иң элгәре өч зур төркемгә аерылалар:

1) сүз ясаучы кушымчалар (ясагычлар – суффиксы);

2) сүз төрләндерүче кушымчалар (төрлекләр – окончания);

3) өстәмә кушымчалар.

**Сүз ясаучы кушымчалар** (ясагычлар яки нигезлекләр) – тамыр кисәкнең артыннан ук беренче чиратта килеп кушылган кисәкләр. Болар үзләре кушылган тамыр сүзләрдән яңа сүзләр ясауга, тамыр сүзнең мәгънәсен күбәйтүгә, төрләндерүгә хезмәт итәләр.

Төрле ясалма сүзләр һәм төрле фигыль, исем, сыйфат дәрәҗәләре ясаучы кушымчалар шушы төркемгә керәләр.

Ясаучы кушымчалар үзләре, тамыр сүзгә нинди тәртиптә килеп тоташуларына һәм хезмәтләренә карап, өч рәткә – катарга аерылалар:

1 нче рәт ясагычлар төрле тамыр сүзләрдән җөмлә кисәге булган яңа сүзләр ясау өчен килеп кушылалар, болар саф ясаучылар гына. Мәсәлән: *эшлә, эшче, атлы, ачкыч, кичке, беренче, агар, уфылда, шулай...* дигән сүзләрдәге *лә, че, ле, кыч, ке, енче, ар, ылда, лай* кушымчалары шул беренче рәттәге ясагычлар булалар. Боларның хәзерге көндә тамыр кисәкнең аерылмас бер кисәге булып киткәннәре – онытылганнары да бик күп. Мәсәлән: *бөтен, өчен...* сүзләрендәге *ен* кебек.

2 нче рәт ясагычлар – бу беренче рәтнең артыннан, яки алар булмаганда, турыдан-туры тамыр сүзләргә кушылып, аларның мәгънәсен төрле юнәлешкә, төрле дәрәҗәгә куя торган кушымчалар. Болар фигыльләрдә фигыль дәрәҗәләре (баблар), исемнәрдә иркәлек-кечелек, сыйфатларда сыйфат дәрәҗәләре ясауга хезмәт итәләр. Мәсәлән: *алдыр, эшләш, уфылдат, малкай, ачкычкай, эшчекәй, каракай, саргылт, маллырак, аксыл... сүзләрендәге дыр, ш, т, кай-кәй, гылт, сыл, рак...* кушымчалары кебек.

3 нче рәттә эшнең булмавын белдерү өчен кушылган *ма-мә, мый-ми* кушымчалары килә. Болар фәкать фигыльләргә генә кушылалар. Мәсәлән: *алдырма, эшләтмә, язгалама...* кебек. Беренче һәм икенче рәт кушымчалары булмаганда, бу соңгылар да тамыр сүзләргә турыдан-туры кушылалар.

Бер үк сүздә 1 нче һәм 2 нче рәт ясагычлары берничәсе янәшә килергә дә мөмкин. (Болар хакында сүзләрнең ясалышын сөйләгәндә тулырак мәгълүмат бирeләчәк.)

**Сүз төрләндерүче кушымчалар** (төрлекләр) – ясаучы кушымчалардан соң икенче чиратта килеп кушылган кисәкләр. Болар сүзнең төп мәгънәсен, аның көчен дә үзгәртмиләр, бәлки җөмлә эчендә сүзләрнең бер-беренә мөнәсәбәтен, бәйләнешен күрсәтү өчен кушылалар. Без бу кушымчаларга карап, аерым сүзләрнең кайда бәйләнгәнлеген һәм җөмләнең нинди кисәге булганлыгын аерып беләбез. Шуңа күрә боларны нәхви кушымчалар[1] дип тә атыйлар. Болар үзләре, нинди сүзләргә кушылуларына карап, фигыль төрлекләре һәм исем төрлекләре дигән ике төркемгә аерылып, һәрберсе, нинди тәртиптә килеп кушылуларына карап өчәр катарга (рәткә) бүленәләр.

Ясаучы кушымчалар булмаганда, төрләндерүче кушымчалар үз төркемендәге тамыр кисәкләргә турыдан-туры да килеп кушылалар. Фигыль төрлекләре тамыр фигыльләргә, исем төрлекләре, гомумән, исемнәргә шул көенчә кушыла алалар.

Безнең телебездә кушымчаларның иң ачык тәсаувыр ителгәннәре шушы төрләндерүче кушымчалар. Аларның башкалардан алдынрак, ачыграк тәсаувыр ителүенең сәбәбе, җөмләдә сүзләрнең төрле урында килүенә карап, бер кушылып, бер аерылып торуларыннан, күп йөртелүләреннән (шуңа күрә, тел сабакларында төрләндерүче кушымчаларны сүз ясаучы кушымчалардан алдарак өйрәтү уңышлырак санала).

Фигыльләрдә заман, япсару, исемнәрдә сан, япсару, килеш *(дан-дән, да, га, ны...)* төрлекләре шушы кушымчалар җөмләсендә булалар. (Боларны озынлап сүзләрнең төрләнешен сөйләгән җирдә күрербез.)

**Өстәмә кушымчалар**. Бездә өстәмә кушымчалар белән төрләнмәгән сүзләр юк диярлек. Болар теләсә нинди сүзләргә иң азакны чиратта килеп кушыла торган, төп сүзнең басымын да үзләренә үткәрми торган кисәкләр. Болар әйтелгән сүзнең мәгънәсенә бер чик кую, очлау өчен, кайсылары җөмлә эчендә сүзнең бәйләнешен белдерү өчен кушылалар: *ук-үк, гына-генә, кына-кенә, рак-рәк, да-дә, та-тә, сана-сәнә, ла-лә, мы-ме, мыный-мени, мын-мен, сың-сең, быз-без, сыз-сез...* кебек кушымчалар шушы төркемгә керәләр

Шуның белән бергә, тамыр сүзләрне ялгыз һәм кушма дип аерган

[1] Нәхви кушымчалар – синтаксик кушымчалар, сүзләрнең үзара бәйләнешләрен күрсәтүче кушымчалар.

кебек, кушымчаларны да, ялгыз кушымча, кушма кушымча дип бүләргә туры килә.

Югарыда күрсәтелеп үткән кушымчаларның ялгыз бер кисәктән гыйбарәт булган көенчә генә үз хезмәтләрен (мәгънәләрен) үти алганнары ялгыз кушымчалар булып, ике я өч кисәктән кушылып, янәшә килгән чагында үзенә башка, аерым бер мәгънә өчен кулланган кисәкләр кушма кушымчалар булалар.

Мәсәлән: *ганчы-гәнче, канчы-кәнче, арлык, әрлек, гәнгә, ганга, гәнлектән, ганлыктан, гәндә, ганда, макчы, мәкче, арга, әргә...* кушымчалары 2–3 кисәктән кушылган булып, үзләренә аерым, яңа мәгънәләр, яңа мөнәсәбәтләр өчен кулланылалар.

Сарыфта тамыр кисәкләрнең ялгыз әйтелгән хәле дә, бер яки берничә кушымча белән әйтелүе дә үзенә башка бер төр (форма) саналган кебек, кушма кушымчалар белән әйтелгән рәвеше дә бер төр булып саналырга тиеш. (Без боларның тәртипләрен, табигатьләрен алда күрербез).

## 3. СҮЗЛӘРНЕҢ ЯСАЛЫШЫ

Безнең төрек телләрендә тамыр сүзләр артык куп түгел. Шуңа күрә бездә бер сүздән икенче сүз ясау бик зур, мөһим[1] урын тота. Бездә сүзләрнең ясалышы өч төрле булырга мөмкин:

1) фонетик төрдә – сүзнең авазын, яки басымын үзгәртү белән;

2) сарфый төрдә – кушымчалар ялгау белән;

3) нәхви төрдә – ике сүзне бергә кушып әйтү, яки кайталау белән.

**Фонетика ягыннан**, тамыр сүзнең авазларын үзгәртү юлы белән бер сүздән икенче сүзләр ясау безнең телебездә хәзерге көндә юк, ләкин бик борынгы бер дәверендә безнең телебездә бу төрле дә сүзләр ясауның булганлыгы сизелә. Мәсәлән: *аяк – азак, чакыр – кычкыр, таш – теш – тыш – ташу, кыс – сык, баз – бас, күр – күз, өй – оя, себер – сыйпа, куз – кур, куй – кой, ти – той, як – йок, укер – угез, куч – кич, кап – кабат – кабак – капка, кабару, капаю, кабан, капчык, кабырчык, кабырга, кабыз, капкач, капыл, кавым, кавын, кауша, кавырсын, кавышыр, кавак, кавыш, симез, симер...* кебек, авазлары бер-беренә якын булган сүзләрнең бер асылдан, фәкать аваз үзгәртү юлы белән ясалганлыкларын аларның мәгънәләре бер-беренә якынлыкларыннан аңларга мөмкин.

Бер сүзнең басымнарын үзгәртеп, икенче сүзләр ясау да бездә бик еш очрый. Мәсәлән:

*бáтыр – баты́р, áша – ашá, кáра – карá, и́рек – ирéк, áшык – ашы́к...*

[1] Мөһим – әһәмиятле.

кебек авазлары һәм мәгънәләре ягыннан бер-беренә охшаш, якын булган сүзләрнең басым урынын үзгәртү белән генә бер-береннән ясалган булулары мөмкин. Болардан башка бер сүзнең калынлык, нечкәлеген үзгәртү белән дә икенче сүз ясалуны очраткаларга була. Мәсәлән, *сыпыр – себер, тыш – теш, сук – сүк,* кебекләр.

Нәхви төрдә, ике сүзне бергә кушып, яңа мәгънәдәге сүзләр ясау (кушма сүзләр) да безнең телебездә күп кенә бар. Аларның борынгырак дәвердә ясалганнары, хәзерге көндә бер сүз булып, сизелмәслек дәрәҗәдә үзгәреп киткәннәр. Мәсәлән:

*Билбау – бил + бау*
*Аккош – ак + кош*
*Алъяпкыч – алын + япкыч*
*Сугар – су + бир*
*Кумәч – куммә + аш*
*Умач – ума + аш*
*Алабута – ала +ут*
*Кузгалак – кузы + колак*
*Ярканат – яры + канат*
*Читек – эч + итек*
*Ыштан – эч + тун*
*Гомбагыш – көн + багыш*
*Балавыз – бал + авызы*
*Кандала – кан +талар*
*Арыслан – арсыл+аң*
*Куян – куй +аң*
*Абыстай – абыс + тутай*
*Абзый – абыз + агай*
*Албасты – алып + басты*
*Беләзек – беләк + йөзек*
*Күгәрчен – күк + иярчен*
*Сиксән – сигез + ун*
*Туксан – тугыз + ун*

Гомумән, 3 буынлы төп сүзләрне ныклап тикшергәндә, аларның күбесе ике сүздән кушып ясалганлыгы беленә. *Апкил (алып кил), аббар яки аппар (алып бар), бөген (бу көн), быел (бу ел), нишли (ни эшли)...* кебек, хәзерге көндә кыскарып ясалып яткан сүзләр дә бар.

Бер сүзне кайталау – тәкърар әйтү юлы белән икенче мәгънәдәрәк сүзләр ясауга мисалны рәвешләрдә очратырга мөмкин. Мәсәлән:

*килә-килә, тора-тора, укый-укый, шәп-шәп, салып-салып...* төрендәге рәвешләр.

Бездә кайталау юлы белән икенче мәгънәдәге сүзләр ясауның икенче бер төре – тагылмалы сүзләр. Бу тагылмалы сүзләр бер-беренә якынлыгы, җенестәшлеге булган ике сүзне бергә кушып әйтү белән ясалалар, монда аларның ике сүздән ясалганлыгы ачык беленеп тора. Бу тагылмалы сүзләр дә безнең телебездә байтак күп кенә. Мәсәлән: *бала-чага, карт-коры, хатын-кыз, кеше-кара, агай-эне, тау-таш, мал-туар, үлем-җитем, ава-түнә, алпан-тилпән, чытыр-чатыр...* кебек сүзләр. Бу тагылмаларның хәзерге көндә ясалуы күренми. Алар халык телендә борынгы әйтелгән көенчә сакланып киләләр. Шуңа күрә болар арасында безнең байтак кына онытылган сүзләребез дә очрый. Соңгы вакытта тагылма сүзләр бездә элекке сүзнең башындагы авазын м авазына үзгәртеп кенә кабатлау белән ясала. Мәсәлән: *ит-мит, чәй-мәй, әз-мәз...* кебек.

**Сарфый төрдә**, төрле кушымчалар ялгап әйтү белән, бер сүздән икенче сүзләр ясау – бусы безнең телебездә сүз ясалышының иң күп, иң мәшһүр бер төре.

Сүз ясаучы кушымчалар безнең телебездә бик күп. Аларның тамыр сүзгә кушылып үзгәреп киткәннәре, сөйләүченең аңында кушымча икәнлеге сизелмәслек булып онытылганнары да байтак кына.

Аларны тикшереп, казып чыгару – тарихи грамматика эше. Хәзерге грамматика телнең, җанлы телебездә барлыгы ачык беленеп торган, тышкы фактлары белән генә эш итә. Телебездә кушымча кушып ясалганлыгы ачык беленмәгән сүзләр безнең мәктәпләребездә фәкать тамыр сүзләр рәвешендә каралып үтелергә тиеш.

Мәсәлән: *багана, кашага, тилегән, балтырган, тәрәзә, капка, күләгә, күгәрчен, күрәзә, йомгак, капкан, күлмәк, ыкчым, билчән, үләт, елдам, сөңге, умач, пычак, сандугач, карлыгач, кыяр, кавын, суган, аркан, елан, көмеш, өчен, бөтен...* кебек сүзләр төбендә берәр ялгау кушып ясалган сүзләр булса да, дәреслек грамматикада тамыр сүзләр итеп кенә каралырга тиешләр.

Сүз ясаучы кушымчаларның өч рәткә бүленгәнен, боларның беренче рәттәгеләре саф ясаучы кушымчалар булганлыгын күреп үткән идек. Менә шушы беренче рәттәге ясаучы кушымчалар ялганып ясалган сүзләрне «ясалма сүзләр» дип йөртәләр.

Кайбер төрләндерүче кушымчалар белән төрләнгән сүзләрдән дә, ясаучы кушымчалар ялгап, икенче төрдәге сүзләр ясала ала. Мәсәлән: *авылда – авылдагы, нәселдән – нәселдәнлек, беләм – «мин беләмлек дәгъвасы – бер мең вагон»* (Г. Тукай).

Кайбер сүзләрнең бер төркемнән икенче төркемгә берничә мәртәбә кабат-кабат ясалуларын да очратырга мөмкин. Мәсәлән: *аш – ашчы – ашчылык, бел – белем – белемле – белемлелек* һ. б.

Ясалма сүзләр бездә дүрт төркем булалар:

1) фигыль, 2) исем, 3) сыйфат, 4) рәвеш. Димәк, бездә ясаучылар белән иң әһәмиятле булганга шушы сүзләр генә ясала.

2 нче рәттәге ясаучы кушымчалар кушылу белән сүзләрдән төрле юнәлеш, төрле дәрәҗәдә булган бер үк төркемдәге сүзләр ясала, шуңа күрә боларны дәрәҗә ясаучылар дип атарга мөмкин. Бу икенче рәт ясагычлар белән бездә бары фигыльләр, исемнәр, сыйфатлар гына ясалалар.

3 нче рәттәге ясаучы кушымчалар фәкать фигыльләрдә генә була ала. Гомумән ясаучы кушымчалар кайсы төркемдәге сүзгә кушылуларына, нинди төркемдәге тамырдан, нинди яңа сүз ясауга карап, бер-берсеннән аерылалар.

Хәзер без югарыда әйтелгән дүрт төркемдәге ясалма сүзләрнең нинди ясагычлар белән һәм нинди төркемнәрдән ясалуын тикшерә башлыйбыз.

## Ясалма фигыльләр

Безнең телебездә ясалма фигыльләр, күбрәк түбәндәге беренче рәт фигыль ясагычлар кушылу белән, түбәндәге сүз төркемнәреннән ясалалар (13 табл.).

Ясагычтан башка да фигыль кушымчалары белән төрләнә алган сүзләр «тамыр фигыльләр» дип аталалар.

13 таблица

| Ясагычлар | Нинди сүзләрдән | Ясалма фигыльләрнең үрнәкләре |
|---|---|---|
| *Ла-лә* | бөтен сүз төркемнәреннән | *Эшлә, җырла, күзлә, майла, йокла, акла, төзлә, орынла, матурла, берлә, унла, йөзлә, меңлә, шаула, гөрлә, ыжла, безлә, кышла, җәйлә, соңла, тизлә, эчлә, барла, юкла.* |
| *Лаш-ләш* | исемнәрдән | *усаллаш, көнләш, урынлаш* |
| *да-дә*<br>*ылда-елдә*<br>*ыра-эрә*<br>*дыра-дерә*<br>*ай-әй* | ымлыклардан, сыйфатлардан | *чатырда, кетердә, шатырда, такылда, чәрелдә, безелдә, уфылда, ялтыра, келтерә, өлтерә*<br>*шалтыра, мөлдерә*<br>*матурай, турай, ныгай, авырай, күбәй, саргай, шәбәй* |
| *а-ә* | исемнәрдән, сыйфатлардан | *кана, тешә, аша, яшә.*<br>*буша, төзә* |
| *ар-әр-р* | сыйфатлардан | *агар, күгәр, кызар, кыскар, яхшыр* |
| *кар-кәр*<br>*ык-ек-к* | исемнәрдән, сан һәм сыйфатлардан | *башкар, җилгәр, искәр, сугар, күзлек, илек, юлык*<br>*тарык, ачык, берек* |
| *сын-сен*<br>*сыт-сет* | сыйфатлардан | *кимсет, күпсен, азсын, кимсен* |
| *ы-э(е)*<br>*ра-рә* | сыйфаттан<br>– | *кимсет, күпсен, азсын, кимсен*<br>*ныгы, бае (байы), төзе*<br>*әлсерә, мәлҗерә, инрә, мөңрә* |

Бу күрсәтелгән төрләрдән башка, сирәк сүзләрдә генә очрый торган фигыль ясаучы кушымчалар да бар. Мәсәлән: *кара, су, тын, төп, сөр, ни...* сүзләреннән *карал, суса, тынчы, төпче, сөрсе, нит...* фигыльләре ясалганнар.

Югарыда күрсәтелгән кушымчаларның иң күп йөргәннәре – иң алдан күрсәтелгәннәре. Кайвакыт тамыр фигыльләрнең үзеннән дә, ясагычлар белән, икенче мәгънәдәрәк фигыльләр ясау бар.

Мәсәлән: *кунек, тапшыр, ашык, ташы, купшы, кызык...* фигыльләре *кун, тап, аш, таш, куп, кыз* дигән тамырлардан ясалганнар.

*Ла-лә* ясагычлары, тамыр сүзләрнең туктар авазына карап, татар телендә ике төрле (*аңна, тыңна, имнә...* төре дә) әйтелеп йөри. Кыргыз-казах телләрендә өч төрле (*ла-лә, та-тә, да-дә*), башкорт телендә дүрт төрле (*ла-лә, та-тә, да-дә, за-зә*[1]) әйтелеп йөриләр.

[1] Интердентальь (сакау) [з] (ягъни телнең очын аскы һәм өске тешләр арасына куеп әйтелә торган) авазы. – *Ред.*

Ылда-елдә кушымчалары үзбәк телендә ылла-еллә рәвешендә әйтелә: шакылла, кыймылла... кебек.

Татар телендәге кайбер фигыльләрдә казах, башкорт телендәге *та-тә* төре дә сакланып калган. Мәсәлән: *макта (макла), кыста (кысла), тапта (тапла)* сүзләре кебек. Фигыльләрнең беренче рәт ясагычлары кушылып ясалулары бездә артык күп түгел. Фигыльләр үзләре күбрәк башка сүзләр ясауга нигез булып хезмәт итәләр.

Искәрмә: *Лаш-ләш* кушымчалары *ла+ш, лә+ш тән, сет, сен* кушымчалары *се+т, се+н нән* кушылганнар.

## Фигыль дәрәҗәләре (баблар)

Безнең телебездә фигыль дәрәҗәләре (искечә баблар) тамыр яки ясалма фигыльләргә 2 нче рәт фигыль ясагычлары кушылу белән ясалалар. Дәрәҗә ясагычлары тамыр фигыльләргә беренче булып, ясалма фигыльләргә 2 нче рәт булып кушылалар. («Баблар» дигән атама безгә гарәпләрдән кергән.) Мәгънә ягыннан бу икенче рәт ясагычлар гомумән сүзнең гамәли көчен, әсәрен, дәрәҗәсен күрсәтәләр. Шуңа күрә аларны телебезнең табигатенә мовафыйк уртак бер атама белән «дәрәҗә ясагычлар» дип, болар белән ясалган фигыльләрне дә «фигыль дәрәҗәләре» дип атау мовафыйк булса кирәк[1]. Бу атама фигыльләрнең төзелеш ягыннан сыйфатка охшаганлыгын да күрсәтеп торачак.

Бездә фигыль дәрәҗәләре (баблар) ничә һәмниләр? Сүзләрне төркемнәргә аергандагы кебек, телебездәге фигыль дәрәҗәләрен билгеләүдә дә безгә шәкли нигезгә таянып эш итәргә тиеш була. Фигыльләрне шәкли нигезгә таянып дәрәҗәгә аеру белән мантыйкый нигезгә таянып дәрәҗәләргә бүлү арасында нинди аерма барлыгын күрсәтү өчен, мисал урынында, элгәре бездәге мантыйкый дәрәҗәләрне күрсәтеп үтәм.

## Мантыйкый яктан фигыль дәрәҗәләре

Фигыльләрне саф мантыйкый җәһәттән, аларның нинди тәмамлыклар теләвенә карап, дәрәҗәләргә аерганда, бездә түбәндәге дәрәҗәләр килеп чыгар иде.

1) **Үтем дәрәҗәсе** – төшем тәмамлыгын теләүче фигыльләр, теләсә ялгау кушылсын, теләсә кушылмасын, бары да шуңа керәләр. Мәсәлән: *укы, җиң, укыт, җиңдер, яз, яздыр, караштыр, белеш...* (кемне? нәрсәне?).

2) **Чыгым дәрәҗәсе** – чыгым тәмамлыгын теләүче фигыльләр. Болар да тышкы яктан төрле дәрәҗәдә булырга мөмкин: *ал, куч, уткәр, кайтар, чыккала...* (кайдан? нәрсәдән? кемнән?).

3) **Юнәлеш дәрәҗәсе** – юнәлеш тәмамлыгын теләүчеләр: *кара, кит, утырт, килгәлә, караштыр...* (кемгә? нәрсәгә? кая?).

4) **Калым дәрәҗәсе** – болардан башка тәмамлыкларны теләүче фигыльләр:

---

[1] Фигыльләрдәге бу категория хәзерге татар грамматикаларында «Фигыль юнәлешләре» дип атала. – *Ред.*

*йокла, көлемсерә, кыжмырда...* (кайда? кайчан? ничек?). Бу бабның «калым» дип аталуының сәбәбе – югарыгы өч тәмамлыкны теләмәвенә карап кына атала. Ләкин теләсә нинди фигыль калым бабының тәмамлыкларын (вакыт, урын, сәбәп, рәвеш...) теләүләре мөмкин.

Бер үк фигыльдә боларның төрле табигатьләре катнаш булырга мөмкин. Аларда катгыйлык юк. Мәсәлән: *кучер* фигыленә *нәрсәне, кайдан, кая, кайчан, ни белән, ничек, ни өчен күчерергә?* дигән сөальләр килә. Димәк, бу фигыль бөтен тәмамлыкны да тели.

Менә мантыйкый яктан бездә фигыль дәрәҗәләре шулар булып чыга.

## Шәкли яктан фигыль дәрәҗәләре

Чын грамматика буенча, тышкы формаль якны гына әсас итеп алганда, безнең телебездә фигыль дәрәҗәләре, икенче төрле әйтсәк, фигыльләрнең 2 нче рәт ясагыч кушымчалар белән төрләнеше, түбәндәгечә булырга тиеш:

1) **Төп фигыль дәрәҗәсе** – 2 нче рәт ясагычтан башка әйтелгән тамыр яки ясалма фигыльләр. Мәсәлән: *ал, утыр, аша, эшлә, шәбәй, ялтыра, төпче...* кебек.

2) **Уртаклык дәрәҗәсе** – *ыш-еш-ш* – кушымчасы кушылып әйтелгән тамыр яки ясалма фигыльләр: *алыш, утырыш, эшләш, языш, ялтыраш, төпчеш, көнләш...*

Кыргыз телендә бу баб бик зур урын тота. Аларда фигыльләрнең күплек саны да күп вакыт шундый баб белән үтәлә. Мәсәлен: *җатышды* (яттылар), *килешде* (килделәр).

3) **Йөкләтү дәрәҗәсе** – күбрәк *ыр-ер, ыт-ет-т* ясагычлары кушып әйтелгән фигыльләр.

Татар телендә фигыльнең туктар авазы сузык булганда *т* ялгавы, яңгыравыклы аваз булганда *дыр-дер* ялгавы, яңгыравыксыз аваз булганда *тыр-тер* ялгавы тоташа. Кайбер фигыльләрнең бөтенләй үзенә махсус йөкләтү ясагычлары да бар: *сәт, кар, кәр, гәр, гәз, гез, гыз, р, з, дар...*

Мәсәлән: *карат, эшләт, укыт, калдыр, яздыр, үстер, түктер, күрсәт (күстәр), үткәр – үткәз, эчер, имез, кергез, аудар, китер, пешер, торгыз...*

4) **Кайтым дәрәҗәсе** – *ыл-ел-л, ын-ен-н* ясагычы кушып әйтелгән фигыльләр: *укын, укыл, юын, алын, ашан, эшлән, язын, языл, бәрел, киерел, сузыл, капшан...*

Бу дәрәҗәне, ясагычларына карап, *н* белән әйтелгәннәрен «билгеле кайтым» дип, *л* белән әйтелгәннәрен «билгесез кайтым» дәрәҗәсе дип, икегә аерырга мөмкин.

5) **Кимлек дәрәҗәсе** – *емсерә-мсерә, ымсыра-мсыра* ясагычлары белән әйтелгән фигыльләр: *көлемсерә, йокымсыра...* кебек.

6) **Өстәү дәрәҗәсе** – *енкерә-нкерә, ынкыра-нкыра* ясагычлары кушып әйтелгән фигыльләр: *киленкерә, исәнкерә, тартынкыра...*

7) **Кабатлау яки сирәклек дәрәҗәсе** – тартык авазга туктаган фигыльләрдә күбрәк *гала-гәлә, кала-кәлә* ясагычлары, сузык авазга туктаган фигыльләрдә *штыр-штер* ясагычлары кушып әйтелгән фигыльләр: *алгала, килгәлә, ашаштыр, караштыр, укыштыр*...

Боларны *кил + еш + тер, ал + ыш + тыр* төрендә, ике катлы дәрәҗә ясагычы белән әйтелгән фигыльләр белән саташтырмаска кирәк. Килгәлә урынына килештер дип әйтү, аналогия буенча, ялгыш таралган.

*Кара + ш + тыр, эшлә + ш + тер* – ике кешене бер-беренә мәгънәсендә, ә *кара + штыр, эшлә + штер,* дигәндә – бер генә кешегә сирәкләп, кабатлап эшләргә кушу була.

Бу соңгы ике төрле дәрәҗә белән төрләнеш җәнүби[1] төрек телләрендә юк. Төрле шивәләрдә боларның әйтелеш, төрләнешләрендә дә беркадәр аерымлыклар булырга мөмкин.

Бу 2 нче рәт дәрәҗә ясагычларының бер үк фигыльдә берничәсе янәшә, аралашып килүләре дә бар. Бу вакыт аларның азаккысы бабны тәгаенли[2]. Аларның тәртипләре, мәгънәнең теләвенә карап, теләсә ничек булырга мөмкин: *языштыр, яздырыш, яздырт, яздыртыш, язышкала, килгәләштер, язгалаш, тарткалаштырынкыра*...

Фигыльләрнең беренче һәм икенче рәт ясаучы кушымчалар белән төрләнеше безнең телебезнең бик зур байлыгыннан саналырга тиеш. Руслар безнең бик күп фигыльләребезне бер сүз белән генә тәрҗемә итә алмыйлар.

Мәсәлән, *каный* дигән фигыльне – русча *кровь течёт* дип, ике сүз белән генә әйтергә була. В. В. Радлов үзенең мәшһүр «Төрек телләренең лөгате» дигән китабында безнең *аптырату* дигән сүзне – русча унөч сүз белән тәржемә итәргә мәҗбүр булган:

«Заставить кого-нибудь придти в такое положение, чтобы он не знал что делать». (Опыт словаря тюркских наречий, В. В. Радлов.)

### Фигыльләрдә барлык-юклык төре

1 нче яки 2 нче рәт ясаучы кушымчалар белән ясалган яки тамыр хәлендә әйтелгән фигыльләр шул торышларынча фигыльләрнең «барлык» төре булып хезмәт итәләр. Юклык төре шул төрнең азагына 3 нче рәт *ма-мә* кушымчасы кушу белән ясала: *килмә, язма, бәрелмә, йокымсырама, килештермә, шаяртма, көнләштермә, тартынкыраштыргалама*... фигыльләре кебек. Бу *ма-мә* кушымчалары басымны үзләренә үткәрмәү белән башкалардан аерылалар.

Фигыльләрдә юклык төренең ясалышы бөтен төрек телләрендә бертөсле дип әйтергә ярый. Тик казах һәм кыргыз телләрендә генә фигыльләрнең исем фигыльгә әйләнгән төрендә аерымлык күренә. Мәсәлән: бездә *килмәгән, булмаган* рәвешендә әйтелгән исем фигыльләр казах телендә

[1] Җәнүби – көньяк.
[2] Тәгаенли – билгели, күрсәтә.

килгән җук, булган җук рәвешендә, ә кыргыз телендә *киләләк, булаләк* рәвешендә әйтеләләр. Чуваш телендә юклык төре фигыльләрнең алдына *ан-ән* кушымчалары ялгау белән ясала. Мәсәлән: *ан кай* (китмә), *ән пул* (булма) кебек.

Шушы өч рәт ясаучы кушымчалар кушылу белән фигыльләрнең ясалышы бетә. Моннан соң аларның төрләнеше, төрлекләр кушып әйтелешләре башлана.

Грамматикада ясаучы кушымчалар белән төрләнгән сүзләр, төрләндерүче кушымчалар тоташудан элгәреге торышларынча, «нигез сүз» дип аталалар. Ясалыш гомумән тамыр сүзләргә корылган булып, төрләнеш шушы «нигез сүзләр»гә корылган санала.

Искәрмә. «Барлык, юклык» төре фигыльләрдән башка сүзләрдә түгел ярдәмлеген кушу, кушмау белән ясала, *түгел* ярдәмлеге кушылмый әйтелгәннәре барлык төре саналып, кушылып әйтелгәннәре юклык төре санала.

Бу вакыт *түгел* ярдәмлеге сүз төрлекләреннән соң 3 нче чиратта гына әйтелә. Мәсәлән, *кеше түгел, авыллардан түгел, килгәнлекләреннән түгел* кебек. Сыйфат һәм рәвешләрдәге *сыз-сез* ялгавын болар белән саташтырырга ярамый.

## Ясалма исемнәр

Исемнәр башка сүз төркемнәреннән түбәндәге беренче рәт ясагыч кушымчалар белән ясалалар. Ясагычтан башка исем булып йөргән сүзләр «тамыр исемнәр» дип, ясагыч кушып әйткәннән соң исем булган сүзләр «ясалма исемнәр» дип аталалар (14 табл.).

Исем ясаучы ялгаулар бездә байтак күп кенә. Мин монда аларның мәшһүррәкләрен, башкалар тарафыннан ачып аңлатылмаган һәм башка төрләр белән саташтырып йөртелгәннәрен генә күрсәтеп китәм.

*14 таблица*

| Нинди сүз төркеменнән (мәгънәсе) | Ялгавы | Ясалма исемнең үрнәге |
|---|---|---|
| Тамыр һәм нигез фигыльләрдән: | *у-ү* | *язу, килү, килмәү, алдырту, утырышу, йөрештергәләү. Уку – яктылык, ә укымау – караңгылык* (үзбәк телендә бу төр сирәк). |
| | *ыш-еш-ш* | *алыш-биреш, сугыш, йөреш, торыш, яздырыш, көнкүреш, ярыш, күрәш.* (Казах телендә бу төрдә исем ясалу юк. Үзбәкләрдә һәрвакыт шул төрдә ясала.) |
| (эш исемнәре) | *мак-мәк, асы-әсе, ыйсы-исе* | *ашамак, эчмәк, яшәмәк, сөйләшмәк, аласы, күрәсе, ярасы, карыйсы, йоклыйсы, яздыртасы, киленкерисе...* (Кайбер төрекләрдә *гүргем, алгысы* кебек төр дә бар.) |
| | *ма-мә, ым-ем-м* | *алма, сөзмә, каптырма, оешма, башкарма, үлем-җитем, өзем, белем, кабым, басма, язма, җәймә.* |

| | | |
|---|---|---|
| (әйбер исемнәре) | *ынты-*<br>*нты (нды)*<br>*енте-нте (нде)* | *казынты, кисенте, агынты, йогынты, үренте.* |
| (корал исемнәре) | *гыч-геч,*<br>*кыч-кеч* | *ачкыч, казыгыч, сөйдергеч, элгеч, тишкеч* (Бездә *у-ү* ялгавы белән нигез фигыльләрнең бөтен төреннән исемнәр ясала ала, башкалар белән юклык төрендәге нигез фигыльләрдән исем ясалуы юк.) |
| Сыйфат, рәвеш һәм саннардан: (сыйфат исемнәре) | *(лык-лек)*<br>*(нык-нек)* | *аклык, яшьлек, җүләрлек, кызулык, шәплек, калынлык, нечкәлек, белгәнлек, тимерчелек, тырышчанлык, караңгылык, төшенкелек, аңсызлык, беренчелек, күренмәгәнлек, җәйгелек, кышлык, берлек, бишлек, йөзлек, түгеллек, кебеклек, сымаклык.* |
| Исемнәрдән: (әйберләрнең урыны, билгеләнгән әйбер) | *(лык-лек)* | *утынлык, тимерлек, ташлык, киемлек, тышлык, күзлек, комлык, көнлек* (татар телендә *лык-лек* кушымчалары борын авазларыннан соң *нык-нек* булып әйтелә: *көннек, тиңнек, кабымнык...*, казах һәм башкорт телләрендә, сүзләрнең төрле бетешләренә карап, *тык-тек, дык-дек, зык-зек*[1] *төрләрендә дә килергә мөмкин: җастык* (яшьлек), *тиңдек* (тиңлек), *барзык* (барлык). |
| Саннардан: (сан исеме) | *ау-әү* | *берәү, икәү, алтау, унау...* |

Болардан башка да исем ясагычлар бик күп, аларның күбесе бер я берничә сүздә генә сакланып калганнар. Аларның беразын түбәндәге сүзләрдә күрергә мөмкин:

*кушымча, таяк, кисәк, пычкы, киерге, ястык, себерке, имгәк, йомгак, пешкәк, шарлавык, гөрләвек, кискә, муенса, чормавык, язмыш, торак, ятак, имчәк, билчән, кызылча, колакчын, үләт, үләксә, сипкел, калкавыч, җилкән, янгын, очкын, каралты, карачкы, кыстыбый, бастырык, сакалдырык, телмәч, күмәч, катырка, йомырка, ябалак, күбәләк, тегермән, чытырман, карлыгач, талкан, капкан, аркан...*

Ныклап тикшергәндә, бик күп исемнәрнең ясалма сүзләр булганлыгын табарга мөмкин. Онытылган исем ясагычлары арасында бездә башка төрек телләре белән уртак булган төрләрнең дә сакланып калганы күренә, мәсәлән: *карындык* (карынлык түгел), *төядек, урындык, улемтек, янтык, ястык...* сүзләренең ясагычлары *л* авазы белән әйтелмичә, борынгы көенчә, сакланып калган булсалар кирәк.

Беренче рәт исем ясагычлары белән төрләнгән сүзләр, теләсә нинди төркемнән ясалган булсалар да, шушы кушымчалар кушылганнан соң,

---

[1] Интерденталь (сакау) [з] авазы. — *Ред.*

чын исемнәр белән бер хокукта булып, башка төрләнешләрдә бөтенләй исемнәр белән бертөсле үзгәреп йөриләр.

### Исем дәрәҗәләре

Тамыр яки ясалма исемнәрнең 2 нче рәт исем ясагычлары кушылып төрләнүләре белән иркәлек, кечелек, хурлау дигән исем дәрәҗәләре ясала.

**Иркәлек** төрләре күбрәк *кай-кәй* ясагычлары белән ясалалар: *балакай, алмакай, малкай, энекәй, эшләтүкәй, картайтукай, яшькелкәй, ашарлыккай, белгәнлеккәй*... сүзләре кебек.

**Кечелек** төрләре күбрәк *чык-чек* ясагычлары белән ясалалар: *капчык, котыйчык, янчык, төерчек, язучык, килешүчек*...

**Хурлау** төре *ук, үк, уш* ясагычлары кушып ясала: *энекәш, Апуш, Гайнүк, Хәйрүк, Шамук*... (бу соңгысы күбрәк кеше исемнәрендә очрый).

Кайвакыт исемнәр турыдан-туры 2 нче рәт ялгау белән дә башка сүз төркемнәреннән ясалалар. Бу вакыт бу төр берьюлы ике хезмәтне үтәгән була. Мәсәлән: *валчык, бөтерчек, орчык, солукай, чибәркәй, тәмлекәй, җылыкай*...

Шушы ике рәт кушымчалар кушылу белән исемнәрнең ясалышы бетеп, исем нигезләре әзерләнгән була. Моннан соң исемнәрнең сүз төрләндерүче кушымчалар белән төрләнеше башлана.

## Ясалма сыйфатлар

Тамыр көенчә сыйфат булып йөргән сүзләр «тамыр сыйфатлар» дип атала; башка сүз төркемнәреннән беренче рәт сыйфат ялгаулары кушып ясалган сыйфатлар «ясалма сыйфат» булалар. Сыйфат ясаучы беренче рәт кушымчалары да безнең телебездә бик күп. Бу урында аларның мәгълүмрәкләрен һәм сарыфларда шөбһәле җирләрне, чуалчык урыннарны ачар өчен кирәк булганнарын гына күрсәтеп үтәм (15 табл.).

Башка сүз төркемнәреннән ясалма сыйфатлар түбәндәге ясагычлар кушылу белән ясалалар:

*15 таблица*

| Нинди суз төркеменнән (мәгънәсе) | Ялгаулары | Ясалган сыйфатның үрнәге |
|---|---|---|
| **Тамыр һәм нигез фигыльләрдән** (якынлык сыйфаты) | *ынкы-енке (ыңкы-еңке)* | *кутәренке, төшенке, узынкы, сузынкы, ятынкы, тартынкы* |
| (тиешлек сыйфаты) | *ыныч-енеч ныч-неч (ыч-еч)* | *аяныч, кызганыч, имәнеч, көленеч, куркыныч, җирәнеч, таяныч, куаныч* |
| (теләк сыйфаты) | *гыры-гере кыры-кере* | *чәнчелгере, төшкере, булгыры, суккыры, тыгылгыры* |

| | | |
|---|---|---|
| (артыклык сыйфаты) | *кыр-кер гыр-гер* | *алгыр, сизгер, булгыр, тапкыр, белгер, чапкыр...* |
| (булган сыйфат) | *ык-ек-к* | *ачык, сутек, китек, ватык, җимерек, ертык,елак, бозык...* *черелдек, калтыравык...* |
| **Тамыр һәм нигез исемнәрдән:** (барлык сыйфат) | *лы-ле (ны-не)* | *атлы, маллы, ярәшүле, билгеле, укымышлы, тыйнаклы, йогышлы, күзәнәкле, каршылыклы, булдыклы, йонлы, утемле...* (Бездә *«м. н, ң»* авазына бетешле сүзләрдә *«ны-не»* төрендә әйтелә, башка төрекләрдә исә, төрле бетешле исемгә карап, *ты-те, ды-де, зы-зе*[1] төрендә дә әйтеләләр. Борынгы төрекләрдә бу кушымча лыйг, лиг төрендә булган.) |
| (юклык сыйфаты) | *сыз-сез* | *атсыз, малсыз, җайсыз, булдыксыз, юньсез, акылсыз, тәмсез, эшсез... ансыз, синсез, нисез, монсыз...* |
| (кәсеп-профессия сыйфаты) | *чы-че* | *тимерче, эшче, аучы, язучы, укытучы, сугышчы, килештерүче, төрләнмәүче, ашамакчы, килмәкче, тагылмакчы...* (Үзбәкләрдә *учы-үче* төре *ячы-гүче* булып әйтелә.) |
| (уртаклык сыйфаты) | *даш-дәш таш-тәш* | *юлдаш, иптәш, авылдаш, көндәш, казандаш, мәсләктәш, сердәш...* (Яңгыравыксыз авазга бетешле исемнәрдә *таш-тәш* әйтелә.) |
| (артыклык сыйфаты) | *чан-чән* | *эшчән, язучан, килешүчән, күлмәкчән, сүзчән...* |
| (яклаучылык сыйфаты) | *чыл-чел* | *кунакчыл, казакчыл, партиячел, советчыл...* |
| **Алмашлардан:** | *ндай-нди* | *нинди, андый, мондый, шундый, тегенди...* |
| **Саннардан:** (тәртип сыйфаты) | *ынчы-енче нчы-нче* | *беренче, икенче, алтынчы, җиденче, унынчы, ничәнче...* |
| (бүлем сыйфаты) | *ар-әр шар-шәр* | *берәр, икешәр, өчәр, алтышар, унар, йөзәр* (сузык бетешле саннарда *шар-шәр*, тартыкларда *ар-әр* килә); |
| **Вакыт-урын сүзләреннән:** (вакыт-урын сыйфатлары) | *гы-ге кы-ке* | *кичке, иртәнге, борынгы, соңгы, элгәреге, кышкы, җәйге, алгы, арткы, өске, аскы (алгандагы, кургәндәге, авылдагы, җирдәге, күптәнге, кайчангы... кебек* төрләргә бу ясагычларның кушылуы да аларда урын-вакыт мәгънәсе булудан килә). |
| **Гарәпчә сүзләрдән** | *ый-и, вый-ви* | *Фәнни, гильми, әдәби, гаскәри, гомуми, мәгънәви, тәрбияви, табигый, сәяси.* |

[1] Интерденталь (сакау) [з] авазы. — *Ред.*

Болардан башка сыйфат ясаучы мәгълүмрәк кушымчаларны түбәндәге мисаллардан күрергә мөмкин: *җитез, миңгерәү, саңгырау, калдык, баткак, җирәнчек, йонлач, картлач, бөтен, җыйнак, чабышкы, сөзгәк, тинтәк, җыентык, килмешәк, елдам, көндәм, телдәр, ыкчым...* Боларның күбесе берничә сүздә генә сакланып калган.

Исемнәрнең кайбер килеш төрләренә *гы-ге* кушып ясалган *дагы-дәге, тагы-тәге (да+гы–дә+ге...), никы-неке (ның+кы – нең+ке)* кушма кисәкләр, фигыльләрнең кайбер заман төрләренә *лык-лек* кушып, мөмкинлек мәгънәсен аңлата торган *арлык-әрлек, ырлык-ерлек...*, ә юклык төрендә *маслык-мәслек* кушымчалары һәм саннарда чама аңлату өчен йөргән *лап-ләп (ла+п-лә+п)* кисәкләре кушма көенчә үк сыйфат ясаучы кушымчалардан саналырга мөмкин. Мәсәлән:

*авылдагы, бездәге, күптәнге, алдынгы, безнеке, Галинеке, ашарлык, көләрлек, белмәслек, бирешмәслек, төшенерлек, унлап, йөзләп...* кебекләр.

Фигыль, исем һәм сыйфатларның *ла-лә, лык-лек, лы-ле, сыз-сез, чы-че, гы-ге, кы-ке* ясагычлары белән бер-берсеннән кабат-кабат, яңадан ясалулары да мөмкин. Бу вакыт, азаккы кушымчага карап, сүз төркемен билгеләргә тиеш. Мәсәлән: *яхшылык, яхшылыклы, яхшылыклану, яхшылыкланучы, артыклык, артыклыклы, тимерләнгәнлек, матурлаучылык, күренерлекле, эшчеләштерү, крестьянлашканлык...* кебек.

Беренче рәт сыйфат кушымчалары белән ясалган сыйфатлар теләсә нинди сүз төркеменнән ясалган булсын, шушы ясагычлар кушылганнан соң, тамыр сыйфатлар белән бер хокукта, һәр төрләнештә сыйфатлар белән бер үк төсле булып китәләр.

## Сыйфат дәрәҗәләре

Сыйфат дәрәҗәләренең ясалышы тамыр сыйфатларда гына була. Дәрәҗәлекләр белән төрләнү ягыннан тамыр сыйфатлар өч төргә бүленәләр:

1) төп сыйфат дәрәжәсе, 2) кимлек дәрәҗәсе, 3) артыклык дәрәҗәсе. Һичбер төрле дәрәҗә ясагычлары кушылмыйча, тамыр хәлендә генә әйтелгән сыйфатлар төп дәрәҗә төрендә саналалар. Мәсәлән: *кызыл, яшел, кара, озын, кыска, зур, күп, ерак...* кебек.

**Кимлек дәрәҗәсе** кайбер тамыр сыйфатларның азагына түбәндәге ясагычлар кушылу белән ясала:

*гылт-гелт, кылт-келт – яшькелт, саргылт,*
*лҗым-лҗем – күгелҗем, каралҗым,*
*су-сү – карасу, күксү, зәңгәрсү,*
*сыл-сел, шел – аксыл, юксыл, күкшел,*
*кылтым-келтем – ачкылтым, төчкелтем,*
*мса, ча-чә – җылымса, җиңелчә, озынча.*

Искәрмә. Сыйфатларда кимлек дәрәҗәсе шушы югарыда күрсәтелгән ясагычлар белән бернichә тамыр сыйфатларда гына очрый. Башка сыйфатларның кимлек дәрәҗәсе белән төрләнешләре юк.

Артыклык дәрәҗәсе тамыр сыйфатларның башындагы берничә авазны *п, м* авазларына кушып, сыйфатларның алдыннан кабатлап әйтү белән ясала. Мәсәлән: *кып-кызыл, зәп-зәңгәр, зуп-зур, оп-озын, төп-төз, бум-буш, җип-җиңел, ямь-яшел, түм-түгәрәк, япа-ялгыз (яп-ялгыз)*... кебек.

Артыклык сыйфатларының башына кушылган бер иҗекле кып, ап... кебек кисәкләр нәрсә? Аларга сүзнең алдына килеп кушылган кушымчалар дип карарга ярыймы? Болар телебезнең ялганмалык табигатенә, бездә кушымчаларның тамырдан соң, һәрвакыт сүз азагына килеп кушылу гадәтенә каршы килмиме? Боларның барына да *юк* дип җавап бирергә туры килә. Чөнки болар, бездәге гади кушымчалар кебек, бөтен сүзләргә, мәсәлән, бөтен сыйфатларга, уртак төрдәге кисәкләр түгел. Алар һәр сыйфатның үзенә аерым, аның белән аваздаш булалар. Шуңа күрә без бу кисәкләргә сыйфатның башыннан алынган бер кисәген кайталап әйтүдән гыйбарәт бер төр дип кенә карарга тиешбез.

Бу кисәкләрнең ясалышларына килсәк: алар сыйфатның башыннан сузык авазга кадәр булган кисәген, сузык авазның үзен дә шунда кертеп алына да, шуның азагына п яки м кебек берәр җиңел тартык аваз кушып, бер ябык иҗек ясала, соңыннан шул ясалма бер иҗекле кисәк сыйфатның алдыннан аңа кушып әйтелә. Бу кисәк төбендә сыйфатны бөтен көенчә тәкрар итүдән кыскартылган булырга тиеш.

Искәрмә. *рак-рәк* кушымчалары белән төрләнеп, безнең сарыф китапларында «чагыштыру сыйфаты» дип йөртелгән төрләр бу урында күрсәтелмәде; бу *рак-рәк* кушымчалары, үзенең иптәшләре булган *гына-генә, ук-үк* ләр белән бергә, сүзләрнең өстәмә кушымчалар белән төрләнешен сөйләгән җирдә күрсәтеләчәкләр. Чөнки алар, сыйфатларга гына түгел, безнең телебездә бөтен сүзләргә дә кушыла ала торган кисәкләр.

## Ясалма рәвешләр

Сыйфатларны исемнәрнең рәвешләре дип карасак, рәвешләрне фигыль сыйфатлары дип карарга кирәк. Рәвеш сүзләре дә безнең телебездә байтак кына мөһим һәм мөстәкыйль бер урын тоталар. Тамыр хәлендәге рәвешләр бездә артык күп булмаса да, бер яктан, сыйфатларның күбесе җөмләдә рәвеш хезмәтен үтиләр, икенче яктан, аларның башка сүз төркеменнән төрләндерүче кушымчалар белән әйтелгән төрләре телебездә бик күп йөртелә (мәсәлән, рәвеш фигыльләре, рәвеш килешләре бар). (16 табл.)

Рәвешләрнең үзенә махсус беренче рәттәге ясаучы кушымчалар белән ясалуы түбәндәге өч төрдә генә була:

1) *лай-ләй* ясагычлары белән алмашлардан ясала: *алай, болай, шулай, тегеләй, бөтенләй*... кебек.

2) *лата-ләтә* ясагычлары белән башка сүз төрләреннән ясала: *акчалата, әйберләтә, товарлата, көмешләтә, кызулата, кайнарлата, икеләтә, күрәләтә, кичләтә, соңлата...* кебек.

3) *тын-тен, ын-ен-н* ясагычлары белән, күбесенчә, вакыт-урын сүзләреннән ясала: *ерактын, якынтын, астыртын, яшертен, орынтын, кичен, җәен, кышын, иртән, көнен, көндезен...* кебек (борынгы төрекләрнең телендә, ә казах телендә хәзерге көндә дә фигыльләрнең азагына галы-гәле кушымчасы ялгап ясалган рәвешләр дә бар. Мәсәлән, *килгәле җөр – килергә йөри*). Рәвешләрнең үзенә махсус дәрәҗәлек кушымчалары юк.

## 4. СҮЗЛӘРНЕҢ ТӨРЛӘНЕШЕ

Югарыда без һәртөрле сүзләрнең ясаучы кушымчалар белән ясалышларын күреп үттек. Тамыр яки ясалма сүзләр шул торышларынча «нигез» сүзләр дип аталалар. Сүзләрнең төрләнеше шушы «нигез сүз»ләргә һәртөрле сүз төрләндерүче кушымчалар (төрлекләр) килеп тоташу белән ясала. Төрләндерүче кушымчалар җөмлә эчендә сүзләрнең бер-беренә бәйләнешен, мөнәсәбәтен билгеләү өчен кушылалар. Аларга карап, без сүзләрнең җөмләнең нинди кисәге булганлыгын, бер сүзнең кайсы сүзгә бәйләнгәнлеген аерып beләбез.

Төрләндерүче кушымчалар белән күбрәк ике төрле сүз төркеменә кергән сүзләр генә төрләнәләр: и с е м н ә р, ф и г ы л ь л ә р. Шуңа карап, төрлекләр үзләре дә ике төркемгә бүленәләр: ф и г ы л ь т ө р л е к л ә р е, и с е м т ө р л е к л ә р е. Җөмлә эчендә башка төркемгә кергән сүзләрнең бер-беренә мөнәсәбәте, аларның җөмләдә тоткан урыннары, күбрәк вакыт, сүз тәртибе белән билгеләнә. Исем я фигыль хезмәтен үтәгән чакта, башка сүз төркемнәре дә исем яки фигыль төрлекләре белән төрләнә алалар.

Төрлекләр дә, ясагычлар шикелле үк, нинди тәртиптә килеп кушылуларына карап, һәр төркеме, берничә рәтләргә бүленә. Һәр рәтнең төрлекләре, башка рәттәге төрлекләр белән аралашмыйча, үзләренә тиешле урыннарга гына килеп кушылалар.

Фигыль төрлекләре ике рәт, исем төрлекләре өч рәт булып, һәрбер рәтнең үз төрлекләре берничәшәр булалар.

Төрлекләр безнең телебездә артык күп түгел. Һәр рәтнең төрлекләре санаулы, билгеле. Боларның табигатьләрен, нинди сүзгә нинди төрлекләрнең кай тәртиптә кушылуларын түбәндә күрәчәкбез.

### Фигыльләрнең төрләнеше

Тамыр хәлендә яки фигыль ясаучы кушымчаларның берәрсе, я барысы бергә янәшә килеп кушылу белән ясалган фигыльләр төрлекләр

## Сүз ясалышлары күрсәткече

*16 таблица*

| **Ясалмалар** / **Тамырлар** | Ясалма фигыль | Ясалма исем | Ясалма сыйфат | Ясалма рәвеш | Дәрәҗәлекләр |
|---|---|---|---|---|---|
| Фигыль | | *у-ү, ыш-еш-ш, ым-ем-м, ма-мә, ыч-еч-ч, кыч-кеч-гыч-геч, асы-әсе, ыйсы-исе* | *нықы- неке, ык-ек-к, ыныч-енеч, гыры-гере, кыры-кере* | | *ыш-еш-ш, дыр-дер, тыр-тер, ыт-ет-т, ыл-ел-л, ын-ен-н, кала-кәлә, гала-гәлә, ынкы-ра-енкерә, ымсыра-емсерә* |
| Исем | *ла-лә, лаш-ләш, ык-ек, а-ә* | *лык-лек* | *лы-ле, сыз-сез, чы-че, даш-дәш, таш-тәш, чан-чән, чыл-чел* | *лата-ләтә* | *кай-кәй, чык-чек, ук-үк, уш-үш* |
| Сыйфат | *ла-лә, ай-әй, ар-әр, ы-е -се* | *лык-лек* | – | – | *гылт-келт, су-сү, сыл-сел, кылтым-келтем, лҗым-лҗем* |
| Сан | *ла-лә* | *лык-лек ау-әү* | *ынчы-енче-нчы-нче, ар-әр, шар-шәр* | – | – |
| Алмаш | – | – | *ндый-нди* | *лай-ләй* | – |
| Вакыт-урын | *ла-лә* | *лык-лек* | *кы-ке, гы-ге* | *ын-ен-н, тын-тен* | – |
| Ымлык | *да-дә, ылда-елдә, ыра-ерә* | – | – | – | – |

белән төрләнешкә нисбәтән «нигез фигыль» булып саналалар. Мәсәлән: *кил, китер, китерт, килештер, килгәлә* «нигез» булалар. Фигыльләрнең төрләнеше шушы нигез төрнең азагына үзенә махсус фигыль төрлекләре килеп кушылу белән ясала.

Фигыль төрлекләре безнең телебездә гомумән ике рәт була: 1) заман төрлекләре, 2) хәбәрлек төрлекләре[1]. Заман төрлекләре, фигыльләрнең табигатенә карап, берничә төрле булалар. Аларны без түбәндә аерып күрсәтербез.

Хәбәрлек төрлекләре гомумән «минлек, синлек, уллык» дигән өч затка (сөйләүче, тыңлаучы һәм чит затларга) нисбәт ителеп, япсарылып, аларның да ялгыз һәм күп булуларына карап, алты төрдә килә.

Безнең телебездә өч затка япсарып, алты төрдә әйтелгән үзенә аерым «зат алмашлары» да бар. Алар түбәндәге сүзләрдән гыйбарәт:

| Япсару (нисбәт) | Берлек санда | Күплек санда |
|---|---|---|
| Минлек | *мин* (ялгыз үзе турында) | *без* (үзләре күп булганда) |
| Синлек | *син* (ялгыз бер тыңлаучыга) | *сез* (күп тыңлаучыларга) |
| Уллык | *ул* (ялгыз бер чит затка) | *алар* (күп чит затларга) |

Фигыльләрдә икенче рәт хәбәрлек төрлекләре шушы япсару сүзләреннән (зат алмашларыннан) кыскартып ясалган булалар.

## Фигыль төркемчәләре

Фигыльләр, заман һәм хәбәрлек төрлекләре белән төрләнешләрендә булган аерымлыкларына карап, безнең телебездә иң элгәре өч төркемчәгә бүленәләр:

1) хәбәр фигыльләре, 2) хәл фигыльләре, 3) исем фигыльләр.

Хәбәр фигыльләрендә беренче рәттәге заман төрлекләре үзләреннән соң икенче рәттәге хәбәрлек төрлекләренең һәрвакыт калмый әйтелүен телиләр. Боларда заман төрлекләре белән хәбәрлек төрлекләре, әлбәттә, бергә, янәшә килергә тиеш була. Боларда ике кушымча бер-берсенә бөтенләй ябышкан була дияргә мөмкин. Шуңа күрә хәбәр фигыльләре һәрвакыт җөмләнең хәбәре булып кына йөриләр.

Хәл фигыльләрендә заман төрлекләре үзләреннән соң хәбәрлек төрлекләре килүне бөтенләй теләмиләр; димәк, алар һәрвакыт беренче рәт заман төрлекләре белән генә төрләнәләр һәм җөмләнең иярчен кисәкләре (вакыт, рәвеш) булып кына йөриләр.

Исем фигыльләрдә беренче рәттәге заман төрлекләреннән соң теләсә нинди кушымчалар килсә дә ирекле: алар ялгыз заман төрлекләре белән генә йөри алалар. Заман төрлекләреннән соң килгән кушымчалар сүз

[1] Хәбәрлек төрлекләре – фигыльләрнең зат белән төрләнешен күрсәтүче кушымчалар – зат кушымчалары. Фигыльләрнең сан белән төрләнеше дә шул ук кушымчалар белән күрсәтелә. – *Ред.*

ясагычлар булырга да, исем төрлекләре яки хәбәрлекләр булырга да һәм боларның берничәсе яки барсы бергә килеп кушылырга да мөмкин.

Кыскасы, хәбәр һәм хәл фигыльләре – ирексез фигыльләр; исем фигыльләр – ирекле – универсаль фигыльләр. Икенче төрле әйткәндә, хәбәр фигыле – тартучы, хәл фигыле – этәрүче, исем фигыльләр – битараф булалар.

Хәзер без боларның төрләнешләрендә булган аерымлыкларын тикшерергә күчәбез.

## Хәбәр фигыльләре

Хәбәр фигыльләре безнең телебездә, нинди төрлекләр белән төрләнешләренә карап, үзләре дүрткә бүленәләр:

1) боерык фигыле, 2) үткән (заман) фигыль, 3) шарт фигыле, 4) хәзерге (заман) фигыль. Боларның һәрберсе, югарыда әйтелгәнчә, әлбәттә, икешәр рәт фигыль төрлекләре белән төрләнәләр. Аларның бер-береннән аермалары – үзләренә махсус беренче рәт заман төрлекләре кушылуда. Боларның хәбәрлек төрлекләрендә дә беркадәр аерымлыклар бар. Аларны түбәндә күрсәтәбез.

**1. Боерык фигыле.** Боерык фигыльләре фигыльләрнең нигез төренә беренче рәттә боерыклык (үзенә махсус заман), икенче рәттә хәбәрлек төрлекләре кушу белән төрләнә.

Боерык төрлеге *ый-и, сын-сен* кушымчалары булып «синлек» нисбәтендә кушымчасыз да килә. (*Ый-и* төрлеге башка төрекләрдәге *ай-әй* дән үзгәргән.)

Боерык фигыльләрнең хәбәрлек төрлекләре, югарыда әйтелгәнчә, өч затка япсарып, алты төрдә әйтелгән түбәндәге кушымчалардан гыйбарәт (берлек санындагы «синлек» төре кушымчасыз була):

| Япсару | Берлек санында | Күплек санында |
|---|---|---|
| минлек | *ыйм-им* | *ыйк-ик* |
| синлек | – | *ыгыз-егез, гыз-гез* |
| уллык | *сын-сен* | *сыннар-сеннәр* |

Мәсәлән: *кил, берләш, шаулама* нигезләреннән боерык фигыльләре түбәндәгечә төрләнеп киләләр:

| | берлек | күплек |
|---|---|---|
| минлек | *килим, берләшим, шауламыйм* | *килик, берләшик, шауламыйк* |
| синлек | *кил, берләш, шаулама* | *килегез, берләшегез, шауламагыз* |
| уллык | *килсен, берләшсен, шауламасын* | *килсеннәр, берләшсеннәр, шауламасыннар* |

Искәрмә. Минлек нисбәтендәге боерык төрлекләренең татар телендә *ыем-ием, ыек-иек* рәвешендә әйтелеше дә бар. Берлек санындагы синлек нисбәтендәге боерыкларның үзенә аерым төрлекләре юк. Нигез төрендә әйтелгән һәрбер фигыль,

һичбер төрлек кушылмастан, берлек санында синлек нисбәтендәге боерык төре булып хезмәт итә. Моны сүз төрләрен ясауда телебезнең экономиясе дип карарга мөмкин. Экономия – кыскалык телдә иң күп йөри торган төрләрдә генә була.

Борынгы телебездә боерыкларның бу төре *гыл, гел, гын, ген* бетемнәре белән әйтелгән. Үзбәк һәм казах телләрендә хәзерге көндә дә бу төр бар әле.

Беренче рәттәге боерыклык төрлекләре төбендә *ай-әй* булып, татар телендә тартык авазга беткән нигезләрдә *ый-и, ыйм-им, ыйк-ик* төрендә, сузык авазларга беткән нигезләрдә исә, сузык авазны төшереп, шул ук *ый-и* төрлекләре кушылу белән ясала. Мәсәлән:

*бар – барыйм, барыйк (бараем, бараек),*

*аша – ашыйм (ашаем), укы – укыйм (укыем),*

*сора – сорыйк (сораек), бир – бирим, бирик (бирәем, бирәек), эшлә–эшлик (эшләек), төпче – төпчик (төпчеек).*

Көньяк төрек телләрендә тиешлек мәгънәсен аңлаткан 1 нче рәт *малымәле* төрлекләре белән әйтелгән боерыклар да бар: *Сен оны гүрмәле иденң (син аны күрергә тиешсең).*

Боерыкларның төрләнешендә башка төрек телләрендә аз-маз аерымлыклар бар (17 табл.).

**2. Үткән (заман) фигыль.** Үткән заман фигыльләре нигез төрләргә беренче рәттә үткәнлек кушымчасы *ды-де, ты-те* төрлеге белән, икенче рәттә алты төрдә боерыктан аз гына аермалы булган хәбәрлек төрлекләре белән төрләнә:

| | берлек санда | күплек санда |
|---|---|---|
| минлек | *м* | *к* |
| синлек | *ң* | *гыз-гез* |
| уллык | – | *лар-ләр* |

Мәсәлән, югарыда күрсәтелгән нигез фигыльләрдән үткән фигыль төрләре түбәндәгечә килә:

| Берлек | күплек |
|---|---|
| *килдем, берләштем, шауламадым,* | *килдек, берләштек, шауламадык, кил-* |
| *килдең, берләштең, шауламадың,* | *дегез, берләштегез, шауламадыгыз* |
| *килде, берләште, шауламады* | *килделәр, берләштеләр, шауламадылар* |

Искәрмә. Бездә яңгыравыксыз авазларга беткән нигезләрдән соң бөтен төрләрдә үткән заман төрлеге *ты-те* булып әйтелә. *Китте, тотты, берләште...* кебек.

Башкорт телендә үткән заман төрлеге дүрт төрдә килә:

1) сузык бетешле нигезләрдә *ны-не* төрендә: *караны, башланым (карады, башладым);*

2) яңгыравыксыз бетешле нигезләрдә *ты-те* төрендә: *китте, юлыкты;*

3) *м, н, ң, л* белән бетешле нигезләрдә *ды-де* төрендә: *тамды, килде;*

4) *р, в (у), и, й, з* белән бетешле нигезләрдә *зы-зе* төрендә: *барзы, куйзылар*[1].

Кыргыз телендә дылар төрлеге урынына *щды-щде* төре килә. Гомумән, кыргыз телендә 3 нче затка япсарылган күплек төрләрендә *лар-лар* төрлеге ш ялгавы белән алмашып әйтелә.

Казах һәм башка төрекләрдә – татарчадагы кебек үк; тик *гыз-гез* урынына *ңыз-ңез* төре килүдә генә аерма бар.

3. **Шарт фигыле.** Шарт фигыльләре нигез фигыльләрнең азагына үзенә махсус беренче рәт шарт төрлеге (*са-сә*) кушып, 2 нче рәттә, үткән фигыльләрдәге кебек, япсару төрлекләре кушып, алты төрдә килә.

Мәсәлән, югарыда әйтелгән нигезләрдән шарт фигыле түбәндәгечә була:

| | |
|---|---|
| *килсәм, алдырсам, шауламасам,* | *килсәк, алдырсак, шауламасак,* |
| *килсәң, алдырсаң, шауламасаң* | *килсәгез, алдырмасагыз, шауламасагыз* |
| *килсә, алдырса, шауламаса,* | *килсәләр, алдырмасалар, шауламасалар.* |

Үткән фигыль һәм шарт фигыльләрендә, гомумән безнең телебездә башка сүзләрдә дә, берлек санында уллык нисбәтендә әйтелгән сүзләрнең төрлекләр белән күрсәтелеше юк. Алар шул торышларынча, уллык япсару төре булып хезмәт итәләр. Бу экономиянең боерыкларда «синлек» төрендә булып, ә менә бу соңгы фигыльләрдә «уллык» төрендә булуы – телебездә ул төрләрнең, башкаларына караганда күбрәк йөртелүеннән килә. Чөнки боерык күбрәк тыңлаучыга карап сөйләнә.

Шарт фигыльләренең төрләнешендә башка төрекләрдә аерма юк диярлек. Башкорт телендә *са-сә* төрлекләре *һа-һә* булып, төрекмән телендә *за-зә*[2] булып әйтеләләр. Мәсәлән: *килһә, барһагыз, алдырмаһа, килзә, барза*... кебек. Көньяк төрекләрдә *гыз-гез* урынына *ңыз-ңез*, казахларда *сагыз-сәгез* урынына *саңдар-сәңдәр* килә.

4. **Хәзерге (заман) фигыль.** Хәзерге заман фигыльләре нигез фигыльләрнең азагына үзенә махсус заман һәм хәбәрлек төрлекләре кушылу белән ясала. Беренче рәттә хәзерге заман төрлеге *а-ә, (ый-и)*, икенче рәттә алты төрдә хәбәрлек төрлекләре килә.

Искәрмә. Татар телендә беренче рәт хәзерге заман төрлекләре, нигез фигыльнең, туктар авазларына карап, ике төрдә килә:

1) тартык авазларга беткән нигез фигыльләрдән соң калын сүзләрдә *а*, нечкәләрдә *ә* төрлеге килә (бу урында *у, и* авазлары тартык авазлардан санала. Мәсәлән: *ау – ава, яу – ява, шу (шыв) – шуа, ю (йыв) – юа, ки (кей) – кия, ти (тей) – тия;*

2) сузык *(а, ә, ы-э (е))* авазларга беткән нигез фигыльләрдән соң, аларның сузык авазлары төшеп кала да, аның урынына *ый-и* төрлеге килә.

Башкорт, казах, кыргыз, үзбәк телләрендә бу төр сузык бетешле

[1] Интерденталь (сакау) [з] авазы. – *Ред.*
[2] Интерденталь (сакау) [c] авазы. – *Ред.*

## Төрек телләрендә боерыкларның төрләнеше

*17 таблица*

| сан | затлар | татар | башкорт | казах | кыргыз | төрекмән | анатули (төрек) | үзбәк | уйгур |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| берлек санында | минлек | *ыйм -им* | *аем-әем* | *аен-әен* | *аен-әен* | *аен-әен* | *алым-әлем* | *ай-әй* | *ай-әй* |
| | синлек | – | – | – | – | – | – | *ың-ең (кын-кен)* | – |
| | уллык | *сын-сен* | *һын-һен* | *сын-сен* | *сын-сен* | *çын-çен*[1] | *сын-сен* | *сын-сен* | *сун-сүн, сын-сен* |
| күплек санында | минлек | *ыйк-ик* | *аек-әек* | *аек-әек* | *алык-әлек, лы-ле* | *айлы-әйле* | *алым-әлем, ялым* | *әйлек* | *айлы-әйле* |
| | синлек | *ыгыз-егез, гыз-гез* | *ыгыз-егез, гыз-гез*[2] | *ыңдыр-еңдер (ңдар-ңдәр)* | *гыла-гелә* | *ың-ең (н)* | *ең-еңез* | *еңләр (ңләр)* | *ыңла-еңлә (ңла-ңлә)* |
| | уллык | *сыннар-сеннәр* | *һындар-һендәр* | *сынвар-сендәр* | *сындар-сендәр* | *çынлар-çенләр*[1] | *сынлар-сенләр* | *сенләр* | *сынла-сенлә* |

[1] Интерденталь (сакау) [*ꞓ*] авазы. — *Ред.*
[2] Интерденталь (сакау) [*з*] авазы. — *Ред.*

нигезләрдән соң, азаккы авазларын төшермичә, шул көенчә генә й төрлеге кушу белән ясала. Мәсәлән, *кара–карай, йөре – йөрей, эшлә – эшләй*... кебек[1]. Төрекмән телендә хәзерге заман төрлеге яр-ыя төрендә, госманлы төрекләрендә ыюр төрендә килә, һәм аларда бу төрлек, төп сүзнең гармониясенә иярмичә, һәрвакыт калын әйтелеп йөри: *языяр, гәлыяр-гәлыя, языюр, гәлыюр*... кебек.

**Хәзерге (заман) фигыльләренең хәбәрлек төрлекләре түбәндәгечә:**

| | берлек санында | күплек санында |
|---|---|---|
| минлек | *мын-мен (м)* | *быз-без* |
| синлек | *сын-сең* | *сыз-сез* |
| уллык | – | *лар-ләр* |

*Кил, эшлә, карама* нигезләреннән татар телендә хәзерге фигыльләрнең төрләнеше түбәндәгечә:

| берлек | күплек |
|---|---|
| Киләмен, эшлимен, карамыймын(м), киләсең, эшлисең, карамыйсың, килә, эшли, карамый. | киләбез, эшлибез, карамыйбыз, киләсез, эшлисез, карамыйсыз, киләләр, эшлиләр, карамыйлар. |

Искәрмә. Хәзерге заман фигылендә дә иң күп йөртелгән төр берлек санындагы уллык нисбәтендәге төр булганга, шул төрдә экономия ясалган. Берлек санында минлек нисбәтендә хәбәрлек төрлеге, башка фигыльләрдәге кебек, кыскартылып *м* төрендә дә әйтелә. Мәсәлән, *киләм, эшлим, карыйм, укыйм, карамыйм*... кебек. (Бу вакытта ул боерык фигыле белән бер төрдәрәк булып китә.)

Хәзерге заман фигыльләренең хәбәрлек төрлекләрендә башка төрек телләрендә беркадәр аерымлыклар бар. Боларны чагыштыру өчен 18 таблицаны карарга кирәк.

## Хәл фигыльләр

Хәл фигыльләре безнең телебездә икәү:

1) рәвеш фигыльләре, 2) вакыт фигыльләре.

Алар икәве дә, ялгыз беренче рәттәге заман төрлекләре белән генә төрләнеп, хәбәрлек төрлекләре белән төрләнмиләр.

**Рәвеш фигыльләре.** Рәвеш фигыльләре, үзенә махсус беренче рәт заман төрлекләре кушылып, өч төрдә килә:

---

[1] Татар телендәге бу форма катлаулы процесс үткәргән. *Аша, эшлә, төзе, казы* кебек нигезләрдәге хәзерге заман хикәя фигыле элек татар телендә дә башкорт, казах һәм үзбәк телләрендәге кебек, *й* кушымчасы китерү белән булган. Мәсәлән: *ашай, эшләй, төзей, казый*. Бара торгач, *ашай, эшләй*, сүзләрендәге а, *ә* авазлары *ы, е* авазлары белән чиратлашкан: *ашый, эшлей* формасы туган. Тагын да соңрак чорда инде, ей дифтонгы гадиләшеп, *и* авазы хасил булган: *эшлә – эшләй – эшлей – эшли, төзе – төзей – төзи*. Хәзерге татар телендә *ый* ның да, дифтонглыктан чыгып, гади бер сузыкка – калын *и* гә әверелүе бар. Хәзерге орфографиябездә моның ике хәреф белән – *ы + й* күрсәтелүе генә телебездә калын *и* нең барлыгын танып җиткерүне тоткарлый төшә. – *Ред.*

## Хәзерге заман фигыльләренең төрләнеше

*18 таблица*

| сан | затлар | татар | башкорт | казах | кыргыз | төрекмән | анатули (госманлы) | үзбәк | уйгур |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| берлек | минлек | *амын-әмен ыймын-имен* | амын-әмен аймын-әймен | амын-әмен аймын-әймен | амын-әмен аймын-әймен | ыярын | ыюрым | әмән-әймән | емән (имән) |
| | синлек | *асың-әсең ыйсың-исең* | айһың-әйһең аһың-әһең | асын-әсен айсын-әйсен | асын-әсен айсын-әйсен | ыярҫың[1] | ыюрсын | әйсән-әсән | есән (исән) |
| | уллык | *а-ә-ый-й* | а-ә-ай-әй | ады-әде айды-әйде | ат-әт айт-әйт | ыяр-ыя | ыюр | ады-әде | еду (иду) |
| күплек | минлек | *абыз-әбез ыйбыз-ибез* | абыз-әбез[1] айбыз-әйбез | амыз-әмез аймыз-әймез | амыс-әмес аймыс-әймес | ыярыҫ[1] | ыюрыз | әмез-әймез | емез (имиз) |
| | синлек | *асыз-әсез ыйсыз-исез* | аһыгыз-әһегез айһыгыз-әйһегез[1] | асыңдар-әсеңдәр асыңдар-әсендәр | айсыңар-әсеңәр | ыярҫыңыз[1] | ыюрсыңыз | әсезләр | есенлә (исизләр) |
| | уллык | *алар-әләр ыйлар-иләр* | алар-әләр айзар-әйзәр[1] | алар-әләр айлар-әйләр | айт-әйт | ыярлар-иярләр | ыюрлар ыюрләр | әделәр | еду (иду) |

Искәрмә. Хәбәрлек төрлекләренең күплек санындагы минлекләре борынгы төркиләрдә (урхун, уйгур язуларында) үткән фигыльләрдә дә *дык-дек* төрендә түгел, *дымыз-демез* төрендә булган. Моның калдыгы үзбәкләрдә хәзерге көндә дә халык телендә бар икән.

[1] Башкорт һәм төрекмән телләрендә бу кушымчалардагы [з] һәм [с] авазлары — интерденталь (сакау) авазлар.— *Ред.*

1) Үткән заман рәвеше «барлык» төрендәге нигез фигыльләрнең азагына *ып-еп-п* кисәге кушып, ә «юклык» төрендәге нигез фигыльләрдә хәзерге фигыльләрнең берлек санындагы уллык нисбәтендә әйтелгән *мый-ми* төренең азагына *ча-чә* төрлекләре кушып ясала. Мәсәлән: *алып, килеп, карап, укып, йөреп, алмыйча, белмичә...* кебек (*мыйча-мичә* төбендә *ма+ен + ча, мә + ен + чә* дән кыскарган).

Төрекмән телендә бу рәвеш фигыльләре юклык нигезендә *ман-мән* төрендә килә: *алман (алмыйча), гәлмән (килмичә), укыйман (укымыйча)* кебек.

2) Хәзерге заман рәвешләре «барлык» төрендәге нигездән дә, юклык төрендәге нигездән дә хәзерге заман хәбәр фигыльләренең берлек санындагы уллык нисбәтендә әйтелгән төрләре белән бер төрдә килә: *ала, күрә, укый, карый, йөри, утырыша, йоклый, алмый, күренми, укымый, эшләми...* кебек.

Искәрмә. «Барлык» нигезеннән ясалган хәзерге рәвеш фигыльләрен кабатлап, янәшә ике мәртәбә әйтү белән «дәвамлы рәвешләр» ясала: *килә-килә, эшли-эшли, укый-укый, бара-бара...* кебек. Шулай ук «барлык» нигезеннән үткән рәвеш фигыльләре дә кабатлау төрендә килә ала: *салып-салып җибәрде, йөреп-йөреп эш чыкмагач...* кебек.

**Рәвеш фигыльләрнең ясалышы:**

| | үткән | хәзер | дәвамлы | кабатлау |
|---|---|---|---|---|
| булу нигезеннән: | *алып* | *ала* | *ала-ала* | *алып-алып* |
| булмау нигезеннән: | *алмыйча* | *алмый* | – | – |

Көньяк төрекләрдә үткән рәвешләр *арак-әрәк (ярак-ярәк)* төрендә килә: *аларак (алып), гәләрәк (килеп), улмаярак, гәлмәярәк...* кебек.

**Вакыт фигыльләре.** Вакыт фигыльләре нигез фигыльләрнең азагына үзенә махсус фәкать беренче рәт заман төрлекләре кушылу белән ясала. Вакыт фигыльләре өч вакытны белдерү өчен, өч төрле киләләр:

1) Киләчәк вакыт – нигез фигыльләрнең азагына *ганчы-гәнче, канчы-кәнче* кисәкләре (юклык төрендә *мыйчы-миче, мас-мәс борын, мас-тан-мәстән элек*) кушып әйтелә. Мәсәлән: *алганчы, килгәнче, булганчы, утлар алганчы кайтып җиттек; революция булганчы, безгә көн юк иде; бездән хәбәр алмыйчы, урыныңнан кузгалма...* кебек.

Искәрмә. Шул ук *ганчы-гәнче* төрендә килгән фигыльләрнең беренче иҗегендә көчле басым белән әйтеп, «дәвамлы вакыт фигыле» ясала: *үтергәнче, егылганчы, туйганчы... үтергәнче кыйнады, егылганчы барды, ярылганчы ашады...* (бу соңгыларында беркадәр рәвешлек мәгънәсе дә бар).

2) Эш вакыты – нигез фигыльләрнең азагына *ышлый-ешли, шлый-шли (ышлай-ешләй), ганда-гәндә* төрлекләре кушып әйтелә: *үтешли, барышлый, килешли, укыганда, төшкәндә, сагынганда...* кебек. Эш вакыты фигыльләре булмау төрендәге нигезләрдән килми.

Көньяк төрек телләрендә вакыт фигыльләре беркадәр башкачарак

төрләнә. Мәсәлән: *варанҗа, варанҗая кадар (барганчы), гүрдекҗә, алмадан (алмыйчы), гидәледән бирү (киткәннән бирле), гидәркән (киткәндә)...* кебек.

3) Ү т к ә н в а к ы т – нигез фигыль төрләренең азагына *гач, гәч, кач, кәч (ганнан соң)* төрлекләре кушып әйтелә: *алгач, килгәч, булмагач, киткәч, кайткач...* кебек.

И с к ә р м ә. Вакыт фигыльләренең бу төрлекләре төбендә *ган соң, гәннән соң* дип әйтелгән төрдән кыскартылган булуы мөмкин. Бу төрлек башкорт телендә *гас, гәс...* рәвешендә әйтелә. Көньяк төрек телләрендә бу төр, югарыда күрсәтелгәнчә, һәрвакыт *соң* сүзе кушып кына әйтелә, бездә дә аның шулай әйтелеше бар.

## Исем фигыльләр (яки уртак фигыльләр)

Исем фигыльләр дә, башка фигыльләр шикелле, безнең телебездә өч төрле булалар: 1) ү т к ә н, 2) к и л ә ч ә к, 3) җ а в а п.

Боларның һәрберсе нигез төрендәге фигыльләрнең азагына үзенә махсус беренче рәт заман төрлекләре кушылу белән төрләнәләр. Исем фигыльләр булу төрендәге нигезләрдән дә, булмау төрендәге нигезләрдән дә киләләр.

**1) Үткән (заман) исем фигыльләр.** Үткән заман исем фигыльләр нигез фигыльләрнең азагына беренче рәт *ган-гән, кан-кән* төрлекләре кушып әйтелә: *килгән, булган, кайткан, ниткән, яздырган, эшләнмәгән, ялтыратылган, тазартылмаган, сөйләнгән, җитеңкерәмәгән...* кебек.

Көньяк төрек телләрендә бу төрлек *ан-ән* төрендә әйтелә. Мәсәлән: *гәлән, алан, язан (килгән, алган, язган)...* кебек. Кыргыз телендә «юклык» төре хәзерге хәбәр фигыленең азагына һәрвакыт нечкә әйтелә торган *ләк* төрлеге кушып ясала: *киләләк, булаләк, җөрәләк, бараләк (килмәгән, булмаган, йөрмәгән...)* кебек. Үзбәк, казах, төрекмән телләрендә бу фигыльнең «юклык» төре *юк* сүзен кушып кына әйтелә: *килгән җук, баран җук, гәлән җук* кебек.

**2) Киләчәк (заман) исем фигыльләр.** Киләчәк исем фигыльләр нигез төрләрнең азагына беренче рәт заман төрлекләреннән *ачак-әчәк, ячак-ячәк* кушымчалары кушып ясала. *Киләчәк, булачак, күрешәчәк, язылачак, белмәячәк, алмаячак...* кебек.

Безнең татар телендә киләчәк заман фигыльләрнең юклык нигезеннән алынган төрләре сирәгрәк. Аның урынына күбрәк барлык тöренең азагына *түгел* ярдәмлеге кушып әйтү гадәт булып киткән. *Киләчәк түгел, алачак түгел...* кебек. Бу хәл көньяк төрек телләрендә дә шулай.

**3) Җавап исем фигыльләре.** Җавап исем фигыльләре, яки хәзерге исем фигыльләр, нигез төрләрнең азагына «барлык» нигезләрендә *ыр-ер, ар-әр-р* төрлекләре кушып, «юклык» нигезендә *с* төрлеге кушып ясала: *янар, агар, күрсәтер, утырышыр, үтәр, көтәр, алыр, калыр..., үтмәс, бетмәс, төгәнмәс, алмас, ишетелмәс...* кебек.

Искәрмә 1. *ар-әр* төрлекләре, *ашар, карар, иләр* кебек, *а-ә* авазына беткән нигезләрнең төрләнешенә ияртеп, тартык авазга беткән нигезләрнең кайберәүләрендә генә килә. Мәсәлән: *табар, утәр, эчәр, көләр, язар...* кебек.

Искәрмә 2. Нигез фигыльләрнең «барлык» төреннән *макчы-мәкче* кисәкләре кушып ясалган сүзләрне дә исем фигыльләрнең бер төре итеп алырга мөмкин. Чөнки бу кушымча *мак-мәк* белән *чы-че* дән кушылган булса да, мәгънәсендә беркадәр, фигыльлек бар.

## Исем фигыльләрнең аргы төрләнешләре

Югарыда күрсәтелгән беренче рәт заман төрлекләре белән әйтелгән исем фигыльләрнең шуннан соңгы төрләнешләре безнең телебездә берничә төрле булырга мөмкин:

1) Алар җөмлә эчендә исемнәрдән алда килгәндә, төп һәм ясалма сыйфатлар кебек, һичбер төрлекләр кушылмастан аергыч булып йөри алалар: *килгән кеше, язылган китап, аткан ук, пешмәгән бәрәңге..., киләчәк заман, алачак мал, эшләнәчәк эш, янар тау, кайнар су, күрер күз, утырышыр кеше, утмәс балта, бетмәс хәзинә...* кебек.

Бу яктан исем фигыльләрнең беренче рәттәге заман төрлекләренә фигыль нигезләреннән сыйфат ясаучы кушымчалар дип карарга була.

2) Бу заман төрлекләренең азагына исем ясаучы *лык-лек* кушымчалары ялганып, аларның исемгә әйләнүләре дә мөмкин. Бу вакыт аларның, төп һәм ясалма исемнәр кебек, тагы 2 нче рәт исем ясагычлары белән төрләнүләре дә, *ла-лә* ясагычлары кушылып, яңадан фигыльгә әйләнүләре дә, яки *лы-ле, сыз-сез* ясагычлары кушылып, яңадан кире сыйфатка әйләнүләре дә мөмкин: *эшләгәнлек, ашарлык, киләчәклек, белмәгәнлек, укылмаслык, ялкауланганлык, бетмәслек..., ашарлыкланган, утмәсләнде..., күренерлекле, укытырлыклы, килешмәгәнлекле, күренерлексез, ишетелерлексез...* кебек.

Димәк, бу яктан исем фигыльләргә тамыр яки нигез сыйфат төрләре дип тә карарга була.

3) Заман төрлекләренең азагына турыдан-туры беренче, икенче һәм өченче рәт исем төрлекләре (аерым-аерым яки берничәсе, яки барысы бергә) килеп кушылулары да мөмкин.

Мәсәлән: *килгәннәре, барганнарны, күргәннәрегезне, утмәслегеннән, барачакларыннан, күрергә, белергә, алмаска, басылмаганга...* кебек.

Бу яктан алар бөтенләй нигез исем табигатен алып, исемнәр белән бертөсле йөриләр. (Исем төрлекләре турында алда сөйләнәчәк.)

4) Шулай ук бу исем фигыльләрнең заман төрлекләре артыннан, башка фигыльләр шикелле, өч затка япсарып әйтелгән алты төрле хәбәрлек кушымчалары белән төрләнүләре дә бар. Мәсәлән:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| берлек | минлек | *килгәнмен* | *бармаганмын* | *беләчәкмен* | *түзәрмен* | *булмамын* |
| | синлек | *килгәнсең* | *бармагансың* | *беләчәксең* | *түзәрсең* | *булмассың* |
| | уллык | *килгән* | *бармаган* | *беләчәк* | *түзәр* | *булмас* |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| күплек | минлек<br>синлек<br>уллык | *килгәнбез*<br>*килгәнсез*<br>*килгәннәр* | *бармаганбыз*<br>*бармагансыз*<br>*бармаганнар* | *беләчәкбез*<br>*беләчәксез*<br>*беләчәкләр* | *түзәрбез*<br>*түзәрсез*<br>*түзәрләр* | *булмабыз*<br>*булмассыз*<br>*булмаслар* |

Искәрмә. Хәбәрлек төрлекләре белән төрләнгән башка фигыльләрдәге кебек, исем фигыльләрнең дә берлек санындагы уллык нисбәтендәге төрләре кушымчасыз төрдә күрсәтелә. Җавап фигыльләренең «юклык» төрләрендә беренче рәттәге *с* төрлеге, минлек өчен булган *мын-мен, быз-без* хәбәрлекләре кушылганда, төшеп кала (башка төрләр кебек килгәндә, *булмасмын-булмасбыз* булып әйтелергә кирәк иде).

Хәбәрлек белән төрләнгән исем фигыльләр, хәбәр фигыльләре кебек, җөмләнең хәбәре булалар.

Гомумән, *мын, сың, быз, сыз, лар*... төрендә йөртелгән япсару кушымчалары бездә җөмләнең хәбәре булып килгән бөтен сүзләргә, бөтен төркемнәргә кушыла алалар. Бу кушымчаларны фигыльләргә генә тоташа торган төрлекләр дип карарга ярамый. Алар бөтен сүзләргә уртак кушымчалар. Шуңа күрә мин аларны «уртак хәбәрлек кушымчалары» дип йөртүне мовафыйк күрәм. Сүзләрнең өстәмә кушымчалар белән төрләнешен сөйләгәндә, боларга тагы тукталырбыз әле.

Көньяк төрек телләрендә исем фигыльләрнең төрләнешендә бераз аермалар бар.

Үзбәк һәм госманлы төрек телләрендә үткән һәм киләчәк фигыльләре түбәндәгечә төрләнә:

| госманлы | үзбәк | госманлы | үзбәк |
|---|---|---|---|
| *гәлмешем*<br>*гәлмешсең*<br>*гәлмешдер*<br>*гәлмешез*<br>*гәлмешсеңез*<br>*гәлмешләрдер* | *килепмән*<br>*килепсән*<br>*килепде*<br>*килепмез*<br>*килепсезләр*<br>*килепделәр* | *гәләҗәгем*<br>*гәләҗәксең*<br>*гәләҗәкдер*<br>*гәләҗәгез*<br>*гәләҗәксеңез*<br>*гәләҗәкләрдер* | *килгусемән*<br>*килгусесән*<br>*килгуседер*<br>*килгусемез*<br>*килгусесез*<br>*килгуселәрдер* |

Госманлы һәм төрекмән телләрендә киләчәк булмау төре *дәгел-дәл* ярдәмлеге кушылып әйтелә.

Хәзерге заман (җавап) исем фигыле түбәндәгечә төрләнә:

| госманлы | | төрекмән | | үзбәк |
|---|---|---|---|---|
| барлык | юклык | барлык | юклык | юклык |
| *гидәрем*<br>*гидәрсең*<br>*гидәр* | *булмам*<br>*булмазсың*<br>*булмаз* | *гедәрен*<br>*гедәрҫең*<br>*гедәр* | *булмарын*<br>*булмарҫың*[1]<br>*булмаҫ* | *булмасмән*<br>*булмассән*<br>*булмайде* |
| *гидәрез*<br>*гидәрсеңез*<br>*гидәрләр* | *булмаез*<br>*булмазсыңыз*<br>*булмазлар* | *гедәреҫ*<br>*гедәрҫеңез*<br>*гедәрләр* | *булмарыҫ*<br>*булмарҫыңыз*<br>*булмарлар* | *булмаймез*<br>*булмассез*<br>*булмайде* |

Югарыда күрсәтелгәнчә, исем фигыльләрнең нинди кушымчалар белән

[1] Төрекмән теле кушымчаларындагы [*ҫ*] һәм [*з*] — интерденталь (сакау) авазлар.— *Ред.*

төрләнешләрен аңлаганнан соң: «*бу ган-гән, кан-кән, чак-чәк, ыр-ер, ар-әр-р, мас-мәс* кушымчалары белән төрләнгән фигыльләрне бөтенләй фигыльләр арасыннан алып, ясалма сыйфатлар арасына кертеп йөрткәндә ничек булыр иде икән?» дигән бер уй башка килә.

Чынлап та, бу исем фигыльләр үзләренең бөтен төрләнешләрендә, һичбер аермасыз, ясалма сыйфатларга охшыйлар ич: сыйфатлар да, шулай ук кушымчасыз көенчә, җөмләдә исемнәрдән алда килгәндә, аергыч булалар; төрле ясагычлар кушылу белән, исем яки фигыль булып, кабат-кабат ясала алалар; шулай ук бөтен исем төрлекләре белән дә төрләнә алалар һәм, җөмләнең хәбәре булган чакта, шул ук хәбәрлек төрлекләре белән төрләнәләр.

Тышкы якны үзенә нигез иткән грамматика өчен, бу исем фигыльләрне бөтенләй фигыльләр арасыннан чыгарып, ясалма сыйфатлардан санап йөртүгә шушы фактлар җитсә кирәк.

Мин аларны, башка фигыльләр кебек, нигез төрләрдән соң заман төрлекләре белән төрләнүләренә карап кына, фигыльләр арасында күрсәтергә мәҗбүр булдым.

## Ким фигыльләр

Элгәреге сарыф китапларында «ярдәм фигыльләре» дип йөртелгән *иде, идем, икән...* кебек фигыльләрне шәкли грамматикада «ким фигыльләр» дип йөртү дөресрәк булачак. Ярдәм фигыле дигән исем мәгънә ягына каратып әйтелгән. Тышкы яктан боларда бер аерымлык барлыгын ул күрсәтә алмый. «Ким фигыльләр» дигән атама исә, аларның нәхви төрләнешләре тулы түгеллеген күрсәтеп торачак.

*Ким* фигыльләрнең иң мәшһүре *и* тамырыннан чыккан фигыльләр булып, хәзерге көндә аның шул тамырдан бары үткән заман фигыленең барлык төрләре генә телебездә йөри: *идем, идең, иде, идек, идегез, иделәр...* кебек. Болар җанлы телдә, *д* авазы *й* гә үзгәреп, *ием, иең, ие, иек...* рәвешендә дә сөйләнә. Борынрак и тамырыннан, ирер, ирермен, ирерсең, ирерләр кебек, хәзерге заман фигыльләре дә йөргән; *тор-дор* тамырыннан торыр, торырмын кебек ким фигыльләр булган. Башкалары бөтенләй йөрми диярлек. (Төрле дәрәҗә ясагычлары белән ясалган нигездән нәхви төрләре тулы йөри: *ит, итен, иттер, итеш...* кебек.)

*Иде* фигыле җәнүп төрекләрендә, *де* гә әйләнеп, аерым «хикәя фигыльләре» тезмәсен хасил итә. Мәсәлән: *гәлмешдем, курсәйде...* кебек. Казах телендә *торган* сүзеннән кыскарган *тын* да бер кушымча булып киткән. Мәсәлән: *алатын, киләтен* (ала торган, килә торган). *Исә, икән, имеш...* дигән берничә төре хәзерге көндә фигыль түгел, бәлки бер ярдәмлек булып кына саналырга мөмкин. Алар – берәр сүз генә. Бер тарыдан, әлбәттә, бутка булмый. Аларның хәбәрлек бетемнәре белән

төрләнүләренә карап кына, фигыль дип уйларга тагын юл юк. Чөнки кайбер ярдәмлекләр уртак хәбәрлек бетемнәре белән төрләнәләр.

*Кирәк* сүзе дә кайбер фигыль төрлекләре белән төрләнә. Мәсәлән: *кирәкми, кирәгер, кирәксә, кирәкмәсә, кирәкмәс.* Башка төрләре килми. *Чү, чүегез, мә, мәгез, әйдә, әйдәгез* сүзләре дә шулай ук. Шуңа күрә бу сүзләрне дә ким фигыльләр төрендә санарга мөмкин.

### Кушма фигыльләр бармы?

*Килә тор, үлә яздым, бара төш, сала бир, сугып ал, бара алмады, шәп итте, бара иде, ала торган...* кебек һәрвакыт алдан телебездә төрләнми торган бер рәвеш фигыле, ярдәмлек, ымлык яки чит бер сүз кушып әйтелгән фигыльләрне сарыф китапларында «кушма фигыльләр» дип йөртәдер идек. Болар бары да мәгънә ягына карап йөртелгән нәрсәләр. Шәкли грамматикада аларны без тулы, ялгыз фигыльләр дип кенә йөртәбез. Аларның гади фигыльләрдән бер дә аермалары юк. Янәшә алдан әйтелгән сүзләрне без рәвеш фигыльләре, рәвеш тәмамлыклары дип карарга гына тиеш булабыз (19 табл.).

## Исемнәрнең төрләнеше

Тамыр хәлендә яки 1 нче һәм 2 нче рәт исем ясагычларының берәрсе яки боларның барсы бергә кушылып ясалган исемнәр, төрлекләр кушылмастан элгәреге торышларынча, исемнәрнең «нигез төре» булалар. Төрләнеш шушы нигез төрнең азагына махсус төрлекләр кушылу белән төзелә. Нигез исемнәр, фигыльләр кебек, аерым төркемнәргә бүленмичә, барсы бертөсле түбәндәге 3 рәт исем төрлекләре белән төрләнәләр: 1 нче рәттә сан, 2 нче рәттә япсарулар (нисбәтләр)[1], 3 нче рәттә килешләр.

### Исем төрлекләренең җәдвәле

*20 таблица*

<table>
<tr><td colspan="2">Беренче рәт</td><td colspan="2">Икенче рәт</td><td>Өченче рәт</td></tr>
<tr><td colspan="2">зат саннары</td><td colspan="2">япсарулар</td><td>килешләр</td></tr>
<tr><td>берлек</td><td>күплек</td><td>бер затка</td><td>күп затка</td><td rowspan="5">баш килеш (кушымчасы)<br>иялек – ның-нең<br>чыгыш – дан-дән, тан-тән, нан-нән<br>юнәлеш – га-гә, ка-кә, на-нә, а-ә<br>төшем – ны-не, ын-ен,<br>вакыт-урын – да-дә, та-тә,<br>рәвеш – ча-чә, ынча-енчә,<br>охшату – дай-дәй (дый-ди)</td></tr>
<tr><td rowspan="2">нигез төрләнә</td><td rowspan="2">лар-ләр<br>нар-нәр</td><td>ым-ем-м<br>ың-ең-ң</td><td>быз-без<br>гыз-гез</td></tr>
<tr><td colspan="2">ы-е<br>сы-се</td></tr>
<tr><td>мин<br>син<br>ул</td><td>без<br>сез<br>алар</td><td>–</td><td>–<br>–<br>–</td></tr>
</table>

[1] Япсарулар (нисбәтләр) – тартым кушымчалары.

## Татар телендә фигыльләрнең заман һәм хәбәрлек төрлекләре белән төрләнеш җәдвәле

*19 таблица*

<table>
<tr><td colspan="3">Фигыль төрләре</td><td colspan="4">Хәбәр фигыльләр</td><td colspan="3">Исем фигыльләр</td><td colspan="2">Хәл фигыльләр</td></tr>
<tr><td colspan="3" rowspan="2">Беренче рәт заман төрлекләре</td><td>боерык фигыль</td><td>үткән заман</td><td>шарт фигыль</td><td>хәзерге</td><td>үткән</td><td>киләчәк</td><td>җавап</td><td>рәвеш фигыле</td><td>вакыт фигыле</td></tr>
<tr><td>ый-и (ай-әй)</td><td>ды-де, ты-те</td><td>са-сә</td><td>а-ә, ый-и (ай-әй)</td><td>ган-гән, кан-кән</td><td>ачак-әчәк, (ячак-ячәк)</td><td>ар-әр, ыр-ер, р, с</td><td>а-ә, ый-и, ып-еп, ча-чә</td><td>гач-гәч, кач-кәч; ышлый-ешли, ганчы-гәнче, канчы-кәнче</td></tr>
<tr><td rowspan="6">Икенче рәттәге хәбәрлек төрлекләре</td><td rowspan="2">уллык</td><td>күплек</td><td colspan="4">сыннар-сеннәр</td><td colspan="3">лар-ләр (нар-нәр)</td><td colspan="2" rowspan="6">Хәбәрлек төрлекләре белән төрләнмиләр</td></tr>
<tr><td>берлек</td><td colspan="4">сын-сен</td><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td rowspan="2">синлек</td><td>күплек</td><td colspan="4">ыгыз-егез, гыз-гез</td><td colspan="3">сыз-сез</td></tr>
<tr><td>берлек</td><td colspan="4">ң</td><td colspan="3">сың-сең</td></tr>
<tr><td rowspan="2">минлек</td><td>күплек</td><td colspan="4">к</td><td colspan="3">быз-без</td></tr>
<tr><td>берлек</td><td colspan="4">м</td><td colspan="3">мын-мен</td></tr>
</table>

## Сан белән төрләнеш

Исемнәрнең сан төрләре бөтен төрек телләрендә икәү:

1) берлек саны, 2) күплек саны.

Исемнәрнең берлек санындагы төре, һичбер төрлек кушылмыйча, нигез хәлендә әйтелү белән табыла. Күплек санында исә, беренче рәт исем төрлекләре *лар-ләр* кушып төрләнә. Бу төрлек татар телендә, нигез исемнәрнең нинди авазга туктавына карап, ике төрле була:

1) борын авазларына беткән исемнәрдә *нар-нәр* төрендә; *таңнар, көннәр, урамнар, бәйрәмнәр, килгәннәр...* кебек;

2) башка авазларга беткән исемнәргә кушылганда, *лар-ләр* төрендә килә: *кешеләр, тимерләр, кошлар, юллар, алмалар, күмәчләр, балалар...* кебек.

Кыргыз, казах телләрендә 3 төрдә әйтелә:

1) сузык авазларга һәм *р* авазына бетешле исемнәрдә *лар-ләр*;

2) яңгыравыксыз бетешле исемнәрдә *тар-тәр*;

3) «каты» бетешле исемнәрдә *дар-дәр* төрендә килә.

Башкорт телендә исә дүрт төрдә әйтелә:

1–2) сузык һәм яңгыравыксыз бетешле исемнәрдә, казах һәм кыргыз телләрендәге кебек *лар-ләр, тар-тәр* төрендә;

3) *л, м, н, ң* авазларына беткән исемнәрдә *дар-дәр*;

4) *р, в (у-ү), й, з* авазларына беткән исемнәрдә *зар-зәр* төрендә килә[1].

Көньяк төрекләрендә күплек саны һәрвакыт *лар-ләр* төрендә генә килә.

Башка сүз төркемнәреннән ясалган ясалма исемнәрнең беренче рәт сан төрлекләре белән төрләнешләрендә шушы күрсәтелгәннәрдән һичбер аерма юк. Мәсәлән: *килешүләр, укулар, язулар, сугышлар, ачкычлар, бүлмәләр, каптырмалар.*

## Япсару белән төрләнеш

Исемнәрнең 2 нче рәт япсару төрлекләре белән төрләнешләре, фигыльләрдәге кебек, өч затка каратып, алты төрдә була. Исемнәрнең япсару төрлекләре дә фигыльләрнекенә бик охшый. Болар беренче рәт исем төрлекләре *лар-ләр* белән бергә дә, аерым үзләре генә дә килергә мөмкин.

Мәсәлән, күз, бала сүзләренең төрләнеше түбәндәгечә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Беренче рәт сан төрлеге белән бергә | *миңлек:* | *күзләрем,* | *балаларым* | *күзләребез* | *балаларыбыз,* |
| | *синлек:* | *күзләрең* | *балаларың* | *күзләрегез* | *балаларыгыз,* |
| | *уллык:* | *күзләре* | *балалары* | *күзләре* | *балалары* |

[1] Башкорт телендә [з] авазы – интердентальдь (сакау) аваз. – *Ред.*

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| сан төрлеле-геннән башка гына | *миңлек:* | *күзем,* | *балам,* | *күзебез,* | *балабыз,* |
| | *синлек:* | *күзең,* | *балаң,* | *күзегез,* | *балагыз,* |
| | *уллык:* | *күзе* | *баласы* | *күзе* | *баласы* |

Бу мисаллардан күренгәнчә, сузык *а-ә, ы-е* авазларына беткән исемнәрнең уллык япсару төрлекләре *сы-се* төрендә, башка авазларга беткән исемнәрдә *ы-е* төрендә килә.

Аннары, уллык япсарулар, берлек һәм күплек төрләренә аерылмыйча, икәве дә бер санда гына әйтеләләр.

Башка сүз төркемнәреннән ясалган исемнәрнең 2 нче рәт япсару төрлекләре белән төрләнешләрендә дә болардан аерымлык юк. Алар да чын исемнәр кебек төрләнәләр. Сыйфатлар, шулай ук исем фигыльләр дә, төп исем урынына йөргәндә, шул ук япсарулар белән төрләнәләр.

Башка төрек телләрендә дә исемнәрнең япсару төрлекләре бертөсле диярлек. Тик татар, башкорт телләреннән башкаларда *быз-без, гыз-гез* төрлекләре *мыз-мез, ңыз-ңез* төрендә әйтелә.

Кыргыз телендә *ларыгыз-ләрегез* урынына *ыңар-еңәр* килә: *балаңар, атыңар, күзеңәр...* кебек; *быз-без, гыз-гез* урынына *быс-бес, ңыс-ңес* килә: *балабыс, атыңыс...* кебек. Госманлы төрек телендә *суы* урынына *суйи (суе)* әйтелә. Исем фигыльләрнең төрләнешендә *гәнем, гәнең, гәне, гәнебез...* урынына *дегем, деген, деге, дегемез, декләре...* төрләре кулланыла.

## Килеш белән төрләнеш

Исемнәрнең саф үзләренә махсус 3 нче рәттәге килеш төрлекләре белән төрләнешләре бар. Бу килеш төрлекләренең 3 нче рәттән саналулары (гомумән бөтен кушымчаларның рәтләре) – аларның югарыда әйтелгән сан һәм япсару төрлекләре белән бергә килгән чагында токкан урыннарына карап бирелә. Саннар, япсару төрлекләренең берсе дә булмаганда, нигез исемнәргә турыдан-туры килеп кушылалар.

Бездә исемнәрнең 3 нче рәт килеш төрлекләре сигез. Шуңа карап, исемнәр 8 төрле килештә булалар:

1) баш килеш, 2) иялек килеш, 3) чыгыш килеше, 4) юнәлеш килеше, 5) төшем килеше, 6) вакыт-урын килеше, 7) рәвеш килеше, 8) ошату килеше.

1) **Баш килеш.** Тамыр яки нигез хәлендә, яки 1 нче, 2 нче рәт исем төрлекләре белән төрләнеп тә азагына 3 нче рәт исем төрлекләренең берсе дә кушылмаган исемнәр баш килештә саналалар. Мәсәлән:

*күз, күзләр, күзе, күзләре, күзегез, күзләребез...* кебек. Баш килештә әйтелгән исемнәр җөмләнең иясе булалар.

2) **Иялек килеш.** Баш килеш төрендәге исемнәрнең азагына 3 нче рәттәге *ның-нең* төрлеге кушып әйтелгән исемнәр шул килештә санала:

*авылның, авылларның, авылларыгызның, авылларыбызның, шәһәрнең, шәһәренең, шәһәрләребезнең*... кебек.

3) **Чыгыш килеше** баш килеш төрендәге исемнәрнең азагына 3 нче рәт *дан-дән, тан-тән, нан-нән, ннан-ннән* төрлекләре кушып әйтү белән була.

Татар телендә яңгыравыклы авазларга беткән исемнәрнең азагында бу төрлекләрнең *дан-дән* төре, яңгыравыксыз бетешле исемнәрдә *тан-тән* төре, борын авазларына бетешле исемнәрдә *нан-нән* төре килә.

Бу төрлек 2 нче рәт япсару төрлекләреннән булган *ы-е, сы-се* кушымчаларыннан соң килгәндә, ике уртага артык бер *н* авазы кушып, *ннан-ннән* төрендә әйтелә: *авылдан, авыллардан, авылларыннан, авылларыгыздан, авылларымнан, баласыннан, авылдашыннан, авылдашларыгыздан*... кебек.

4) **Юнәлеш килеше** баш килештә саналган исемнәрнең азагына татар телендә *га-гә, ка-кә, на-нә, а-ә* төрлекләрен кушып әйтү белән төзелә. Боларның аермалары исемнең бетешләренә карап була: 1) яңгыравык бетешле нигез исемнәрнең азагына – *га-гә* төре, 2) яңгыравыксыз бетешле исемнәрнең азагында – *ка-кә* төре, 3) икенче рәт *ы-е, сы-се* япсару төрлекләреннән соң *на-нә* төре, 4) икенче рәт *м, н* япсару төрлекләреннән соң *а-ә* төре килә. Мәсәлән: *балага, атка, кешеләргә, кешеләрегезгә, баласына, атыма, кешеләренә, кешесенә*... кебек.

Искәрмә. Юнәлеш килешендә булган сүзләрнең *чаклы, чикле* сүзләреннән кыскартылган *ча-чә* кисәге белән кушылып әйтелгән төре дә бар: *шәһәргәчә, күргәнгәчә, авылгача, түбәнгәчә*, кебек. (Бу *ча-чә* юнәлеш килешләреннән соң гына кушылганлыктан, уртак өстәмә кушымчалар арасында күрсәтелмәде.)

5) **Төшем килеше** баш килештәге исемнәрнең азагына 3 нче рәттәге *ны-не, ын-ен* төрлекләре кушып әйтелә. 2 нче рәт *н-е, сы-се* япсару төрлекләреннән соң *н* төре, башка төрле бетешләрдән соң гомумән *ны-не* төре килә: *баланы, атны, кешеләрне, балаларыгызны, баласын, кешеләрен*... кебек.

6) **Вакыт-урын килеше** 3 нче рәттәге *да-дә, та-тә, нда-ндә* төрлекләрен кушып әйтү белән төзелә. Яңгыравык бетешле исемнәрнең азагында боларның *да-дә* төре, яңгыравыксыз бетешле исемнәрнең азагында *та-тә* төре, 2 нче рәт *ы-е, сы-се* япсаруларыннан соң ике уртага бер *н* кушылып, *нда-ндә* төре килә. Мәсәлән: *юлда, кешедә, авылдашта, мәктәптә, юлларында, кешесендә, килгәндә*... кебек.

7) **Рәвеш килеше** баш килештәге исемнәрнең азагына 3 нче рәттәге *ча-чә, нча-нчә* төрлекләре кушып әйтелә. 2 нче рәттәге *ы-е, сы-се* япсару төрлекләреннән соң килгәндә, бер артык *н* белән *нча-нчә* төрендә, башкача булганда, *ча-чә* төрендә генә була. Мәсәлән: *татарча, русча, шәһәрчә, авылча, юлынча, көенчә, әйтүенчә* кебек.

8) **Ошату килеше** баш килештәге исемнәрнең азагына *тай-тәй, дай-дәй (дый-ди)* төрлекләре кушылу белән була: *ы-е, сы-се* япсаруларыннан

соң *ндай-ндәй (ндый-нди)* төрендә әйтелә: *андый, бүредәй, эттәй, аттай, баласыдай (баласындай...)* кебек.

Искәрмә. Килеш төрлекләреннән *ча-чә, дай-дәй, тай-тәй* кушымчаларының башка иптәшләреннән бераз гына аерымлыклары бар: беренче – болар басымны үзләренә үткәрмиләр. Бу яктан алар уртак кушымчаларга охшыйлар. Икенче – кайвакыт үзләреннән соң башка килеш төрлекләрен кабул итә алалар. Бу яктан алар сыйфат һәм рәвеш ясаучы кушымчаларга охшый төшәләр.

Ләкин тәртипләре ягына һәм хезмәтләренә караганда, алар башка килеш төрлекләре кебек, исемнәргә 2 нче рәттәге япсару төрлекләреннән соң килеш кушылганлыктан һәм исемнәрнең фигыльгә бәйләнешләрен билгеләүгә хезмәт иткәнлектән, аларга килеш төрлекләре арасыннан урын бирергә туры килде.

Бер рәттәге кушымчаларның үзара алмашып килүләре, басымны үткәрү-үткәрмәүләре, ясаучы кушымчаларда да, өстәмә кушымчаларда да бар. Шулай булгач, бу күренеш сүз төрләндерүче кушымчаларда да булырга мөмкин[1].

Килеш төрлекләре арасында *белән* ярдәмлеген дә күрсәтү бездә рус сарыфларына иярүдән килеп кергән булса кирәк. Безнең телебездә бу белән – гармониядә һәм басымда тамыр яки нигез сүзнең әйтелешенә иярми торган фонетик мөстәкыйль сүзләрдән. Шуңа күрә ул кушымча була алмый, аны үзенең иптәшләре булган өчен, саен, кебек, сымак... ярдәмлекләре арасында йөртергә тиеш.

Исемнәрнең төрләнешләре, төрлекләре шушы өч рәт белән бетә. Һәрбер төрләнүче исемдә аларның өчесе дә бергә килүләре лазим түгел[2]. Аларның кайбер рәттәгеләре әйтелми калырга да мөмкин. Ләкин ул вакыт, хисаптагы саннар – цифрлар шикелле, әйтелмәгән төрлекләрнең дә буш калган урыннары бар дип саналырга тиеш була. Алар кирәк булган чагында үзләренең рәтенә генә килеп тезеләләр.

Мәсәлән:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| *Кеше* | + – | + – | + *дән* | = *x* | + 003 |
| *Кеше* | + *ләр* | + – | + *дән* | = *x* | + 301 |
| *Кеше* | + *ләр* | + *егез* | + *не* | = *x* | + 521 |
| *Кеше* | + *ләр* | + *е* | + – | = *x* | + 310 |

Исемнәрнең килеш төрлекләре белән төрләнешләренә үрнәкләр

[1] *Русча, татарча, шәһәрчә, аттай, аюдай* кебек сүзләр хәзерге грамматикаларда исем төркеме итеп түгел, бәлки рәвеш төркеме итеп өйрәнелә. Бу сүзләрдәге шикелле басымны да үзләренә күчермәгән *ча-чә, дай-дәй..* формаларын килеш формасы дип тану ялгыш. Бу кушымчалар бер сүздән икенче төрле сүз ясауга хезмәт итәләр. Килешләр – синтаксик категория. Килеш кушымчалары сүзнең мәгънәсен үзгәртмиләр, алар сөйләмдә сүзләрне үзара бәйләүгә генә хезмәт итәләр. *Авылча, шәһәрчә, аюдай..* кебек сүзләрне «килеш» формасы дип тану морфологик категорияләрне синтаксик категорияләр белән саташтырудан килеп чыккан.– *Ред.*

| Баш к. | күз | ат | имән | сүзе | баласы | күзем | күзебез | балаларыгыз |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Иялек к. | күзнең | *-ның* | *-нең* | *-нең* | *-ның* | *-нең* | *-нең* | *-ның* |
| Чыгыш к. | күздән | *-тан* | *-нән* | *-ннән* | *-ннан* | *-нән* | *-дән* | *-дан* |
| Юнәлеш к. | күзгә | *-ка* | *-гә* | *-нә* | *-на* | *-ә* | *-гә* | *-га* |
| Төшем к. | күзне | *-ны* | *-не* | *-н* | *-н* | *-не* | *-не* | *-ны* |
| В.-урын к. | күздә | *-та* | *-дә* | *-ндә* | *-нда* | *-дә* | *-дә* | *-да* |
| Рәвеш к. | күзчә | *-ча* | *-чә* | *-нчә* | *-нча* | *-чә* | *-чә* | *-ча* |
| Ошату к. | күздәй | *-тай* | *-дәй* | *-ндәй* | *-ндай* | *-дәй* | *-дәй* | *-дай* |

*Язу, бирәү, сугыш, ачкыч, йөзлек, яшьлек, ашарлык, күренмәгәнлек, бетмәслек, тимерлек, энекәй, коточкыч, матуркай* кебек ясалма исемнәр дә 1, 2, 3 нче рәт төрлекләр белән югарыдагы кебек төрләнеп йөриләр. Кушма исемнәр, тагылмалы сүзләр, бер ялгыз сүз кебек азаккылары белән төрләнә.

Башка төрек телләрендә бу килеш төрлекләрендә дә азмы-күпме аерымлыклар бар. Үзбәк теленда, мәсәлән, килеш төрлекләре нинди авазлар артыннан килсәләр дә, күп үзгәртелмичә, асыл төрдә киләләр. Мәсәлән: *сүзедән, сүзегә, сүзене, сүзедә, сүзечә, күземгә, баласыдан, баласыга, баласыны, баласыда...* кебек.

Башкорт телендә *ы-е, сы-се* япсаруларыннан соң чыгыш төрлекләре артык *н* кушылмыйча *нан-нән* төрендә генә әйтелә: *биленән, балаһынан...* кебек. Сузык авазлардан соң чыгыш төрлекләре *нан-нән* төрендә, вакыт-урын төрлекләре *ла-лә* төрендә килә; *в (у-ү), й, р, з* авазларыннан соң иялек, чыгыш, төшем, вакыт-урын, охшату төрлекләре, *з* авазы белән башланып, *зың-зең, заң-зәң, зы-зе*[1]... төрендә киләләр. Яңгыравыксыз авазларга беткән исемнәрдән соң бөтен килешләрдә дә *т* авазы белән башланган төрлекләр килә.

Көньяк төрек телләрендә тартык авазлардан соң гомумән иялек килеше *ың-ең* төрендә, чыгыш килеше *дан-дән* төрендә, юнәлеш килеше *а-ә*, сузыклардан соң *я (йа)* төрендә, төшем килеше *ы-е* төрендә генә, сузыклардан соң *е (йэ)* төрендә килә. Охшату килеше аларда юк, башка урыннарда татар телендәге кебек (150 нче биттәге таблицаны кара).

## Алмашларның төрләнеше

Безнең телебездә алмашларның гомумән үзләренә аерым төрлекләре юк. Исем алмашлары шул ук исем төрлекләре белән төрләнәләр, ләкин аларның төрләнешләрендә фонетика ягыннан, башка исемнәргә караганда, байтак аерымлыклар бар. Бу аерымлык, бер яктан, төрлекләрнең үзгәреп әйтелүендә булса, икенче яктан, алмашларның үзләре үзгәреп йөрүендә күренә.

Мәсәлән: *мин, син, ул, шул, бу* алмашлары күплек санында *без, сез,*

[1] Интердентальь (сакау) [з] авазы. – *Ред.*

*алар, шулар, болар* төрендә килә. (Казах, кыргыз телләрендә *сез* урынына *синдәр, сездәр* төре әйтелә. Госманлы төрек телендә *о (ул)–онлар (алар), шу (шул) – шунлар* килә.) (22 табл.)

*Мин, син, ул* алмашлары икенче рәттәге япсару төрлекләре белән бөтенләй төрләнмиләр. Чөнки алар үзләре япсару өчен йөргән сүзләр. *Бу, ни, ул, теге, кай* алмашларының япсару формалары *ансы, бусы, ние–нисе, нием, тегесе, кайсысы, алары, болары, ниләре, кайсылары* төрләре генә телебездә йөри.

Алмашларның 3 нче рәт килеш төрлекләре белән төрләнешләре түбәндәгечә була:

| Баш к. | *мин* | *син* | *ул* | *шул* | *бу* | *ни* | *теге* |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Иялек к. | *минем* | *синең* | *аның* | *шуның* | *моның* | *нинең* | *тегенең* |
| Чыгыш к. | *миннән* | *синнән* | *аннан* | *шуннан* | *моннан* | *нидән* | *теген-нән* |
| Юнәлеш к. | *миңа* | *сиңа* | *аңа* | *шуңа* | *моңа* | *нигә* | *тегеңә* |
| Төшем к. | *мине* | *сине* | *аны* | *шуны* | *моны* | *нине* | *тегене* |
| Вакыт-урын к. | *миндә* | *синдә* | *анда* | *шунда* | *монда* | *нидә* | *тегендә* |
| Рәвеш к. | *минем-чә* | *синең-чә* | *аның-ча* | *шун-ынча* | *мо-нынча* | *ничек (ничә)* | *теге-нençә* |
| Ошату к. | *миндәй (минди)* | *синдәй (синди)* | *андый* | *шун-дый* | *мон-дый* | *нинди* | *теген-ди* |

Алмашларда рәвеш төрлеге һәм иялек төрлеге *ның-нең* белән бергә әйтелеп, *минемчә, синеңчә, анынча, безнеңчә, шунынча, монынча...* төрендә килә.

*Минем* төре безнең әдәби телебездә йөри. Халык телендә бу төр күбрәк, *синең* белән бертөсле, *минең* булып әйтелә.

*Миңа, сиңа* дигән төр Казан шивәсеннән әдәби телгә кергән, югыйсә ул башка татарларда, гармонияне үзгәртмичә, *миңә, сиңә* төрендә килә. *Аңа, шуңа, тегеңә* дигән төрләр халык телендә *анарга, шунарга, тегенәргә* дип йөртелә.

*Бу* алмашы халык телендә *моның, моннан, монарга, монда, монынча, мондый* булып төрләнә. Башка төрек телләрендә алмашларның төрләнешендә булган аерымлыклар 22 таблицада күрсәтелә.

## Сыйфат һәм саннарның төрләнеше

Тамыр яки ясалма сыйфатлар һәм саннарның үзләренә махсус төрлекләр белән төрләнешләре юк. Алар җөмлә эчендә исемнәрдән алда килгәндә, шул торышларынча, тамыр яки нигез хәлендә генә калып, исемнәргә сыйфат (аергыч) булып йөриләр.

**Төрек телләрендә исемнәрнең килеш төрлекләре белән төрләнешен күрсәткән кыскача җәдвәл**

*21 таблица*

| Килешләр | татар | башкорт | казах | кыргыз | төрекмән | анатули (госманлы) | үзбәк | уйгур |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Баш | – | – | – | – | – | – | – | – |
| Иялек | *ның-нең* | *ның-нең, тың-тең, дың-дең, зың-зең*[1] | *ның-нең тың-тең, дың-дең,* | *нын-нен тын-тен дын-ден* | *ың-ең ның-нең* | *ың-ең ның-нең-ең* | *ның-нең* | *ның-нең* |
| Чыгыш | *дан-дән тан-тән нан-нән* | *нан, тан, дан, зан, нән, тән, тән, зән* | *дан, тан дән, тән* | *дан, тан, ан, дән, тән,* | *дан, дән* | *дан-дән* | *дән* | *дән* |
| Юнәлеш | *ка-кә, га-гә* | *ка-кә, га-гә* | *ка-кә, га-гә* | *ка-кә, га-гә* | *а-ә, я* | *а-ә, я* | *гә* | *гә, га* |
| Төшем | *ны-не* | *ны-не, ты-те ды-де, зы-зе* | *ны-не, ты-те, ды-де* | *ны-не, ты-те, ды-де* | *ный-ни, ый-и* | *и. е (эй)* | *не* | *не* |
| Вакыт-урын | *да-дә, та-тә* | *ла, та, да, за лә, тә, дә, зә* | *да, та дә, тә* | *да, та дә, тә* | *да, дә* | *да, дә* | *дә* | *да, дә* |
| Рәвеш | *ча-чә* | *са-сә* | *ша-шә* | *ча-чә* | *ча-чә* | *җа-җә* | *чә* | *чә, ча* |
| Ошату | *дай-дәй, тай-тәй* | *лай, тай, дай, зай ләй, тәй, дәй, зәй* | *тай, дай* | *тай, дай* | – | – | *дәк* | *дак-дәк* |

[1] Башкорт телендә кушымчалардагы [з] авазы интердентал (сакау). — *Ред.*

Югарыда күрсәтелгән өч рәт исем төрлекләре белән төрләнеш – асылда исемнәрнең үзләренә генә хас булган бер нәрсә. Ләкин җөмлә эчендә, исемнәр үзләре әйтелми калган чагында, бу сыйфат, сан һәм аларның алмашлары ул исемнәрнең урынына килеп, исем төрлекләре белән төрләнәләр. (Гомумән телебездәге теләсә нинди сүзләр, хәтта сүз кисәкләре дә, үзенең туры мәгънәсендә кулланылмыйча, исем итеп, хикәя итеп сөйләгәндә, барлык исем төрлекләре белән төрләнергә мөмкин *килдемеңне күп ишеттем инде: дырны чәчкәннәр дә уңмаган, ди...* кебекләр.)

Мәсәлән: *кызыл кешеләрдән – кызыллардан, кызылдан,*
*биш кешегезгә – бишегезгә, бишкә,*
*иртәнге ашауга – иртәнгегә, иртәнгебезгә,*
*икенче кешеләрнең – икенчеләрнең, икенченең,*
*сугышчы батырлардай – сугышчылардай,*
*теге кешеләрегездә – тегеләрегездә, тегеләрдә.*

Кушма саннар бер бөтен сүз кебек, исемнәр урынын тотканда, кушымчалар белән иң ахыргысы гына төрләнә: *биш йөз утыз алтынчы, унсигезгә, егерме биштән...* кебек.

**Төрек телләрендә алмашларның килеш төрлекләре белән төрләнешен күрсәткән чагыштырмалы җәдвәл**

*22 таблица*

| Килешләр | татар | башкорт | казах | кыргыз | төрекмән | анатули (госманлы) | үзбәк | уйгур |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Баш килеш | *мин бу* | *мин был* | *мән бол* | *мән бул* | *мән бо* | *бән бо* | *мән бо* | *мән бо* |
| Иялек к. | *минем моның* | *минең мының* | *мәнең моның* | *мәнен моның* | *мәнең моның* | *бәнем боның* | *мәнең моның* | *минең бөнең* |
| Чыгыш к. | *миннән моннан* | *минән мынан* | *мынән бодан* | *мәнән бодан* | *мәндән мондан* | *бәндән бондан* | *мәндән мөндән* | *мәнден бөнден* |
| Юнәлеш к. | *миңа моңа* | *миңә быга* | *маган боган* | *маган боган* | *маңа моңа* | *бана бона* | *мәнгә мөнгә* | *маңа бөңа* |
| Төшем к. | *мине моны* | *мине мыны* | *мәне мынаны* | *мәне мынаны* | *мәне моны* | *бәни боный* | *мәне мөне* | *мине бөне* |
| Вакыт-урын к. | *миндә монда* | *миндә мында* | *мәндә бода* | *мәндә бода* | *мәндә монда* | *бәндә бонда* | *мәндә мөндә* | *миндә бонда* |
| Рәвеш к. | *минемчә моныңча* | *миненсә мыныңса* | *мәнеңшә мынаныңша* | *мәнекчә мынаныкча* | *мәнемчә моныңча* | *бәнчә бонча* | *мәнчә мөнчә* | *минчә бонча* |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Ошату к. | *миндәй (минди) мондый* | *миндәй мындай* | *мәндәй мынадай* | *мәндәй мынадай* | – – | – – | *мәндәк мөнәка* | *миндәк бондак* |

### Исем фигыльләрнең исем төрлекләре белән төрләнеше

Исем фигыльләр дә, ясалма сыйфатлар кебек, барлык өч рәт исем төрлекләре белән төрләнәләр.

Мәсәлән:

| Килешләр | үткән фигыльләр | киләчәк фигыльләр | җавап фигыльләр |
|---|---|---|---|
| Баш к. | *укыган, белмәгән* | *киләчәк, калмаячак* | *язар, аңламас* |
| Иялек к. | *укыганның, белмәгәннең* | *киләчәкнең, калмаячакның* | *язарның, аңламасның* |
| Чыгыш к. | *укыганнан, белмәгәннән* | *киләчәктән, калмаячактан* | *язардан, аңламастан* |
| Юнәлеш к. | *укыганга, белмәгәнгә* | *киләчәккә, калмаячакка* | *язарга, аңламаска* |
| Төшем к. | *укыганны, белмәгәнне* | *киләчәкне, калмаячакны* | *язарны, аңламасны* |
| Вакыт-урын к. | *укыганда, белмәгәндә* | *киләчәктә, калмаячакта* | *язарда, аңламаста* |
| Рәвеш к. | *укыганча, белмәгәнчә* | *киләчәкчә, калмаячакча* | *язарча, аңламасча* |
| Ошату к. | *укыгандай, белмәгәндәй* | *киләчәктәй, калмаячактай* | *язардай, аңламастай* |

Боларның күплек, япсару төрлекләре белән бергә төрләнешләре дә исемнәрдәге кебек үк: *укыганнарыңны, белмәгәннәрегездән, булмаячагыгызны, киләчәкләрегезне, белмәгәннәргә, укыганнарча, киләчәкләрендәй, язарымны, аңламасыгызны*... кебек (20 табл.).

### Кабат ясалып, кабат төрләнү

Безнең телебездә 3 нче рәт төрлекләр белән төрләнгән исемнәрнең кайберләре, яңадан беренче рәт сыйфат ясагычлары кушылып, ясалма сыйфатка әйләнәләр.

Мәсәлән, исемнәр, өченче рәттәге *да-дә, та-тә, дан-дән, тан-тән, ның-нең* төрлекләреннән соң *гы-ге, кы-ке* кушымчалары ялганып, яңадан сыйфат булып ясалалар (бу вакыт *ның+гы, нең+ге* төрләре *ныкы-неке* булып үзгәрә).

Мәсәлән: *авылдагы, авыллардагы, авылыгыздагы, килгәннәрегездәге... күптәнге, алдынгы* (алдангы), *өстенге* (өстәнге)... *каланың-каланыкы, аның-аныкы, минем-минеке* (минеңке), *тегеләребезнеке*. Бу исемнәр шулай кабат ясалганнан соң, җөмлә эчендә исем урынына торучы сыйфатлар

роленә кучеп, тагы тәкрар өч рәт исем төрлекләре белән дә төрләнә алалар.

Мәсәлән: *авылларлардагыларыбызның, авылларыгыздагыларга...*
*килгәннәребездәгеләренең,*
*китерешкәләгәннәрегездәгеләрне,*
*куптәнгеләреңне, кубегездәгеләрегездәй...*
*минекеләрдән, минекеләрегездәгеләрегезчә...*
*минекендәйләрнекенең.*

Шулай ук *ча-чә* төрлекләре белән төрләнгән сүзләр исемгә әйләнеп катканнан соң, фигыль ясаучы *ла-лә* кушымчалары ялганып, фигыльгә әйләнүләре мөмкин: *русчалап, татарчалаштырып, синеңчәләтеп, төрекчәләштереп...* кебек.

## Өстәмә төрләнеш

Югарыда, кушымчаларны сөйләгән җирдә, бөтен сүз төркемнәренең азагына өченче чиратта килеп кушыла торган кисәкләрне «өстәмә кушымчалар» дигән бер төркемгә аерып күрсәткән идек. Хәзер без шушы өстәмә кушымчалар белән төрләнешне тикшерә башлыйбыз.

Өстәмә кушымчалар һәр төркемдәге тамыр һәм нигез сүзләргә дә, бөтен фигыль һәм исем төрләренә дә кушыла алалар. Аларның өченче чираттагы кушымчалардан саналулары, ясаучы һәм төрләндерүче кушымчалар булган чагында, алардан соң килүләренә карап әйтелә (23 табл.).

Өстәмә кушымчалар үзләре, гадәттәге кушылу тәртипләренә карап, өч рәткә бүленәләр: 1) чикләүләр, 2) хәбәрлекләр, 3) очлыклар.

### 1) Чикләү кушымчалары

Болар үзләре өч төрле була:

1) Якынлык чикләү – моның кушымчалары *рак-рәк (ырак-эрәк)* була.

2) Артыклык чикләү – моның кушымчалары *ук-үк* була.

3) Төгәллек чикләү – моның кушымчалары *гына-генә, кына-кенә* була.

Бу соңгысының *рак-рәк* белән янәшә килеп, аңардан соң әйтелеше дә бар. Мәсәлән: *килде генә, килсәгез үк, алгач ук, базарданрак, килебрәк, янынданрак кына, безгә үк, аның өчек үк, килгән белән генә, шундарак кына, бирсдәрәк кенә...* кебек.

Чикләүләр белән төрләнешкә мисаллар:

*килебрәк, килеп кенә, килеп үк, язышкач ук..., авылда гына, авылдагылардан гына, авылчарак, калачарак, юлда ук, минекедәй үк...,*

*кызыл гына, укытучы гына, килешкәнрәк, киләчәк үк, төшенкерәгәнрәк...,*

*ике генә, бөтенрәк, бөтен генә, ничә үк...,*

*теге генә, үзе үк, тегеннәнрәк кенә, тегеләйрәк үк...,*

*иртә генә, иртә үк (иртүк), иртәрәк, кышрак, кыш үк...,*

*өчен генә, өченрәк, саен гына, кебегрәк кенә...*

Искәрмә. *Рак-рәк, кына-кенә, гына-генә* кушымчалары күп вакыт төп яки ясалма сыйфатларның һәм исем фигыльләрнең азагына турыдан-туры кушылып йөриләр.

Сыйфат һәм исем фигыльләр исем төрлекләре белән төрләнеп әйтелгән чагында, бу өстәмә кушымчалар исем төрлекләреннән алда (нигез кисәк белән төрлекләр арасында) килергә дә мөмкин. Мәсәлән:

*Яшелрәкләрне, яшелрәкләреннән, кызыл гыналарыннан, кызыл гынасыннан, пешкәнрәкләрен, пешкәнрәкләреннән генә, матур гыналарыгызны, матурракларыбыздагысын гына, күрмәстәйрәкләренең, күрмәстәйрәкләренекеннән, белүчерәгегезне, белүчерәкләребезгә генә дә* (бу вакыт алар чагыштыру мәгънәсен аңлаталар).

### 2) Хәбәрлек кушымчалары

Хәбәр һәм хәл фигыльләреннән башка һәрбер сүз җөмләнең хәбәре булып килгәндә, өч затка япсарып, алты төрдә сөйләнелә ала. Шуңа карап, һәрбер сүз хәбәрлек кушымчалары белән төрләнеп әйтелә. Уртак хәбәрлек кушымчалары түбәндәгеләр:

| япсару | бер затка | күп затка |
|---|---|---|
| минлек | *мын-мен* | *быз-без* |
| синлек | *сың-сең* | *сыз-сез* |
| уллык | – | *лар-ләр (нар-нәр)* |

Хәбәрлек кушымчалары күбрәк чикләү кушымчаларыннан соң, 2 нче рәттә киләләр. Уллык нисбәтендәге хәбәрлек төре кайвакыт *ул*, алар алмашы белән дә күрсәтелгәли.

Хәбәрлекләр белән төрләнешкә мисаллар:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| бер затка | *кеше*<br>*кешемен*<br>*кешесең*<br>*кеше (ул)* | *кызыл*<br>*-мын*<br>*-сың*<br>– | *шәп*<br>*-мен*<br>*-сең*<br>– | *алган*<br>*-мын*<br>*-сың*<br>– | *тимерче*<br>*-мен*<br>*-сең*<br>– | *киләчәк*<br>*-мен*<br>*-сең*<br>– | *укыр*<br>*-мын*<br>*-сың*<br>– | *түгел*<br>*-мен*<br>*-сең*<br>– |
| күп затка | *кешебез*<br>*кешесез*<br>*кешеләр (алар)* | *-быз*<br>*-сыз*<br>*-лар* | *-без*<br>*-сез*<br>*-ләр* | *-быз*<br>*-сыз*<br>*-нар* | *-без*<br>*-сез*<br>*-ләр* | *-без*<br>*-сез*<br>*-ләр* | *-быз*<br>*-сыз*<br>*-лар* | *-без*<br>*-сез*<br>*-ләр* |

Чикләү кушымчалары белән аралаш мисаллар: *авылда гынамын, килгәнрәкмен, калачараксыз, авылданраклар, миндәй уксең, бөтенрәксез, тегендирәкләр, шәбрәк кенәсез, беренче геналәр, беренчеләр генә, базардасың, кызыллардanмын, сезнекеләрчәмен, кешегезмен, аюдайсың, кебекмен.*

### 3) Очлыклар

Болар безнең телебездә бөтен кушымчалардан соң, сүзнең иң очында, азагында әйтеләләр, өстәмә башка кушымчалар да булганда, 3 нче рәттә киләләр.

Безнең телебездә түбәндәге очлык өстәмә кушымчалар бар:

1) Үтенеч – *чы-че, сана-сәнә*. Болар күбрәк боерык һәм шарт фигыльләреннән соң килүчән.

Мәсәлән: *барсаңчы, килче, бирсәнә, алсагызсана...* кебек.

2) Борчылу – *ла-лә, лабаса-ләбаса...* Болар бөтен сүзләргә кушыла ала.

Мәсәлән: *килдең лә, юк ла, килермен лә, утырды, лабаса, кирәкми лә, булмас ла.* (Фигыль ясаучы *ла-лә* белән саташтырмаска кирәк.)

3) Җыю-кушу – *да-дә, та-тә.* Мәсәлән: *син дә кердең ишектән, мин дә кердем ишектән; уйна да көл, исәплә дә бел.* (Вакыт-урын килеше булган *да-дә, та-тә* бөтенләй башка.)

4) Сорау – *мы-ме, мыный-мени.* Мәсәлән: *сездәме, юкмы, булдымы, яздырмадыгызмыный.*

5) Икеләнү – *дыр-дер, тыр-тер.* Мәсәлән: *килгәндер, юктыр ла...*

(Фигыль дәрәҗәсе ясаучы *дыр-дер...* белән саташтырмаска кирәк.)

Мисаллар:

*килче, алсамчы, укысагызчы, күрсәнә, карасана, күрдемсәнә, килгән лә, ярар ла, юк ла, булмады ла, алачакбыз ла, килербез дә, киләчәкләр дә, тегендәйрәкләр дә, аныкы да, алгансыңмы, киләчәксезме, күрәсеңме, төшкәнбезме, шулай гынадыр, юктыр ла, юктырсың ла.*

Хәбәрлек төрлекләре белән сорау кушымчасы бергә килгәндә, кайбер төрләрнең тәртибендә алмашу ясалырга мөмкин. Мәсәлән: *киләмсең (киләсеңме), күрәмсез (күрәсезме); әмма киләмеләр, күрәмебез* төрендә сөйләү юк.

Бу өстәмә кушымчалар телдә сирәк кулланылалар, аларның 1 нче, 2 нче, 3 нче рәттә кайсылары килеп кушылуы да төрлекләрдәге кадәр ныгып, урынлашып җитә алмаган әле. Боларның *рак-рәк* тән башкалары төп сүзнең басымын үзләренә үткәрмиләр. Аларның кушымчалардан саналулары гармониядә төп сүзгә ияреп йөрүләренә карап. Бәгъзе бер[1] төрек телләрендә аларның кайберләре төп сүзнең гармониясенә иярми.

Шушы өченче төркем өстәмә кушымчалар белән төрләнгәннән соң, сүзләрнең, теләсә нинди булсын, бөтен төрләнешләре бетә. Бу кушымчалардан соң калынлыкта, нечкәлектә тамырга ияргән кисәкләр булмый. Телебезнең бөтен ялганмалык табигате, бөтен морфологиясе шушы өч төркем кушымчалардан гыйбарәт. Бер иҗекле тамыр сүзләрнең шушы ныгып урнашкан, математик рәтләрдә тезелгән кушымчалар ялганып, 10–15 иҗекле сүзләргә әйләнүе, бер тамырдан әллә никадәр сүз төрләре чыгуы мөмкин.

[1] Бәгъзе бер – кайсы бер, кайбер.

## Сүз кисәкләре, аларның төркемнәре, рәтләре

23 таблица

| Тамыр-лар | Кушымчалар | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | I – сүз ясаучы кушымчалар | | | II – төрләндерүче кушымчалар | | | III – өстәмә кушымчалар | | |
| | 1-рәт ясагычлар | 2-рәт дәрәҗәләр | 3-рәт юклык | 1-рәт заманнар-күплек | 2-рәт япсару-лар | 3-рәт килеш-ләр | 1-рәт чикләү-ләр | 2-рәт хәбәр-лекләр | 3-рәт очлык-лар |
| *Фигыль* | *ла-лә, ра-рә, ай-әй, а-ә, ылда-елдә- ыра-ерә* | *дыр-дер, ыт- ет, т, ыш-еш, ш, ыштыр-ештер ыл-ел-л, ын- ен-н, ымсыра- емсерә ынкыра-енкерә, гала-гәлә, кала-кәлә* | *ма- мә мый-ми* | *ый-и, сын-сен, ды-де, ты-те, са-сә*<br>*а-ә, ый-и* | *м, к*<br>*н-гыз-гез лар-ләр* | –<br>– | –<br>– | <br>– | *чы-че*<br>*сана-сәнә* |
| | | | | *(мый-ми) ча-чә а-ә, ыш-лый-ешли, гач-гәч, ганчы-гәнче* | – | | *рак-рәк* | | *мы-ме, мыный-мени* |
| *Исем* | *у-ү, ыш-еш-* | *кай-кәй* | | *кан-кән,* | | | | | *дыр-дер,* |
| *Сыйфат* | *ш, ым-ем,* | | | *ган-гән,* | | | | *мын-мен* | *тыр-тер* |
| *Сан* | *ма-мә* | *чык-чек* | | *ачак-әчәк* | | | *гына-* | *быз-без* | *ла-лә* |
| *Вакыт-урын* | *мак-мәк гыч-геч, кыч-кеч, асы-әсе,* | *ук-уш* | | *ар-әр-р, с* | *м-быз-без н-гыз-гез* | *ның-нең дандән да-дә* | *генә, кына-* | *сың-сең сыз-сез* | *да-дә, та-тә ча-чә* |
| *Алмаш* | *лык-лек, ныкы-неке,* | *гылт-келт* | | | *ы-е-* | *га-гә ны-не-* | *кенә,* | *лар-ләр* | |
| *Рәвеш* | *ык-ек, к, ныч-неч лы-ле, сыз-сез, чы-че* | *су-сү, сыл-сел* | – | *лар-ләр* | *сы-се* | *н ча-чә* | *ук-үк* | *(нар-нәр)* | |

| Тамыр-лар | Кушымчалар | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | I – сүз ясаучы кушымчалар | | | II – төрләндерүче кушымчалар | | | III – өстәмә кушымчалар | | |
| | 1-рәт ясагычлар | 2-рәт дәрәҗәләр | 3-рәт юклык | 1-рәт заманнар-күплек | 2-рәт япсарулар | 3-рәт килешләр | 1-рәт чикләүләр | 2-рәт хәбәр-лекләр | 3-рәт очлыклар |
| *Ымлык* | *даш-дәш, таш- таш, чан-чән, ынчы-енче, шар-шәр...* | *ылҗем-елҗем кылтым-келтем* | | *(нар-нәр)* | | *дай-дәй, тай-тәй* | | | |
| *Ярдәм-лек* | *гы-ге, кы-ке, ын-ты-енте, лата- ләтә, лай-ләй, тын-тен* | – | – | – | – | – | | – | |
| *яз* | – | *дыр* | *ма* | *ды* | *гыз* | – | – | – | *мыный* |
| *уф* | *ылда* | – | *ма* | *ган* | *ы* | *ннан* | *гына* | – | – |
| *күк(г)* | *әр* | *енкерә* | – | *б* | – | – | *рәк* | – | *тә* |
| *уй* | *ла* | *штыр* | – | *са* | *лар* | – | – | – | *чы* |
| *кил* | – | *еш* | *мә* | *ячәк* | – | – | – | *мен* | *лә* |
| *баба* | – | *кай* | – | *-лар* | *ыбыз* | *ча* | *рак* | – | – |
| *көч* | *ле* | – | – | *-ләр* | *е* | *ннән* | *рәк* | *сең* | *дер* |
| *юл* | *даш* | *кай* | – | *-лар* | *ым* | *ның* | – | – | *да* |
| *күр* | *әсе* | *кәй* | – | *-ләр* | *ең* | – | *гена* | – | – |
| *кыз(л)* | *гылт* <br> – | – <br> – | – <br> – | – <br> *+ лар* | – <br> *ы* | – <br> *ннан* | *рак + гына* | – | *мы* |
| *бер* | *енче* <br> *+че* | – <br> – | – <br> – | – <br> *+ ләр* | *егез-гез* <br> – | *дә+ гә(чә)* | *генә* | – <br> – | *ме* <br> *лә* |
| *күп* | – <br> *+ге* | – <br> – | – <br> – | – <br> *– ләр* | – <br> *е* | *тән+ н* | – | | |
| *якын* | *тын* | – | – | – | – | – | *рак + кына* | – | – |
| *кур* | – <br> *+ лек* | *сәт* <br> – | *мә* <br> – | *гән +* <br> *– нәр* | *е* <br> – | *ннән* <br> *да +* | *ук* | – | – |
| *очра* | *ш* <br> *гы* | *тыр* <br> – | – <br> – | *ган* <br> *-лар* | – | *ны* | *гына* | – | *дыр + ла* |

**Татар телендәге сүзләрнең морфологик төзелеш схемасы**




Бу схемада тамыр сүзләр буй озынчык белән, ясагычлар аркылы озынчык белән, төрлекләр түгәрәк белән, өстәмә кушымчалар өчпочмак белән күрсәтелә. Кайбер төрләрнең яңадан ясалу, яңадан төрләнүләре уклы сызыклар белән күрсәтелде. Уксыз сызыклар табигый тәртип белән төрләнешне күрсәтә. Сүзләрнең кушымчаларның барсы белән азакка чаклы төрләнмичә әйтелешләре, яки бернichә кушымчаларны калдырып, аша атлап төрләнешләре, әлбәттә, ирекле була. Хәбәр фигыльләрнең хәбәрлек төрлекләре белән төрләнеше генә ирексез. Шуңа күрә алар бер-берсенә тоташкан түгәрәкләр белән күрсәтелде.

## Ярдәмлекләр

Үзенә аерым гармонияле һәм басымлы, ләкин ясаучы һәм төрләндерүче кушымчалар белән төрләнми торган сүзләр «ярдәмлекләр» дип атала.

Ярдәмлекләр төбендә тулы мәгънәләрен югалтып та кушымча булып өлгермәгән сүзләр дип каралырга мөмкин. Ярдәмлекләр үзләре ялгыз көенчә җөмләнең аерым бер кисәге була алмыйлар.

Ярдәмлекләр, хезмәтләренә һәм башка сүзләрнең алдыннан я артыннан янәшә әйтелүләренә карап, тышкы яктан өч төркемчәгә бүленәләр:

1) бәйләүче, 2) аеручы, 3) уртак.

1. **Бәйләүче** ярдәмлекләр һәрвакыт исемнәрнең азагыннан килеп, аларның фигыльгә мөнәсәбәтләрен билгеләүгә, фигыльгә бәйләнешенә хезмәт итәләр. Бу яктан алар исемнәрдәге 3 нче рәт килеш төрлекләре белән бер табигатьтә булып, әйтелгән урыннарында да, уртак төрлекләр белән төрләнүдә дә килеш төрлекләренә охшыйлар. Мәсәлән: *белән, өчен, кебек, саен, башка, соң, таба, күрә*... кебек сүзләр.

*Каләм белән, синең өчен, урманга таба, атна саен, сездән башка...*

2. **Аеручы** ярдәмлекләр. Болар – теләсә нинди сүзләрнең күп вакыт алдыннан килә торган ярдәмлекләр: *бик, иң, ләкин, һич, һәр, һәм, тагын, нәкъ, я, яки, ни, бәлки, әгәр*... кебекләр. Болар кайберсе өстәмә кушымчалар белән төрләнә дә алалар.

Мәсәлән: *бик зур, һич тә юк, тагы да булмады, нәкъ үзе, я явар, я юк, ни әйт, ни әйтмә...*

3. **Уртак** ярдәмлекләр. Югарыда күрсәтелгән шушы ике төркемгә кермәгән вак сүзләр: *түгел, ич, бит, әллә, ахры, шәт, инде, әле, юк, бар*... кебекләр. Юк, бар ярдәмлекләре *ла-лә, лык-лек* ясагычлары белән фигыль исем булып ясалалар. Шул торышларынча исем төрлекләре белән дә төрләнә алалар. *Түгел, юк* ярдәмлекләре исемнәрдә юклык төре булып хезмәт итәләр һәм күп вакыт, җөмләнең хәбәре булган исемнәргә кушылып, хәбәрлек төрлекләре белән дә төрләнәләр.

Мәсәлән: *мин барачак түгелмен; Әхмәтнең йөрәге таш түгел; минем күргәнем юк; ул китап бездә бар...*

Ярдәмлекләргә, гомумән тамыр сүзләргә ияреп, бөтенлеген югалтып өлгермәгән кушымчалар дип караганда, боларга исемнәрнең юклык төрен күрсәтүче кисәкләр дип карарга да ярый. Һәрхәлдә алар әле гармониядә бөтөп төп сүзләрдән саналырга тиешләр.

## Ымлыклар

Ымлыкларның күбесе бертөрле кушымчалар белән дә төрләнмиләр. Аларның беразы исем төрлекләре белән, беразы фигыль төрлекләре белән төрләнгәли.

Ымлыклар күбрәк, фигыль ясаучы кушымчалар белән төрләнеп, фигыльгә әйләнәләр, яки шул торышларынча, җөмлә эчендә фигыльләрдән алда килеп, рәвеш тәмамлыгы булып хезмәт итәләр. Җөмлә эчендә алар кереш, эндәш сүзләре булып та йөриләр.

Мәсәлән: *аһ, аһлары, уфылда, шапылдат, песелдә, мә, мәгез, ясанә; уф итте, ах итеп тора, чүегез, жу итте, шау-гөр киләләр, гөрләтеп, шаулап, гыжлады... Уф, мин бик ардым. Әй, кил әле бире. Тс! Тукта әле...уф, нишләтергә инде бу нәрсәләрне! Әләлә, бигрәк шәп икән бу әкәмәт!*

## Дүртенче бүлек

# ТЕЛЕБЕЗНЕҢ НӘХҮЕ

## НӘХҮ НИГЕЗЛӘРЕ

Грамматиканың бер бүлеге булган нәхүнең да маузугы[1] сүз тезмәләренең тышкы күренешләре булырга тиеш. Сөйләшкән вакытта безнең телебездәге сүзләрнең тезелешләрендә нинди тышкы күренешләр, нинди фактлар бар? Булса,ниләр? Менә грамматиканың бер кисәге булган нәху шушы мәсьәләләрне ачып бирергә, шушы сүз тезмәләрендәге тышкы күренешләрне бер системага салып күрсәтергә тиеш. Сүз тезмәләренең мәгънә, фикер аңлату ягын тикшерү шәкли грамматиканың вазыйфасына керми. Ул мантыйк эше. Шуңа күрә нәхүне «сүз тезмәләренең тышкы күренешләрен, сүзләрнең берберенә тышкы бәйләнешләрен һәм нинди тәртиптә тезелеп әйтелешләрен тикшерә торган гыйлем», дип тәгъриф итәргә кирәк.

Телебезнең нәхви төзелешендә нинди тышкы фактлар булырга мөмкин? Алдагы юлыбыз ачык күренеп торсын өчен, иң элгәре шул турыда берике сүз әйтеп китәргә туры килә.

Безнең телебезнең сүз тезмәләрендә тышкы күренешләр, китапның башында сөйләнеп үтелгәнчә, түбәндәге нәрсәләрдән гыйбарәт:

1) **Ялганмалык.** Җөмлә эчендәге сүзләрнең бер-беренә бәйләнешләре сүз төрләндерүче кушымчаларның берәрсе белән күрсәтелгән булырга тиеш. Бу яктан кушымчалар белән төрләнмәгән кайбер әйтешләрнең дә аерым бер төр саналганлыгын әйткән идек. Шулай ук кушымчалар рәтендә йөргән бәйләүче ярдәмлекләр дә аерым төрләр булып саналалар.

2) **Тәртип.** Тышкы яктан сүзләрнең бер-беренә бәйләнеше нәхви төрләрнең берсе белән дә күрсәтелмәгән булса, ул вакыт җөмләдә сүзләрнең торган урыннары, аларның нинди тәртиптә әйтелүләре, тышкы бер күренеш булып санала. Бер үк сүздә бу ике күренеш икәве дә булырга мөмкин.

Безнең телебездә җөмлә төзелешенең иң әһәмиятле ягы сүзләрнең тәртибе. Бездә бер җөмлә эчендәге сүзләр, төрле кушымча һәм ярдәмлекләр белән төрләнүләренә яки төрләнмәүләренә карамастан, аерым бер канун һәм урынлашып каткан ныклы бер тәртип белән тезеләләр. Җөмләдә шул тәртип аз гына бозылса да, без аны бик тиз сизәбез, ул шунда ук «мин төрек теленчә түгел» дип кычкырып тора. Бу тәртип бөтен төрек

[1] Маузугы – темасы, проблемасы.

телләрендә бертөсле дияргә ярый. Вак-төяк аерымлыклар булса, чит телләргә артык катнашып, аның тәэсиренә бирелеп киткән телләрдә генә булырга мөмкин.

Сүз тәртибе ягыннан рус теле белән төрек телләре арасында аерма зур. Рус телендә ныгып урынлашкан, катып калган бер тәртип юк диярлек. Рус җөмләләрендә сүзләрнең теләсә нинди тәртиптә килүе артык хатага саналмый. Булган тәртибе дә бөтенләй безнең телләребезнең киресенчә. Шуңа күрә алар моны үз нәхүләрендә тикшереп тә тормыйлар, әмма бездә тәртип мәсьәләсе нәхү өчен иң зур мәсьәләләрнең берсе булып, нәхүләребездә, әлбәттә, өйрәтелергә тиеш.

Төрек җөмләләрендәге сүзләрнең нинди тәртиптә килүен бер авыз сүз белән әйткәндә: «бездә иң кирәкле сүз иң соң әйтелә» яки: «бездә башкарылган сүз башкаручыдан элгәре килә» дигән ныклы бер канун килеп чыгар иде. Нигә дисәң, бездә: 1) җөмләнең иң төп кисәге – төп башкаручысы булган хәбәр (хөкем) иң соңыннан килә, аның тарафыннан башкарылган кисәкләр хәбәрдән элгәре әйтелә; 2) тәмамлыкларның иң кирәкле булганы (ия дә шуның эчендә) иң азакта хәбәр янында гына, ә башкалары исә, кирәкләренә карап, шул ук тәртиптә урын алалар, бик кирәкмәгәне алдан әйтелә; 3) сыйфатланган исем, сыйфатына караганда үзе әһәмиятлерәк булганга, сыйфатыннан соң килә; 4) сыйфатлар (аергычлар), үзара тагын кирәкләренә карап, исемнең алгы ягында тезелеп киләләр, кирәклесе соң әйтелә; 5) кушма җөмләләрдә дә хәл шулай: иярчен җөмләләр бездә элек әйтелеп, төп җөмлә соң әйтелергә тиеш, шуңа күрә дә безнең *чөнки, ә, әмма, ләкин, ки...*ләр белән төзелгән җөмләләребездән русча яки фарсыча төзелгәнлек сизелеп тора. Рус теленә килсәк, анда эшләр бөтенләй бездәгенең киресенчә: аларда иң кирәкле сүз иң элек әйтеп куела да, шуңа бәян рәвешендә[1] булган иярчен сүзләр соңыннан әйтелә. Безнең сүз тезмәләрендә тышкы күренеш, сүзләрнең бер-берсенә бәйләнеше шушы тәртип белән күрсәтелүдән гыйбарәт.

**3) Басым, аһәң, тыныш.** Шушы әйтелгәннәр өстенә, эчендә сүзләр бер-берсеннән үзенә аерым басым белән, аерым бер аһәң (тон) белән әйтелү, тавышны кисеп, төрлечә туктап тыныш ясау белән дә аерылалар. Җөмлә эчендәге иң әһәмиятле сүз көчле басым белән әйтелә, ия һәм хәбәр бер-береннән аерым тавыш белән, үзенә махсус тыныш ясап әйтелү белән аерылалар. Баш һәм иярчен җөмләләрне дә бер-берсеннән шушы аһәң һәм тынышта аерымлыкларына карап аерырга була.

Шушы әйтелгән күренешләр бары да безгә телебезнең нәхви төзелешен тышкы яктан карап тикшерүгә корал булып, тышкы фактлар булып хезмәт итәләр. Нәхүгә, җөмләләрнең төзелешен тикшерергә кергәндә, безгә шушы кораллар белән әзерләнеп керергә тиеш була.

[1] Бәян рәвешендә – ачыклау, аңлатма рәвешендә.

## ҖӨМЛӘ ТӨЗЕЛЕШЕ

Сүз тезмәләренең иң әһәмиятлесе – бер сөйләм итеп төзелгән сүзләр җыентыгы, ягъни җөмлә. Җөмлә нәрсә ул?

Шәкли грамматикада без җөмләне, ялганмалык табигатенә караганда, «баш килештәге иягә бәйләнеп, аңа ярашып әйтелгән хәбәрдән гыйбарәт сүзләр тезмәсе» дип тәгъриф итәргә тиеш булабыз. Аһәң ягыннан исә җөмләне «тоташ бер аһәң белән сөйләнгән, бер тыныш белән тукталган, бер-беренә бәйләнешле сүзләр җыентыгы» дип танырга була.

### Баш кисәкләр

Җөмләдә баш килештә әйтелгән сүз «ия» булып, аңа ярашып, бәйләнешле итеп әйтелгән сүз җөмләнең «хәбәре» була. Җөмләнең баш кисәкләре шушы ия белән хәбәр, бәлки, иң төп кисәге фәкать хәбәр генә дип әйтергә ярый, чөнки иясез нәхви сөйләм булса да, хәбәрсез сөйләм булырга мөмкин түгел. Бу – бер. Икенчедән, иянең үзенә хәбәрнең (фигыльнең) баш тәмамлыгы дип кенә карарга да юл бар.

Ия белән хәбәрнең бәйләнешләре, тышкы күренешләре түбәндәге нәрсәләрдән гыйбарәт:

1) Төрләнеш ягыннан ия һәрвакыт баш килештә, ягъни 3 нче рәт исем төрлекләре кушылмаган төрдә, әйтелгән исемнән гыйбарәт була. Бу исем тамыр хәлендә дә, төрле сүз төркемнәреннән ясалган нигез төрендә дә, 1 нче, 2 нче рәт исем төрлекләре белән (сан һәм япсарулар белән) төрләнгән теләсә нинди сүзләр төрендә дә булырга мөмкин.

Хәбәр үзенә махсус заман һәм хәбәрлек төрлекләре ялганып әйтелгән фигыльләрдән яки күп вакыт уртак хәбәрлек кушымчалары белән төрләнгән исем яки башка сүз төркемнәреннән гыйбарәт була.

Хәбәрлек кушымчалары хакында сарыф бүлегендә сөйләнгән иде. Берлек санындагы 3 нче затка каратып әйтелгән хәбәрләрнең хәбәрлек төрлекләре юк. Ләкин кайвакыт җөмләнең хәбәре булганда, аларга да *ул–алар* сүзе кушып әйтелгәли. Мәсәлән:

*мин кызумын; син бик усалсың; Әхмәт батыр ул; сез кайдасыз? Казлар тугайда алар; теге дару бик килешә ул...* дигән мисалларда мин, сың, сыз белән бер рәттә йөргән *ул, алар* җөмләнең хәбәре булган сүзләрнең хәбәрлек билгеләре булалар.

Хәбәрнең иягә бәйләнеше, аңа ярашуы да шушы хәбәрлек төрлекләре дип аталган кушымчалар белән күрсәтелә. Безнең телебездә ия кайсы затка каратып, нинди санда әйтелгән булса, хәбәр дә шул затка япсарып, шул санда килергә тиеш.

Татар, башкорт телләрендә *уллык* нисбәтендә әйтелгән хәбәрләр күплек санындагы иягә ярашмыйча, күбрәк берлек санында гына әйтеләләр. Мәсәлән: *игеннәр үсте; җиләкләр өлгергән; пионерлар килә...* кебек.

2) Уллык нисбәтендә сөйләнгән җөмләләрдә күп вакыт хәбәрнең ияге бәйләнеше – ярашуы төрлекләр белән күрсәтелеп бетми. Җөмләнең хәбәре исемнәрдән, сыйфатлардан яки башка сүз төркемнәреннән булганда, бу хәл биграк тә еш очрый. Ул вакыт без хәбәрнең ияге бәйләнешен аларның тәртибеннән беләбез. Бөтен төрек телләрендәге гадәт буенча, ия һәрвакыт алда, хәбәр һәрвакыт диярлек җөмләнең азагында килергә тиеш: *Кызыллар көчле; тау биек; Гали Казанда; тел сөяксез...* кебек.

3) Болар өстенә ия күп вакыт күтәренке тавыш белән әйтелә дә, сүзнең ахыры булачагын көттергән кебек, тын алмыйча аз гына туктау ясала. Хәбәрне әйткәннән соң исә, бөтенләй тынычланып, тулы тыныш ясалырга мөмкин. Гадәткә каршы хәбәр иядән элек әйтелгәндә дә (мондый хәл булгалый), без шушы тавышка, ике арадагы тыныш аермасына карап, аның кайсы ия, кайсы хәбәр икәнен аерып таный алабыз.

Мәсәлән: *вакытны бушка уткәрмә, кадерле – минуты да.*

## Ким җөмләләр

Һәрбер сүз тезмәсе җөмлә булып саналмый. Җөмлә булу өчен ул сүзләр тезмәсендә югарыда әйтелгән ия белән хәбәр булырга тиеш. Ләкин хәбәр булган сүз үзенең тышкы шәкле төрлекләре белән иянең нидән гыйбарәт икәнлеген күрсәтеп торганда, иясез, ялгыз хәбәр үзе генә булганда да җөмлә саналырга ярый. Мәсәлән: *авылдан килдем* (иянең *мин* икәнлеген: *килдем* нең минлек нисбәтендәге төрлеге *м* күрсәтеп тора). *Ни чәчсәң, шуны урырсың* (*сың* төрлеге иянең *син* икәнлеген күрсәтә.) *Суытты; өшетә...* кебекләр дә – шул җөмләдән.

Ләкин мондый сүзләрне ким җөмлә дип карарга тиеш түгел. Аларның ияләре нинди сүз икәнлеге беленеп торганга күрә, тулы бер җөмлә саналырга хаклары бар.

Бу мисаллар безгә икенче яктан җөмләдә хәбәрнең иң төп кисәк булганлыгын, иянең хәбәргә бәйләнгән баш тәмамлык булып саналырга яраганлыгын күрсәтәләр.

Түбендә ия белән хәбәрсез җөмлә юк. Ләкин кара-каршы сөйләшкән чакта (диалогларда) әйтелгән хәбәрсез дә, иясез дә сүзләр нәрсә булалар?– *әйе – юк – нәрсә? – кем белән?* – кирәкми... кебек бер кеше тарафыннан аерым бер уй итеп сөйләнгән сүзләрнең ияләре, хәбәрләре кайда?

Кара-каршы сөйләшүләрдә сөйләүче үз сүзенә генә түгел, иптәшенең сүзләренә дә бәйләп әйтүчән була. Җаваплашу нихәтле тиз барса, шул чаклы анда җөмләнең тулылыгы да кими бара. Хәтта берәүсенең сүзе ялгыз бер ярдәмлек, бер төрлек хәлендә генә дә әйтелергә мөмкин.

Чөнки һәрнәрсәдә булган икътисад[1] дигән нәрсә телдә дә бар. Шул хәл җөмлә кисәкләренең иң актыкка кадәр кыскартылуына сәбәп була.

[1] Икътисад – экономия.

Бу вакыт ул җөмләнең иясен, хәбәрен ике яктан әйтелгән сүзләрнең барсыннан да эзләргә кирәк була. Шуңа күрә андый иясез дә, хәбәрсез дә әйтелгән сүзләргә җөмләнең бер кисәге генә дип карарга тиеш була. Ләкин ялгыз сөйләнгән сүзләрдә (монологларда), хикәяләрдә мондый җөмләләр булмый.

## Иярчен кисәкләр

Ия белән хәбәр җөмләнең баш кисәкләре санала дигән идек. Җыйнак җөмләләрдә бары ия белән хәбәрдән гыйбарәт ике сүз генә булырга мөмкин. Таркау җөмләләрдә исә, ия белән хәбәрдән башка да байтак сүзләр була. Боларны җөмләнең «иярчен кисәкләре» дип атыйлар. Җөмлә эчендәге иярчен кисәкләр дә, ия белән хәбәр кебек, үзләре ияргән сүзгә эчке мәгънәләре ягыннан да, тышкы әйтелешләре ягыннан да бәйләнгән булырга тиешләр. Аларның эчке яктан бәйләнешләре ия белән хәбәрне яки башка берәр сүзне әйткәннән соң тыңлаучы тарафыннан бирелүе мөмкин булган сорауларга җавап булып әйтелүләренә карап йөри. Иярченнәрне мәгълүм бер җөмлә кисәге теләми, бәлки мәгълүм сүз төркемнәре телиләр. Без монда аларның эчке бәйләнешләрен түгел, бәлки тышкы әйтелеш ягыннан нинди булса да тышкы бер төр белән бәйләнешләрен генә тикшерергә, аларны шул тышкы яктан булган аерымлыкларына карап өйрәнергә тиеш булабыз.

Иярчен кисәкләрнең җөмләнең баш кисәкләренә яки ияртүче башка бер сүзгә тышкы яктан булган бәйләнеше ике төрле күренештә булырга мөмкин:

1) ияргән сүзләрнең нинди булса да кушымчалар белән төрләнеп әйтелүе рәвешендә. Бу яктан алар, әлбәттә, сүз төрләндерүче кушымчаларның берәрсе белән төрләнеп әйтелгән булырга тиешләр;

2) ияргән сүзләрнең нинди тәртиптә, кай урында әйтелүе белән. Бу яктан алар иярчен кисәкләр булу җәһәтеннән, әлбәттә, үзләре ияргән (ияртүче) сүзләрдән алда, алардан элек әйтелгән булырга тиешләр. Чөнки, югарыда телебезнең нәхви төзелеше хакында сөйләнгән әсаслар буенча, ияртүче сүз ияручегә караганда кирәклерәк булганга күрә, ахырдан әйтелгән булырга тиеш.

Иярчен кисәкләрне, җөмләнең кайсы кисәгенә бәйләнүләрен игътибарга алмыйча, нинди төркемнән булган сүзгә бәйләнүләренә карап, дүрт төркемгә аерырга туры килә:

1) фигыльгә бәйләнгән иярченнәр (тәмамлыклар); 2) исемгә бәйләнгән иярченнәр (аергычлар); 3) сыйфатка бәйләнгән иярченнәр (ачыклаулар); 4) ярдәмлеккә бәйләнгән иярченнәр (тәмамлыклар).

### 1. ТӘМАМЛЫКЛАР

Җөмлә эчендә нинди булса да бер тамыр яки нигез фигыльгә бәйләнеп әйтелгән иярчен сүзләр гомумән «тәмамлыклар» дип аталалар.

Тәмамлыкларның фигыльгә бәйләнешләре тышкы яктан ике төрдә була:

1) исем кушымчаларыннан 3 нче рәттәге килеш төрлекләре белән төрләнүдә, 2) тәртипләрендә, ягъни һәрвакыт фигыльдән алда әйтелүләре рәвешендә. Шуның өчен дә тәмамлыкларны кыскача «җөмлә эчендә фигыльләрдән алда килеп, аңа килеш төрлекләре белән бәйләнгән сүзләр» дип тәгъриф итәргә була. Тәмамлыклар нинди килеш төрлекләре белән төрләнгән, нинди төрдә әйтелгән булуларына карап, 8 төрле булалар:

1) **Чыгыш тәмамлыгы** – 3 нче рәттәге чыгыш килеше (дан, дән) белән төрләнеп әйтелгән исемнәр – бары да җөмләнең чыгыш тәмамлыгы булып йөриләр. Шушы төрлекләр ул исемне фигыльгә бәйлиләр. Мәсәлән: *Әхмәт урманнан кайтты; син безнең турыдан үтеп киттең; бөтен бәхетсезлекне үземнән күрәм; без азыкны көздән әзерләп куйдык: аңсыздан каршыбызга бер бүре килеп чикты; син моның метрын ничә тиеннән алдың? Ул һәрвакыт эшләпәдән йөри...* диган җөмләләрдә *дан-дән, нан-нән* төрлекләре белән төрләнгән сүзләр кебек.

2) **Юнәлеш тәмамлыгы**. Юнәлеш төрлекләре (*га-гә–ка-кә, на-нә...*) белән төрләнеп, фигыльгә бәйләнгән сүзләр юнәлеш тәмамлыгы булалар. Мәсәлән: *син бу каләмне миңа бир; ул минем каршыма килеп чыкты; иртәгә син кая барасың? Әхмәт көзгә калага укырга китә; бу китапны күпмегә саталар? Ул минем сүземә төшенмәгән икән; син нигә ишетмәгәнгә салышасың?* диган җөмләләрдәге *га, гә, а, ә, ңа* төрлекләре белән төрләнгән сүзләр кебек.

3) **Төшем тәмамлыгы**. 3 нче рәттәге төшем төрлекләре *(ны-не-н)* белән төрләнеп, фигыльгә бәйләнгән сүзләр җөмләдә төшем тәмамлыгы булалар. Мәсәлән: *син аны кайдан ишеттең? Белгән – белгәнен эшләр, белмәгән бармагын тешләр; бу китапны мин базардан алдым; каләмеңне миңа биреп тор әле; яшь чагыңда кемне сөйсәң, күңелең шуңарда була...* диган җөмләләрдә *ны-не-н* төрлекләре белән төрләнгән сүзләр кебек.

Искәрмә. Төшем тәмамлыгы, иядән сон әйтелгәндә, күп вакыт *ны-не* төрлекләре белән төрләнмичә, баш килештәге төрдә генә дә килә (ләкин төшем тәмамлыгы алмашлардан булганда, төшем төрлекләре белән төрләнми калмый), аның төшем тәмамлыгы икәнен хәбәр белән ярашмавына, иядән соң килүенә, хәтта кайвакыт фигыльнең янында ук әйтелүенә карап беләбез.

Мәсәлән: *мин сиңа бер табышмак әйтәм; без калада яшьләр газетасы чыгарабыз; театр уйныйбыз; мин дә газетага хәбәрләр язам: безгә мәктәптә ана теле укыталар; без болында җиләк җыйдык, карагат ашадык; безнең эт бер куян тотты...* диган җөмләләрдә *табышмак, газетасы, театр, хәбәрләр, теле, җиләк, карагат, куян* сүзләре төшем тәмамлыгы булалар. Боларның төшем тәмамлыгы икәнлеген белер өчен аларга *не-ны-н* төрлекләре кушып яки тәртибен алыштырып әйтеп карарга да мөмкин. Бу сүзләрнең тәртибен, урыннарын алыштырып әйткәндә *ны-не* төрлекләрен кушмасак, мәгънә бозылып китәргә тиеш. Мәсәлән: *куян эт тотты; табышмак мин сиңа әйтәм...* Бу вакыт мәгънә бозылмасын өчен, аларга

*ны* кушып әйтергә кирәк була: *куянны эт тотты; табышмакны мин сиңа әйтәм*... кебек. Әмма иянең урынын алыштырсаң да, аңа төрлек кушарга кирәк булмый (мәгънә ягыннан *ны-не* белән әйтелмәгән төшем тәмамлыгы билгесезлекне, *ны-не* белән әйтелгәне билгеле сүзне белдерә).

4) **Урын тәмамлыгы.** *Да-дә, та-тә* төрлекләре белән төрләнеп, вакыт-урын килешендә әйтелгән сүзләр җөмләдә күбрәк урын тәмамлыгы булалар.

Искәрмә. Бу килеш төрлеге булган *да-дә, та-тә* кисәкләрен өстәмә кушымчалардан булган *да-дә, та-тә* белән саташтырырга ярамый. Өстәмә кушымча төркемендәге *да-дә, та-тә*, бердән, бөтен сүзгә һәм фигыльләргә дә кушыла ала. Икенчедән, төп сүзнең басымын үзенә чыгармый. Килеш төрлеге булган *да-дә, та-тә* исә, исемнәргә, исем урынына торган сыйфатларга гына кушыла, басымны да үзенә үткәрә.

Мәсәлән: *быел май бәйрәмендә бик кызык булды; Октябрь революциясе 1917 елда, яңача 7 нче ноябрьда булды.*

*Күкрәгемдә минем шигырь утым саумы?*
*Күтәрәм мин, карт булсам да, авыр тауны:*
*Күңелемдә көн һаман аяз, һаман да яз,*
*Шагыйрь күңелендә кыш булмый да, кар яумый.* (Г. Тукай.)

*Туды. Ул туганда кеше иде; «бер, ике, өч» дигәндә, ярыш башланып китте; без, кояш батканда, шәһәргә килеп кердек; аның бөтен кимчелеге шул тырышмавында гына булды*... дигән җөмләләрдә, *да-дә, та-тә* төрлекләре белән төрләнгән сүзләр урын тәмамлыгы булалар.

5) **Рәвеш тәмамлыгы.** Җөмләдә рәвеш төрлекләре (*ча-чә*) белән төрләнеп әйтелгән яки *белән, өчен, саен, аша, аркылы*... кебек ярдәмлекләр кушып әйтелгән сүзләр, ясалма рәвешләр һәм рәвеш фигыльләре – бары да рәвеш тәмамлыгы булып йөриләр (рәвеш тәмамлыгы эчке яктан күбрәк ничек? дигән сорауга җавап булып әйтелгән була).

Шуның өстенә рәвеш тәмамлыгы гомумән фигыльнең янында гына, аның белән янәшә генә әйтелүчән. Төп рәвеш сүзләре, төп һәм ясалма сыйфатлар, ымлыклар һәм «чит сүзләр» фигыль алдыннан, аның белән янәшә килгәндә, рәвеш тәмамлыгы булып саналырга тиешләр. Мәсәлән: *мин русча сөйләшә беләм; ул эш теләгәнчә булып чыкмады; Галинең сүзенчә шулай булырга тиеш иде; коммунамда җирне трактор белән сөрәләр; Уфага Самара аша кайту уңайрак була; бу утын бик кызу яна икән; һәр эш баштарак шулай була инде; быел иген бик мул булыр, ахры; син шунда кузгалмый гына тор әле, мин хәзер килеп җитәрмен, аннары, бакчага бергәләп чыгарбыз; мин сиңа ул сүзне юри әйттем; без сабан туена ат белән килдек; Әхмәдиләр атсыз килгән; сәгать келт-келт итәдер, форсат кулдан китәдер; бүгенге җыелышта Әхмәдинең тәкъдиме бер тавыштан кабул ителде*... дигән җөмләләрдә фигыльләрдән алда әйтелгән сүзләр рәвеш тәмамлыгы булалар.

6) **Охшату тәмамлыгы.** Фигыльләрдән алда килеп, аңа өченче рәт исем төрлекләре булган охшату килешләре (*ди-нди, дай-дәй*...) белән яки

шулар рәтендә йөргән кебек, шикелле, сымак, төсле ярдәмлекләре белән бәйләнеп әйтелгән сүзләр охшату тәмамлыгы булалар. Мәсәлән: *азрак күргәндәй булыйм, ичмасам; оятымнан җиргә кергәндәй булдым; ул да миңа таудай күренә; корсагы каптай булды; аның күзләре ут шикелле яна; ул егет сымак йөри.*

7) **Вакыт тәмамлыгы.** Вакыт фигыльләре (*ганчы, миче, ышлый, гач, ганда, гәндә...*), гомумән вакыт сүзләре, вакыт ярдәмлекләре (*элек, соң, бирле, хәзер, инде, әле...*) белән тезелеп әйтелгән башка сүзләр җөмлә эчендәге фигыльнең вакыт тәмамлыгы булалар. Мәсәлән: *без былтыр бу вакытта уракка төшмәгән идек әле; мин хәзер килеп җитәрмен; син сәгать алтыда шунда бул; җыелыш беткәч, театрга бергәләп барырбыз; ул көздән бирле авырый иде; базарга барышлый, сезгә кереп чыктым* (эчке яктан вакыт тәмамлыклары «кайчан» дигән сорауга җавап булып килә).

8) **Сәбәп тәмамлыгы.** Фигыльләрдән алда килеп, аңа *ганга-гәнгә (күрә), гәнлектән-ганлыктан, кәненнән, ачагыннан, арга-әргә, (маска-мәскә)...* төрләре белән бәйләнгән фигыльләр, *өчен, сәбәпле* ярдәмлекләре белән әйтелгән сүзләр гомумән сәбәп тәмамлыгы булалар (мәгънәләре ягыннан сәбәп тәмамлыклары, *нигә? ни өчен?* дигән сорауга җавап булып килгән булалар). Мәсәлән: *көн болытлы булганга (күрә), без кичә уракка чыкмадык; алар үзара килешә алмаганлыктан, аерылырга мәҗбүр булдылар; Әхмәт бездә эшләргә кайтты; мин анда бармаска булган идем дә, синең өчен риза булдым.*

## Тәмамлыкларның тәртибе

Бер фигыльгә караган тәмамлыклар берничә булганда, алар фигыльнең алдыннан, үзләренең әһәмиятләренә, сөйләүче карашындагы дәрәҗәсенә карап, урын алалар: иң кирәкле булган тәмамлык фигыльнең янында, кирәксезрәкләре ул тәмамлыктан элегрәк килә бара. Бу тәртипкә җөмләнең иясе дә тәмамлыклар белән бертигез буйсына. Ия тәмамлыклардан алда да, аларның уртасында да, хәтта, мәгънә әһәмиятенә карап, фигыльнең янында гына да килергә мөмкин. Фигыль янында әйтелгән сүз, гадәттә, мантыйкый басым белән әйтелә.

Мәсәлән: *Казанда мин бу китапны Татгиздан 55 тиенгә сатып алдым (кирәкле сүз – 55 тиенгә).*

*Казанда мин Татгиздан 55 тиенгә менә бу китапны сатып алдым (кирәкле сүз – бу китапны).*

*Мин бу китапны Татгиздан 55 тиенгә Казанда сатып алдым (кирәкле сүз – Казанда).*

*Мин бу китапны Казанда 55 тиенгә Татгиздан сатып алдым (кирәкле сүз – Татгиздан).*

*Бу китапны Казанда Татгиздан 55 тиенгә мин сатып алдым (кирәкле сүз – мин).*

*Ләкин* ия һәм тәмамлыкларның шуннан башка, бер тәртибе дә юк

дип булмый. Аерым әһәмиятле сүзне игътибарга алмаганда, фигыльгә бәйләнгән бөтен сүзләр гадәттә күбрәк түбәндәге тәртиптә килүчән булалар:




Бер җөмлә эчендә тәмамлыкларның барысы да булуы лазим түгел. Аларның рәттән бер төрдәгеләре янәшә тезелеп килергә дә мөмкин. Бу бер яктан. Икенче яктан, тәмамлыклар үзләре фигыльдән ясалган булсалар, аларның үзенә караган тагы икенче һәм өченче рәт тәмамлыклары да булырга мөмкин.

Мәсәлән: *Байларда бу капитал – эшчеләргә тиешле хакын биреп бетермичә, алып кала-кала килеп жыелган була* дигән җөмләдәге рәвеш тәмамлыклары кебек.

**Фигыльләрнең нинди тәмамлык теләүләре**

Тәмамлыкларның фигыльләргә бәйләнешләре төбендә ул фигыльләрнең үзләре шул тәмамлыклар теләвеннән килә. Нинди фигыльләрнең нинди тәмамлыклар теләве һәр телнең үз табигатенә карап йөри. Бер телдә мәгълүм бер тәмамалыкны теләгән фигыль башка телдә тәмамлыкны теләмәскә мөмкин.

Мәсәлән, безнең телебездә *ал, бир* фигыльләре, гадәттә, төшем тәмамлыкларын телиләр. Шуңа күрә *без фәләнне ал, тегәнне бир* дип әйтәбез; рус телендә исә, бу фигыльләр күбрәк чыгыш тәмамлыгын (родит. пад.) телиләр. Шуңа күрә алар: *дай этого, возьми того* дип сөйлиләр. Бездә *башкара* дигән фигыль төшем тәмамлыгын тели (*нине башкара*); *үч ала* дигән фигыль чыгыш тәмамлыгын тели (кемнән үч ала). Моңа каршы русларда *управлять* дигән фигыль *ни белән* (чем?) соравын, *отомстить* дигән фигыль юнәлеш тәмамлыгын (кому?) тели. Фигыльләрнең нинди тәмамлык теләүләре аларның дәрәҗәлек (баб) кушымчалары белән төрләнешенә бәйле.

## 2. АЕРГЫЧЛАР

Җөмлә эчендә исемнәрдән алда әйтелеп, аңа һичбер төрлексез яки үзенә махсус төрлекләр белән бәйләнгән сүзләр «аергыч» дип атала. Аерылган исем «аерылмыш» дип йөртелә.

Аерылмыш исем җөмләнең иясе дә, фигыльгә бәйләнгән тәмамлыклары да булырга мөмкин.

Аергычларны, тышкы аерымлыкларына карап, ике төрлегә бүләргә туры килә:

1) сыйфатлык аергыч, 2) иялек аергыч.

**Сыйфатлык аергычлар** һичбер төрлекләр белән төрләнмичә исемнәрдән алда килеп, аларга бәйләнеп әйтелгән сүзләр, тамыр сыйфатлар, уртак фигыльләр, хәтта исемнәр, үзеннән соңгы исемгә бәйләнеп әйтелгән чагында, бары да сыйфатлык аергыч булалар. Аергыч белән аерылмышның санда бер-берсенә ярашулары лазим түгел.

Мәсәлән: тамыр сыйфатлардан: *кызыл каләм, ал байрак, яшел үлән, ерак юл...*;

ясалма сыйфатлардан: *тимерче Гали, киләсе кеше, бишәр кеше, беренче группа, тимерле арба, бәхетсез егет*;

исем фигыльләрдән: *үтмәс товар, пешмәгән ит, янар тау, киләчәк заман, табылдык мал*;

саннардан: *бер кеше, биш ат, алты сабан*;

алмашлардан: *бу китап.., шушы сүз, теге бала, һәр кеше, нинди эш, ничә сүз, бер көнне, бер-бер кеше, бүтән әйбер...*

исемнәрдән: *тимер каләм, агач йорт, таш йөрәк, алтын йөзек, бер табак ит, ике кап шырпы, ун баш мал, пыяла күз, кыл муен, чиләк карын*[1].

Ясалма сыйфатларның ясаучы кушымчаларына сыйфатлык аергычның төрлекләре кебек карарга мөмкин. Сыйфатлык аергычлар, югарыда әйтелгәнчә, сүз төрләндерүче кушымчалар белән төрләнмиләр, ләкин аерылмыш исемнәре әйтелми калып, аның урынына шушы сыйфат аергычы гына әйтелгәндә, бу аергычлар үзләренең ахырына исем төрлекләрен дә кабул итәләр.

### Сыйфатлык аергычларның тәртибе

Бер исемгә бәйләнеп әйтелгән сыйфатлык аергычларның берничәсе рәттән килергә дә мөмкин. Бу вакыт аларның сөйләүче карашында кирәклерәк булып танылганы исемнең янындарак, калганнары аннан элегрәк әйтелергә тиеш була.

Мәсәлән: *зур таш йорт*;

[1] Янәшә ике исем аергычлы булганда, беренчесе басым белән әйтелә. Ия, хәбәр булсалар, ике арада пауза белән әйтелә; кушма яки тагылмалы сүз булсалар, бер сүз кебек берьюлы, бер басым белән әйтеләләр. – *Автор.*

*биек ике катлы таш йорт,*
*ике катлы биек сары таш йорт,*
*ике катлы зур сары йорт,*
*бу сары ике катлы биек йорт...*

Бу аергычларның кайсын элек, кайсын соң әйтү хакында ныклы бер тәртип күрсәтү кыен. Аның әһәмияте мәгънәви. Күп вакыт сөйләүченең үз теләгенә, үз тәсаувырына карап йөри. Ләкин, һәрхәлдә, үз телен яхшы белгән кешегә аларның тәртибе дөрес әйтелмәгәне бик ачык сизелүчән була.

Сыйфатлык аергычлар исемнәрдән булганда, аларның үзенә тагын икенче рәт аергычлары да килергә мөмкин: *озын мыеклы кеше, зур башлы егет, кызыл галстуклы бала, кыска җиңле камзул, хәтфә тышлы бүрек, артык батыр кеше...* дигәндәге *озын, зур, кызыл, артык* сыйфатлары аергычка аергыч булып килгәннәр.

Искәрмә. Сыйфатлык аергычлар, гадәттәгегә каршы, кайвакыт аерылмыш исемнең соңыннан да килергә мөмкин: *Гали иптәш, Мәҗит агай, Салсал батыр..., Әхмәт бай, Риза казый...* кебек. Ләкин тышкы яктан без һаман да аларның элек әйтелгәннәрен аергычлар, соңгыларын аерылмышлар дип карый алабыз. Тышкы яктан аларның исемнәр рәтеннән төрләнеп йөрүләре булса, безгә шул житә. Аларга эчке яктан да аерылмыш дип карарга юл бар:

*Әхмәт байның малы күп булган; Колчак явыздан котылдык; Гата иптәшне очратмадыңмы? Салих туганны күрә алмадым...* кебек.

**Иялек аергычы.** Исемнәрнең икенче рәт япсару төрлекләре (*ым-ем-м, ың-ең-ң, ы-е, сы-се, ыбыз-ыгыз...*) белән төрләнгән калыбына бәйләнеп, аннан элгәре иялек килешендә әйтелгән исемнәр иялек аергычы булалар. Иялек килешендәге сүзләрнең тәмамлыктан саналмавы, аның фигыльләргә бәйләмичә, исемнәргә бәйләнеп әйтелүеннән генә. Юкса, бөтен аергычларга да тәмамлыклар дип карарга мөмкин.

Мәсәлән: *минем китабым, безнең китабыбыз, синең атың, сезнең атыгыз, аның сүзе, аларның бәйләнүе; биргәннең битенә бакма, сыйлаганның суын эч, дөнья күрмәгәнлекнең бәласе...* дигәндә *минем, безнең, биргәннең* сүзләре кебек.

Иялек аергычы да гомуми әсаска мовафыйк рәвештә һәрвакыт аерылмыш исемнән элек әйтелә. Аерылмыш әйтелми калган чагында аның урынына калып, исем төрлекләре, хәбәрлек төрлекләре белән дә төрләнә ала. Бу вакыт иялек аергычының ның-нең кисәге *гы-ге* белән кушылып, *нықы-неке* булып әйтелә.

Мәсәлән: *бу – минеке; сезнекеләр генә шәп; син анда безнекеләргә очрамадыңмы? Садыйкныкылар уракка китте; теге ат Әхмәтләрнеке...* кебек. Кайвакыт аерылмыш, аергычтан башка, үзе генә килә: *берсе күренмиме, башкасы юк, барсы шул, беразы югалды...*

Искәрмә. Кайвакыт аерылмыш сүзләр, иялек аергычы белән килгәндә, 2 нче рәт япсару төрлекләре белән төрләнми әйтеләләр.

Мәсәлән: *Безнең ат югалды* (безнең атыбыз...); *тау башына салынгандыр безнең авыл* (Г. Тукай); *синең бүрек бик шәп икән, малай!*

Күп вакыт иялек аергычлары үзләре дә ның–нең белән төрләнмичә генә әйтеләләр (бу вакыт аларны сыйфатлык аергычлар дип карарга да була). Мәсәлән: *алма агачы, халык теле, Совет хөкүмәте, Идел елгасы, Урал тавы, Казан шәһәре, авыл хәбәрчесе, партия члены, эшчеләр партиясе, китап тышы...*

*Ләкин* алмашлар, иялек аергычы булып килгәндә, һәрвакыт *ның-нең* белән төрләнеп кенә әйтелергә тиешләр: *моның сүзе, синең улың, безнең авыл...* кебек. Мәгънә ягыннан *ның-нең* белән төрләнмәгән иялек аергычы билгесез аергыч булып, теләсә ниндилек, уртаклык мәгънәсен аңлата, *ның-нең* белән төрләнеп әйтелгән аергычлар, аерым билгеле бер мәгънәне генә аңлаткан өчен, билгеле аергыч булалар.

Мәсәлән: *китап тышы* (теләсә нинди китап) –
*китапның тышы* (мәгълүм бер китапның тышы);
*баланың уенчыгы кайда?* (мәгълүм бала турында) –
*бала уенчыгын кайда саталар?* (гомумән балалар);
*татар бишмәте шундый була* (гомумән татар) –
*теге татарның бишмәте ич бу* (мәгълүм бер татар).

Бер аерылмыш сүзгә сыйфатлык, иялек аергычлары бары да бергә янәшә килергә дә мөмкин. Бу вакыт сыйфатлык аергычы аерылмышның янында, иялек аергычы аңардан элек әйтелергә тиеш була. Чөнки, бердән, иялек аергычының бу исемгә бәйләнеше тәртип белән генә түгел, бәлки *ның-нең* төре белән дә күрсәтелгән, икенчедән, ул башка аергычларга караганда әһәмиятсезрәк урынны тота (әйберләрнең нинди булуы кемнеке булуыннан алдарак кирәкле). Мәсәлән: *безнең аюдай таза атыбыз бар; Галинең элгәреге кечкенә фатиры...*

Бер иялек аергычының үзенә тагын берничә рәткә кадәр иялек аергычлары килүе дә мөмкин. Бу вакыт аларның *ның-нең* төрлекләре гадәттә төшерелеп яки башкача сыйфат кушымчаларына үзгәртеп әйтелергә тиеш була.

Мәсәлән: *Безнең Казан пионерларының отряд башлыкларының тырышлыгы* («безнең Казанның пионерларының отрядының башлыкларының тырышлыгы» дигән сүздән);

*РСФСР*(ның) *Мәгариф Халык Комиссариаты*(ның) *янындагы азчылык милләтләр*(нең) *мәгарифе*(нең) *советының төрек халыклары*(ның) *бүлегенең катнашы белән...* (Москва нәшриятыннан).

## 3. АЧЫКЛАУЛАР

Җөмләдә сыйфатларга бәйләнеп әйтелгән иярчен кисәкләрне ачыклаулар дип атарга мөмкин. Алар бездә өч төрле була:

1) чагыштыру, 2) охшату, 3) артыклык. Сыйфатларның алдыннан аларга чыгыш килеше (*дан-дән...*) белән бәйләнеп әйтелгән сүзләр чагыштыру

ачыклавы булалар. Бу вакытта ачыкланган сыйфатлар ачыклауга бәйләнеп, күбрәк *рак-рәк* кушымчалары белән төрләнеп әйтеләләр. Төрләнмәүләре дә мөмкин. Мәсәлән:

*ул миннән олырак; мин Гарифтан тазаракмын, безнең бүлмә бу өйдән зуррак булыр; аның йөрәге таштан катырак; вакыт кичәгедән иртәрәк әле...* кебек.

Сыйфатларның алдыннан аларга охшату килеше яки охшату ярдәмлекләре белән бәйләнеп әйтелгән сүзләр охшату ачыклавы булалар: *аюдай таза бер кеше; андый авыр нәрсәне күтәрергә ярамый; таштай каты, боздай салкын; ул синең кебек ялкау түгел шул.*

Сыйфатларның алдыннан, һичбер төрле кушымчалар белән төрләнмичә, аңа тәртип белән генә бәйләнеп әйтелгән сүзләр артыклык ачыклавы булалар (болар күбрәк ярдәмлек сүзләре була). Артыклык ачыклаулары шул ук сыйфатларның үзләрен кабатлап әйтү төрендә дә килергә мөмкин. Мәсәлән:

*бик озын кеше; артык усал малай; үтә кызыл тиз уңар; дөм сукыр бер карт тора; иң яхшы эш шул булыр; күп-күп кабып ашый; озын-озын Рамазан агай; вак-вак кына басып йөри; япа-ялгыз калдым; ишекне шар ачык калдырган.*

## 4. ЯРДӘМЛЕКЛӘРГӘ БӘЙЛӘНГӘН ИЯРЧЕННӘР

Ярдәмлекләр үзләре генә җөмләнең махсус бер кисәге була алмыйлар. Бәлки башка сүзләрне бер-беренә бәйләүгә, аларның мөнәсәбәтләрен билгеләүгә хезмәт итәләр. Бу яктан аларны төрлекләргә охшатырга мөмкин. Алар, башкаручы сүз белән бәйләнүче сүзнең ике арасында торып, ике арадагы мөнәсәбәткә васиталык[1] итәләр. Бу вакыт ярдәмлекләрнең кайберләре үзләреннән алда килгән сүзнең берәр төрле төрлекләр белән төрләнеп, үзләренә бәйләнүен телиләр. Безнең телебездә, үзләренә бәйләнеп әйтелгән иярчен сүз теләүче ярдәмлекләр өч төрле:

1) чыгыш килешен теләүчеләр: *соң, элек, ары, бире, башка, тыш, бүтән, үзгә..* кебек ярдәмлекләр. Болар үзләреннән алда килгән исемнәрнең чыгыш төрлекләре (*дан-дән...*) белән төрләнеп, үзләренә бәйләнеп әйтелүләрен телиләр; *килгәннән соң; аннан элек, былтырдан бирле, бездән бүтән, программадан тыш, аңардан башка...* кебек (бу соңгысын *га-гә* башка... төрендә куллану дөрес түгел);

2) юнәлеш килешен теләүчеләр: *таба, чаклы, күрә, каршы...* кебек ярдәмлекләр. Болар үзләреннән алда килгән исемнәрнең, юнәлеш төрлекләре (*га-гә, ка-кә, на-нә...*) белән төрләнеп, үзләренә бәйләнеп әйтелүләрен телиләр: *авылга таба йөз белән; көзгә чаклы, белмәгәнгә күрә, дошманга каршы; шәһәргә хәтле; чиләгенә күрә капкачы...* кебек;

[1] Васиталык – арадашлык.

3) иялек килешен теләүчеләр: *белән, өчен, саен, аша, кебек, шикелле, аркылы, сымак...* ярдәмлекләре. Болар үзләреннән алда килгән алмашларның иялек төрлеге (*ның-нең*) белән төрләнеп әйтелүен телиләр (алмашлардан башка исемнәр белән бәйләнешләре кушымчасыз, тәртип белән генә беленә): *минем белән, синең белән, сезнең өчен, аның саен, безнең кебек..., атна саен, тормыш өчен, аю кебек, шуның тикле, егет сымак, почта аркылы...* кебек.

## 5. ИЯРЧЕННӘРНЕҢ РӘТЛӘРЕ

Инде, җөмләнең кайсы кисәгенә бәйләнеп әйтелүләренә карап, иярченнәрне берничә рәтләргә аерырга мөмкин.

**Беренче рәт иярченнәр.** Болары – турыдан-туры җөмләнең баш кисәкләренә – ия белән хәбәргә бәйләнеп әйтелгән сүзләр. Болар тәмамлыклар да, аергычлар да булырга мөмкин.

Мәсәлән: *кызыл гаскәрләр Советлар илен явыз байлардан тазартты.*

**Икенче рәт иярченнәр** – җөмләнең беренче рәт иярченнәре булган тәмамлыкларга, яки аергычларга бәйләнеп әйтелгән сүзләр. Болар да, үзләре бәйләнгән сүзнең кайсы төркемнән булуына карап, тәмамлыклар да, аергычлар да була алалар. Аларның тагы үзләренә караган 3 нче, хәтта 4 нче рәт иярченнәре дә булырга мөмкин.

Иярчен кисәкләр ничә рәт булсалар да, югарыда әйтелгәнчә, бәйләнешләре тышкы төрләрнең берсе белән, күрсәтелгән булырга тиеш. Бу яктан алар кайсы рәттән булсалар да, бертөсле үк тышкы төрләр белән бәйләнешәләр.

**Җәенке җөмләнең төзелеш схемасы**




(Бу схемада уклар белән җөмлә кисәкләренең кайсы тәртиптә әйтелүләре күрсәтелде.)

Мәсәлән:

«Коммунистлар партиясе Ленин иптәшнең юлбашчылыгы белән җир шарының алтыдан бер өлешен капитализм коллыгыннан азат итте».

(Бу мисалда иярчен кисәкләрнең ничәнче рәттән икәнлеге сүзләрнең астына сызылган сызыклар белән күрсәтелде. Сызылмаган сүзләр – җөмләнең баш кисәкләре.)

Яки, икенче бер мисал алып, баскычлап тезеп күрсәтик:

| | |
|---|---|
| 4 | бик |
| 3 | Ана безнең кебек зур |
| 2 | теленең өйрәнчек көч |
| 1 | грамматикасын телчеләрдән түгүне |
| | төзү сорый |

(Бу мисалда җөмләнең баш кисәкләре аскы юлда, иярчен кисәкләр үз рәтләре белән өске юлларда күрсәтелде.)

## Эндәш һәм кереш сүзләр

Җөмлә эчендә ни берәр кушымча яки ярдәмлек белән, ни бер тәртип белән үзеннән соңгы сүзгә бәйләнмичә, аерымрак бер тавыш белән әйтелгән сүзләр дә булгаларга мөмкин. Боларның башка сүзләргә һичбер төрле бәйләнеше булмаганга күрә, җөмлә кисәге булып саналырга хаклары да юк. Алар бөтенләй чит, аерым сүзләр һәм аларны ташлаганда да җөмләнең тулылыгына һичбер кимчелек килми. Аларны иярчен кисәк дип йөртү дөрес түгел.

Мондый сүзләрне нинди тавыш белән әйтелүләренә карап: 1) эндәш сүзләр, 2) кереш сүзләр дигән ике төргә бүләргә мөмкин.

Эндәшләр – тавышны күтәреп, бер кешегә я бер әйбергә эндәшеп әйтелгән сүзләр. Мәсәлән:

*Яз, газиз улым, кара тактаны сыз акбур белән (Г.Тукай). Ай! Син мине үзеңә ал. Син юкка кайгырма, дускаем. Мин сине, сөеклем, мәңгегә ташламам.*

Кереш сүзләр – тавышны гадәттән тыш төшереп, сүз арасында, читкә карап әйткән шикелле, тиз генә әйтелеп калынган сүзләр. Мәсәлән:

*Сәфәр Гали агайның борыны, ташка үлчим, менә шундый булып шешкән. Ул заманнарда, хәтереңдәме, нинди авыр шартларда яши идек...*

Чит сүзләр. Язучы тарафыннан бер дә үзгәртелмичә алынган башка бер кешенең сүзләре «чит сүзләр» дип атала. Мәсәлән: *«Менә Казанга килеп җиттек» – дип, кучер атларны туктатты. Карл Маркс: «Европада коммунизм шәүләсе йөри», – дигән.*

Кереш сүзләр, чит сүзләр, аерым ялгыз сүзләр булган кебек, бөтен җөмләләр дә булырга мөмкин.

## Җөмлә төрләре

Җөмләләрне эчке мәгънәләренә карап та, тышкы күренешләренә карап та бик күп төрләргә аергаларга була. Без монда мөмкин кадәр аларның тышкы күренешләрендә булган аерымлыкларына карап эш итәргә тырышабыз.

Җөмләләрдә тышкы як, аларның нинди кисәкләрдән, ничек төзелешләренә һәм бу кисәкләрнең бер-беренә бәйләнеш-аерылышлары нинди кушымча, нинди ярдәмлекләр белән күрсәтелүләренә һәм нинди тыныш, нинди аһәң белән әйтелүләренә карап, билгеләнергә мөмкин.

Менә шул яклардан карап, җөмләләрне иң элгәре «гади, оешма, кушма» дигән өч зур төркемгә бүләргә туры килә.

### Гади җөмләләр

Бер-беренә бәйләнгән бер төрдәге кисәкләре берәр генә булган аерым җөмләләр «гади җөмлә» булалар. Мәсәлән: *нурлы кояш болытлар арасыннан ялтырап чыкты. Коммунистлар партиясе бөтен эшчеләрне капитал коллыгыннан азат итәргә тырыша. Яшәсен Бөек Октябрь революциясе! Син коммунистлар партиясенең тарихын укыганың бармы?*

Менә бу җөмләләрнең һәрберендә ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч һәм бу соңгыларының бер төре берәр генә килгәннәр. Шуна күрә болар гади җөмлә булалар.

(Безнең югарыда тикшереп үткән җөмләләребез бары да шушы гади җөмләләр иде.)

### Оешма җөмләләр

Оешма җөмләләрнең гади җөмләләрдән артык зур аермасы юк дияргә ярый. Тик монда җөмлә эчендәге бер сүзгә бәйләнеп әйтелгән кисәкләрнең бер төрдә, бер исемдә булганнары берәр генә булмыйча, берничәсе янәшә килгән була. Бу бер төрдәге янәшә кисәкләр бер хәбәргә бәйләнгән берничә ия, яки бер иягә ярашып әйтелгән, аңа бәйләнгән берничә хәбәр булырга, яки бер фигыльгә бәйләнгән бер үк төрдәге тәмамлыклар, бер үк исемгә бәйләнгән бертөрле аергычлар булырга да мөмкин.

Мәсәлән: *капиталистлар, алпавытлар совет хөкүмәтен җимерергә тырыштылар, алар ул явыз теләкләренә ирешә алмадылар, җиңелделәр.*

*Аның йөрәге бөтен эшчеләргә, бөтен изелгән халыкларга, кайнар мәхәббәт белән тибә иде* (Ленин турында Крупская сүзе).

Менә бу җөмләләрнең баштагысында тырыштылар хәбәренә бәйләнгән ияләр *капиталистлар, алпавытлар* дигән ике сүздән килгән, икенчесендә *алар* дигән иягә бәйләнгән хәбәрләр икәү әйтелгән. Крупская сүзендә *мәхәббәт* сүзенә бәйләнгән юнәлеш тәмамлыклары (эшчеләргә, халыкларга) икәү әйтелгән.

Бу җөмлә эчендәге шушындый бер сүзгә бәйләнгән, бер төрдә һәм бер исемдәге берничә кисекләр «тиң кисәкләр» дип атала. Җөмлә эчендә бер сүзгә бәйләнмәгән кисәкләр, бер исемдә булса да, шулай ук бер сүзгә бәйләнеп тә башка исемдә, башка төрдә әйтелгән сүзләр «тиң кисәкләр»дән санала алмыйлар.

Мәсәлән: *кичә иртән мин сезгә барырга булган идем* дигән җөмләдә вакыт һәм юнәлеш тәмамлыклары икешәр килгән булса да, югарыгы шартлар табылмаганга, «тиң кисәкләр» булмыйлар. Чөнки *иртән* сүзе *кичә* гә тиң түгел, аның тәфсыйле-төбәве булып әйтелгән; *барырга* сүзе *булган* фигыленә бәйләнсә, *сезгә* сүзе *барырга* сүзенә бәйләнгән; шуңа күрә бу җөмлә гади җөмлә генә була.

Әгәр дә без *кичә, бәйрәм көн мин сезгә, үзегезгә бардым* дисәк, мондагы вакыт һәм юнәлеш тәмамлыклары бер-беренә тиң булалар. Шуңа күрә бу җөмлә «оешма җөмлә» булып чыга.

Оешма җөмләләрнең тиң кисәкләре үзара нинди тәртиптә, кайсы элек, кайсы соң әйтелсә дә, җөмләнең төзелеше, мәгънәсе бозылмый. Гади җөмләдә исә, бер исемдәге кисәкләрнең урыннарын алмаштырып әйтү дөрес булып чыкмый.

Тиң кисәкләрнең үзенә бәйләнгән иярченнәре булмаганда, алар янәшә әйтеләләр. Тиң кисәкләрне без, тышкы төрдә охшашлыкларыннан башка, тагы нинди аһәң, нинди тыныш белән әйтелүләренә карап та, белә алабыз. Алар икәве, өчәве бертөсле аһәң белән үзара бер-береннән, санап биргәндәге кебек, кечкенә бер тыныш (пауза) белән аерып әйтеләләр.

Шулай ук бер сүзгә бәйләнеп әйтелгән кисәкләре мәгънәне көчәйтү өчен кабатлап әйтелгән җөмләләрне дә тышкы яктан оешма җөмлә дип санарга кирәк була. Мәсәлән: *урманда йөрдем, йөрдем, бернәрсә дә таба алмадым җөмләсе кебек.*

### *Оешма җөмлә ярдәмлекләре*

Оешма җөмләләрдә тиң кисәкләрнең бер-беренә мөнәсәбәтләре кушымчалар яки ярдәмлекләр, хәтта аерым сүзләр белән дә күрсәтелергә мөмкин.

Күп вакыт тиң кисәкләрнең ике арасында *дә-да–тә-та, һәм, янә, тагы, белән, тагы да, әллә, ләкин, әмма, тик, фәкать, мәгәр, яки, я, шулай да, ягъни, хәтта, бигрәк тә, яисә, янәсе* кебек, кушучы, аеручы, бүлүче ярдәмлекләр киләләр:

Мәсәлән: *эшче һәм крестьяннар хөкүмәте яши.*

*Алар сине дә, мине дә якын күрәләр.*

*Ул аңламады, әллә ишетмәде инде.*

*Без җиңәргә я үләргә тиеш.*

*Теге үзен бик эре тота, янәсе, зур кеше була.*

Кайвакыт тиң кисәкләрнең бер-беренә мөнәсәбәте ике яктан да

ярдәмлекләр белән күрсәтелергә мөмкин. Мәсәлән: *моны алдың ни, алмадың ни – барыбер; иртәгә яңгыр я явар, я юк; Октябрьның әһәмиятен эшчеләр генә түгел, хәтта крестьяннар да бик яхшы төшенәләр; элгәре Гали, аннары Вәли килеп керде; ул мәҗлестә Вәлидән башка тагы бер кеше бар иде...* җөмләләрендәге *ни – ни, я – я, генә түгел, хәтта, элгәре, аннары, дан башка, тагы* сүзләре кебек.

Оешма җөмлә түбәндә берничә җөмләдән гыйбарәт булып, аларның бертөсле уртак сүзләрен ташлап, берничәсен бергә оештырып, бер җөмлә итеп төзелгән була. Мәсәлән: *эшчеләр хөкүмәтне үз кулларына алдылар, крестьяннар хөкүмәтне үз кулларына алдылар* дигән ике җөмләнең уртак сүзләрен кабатламыйча, бергә кушып әйтсәк *эшчеләр, крестьяннар хөкүмәтне үз кулларына алдылар* дигән бер оешма җөмлә килеп чыга.

## Кушма җөмләләр

Кушма җөмлә дип, нинди булса да тышкы бер күренеш белән бер-беренә бәйләнгән, бергә кушыбрак әйтелгән, аерым ияле, аерым хәбәрле берничә җөмләдән төзелгән сүз тезмәләренә әйтәләр.

Кушма җөмләләр күбрәк вакыт ике җөмләдән кушып төзелгән булалар. Сирәгрәк аларның бер-беренә бәйләнешкән күп җөмләләрдән гыйбарәт булуы да мөмкин.

Кушма җөмләләрнең бер-беренә ияреш, бәйләнешләре сүз төрләндерүче кушымчалар, ярдәмлекләр, алмашлар белән һәм аһәң, тыныш белән күрсәтелә.

Бу тышкы билгеләрнең югалуы я үзгәрүе белән кушма җөмләләрдән үзенә аерым, тулы берничә гади җөмләләр ясала ала. Кушма җөмләләрнең үз эчендәге төзелешләре, кисәкләренең тәртибе гади җөмләдәге кебек була.

Кушма җөмләләр, шушы тышкы билгеләренә карап, өч төрле булалар:

1) иартүле кушма җөмләләр,
2) бәйләнүле кушма жөмләләр,
3) тезмәле кушма җөмләләр.

## Ияртүле кушма җөмләләр

Ияртүле кушма җөмләләрнең берсе «баш җөмлә», берсе шул баш җөмләнең берәр кисәгенә тәмамлык булып бәйләнгән «иярчен җөмлә» була. Ияртүле кушмаларда баш җөмлә, һичбер үзгәрмәстән, шул көенчә аерым бер бөтен гади җөмлә була ала. Иярчен җөмләне дә, баш җөмләгә кушучы төрлекләрен үзгәртү, ярдәмлекләрен төшерү юлы белән, үзенә аерым ияле, хәбәрле гади җөмләгә әйләндерергә мөмкин була.

Иярчен җөмлә баш җөмләнең хәбәренә (яки аның эчендә – башка бер

фигыльгә) тәмамлык булып килгәнлектән, азагыннан килеш төрлекләренең берсе белән төрләнеп әйтелгән була.

Исем фигыльләргә кушылып килгән килеш төрлекләре, ияртүче ярдәмлекләр, шарт, вакыт, рәвеш фигыльләре тәмамлык булган иярчен җөмләне баш җөмләгә ялгаучы тышкы төрләр булып хезмәт итәләр.

Шуның белән бергә без иярчен җөмләләрне аларның урыннарына, тәртипләренә һәм нинди аһәң, нинди тыныш белән әйтелүләренә карап та аера алабыз.

Тәртип ягыннан иярчен җөмләләр, гади җөмләнең бер кисәге кебек, югарыда сөйләнеп үткән нигезләр буенча, баш җөмләдән элгәре килгән була, чөнки ул баш җөмләгә ярдәмче бер урынны гына тота. Аның тарафыннан башкарыла.

Иярчен җөмләләр, кереш сүзләр кебек, тизрәк һәм тавышны күтәребрәк әйтелә. Баш җөмлә исә тавышны төшереп, тынычрак һәм бер нәтиҗә чыгарган тавыш белән әйтелә.

Иярчен җөмләләрне, нинди төр белән баш җөмләгә ияртелүләренә карап, берничә исемнәр белән аерырга мөмкин:

**Шарт җөмлә** – моның тышкы төре – хәбәренең шарт фигыле булуында яки мәгънәсендә шуңа охшаган *кирәк, сын-сен, сын гына..., а-ә икән* кебек, төрләр белән күрсәтелгән фигыльләр булуында. Мәсәлән: *ни чәчсәң, шуны урырсың; Җиһанша үзе бай булса да, тормышы начар; килеп кенә карасын, бирермен мин кирәген; кирәк бөтен дөньяны су бассын, анда да ул кайгырмас; әгәр үзем исән булсам, мин аларга кушып та тормас идем; әгәр тырыша икән, булдырыр...*

**Вакыт җөмлә** – хәбәрләре вакыт фигыле булган һәм баш җөмләнең фигыленә вакыт тәмамлыгы булып ияргән җөмләләр. Моның тышкы төрләре *ганчы-гәнче, гангача, гәнгә чаклы, ышлый-ешли, ганда-гәндә, гач-гәч, мыйчы-миче, ган-гән саен..* кебек төрләрдән гыйбарәт була. Мәсәлән: *мин шәһәргә кергәндә, кояш чыккан иде; әрләләр әрләнеп торганчы, әрсезләр ашап туя; алар килеп керү белән, эшләр төзәлеп китте; буржуйларны куып җибәргәч, дөнья тынычланып китте; миннән хәбәр булмыйча, урыныңнан кузгалма; син әйткән саен, ул тискәреләнә генә.*

**Сәбәп җөмлә** – баш җөмләнең фигыленә сәбәп тәмамлыклары булып ияргән, *гәнлектән-ганлыктан, ганга-гәнгә күрә, кән өчен, ган сәбәпле, сен өчен...* кебек төрләр белән күрсәтелгән иярчен җөмләләр. Мәсәлән:

*Каты суык агачларның дымнарын кысып чыгарганлыктан, бөтен үсемлекләрне мамык кебек ап-ак бәс чолгап алган иде. Мин сине бик күрәсем килгәнгә күрә, ерак җирләрне якын итеп килдем; социализм төзер өчен, илебездә шартлар җитәрлек табыла.*

**Рәвеш җөмлә** – баш җөмләнең фигыленә *ып-еп-п; мыйча-мичә, а-ә, мый-ми, ча-чә, ый-и ...* төрләре белән рәвеш тәмамлыгы булып бәйләнгән иярчен җөмләләр.

Мәсәлән:

*Чүбек чәйнәп, май чыкмас; җәй көне кымыз эчеп, бераз хәл җыеп кайттым; ул безнең кайда торганны белмичә, эзләп йөргән; кызыл гаскәр дошман позициясен ала-ала, бер туктаусыз алга бара; гомер буе байга эшләп, бөкресе чыккан;*

*Ленин иптәш әйткәнчә, партиядә бердәмлек булырга тиеш.*

**Ошату җөмләсе** – *кән кебек, гандай, гән сымак, ган шикелле...* кебек төрләр белән баш җөмләгә охшату тәмамлыгы булып килгән иярчен җөмлә.

Мәсәлән: *өстәге кием тузган кебек, яшь гомер дә бик тиз уза; Әхмәт әйткәндәй, син бик чәпчемә әле; туйган үрдәк шикелле, ава-түнә басып йөри...*

**Чит җөмлә** – берәүнең сүзен үзгәртми күчереп әйтелгән һәм баш җөмләнең фигыленә төшем тәмамлыгы булып килгән иярчен тулы җөмлә. Мәсәлән:

*Берәү бер кешедән: «Чыршы Габди кайсы авылныкы була?» – дип сорады. Ул миңа: «Хәзер барып җитәрмен», – дигән иде. Ленин иптәш: «Эшче – крестьян элемтәсен өзмәгез», – дип әйткән.*

*Сандугач сайрый чут-чут итеп,*  
*«Кунар җирем юк, юк» – дип;*  
*Сандугач, сайрый, мин елыймын:*  
*«Син, җанкаем, юк, юк» – дип.*

Кайвакыт баш җөмләгә бәйләнгән иярчен җөмләләрнең үзенә караган тагы икенче дәрәҗәдәге иярчен җөмләләр һәм бу соңгы җөмләгә ияргән тагы өченче дәрәҗәдә иярчен җөмләләр булырга мөмкин. Бу вакыт үзенә караган җөмләләргә нисбәтән иярчен җөмләләр дә баш җөмләләр итеп саналалар.

Мәсәлән: *Россиядә Февраль революциясе булып, эшчеләргә үз сафларын ныгытып алырга юл ачылгач, Октябрь революциясе ясалды.*

### Бәйләнүле кушма җөмләләр

Бәйләнүле кушма җөмләләрнең бер-беренә кушылуы баш җөмләгә тәмамлык булып килү рәвешендә түгел, бәлки янәшә әйтелгән тулы җөмләләрнең берсендә яки икәвендә дә бер-беренә бәйләнешне күрсәткән махсус ярдәмлекләр, алмашлыклар кулланылуы рәвешендә була. Бәйләнүле җөмләләрнең кушмамы, яки аерым җөмләме икәнлеген без шушы ярдәмлекләргә карап беләбез: ике я өч җөмләне бергә бәйли торган бу ярдәмлекләр төшеп калу белән, һичбер үзгәрмәстән, болар үзенә аерым тулы гади җөмлә булып китә алалар. Бәйләнүле кушма җөмләләрнең берсе баш, берсе иярчен булып аерылмый. (Шуның белән бергә, саф үз телебезнең табигатенчә төзелгән бәйләнүле кушма җөмләләрнең дә азакларын баш җөмлә, алгәреләрен иярчен җөмлә дип карарга мөмкинлек

бар. Ләкин бу төрле җөмләләрнең тәртибендә, төзелешендә рус, фарсы теле тәэсире көчле булганлыктан, һәрвакыт баш җөмләләр азакта килә дип өзеп әйтеп булмый.)

Бәйләнүле кушма җөмләләрне үз эчендә тагы әллә ничә исемнәргә бүлеп йөртергә хаҗәт юк.

Җөмләләрнең бер-беренә бәйләнешен ике яктан да кара-каршы күрсәтә торган ярдәмлек һәм алмашлыкларның мәшһүрләре менә шулар:

| беренче җөмләдә | икенче җөмләдә | беренче җөмләдә | икенче җөмләдә |
|---|---|---|---|
| *да, дә* | *да, дә* | *кем, ни, нәрсә–* | *шул, шул нәрсә* |
| *я* | *я* | *нинди –* | *шундый, шундый ук* |
| *ни* | *ни* | *ничек –* | *шулай, шунынча* |
| *мы–ме* | *яки* | *кайчан –* | *шул чакта, шунда* |
| *мы–ме* | *әллә* | *кайсы –* | *шунысы, шушы* |
| *түгел* | *бәлки...*<br>*да* | *кая* | *шуңа, аңа...* |
| *гына түгел* | *хәтта...* | *кайда –* | *шунда, анда* |
| *саң ни, сәң ни* | *дә* | *күпме, ничә –* | *шул чаклы, һаман да* |
| | *барыбер,* | *ничаклы –* | *шул кадәр, шунча* |
| | *шулай да* | *нигә, ни дип –* | *шуңа, шуның өчен* |
| *элек, элгәре* | *аннары, соңра* | *нилектән* | *шунлыктан, аның* |
| *башта* | *инде, азактан* | | *өчен* |
| *шул чаклы* | *хәтта, шулай да* | | |

Мәсәлән:

Бүре *дә* тук булсын, куй *да* исән булсын.

Яшь чагында *кемне* сөйсәң, күңелең *шуңарда* була.

Өстә кием *ничек* туза, яшь гомер *шулай* уза.

*Кемнең* белеме бар, *шуның* кадере бар.

*Нинди* бүләк алып килгән, *шундый* бүләк алып китәр.

*Кайдан* килдең, *шунда* кит.

*Кайчан* ул килеп утырды, *шуннан соң* эшләр рәтләнде.

Ул *күпме* тапкан, *шул хәтле* бетереп тора.

Гали *шул чаклы* ачуымны китерде, *хәтта* сугып жибәрә яздым.

Син шәһәрдән килдең*ме*, *әллә* авылданмы?

Син *дә* кердең ишектән, мин *дә* кердем ишектән.

*Анда* ямьсез, куркыныч тавыш белән бүреләр улый, *монда* курыккан тавыш белән генә этләр өрә.

Октябрь революциясендә эшчеләр *генә түгел*, *хәтта* крестьяннар да катнашты.

*Кайсы* алдан килеп керде, *шунысы* минем иптәшем була.

*Элек* мин игътибар итмәгәнмен, *инде* азактан бернәрсә дә эшләп булмый.

Кичә *шул чаклы* караңгы булды, *хәтта* күзгә төрткәнне дә күрерлек түгел.

Кушма җөмлә эченә кергән тулы җөмләләрнең бер-беренә бәйләнешен бер яктан гына күрсәтә торган ярдәмлек һәм алмашлыклар күп вакыт соңгы җөмләнең алдыннан киләләр. Аларның телебездә күбрәк йөргәннәре шулар:

*ләкин, әмма, фәкать, мәгәр, тик, ә, хәлбуки, яки, я, яисә, әллә, ни(нә), тагы, һәм, да-дә, тагын да, шулай да, бигрәк тә, барыбер, шуңа күрә, шуның өчен, шунлыктан, шул чакта, шуның кебек, аның саен, шулай итеп, бары да, болар һәммәсе, бөтенесе, чөнки, ки...*

Мәсәлән:

ул бик уңайлы кеше, *шуңа күрә* мин аны яратам да.

Гайнетдин абзый бик тырыша иде, *шулай да* тормышы начар иде.

Җиһанша – бай кеше, *ләкин* үзе бик саран.

Иптәшем ару кеше туры килде, *тик* әз генә эчә торган гадәте бар.

Менә завод кычкыртты, эшчеләр *тагын* эшкә башлады.

Фашистлар юкка гына тыпырчыналар, *барыбер* эшчеләр өстен чыкмый калмас.

Сагынганда айга карыйм, ай *да* ялгыз минем күк.

Аларның булуыннан безгә файда юк, чөнки алар бик ялкаулар[1].

## Тезмәле кушма җөмләләр

Югарыда сөйләнеп үткән кушма җөмләләрнең бер-беренә бәйләнеше тышкы яктан нинди булса да берәр төрле ярдәмлек, алмашлык яки кушымчалар белән күрсәтелгән булса, тезмәле кушма җөмләләрдә боларның берсе дә булмый. Боларда үзара бәйләнеш барлыгын без тик аларның нинди аһәң, нинди тыныш белән әйтелүләренә генә карап беләбез. Шуның белән бергә тезмәле кушма җөмләләрдә югарыда күрсәтелгән бәйләүче ярдәмлекләр, алмашлыкларны кушып әйтү мөмкин булырга тиеш. Юкса, һәрбер янәшә әйтелгән җөмләне тезмәле кушма җөмлә дип карарга ярамый. Монда иң әһәмиятле нәрсә, ике җөмлә арасында тавышны төшереп туктамыйча, сүзнең азагы барын сиздергән кебек, тын алмый гына тыныш ясауда.

(Тезмәле кушма җөмләләрне эчке мәгънәләре ягыннан бер вакытта, бер урында, бер хәлгә каратыбрак сөйләнгән җөмләләр булуына карап аералар.)

---

[1] Бәйләнүле кушма җөмләләр» бүлегендә төрле типтагы җөмләләр бергә бутала. Монда, мисаллардан күренгәнчә, оешма җөмләләр дә, тезмәле кушма җөмләләр дә һәм иярченле кушма җөмләләр дә бар. Мәсәлән:

*Октябрь революциясендә эшчеләр генә түгел, хәтта крестьяннар да катнашты* (оешма җөмлә);

*Менә завод кычкыртты, эшчеләр тагын эшкә башлады* (тезмәле кушма җөмлә); *Яшь чагында кемне сөйсәң, күңелең шунарда була* (иярченле кушма җөмлә).

Мисаллары:

*Менә кояш чыкты, сандугачлар сайрый башлады.* | *Бөтен күкне кара болыт каплап алды, коеп яңгыр ява башлады.* | *Октябрь революциясе булды, юксыллар эш башына менде.* | *Байлар качты, ил тыныч калды.* | *Сәгать тугыз булды, инде укулар башланыр да.* | *Эт өрә, бүре йөри.* | *Минем ашым өлгермәгән, сабанчылар кайтып керделәр дә.* | *Син кичә кайда булдың, нигә күзгә-башка күренмәдең.* | *Бүген тышта җылыткан, түбәдән тамчылар тама.* | *Шаулый диңгез, җил өрәдер, җилкәнен киергән кораб (Дәрдемәнд).* | *Кыш, буран, салкын һава, яфрак кадәрле кар төшә (Г.Тукай).* | *Мин сине алай дип белми идем, син юк нәрсә артыннан йөрисең икән.*

Шуны да әйтеп китәргә кирәк: янәшә әйтелгән җөмләләрне тезмәле кушма итеп төзү яки аларны бер-берәнә кушмыйча аерым гади җөмләләр ясау – сөйләүче һәм язучының үз ирегендә. Бер язучы төрле фикерләрне бергә кушып, кушма җөмлә итеп язса, икенче берәүнең шул ук фикерләрне аерым, өзек, гади җөмләләр итеп язуы мөмкин.

### Сорау, өндәү, хикәя, боерык, үкенеч җөмләләре

Гади, оешма яки кушма булып-булмауларына карамастан, нинди аһәң, нинди тавыш белән сөйләнүләренә генә карап, теләсә нинди җөмләләрне тагы берничә төрләргә бүләргә мөмкин:

1) Сорау җөмләсе. Җөмләнең азагына таба тавышны күтәреп, кинәтрәк сорау белән туктап әйтелә. Мәсәлән: *нигә син кичә укырга килмәдең? Бу китап кемнеке? Кичә күренмәдең, әллә авырдыңмы?..*

2) Өндәү җөмләсе. Җөмләнең бөтен сүзләре көчле тавыш белән, ачык итеп, күңелне үзенә тартырлык итеп әйтеләләр. Мәсәлән: *Яшәсен Октябрь революциясе! Берләшегез, бөтен дөнья эшчеләре! Ах, бу матур, айлы кичләр!..*

3) Хикәя җөмләсе. Бу җөмлә, сорауның киресенчә, һәрвакыт тавышны түбән төшереп, тынычлап килеп туктау белән әйтелә: *мин авырып яттым.* / *Без Идел аръягына хозурга чыккан идек.* / *Аның йөрәге бөтен эшче, бөтен изелгән халыкларга кайнар мәхәббәт белән тибә иде.*

4) боерык җөмләсе, ачык, кыска тыныш белән, боерык яки үтенеч тавышы белән әйтелә. Мәсәлән: *эшеңне вакытыннан калдырма.* / *Атны тизрәк туарып, печәнгә куш.* / *Бик соңга калма, куркырсың.*

5) Үкенеч җөмләсе. Сузып-сузып, кайгы тавышы белән әйтелгән җөмләләр: *Сабый чакта үлгән булсам! Ах, нигә генә килдем, икән монда!..*

## Тезем

Бер-берәнә бәйләнешкән кушма җөмләләрдән, укырга уңайлы һәм тәртипле итеп тезелгән озын, тулы тасвирлы тезмәләр тезем дип атала. Сүз тезмәләренең иң югары, иң оста төзелгәннәре шул теземнәр була.

Теземнәрдә без ике зур бүлем күрәбез: тавышны күтәрү бүлеме, төшерү бүлеме.

Теземнәрдә төп әйтергә теләнгән фикер – баш җөмлә иң азактан әйтелгән төшерү бүлемендә булып, аңа бәйләнгән, шул бүлемдәге уйны ачу, аңлату өчен әйтелгән җөмләләр алдагы күтәрү бүлемендә киләләр.

Теземнәрнең күтәрү бүлеме тавышны күтәреп, соңгы бүлеме тавышны төшереп, нәтиҗә чыгарган аһәң белән әйтелә. Күтәрү бүлемендәге җөмләләр үз арасында бертөслерәк санап бирү аһәңе белән, араларында тын алынмаган кыска паузалар ясап әйтелә дә, төшерү бүлеме алдыннан озаграк тыныш ясала. Тезем бөтенләй беткәннән соң, тәмам тулы иркен тыныш ясала.

Теземнәрнең күтәрү бүлемендәге җөмләләренең зурлыклары бертигез, тышкы төрләре бер-беренә охшаш булырга, гомумән бөтен тезем укыр өчен бик җиңел, тиз аңлаешлы, агымлы итеп төзелгән булырга тиеш. Эчке яктан теземнәр вакыт, урын эчендә бер-беренә мөнәсәбәтле хәлләрне, төп бер фикерне тулы итеп аңлатудан гыйбарәт булырга тиеш.

Мисаллары:

Кайчан кара болытлар килә башласа, кара урман каты җил белән тирбәнсә, яшеннәр ялтырап, күкләр күкрәсә, – шул чакта Идел елгасы да куркыныч бер төскә керә.

Һич тә күңелем ачылмаслык эчем пошса,
Үз-үземне күрәлмыйча рухым төшсә,
Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм бу башымны
Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә;
Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш,
Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,
Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса
Хәзер генә сыгылып-сыгылып елаган яшь,–
Шул вакытта мин кулыма китап алам,
Аның изге сәхифәләрен актарам;
Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,
Шуннан гына дәртләремә дәрман табам.

(Г. Тукай.)

Ничә, ничә гасырлар буенча дәвам итеп килгән коллык богауларын өзеп, дөнья биләүче залимнарның эчләренә курку төшергән, бөтен җир йөзен дерр селкеткән Бөек Октябрь революциясе булгач, бөтен завод-фабрикалар үз көчләре белән дөньяны төзүче, бөтен илнең кирәген җитештереп торучы эшчеләр кулына күчеп, җир, су, урман кебек, табигый байлыклар бөтен халыкларны маңгай тире белән туйдырып торучы крестьяннарга бирелгәч, эшче-крестьян көче белән яшәүче әрәм тамаклар, канэчкеч түрәләр эш башыннан төшерелеп, бөтен халыкларга тигез яшәү хокукы бирелгәч, – менә шул чакта гына без иркенләп тын ала башладык, шуннан соң гына безгә кеше төсле тормыш төзергә, алга барырга киң юл ачылды.

(Г. Алпар.)

# ҖӨМЛӘ ЭЧЕНДӘ МАНТЫЙКЫЙ БАСЫМ, АҺӘҢ, ТЫНЫШ УРЫННАРЫ

Җөмләләрдә мантыйкый басым, аһәң үзгәртү (интонация) һәм тыныш урыннары, күбесенчә, сөйләүче яки язучының шәхси тәсаувырына, аның үз психологиясенә карап йөри торган нәрсәләр. Шуңа күрә бу нәрсәләрне ныклы бер канун астына алып, билгеләп күрсәтүе дә кыен. Бездә әле җөмлә эчендәге сүзләрнең кайсы нинди басым белән әйтелүләре, нинди кисәкләрнең нинди аһәң белән, нинди тыныш белән сөйләнүләре – бөтенләй тикшерелмәгән, тиелмәгән бер мәсьәлә. Шулай булса да боларның телебездә азмы-күпме шәкли бер төс алганнарын, урнаша төшкәннәрен, тыныш билгеләрен куюда гамәли әһәмиятләре булганга күрә, бу урында кыскача бер тәҗрибә рәвешендә генә күрсәтеп үтәргә туры килә.

1) Гади хикәя җөмләләренең иясе күбрәк күтәренке тавыш белән, хәбәре төшенке тавыш белән әйтелә; ияләрне әйткәннән соң кечкенә бер пауза ясап алына.

Язуда ия белән хәбәр арасында, башка җөмләләр, кереш сүзләр булмаганда, бертөрле дә тыныш билгесе куелмый. Ләкин җөмләнең хәбәре фигыль булмаса, ике арага бер сызык (–) куеп язарга ярый. Мәсәлән: *бу – китап. Каләм – кыска. Гали – авылда*... кебек.

2) Кушма хәбәрләрнең (рәвеш фигыле, ымлыклар, чит сүзләр белән янәшә әйтелгән фигыльләрнең) беренчесе һәрвакыт кечкенә мантыйкый басым белән, икенчесе басымсыз һәм алдагысына кушып әйтелә (кушма хәбәрләр арасына язуда һичбер билге куярга ярамый). Мәсәлән: *алып килде; утыра тор; килә бирә; шау итәләр; мәгълүм булды*... кебек.

3) Тәмамлыкларның хәбәр яки фигыль алдыннан килгәннәре гади җөмләләрдә һәрвакыт тулы мантыйкый басым белән әйтелә (язуда аерылмый).

4) Җөмлә эчендә килгән сорау һәм эндәшү сүзләре һәрвакыт тулы басым белән әйтеләләр: *ничә кеше бар? ничек булды? кая барасың? бу – кем? нәрсә ул?* кебек.

5) Исемнәргә аергыч булып янәшә килгән сүзләр, сыйфатларны көчәйтү өчен алдан әйтелгән сүзләр, кисәкчәләр мантыйкый басым белән әйтеләләр; аергычлардан соң килгән сүзләр басымсыз булалар: *зур йорт, матур кеше, кып-кызыл, түм-түгәрәк, үтә кызыл, бик әйбәт*... кебек.

6) Янәшә килгән аергыч белән аерылмышлар, кушма һәм тагылмалы сүзләр, исемнәр артыннан әйтелгән ияртүче ярдәмлекләр, кушма рәвешләр, кушма хәбәрләр арасында һичбер пауза ясалмый, бәлки икәве бер сүз кебек кушып әйтеләләр.

Язуда тагылмалы сүзләр, кушма рәвешләр арасында гына сызыкча (-) куелырга тиеш, башкаларында бер билге дә куелмый.

7) Җөмлә башында килгән *әйе, юк, димәк, кыскасы, ярар, мәсәлән,*

*бәс...* кебек сүзләр, тавышны күтәреп, басым белән әйтеләләр, һәм болардан соң тын алмыйча гына пауза ясала.

Язуда мондый сүзләрдән соң өтер (,) куелырга тиеш.

Мәсәлән: *әйе, ул кайтмаган икән шул. Димәк, бу эш барып чыкмады...*

8) Мыскыл итеп, булмаганны бар итеп әйтелгән сүзләр беркадәр басым белән, башка сүзләрдән аера төшеп әйтелә. Язуда мондый сүзләр тырнаклар («») эченә алып күрсәтелә.

Мәсәлән:

*Россиянең иске бөтенлеген кайтарырга теләүче «бөек» Колчакның «каһарман» гаскәрләре «мовәффәкыятъ белән «Себергә китеп, уңайлы позицияләргә» урнаштылар. / Гали иптәш үз фикерен исбат итәр өчен бик «көчле» дәлилләр китерде.*

9) Кереш сүз, кереш җөмләләр, беркадәр тавышны төшереп, читкә карап, тиз-тиз генә әйтеп алган кебек аһәң белән һәм башка сүзләр белән ике арада тын алынмаган паузалар белән әйтеләләр.

Язуда кереш сүз, кереш җөмләләр төп җөмлә сүзләреннән өтер (,) белән аерылалар.

Төп җөмләгә мөнәсәбәте ерак булган кайбер кереш сүзләр ике яктан җәя эченә алып күрсәтелә. Мәсәлән: Авыл халкы, белмим нидән, бик акрын кузгала.

*Бу турыда татар матбугаты (газета-журналлары) бер сүз дә әйтми калды.*

10) Чит сүз, чит җөмләләрнең әйтелешләре дә шушы югарыгылар кебек, тик алар тавышны бераз күтәребрәк әйтеләләр.

Язуда төп җөмлә эченә кергән чит сүз, чит җөмләләр тырнаклар (« ») белән ике якта бүлеп күрсәтелә. Чит сүзләр алдындагы төп җөмлә кисәгеннән соң ике төртке (:) куела. Төп җөмләдән башка, язучының үз сүзен аралаштырмый күчерелгән чит сүзләр юл башыннан бер сызык (–) куеп кына языла лар. *Вәли миңа:«Хәзер килермен», – дигән иде.*

*– Нигә син китапны алдың?*

*– Ул минем эшем.*

*– Мин сине кыйнармын.*

*– Анысы синең эшең...*

11) Гади хикәя җөмләләре азакка таба тавышны төшерә барып, иркен сулыш алып туктала.

Язуда гомумән гади тавыш белән сөйләнгән хикәя, үкенеч, боерык, хәтта өндәү җөмләләреннән соң да тулы тыныш билгесе – бер төртке (.) куела. Мәсәлән: *Ява атавындагы восстание көннән-көн көчәя бара.– «Татарстан» газетасын алып кара әле.*

12) Сорау, гаҗәпләну җөмләләре азакка таба тавышны күтәрә барып, кинәтрәк туктау белән әйтеләләр.

Язуда сорау җөмләләреннән соң сорау билгесе (?) куела. Әгәр гаҗәпләнү

катыш сорау булса, ул чакта азактан сорау белән өндәү янәшә (?!) куелырга да ярый.

Мәсәлән: *Син шәһәргә кайчан барып килдең?Ниләр эшләнеп ятканнан аның хәбәре юкмы икәнни?!*

13) Өндәү җөмләләрендә бөтен сүзләр тавышны күтәреп, ачык, тигез көч белән әйтелә.

Язуда өндәү сүзләреннән, өндәү җөмләләреннән соң өндәү билгесе (!) куела. Көчлерәк тойгы белән әйтелгән өндәү җөмләләреннән соң ике-өч өндәү билгесе янәшә куелырга да ярый.

Мәсәлән: *Берләшегез, бөтен дөнья эшчеләре! Яшәсен Бөек Октябрь революциясе!!*

14) Артык көчле әйтелгән боерык җөмләләре, кайгы, үкенеч җөмләләре дә язуда өндәү билгесе куеп язылалар. *Аһ, харап булдык!.. Янгын бар!! Бер генә таяныр кешем дә калмады бит инде!*

15) Оешма җөмләнең тиң кисәкләре, бер-беренә тиң тезмәле кушма җөмләләр үзара бертигез аһәң белән, ике арада санап әйтелгән кебек кушучы паузалар (тын алмый туктаулар) ясап әйтеләләр.

Язуда тиң кисәкләр, тиң җөмләләр арасында өтер (,) куела. Мәсәлән: *яңгырдан соң бөтен кыр, бөтен басу ямьләнеп, яшәреп китте. Болытлар таралдылар, көн аязланды.*

16) Ияртүле һәм бәйләнүле кушма җөмләләрнең элгәрегесе тавышны күтәреп, икенчесе тавышны төшереп, тынычлабрак әйтелә. Ике җөмлә арасында кушучы паузалар ясала.

Язуда кушма җөмләләр гомумән бер-береннән өтер белән (,) аерылалар. Мәсәлән:

*Хезмәт иясе, үз кулында корал булмаганлыктан, ялланып эшләргә мәҗбүр була иде! Эшче-крестьян элемтәсен ныгытырга кирәк, чөнки шул чакта гына безгә революцияне саклап калу мөмкин булачак.*

17) Соңыннан тәфсыйль ителәчәк[1] булган башлангыч җөмләләр, санап һәм бүлгәләп күрсәтү алдыннан әйтелгән дәгъвалар, ачыграк, көчлерәк тавыш белән әйтелеп, соңгылары тавышны төшереп әйтелә. Мондый башлангыч, гомуми дәгъва җөмләләреннән соң тавышны кисеп, озаграк пауза ясала.

Язуда мондый җөмләләрдә санау, озынлау алдыннан ике төртке (:) куела. Мәсәлән:

*Бу мәсьәләдә ике төрле караш бар: берәүләр, тормыш аңны билгели, ди (материалистлар), ә икенчеләр, аң тормышны, ди (идеалистлар).*

18) Теземнәрнең алдагы бүлекләре күтәренке тавыш белән, тиң җөмләләре тигез тавыш белән һәм санау паузалары белән әйтелеп, азаккы – нәтиҗә бүлекләре төшенке, тыныч аһәң белән әйтеләләр. Күтәренке бүлек белән төшенке бүлек арасында кушучы озын пауза ясала.

[1] Тәфсыйль ителәчәк – детальләштереләчәк, аерым-аерым әйтеләчәк.

Язуда күтәренке бүлек белән төшенке бүлек арасында өтер белән бергә сызык (,–) куела; тиң җөмләләрнең үзенә ияргән вак җөмләләр булганда, икенче дәрәҗә баш (тиң) җөмләләр соңыннан өтерле төртке (;) куярга тиеш була (мисаллары үтте).

19) Көчле әсәрләнү, әйтә алмау, яки әйтергә теләмәү сәбәпле кайбер җөмләләрнең бөтен кисәкләре әйтеп бетерелми тукталган яки бүлеп-бүлеп сөйләнгән булалар. Кайвакыт фикернең табигый агымын үзгәртеп, җөмләнең беразын әйткәннән соң пауза ясап, көтелмәгән сүзләр сөйләнеп куела.

Мондый өзеп сөйләнгән, әйтеп бетерелмәгән яки көтмәгәндә туктап, икенчегә борып җибәрелгән урыннар язуда күп төрткеләр (...) белән күрсәтелә.

*– Ах, йөзе кара!.. Кулыма эләксә, мин...*

*– Ярар, мин иртәгә үзем... Клубка барганда гына кереп алырсың инде.*

20) Китап мәкалә, газета, журнал, мосафирханә[1], пароход, кооператив, завод, фабрика... кебек мәдәни нәрсәләрнең исемнәре язуда тырнаклар (« ») эченә алып күрсәтелергә тиешләр.

Мәсәлән: *«Спартак» заводы турында «Кызыл Татарстан»да бер хәбәр язылган иде. Быел безнең «Кызыл Йолдыз» артеле «Фурдзон» тракторы белән сөрә башлады.*

[1] Мосафирханә – гостиница.

# ТАТАР ГРАММАТИКАСЫНА КАРАГАН ӨСТӘМӘ МАТЕРИАЛЛАР[1]

## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ЯЛГАНМАЛЫК ТАБИГАТЕ ТУРЫНДА[2]

Татар теленең, гомумән барлык төрек телләренең дә, морфологик төзелеш ягыннан күп үзенчәлекләреннән берсе – ялганмалык.

Бу үзенчәлекнең чынысы нәрсәдән гыйбарәт? Ни өчен тел гыйлемендә безнең телебез агглютинатив – ялганмалы телләрдән санала, ни өчен телебезнең характеры агглютинативлык – ялганмалык белән билгеләнә?

Мәгълүм ки, төрек телләрендә сүз формаларының үзгәреше, сүз ясалышы, сүзләрнең төрләнеше төп яки тамырга кушымчалар ялгау юлы белән реальләшә. Төп яки тамыр – сүзнең реаль мәгънәле кисәге ул. Төп-тамыр телдә үзе генә дә, бер төрле кушымчалар ялганмыйча да, сөйләнә ала. Кушымчалар исә телдә аерым үзләре генә кулланылмыйлар һәм, аерым алганда, үзләре генә бер төрле дә мәгънә аңлатмыйлар, алар төп яки тамырга ялганып кына киләләр һәм шул чакта гына сүзнең мәгънәле кисәге булалар. Кушымчалар төп-тамырдагы авазлар гармониясенә буйсыналар. Шуның белән бергә, төп яки тамырлар да, кушымчалар да үзләренең элекке формаларын саклыйлар, әйтерлек үзгәрешләргә очрамыйлар диярлек, һәм аларны теләсә нинди сүзнең составында да җиңел табарга һәм аерырга мөмкин була. Мәсәлән:

*кил – килгән, килгәннәр, килгәннәрме?*

*ат – атлар, атларым, атларымнан;*

*бул – булганлык, булмаганлыкларыннан,*

*булышмаганлыкларыннанмы – бул + ыш + ма + ган + лык + лар + ы(н)нан + мы.*

Бу мисаллардагы *кил, ат, бул* кисәкләренең төп (яки тамыр) икәнен, *гән-ган, нәр-лар, ым, ме-мы, ыш, нан, мә-ма, лык* кисәкчекләренең әйтелеш ягыннан әнә шушы төп-тамырлардагы авазлар гармониясенә ияргән һәм

---

[1] Г.Алпаровның 1927–1936 елларда язылган бу хезмәтләре «Сайланма хезмәтләр» китабыннан үзгәрешсез алып бирелде. – *Ред.*

[2] Г. Алпаров үзенең бу мәкаләсен, атаклы тел галиме профессор В.А. Богородицкийга багышлап, рус телендә язган. Мәкалә профессор В. А. Богородицкийның тууына 70 ел һәм гыйльми хезмәтләренә 45 ел тулуга багышланып чыгарылган «Вестник научного общества татароведения» исемле җыентыкта (1927 ел, № 7) басылган. Татар теленә тәрҗемә итүче – Ш. Рамазанов.– *Ред.*

үзләре генә аерым мәгънәгә ия булмаган кушымчалар икәнлеген һәркем күрсәтә ала.

Әгәр без бүтән системадагы телләрнең морфологик төзелешенә игътибар итсәк, без ул телләрнең сүзләрендә мондый ачык ялганмалыкны тапмыйбыз. Мәсәлән, гарәп телендә (сам семьясыннан) сүз ясалышы да, сүз төрләнеше дә тамыр һәм төпнең үз составындагы авазларын үзгәртү юлы белән була. Мәсәлән: *ктб* – كتب (укылышы – кәтбөн; язу мәгънәсендә) тамырыннан *китаб* – كتاتب, *катиб* – كاتب (язучы), *мәктүб* – مكتوب (язылмыш), *мәктәб* مكتب, *көтөб* – كتب (китаплар); *глм* – علم (укылышы – гыйльмөн; белү, белем мәгънәсендә) тамырыннан *галим* – عالم, *мәгълүм* – معلوم, *мәгълүмат* – معلومات, *игълам* – اعلام (белдерү), *тәгълим* – معلم (өйрәтү), *мөгаллим* – معلم (өйрәтүче, укытучы) һ. б. формалар ясала. Шуңа күрә бу телләр флектив телләр дип атала. Кытай телендә исә сүзләрнең бернинди дә формалары юк; аларда телнең тик синтаксик төзелеше генә бар (тамыр телләр).

Морфологик төзелеш ягыннан рус телендә ялганмалык билгеләре бар кебек күренсә дә, җентекләп тикшергәндә һәм төрек телләре белән чагыштырганда, рус телен агглютинатив телләрдән саный алмыйбыз. Бу яктан рус телендә түбәндәге аерымлыкларны табабыз:

1) рус телендә сүзләрнең формалары авазлар составын үзгәртү белән дә ясалырга мөмкин,

2) рус телендәге кушымчалар төп яки тамырның гармониясенә буйсынмыйлар,

3) рус телендә кушымчалар тамырның алгы ягына да, азагына да кушылырга мөмкин,

4) шуның белән бергә төп-тамыр да, кушымчалар да авазлары ягыннан бик нык үзгәрәләр,

5) бер үк мәгънәдә бик күп төрле кушымчалар йөри, үзләрендә даимилек юк.

Мәсәлән: *нёс, несу, нести, принёс, относится, ношу; принял, приму, отниму; течёт, отёк, стекло, приток; ход, хожу, пошёл, шлю, расхождение* һәм ш. о.

Төрек телләрендәге ялганмалык исә аеруча ачык һәм конкрет. Бу телләрдәге ялганмалык аеруча төзек – системалы, кушымчалар даими, һәм аларның ялганулары механик характердарак була. Менә бу үзенчәлек ягыннан Казан татар теле бүтән төрек телләре арасында тагын да аерымрак урын тота. Чөнки, бездә кушымчаларның сингармонизмга буйсынмавы беркайда да очрамый. Бүтән төрек телләрендә исә, сирәк булса да, мондый хәл очраштыргалый. Шунлыктан татар теленең ялганмалык табигатен җентекләп өйрәнү тел гыйлеме өчен аеруча интереслы булырга мөмкин. Грамматикада формаль принципка күчү уңае белән телебезнең ялганмалык үзенчәлеген, ялганмалыкның табигатен тикшерү безнең өчен чираттагы мәсьәлә булып тора. Кушымчаларыбызның ял-

ганмалык үзенчәлеген һәм табигатен тикшерүнең гомуми төрек телләре грамматикаларын төзү өчен зур әһәмияте бар. Морфология бүлеге фәкать шушы кушымчаларны тикшерү һәм аларны системалаштыру белән генә шөгыльләнә дә диярлек. Сүз ясалышы, сүз төрләнеше формаларын тикшерү, төп-тамырларны классификацияләү (сүз төркемнәрен билгеләү), фигыльләрне һәм исемнәрне төрләнүче һәм төрләнмәүче формаларга бүлгәләү – болар бары да төбендә кушымчаларның үзенчәлекләрен, аларның табигатен өйрәнү була һәм кушымчаларыбызның бөтен запасын системалаштыруга (дөресрәге, системалаштыруга омтылуга) кайтып кала. Кыскасы, морфологиянең 99% ы кушымчаларны тикшерү һәм аларны системалаштыру белән мәшгуль. Синтаксис һәм фонетикада да кушымчалар әһәмиятле генә урын тоталар. Шуңа да карамастан, бездә әле кушымчаларның табигате һәм характеры аз тикшерелгән, аз өйрәнелгән; алар җыелмаган, бер төрле дә төркемләнмәгән – классификация ясалмаган, аларның ялгануларындагы механик һәм законлы тәртип тә аңлатылганы юк әле. Хәлбуки, нәкъ менә шунда күп кенә бәхәсле мәсьәләләрнең сере яшеренгән: телебездәге сузык авазларның төгәл санын билгеләү, *у-у* һәм *и-ый* сузыкларының гади яки катлаулы икәнлеген ачу (шуңа карап, бу авазларның орфографиясен урнаштыру), телебездәге төп тамырларның тулы һәм төгәл классификациясе, фигыль дәрәҗәләрен (залоги), килешләрне (падежи) һәм аларның саннарын билгеләү һ. б. Бер сүз белән әйткәндә, телебезнең грамматикасын гыйльми итеп төзүнең барлык нигезләре һәм принциплары кушымчаларны һәм аларның законнарын өйрәнүгә бәйләнгән.

Телебездәге кушымчаларны җыйнау һәм аларны системалаштыру белән озак вакыт шөгыльләнгәннән соң, мин кушымчаларның кайбер якларын үземнең «Татар грамматикасы» исемле китабымда башка мәсьәләләр уңае белән кыскача гына аңлатырга тырыштым. Хөрмәтле остаз – тел галиме В. А. Богородицкийга багышланган бу мәкаләмдә специаль рәвештә телебезнең кушымчалары өстендәге күзәтүләремне бәян итәргә тырышып карыйм.

### Кушымчаларны ничек табарга һәм ничек өйрәнергә?

Ике, өч һәм артыграк иҗекле теләсә нинди татарча бер сүзне алыгыз да, азагыннан берәр-икешәр яки өчәр авазын төшерә-кыскарта барып әйтеп карагыз, бу вакытта сез (әгәр татарча сөйләү телен белсәгез) сүзнең азаккы ягыннан мөстәкыйль мәгънәләре булмаган, бүтән сүзләр азагында да очрый торган һәм сүзнең төп (тамыр) кисәгендәге авазларының гармониясенә буйсынып килгән кисәкчекләрнең аерылып чыкканлыгын күрерсез. Менә шулар кушымчалар була да инде. Сүзнең, азаккы чиккә кадәр кыскарып та, үзенең башлангыч мәгънәсен саклаган һәм авазлары ягыннан да мөстәкыйль булган кисәге – төп (яки тамыр) сүз була.

Телебездә *һәм, я, иң* һ. б. кебек кайбер сүзләр бөтенләй кушымчасыз

булалар. Әмма сүзләребезнең зур күпчелеге аерым кисәкләрдән – морфемалардан төзелгән була. Мәсәлән: *килгәннәр* сүзе *кил+гән+нәр* дигән кисәкләрдән, *юлдагыларны* сүзе *юл+да+гы+лар+ны* дигән кисәкләрдән, *булышмаганлыкларыннан* гына сүзе *бул+ыш+ма+ган+лык+лар+ы+ (н)нан+гына* дигән кисәкләрдән – морфемалардан тора.

Күренә ки, бер төп-тамырга тоташтан берничә кушымча ялгана ала икән. Төп-тамырлар кушымчасыз, аерым үзләре генә дә, һәм кушымчалар белән дә кулланыла, ә кушымчалар исә төп-тамырдан башка аерым үзләре генә телдә кулланылмыйлар.

Төп-тамырлар сүзлекләрдә җыйнала һәм тикшерелә, аларны лексикология тикшерә. Төп-тамырлар күбесенчә гади бер яки ике иҗекле була. Мәсәлән; *кил, бар, тор, кеше, бала, утыр* һ. б. Болардан башка тагын телебездә *билбау, Биктимер, Сөембикә, аккош..* кебек ике тамырдан ясалган кушма сүзләр һәм *ат-тун, тау-чагыл, ут-күз, бала-чага, хатын-кыз..* кебек тагылмалы кушмалар да бар.

Кушымчаларны җыйнау һәм аларны тикшерү морфология эше булырга тиеш.

Кушымчаларны тикшерү – аларны җыйнаудан, авазларының составына һәм билгеле сүзләргә ялгану-ялганмауларына карап характерлау һәм төркемләүдән, ялгану тәртипләрен һәм ялганганда була торган фонетик үзгәрешләрне ачыкландырудан, аларны үзара бер-берсе белән һәм бүтән төрек телләрендәге кушымчалар белән чагыштырудан гыйбарәт.

### Кушымчаларның килеп чыгуы

Тел галимнәренең ышанычлырак фикерләренә караганда, төрек телләрендәге кушымчалар, хәзерге кытай теле кебегрәк, аморф (формасыз) булган тәүге телебездә аерым, үзбаш һәм материаль мәгънәле, мөстәкыйль гармонияле сүзләр булганнар. Тел үсеше тарихында кайбер сүзләр, гелән бер төркем сүзләр соңында, аларга ярдәмче сыйфатында озак йөри торгач, әкренләп үзләренең мәгънәләрен югалтканнар. Ул чакта әле алар (мәгънәләрен югалта барган сүзләр. – *Ш. Р.*), хәзерге телебездәге *өчен, белән, кебек, бугай..* сүзләре шикелле, авазлары ягыннан үзбаш берәмлек булып торуларын – үз гармонияләрен саклаганнар. Соңыннан инде, аваз составлары кыскарып, әйтелешләре ягыннан да бик нык үзгәреп, алдагы сүзнең – төп-тамырның – гармониясенә ияртелгәннәр һәм әкренләп кушымчага әйләнгәннәр. Төп-тамырга якын ук торган бик борынгы кушымчаларның артык кыскарып, бөтенләй төп-тамыр белән берегеп, аның аерылмас бер элементы булып киткәннәре дә бар. Шулай итеп, телебездәге кушымчаларны икегә бүләргә мөмкин:

1) җанлы кушымчалар, 2) җансыз кушымчалар

**Җанлы кушымчалар** – хәзерге көндә тамыр көенчә телдә йөргән сүзләрнең азагында барлыгы ачык беленеп торган кисәкләр. Җанлы кушымчалар җиңел сиземләнә һәм аерыла ала. Мәсәлән: *кешеләр,*

*килгән, яздыр, башлык...* сүзләрендәге *ләр, гән, дыр, лык* кушымчалары кебек.

**Җансыз кушымчалар** – хәзерге җанлы телдә тамыр көенчә аерым йөртелмәгән сүзләрнең азагындагы кисәкләр. Төп-тамырның аерылмас бер элементы булып киткән җансыз кушымчаларны фәкать чагыштырмалы-тарихи эзләнүләр юлы белән генә табып аерырга мөмкин. Мәсәлән: *югары, сиксән, акыр, исер, аек, тавык, макта, елан, куян, якын, бөтен, тавыш, өләш...* сүзләрендәге *ары, ән, ан, ыр, ер, ык, та, ын, ен, ыш, әш* кисәкләре кебек.

Кайбер кушымчаларны яки аларның кайбер авазларын борынгы формаларның калдыклары дип яки аналогия буенча китерелгән, яисә иҗек тулыландыру өчен өстәлгән кисәкчекләр дип карарга мөмкин. Мәсәлән: *баласы, караячак (карайачак), язылa, атына, юлыннан, икешәр* сүзләрендә *ы, ачак, ла, а(га), нан, әр* кушымчалары урынына *сы, йачак, ыла, на, ыннан, шәр* кушымчалары китерү кебек.

Югарыда күрсәтелгән аерым моментларның үсеш эзләрен җанлы телебездә хәзер дә ачык күрергә була. Мәсәлән, җанлы телебездә, ярдәмлек – бәйлек ролендә еш куллану аркасында, әле яңарак кына үзләренең төп мәгънәләрен югалта башлаган *курә, аша, утә, таба...* кебек сүзләр бар. Болар үзләренең гармонияләрен саклыйлар әле, кайчакта фигыль-рәвеш сыйфатында үзләренең реаль мәгънәләрендә дә кулланылалар.

Телебездә мөстәкыйль мәгънәләрен бөтенләй югалтып, ләкин гармонияләрен саклап килгән ярдәмлекләр, тулы мәгънәсендәге бәйлекләр дә бар. Мәсәлән: *белән, өчен* кебек. *Белән* бәйлеге исә кайбер төрек телләрендә үзенең гармониясен дә югалтып бара. Анатули-госманлы төрек телендә бу бәйлек, үзенең гармониясен саклаганы хәлдә, бик нык кыскарып, *лә* формасында кушымчага әйләнгән. Мәсәлән: *сенеңлә, бенемлә, Әхмәтлә, онынлә...* (бездә дә бер сүздә, *төнлә* дигән сүздә, шулай кыскарып калган). Казах телендә *белән* бәйлеге *менән* рәвешендә булып, шуннан мән формасына кыскарган, калын сүзләр соңында килгәндә, сөйләү телендә кайчакта ман рәвешендә әйтелә: *оныман, атыман* (аның белән, аты белән). Кайбер татар авылларында (минем үз туган авылымда) *былан* рәвешендә, мәсәлән, *аным былан* (аның белән) итеп сөйләүне ишеткәнем бар.

Аннары, телебездә төп-тамырның гармониясенә буйсынып та, ләкин үз басымнарын саклап килгән, шунлыктан төп сүзнең басымын үзләренә үткәрмәгән кисәкләр бар. Мәсәлән: *барамын, килерсең, килгәндер, юкмы, үзе генә, алар гына...* сүзләрендәге *мын, сең* (мин, син сүзләреннән) *дер* (торыр сүзеннән) *мы, генә-гына...* кисәкләре кебек. Болар инде – кушымчалар, дөресрәге, ярым кушымчалар. Кайбер төрек телләрендә болар әле гармония ягыннан да төп-тамырга тәмам ияртелеп җитмәгәннәр.

Болардан соң инде чын кушымчалар килә. Чын кушымчалар гармония ягыннан да, басым ягыннан да төп-тамырга буйсыналар, ләкин барлыклары ачык беленеп, сизелеп тора. Мәсәлән: *килде, атлар, кешеләр, булган, белгән, эздән, юлдан*... сүзләрендәге *де, лар-ләр, ган-гән, дән-дан* кушымчалары кебек.

Ниһаять, тамырга бик нык берегеп, аның белән тәмам бер бөтен булып укмашкан, хәзерге тел аңында кушымча икәнлекләре сизелмәслек булган, бары тик чагыштырмалы-тарихи тикшерүләр юлы белән генә аерыла алган бик борынгы, җансыз кушымчалар бар. Мәсәлән: *елан, өләш, караңгы, пычкы, бөтен, тавыш, кавын, аяк*... сүзләрендәге *ан, әш, ңгы, кы, ен, ыш, ын, ак*... кисәкләре кебек.

Төп-тамыр сүзләрне ялгыз һәм кушма дип аерган кебек, кушымчаларны да ялгыз (гади кушымча) һәм кушма кушымчадан аерырга туры килә. Чөнки телебездә, ялгыз бер кисәктән генә гыйбарәт булган кушымчалар белән бергә, ике-өч кисәктән кушылып, янәшә килгән чагында үзенә башка, аерым бер мәгънә өчен кулланыла торган кушма кушымчалар да бар. Кайбер кушымчалар, янәшә кулланыла торгач, шулай берегеп, аерылмас бер кушымчага әйләнеп китәләр. Мәсәлән: *юлдаш, авылдагы, сезнеке, килсәнә, алынкыра, күмәкләшә*... сүзләрендәге *даш (да+ш), дагы (да+гы), неке (нең+ке), сәнә (сәң+а), ынкыра (ын+кы+ра), ләш (лә+ш)* кушымчалары шундыйлар.

Бу урында тагын телебездәге характерлы бер кисәкчә турында искәртеп үтәргә кирәк. Артыклык дәрәҗәсендәге төп-тамыр сыйфатлар алдында кулланыла торган (мәсәлән, *ямь-яшел, кып-кызыл, оп-озын, нәп-нәзек*... сүзләрендәге кебек) кисәкчәләр турында әйтмәкче булам. Бу кисәкчәләр төп-тамырның гармониясенә ияреләр, ләкин, кушымчалар яки бүтән кисәкчәләр кебек, төп-тамырның азагында түгел, бәлки алгы ягында киләләр. Бу нинди кисәкчәләр соң? Кушымчаларны югарыдагыча сыйфатлавыбызга һәм телебезнең характерына каршы килмиләрме?

Юк, каршы килмиләр. Болар кушымчалар түгел. Чөнки болар даими түгелләр һәм, кушымчалар кебек, пар-пар да килмиләр, бәлки һәр сыйфатның аерым үзенә караган кисәкчәләр генә. Бу кисәкчәләр сыйфатның мәгънәсен көчәйтү өчен аның баштагы авазларын кабатлаудан гыйбарәт. Мәгънәне көчәйтү өчен телебездә сыйфатларны, *кызыл-кызыл, сары-сары, матур-матур, озын-озын* рәвешендә, тулысынча кабатлап әйтү формасы да бар. *Кып, нәп, оп*... кебек көчәйткеч кисәкчәләр менә шушы тулы кабатлаулы форманы кыскартып әйтүдән килеп чыкканнар.

### Кушымчаларның аваз ягы

Кушымчалар күбрәк 2–3 авазлы, бер иҗекле булалар. Бер генә авазлы, шулай ук 4–5 авазлы кушымчалар да бар.

Кушымчаларда телебездәге сузыклардан тик ике пары гына – *а-ә, ы-е*

ләр генә очрый. Татарча сүзләрдә, *о-ө* сузыклары кушымчаларда бөтенләй килмиләр. Кушымчаларда *о-ө* булып әйтелә торган сузыклар – асылда *ы-е* авазлары алар. Мәсәлән: *тормошо, көмөшө.* Монда тамырдагы *о-ө* авазлары кушымчалардагы *ы-е* авазларына да йогынты ясыйлар һәм боларны да иренләштерәләр. Кушымчаларда очрый торган *у-ү, и* сузыклары – асылда дифтонглар, ягъни түбәндә *ыв-эв-эй* авазларыннан гыйбарәт булып, хәзер кыскарып калганнар.

Тартык авазлардан кушымчаларның башында *н, в, р, з, й, ң* авазлары, кушымчаларның азагында *б, г, с, д* авазлары килмиләр, *җ, ж, х, һ, ф* авазлары исә кушымчаларда бөтенләй булмыйлар. Кушымчалар азагында беррәттән ике тартык янәшә килми. Төп-тамырларда да ике тартыкның янәшә килүе бездә сирәк очрый. (Иҗек башында ике тартык килү татарча сүзләрдә гомумән юк.)

Татар телендәге кушымчалар, кагыйдә рәвешендә, пар-пар булалар: 2, 4, 6 һәм 8. Кушымчаларның парлылыгы төп-тамырның гармониясенә иярүдән һәм ассимиляция законнарыннан килә. Мәсәлән: *барган, килгән, киткән, качкан, юлдан, сездән, баштан, эштән, урамнан, бәйрәмнән.*

Җанлы һәм җансыз, гади һәм кушма кушымчаларның җыйналып беркадәр тәртипкә салынган барлык запасын түбәндәге таблицаларда күрсәтәм.

**Күп авазлы һәм катлаулы кушымчалар:**

ачак-эчәк = а + чак, ә +чәк
(ячак-ячәк)
арта-әртә
арга-әргә=ар + га, әр + гә
арка-әркә
әзә
асы-әсе = а + сы, ә + се
(ыйсы-исе = ый + сы, и + се)
ага-әгә
әксә = әк + сә
алак-әләк = ал + ак, әл+ әк
давык-ләвек = да + вык...
дырык-дерек = дыр + ык...
ртын-ртен
рка -ркә
сана-сәнә = сан +а...
сыра-серә = сы + ра...
штыр-штер = ш + тыр...
шкы=ш + кы
шлый-шли = ш + лый
гача-гәчә = га +ча...
гары-гәре
кары-кәре
гала-гәлә
кала-кәлә
галы-гәле
калы-кәле
ганчы-гәнче = ган + чы

әмсә = әм+ сә
амык-әмек
ана-әнә
анак-әнәк
авык-әвек
бәзәк
быра-берә = бы + ра, бе + рә
тыбы
җыра-җерә =җы + ра =җе+рә
чкы
лты
лда-лдә
лдык-лдек= лды +к...
лҗым-лҗем = л + җым
маза = ма + за
мача = ма +ча
макчы-мәкче =мак + чы...
мага-мәгә = ма (к)
малы-мәле = ма + лы
мавык-мәвек
мта-мтә (мты–мте) =м + та
мтык-мтек = м + тык...
мсыра-мсерә = м + сы + ра...
мса-мсә = м + са...
мсак-мсәк = м + са + к
мышлый-мешли = мыш + лый...
мышлы-мешле=мыш+лы...

| | |
|---|---|
| канчы-кәнче = кан + чы... | млы-мле = м + лы... |
| клә | мыйча-мичә = мый + ча... |
| гылт-гелт | (мыйчы-миче) |
| кылт-келт | мыный-мени = ме + ни... |
| кылтым-келтем = кыл+тым... | нты-нте (нта-нтә) = н + ты... |
| гына-генә = гы + (н) а... | нчы-нче |
| кына-кенә | нча-нчә =н +ча... |
| гыра-герә = гы + ра | нда-ндә |
| гырау-герәү = гы + рау | ндый-нди (ндай–идәй) |
| гыры-гере = гыр + ы... | нды-нде |
| ңгы-ңге = ң (н) + гы... | нкы-нке = н + кы... |
| лата-ләтә = ла + та... | нкыра-нкерә = н + кы + ра... |
| ләшкә | ныкы-неке = ның + кы– |
| лавык-ләвек = лав + ык... | нең + ке |
| лта-лтә | |

## Кушымчаларны төркемләү

Хәзер без кушымчаларны, нинди төп-тамырларга ялгануларына карап, төркемләргә керешәбез. Кушымчалар безнең телебездә бик зур урын тоталар. Алар бездә шактый күп (24 табл.).

Төрле төп-тамырларга ялгану мәсьәләсендә кушымчаларның бары да бертигез түгелләр. Кайбер кушымчалар барлык төп-тамырларга диярлек ялгана алалар, кайберләре исә тик мәгълүм сүз төркемнәренә генә, мәсәлән, фигыльләргә яки исемнәргә генә ялгана, ә кайберләре исә мәгълүм бер сүз төркеменең дә билгеле формаларына гына ялгана ала. Төрле төп-тамырларга, төрле формадагы сүзләргә кушымчалар ялгап карау тәҗрибәләре ясаганда, бик кызыклы фактлар ачыла. Кушымчаларның бер тамырга ялгыз берәве генә кушылганы кебек, берничәсе янәшә килеп кушылулары да бар. Мәгълүм кушымчалар мәгълүм төпләргә, берсе артыннан берсе ныклы бер тәртип һәм һәркайсы үз урынында килеп кенә ялгана. Шуның белән бергә, мәгънәләре ягыннан бер-беренә якын һәм функциональ рольләре буенча бердәйрәк кушымчалардан гадәттә берсе генә килеп, билгеле бер урын ала.

Кушымчаларның менә шушы үзенчәлекләре аларны төгәленчә классификацияләргә һәм дөрес төркемләргә мөмкинлек бирә.

Татар телендәге кушымчалар башта ике зур төркемгә бүленәләр: 1) уртак-гомуми кушымчалар, 2) хосусый кушымчалар.

Уртак кушымчалар гадәттә сүзнең иң азагында, барлык кушымчалардан соң киләләр. Алар төрләнүче һәм төрләнмәүче (төрләнү бу урында шартлы рәвештә генә алына) сүзләр соңында да килә алалар. Уртак кушымчаларның бүтән кушымчалардан аермасы – мөстәкыйль басымлы булуда. Мәсәлән: *ул гына, син генә, баргач ук, килгәч үк, юк ла, бетте лә, яхшырак, эшлерәк, барырмын, килерсең, табарсың, кайткандыр, килдеме, алдымыный...* сүзләрендәге *гына-генә, ук-үк, ла-лә, рак-рәк, мын, сең, сыз, дыр, ме, мыный* һ. б. кебек.

Хосусый кушымчаларны, аларның билгеле төп-тамырларга һәм бүтән кушымчаларга мөнәсәбәтләрендәге уңай һәм кире билгеләренә ка-

# Бер, ике, өч авазлы гади кушымчалар

*24 таблица*

| а-ә-<br>ы-е | п+<br>ып-<br>еп | ат-әт<br>ыт-ет-т | ач-әч<br>ыч-еч | ар-әр<br>ыр-ер | аз-әз<br>ыз-ез | әс<br>- | аш-әш<br>ыш-еш | ак-әк<br>ык-ек-е | н-ың-ең | ал-әл<br>ыл-ел-л | ам-әм<br>м-ым-ем | ан-ән<br>ын-ен-н | ау-әү<br>у-ү | ай-әй<br>ый-и<br>(әй) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| би-пе | | -бәт | | быр-бер | быз-без | | | | | | | | | |
| та-тә<br>ты-те | - | - | - | тар-тәр<br>тыр-тер | - | тәс | таш-тәш<br>- | так-тәк<br>тык-тек | - | тәл | -<br>тым-тем | тан-тән<br>тын-тен | - | тай-тәй<br>(тый-ти) |
| ча-чә<br>чы-че;<br>же | - | - | - | - | - | - | - | чак-чәк<br>чык-чек | - | -<br>чыл-чел | -<br>чым-чем | чан-чән<br>чын-чен | -<br>чү | -<br>чи |
| да-дә<br>ды-де | - | - | - | дар-дәр<br>дыр-дер | - | - | даш-дәш | дак-дәк<br>дык-дек | дың-<br>дең | - | -<br>дам-дәм<br>дым-дем | дан-дән<br>-<br>дын-ден | - | дай-дәй<br>дый-ди |
| ра-рә | - | - | - | - | - | - | - | рак-рәк<br>рык-рек | - | - | - | - | - | рый-ри |
| за-зә | - | - | - | - | - | - | - | зык-зек | - | - | - | - | - | - |
| са-сә<br>сы-се | - | сәт<br>сыт-<br>сет | - | сар-сәр | сыз-сез | - | - | сак-сәк | саң-сәң<br>сың-<br>сең | -<br>сыл-сел | сам-сәм<br>сым-сем | сән<br>сын-сен | -<br>су-сү | - |
| ша-шә<br>шы-<br>ше | - | - | - | шар-<br>шәр<br>шыр-<br>шер | - | - | - | шак-шәк<br>шык-<br>шек | - | -<br>шыл-<br>шел | - | шән-<br>шын-<br>шен | - | - |
| га-гә<br>гы-ге | - | - | гач-гәч<br>гыч-геч | гар-гәр<br>гыр-гер | гәз<br>гыз-гез | - | - | гак-гәк<br>- | - | гал-гәл<br>гыл-гел | -<br>гым-гем | ган-гән<br>гын-ген | - | гай-гәй<br>гый-ги |
| ка-кә<br>кы-ке | - | - | кач-кәч<br>кыч-кеч | кар-кәр<br>кыр-кер | каз-кәз<br>кыз-кез | - | кәш<br>кыш-кеш | как-кәк<br>- | - | -<br>кыл-кел | -<br>кым-кем | кан-кән<br>кын-кен | - | кай-кәй |
| ңа-ңә | - | - | | (ңар-ңәр) | (ңыз-ңез) | - | - | - | - | - | - | - | - | - |
| ла-лә<br>ды-ле | лап-<br>ләп<br>- | лат-<br>ләт<br>- | лач-ләч | лар-ләр<br>- | - | - | лаш-ләш<br>лыш-леш | лак-ләк<br>лык-лек | - | - | лам-ләм<br>- | лан-лән<br>- | лау-<br>ләү<br>- | лай-ләй<br>лый-ли |
| ма-мә<br>мы-ме | - | мат-<br>мәт<br>- | мач-<br>мәч<br>- | -<br>мыр-мер | маз-мәз<br>мыз-мез | мас-<br>мәс<br>- | маш-мәш<br>мыш-<br>меш | мак-мәк<br>мык-мек | - | мал-мәл<br>мыл-мел | - | ман-мән<br>мын-мен | - | май-мәй<br>мый-ми |
| на-нә<br>ны-не | - | - | -<br>ныч-<br>неч | нар-нәр<br>- | - | - | - | нәк-нәк<br>нык-нек | -<br>ның-<br>нең | - | - | нан-нән<br>- | - | - |
| - | - | - | - | выч-веч | - | - | выш-веш<br>үш-үш | вык-век<br>ук-үк | - | -<br>выл | - | - | - | - |
| - | - | - | - | - | - | - | | ыйк-ик<br>екъ-ек | - | - | ыйм-им<br>(ем) | - | - | - |

рап, өч төркемгә бүләргә мөмкин: 1) фигыльлекләр, 2) исемлекләр, 3) рәвешлекләр.

Үзләреннән алдагы һәм азактагы морфологик элементлар белән кушыла алу-алмауларына карап, болар һәркайсы тагын вак төркемчәләргә бүленәләр. Мәсәлән, фигыльлекләр үзләре өч төркемчәгә бүленә: 1) саф-фигыльлекләр: *ды, сын, ый-и, са-сә, а-ә* һ. б.; 2) фигыльлек-рәвешлекләр: *ып-еп, гач-гәч, ганчы-гәнче, мыйча-мичә, ышлый-ешли* һ. б.; 3) фигыльлек-исемлекләр: *ган-гән, ачак-әчәк, асы-әсе, ар-әр* һ. б.

Исемлек кушымчалар ике төркемчәгә бүленәләр: 1) уртак-гомуми исемлекләр: *лар-ләр, ның-нең, га-гә, ны-не, дан-дән, да-дә, ы-е, ың-ең, ым-ыбыз*... һ. б. 2) Хосусый исемлекләр. Болары тагын саф исемлекләр, сыйфатлыклар, санлыклар, урын-вакытлыклар һәм алмашлыклар дигән төркемчәләргә бүленәләр.

Бу әле кушымчаларны горизонталь сызык буенча төркемләү була. Алдарак без аларны вертикаль сызык буенча да тикшерәбез. Ул чакта без кушымчалар белән тагын да якынрак танышырбыз һәм икенче сызыкта төркемләү килеп чыгар.

### Кушымчаларның тәртибе

Югарыда күрсәтелгән төркем һәм төркемчәләрдәге кушымчаларның бер үк тамырга берәве генә яки берничәсе рәттән килеп кушылырга да мөмкин. Бер тамырга берничә кушымча ялганганда, югарыда әйткәнемчә, алар бер-бер артлы, ныклы механик бер тәртиптә тезелеп килергә тиеш. Аларның урыннарын алмаштыру мөмкин булмый. Әгәр мәгънә ягыннан бер-беренә якын кушымчаларның берсе мәгълүм урында килгән икән, бу группадагы икенче бер кушымчаны инде китереп кертеп булмый. Кирәк булса, андый кушымчалар бер-берсен алмаштырып кына килергә мөмкин, кирәк булмаса, аларның урыны ачык калып тора. Шулай итеп, мәгълүм төркем кушымчалар арасында урыннар бүленгән, һәр кушымчаның урыны билгеле, һәм алар, арифметик саннардагы кебек, механик тәртиптә тезелеп киләләр (25 табл.). Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| *язышмаганнардыр* | *кешеләрегездән генәме?* |
| *яз – маганнардыр* | *кеше – гездән генәме?* |
| *языш – каннар –* | *кешеләр – дән генәме?* |
| *яз – – ганнардыр* | *кешеләрегездән – ме?* |
| *яз – –ган – дыр* | *кешеләр – дән генә –* |
| *яз – – ган – –* | *кешеләр – – генә –* |
| *яз – ма – – –* | *кеше – – – – ме?* |

Ләкин кушымчаларның бу үзенчәлекләрендә кайбер чыгармалар да очраштыргалый. Алдарак ул турыда да әйтербез әле.

Тоткан урыннарына, үтәгән хезмәтләренә һәм кушылу тәртипләренә карап, мин татар телендәге кушымчаларны вертикаль сызыкта түбәндәге өч төркемгә бүлүне методологик яктан максатка мовафыйграк дип саныйм:

1) **Сүз ясаучы кушымчалар** (ясагычлар – суффикслар). Болар аерым морфемаларга аерылмый торган, даимирәк төп сүзләргә тамыр кисәкнең артыннан ук беренче чиратта килеп кушылалар. Бу кушымчалар күп кенә очракларда «үлекләнгән» булалар һәм, нинди тәртиптә кушылуларына карап, ике рәт тәшкил итәләр. Беренче рәттә төрле тамыр сүзләрдән бөтенләй яңа сүз ясаучы саф ясагычлар, ә икенче рәттә дәрәҗәлекләр, ягъни фигыльләрдә юнәлеш, исемнәрдә иркәлек, кечелек, сыйфатларда сыйфат дәрәҗәләре ясауга хезмәт итә торган кушымчалар килә.

Сүз ясаучы кушымчалар, мәгълүм сүз төркемнәренә һәм мәгълүм төп-тамырларга гына кушылып, икенче төрле суз ясыйлар. Һәр сүз төркеме өчен махсус кушымчалар бар. Шундый ясагычлар ярдәме белән дүрт төрдә ясалма сүзләр барлыкка килә.

а) ясалма фигыльләр. Болар *ла-лә, ра-рә, ай-әй, а-ә, ы-е, лда-лдә* һ. б. кушымчалар ярдәме белән ясалалар. Мәсәлән: *ташла, эшлә, очра, иңрә, матурай, шәбәй, аша, яшә, ныгы, уфылда, чәрелдә* һ. б.

б) ясалма исемнәр. Болар *лык-лек, кыч-кеч, гыч-геч, ма-мә, ым-ем-м, ыш-еш-ш* һ. б. кушымчалар ялгану белән ясалалар: *матурлык, яшьлек, ачкыч, элгеч, алма, бүлмә, алым, бирем, ярыш, кереш* һ. б.

в) ясалма сыйфатлар. Болар *лы-ле, сыз-сез, кы-ке, гы-ге, ык-ек, ынкы-енке, ныч-неч, чы-че, ынчы-енче, шар-шәр* һ. б. кушымчалар ярдәме белән ясалган була: *атлы, эшле, язгы, көзге, кышкы, юлсыз, эзсез, ачык, сүтек, сузынкы, күтәренке, эчке, тышкы, аяныч, сөенеч, унынчы, беренче, икешәр, алтышар...*

г) ясалма рәвешләр. Болар *лата-ләтә, лай-ләй, тын-тен, ын-ен* һ.б. кушымчалар ялгау белән ясалалар. Мәсәлән: *акчалата, икеләтә, тегеләй, болай, якынтын, яшертен, кышын, көзен...*

Шулай итеп, беренче рәт ясагычларын, нинди төп-тамырларга ялгануларына һәм нинди сүз төркеме ясауларына карап, фигыльлекләр, исемлекләр, сыйфатлыклар, санлыклар, рәвешлекләр, алмашлыклар, ымлыклар һ. б. дигән төркемчәләргә бүләргә мөмкин.

Югарыда әйткәнебезчә, ясагыч кушымчалар теләсә нинди сүз төркеменә һәм теләсә нинди төп-тамырга ялгана алмыйлар. Менә бу күрсәтелгән дүрт төркем ясалмалар мәгълүм сүз төркемнәреннән һәм махсус кушымчалар ярдәме белән генә ясалдылар. *Таш, куз* дигән исемнәрдән *ылда-елдә* яки *ай-әй* кушымчалары ялгау белән фигыльләр ясап булмый, ә бәлки *ла-лә* кушымчалары белән генә ясарга мөмкин. Мәсәлән, *ташла, кузлә*; *ылда-елдә* кушымчалары белән ымлыклардан гына, *ай-әй*ләр белән исә сыйфат һәм рәвешләрдән генә фигыльләр ясала. Мәсәлән: *шарылда, безелдә, ныгай, кубәй* һ. б.

Бер үк сүздә ясагыч кушымчаларның берничәсе янәшә килергә һәм, шулай итеп, сүз кат-кат ясалма булырга мөмкин. Мәсәлән, ясалма фигыльдән ясалма исемнәр яки ясалма сыйфатлар, һәм киресенчә

дә, ясалырга мөмкин: *таш – ташла – ташлагыч; эл – элгеч – элгечлә; акыл – акыллы – акыллылык* һ. б.

Фигыль юнәлешләре һәм дәрәҗәлек кушымчалары, беренче рәттә килә торган саф ясагычлардан соң килеп, 2 нче рәттә урын алалар. Болар фигыльләрдә юнәлеш, исем һәм сыйфатларда дәрәҗәләр ясауга хезмәт итәләр. Мәсәлән: *яздыр, ашат, эшләш, әлсерә, алынкыра, килгәлә*... фигыльләрендәге *дыр, т, ш, серә, ынкыра, гәлә*... кушымчалары; *балакай, кешекәй, кошчык, төерчек*... кебек исемнәрдәге *кай-кәй, чык-чек* кушымчалары; *сарырак, яшелрәк*... сыйфатларындагы *рак-рәк* һ.б. кушымчалар кебек (кайбер сыйфатларда кимлек дәрәҗәсе ясый торган *кылт-келт-гылт, сыл-сел, кылтым-келтем, лҗым-лҗем, су-сү*... кебек кушымчалар беренче рәттә үк киләләр).

Фигыльләрдәге 2 нче рәт юнәлеш кушымчалар, гомуми кагыйдәгә каршы буларак, берничәсе янәшә килергә дә мөмкин. Мәсәлән: *яздыргала, тарткалаштыргала, әйттерткәләш, күрсәтенкерәттер* һ. б.

Бу урында тагы бер факт турында искәртеп үтәргә кирәк: составында сүз төрләндерүче кушымчалары булган сүзләрнең кайбер формалары «үлекләнә»ләр һәм яңа ясалмалар өчен төп нигез булып хезмәт итәләр. Мәсәлән: *ның-нең* (иялек килеше формасы) һәм *да-дә*... (урын- вакыт килеше формасы) кушымчаларына беткән сүзләргә *кы-ке-гы-ге* ясагычлары ялгап сыйфатлар ясала: *авылныкы (авылның+кы), шәһәрнеке (шәһәр+нең+ке), авылдагы, үзегездәге*... Шулай ук *ча-чә* (чагыштыру килеше формасы) кушымчаларына беткән сүзләргә *ла-лә* кушымчалары ялгап фигыльләр ясалырга мөмкин: *татарчалаштыр, французчалап* һ. б. Мондый кабат ясалулардан мәгънәләре ягыннан катлаулы һәм аваз составлары ягыннан артык җәенкеләнгән сүзләр килеп чыга. Мәсәлән: *авылдагыларныкылырыгыздан, үткәндәгерәкләрегезнекеләрне genә*...

2) **Сүз төрләндерүче кушымчалар** (төрләндергечләр – окончания = бетемнәр). Болар, сүз ясаучы кушымчалар белән бергә килгәндә, ясагычлардан соң 2 нче рәттә килеп ялганалар.

Сүз төрләндерүче кушымчалар, нинди сүз төркемнәренә кушылуларына карап, горизонталь сызыкта ике төркемчә – фигыль төрлекләре һәм исем төрлекләре дигән төркемнәргә, ә вертикаль сызыкта, ягъни һәркайсы нинди тәртиптә килеп кушылуларына карап, өч катарга – рәткә (кушымчаларның гомуми тәртибендә 3 нче, 4 нче һәм 5 нче рәтләр) бүленәләр. Ясаучы кушымчалар булмаганда, бу кушымчалар тамыр кисәкләргә турыдан-туры да килеп кушылалар.

Фигыль төрлекләре: а) юклык кушымчалары (*ма-мә*), б) заман кушымчалары һәм в) саф фигыльләрнең хәбәрлек формасы булган зат кушымчалары. Юклык кушымчалары, (*ма-мә*) 3 нче рәттә килеп ялганалар һәм тамырның басымын үзләренә үткәрмиләр (тик исем фигыльләрнең киләчәк заман формасындагы юклык кушымчалары гына басымны үзләренә алалар: *килмәс, килмәсләр, килмәмен, килмәссең*...).

Заман кушымчалары 4 нче рәттә килеп ялганалар һәм, үзләреннән соң килә торган зат кушымчаларына карап, өч төркемчәгә бүленәләр:

1) саф фигыльләрдәге заман кушымчалары. Болар зат кушымчалары белән бергә генә йөриләр, зат кушымчаларыннан башка кулланылмыйлар. Боерык фигыльләрдәге *ый (м)-и (м), ый (к)-и (к), сын-сен*, үткән заман фигыльләрендәге *ды-де, ты-те*, шарт фигыльләрендәге *са-сә* һәм хәзерге заман фигыльләрендәге *а-ә, ый-и* кушымчалары кебек.

2) Хәл фигыльләрендәге заман кушымчалары. Болар зат кушымчалары белән сыеша алмыйлар һәм зат кушымчалары белән бергә килмиләр. Мәсәлән: *ып-еп-п, мыйчы-миче (мыйча-мичә), гач-гәч-кач-кәч, ганчы-гәнче..., ышлый-ешли* кушымчалары кебек.

3) Исем фигыльләрдәге заман кушымчалары. Болар зат кушымчалары белән дә, исем төрлекләре белән дә, хәтта кайбер ясагычлар белән дә бергә килә алалар. Мәсәлән: *ган-гән, кан-кән, ачак-әчәк (ячак-ячәк), ар-әр, ыр-ер-р, (ма)* с кушымчалары кебек.

Саф фигыльләрнең хәбәрлек формасы булган зат кушымчалары, бүтән төрләрдәге кушымчалар (ясагычлар һәм төрләндергечләр) булганда, 5 нче рәттә килеп урын алалар: *килдем, алыйк, белсәк, укыгыз, килдегез, күрсәләр, әйтмиләр...* фигыльләрендәге *м, к, гыз, гез, лар-ләр...* кушымчалары кебек. Бу формалар исем фигыльләрендә килми, ә хәл фигыльләре исә зат кушымчаларын бөтенләй кабул итмиләр.

Исем төрлекләре: а) күплекне күрсәтүче *лар-ләр-нар-нәр* (3 нче рәттә киләләр). Мәсәлән: *кешеләр, атлар, балакайлар, бүлмәчекләр...* б) тартым кушымчалары (4 нче рәттә киләләр): *атым, атасы, балакайлары, иптәшләрегез, юлдашкаем...* сүзләрендәге... *ым, сы, ы, гез...* кушымчалары кебек, в) килеш кушымчалары (5 нче рәттә киләләр): с*езнең, малкайларга, балакайларымны, иптәшләрегездән, авылларыгызда, бабаларыбызча, күргәннәрегездәй...* сүзләрендәге *нең, га, ны, дән, да, ча, дәй...* кушымчалары кебек.

Кушымчалар арасында иң күп кулланыла, торганнары – сүз төрләндерүче кушымчалар, алар жанлылар һәм безнең телебездә ачык беленеп торалар.

Исем төрлекләре арасында тик *ча-чә* һәм *дай-дәй-тай-тәй* кушымчалары гына басымны үткәрмиләр. Кайчакта юнәлеш килеше кушымчалары (*га-гә-ка-кә, на-нә-а-ә*) соңында тагын өстәмә кушымчалардан *ча-чә* кушымчалары ялганып килергә мөмкин. Мәсәлән: *авылгача, шәһәргәчә, туган көненәчә...* Мондагы *ча-чә* кушымчалары да басымны үзләренә алмыйлар, ләкин боларның мәгънәләре һәм килеп чыгышлары башка (болар *чаклы-чикле* сүзләреннән килә). Сыйфатлар, саннар, алмашлыклар һәм исем фигыльләр (сыйфат фигыльләр), үз функцияләрендә килгәндә, 3 нче, 4 нче һәм 5 нче рәттәге исем төрлекләре белән төрләнмиләр. Әгәр, сыйфатланмышлары яки саналмышлары төшеп, үзләре исем урынында килсәләр, болар да исем төрлекләре белән төрләнәләр.

3) **Өстәмә кушымчалар**. Бездә өстәмә кушымчалар алмаган сүзләр юк диярлек. Болар теләсә нинди сүзгә, кушымчалар системасында, иң азаккы чиратта килеп тоташалар. Өстәмә кушымчалар: *кына-кенә-гына-генә, ук-үк, ла-лә, дыр-дер-тыр-тер, мы-ме* һ. б. Боларның зур күпчелеге барлык сүз төркемнәре өчен уртак диярлек. Болар төп-тамырдагы басымны кабул итмиләр, чөнки үзләрендә басым бар. Шундый ук үзенчәлекләргә ия булган һәм фигыльләргә ялганып йөри торган *сана-сәнә, чы-че* кушымчаларын һәм үзләренә басымны да үткәрә торган *рак-рәк* кебек кайбер хосусый кушымчаларны да өстәмә кушымчалардан санарга туры килә. Чөнки болар, мәгънәләре, үтәгән хезмәтләре һәм нинди тәртиптә килүләре ягыннан, өстәмә кушымчаларга бик якын торалар.

Вертикаль сызык буйлап караганда, өстәмә кушымчалар үз нәүбәтендә өч төркемгә бүленәләр һәм, барлык кушымчалар системасында алганда, 6 нчы, 7 нче һәм 8 нче рәтләрдә киләләр:

а) билгеләгечләр (төгәлләүче, чикләүче өстәмәләр): *кына-кенә–гына-генә, ук-үк, рак-рәк*. Мәсәлән *укытучыларыгызга гына, сез генә, Казанда ук, күргәнегездәй үк, авылларыгызданрак, килебрәк*... (*рак-рәк* кушымчалары икенче рәттә үк тә килергә мөмкин: кызылракларын, пешкәнрәкләрегездәнрәк һ. б.);

б) хәбәрлекләр: *мын-мен, быз-без, сыз-сез, лар-ләр* (ул – алар). Хәбәрлек кушымчалары, саф фигыльләрдән һәм хәл фигыльләрдән башка, җөмләнең хәбәре булып килгән теләсә нинди сүзгә дә кушыла алалар. Мәсәлән: *укучымын, барганмын, дәртлемен, тегендирәксез, белермен, комсомоллардандбыз, пионерсың, алар шәпләр* һ. б.;

в) очлыклар: *дыр-дер-тыр-тер, ла-лә, да-дә, мы-ме–мыный-мени, чы-че, сана-сәнә* һ. б. Болар бөтен кушымчалардан соң сүзнең иң очында – азагында әйтеләләр. Өстәмә кушымчаларның башкалары белән бергә килгәндә, болар 3 нче рәттә киләләр: *килгәндер, күрмәдем лә, барсана, килсәгезче, барганнармы, үйларыгызда гына да, шәп кенәсезме*?...

Монда бер искәрмә ясап үтүне тиешле табам: кайбер өстәмә кушымчаларның нинди тәртиптә килүе һәм үзара сыешу-сыешмауларында телебездә кайбер икеләнүләр-тирбәлүләр бар. Мәсәлән: *исәнмесез* (исәнсезме)? *күрәмесең* (күрәсеңме)? *юктырсың ла* (юксындыр ла), *бармыдыр* (бардырмы)? һ. б.

Бу мисаллардан күренә ки, хәбәрлек-затлык кушымчалары белән сорау кушымчасы, шулай ук икеләнү яки борчылу аңлата торган кушымчалар (*дыр-дер..., ла-лә*) бергә килгәндә, кайбер төрләрнең тәртибендә алмашу-күчешү булырга мөмкин икән. Ләкин кайбер төрләрдә генә шулай. Мәсәлән, *исәнмесез, беләмесең* рәвешендә сөйләнсә дә, *исәнмеләр, беләмебез* төрендә сөйләү юк. Шунлыктан гомумән кушымчаларның, шул җөмләдән өстәмә кушымчаларның да, нинди тәртиптә килүләре турында югарыда сөйләнгән кагыйдәләр үз көчләрендә кала.

Менә шушы 8 рәт булып килә торган кушымчалар белән татар теленең

морфологик төзелеше тәмамлана. Бу кушымчалар, югарыда күрсәтелгән тәртиптә, күбесенчә бер иҗекле төп-тамырларга ялганалар. Кайчакта бер үк рәтнең кушымчалары янәшә берничә дә (мәсәлән, фигыльләрдәге юнәлеш кушымчалары) килергә мөмкин. Ә кайчакта исә һәр рәтнең кушымчалары кабат-кабат ялганып, күп иҗекле берничә басымлы һәм мәгънәсе ягыннан да гаять катлаулы озын сүзләр ясала. Мондый сүзләрне икенче телдә бер генә сүз белән бирү һич мөмкин түгел.

**Кушымчаларның нормаль тәртибе һәм төркемнәре**

*25 таблица*

<table>
<tr><th colspan="2" rowspan="3">Төп тамырлар</th><th colspan="8">Кушымчалар (тәртип һәм төркемнәре)</th></tr>
<tr><th colspan="2">Сүз (нигез) ясаучылар</th><th colspan="3">Сүз төрләндерүчеләр</th><th colspan="3">Өстәмә (уртак) кушымчалар</th></tr>
<tr><th>1</th><th>2</th><th>3</th><th>4</th><th>5</th><th>6</th><th>7</th><th>8</th></tr>
<tr><td rowspan="5">кечәйткеч кисәкчәләр</td><td rowspan="2">фигыль</td><td rowspan="2">исемнәрдән сыйфатлардан ымлыклардан һ.б.</td><td rowspan="2">фигыль юнәлешләре</td><td rowspan="2">юклык</td><td>саф фиг. хәл фиг.</td><td>зат –</td><td rowspan="5">билгеләгечләр (төгәлләүче, чикләүче өстәмәләр)</td><td rowspan="2"></td><td>саф</td></tr>
<tr><td>исем фиг.</td><td>–</td><td rowspan="4">очлыклар</td></tr>
<tr><td>исем</td><td>фигыльләрдән сыйфатлардан саннардан һ.б.</td><td>иркәлек, кечелек, кимсетү</td><td>күплек саны</td><td>тартым</td><td>килеш</td><td rowspan="2">хәбәрлекләр–затлыклар</td></tr>
<tr><td>сыйфат</td><td>исемнәрдән фигыльләрдән саннардан сыйфатлардан ур.-вакыт сүзләреннән алмашлыктан һ.б.</td><td>иркәлек, чагыштыру, кимлек</td><td>–</td><td>–</td><td>–</td></tr>
<tr><td>рәвеш</td><td>алмашлыклардан ур.-вакыт сүзләреннән исемнәрдән исем фигыльләрдән</td><td>чагыштыру</td><td>–</td><td>–</td><td>–</td><td>–</td></tr>
</table>

# Нәтиҗәләр

Телебездәге кушымчаларның табигатен ныклап өйрәнү аркасында, телебезнең мәктәп грамматикасын һәм гыйльми грамматикасын тагын да ныклырак һәм гыйльмирәк нигезгә куя алабыз. Грамматикаларыбызда әлегә кадәр чишелмәгән мәсьәләләр һәм күп кенә бәхәсле моментлар бар. Мәсәлән: морфологик элементларны билгеләү, сүзләрне төркемләү, фигыль юнәлешләре, килешләр турындагы мәсьәләләр, ниһаять, телебезне укыту методикасын дөресрәк, рациональрәк системага кую кебек мәсьәләләр. Бу мәсьәләләрне, яки алардан берничәсен генә булса да чишү телебезнең ялганмалык табигатен өйрәнүгә бәйләнгән. Мин биредә шушы мәсьәләләрнең кайберләрен чишәргә тырышып карыйм.

**Морфологик элементлар.** Бу мәсьәләне ике яктан карап чишәргә мөмкин: телебездәге морфологик элементларның барлык запасын тышкы (формаль) яктан да, эчке яктан да тикшереп чыгу максат ителәме? Әллә күп формалы аерым сүзләрнең составына кергән морфологик элементларны гына формаль яктан аеру максат ителәме?

Беренче хәлдә без телебездә түбәндәге элементларны табабыз:

1) Гади төп-тамырлар (ялгыз сүзләр). Мәсәлән: *кеше, ат, кил, яз* һ. б.

2) Тагылмалы төп-тамырлар (тагылмалы сүзләр). Мәсәлән: *хатын-кыз, бала-чага, фәлән-төгән, җир-су, ут-күз* һ. б. Тагылмалы сүзләрнең гармония ягыннан бер-берсенә буйсынулары мәҗбүри түгел, ә мәгънә ягыннан исә алар икәве гомуми бер төшенчә белдерәләр.

3) Предлог тамырлар. Болар – гармонияләре ягыннан мөстәкыйль, ләкин үзбаш мәгънәләрен югалткан сүзләр. Мәсәлән: *иң, чом, дөм, шыр...* кебек, икенче сүзләрнең алдында килеп, аларның мәгънәләрен көчәйтү өчен хезмәт итүче сүзләр.

4) Послелог тамырлар. Болар да, гармонияләре ягыннан мөстәкыйль булып, үзбаш мәгънәләрен югалтканнар. Ләкин болар тулы мәгънәле сүзләрдән соң киләләр: *өчен, белән, кебек, таба* һ. б.

5) Тулы мәгънәле сүз булып та, ярдәмлек сүз булып та йөри торган сүзләр. Мәсәлән: *аркылы, әле, күрә, үтә, аша, соң* һ. б.

6) Үзләренең басымнарын саклаучы кушымчалар яки ярым кушымчалар: *кына-кенә-гына-генә, дыр-дер..., мы-ме..., сың-сең, мын-мен, ча-чә, дай-дәй..., ма-мә* һ. б.

7) Чын кушымчалар (гармония ягыннан да, басым ягыннан да мөстәкыйль түгелләр): *дан-дән-тан-тән-нан-нән, ны-не, да, дә..., ган-гән..., ы-е, лар-ләр...* һ. б.

8) Морфемалар арасындагы бәйләвеч элементлар. Мәсәлән: *языла, сүзенчә, баласы, күрмәячәк (күрмәйәчәк)* сүзләрендәге *и, е, и, с, й* элементлары кебек.

9) Артыклык сыйфатлары алдында килә торган кисәкчәләр. Мәсәлән: *кап-кара, туп-туры, сип-сирәк* һ. б.

Икенче хәлдә, ягъни күп морфемалы аерым сүзләр составындагы морфологик элементларны табуны гына максат итеп алганда, без түбәндәгечә аерабыз:

1) Тамыр кисәкләр. Сүз төркеме булып тикшерелә торган гади, кушма һәм тагылмалы тамыр сүзләр дә, шулай ук предлог һәм послелоглар да шуңа керәләр.

2) Тамыр кисәктән соң килеп ялгана торган кисәкләр – кушымчалар. Болар фонетик яктан мөстәкыйль түгелләр. Чын кушымчалар да, ярым кушымчалар да (өстәмә кушымчалар) шунда керәләр. Боларны детальләп төркемләү – морфология эше.

3) Артыклык сыйфатлары алдында килә торган кисәкләр.

**Морфологик элементлар таблицасы**

<table>
<tr><td colspan="3">Тамыр кисәкләр</td><td colspan="3">Кушымчалар</td><td rowspan="3">артыклык сыйфатлары алдында килә торган кисәкчәләр</td></tr>
<tr><td rowspan="2">тагылмалы</td><td rowspan="2">кушма</td><td rowspan="2">гади</td><td colspan="2">чын кушымчалар</td><td rowspan="2">ярым кушымчалар (үзләренең басымнарын саклаган кушымчалар)</td></tr>
<tr><td>сүз ясаучылар</td><td>сүз төрләндерүчеләр</td></tr>
</table>

**Сүзләрне төркемләү.** Монда телдәге сүзләрнең бөтен запасы күздә тотылырга тиеш. Сүзләрне, саф эчке мәгънәләренә карап, логик принцип буенча яки, нинди кушымчалар алу-алмауларына карап, формаль принцип буенча төркемләргә мөмкин.

Билгеле, сүзләрнең мәгънәләре белән формалары арасында тыгыз бәйләнеш бар. Форма һәм гомумән телнең аваз ягы безне мәгънәгә юнәлдерә, мәгънәләрнең күрсәткече булып тора. Шуңа күрә сүзләрне төркемнәргә бүлүдә мин аларның нинди кушымчалар белән килү үзенчәлекләренә карап эш итәм. Сүзләрне төркемләү, ягъни формаль яктан сүз төркемнәрен билгеләү, асылда, нинди кушымчалар белән килүләрендәге аерымлыкларга карап, төп-тамыр сүзләрне төркемләүгә кайтып кала.

Беренче чиратта сүзләрнең төрләндерүче кушымчалар алу-алмауларына игътибар итәргә кирәк. Төрләндерүче кушымчаларны алу-алмауларына карап төркемләгәндә, түбәндәге төркемнәр килеп чыга:

1) **Төрләнүче сүзләр.** Болар үз эчләрендә тагын ике төркемгә бүленәләр: а) фигыльләр, б) исемнәр. Бу төркемнәрдәге сүзләр, үз функцияләрендә килгәндә, мәгълүм төрләндергечләр белән төрләнәләр.

2) **Төрләнмәүче сүзләр.** Болар исә, үз функцияләрендә килгәндә, сүз төрләндерүче кушымчаларны кабул итмиләр.

Бу билгеләр буенча эш иткәндә, телебездәге төп-тамырларны баштан ук өч төркемгә бүләргә мөмкин: 1) фигыльләр, 2) исемнәр, 3) төрләнмәүче сүзләр.

Барлык фигыль кушымчалары, мәсәлән, заман, зат, юклык (ма-мә) һәм юнәлеш кушымчалары, фигыльлек билгеләре булып торалар. Фигыль билгеләре арасында иң күренеклесе һәм фигыльләр өчен иң характерлысы – заман кушымчалары. Барлык фигыльләр, һичбер чыгармасыз рәвештә, заман кушымчалары белән төрләнәләр һәм, шушы кушымчаларга карап, өч төркемгә бүленәләр: 1) саф фигыльләр, 2) хәл фигыльләре, 3) исем фигыльләр (сыйфат фигыльләр).

Юклыкны белдерүче *ма-мә* кушымчаларын фигыльлекнең характерлы билгесе итеп алуны җитәрлек дип тапмыйм, чөнки бу кушымчаларны алмый торган фигыльләр дә бар (хәл фигыльләренең кайбер формалары һәм ким фигыльләр юклык кушымчалары белән төрләнмиләр).

Сан, тартым һәм килеш кушымчалары, гомумән исемлек билгеләре булып торалар. Болар арасында исемнәр өчен иң характерлы булганы – килеш кушымчалары, чөнки кайбер исемнәр (мәсәлән, кайбер алмашлыклар һәм саннар) 3 нче һәм 4 нче рәтләрдә килеп ялгана торган сан һәм тартым кушымчаларын алмыйлар.

Исемнәр төркемен билгеләү өчен сүз төрләндерүче кушымчалар гына җитми. Моның өчен без сүз ясаучы кушымчалар белән дә файдаланабыз. Ул чакта түбәндәге исем төркемнәре килеп чыга:

1) Зат исемнәре (имена существительные). Болар 1 нче рәттә килеп ялгана торган *даш-дәш-таш-тәш, чы-че, сыз-сез* кушымчаларын кабул итәләр.

2) Сыйфат исемнәре (имена прилагательные). Болар *кып, нәп, ап...* кебек алгы якта килә торган көчәйткеч кисәкчәләрне кабул итәләр.

3) Сан исемнәре (имена числительные). Болар *ынчы-енче..., ар-әр-шар-шәр* кушымчаларын кабул итәләр.

4) Урын һәм вакыт исемнәре. Болар турыдан-туры *кы-ке-гы-ге* кушымчаларын алалар.

5) Алмашлыклар. Болар югарыда күрсәтелгән ясагыч кушымчаларны кабул итмиләр, фәкать килеш кушымчалары белән генә төрләнәләр.

Зат һәм сыйфат исемнәре билгеле ясагычлар ярдәме белән бүтән сүз төркемнәреннән дә ясала алалар.

Төрләнмәүче сүзләрдән бер төрлесе морфологик яктан ясаучы да, ясалучы да була ала. Болар – рәвешләр. Үзләренең туры мәгънәләрендә килгәндә, рәвешләр сүз төрләндерүче кушымчалар белән төрләнмиләр. Ләкин сүз ясаучы кушымчалар ярдәме белән алардан икенче төрле сүзләр ясарга һәм бүтән сүз төркемнәреннән үзләре дә ясалырга мөмкин.

Төрләнмәүче сүзләрдән булган ымлыклар үзләре бүтән сүз төркемнәреннән ясалмыйлар. Ләкин *лда-лдә, да-дә, ыра-ерә* кушымчалары ярдәме белән фигыль булып ясалулары мөмкин.

Төрләнмәүче сүзләрдән бер төркеме – ярдәмлекләр исә төрләнмиләр дә, ясалмыйлар да, ясамыйлар да.

Синтаксик үзенчәлекләренә, җөмләнең нинди кисәкләре белән һәм

нинди тәртиптә кулланылуларына карап, төрләнмәүче сүзләрне тагын да ваграк төркемчәләргә бүләргә мөмкин:

1) алда килүчеләр:
   а) фигыльләрдән алда (рәвешләр),
   б) исемнәрдән алда,
   в) сыйфатлардан алда (көчәйткечләр);
2) азакта килүчеләр (бәйлекләр);
3) теркәгечләр;
4) хәбәрлек кисәкчәләр һәм
5) грамматик бәйләнешсез сүзләр:
   а) ымлыклар,
   б) кереш кисәкчәләр.

## Морфология ягыннан сүз төркемнәре схемасы

*26 таблица*

| Төрләнүче сүзләр | | | | | | | | Төрләнмәүче сүзләр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| заман кушымчалары белән төрләнүчеләр – фигыльләр | | | килеш кушымчалары белән төрләнүчеләр – исемнәр | | | | | | | |
| саф фигыльләр | хәл фигыльләр | исем фигыльләр | исемнәр | сыйфатлар | саннар | урын-вакыт исемнәре | алмашлыклар | рәвешләр | ымлыклар | ярдәмлекләр |
| зат кушымчалары белән төрләнүчеләр | зат кушымчалары белән төрләнмәүчеләр | зат кушымчалары белән төрләнүдә пассивлар | *чы-че, сыз-сез* кушымчалары алучылар | *ап, кып, нәп* кисәкчәләре алучылар | *нчы-нче* кушымчалары алучылар | *кы-ке, гы-ге* кушымчалары алучылар | фәкать килеш кушымчалары гына алучылар | ясаучы да, ясалучы да | фигыль булып кына ясалучылар | ясамыйлар да, ясалмыйлар да |

**Фигыль юнәлешләре һәм килешләр.** Телебездә бу формаларның барлыгын исбат итеп торуның кирәге юк дип, беләм. Чөнки телебезнең ялганмалык табигатен сыйфатлап, андагы кушымчаларның рәтләрен күрсәтеп чыкканнан соң, телебездә танылган бүтән формалар белән берлектә фигыль юнәлешләре һәм килеш формаларының булуы турында инде бәрәү дә шикләнә алмас дип, уйлыйм. Тик боларга үз телебезнең табигатенә мовафыйк рәвештә кила белергә генә кирәк. Билгеле, икенче системадагы телләрнең үзенчәлекләренә ияреп эш итәргә ярамый. Безнең телебездә фигыль юнәлешләре һәм килешләрнең саны фигыльләрдә 2 нче рәт, исемнәрдә 5 нче рәт булып ялгана торган мәгълүм мәгънәләрдәге кушымчалар саны белән билгеләнергә тиеш.

**Методологик як.** Мәкаләм азагында телебезне өйрәнүнең методологиясе һәм мәктәп грамматикасының куелышы турында берничә сүз әйтергә тиешлемен.

Беренчедән, мәктәп грамматикалары ныклы фәнни нигездә – формаль принцип буенча төзелергә тиеш. Сүзләрне, сүзләрнең формаларын һәм җөмлә кисәкләрен логик тәгърифләү кебек балластлардан грамматикаларыбызны тазартырга кирәк.

Икенчедән, морфологияне түбәнге классларда үткәндә, элгәре сүз төрләндерүче кушымчаларны күзәтергә кирәк. Чөнки болар – күренеклерәк һәм ачыграк формалар. Болар арасында 3 нче һәм 5 нче рәт кушымчалары тагын да җиңелрәк аерыла. Сүзләрнең бу формаларын синтаксик анализ – җөмләләр тикшерү белән бәйләргә дә җиңелрәк була. Монда әле килешләрнең һәм тәмамлыкларның аерым формаларын тикшереп – тәгърифләп тормаска да мөмкин. Чөнки бездә килешләр белән төрләнеш, рус телендәге кебек, катлаулы һәм күп төрле түгел.

Төрләндерүче кушымчалардан соң өстәмә кушымчалар (6 нчы, 7 нче һәм 8 нче рәтләрдәге кушымчалар) белән таныштырырга кирәк. Өйрәнү өчен кыенрак булганы – сүз ясаучы кушымчалар. Аларны өлкәнрәк классларга калдырырга кирәк. Исемнәрне төркемләү һәм төрләнмәүче сүзләрне ваграк төркемнәргә бүлгәләп өйрәнүне дә өлкәнрәк классларда куярга кирәк.

Телебездәге барлык кушымчаларны һәм формаларны өйрәнеп үткәннән соң морфология буенча алган белемнәрнең һәм күзәтүләрнең йомгагы итеп, ялгануларындагы тәртип буенча кушымчаларның бөтен системасын күрсәтеп үтәргә кирәк булыр.

Безнең телебезнең төзелеше гади, җиңел һәм төзек системалы. Төрле чыгармалар һәм артык формалар безнең телебездә юк. Шунлыктан телебезнең законнарын өйрәнүне, мәктәпләрдә үзләштерү өчен дә, бик уңайлы системага салырга мөмкин. Шулай рациональ өйрәнү аркасында артып калган сәгатьләрдә бүтән төрек телләре өстендә дә чагыштырмалы күзәтүләр ясарга мөмкин булыр иде.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ КУШМА ТӨРЛӘР[1]

## КЕРЕШ

Кушма сүзләр, кушма төрләр – төрек телләренең үзенә аерым бер табигате, татар теленең үзенә аерым бер байлыгы. Безнең телебездә кушымчалар ялгау белән бер төп сүздән яңа сүзләр, яңа төрләр чыгару юлы яхшы ук тулы, низамлы булу белән бергә, әлбәттә, аның бер чиге дә бар. Хәлбуки мәгънә, тәсаувыр дигән нәрсә бик киң, бик катлаулы. Ул низамлы, чикле морфология рамкаларына гына сыеп бетәрлек түгел. Кайбер хәлләрдә, кушымчалар ялгау юлы белән генә теләгән бер төп сүздән теләгән мәгънәдәге, теләгән төрдәге яңа сүзләр чыгарып, яңа төрләр ясап булмый. Менә шундый чакларда, яңа мәгънәләр тудыру, кайбер сүзләрне теләгән рәвештә төрләндерү өчен, телебездә, кушымчалар белән беррәттән, кушма төрләрдән файдаланырга туры килә. Шуңа күрә безнең сүзлекләребездә һәм грамматикаларыбызда, ялгыз сүзләр белән бергә, кушма сүзләр, кушма төрләр дә бик зур урын алырга тиеш булалар. Сүзлекләребез телебездәге кушма сүзләр байлыгын җыелмаларның үзенә махсус мәгънәләрен тикшерергә, грамматикаларыбыз аларның уртак табигатьләрен, төзелү, ясалу рәвешләрен ачып күрсәтергә тиеш булалар.

Мин монда телебездәге кушма төрләрне грамматик бер факт булулары ягыннан карап, аларның нинди кисәкләрдән кушылып, нинди юллар белән төзелүләрен, нинди төркемнәргә бүленүләрен һәм мәгънә ягыннан функцияләре нинди булганлыгын күрсәтмәкче булам. Монда тикшереләчәк кушма сүзләр, кушма төрләрнең күбесе – матбугатта күптән күрелгән, грамматикаларда өзек-өзек тикшерелә килгән нәрсәләр. Шуңа күрә монда, эчтәлек ягыннан әллә ни яңалык юк дияргә ярый. Минем теләгем – аларны шәкли яктан карап тикшерү, таркау, чуалчык материалны бергә җыйнап, бер системага салып күрсәтү генә.

Телебездәге кушма төрләр ныклап тикшерелмәгәнгә күрә, тел өйрәнүчеләргә җөмлә төзелешләрен тикшергәндә аңлашылмаган, чуалчык урыннар очрый; укучыларга, аларны ничек аерырга, ничек дип атарга белмичә, аптырап калырга туры килә иде. Бу чокчынып табылган нәрсәләр телебезне өйрәнүчеләргә әнә шул чуалчык урыннарны ачу юлында бераз ярдәм итмәсләрме, дип уйлыйм.

Башта ук шуны әйтеп китәргә кирәк: «кушма төрләр» дигән атаманы мин монда шартлы бер мәгънәдә кулланам. Мин монда кушма төрләр дип, телебездәге ике сүздән, яки бернечә сүздән кушылып, янәшә тезелеп, бергә оештырылып әйтелгән күренешләрне алам. Кушма төрләр җөмлә эчендә грамматик бер бөтен булып йөриләр. Мәгънәләре ягыннан, кушма төрләр эченә кергән аерым сүзләрнең берсе үзенең туры мәгънәсен

[1] Бу материал – Г. Алпаровның 1928 елда Ленинградта укыган чагында Востоковедение институтында ясаган доклады. – *Ред.*

бөтенләй яки кисәкчә югалтып, икенчесенә ярдәмче булып килгән була. Аларның икәвеннән яңа уртак бер мәгънә яки яңа бер мөнәсәбәт аңлана. Җөмлә эчендә кушма төрләр эчендәге аерым сүзләрне, гадәттә, башка тәртиптә китереп әйтергә яки аларның арасына җөмләнең башка бер кисәген кертеп әйтергә мөмкин булмый: аларның тәртибен, төрен үзгәртү, бер-береннән аеру теләнгән мәгънәнең үзгәреп китүенә сәбәп була.

Монда мин, мәгънә ягын карап, кушма төрләр эченә *билбау, аккош, алтатар* кебек кушма исемнәрне *дә*, *бала-чага, савыт-саба, аталы-уллы, килә-килә* кебек куш сүзләрне *дә*, *бара бир, кабул ит, килә тор* кебек кушма фигыльләрне *дә*, *бара торган иде, кабул итә алыр иде микән* кебек катлаулы кушма фигыльләрне *дә* кертәм. Кушма төрләрнең бер як читендә *читек* (эч итек), *беләзек* (беләк йөзек), *кузгалак* (кузы колак) *ярканат* (яры канат), *яисә* (я исә), *юкса* (юк исә)... кебек кушмалыктан чыгып, тәмам ялгыз сүзгә әйләнеп җиткән төрләр торса, икенче як читендә бирмәскә *итә, ашарга тора, шөр җибәрү, ваз кичү, зык кубу, хөкем сөрү*... кебек, төп мәгънәсен әле генә югалтып килә торган «тоташ тезмәләр», «кушма тәгъбирләр» тора. Бу соңгылары әле җанлы тезмәлектән яңа гына чыгып киләләр, шуңа күрә аларны кушма төрдән санаргамы, яки сүз тезмәләре итеп караргамы дип, аптырыйсың.

Гомумән кушма төрләр – телебезнең тарихи үсү, үзгәрүе ягыннан караганда, синтаксик сүз тезмәләреннән морфология төренә, ялгыз сүзгә әйләнү хәлендә булган күчмә, ике арадагы күренешләр алар. Ярдәмлекләр кыскарып, үзгәреп, кушымчаларга, кушымчалар төп сүз белән бергә кушылып бер сүзгә әйләнгән кебек, без монда да синтаксик тезмәләрнең иң элгәре үзгәрми торган бер тәртип белән, бер тоташ, янәшә әйтелә торган тезмәләргә әйләнүен, аннары, төп мәгънәләрен югалтып, ярдәмлек булып йөри башлауларын, соңыннан кыскарып, авазлары үзгәреп, калынлык-нечкәлектә дә төп сүзгә ияреп әйтелә торган кушымчага, бер сүзгә әйләнеп китүләрен күрәбез. Бу күчмә хәлләрнең һәрберенә телебездән мисаллар табып күрсәтеп була.

Мәсәлән, *юк исә – югыйсә – югыйса – юкса, кирәк исә – кирәгисә – кирәксә; килә алмадым – килалмадым – киләлмәдем, юк иде – юк ие – югые...*

Бу урында бик табигый бер сорау килеп чыгарга мөмкин.

– Болай булгач, морфология кайда бетә дә, синтаксис кайдан башлана? Монда шуны әйтергә кирәк: бер яктан, сарыф белән нәху үзара бер-береннән әллә никадәр ерак бер нәрсә түгелләр; хосусан, төрек телләрендә алар бер-беренә бик якын күренешләр. Чөнки аерым сүзләрнең төрләнеше дә бит, аларның җөмләдә торткан урыннарына, сүз тезмәләрендәге рольләренә карап йөри, җөмләнең кайсы кисәге булып килүләре сүзләрнең төреннән, урыныннан беленә. Шуңа күрә морфология белән синтаксис арасына кискен бер чик ара куярга кирәк түгел, һәм бу мөмкин дә түгел. Алар икәве бергә өйрәнелә, бергә укытыла»,

алар берсен берсе ача, берсен берсе тутыра. Икенчедән, башка бөтен табигать дөньясында күргәнебез кебек, җанлы телдә дә ачык, катгый чик аралар юк. Табигать эчендә үсемлек белән хайваннар арасында да мондый күренешләр барлыгы билгеле; шундый нәрсәләр бар, бер карасаң – хайван, бер карасаң – үсемлек; хайван дисәң – күчеп йөрми, үсемлек дисәң – әгъзасын хәрәкәтләндерә, тышкы тәэсирләргә җавап бирә ала... Тел хадисәләре дә шулай: анда да бер күренеш икенчесеннән тирән яр белән аерылмаган, бәлки аралыклары күчмә хәлләр белән сөзәкләп килеп берләшкән була. Шуңа күрә бу кушма төрләрне тоташы белән барын бергә аерым сүз исеме астына – морфологиягә кертү дә, җанлы сүз тезмәләреннән санап, синтаксиска гына кертү дә кыен. Сүз тәгърифенә туры килгән яклары күбрәк булуга карап, *билбау, күкташ, куштирәк* кебек, кушма исемнәрне *ярты гөнаһ* белән бер сүз итеп алырга мөмкин. Чөнки кушма исемнәрнең гармония ягыннан авазлары берберенә ярашып бетмәгән булса да, басымнары, мәгънәләре ягыннан алар башка ялгыз сүзләр кебек әйтеләләр һәм сөйләүче тарафыннан бер бөтен итеп тәсаувыр ителәләр. Алар авазда да бер-беренә ярашуга йөз тотканнар. Ләкин башка кушма төрләрнең барын да сүз тәгърифе астына һичбер төрле дә кертә алмыйбыз. Алар бу хокукка ирешмәгәннәр әле.

Озын сүзнең кыскасы, мин монда кисәкләре бер-береннән аерым башкарылмый, үз башына аерым җөмлә кисәге була алмый торган, бәлки бер тоташ, янәшә көе генә җөмлә кисәге булып йөргән, бергә башкарылып төрләнгән сүз тезмәләрен тикшерәм һәм аларны шартлы рәвештә «кушма төрләр» дип атыйм. Ләкин һәр кисәге үз башына аерым ирекле тезелеп, аерым төрләнеп йөри алган сүз тезмәләренә, шартлы рәвештә әйткәндә, сүзләрнең үзара синтаксик төзелешләренә кагылмаска тырышам.

Кушма төрләр башлыча ике максат өчен төзеләләр:

1) яңа мәгънәдә яңа сүз ясау өчен,

2) мәгънә үзгәртү, төрләндерү өчен.

Нинди элементлардан кушылып ясалуларына карап, алар:

1) я икәве дә тулы мәгънәле, мөстәкыйль сүзләрдән,

2) я берсе тулы мәгънәле, берсе ким мәгънәле (яки мәгънәсез) сүзләрдән оештырылган булалар.

Үзара бер-беренә бәйләнү рәвешләренә карап:

1) гади тезеп әйтү төрендә,

2) тагу, ияртү төрендә,

3) кабатлау төрендә, яки

4) теркәү, башкару төрендә бәйләнешкән булалар.

Әйтелешләре, басым, интонацияләре ягыннан:

1) я икәве дә тигез тавыш, тиң басым белән,

2) я икәве ике төрле басым, ике төрле тавыш белән,

3) я бөтенләй бер басым белән бер тоташ әйтелергә мөмкин. Шуның

өстенә кайбер кушма төрләр бөтен сүз төркемнәре өчен уртак булалар, кайберләре билгеле бер сүз төркемендә, җөмләнең билгеле бер кисәгендә генә очрыйлар.

Шушы әйтелгән нигезләр буенча, хәзер без кушма төрләрне кушма сүзләрне төрле төркемнәргә аерып, берәм-берәм тикшерә башлыйбыз.

## Кушма сүзләр

Кушма төрләрнең бөтен сүз төркемнәрендә очрый торганнары – ике сүздән кушып ясалган «кушма сүзләр». Болар үзләре, тышкы һәм эчке төрләренә карап, өч төркемгә аерылалар: 1) тагылмалы кушмалар, 2) кабатлы кушмалар, 3) көчәйтүле кушмалар.

### 1. ТАГЫЛМАЛЫ КУШМАЛАР

Телебездәге кушма төрләрнең иң оригиналь булганнары – тагылмалы кушма сүзләр. Болар, яңа мәгънәдәге яңа бер тәсаувыр аңлату өчен, авазларында яки мәгънәләрендә үзара бер-беренә нинди булса да охшашлык, якынлык булган ике төп сүзне бер-беренә тагып, ияртеп әйтү белән ясалган булалар. Аларның беренчесе һәрвакыт мәгънәле, мөстәкыйль сүз булып, икенчесе күп вакыт ярым мәгънәле, яки бөтенләй мәгънәсез ярдәмче бер әйтем генә дә булырга мөмкин. Шуңа күрә бу соңгысын «тагылма сүз» (яки «иярчен сүз») дип атарга ярый. Тагылмалы кушма сүзләр, икәве бер төсле басым, бертигез тавыш белән, ике арада пауза ясалмыйча әйтеләләр. Монда аларның ике сүздән торганлыклары аерым-ачык беленеп торырга тиешле. Шуңа күрә алар бер-берсеннән пауза белән аерылмасалар да, кушма исемнәрдәге кебек, бөтенләй бергә кушылып ук әйтелмиләр, бәлки һәрберсе үзенә аерым мөстәкыйль басым белән әйтеләләр.

Мәгънәләре ягыннан да тагылмалы кушма сүзләрнең алдагысы нигез урынында булып, әйтергә теләгән мәгънәнең 90 процентын шул беренче сүз бирә, тагылма кисәге исә шул мәгънәне киңәйтүгә ярдәмче роль уйный һәм беренче сүз белән бергә аңа җенестәш булган, аңа охшаган нәрсәләрнең дә бергә, аңланырга тиеш булуын белдерә. Мәсәлән:

*аксак-туксак* (аксак кебек гарип кешеләр),

*мулла-мунтагай* (мулла кебекләр – динчеләр),

*анда-санда* (кайда булса да берәр җирдә).

Тагылмалы кушмаларның күбесе безнең телебездә борыннан ясалып калган ишетмә (симагый) сүзләр булалар. Аларны сонгый рәвештә[1] теләгән сүздән ясап булмый. Шуңа күрә бу тагылмалы кушма сүзләр арасында хәзерге телебездә кулланылмый торган, онытылган сүзләр дә байтак очрый. Тагылмалы кушма сүзләрнең беренчесе телебездә үзенә аерым көенчә дә

[1] Сонгый – искусственный, ясалма рәвештә.

йөри, икенчесе күп вакыт үзе ияргән сүздән башка ялгыз көенчә генә телебездә йөртелми.

Бу төрдәге кушмаларның тагылма кисәкләре түбәндәгечә ясалган булалар:

1) Баш сүзнең башындагы берничә авазын үзгәртеп әйтү белән. Мәсәлән: *агач-богач, малай-шалай, әрәм-шәрәм, ыбыр-чыбыр, берәм-сәрәм.*

2) Баш сүзнең эчтәге берничә авазын үзгәртеп: *тамыр-томыр, чокыр-чакыр, шәкерт-шөкерт, чүпрәк-чапрак, чыбык-чабык, ялт-йолт, шау-шу, тимер-томыр.*

3) Баш сүзнең азагыннан берничә авазны үзгәртеп: *кош-корт, җиләк-җимеш, курше-кулән, карт-коры, усал-унтагай, тиз-тиләмән, килеш-килбәт.*

4) Мәгънәләре бер-беренә якын, бер ише сүзләрне тезеп әйтү белән: *хатын-кыз, энә-җеп, катык-сөт, җир-су, көн-төн, биш-алты, юк-бар, кунак-төшем, үпкә-бавыр, агай-эне, ялгыз-ярым.*

5) Мәгънәләре дә, кушымчалары да бер ише сүзләрдән: *бата-чума, арып-талып, килде-китте, кием-салым, калган-поскан, алдым-бирдем, уку-язу, йөреш-торыш.*

6) Баш сүзнең беренче авазын *м, п, б* гә алмаштырып кабатлау белән: *кирле-морлы, әз-мәз, кызыл-мызыл, чәй-мәй, иске-москы, кылт-мылт, агач-богач, шатыр-потыр.*

7) Беренче сүзгә фәлән, мазар, ни сүзләрен кушып әйтү белән: *кеше-фәлән, ат-мазар, таяк-мазар, юлда-нидә, ут-фәлән, балта-ни, бүре-ни (чыга калса...)*

8) Фигыльләргә охшаш төрдә нит сүзен әйтү белән: *барып-нитеп, төшә-нитә, килсә-нитсә, күргән-ниткән, эләгеп-нитеп, чыгасы-нитәсе, бәйләргә-нитәргә.*

Бу урында кайбер тагылмаларның аваз үзгәрту белән бергә, баш сүзнең гармониясен үзгәртеп тә ясалганын игътибарга алырга кирәк. Мәсәлән: *чүпрәк-чапрак, кирәк-ярак, иске-москы, үги-кагый, тоз-тибез, үпкә-сапка, алпан-тилпән...* кебекләр. Тагылмаларның гармониядә беренче сүзгә охшамаган төрләре яратылыбрак та сөйләнелә. Бу хәл аларның мәгълүм мәгънәне аңлату өчен ике сүздән торганлыклары сизелеп, аерылып торырга кирәк булуын күрсәтә.

Тагылмалы кушмаларның бик сирәк ике кушма фигыльдән ясалганнары да очраштыргалый: *элеп алып-селкеп салып* кебек.

Югарыда күрсәтелгән төрләрдән соңгы өч пункттагылары (6, 7, 8 дәге төрләр) – кагыйдәле төрләр. Алар борынгы бабайлардан ишетеп кенә түгел, бәлки хәзерге телебездә дә шул юл белән ясала алалар. Тагылмалы кушмаларның җөмлә эчендә гадәттә соңгысы гына кушымчалар белән төрләнә, ләкин сирәгрәк аларның икәве дә бер төсле кушымча белән төрләнеп килүләре дә мөмкин. Мәсәлән, *уттан-күздән саклана күрегез (ут-күздән), ашны-суны яхшы әзерли ул* (*аш-суны...*)

Тагылмалы кушмалар, мисаллардан күренгәнчә, исем дә, фигыль дә булырга, башка сүз төркемнәреннән дә килергә мөмкин. Шуңа карап, җөмлә эчендә алар икәве бер тоташ ия дә, хәбәр дә һәм иярчен кисәкләр дә булып йөри алалар.

## 2. КАБАТЛЫ КУШМАЛАР

Бу урында без кабатлы кушмалар дип бер үк калыпта, бер үк тәрдәге бер сүзнең янәшә ике кабат әйтелгән төрен генә аңларга тиеш булабыз. Боларны, бер яктан, тагылмалы кушмаларга охшатырга, икенче яктан, стиль үзгәртү өчен кабатлау (тәкрар әйтү) төрләре белән саташтырырга мөмкин. Шуңа күрә аларның аермасын монда ныклы күрсәтеп үтәргә туры килә. Кабатлы кушмаларның тагылмалардан аермасы, бер яктан, бер үк сүзне ике кабат әйтүдә булса, икенче яктан, монда беренче сүз аерым-ачык басым белән һәм икәве берьюлы тизрәк тә әйтелүчән була. Мәгънәләре ягыннан да болар җенестәшлек аңлату өчен түгел, бәлки дәвамлылык, тезелү, төркемләнү кебек бер рәвеш, бер күренеш белдерү өчен кулланылалар. Шуңа күрә болар җөмлә эчендә күбрәк фигыль рәвеше булып йөриләр. Мәсәлән: *килә-килә арып беттем; төркем-төркем йөриләр; килеп-килеп авырта; көчкә-көчкә генә котылдым.*

Стиль өчен кабатлап әйтү төреннән аермалары түбәндәгечә:

1) Кабатлы кушмалар фәкать ике рәт кенә әйтеләләр. Стиль өчен булган кабатлау ике дә, күбрәк тә әйтелергә мөмкин. Мәсәлән:

*Су анасыннан котылгачтан тынычлангач, әни*
*Әй орышты, әй орышты, әй орышты соң мине.*

*(Г. Тукай.)*

2) Кабатлы кушмалар бары ялгыз сүзләрдән генә төзелә, ә стиль өчен булган чын кабатлау исә берничә сүзне, хәтта бер җөмләне кабатлау белән дә төзелергә мөмкин. Мәсәлән: *таң ата да кич була, таң ата да кич була.*

3) Кабатлы кушмаларның арасына башка сүз кертеп, хәтта бер кушымча ялгап та булмый, мәгънә үзгәреп китә; ә кабатлау өчен әйтелгән сүзләр арасына башка сүз керү белән мәгънә үзгәрми, кушымча ялгау да аны бозмый, бәлки ачыкландыра гына. Мәсәлән:

*Килегез, килегез = килегез, дим бит инде, килегез.*

*Юк, юк = юк әле хәзергә, юк.*

*Шәп, шәп = шәп инде, бик шәп.*

4) Кабатлы кушмаларның беренчесе басым белән, икәве берьюлы тиз генә әйтелә, арада пауза ясалмый, ә стиль өчен булган кабатлауда ике сүз икәве тигез басым белән, хәтта икенчесе тагын да көчәйтә төшеп әйтелергә мөмкин, һәм аларның ике арасында, урынына карап, теләгән чаклы пауза (тыныш) ясап та була (югарыгы мисалларны кара).

5) Кабатлы кушмалар бары мәгънә төрләндерү бер рәвеш аңлату өчен төзеләләр, ә стиль өчен кабатлап әйтү исә мәгънә көчәйтү, бер сүзне яңадан ныклап анлату өчен килә. Мәсәлән:

*Сызла, сызла, сызла, күңелем,*
*Сызла бер туктамыйча...*
*Сызла айлар, сызла еллар,*
*Сызла төн йокламыйча...*

*(С. Рәми.)*

6) Кабатлы кушмаларның бер сүзен калдырып әйткәндә, аңлатырга теләнгән мәгънә үзгәреп китә, ә стиль өчен булган кабатлауда алай түгел, монда бер генә мәртәбә дә әйтергә була, төп мәгънә дә үзгәрми: *Әни әй орышты соң мине!*

– *Сызла, күңелем, бер туктамыйча...* кебек.

Кабатлы кушмалар күбрәк түбәндәгечә ясалалар:

1) Ике хәзерге рәвеш фигыленнән (дәвам итү рәвеше): *килә-килә, кайта-кайта, укый-укый, эшли-эшли өйрәндем.*

2) Ике үткән рәвеш фигыленнән (кабат эшләү рәвеше): *килеп-килеп авырта, сугып-сугып җибәрде, башым авып-авып китә...*

3) Барлык һәм юклык төрендәге ике җавап фигыленнән (ике урталык хәл): *явар-яумас, килер-килмәс, сүнәр-сүнмәс, абыныр-абынмас...*

4) Ике исемнән (эшнең рәвеше): *төркем-төркем йөриләр, ябалак-ябалак кар ява, тау-тау өелеп ята.*

5) Исемнәр һәм сыйфатлардан (өзек-өзек тезелү рәвеше): *аның базында тәпән-тәпән май, батман-батман бал ята. Быел бодай җире-җире белән бик уңган. Матур-матур кызлар килгән. Биек-биек өйләрдә кемнәр яши бу чакта.*

6) Саннардан (бүлү, төркемләү рәвеше): *өчәр-өчәр, унар-унар, йөзләп-йөзләп...*

7) Рәвешләрдән (өзек-өзек көчәйтү өчен): *кызу-кызу, тиз-тиз, шәп-шәп, көчкә-көчкә, чак-чак кына...*

8) Кайбер сүзләрнең уртасына *ма-мә-бә* кисәкчәләре (борынгы телебездә һәм урынына йөргән кисәкчәләр) ялгау белән ясала (кара каршы тиңләшү рәвеше): *күзмә күз, башма баш, бермә бер, йөзмә йөз, тиңмә тиң, ничәмә ничә, тикмә тик, каршыма каршы (карма-каршы, капма-каршы, кара-каршы, капа-каршы* дип тә әйтелә).

Искәрмә. Һәр икәве *лы-ле* кушымчасы белән әйтелгән кушарлы сүзләрне дә, төп сүзләре кабатланып әйтелмәсә дә, болар арасында күрсәтеп үтәргә туры килә. Мәсәлән, *аталы-уллы, ирле-хатынлы, уңлы-суллы, агалы-энеле, туталы-сеңелле, аслы-өсле...* Чөнки болар, тагылмалы сүзләр кебек, ишетмә түгел, бәлки кагыйдәлеләр, һәм җенестәш уртак мәгънә дә аңлатмыйлар, мәгәр кушарлык, икәүлек рәвешен генә күрсәтәләр. Боларны тагылмалы кушмаларның кайвакыт икәве бер төрле кушымча белән төрләнеп әйтелүләренә охшатырга ярамый.

Югарыда күрсәтелгән төрләрдән башка тагын безнең телебездә үзара бер-беренә башкару юлы белән (кушымча аркылы) бәйләнешкән кабатлы кушма тәгъбирләр дә байтак кына очрый. Мәсәлән: *як-ягына, бер-береннән, үз-үзенә, чит-читенә, баш-башы, елдан-ел, көннән-көн, күптән-күп, яңадан-яңа, килеп килә, ашап ашый, йөреп йөри, котырып котыралар, ашавы ашый, эчүен эчә дә, барын бар инде, күптән дә күп шул, ярар яравын да, тиленең тилесе, усалның усалы*... һәм башкалар.

Бу соңгыларның күбесе, синтаксик яктан аерыла – тәхлил ителә алганлыктан, кушма төрләрдән саналмыйлар.

## 3. КӨЧӘЙТҮЛЕ КУШМАЛАР

Көчәйтүле кушмалар, тагылмалы кушмалар кебек үк, берсе тулы мәгънәле, берсе ким мәгънәле ике сүздән ясалган булалар. Ләкин боларда, тагылмаларның киресенчә, иярчен сүз алдан килеп, баш сүз исә соңыннан әйтелгән була, һәм монда алдагы иярчен сүз көчле басым белән әйтелә. Мәгънә ягыннан мондагы иярчен сүзләр баш сүзнең мәгънәсен көчәйтү өчен кулланылалар.

Көчәйтүле кушмалар да – тагылмалар кебек ишетелмәгән нәрсәләр; болар безнең телебездә артык күп булмаса да, бөтен сүз төркемнәрендә очрыйлар. Боларның иярчен сүзләре үзе ияргән сүзеннән башка аерым көенчә телебездә йөрми дә.

Мәсәлән:

1) Көчәйтүле кушма исемнәр: *шыр тоз, шабыр су, шабыр тир, лыч су.*

2) Көчәйтүле сыйфатлар: *җете кызыл, чылт сары, өр-яңа, дөм сукыр, шар ачык, шыр ялангач, шыр тиле...*

3) Көчәйтүле рәвешләр: *кара-каршы, япа-ялгыз, көпә-көндез, зыр түгәрәк, ду аләмәт, токтомал.*

4) Көчәйтүле фигыльләр: *гөж киту, гөр килү, шөр җибәрү, урә сикерү, зык кубу, ваз кичү, шак кату, пыр туздыру.*

Шуны да әйтеп китәргә кирәк: бу көчәйтүле кушмалар морфологик төр белән синтаксик тезмәләр уртасындарак торган ике аралык бер тәгъбирләр итеп каралырга тиеш. Бу кушмаларның алдындагы көчәйтүче кисәкләр синтаксик яктан *бик, иң, гаять, артык, утә*... кебек ачыклаучы ярдәмлекләргә, морфологик яктан төп сыйфатларның алдына кушыла торган *кып-кызыл, ап-ак, ямь-яшел* дигәндәге *кып, ап, ямь* кебек, кабатлау (көчәйтү) кисәкләренә охшыйлар. Ләкин мондагы кисәкләр, ул сүзләр, ул төрләр кебек, кагыйдәле, канунлы түгелләр, ягъни болар теләсә нинди сыйфатларга билгеле бер кагыйдә буенча ясалып кушыла алмыйлар, бәлки үткән буыннардан ук килгән ишетмә нәрсәләр. Мәгънә ягыннан охшашлык якын булса да, тышкы яктан болар, ни ачыклаучы ярдәмлекләр кебек, теләсә нинди сүзгә өстәп әйтелә алмыйлар, ни ка-

батлау кисәкләре кебек, төп сүзләрнең үзеннән дә ясалмыйлар, бәлки бабайлардан ишетү буенча, кайбер сүзләрнең аерым үзенә генә өстәлеп, кушылып әйтелә торган нәрсәләр. Шуңа күрә боларны морфологик төрләр белән, синтаксик тезмәләр уртасындагы аралык күренешләр итеп карарга һәм кушма төрләр арасында үзенә аерым күрсәтергә туры килә. Синтаксик тезмәләрне тикшергәндә, җөмлә төзелешен анализлаганда, аларны ваклап тормыйча, тоташ көенчә, җөмләнең кушма бер кисәге итеп кенә санарга кирәк.

Ләкин монда «кушма төрләр»не артык киңәйтеп җибәрергә, мәгълүм бер чиктән узып китәргә дә ярамый. Шәкли яктан җөмләнең аерым кисәге итеп анализларга мөмкин булган төрләрне, мәгълүм сүзләргә бәйләнеп кенә йөрүләренә карамастан, синтаксик тезмәләрдән санарга тиеш була. Мәсәлән, безнең телебездә *көрчеккә терәлү, ләчтит сату, баш күтәрү, казан асу, җенен өзү, күк күкрәү, таң ату, концерт бирү...* кебек бик күп кушма тәгъбирләр бар. Ләкин боларның алдагы сүзләре шәкли яктан ия, яки тәмамлык булып аерыла алалар, шуңа күрә мондый төрләрне барын да кушма итеп санап бетәргә ярамый.

## Кушма исемнәр

Кушма исемнәр бер сүзне икенче сүзгә бөтенләй кушып әйтү –берләштерү белән ясала. Тагылмалы сүзләрдәге кебек, монда басым ике сүзнең икәвендә тигез дә булмый, кабатлы көчәйтүле кушмалардагы кебек, беренче кисәге генә дә басым белән әйтелми, бәлки монда басым иң ахыргы иҗектә була. Шулай ук ике арада кечкенә пауза да ясалмый, бәлки бер сүзнең авазларын әйткән кебек берьюлы әйтелә. Шуңа күрә кушма исемнәрдәге кисәкләр үзләренең аерымлыкларын югалтып, үзгәреп, бөтенләй бер сүзгә әйләнеп китүчән булалар. Аларның бөтенләй бергә кушылып язылулары да шуннан килә. Кушма исемнәрнең мәгънәләре бөтенләй яңа бер нәрсә, яңа бер әйбер исеме була.

Кушма исемнәр түбәндәге юллар белән ясала:

1) Сыйфат белән исемнән. Мәсәлән: а*ккош, акбур, актамыр, кызылбаш, күкташ, алабуга, тилбәрән* (тилебәрән), *кайнана, кайнигәч, ярканат, Сөембикә, таныкнамә...*

2) Төбендә иялек (теркәү) аергычы белән аерылмыш булган ике исемнән. Мәсәлән: *билбау* (билнең бавы), *ашъяулык, алмагач, табагач, чәчкап, көнчыгыш, төньяк, кулбаш, ашханә...*

3) Сан белән исемнән. Мәсәлән: *биштау, өчаяк, Дүртиле, бишъеллык (план), куштирәк, куштау, кыргаяк, унбашы...*

4) Исем белән фигыльдән: *юлбасар, җилкуар, алтатар, алыпсатар, урынбасар, Илгизәр.*

5) Ике сүзне дә кыскартып кушу белән: *эшхәб* (эшче хәбәрче – (рабкор), *авылхәб* (селькор), *Татнәшер* (Татиздат), *эшфак* (рабфак).

Бу соңгы ысул бездә, ничектер, әле гамәлгә кереп китә алмый. Кыскартылган сүзләрнең бездә русчалары күбрәк йөртелә.

Искәрмә. Кушма исемнәрнең бөтенләй берләшеп, үзгәреп, бер сүзгә әйләнгәннәре дә телебездә байтак очрый. Мәсәлән:

*Ярканат* (яры канат), *кузгалак* (кузы колак), *алабута* (ала ут), *беләзек* (беләк йөзек), *читек* (эч итек), *кандала* (кан талар)...

## Кушма саннар

Хәзерге төрек телләрендә кушма саннарның ничек итеп ясалуы һәркемгә мәгълүм. Бездә кушма саннар эре саннан вак санга бару тәртибендә гади тезү юлы белән ясалалар. Берләр белән уннарның үзенә аерым исемнәре бар. Йөзләрнең юк. Шуңа йөзләр рәтендәге санны ялгыз (берләр кебек) атап әйткәч, йөз дигән сүз өстәлә. Аннары, югары яктагы һәрбер аерым бүлү (өч төркем) саннар, актык бүлектәге өч сан кебек, аерым әйтелеп беткәннән соң, аларның барысына бердән шул бүлекнең исеме (мең, миллион, миллиард..) әйтелеп барыла. Буш (ноль) булган урыннар әйтелми кала. Кайвакыт *йөз, мең, миллион* сүзләреннән соң *дә-да* кисәкчәсе өстәлергә мөмкин. Җөмлә эчендә төрләнергә кирәк булганга, кушма саннарның иң азактан әйтелгәне генә төрләнә. Мәсәлән:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 532 | 047 | 608 | |
| биш йөз утыз ике миллион (да) | кырык җиде мең (дә) | алты йөз (дә) сигез | (биш йөз утыз ике миллион кырык җиде мең алты йөз сигез) |

*ау-әү* кушымчалары белән гадәттә 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, (8, 9), 10, (100) саннары гына төрләнә: *берәү, икәү..., унау* кебек. Кәсерле (вакланмалы) саннар, *ярты, ярым, чирек* (бер чирек, ике чирек, өч чирек[1]) тән башкалары, *бүлүче* санга *дән-дан-тән-тан, нән-нан* кушып, бүленүче санны актыктан әйтү белән ясала.

Мәсәлән: $\frac{1}{5}$ – *биштән бер*, $\frac{2}{3}$ – *өчтән ике*, 0,7 – *уннан җиде*, 0,15 – *йөздән унбиш*... кебек.

Искәрмә. Борынгы төрек телендә кайбер саннарның вактан эрегә (кирегә) таба ясалган булулары күренә. Иске памятникларда, мәсәлән, «тугыз утызга» – 39 ны, «биш егермегә» – 25 не аңлаткан.

Аннары, унарлы саннарның да үзенә аерым исемнәре булмыйча, ничә ун икәнлеге генә әйтелеп йөргәне күренә. Себер татарларында хәзерге көндә дә 60 – *алтун*, 70 – *җидун*, 80 – *сигезун*, 90 – *тугызун* әйтелә. Бездә дә соңгы икәве шуннан үзгәреп, *сиксән, туксан* төрендә әйтелә башлаганы күренеп тора.

---

[1] Кисеп бүленгән ашамлык нәрсәләргә карата *чирек* сүзе урынына *түтәрәм* сүзе дә кулланыла. Бу сүз *дурт ярам* нан алынган сүз (түтәрәм икмәк, түтәрәм каз).– *Автор.*

## Кушма алмашлар

Сорау алмашлары булган *кем, нәрсә, ни, нинди, нигә, ничек, ничә, кай, кайсы, кая, кайчан* сүзләре алдыннан барлык, бөтенлек (барчалык) мәгънәсен аңлаткан *һәр* сүзе, бөтенләй юклык мәгънәсен аңлаткан *һич* сүзе, билгесезлекне аңлаткан *әллә* сүзе һәм билгесезлек – атаусызлык белдергән бер сүзе кушып икешәр, катлаулы кушма алмашлар ясала. Мәсәлән:

*һәркем, һәрнәрсә, һәрничек, һәркайсы, һәркая...;*

*һичкем, һичнәрсә, һичнинди, һичкайсы, һичкая...;*

*әллә кем, әллә ни, әллә нигә, әллә ничә, әллә кай, әллә кайчан.., бер кем, бер нәрсә, берничә, бер кая, бер кайдан...*

*Һәр, һич, бер, кай, кайсы* сүзләре *бер* сүзенә кушылып та ике катлы алмашлар ясыйлар: *һәрбер, һичбер, бер-бер, кайбер, кайсыбер.*

Шулай ук *һәрбер, һичбер* төрләре, яңадан әлеге сорау сүзләренең кайберләренә кушылып, өчәр катлы кушма алмашлар ясый алалар, мәсәлән:

*һәрбер нәрсә, һәрбер кем, һәрбер кайсы, һәрбер кайчан, һичбер кем, һичбер нәрсә, һичбер кая...*

Кушма алмашлар, үзләренең урыннарына һәм төрләренә карап, җөмләнең теләсә нинди бер кисәге булып йөри алалар.

Искәрмә. *Һәр, һич, бер* сүзләре, җөмлә эчендә башка сүзләр алдыннан килгәндә, аергыч булып саналалар. *Әллә* сүзе кереш сүз дә, бәйлек ярдәмлеге булып та йөри. Гомумән бу төрләр – синтаксик тезмәләргә бик якын күренешләр, мин монда аларны, шартлы рәвештә, сорау алмашлары белән бергә әйтелгән һәм аның сораулыгын үзгәртеп, яңа мәгънәдәге алмаш ясаган өчен генә кушма төрләр арасында күрсәтәм.

## Кушма фигыльләр

Кушма төрләрнең иң катлаулы, иң күп төрле булганы – кушма фигыльләр. Морфологик төрләрдәге кебек монда да фигыльләр башка төрләргә караганда тулырак, байрак күренә. Кушма фигыльләр, башка кушмалар кебек, ике катлы гына түгел, бәлки өч, дүрт, хәтта күбрәк катлы да булып килә алалар. Башка кушмаларда булган кебек, фигыльләрдә дә кушма булып танылуның иң беренче шарты – мәгълүм бер төрдә үзара бәйләнеп янәшә әйтелү, гадәттә арага башка сүз керүен һәм тәртип алмаштыруны күтәрә алмау, мәгънә ягыннан яңа бер аң тудыру яки бер яңа мөнәсәбәт белдерү.

Кушма фигыльләр, үзләренең башкарган хезмәтләренә, үзара бәйләнеш һәм тышкы төзелешләренә карап, иң элгәре эч зур төркемгә аерылалар:

1) фигыль ясаучы кушма төрләр,
2) фигыль күренешләре ясаучы кушмалар,
3) хикәя төре кушмалары.

## Фигыль ясаучы кушма төрләр

Морфологиядә башка сүз төркемнәреннән, үзенә махсус кушымчалар ялгап, «ясалма фигыльләр» төзелә алганын беләбез. Ләкин фигыль ясаучы кушымчалар ялгау белән генә теләсә нинди сүзләрдән теләгән мәгънәдәге фигыльләр ясалып бетә алмый. Бүтән телләрдән кергән сүзләр, ымлыкларның күбесе һәм кайбер төрләнми торган сүзләр морфология юлы белән генә фигыль булып ясала алмыйлар. Менә шул вакыт андый сүзләрдән (фигыль ясалу өчен телебездә кушма төрләрдән файдаланырга туры килә. Бу урында бездә фигыль ясаучылык хезмәтен «ярдәмче фигыльләр» үтиләр. Бу вакыт ярдәмче фигыльләр, әлеге төрләнмәгән сүзләрнең артыннан килеп, үзләренең аерым хәлдәге туры мәгънәләрен бөтенләй яки өлешчә югалтып, бары алдагы сүзләрне «фигыльләштерү» хезмәтен генә башкаралар. Алдагы сүз, шушы ярдәмче фигыль белән янәшә килеп, мәгънә һәм шәкел ягыннан үзгәрмәгән көенчә әйтелә, ә ярдәмче фигыль исә теләсә нинди фигыль кушымчалары белән төрләнә. Монда беркадәр ярдәм фигыльләрен фигыль ясаучы кушымчалар (*ла-лә, ай-әй, лда-лдә, ра-рә*) белән алмаштырырга да мөмкин була, чөнки болар да шул ук функцияне үтиләр, шул ук урында кулланылалар.

Фигыль ясаучы булып хезмәт итүче ярдәм фигыльләренең телебездә күбрәк йөргәннәре – *ит, кыл* фигыльләре.

1) *Итү* фигыле белән күбрәк чит телдән алынган сүзләрдән һәм тиз, кинәт булган тавышларны, хәлләрне аңлаткан ымлыклардан, шулай ук кайбер төрләнми торган (кушымча белән ясала алмаган) сүзләрдән фигыльләр ясала. Мәсәлән, *тәэмин итү, тәэсир итү, танцовать итү, гулять итү, ялт итү, гөлт итү, черем итү, ял итү, юк итү, көн итү...*

Монда *итү* фигыле, башка сүзне фигыльгә әйләндерү белән бергә, кайвакыт «үзгәрү, әверелү» мәгънәсен дә бирә, хәтта кайвакыт шул мәгънә өчен генә дә кулланыла. Мәсәлән, *бишмәтне бозып, казаки иттем; скрипканы чана итеп, гармоныңны җигәрсең; төймәне төя итеп күрсәтә.*

Искәрмә. *Итү* фигыле, кайбер исем фигыльләргә кушылып килгәндә, икенче мәгънәдәрәк тә кушма фигыльләр ясый. Боларны алда күрербез әле.

2) *Кылу* фигыле белән күбрәк чит, дини сүзләрдән фигыльләр ясала. Мәсәлән: *гыйбадәт кылу, дога кылу, хаҗ кылу, сәҗдә кылу, тәүбә кылу, корбан кылу...*

Искәрмә. Бу фигыль безгә чыгтай әдәбияты аркылы кереп, тарихи традиция белән генә сакланып калган. Юкса, җанлы татар телендә *кылу* фигыле белән чит сүзләрдән фигыль ясау юк, гадәттә бу урында *итү* фигыле генә кулланыла.

3) Фигыль ясаучы ярдәмче фигыльләр арасында *килү* фигыле дә йөрештергәли. Бу фигыль белән дәвамлы тавыш, дәвамлы күренешләрне белдергән ымлыклардан фигыль ясала. Мәсәлән, *ду килү, шау килү, гөр килү, мәш килү, тар-мар килү, дөбер-шатыр килү...*

Искәрмә. Фигыль ясаучы кушма төрләр белән тезмәләр арасында ике уртадарак торган тәгъбирләр бар. Алардан берсе *булу* фигыле белән ясалган тәгъбирләр. Бу фигыль исемнәр белән бергә килгәндә, *әверелү, ошап күренү* мәгънәләрендә яңа бер кушма хасил итә. Мәсәлән, *ат булып кешни, әтәч булып кычкыра; сандугач булып сайрый; күзләре ут булды* һ. б. Боларны кушма фигыльләрдән санамыйча, алдагы сүзләрен рәвешләр дип тә карарга була. Шулай ук *концерт бирү, сәлам бирү, туй ясау, жыелыш ясау...* кебек төрләр дә ике урталыктагы тәгъбирләргә керә торганнардыр.

## Фигыль күренешләре ясаучы кушмалар

Морфологиядә төп һәм ясалма фигыльләрдән, үзенә махсус кушымчалар ялгап, һәртөрле фигыль дәрәҗәләре (баблар) ясалганы кебек, телебездә мәгълүм бер төрдәге теләсә нинди фигыльләрдән, үзенә аерым фигыльләр кушып, фигыль күренешләре (виды) ясау бар. Монда ике фигыль бергә янәшә килә, янәшә йөриләр. Мондагы фигыльләрнең икәве дә үз башларына аерым йөри ала торган тулы мәгънәле фигыльләр була. Алар икәве берберенә мәгълүм төрдә бәйләнеп әйтелгән һәм мәгънәсен үзгәрткән чакта гына кушма булалар. Монда алдагы фигыль соңгы фигыльгә рәвеш төрендә әйтелеп бәйләнгән була. Мәгънә ягыннан беренче фигыль нигез – төп урынны тотканга күрә, ул үзенең төп мәгънәсен югалтмый, соңгы фигыль исә, үзенең аерым ялгыз хәлендәге мәгънәсен югалтып, алдагы фигыльгә бер күренеш бирү, аның ничек башланып, ничек үтәлүе турында өстәмә бер төшенчә бирү хезмәтен генә үти.

Күренеш ясаучы кушма фигыльләрнең төрләнешендә түбәндәге аерымлыклар бар: боларда, фигыль кушымчалары белән төрләнү ягыннан, ниндидер хезмәт бүлешү бар. Алдагы фигыль монда һәрвакыт рәвеш фигыле төрендә *килү* белән бергә, баб кушымчалары[1] белән дә төрләнә ала, ләкин фигыль төрләндерүче кушымчалар (*ма-мә*, заман, хәбәрлек) белән төрләнә алмый. Икенче (ярдәмче) фигыль исә, баб кушымчалары белән төрләнми, юклык (*ма-мә*) кушымчасы, заман һәм хәбәрлек (зат) кушымчалары белән төрләнә ала.

Бу төрдәге кушмаларның, алдагы фигыльнең кайсы рәвеш төрендә килүенә карап, ярдәмче фигыльләрдә, аларның мәгънәләрендә беркадәр аерымлыклар була. Шуңа карап, без аларны ике төркемчәгә аерабыз:

1) Хәзерге заман рәвеш фигыле (*а-ә, ый-и*) төренә бәйләнгән фигыльләр. Мәсәлән: *яза алыр, сөйли бирде, укып барды, сизә алды...*

2) Үткән заман рәвеш фигыле (*ып-еп-п*) төренә бәйләнгән фигыльләр. Мәсәлән: *укып алды, язып бара, сөйләп бирде.*

Болар арасыннан үзара берләшүләре ныклырак булганнары – хәзерге заман рәвеш фигыле төренә бәйләнеп ясалган кушма төрләр. Боларда *а-ә, ый-и* төрендәге фигыль һәрвакыт кушма хәлдә генә йөри диярлек. Ул, кушма булмаганда, хәзерге заман хикәя фигыле булып йөри, аерым

---

[1] Баб кушымчалары – фигыль юнәлеше кушымчалары.

ялгыз көенчә рәвеш мәгънәсендә йөри алмый, югарыда күрсәтелгән кабатлы кушма төрендә килгәндә һәм түбәндә күрсәтеләчәк ярдәмче фигыльләр белән кушылганда гына рәвеш төрендә була ала.

I. *а-ә, ый-и* төренә бәйләнеп, күренеш ясаучы ярдәмче фигыльләр түбәндәгеләр:

1) *ал* (көч җиту, булдыру, ә юклык формасында килгәндә, көч җитмәү мәгънәсендә): *эшли алмадым, бара алмаган, китерә алса, күрә алдыңмы, яздыра алыр микән, укый алачак.*

Искәрмә. Бу фигыль безнең телебездә бик күп кулланыла. Ул җанлы телдә кыскарып, үзгәреп, кушымчага әйләнеп китеп бара: б*аралмадым, киләлмәдем, әйтәлми*... кебек. Анатули төрекләрендә *варамади, язамаюр, гәләмәдем, яшаямади, сөйләямәз* кебек төрләрдәге *а-ә, я* төрләре дә шуннан кыскарган кушымчалар. Бу вакыт аларны күренеш (вид) ясаучы кушымчалардан берсе итеп санарга кирәк була.

2) *бар* (өзекле, кабатлы дәвам мәгънәсен бирә): *ала бар, үсә бара, ел саен яхшыра бара, арттыра* барасыз.

3) *бир* (өстәү, дәвам итү мәгънәсен бирә): *китә бир, бара бир, утыра бир, йөри бир, эшли бирсен.*

4) *тор* (вакытлы, чикле, һәм билгесез дәвам): *син әз генә утыра тор; менә шул китапны укып тор; сез сөйләшә торыгыз әле; әйдә, китә торсын, мин караштыра торырмын.*

Искәрмә. Шул ук төргә бәйләнеп әйтелгән һәм шушы тор тамырыннан ясалган торган сүзе хәзерге заман сыйфат фигыльнең икенче формасы булып йөри; *баручы = бара торган, килүче = килә торган, караучы = карый торган*... Бу төр телебездә бик күп кулланыла, кушма фигыльләрнең үзенә яңадан бер кабат килеп тә кушыла ала. Мәсәлән, *укый ала торган, сөйли бирә торган*... *Торган* фигыле казах телендә *тын-тен* төренә кыскарып, сыйфат ясаучы кушымчага әйләнеп киткән.

Бу фигыль *торып* төрендә әйтелгәндә, *гәрчә,... гә карамастан,... сә дә,... гән булса да* мәгънәләрендә кулланыла. Мәсәлән: *күрә торып әйтмәгәнсең; шунда була торып алмадың бит...*

5) *төш* (аз гына өстәү, арттыру мәгънәсен бирә): *сала төш әле; якынрак килә төшегез; бара төш, тутыра төшсеннәр әле.* (Бу фигыль баблар ясаучы нкыра, нкерә кушымчалары белән бер мәгънәдәрәк йөри, шул кушымча белән алмаша ала.)

6) *сал* (өзү, тиз бетерү мәгънәсен бирә): *ашыгып әйтә салдым; тиз генә ычкындыра салмасын әле ул.*

7) *куй* (өзү, бетерү, сал фигыле кебек): *тиз генә ала куйды; аны-моны карамыйча, тиз генә әйтә куйган; кинәт бирә куймасын.*

8) *кил* (бар фигыле кебек, өзекле дәвамны аңлата): *ала килдем; ел саен арта килә; мин сиңа әйтә килдем түгелме; көн саен бер кадак арта килә.*

9) *яз* (чиккә җиту, якын килү мәгънәсен бирә): *үлә яздым; егылып китә язды; ычкындырып җибәрә язган; барып җитә язып тукталды.*

10) *күр* (үтенү, сорауны аңлата): *бара күрсәнә; ала күрмәгез; биреп җибәрә күрсәгез лә; егылып төшә күрмәсен.* (Бу соңгы фигыль бөтен төрләрдә килми, бары боерык төрендә генә йөри.)

Искәрмә. Югарыда күрсәтелгән фигыльләрдән башка тагы *а-ә, ый-и* төренә бәйләнеп әйтелгән *башла, утыр, бел* һәм башка фигыльләр дә бар. Ләкин болар үзләренең туры мәгънәләрендә кулланылалар. Аларны да җөмлә эчендә кушма фигыльләрдән санап йөртергә мөмкин: *эшли башла, эшли бел, әйтә белергә кирәк, әйтә белмәде.*

II. Үткән заман рәвеш фигыле (*ып-еп-п*) төренә бәйләнеп, фигыль күренеше ясаучы ярдәмче фигыльләрнең күбрәк йөргәннәре:

1) *ал* (әз генә, тиз генә эшләү мәгънәсен бирә): *ашап алыйм әле; черем итеп алдым (ләкин, тартып алдым, барып алган...* кушма түгел).

2) *утыр* (дәвам итү төсмерен бирә): *әкрен генә агып утыра.*

3) *бар* (башлану төсмерен бирә): *йоклап китеп барам; онытып барасың.*

4) *бул* (көч җитү, ә юклык формасында килгәндә, көч җитмәү мәгънәсен аңлата): *алып булмый, күреп булса, белеп булыр микән.*

5) *тор* (югарыда сөйләнгән кебек, чикле, вакытлы дәвам төсмерен бирә): *шунда карап тор әле; әз генә утырып тор.* (Бу фигыльнең алдагысы юклык төрендә дә килә: килми тор әле, белми торам.)

Искәрмә. Бу фигыль дип фигыленә бәйләнеп килгәндә, *уйлау, ниятләү, карар* итү мәгънәләрен анлата: *аңламас дип торасыңмы; кеше дип торам; базарга барам дип тора иде...* Шул ук фигыль, *торып* төрендә килгәндә, *көтелмәгәнлек, кинәтлек, гаҗәплек аңлата: килеп торып төште; салып торып җибәрмен...*

6) *җибәр* (башлау төсмерен бирә): *җырлап җибәрде; лампаны кабызып җибәрегез әле.*

7) *кара – күр* (сынау төсмерен бирә): *барып карасын әле, бирермен...; күтәреп кара әле; тәмләп күр; алып күрергә ярый.*

8) *кал* (форсаттан файдалану төсмерен бирә): *әйтеп кал; туйганчы ашап калдым; яшәп кал...*

9) *куй* (алдан әзерлек төсмерен бирә): *алып куйдым; алдан эшне бетереп куйган; сабагыңны кичтән белеп куй...*

10) *кит* (әйләнү, үзгәрү төсмерен бирә): *үлеп китте; кызарып киттем...*

11) *ят* (дәвам итү төсмерен бирә): *эшләп ята; юл белән китеп ята...*

Бу күрсәтелгән фигыльләрдән башка тагы шул ук *ып-еп-п* төренә бәйләнеп әйтелгән, ләкин туры мәгънәләрендә кулланылган *бет, бетер, уз, ут, чык, йөр, екъ...* кебек байтак фигыльләр бар. Бу төрдәге кушмалар югарыдагылары кебек үк үзара нык берләшеп җитмәгәннәр. Боларда алдагы фигыльне соңгының рәвеше итеп тә карарга мөмкин.

Бу *ып-еп-п* төренә бәйләнеп йөргән фигыльләр үзләре *а-ә, ый-и* төрендә килеп, яңадан бер кабат ярдәмче фигыльләр белән кушылып, өч катлы

кушма фигыльләр дә ясый алалар: *китеп бара яздым; утырып тора торыгыз әле; кычкырып җибәрә яздым; алып кала күрегез; тик сөйләп ята бирсен шунда.*

Искәрмә. *Дип* фигыленнән соң *әйтү, әйтеп әйтү* фигыльләре күп вакытта мәгънәсез бер өстәмә генә булып йөриләр: *ярар дип әйтеп әйтә диген; ялган дип әйттем; барырмын дип әйтеп әйтә* (барырмын ди), *юк дип әйтеп әйтә ди* (юк дия ди).

## Исем фигыль төренә бәйләнгән кушмалар

Күренеш ясаучы кушма фигыльләр белән хикәя фигыльләре уртасындарак тагын бер төрле кушмалар бар. Боларда үзенә махсус ярдәмче фигыльләр исем фигыль төрләренә бәйләнеп әйтелгән булалар. Ләкин боларның бәйләнешләре тагы да йомшаграк була. Боларда алдагы исем фигыльләр баб (фигыль юнәлеше), юклык кушымчалары белән дә төрләнә алалар, тик хәбәрлек төрләре (зат кушымчалары) белән генә төрләнмиләр. Соңгы фигыль (ярдәмче фигыль) баб кушымчалары белән төрләнми, башкалар белән төрләнә ала.

Исем фигыль төрләренә бәйләнгән кушмалар мәгънә ягыннан эшне үтәүгә кадәр эшләүчедә булган хәлне (теләк, ният, карар, әзерлек, омтылыш) аңлату өчен кулланылалар. Боларның ярдәмче фигыльләре күбрәк *бул, ит, кил* һәм башка бернечә фигыль була. Боларның кайсы, нинди төрдәге исем фигыльгә бәйләнеп килүенә карап, мәгънәләрендә бераз аермалар бар:

1) *ит* фигыле *ган, гән* төрендәге исем фигыльдән соң килгәндә, *сынап карау, аз гына эшләү, күренеш ясау мәгънәләрен аңлата: ашаган ит әз генә, әз генә эшләгән итегез инде.*

*исе-ыйсы, макчы-мәкче, рга-ргә, маска-мәскә* төрләреннән соң килгәндә, теләү, омтылу мәгънәләрендә була: *барасы итмәдем шул; иртә үк кайтмакчы иткән дә...; этегез тешләргә итә, кара әле; бирмәскә итәсеңме әллә, әйтергә иткән идем дә...*

2) *бул* фигыле *ган-гән* тереннән соң килгәндә, «күренеш ясау» мәгънәсендә, ә башка төрләр белән килгәндә, «карар итү, ният» мәгънәләрендә була. Мәсәлән: *күрмәгән булды; йоклаган булып ята; ул безгә киләчәк булды; алмакчы булган икән; барырга булган.* (Кайвакыт хикәя, мөмкинлек мәгънәләрендә дә килә: *ул кайткан булган; шуннан соң безгә килмәс булды; монда керергә буламы? монда уйнарга буламы?*)

3) *кил* фигыле *асы-әсе-ыйсы-исе* тереннән соң килгәндә, «теләү, кәеф булу» мәгънәләрендә була: *аласы килгән, бер дә эшлисе килми; укыйсы киләме?* (Бу төрдәге исем фигыль күп вакыт «тартым» кушымчалары белән төрләнүчән. Ул вакыт, әлбәттә, ул кушма фигыль итеп санала алмый: *минем күрәсем килә; аның йоклыйсы килгән; ашыйсыгыз киләме? ...*)

Искәрмә. *Га, гә, ка, кә* кушымчалары белән әйтелгән юнәлеш фигыльләреннән соң килгән *тор, бар, тотын, салыш* фигыльләре үзләренең туры мәгънәләрендә кулланмасалар да, шәкли яктан аларны кушма фигыльләрдән санап булмый,

бәлки юнәлеш тәмамлыгы белән әйтелгән тезмәләрдән саналырга тиеш булалар. Мәсәлән: *ашарга торалар, хәзер алырга бара, язарга тотынды, эчәргә салышкан, күрмәгәнгә салышып утыра, бер дә эшләмәскә салышты..* Юнәлеш фигыльләреннән соң *telә, маташ, кереш, тырыш, йөр...* фигыльләре үзләренең туры мәгънәләрендә киләләр.

Юнәлеш фигыльләре күп вакыт фигыль ярдәмлекләре булган *кирәк, тиеш, ярый, мөмкин* сүзләре белән кушылып йөриләр. Мәсәлән: *алырга кирәк, эшне вакытында үтәргә тиеш, монда утырырга ярыймы, аңа сөйләргә мөмкин...*

*Кирәк* сүзе кайвакыт боерык һәм шарт фигыльләр белән дә кушылып әйтелә. Бу вакытта ул кушма төрдән санала: *шулай булса кирәк иде; барып җитә алсам кирәк...*

Бу ярдәмлекләр гадәттә югарыда сөйләнгән кушма фигыльләрдән соң килеп кушылалар.

Болар өстенә җөмләнең хәбәре булып килгән бөтен исемнәр, исем фигыльләр һәм югарыда әйтелгән фигыль ярдәмлекләре, юклык төрендә булганда, *түгел* ярдәмлеге белән кушылып әйтеләләр. Димәк, бу төрләр белән дә телебездә 2–3 катлы кушма хәбәрләр ясала ала. Мәсәлән: *алырга кирәк түгел иде; шулай уйламаска мөмкин түгел иде шул.*

## Хикәя кушма фигыльләре

Җөмләнең хәбәре булып килгән һәрбер сүз, үткәннән хикәя итеп сөйләнгәндә, хикәя ярдәмче фигыльләре белән кушылып, үзенә бер төрле кушма фигыльләр ясыйлар. Хикәя фигыле булып, *и* тамырыннан алынган *иде, икән, имеш, исә* кебек ким фигыльләр йөри.

Искәрмә. Борынгы төрек телендә бу фигыль *ирде, иркән, ирмеш, ирсә, ирер, ирмәс* төрләрендә кулланылган һәм башка фигыльләр кебек бөтен төрләре дә тулы йөргән булса кирәк[1]. Бу фигыльнең *имәс* төре үзбәк, казах, кыргыз, алтай телләрендә йөри, бездә бу урында *түгел* сүзе килә. Төрекмән телендә *иде* фигыле, кыскарып, үзгәреп *ди* төрендәге хикәя кушымчасына әйләнеп киткән. Җанлы татар телендә *идем, идек, идең, идегез, иде* төрләре *ием, иек, ием иегез, ие* кебек сөйләнәләр (*д* авазы *й* гә үзгәрә). Хәтта калынлык, нечкәлектә дә алдагы сүзгә ияреп әйтелгәли; димәк, бездә дә кушымчага әйләнеп бара.

Бу фигыльләрдән телебездә иң күп йөргәннәре – *иде, икән* төрләре. Болар, 2 нче зат формасындагы боерык, үткән заман чын (хикәя) фигыльдән һәм хәл фигыльләреннән (рәвеш, вакыт фигыльләре) башка, һәрбер фигыльгә һәм җөмләнең хәбәре булып килгән бөтен сүзләргә кушыла алалар. Мәсәлән: *Без күрсәк иде, әйткән булыр идек; алар уйнамасыннар иде; булган иде; килмәгәй иде* (*килмәгәе, булмагае* төрендә дә әйтелә); *алганнар икән; килмәс идем; күрәчәк икәнмен; әйтмәкче идем дә...*

---

[1] Татар телендә *нәрсә сүзе нә ирсә* төреннән кыскарып, соңыннан мәгънәсен дә үзгәртә төшүдән килеп чыккан бер сүз. – *Автор.*

Рәвеш, вакыт (хәл) фигыльләре җөмләнең хәбәре була алмаганга, үткән фигыль үзе хикәя мәгънәсендә булганга, аларга бу фигыльләр өстәлә алмый.

Искәрмә. Иде фигыле казах, кыргыз, үзбәк, төрекмән телләрендә үткән рәвеш фигыльләре белән дә кушыла ала, *де-ды* төренә кыскарган була: *әйтеп идем – айдыбдым; килеп идем – гелебдем.*

*Имеш* белән *икән* төрләре татар телендә икәве бер мәгънәдәрәк йөриләр һәм бер-берен алмаштыра алалар: *юк икән, юк имеш, киләчәк икән, киләчәкләр имеш,* (*күренә ки, булып чыкты – оказывается...* мәгънәләрен аңлаталар).

*Ләкин* *имеш* төре, хикәя мәгънәсендә йөрүдән бигрәк, күп вакыт юкны бар итеп сөйләүчедән көлү урынында – *гуя, янәсе* мәгънәләрендә йөрүчән, бу вакыт ул кушма хикәя төре булудан чыгып, кереш сүзгә әйләнә, һәм соңгы мәгънәдәге *имеш* җөмләнең теләсә кай урынында һәм рәвеш, вакыт, үткән заман фигыльләреннән соң да килә ала. Мәсәлән: *имеш, мин аны күрмәгән! Син бернәрсә дә эшләмәдең, имеш!*

Бу фигыльләрдән шарт төрендәге исә фигыле күбрәк хәбәр ярдәмлекләре булган *бар, юк, кирәк, тиеш, мөмкин, түгел* сүзләреннән соң килүчән. Башка сүзләрдән соң бездә аның урынына күбрәк *булса* сүзе йөри. *Исә* фигыле бу ярдәмлекләр белән кушылып, кыскарып һәм үзгәреп, бер сүзгә дә әйләнеп киткән. Мәсәлән: юк исә – югыйсә – юкса, кирәк исә, кирәксә.

Искәрмә. *Исә* фигыле, үткән заман чын фигыльгә кушылып, *шул чакта, шунда ук* мәгънәсендәге яки шарт фигыль мәгънәсендәге кушма фигыль ясый: *әйттем исә* (әйткәч тә), *ачулана; эшкә кереште исә, дөньясын оныта.*

## *Иде, икән, имеш* ярдәмче фигыльләре белән ясалган кушма фигыльләрнең төрләнеше

Хикәя ярдәмче фигыльләре баб – дәрәҗә кушымчалары һәм юклык (*ма-мә*) кушымчалары белән һич тә төрләнмиләр (кайбер төрек шивәләрендә *имәс* төре генә бар).

Хәбәрлек (зат) кушымчалары белән төрләнешләренә килгәндә, җанлы татар телендә аларның күплек санындагы өченче затка нисбәт белән төрләнешләре дә юк (*иделәр, икәннәр, имешләре* төре килми). Аның урынына алдагы сүзләр *лар-ләр* белән әйтелүчән. Беренче, икенче затка нисбәт ителгәндә, алдагы сүзләр фигыль булмаганда, хикәя фигыльләре төрләнә, ләкин алдагы сүзләр фигыль булса, 1–2 нче зат кушымчалары белән боларның кайсы булса да берәрсе генә төрләнергә тиеш була. Алдагы фигыль 1–2 зат кушымчалары белән төрләнсә, хикәя фигыльләре төрләнми, хикәя фигыльләре төрләнсә, алдагы фигыльләр төрләнми. Боларның кайсысын нисбәт белән төрләндереп әйтү сөйләүченең үз ихтыярында. Шулай булса да, монда теге яки бу фигыльнең 1–2 зат

кушымчалары белән төрләнүендә, хикәя фигыльләрнең нинди фигыль белән әйтелүләренә карап, азмы-күпме карарлашу тенденциясе барлыгы да сизелә. Моны 27 таблицадан күрергә мөмкин. (Монда 1–2 затка нисбәт белән төрләнгән урыннар плюс (+) билгесе белән, төрләнмәгәннәре минус (–) белән күрсәтелә.)

27 таблица

| Алдан килгән фигыль төре | | | Хикәя ярдәм фигыльләре, төрләнеп төрләнмәүләре | | |
|---|---|---|---|---|---|
| төре | мисалы | нисбәт белән төрләнү, төрләнмәү | иде | икән | имеш |
| 1) Боерык | ал | +, – | +, – | – | |
| 2) Теләк | алгай | – | + | | |
| 3) Шарт | алса | + | – | – | |
| 4) Хәзер | ала | +, – | + | – | – |
| 5) Үткән | алган | +, – | + | +, – | – |
| 6) Җавап | алыр, алмас | +, – | + | – | – |
| 7) Киләчәк | алачак | +, – | + | –, + | – |
| 8) Киләсе | аласы | – | + | + | + |
| 9) Карар | алмакчы | – | + | + | – |
| 10) Каргау | алгыры | – | | + | |
| 11) Юнәлеш | алырга | – | + | + | – |

## Хикәя фигыльләрнең өстәмә кушымчалар (кисәкчәләр) белән элемтәсе

Өстәмә кушымчалар (яки ярым кушымчалар) гадәттә башка сүзләрнең, башка төрләрнең иң азагында килеп кушылалар. Ләкин аларның хикәя фигыльләре белән кушылуында шушы гомуми кагыйдәдән беркадәр авышу барлыгы күренә. Шуңа күрә хикәя фигыльләренең бу кушымчалар белән элемтәсе турында бер уңайдан берничә сүз әйтеп китәргә туры килә.

1) өстәмә кушымчалардан *дыр* (*торыр* дан үзгәргән) 3 нче затка нисбәт ителгән хәзерге заман фигыле белән иде хикәясенең ике уртасында гына килә, башка фигыльләрдә, башка урында кулланылмый: *аладыр идем, китәрәдер иде, беләдер идең, барадыр идегез*...

2) *ла-лә* кисәкчәсе, башка сүзләрдәге кебек, хикәя фигыльләреннән соң иң азактан килеп кушыла: *килгән идем лә, юк икән лә, күрәчәк идегез лә*...

3) *да-дә* кисәкчәсе хикәя фигыльләреннән элек тә, соң да килүе мөмкин, ләкин хикәядән соң килүе күбрәк очрый һәм телгә ягымлырак та: *алмакчы идем дә – алмакчы да идем; алыр идем дә – алыр да идем; күргән икән дә – күргән дә икән*...

4) *мы-ме* кисәкчәсе иде фигыленнән алда да, ахырда да килә ала,

ләкин ахырдан килүе артыграк. Мәсәлән: *алган иденме– алганмы иден; юк идеме – юкмы иде..., ә икән* фигыле белән, киресенчә, бу кисәкчә, һәрвакыт алдан гына килә. Мәсәлән: *алганмы икән, бармы икән, юкмы икән...*

*Мы-ме* кисәкчәсе, беренчедән, һәрвакыт *икән* алдыннан гына килгәнлектән, икенчедән, алдагы сүзнең басымын үзенә алмаганлыктан (басымсыз әйтелгәнлектән), бу фигыль белән бергә кушылып, *микән* төрендә үзенә аерым бер сорау ярдәмлеге булып киткән. Шуңа күрә ул *микән* төрендә теләсә нинди сүз артыннан (үткән фигыль һәм иде хикәясе артыннан да) килә ала. Мәсәлән: *барды микән? юк микән? шулай итәргә уйлый иде микән?* (Сорау алмашлары артыннан *микән* төре килми, *икән* төре генә килә: *нәрсә икән? ничек икән? кайсы икән? кая икән? кайда икән?*)

5) *мыный-мени* кисәкчәсе иде фигыленнән соң килә; *икән* фигыле белән очрашканда исә, икегә бүленеп, *ме* кисәге алдан, *ни* кисәге азакта кушыла: *таба алган микәнни? күреп булмас микәнни? китте микәнни?*

Искәрмә. Ярым хикәя, ярым кереш сүз урынында кулланылган ди фигыле белән очрашканда, да-дә кисәкчәсе алдан, *мы-ме-мыный-мени, микән, микәнни* сораулары һәрвакыт ахырдан килә. Мәсәлән: *алып китә, нитә, китә икән дә, ди...; пионер шулай була димени; шулай итәргә ярый ди микәнни...*

Өстәмә кушымчалар (кисәкчәләр) белән бер рәттә кулланыла һәм аларның кайберәүләре белән алмаша да ала торган *ласа, лабаса, ич, бит, бугай, әллә, шул, әле, инде, ахры, соң* кебек өстәмә хәбәр ярдәмлекләре исә, ялгыз хәбәр белән дә, кушма хәбәрләр белән дә иң азактан гына кушылып йөриләр. Болар хәбәрнең катгыйлеге, дөреслеге ни дәрәҗәдә булуын аңлату өчен кулланылалар. Мәсәлән: *юк әллә, юкмы әллә, юк бугай, юк ахры, юк ласа, юк ич, юк бит, юк шул, юк әле, юк инде...*

## Күп катлаулы кушмаларда сүз тәртибе һәм аларның морфологик төрләр белән элемтәсе

Кушма фигыльләрнең ясалышы һәм кушма хәбәр төрләре турындагы тикшеренүләрнең нәтиҗәсе итеп, түбәнге фикерләрне әйтеп китәргә туры килә:

1) Югарыда сөйләнгән кушма фигыльләр, берсе артыннан берсе мәгълүм тәртиптә тезелеп, күп катлаулы фигыльләр, күп катлаулы хәбәр төрләре ясый алалар, бу катлаулы төрләр *кирәк, тиеш, түгел...* кебек ярдәмлекләр белән аралашып һәм хәбәр ярдәмлекләре (*ласа, ич, әле...*) белән өстәлеп, тагын да ныграк катлаулана алалар. Мәсәлән: *шау киләләр иде; тәэсир итә алмаган; кабул итә алыр микән; алып бара бирергә кирәк иде; бара алыр иде микән соң; кирәк түгел иде әле.*

2) Бу катлаулы төрләр һәр яктан, тәртипләре һәм функцияләре ягын-

нан да, ялгыз фигыльләрнең морфология юлы белән төрләнешләренә охшыйлар, алар белән тиңдәш төрләр: фигыль ясаучы кушма төрләр – фигыль ясаучы кушымчаларга тиңдәшләр, күренеш ясаучы төрләр – баб (дәрәҗә) ясаучы кушымчаларга охшыйлар. (Бу соңгылары һәр икәвендә берничә катлаулы була ала.) Ялгыз фигыльләрдәге юклык (*ма-мә*) төрләрендә – *түгел* ярдәмлеге, заман һәм хәбәрлек кушымчаларына – хикәя ярдәм фигыльләре, ниһаять, өстәмә хәбәр ярдәмлекләре тәңгәл киләләр. Аларның урыннары, тәртипләре дә бер үк төсле була. Мин ул кушма төрләрне баштан ук, аларның үзара берсе артыннан берсе кушылып килү тәртипләре буенча, тикшереп килдем. Кушымчаларның ялгануларында күренгән кебек, кушма төрләрнең тезелүләрендә дә азмы-күпме урынлашу, ныгу сизелә, шул тәртипне үзгәртү я мөмкин булмый, я мәгънә үзгәртүгә сәбәб була.

Кыскасы, кушымчалар ярдәме белән сүз төрләндереп, фикер аңлату белән кушма төрләр аркылы уй белдерү арасында тулы рәвештә шәкли һәм мантыйкый берлек, элемтә бар.

Бу фикерләрнең нәтиҗәсе буларак, безнең грамматикаларыбызда аерым сүзләрнең кушымчалар белән төрләнеше өйрәнелгәндә, шулар белән берләттән, телебезнең бер үк мантыйкый табигате, бер-беренә тәңгәл күренеше булганы өчен, шул кушымчаларга каршы кушма төрләрне, ярдәмлекле тезмәләрне дә бергә чагыштырып, тиңләштереп өйрәнә барырга тиеш булачагы үзеннән-үзе килеп чыга торгандыр.

## ФУНКЦИОНАЛЬ СҮЗЛӘР (ЯРДӘМЛЕКЛӘР)[1]

Функциональ сүзләр (ярдәмлекләр) дип, тулы мәгънәле булмыйча (яки булса да аны югалтып), тел белән аралашу вакытында сүзләрнең, сүз тезмәләренең үзара бер-беренә бәйләнешен, мөнәсәбәтен белдерү функциясен үтәгән ярым сүзләр, сүзчекләргә әйтәбез. Болар җөмләдә фикер матдәсе, җөмләнең материаль мәгънәле кисәге була алмыйлар.

Телебездәге кушымчаларны өйрәнү нихәтле кирәкле булса, бу ярдәмлекләр дә шулай өйрәнелергә тиешләр. Болар фикерне оештыру, бәйләү һәм формалаштыруда әһәмиятле урын тоталар. Бигрәк тә рус теленнән татарчага, һәм киресенчә, тәрҗемә итү эшләренең уңышлы баруы өчен бу ярдәмлекләр белән ныклап таныш булу кирәк.

Шулай булса да, әлегә кадәр татар телендә ярдәмлекләрнең ныклап өйрәнелүе күренми әле.

Әлегә кадәр чыккан татар грамматикаларында бу мәсьәләдә телебезнең табигатенә нигезләнгән, таянычлы гыйльми мәгълүмат юк. Булган хәтлесе дә я гарәп теленең иске сарыф-нәхүләренә ияреп төзелгәннәр, я иске рус

[1] Бу материал – Г.Алпаровның 1933 елда Казан дәүләт педагогия институтында укыган бер лекциясенең конспекты. – *Ред.*

грамматикалары аркылы иске грек грамматикалары традициясен дәвам иттерәләр. Шуның аркасында без телебездә функциональ сүзләрне тулы мәгънәле сүзләрдән чын мәгънәсе белән аерып таный алмыйбыз. Бигрәк тә, телгә һәм тел фактларына диалектик материализм методлары буенча карый белмәгәнлектән, без андагы каршылыкларны, аларның диалектик берлекләрен аңлый алмый аптырыйбыз.

Каюм Насыйридан башлап, Октябрь революциясенә чаклы чыккан татар грамматикаларында, беренчедән, бу ярдәмлекләргә бик аз урын бирелгән, икенчедән, аларны төркемләүдә ныклы бер принцип куелмаганлыктан, алар телнең башка фактлары белән аралашып, чуалтып күрсәтелгәннәр.

Монда ярдәмлек төркемчәләре арасында без, кушымчалардан алып, җөмләнең мөстәкыйль кисәге була алган вакыт, урын сүзләрен дә, рәвеш, ымлык, кереш сүзләрне дә очрата алабыз. Мәсәлән, Каюм Насыйри ярдәмлекләрне, гарәп теленә ияреп, «хәрефләр» дип атап, гарәп теле сарыф нәхүләрендәге кебек итеп, аларны хәрфеҗәр, гатыф, истисна, тәшбиһ, бәян, заман һ. б. төркемнәргә (барлыгы 18 төркем) аера. Алар арасында *белән, өчен, ләкин, бәлки, әгәр, яки*... кебек чын ярдәмлекләр белән бергә *ча, да, дан, сыз, мы-ме* кебек кушымчалар да һәм *кайчан, инде, әйе, аст, өст*... кебек тулы мәгънәле сүзләр дә бар.

Насыйридан соң 30–35 ел эчендә язылган грамматикаларда ярдәмлекләр төрлечә исемләнәләр һәм төрлечә төркемләнәләр. Боларда да ярдәмлекләр, кушымчалар һәм тулы мәгънәле сүзләр аралашалар, буталалар. Бу мәсьәләдә грамматикаларыбызда бердәмлек тә һәм кирәгенчә ачыклык та юк. Димәк, ярдәмлекләрне ныклап тану һәм аларны гыйльми категорияләргә аеру бездә чишелеп бетмәгән мәсьәлә булып тора әле.

Кирәк тулы мәгънәле сүзләрне, кирәк ярдәмлекләрне грамматик төркемнәргә аерганда, аларның мәгънә якларын, функцияләрен игътибарга алу белән бергә, грамматик формалашу якларына да дикъкать итәргә кирәк була. Фәкать шул чакта гына без туры нәтиҗәләргә ирешә алачакбыз.

Грамматик якларны күзәтү дигән сүздән барлык тышкы фактларны, шәкли якларны аңларга кирәк. Тулырак әйткәндә, фонетик яктан басым һәм интонация, морфологик яктан ясалу, төзелеш, төрләнү, төрләндерү, кабатлануларны аңларга кирәк. Синтаксик яктан сүз тезмәсендә нинди сүзләргә, сүз төркемнәренә бәйләнеп йөрүләрен яки бәйләнмәүләрен, тезмәдәге урын, тәртипләрен, бәйләнеш, оешу, ярашу, теркәлүләрен һәм башка эчке-тышкы аерымлыкларны игътибарга алуны аңларга кирәк.

Авазлар гармониясе (сингармонизм) ягыннан караганда, без монда ярдәмлекләрнең әйтелүендә төп сүзгә ияреп йөргән кушымчалар һәм ярым кушымчалар арасында зур аерма күрәбез. Аларны бер-бере белән саташтырудан котылабыз. (*Дай-дәй, тай-тәй, ча-чә, гына-генә, кына-кенә, да-дә,*

*та-тә, ук-үк, мы-ме, мыный-мени, сана-сәнә...* монда кермиләр, кушымчага калалар.)

Морфологик яктан күзәткәндә, турыдан-туры үз мәгънәләрендә кулланган һәм килеш (падеж) кушымчаларын алган вакыт, урын исемнәре дә, үз башына аерым, тулы мәгънәле (материаль мәгънәле) бүтән сүзләр дә ярдәмлекләр белән чуалмаячак.

Синтаксик яктан үзлекләрен күзәткәндә, җөмлә кисәкләренә бәйләнеше булмаган ымлыклар, кереш, эндәш сүзләрне ярдәмлекләр белән бутап йөртүдән котылабыз.

Шулай итеп, без саф функциональ сүзләрнең үзләрен аерып алып, аны башкалар белән аралаштырмыйча, анализ ясый алабыз һәм, аларны үзара төркемнәргә бүлгәндә дә, бу метод белән дөрес нәтиҗәләр чыгара алабыз. Кайбер сүзләрнең төрле төркемнәр арасында, төрле функцияләрдә йөрүләренә аптырарга ярамый. Моның кебек хәлләр башка категорияләр арасында да очрый. Чөнки без монда сүзләрнең ялангач – формаль үзләрен генә төркемнәргә бүлмибез, бәлки аларны грамматик-функциональ категорияләргә аерабыз. Бу икәве – ике нәрсә. Шуны да әйтеп китәргә кирәк, мин монда һәрбер аерым ярдәмлекнең үзенә аерым булган мәгънәләренә, төрле оттенокларына тукталмыйм; монда минем теләгем – аларның уртак грамматик функцияләрен, категорияләрен билгеләү. Аларның һәрберсенең үз мәгънәләрен тикшерү, бер яктан, лексикология эше булса, икенче яктан, артык тирәнгә керү булганлыктан, монда мин ярдәмлекләрнең ул якларына тукталмыйм.

Югарыда әйтелгән барлык шартларны күздә тотып, без телебездәге ярдәмлекләрнең түбәндәге төркемнәргә бүленүен күрәбез:

1) с ү з   я р д ә м л е к л ә р е;

2) т е з м ә   я р д ә м л е к л ә р е.

**Сүз ярдәмлекләре** билгеле бер сүз төркеменә, җөмлә кисәге була алган, үзенә аерым материаль мәгънәле мөстәкыйль бер сүз белән бәйләнеп йөри торган була.

Сүз ярдәмлекләре үз эчләрендә, функцияләрендә һәм формаларында булган үзлекләренә карап, тагы өч төркемгә бүленәләр:

а) көчәйтүче ярдәмлекләр (рәвеш ярдәмлекләре – наречийные),

б) бәйләүче ярдәмлекләр (тәмамлык-килеш ярдәмлекләре – послелоги),

в) өстәмә ярдәмлекләр (хәбәр ярдәмлекләре – сказуемые послелоги).

Рәвеш ярдәмлекләре аерым сүзнең алдыннан аның белән янәшә әйтелеп йөриләр, синтагманы башлаучы бер кисәк булып киләләр. Функциональ яктан бу төркемгә кергән ярдәмлекләр үзе бәйләнгән сүзнең мәгънәсен көчәйтүче, дәрәҗәсен билгеләүче булып хезмәт итәләр.

Гыйбарә (синтагма) басымы боларның үзләрендә була. Функцияләре ягыннан болар рәвешләргә тиң булалар, шулай ук үзләре дә рәвешләргә һәм сыйфатларга бәйләнеп йөриләр. Башка сүз төркемнәренә бәйләнеп

йөргән рәвешлекләр дә сирәкләп очрыйлар. Болар кушымча белән төрләнмиләр, шулай ук ясалмыйлар да. Бу ярдәмлекләр шулар:

| | | | |
|---|---|---|---|
| *иң* | *утә* | *гаять* | *аеруча* |
| *бик* | *артык* | *шактый* | *гаҗәп* |
| *шау* | | *әллә* | *биниһая* |
| *һич* | *ифрат* | *аерата* | *бихисап.* |

Искәрмә. Без монда функциональ сүзләрнең грамматик бер категориягә хас булганнарын алдык. Аларның грамматик булмыйча, бер я берничә сүзгә генә бәйләнгәннәре һәм конкрет бер сүзгә хас булганнары бар. Боларны кушма сүздән санарга туры килә. Мәсәлән: *зык кубу, шөр җибәрү, тап килү, тач төшү, кырт кису, шак кату, дөм сукыр, өр яңа, шыр ялангач, шыр тоз, шар ачык, җете кызыл* һ. б. Боларга параллель функцияле кушымчаланган төрләрдән *кып-кызыл, нәп-нәзек...* сүзләрендәге *кып, нәп* кебек сыйфатларның башына ялганып йөри торган кисәкләр бар.

**Тәмамлык ярдәмлекләре (послелоги).** Болар килешләр белән төрләнә алган һәрбер сүзләргә (исемнәргә) ияреп, алар ахырыннан янәшә әйтелеп йөриләр, синтагма басымын үзләренә алмыйлар. Боларның функциясе дә килешләр кебек үк булып, үзләре белән бергә әйтелгән сүзләрнең (исемнәрнең) фигыльләргә, башка сүзләргә бәйләнешен, мөнәсәбәтен белдерү өчен кулланылалар. Болар исем төрлекләре белән төрләнмиләр һәм ясалмыйлар.

Искәрмә. Тезмәдә охшату функциясен үтәгән ярдәмлекләр, охшатылмышлары әйтелмәгәндә, үзләре исем төрлекләре белән төрләнә алалар, үзләренең алдындагы сүз белән теләсә нинди тәмамлык булып куллана алалар (ул чагында аларда гыйбарә – синтагма басымы да була ала).

Бу тәмамлык ярдәмлекләренең үзләре караган исемнәр белән бәйләнешләре тезү юлы белән дә, ияртү юлы белен дә була ала. Бу яктан алар 4 төркемгә аерылалар:

а) фәкать тезү юлы белән бәйләнүчеләр – *килеш, көе, көенчә, хәлдә, рәвештә, тәүмәл;*

б) алдагы сүзнең (күбрәк алмашлыкларның) иялек килешендә булуын (*ның-нең* белән төрләнүен) теләүче ярдәмлекләр – *белән, белән бергә, белән янәшә* (бергәлек, корал, сәбәп, рәвеш, кушу мәгънәләрендә):

– *кебек* (күк, кеби), *төсле, шикелле, сымак* (сыман), *рәвешле, ише* (охшату мәгънәсендә);

– *чаклы, чикле, тикле, тик, тигентен, шай, хәтле, кадәр, тәүмәл* (чагыштыру мәгънәсендә), *буе;*

– *өчен* (багышлау, сәбәп, максат мәгънәләрендә), *сәбәпле, саен* (сан);

– *аркылы, аша, утә, утәли, таба, сары* (арачылык);

в) алдагы сүзнең чыгыш килешендә булуын (*дан-дән...* кушымчалары белән төрләнүен) теләгән ярдәмлекләр:

– *элек, борын, әүвәл, ары, аннары, бире, бирле, соң* (соңра), *кире, түбән* (кала);

– *башка, бүтән, битәр, бигрәк, гайре, үзгә, тыш, артык;*

г) юнәлеш килешен (*га-гә*... кушымчалары белән төрләнүен) теләүче ярдәмлекләр:

– *таба, каршы* (юнәлеш мәгънәсендә), *була, күрә, карап, бинаән, нисбәтән, караганда* (сәбәп, чагыштыру);

– *чаклы, чикле, тикле, кадәр, хәтле* (чикләү мәгънәсендә).

Искәрмә. Бу ярдәмлекләр килеш кушымчалары булган *ның-нең, га-гә, ка-кә, ны-не, дан-дән..., ча-чә, дай-дәй*... кушымчаларына параллель булалар. Бу бер яктан. Икенче яктан, бу ярдәмлекләр белән тулы мәгънәле сүзләр арасында ике уртада торган, ялгыз кулланылмый торган, ләкин исемнәр белән иялек төрендә бәйләнеп, үзләре төрләнә һәм һәрвакыт тартымлы формада гына кулланыла торган ярым сүзләр бар: *алд, арт, аст, өст, тыш, кат, карш (ы), тур (ы), хак, ара, тирә, урын, җир, төш, әйләнә, чак, ян, як, кыр, чит, урта, төп, буй, уңай, кире, җай, рәт* кебекләр.

**Өстәмә ярдәмлекләр (хәбәрлекләр).** Болар – җөмләнең теләсә нинди төркемнән булган хәбәре артыннан аның белән янәшә әйтелә торган ярдәмлекләр. Болар хәбәрнең урыны үзгәрү белән аннан аерылмыйлар. Синтагма басымнары боларга күчми, җөмләнең хәбәрендә була. Болар хәбәрләрнең мәгънәсен төгәлләү, карарлылык яки карарсызлык белдерү өчен киләләр, үзләре төрләнмиләр. Болар өстәмә кушымчаларга параллель булалар, шундый ук функцияне үтиләр. Өстәмә ярдәмлекләр шулар: *бит, ич, лабаса, ласа* (казахчада – *гой*, үзбәкчәдә – *ку*), *ахры, ахрысы, бугай, шикелле, сымак, күрәсең, әле, инде, соң, шул, ул, микән, әллә, икән, имеш* (булыр, булса кирәк).

Искәрмә. 1. *Түгел* ярдәмлеге дә шушы хәбәрлекләргә керә, ләкин моның аермасы бар. *Түгел* ярдәмлеге зат белән төрләнә, өстәмә кушымчаларны да ала. *Түгел* ярдәмлеге исемнәрдә юклык төре ясый һәм юклык төрендәге фигыльләрнең *ма-мә* ләренә параллель килә.

2. Тулы мәгънәле сүз белән ике арада торган шул ук хәбәрлек функциясендәге сүзләр бар: *кирәк, тиеш, мөмкин, юк, бар.* Болар үзләре аерым торганда да хәбәр була алалар һәм өстәмәләр белән төрләнә алалар. Боларны үзенә бер төркем «хәбәрлек сүзләр» дип атап аерырга ярый.

3. Шулай ук ярдәмче фигыльләр дә тулы мәгънәле сүз белән ярдәмлекләр арасында торалар дияргә мөмкин. Болар үз мәгънәләрендә кулланылмаганда гына ярдәмлек булалар. Бу төркемгә *ит, бул, тор, иде, ди*... керәләр.

## Тезмә ярдәмлекләре

Хәзер тезмә ярдәмлекләрен карыйк.

Болар аерым бер сүз, сүз төркеме яки җөмлә кисәге белән дә бәйләнмичә, һәрбер сүз тезмәсенең үзара бер-берсенә билгеле бер эчке бәйләнешен телдә күрсәтү өчен, гомуми мөнәсәбәтне белдерү функциясен үтәү өчен кулланылалар. Сүз ярдәмлекләре тар, хас булсалар, тезмә

ярдәмлекләре киң, уртак ярдәмлекләр булып торалар. Болар аерым сүз яки аерым кисәк белән бәйләнмәгәнгә күрә, үзләренә аерым басымлы да булалар (басым күп вакыт беренче иҗекләрдә була). Алар кайвакыт тулы мәгънәле сүзләр кебек, үз башларына синтагма булып та килергә мөмкин. Болар ике якка тигез бәйләнәләр (боларның кайсылары ахыргы сүзләргә, кайсылары алдагы сүзгә якынрак торалар).

Тезмә ярдәмлекләре төрләнү, төрләүгә дә катнашмыйлар, пассивлар.

Тезмә ярдәмлекләрен үз эчләрендә, функцияләренә карап, бик күп төрле төркемчәләргә аерырга мөмкин (28 табл.). Иң башта, болар өч төркем хасил итәләр:

1) тезүчеләр (сочинительные),

2) ияртүчеләр (подчинительные),

3) мөнәсәбәтле сүзләр (относительные слова).

Тезүчеләр тезмә кисәкләренең нинди булса да үзара бер мөнәсәбәттә торуларын, шулай торып оешуларын билгертәләр.

Болар үзләре түбәндәге группаларга бүленәләр:

**Кушучылар**: *һәм (һәм дә), тагы (н), тагы (н) да, (дәхи, дәхидә, дәхидәк тә), янә, шулай ук* (ушандак), *аннары.* Болар кушу-җыю функциясен үтиләр.

**Каршы куючылар**: *ләкин, әмма, ә, тик, фәкать, бары, мәгәр* (анчак, ялгыз), *исә, булса.* Болар каршы кую функциясен үтиләр.

**Өстәүче**: *хәтта* ( – түгел, хәтта..., – кая, хәтта...).

**Алмаштыручылар**: *ягъни, бәлки* ( – түгел, бәлки...).

**Янәшәләүчеләр** (тигезләүчеләр): *я, яисә, яки, яхут* (я булмаса, булмаса, әллә).

Тезүче ярдәмлекләр җөмләнең аерым кисәкләрен һәм шулай ук аерым җөмләләрне дә үзара бәйләүгә хезмәт итәләр, ярдәмлекләрнең кайберләре (*һәм, янә, яки...*) кабатланып килергә дә мөмкин; кайберләре исә (*ләкин, әмма, ә, фәкать...*) тик бер генә тапкыр әйтеләләр, ә кайберләре (*ни – ни, әллә – әллә, бер – бер, кирәк – кирәк...*) тик кабатланып кына киләләр.

**Ияртүчеләр** (подчинительные). Болар тезмә кисәклеләренең берсенең икенчесенә ияреп бәйләнүен күрсәтәләр, күбесенчә, җөмләләрне берберсенә бәйлиләр һәм алар арасында сәбәплек, нәтиҗә, шартлык, кире, чагыштыру, аңлату, охшату... кебек мөнәсәбәтләрне күрсәтәләр. Боларның үз эчләрендә шушы группалар бар:

**Сәбәплек**: *чөнки* (аның өчен, нигә дисәң), *нигә, нишләп, ни өчен, өчен* (зираки, мадәмки, рас, таки, таинки);

**Шартлык**: *әгәр* (әгәр дә, әгәренки, әгәр дә мәгәр);

**Шартсызлык** (кирелек): *хәлбуки, халәнки, гәрчә* (әгәрчә);

**Ошату, чагыштыру**: *гүя, янәсе* (санки), *гүяки, нәкъ, әйтерсең* (кебек, шикелле...).

## Мөнәсәбәтле сүзләр (кайтаручылар)

Болар бер-беренә каршы әйтелгән сорау алмашлыклары белән күрсәтү алмашлыклары булып, монда алар фәкать җөмләләрнең фикер элементларының үзара бәйләнешен күрсәтү өчен генә кулланылалар. Шуңа күрә сорау сүзләрендә синтагма басымы да булмый.

Мөнәсәбәтле сүзләр икесе ике җөмләдә торып, ул җөмләләрнең кара-каршы бер-беренә бәйләнешен белдерәләр. Бу охшашлыкларның берсе генә булуы да мөмкин. Күрсәтү, алмашлыгы – баш җөмләдә, ә сорау алмашлыгы иярчен җөмләдә килә. Баш һәм иярчен җөмләләрнең тәртибе, урынына карап, төрлечә булырга мөмкин.

Мөнәсәбәтле сүзләр булып кулланыла торган сорау алмашлыклары шулар:

*кем, нәрсә, ни* (кем дә кем), *нинди, ничә, ничек, күпме, ничаклы, никадәр, кайсы, кайсы кем, кайда, кая, каян, кайчан, кайчан да.*

Боларга каршы кулланылган күрсәтү алмашлыклары: *шул, ул, шундый, шулай, алай да, шулчаклы, шулкадәр, шунда, шулчакта* (шуңа күрә, шуның өчен, аның саен, шунлыктан) һ.б.

Искәрмә. Мөнәсәбәтле сүзләр бөтен килеш төрләре белән күп вакыт икәве дә бер төсле үк төрләнәләр, тиң – мовафыйк бәйләнәләр. Кайвакыт аларның берсе төшеп тә кала.

**Фукциональ сүзләр (ярдәмлекләр)нең схемасы**

*28 таблица*

| | |
|---|---|
| Сүз ярдәмлекләре | Тезмә ярдәмлекләре |
| Рәвеш ярдәмлекләре (ачыклаучылар-көчәйтүчеләр) | Тезүчеләр-теркәүчеләр |
| Тәмамлык ярдәмлекләре (бәйләүчеләр) | Иярткүчеләр-буйсындыручылар |
| Хәбәр ярдәмлекләре (төгәлләүчеләр) | Мөнәсәбәтле сүзләр |

Сүз ахырында шуны әйтергә кирәк: безнең бу схемабыз телне марксизм-ленинизм өйрәтүләре буенча, диалектик материализм методологиясе буенча тану булып торачак, чөнки без аны телнең үз фактларыннан алабыз, ул догматик түгел. Монда телнең чынбарлыгы һәм аны дөрес аңлау чагыла, тел чынбарлыгындагы фактлар, күренешләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтләре күренә. Нәкъ без күреп үткән ярдәмлек сүзләрнең дә кайберләре фактларны ачыклый, фактлар арасындагы бәйләнешләрне күрсәтә, төгәлли; кайберләре фактларны куша яки аера, өсти, тигезли, алмаштыра; ә кайберләре исә үзара шарт, сәбәп, нәтиҗә, охшашлык

бәйләнешләренә, үткәндәге фикер белән хәзерге фикер арасындагы бәйләнешкә күрсәтә. Болар – бары да чынбарлыкта, тормышта һәм анда бар нәрсәләр, шуңа күрә әнә алар телдә дә шул рәвешчә чагылганнар. Телдә, татар телендә, аның ничек чагылуын, аның чагылу формаларын ачу һәм шуннан соң аларны системага салу – менә безнең телне белү дәрәҗәбез шуның белән табыла һәм билгеләнә.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ИЯРЧЕН ҖӨМЛӘЛӘР БАРМЫ?[1]

Татар теленең грамматикасында гыйльми эшләнеп, системага салынып бетмәгән урыннар бар. Шулардан берсе – иярчен җөмләләр мәсьәләсе. Безнең әлегә чаклы иярчен җөмләләр дип аерып килгән грамматик категориябез башка грамматик фактлардан аерым-ачык итеп чикләнмәгән, билгеләнелмәгән. Шуның өстенә аларның бармы-юкмы икәнлеге дә чишелмәгән бер мәсьәлә булып тора.

Эш менә нәрсәдә: безнең иярчен җөмләләребез башка теллардәге ияртелмә (придаточное – гипотаксис) җөмләләргә охшамыйлар. Мәсәлән, рус телендәге ияртелмә җөмләләр, күбесенчә, баш җөмләгә теркәгечләр (союзы) белән бәйләнгән булалар, һәм аларның хәбәрләре тәмамланган формада килгән була. Мәсәлән: По лицу вижу, что говоришь неправду. (Чехов.) *Если ты его увидишь, обними его братски.* (Пушкин.) *Так как работать было трудно, вызвали двух новых рабочих.*

Татар телендәге иярчен җөмләләр дип йөртелгән сүз тезмәләре исә, баш җөмләгә теркәгечләр белән түгел, бәлки иярчен фигыльләр (шарт, вакыт, хәл һ. б.) формалары белән, шулай ук тәмамлык төрләре белән бәйләнгән булалар. Мәсәлән: *Атна буенча яңгыр яуганга, иделдә су бик арткан. Бер шытырдауны ишетсәм, авызыма җаным килә.* (Г.Тукай.) *Байлар, көчең барда эшкә кушып, көчең бетсә, куалар икән.* (М. Гафури.)

*... Минем атым юаш булганлыктан,*
*Бер малайга җигеп бирәбез.*
*Малай алда йөри, мин артыннан,*
*Үзем йөрим, үзем сагалыйм;*
*Минем атны суга-нитә калса,*
*Тотып яңакларга чамалыйм.*

*(Һ. Такташ.)*

*Бүреләр комсыз икәнен һәркем белә.* (Крылов.)

[1] Бу – Г. Алпаровның иң соңгы хезмәтенең бер кисәге. Ул моны 1936 елда, үлүеннән 3–4 ай гына элек, инде авыру хәлендә язган. Автор мәсьәләне киң алып, тирән анализдан үткәрергә уйлаган. Ләкин, үкенечкә каршы, бу хезмәт тәмамланып җитмәгән, эскизлар һәм каралама хәлендә генә калган. Без монда шушы эскизларның методологик әһәмияте булган һәм эшләнгәнрәк өлешен генә керттек. (1937 елгы «Совет әдәбияты»ның 2 нче санында басылган иде). – *Ред.*

Тулы рәвештә башкарылып ияргән бу формадагы иярчен җөмләләр белән бергә, безнең татар телендә, рус телендәге кебек, теркәгечле ияртелмә җөмләләр дә бар. Мәсәлән:

*Иделдә су бик арткан, чөнки атна буенча яңгыр яуды.*

*Һәркем белә ки, бүреләр комсыз булалар.*

Теркәгечле ияртелмә җөмләләр үзгәртелмәстән, шул көенчә аерым җөмлә булып килә алалар. Аларның җөмлә иканлекләрендә һичбер шөбһә юк. Ләкин башкарылып бәйләнгән иярчен җөмләләр шул көенчә аерым җөмлә булып сөйләнә алмыйлар. Рус теле грамматикаларына карасак, без анда татар телендәге кебек башкарып ияртелгән, тәмамланмаган хәбәрле иярчен җөмләләрнең булмаганлыгын күрәбез. Бездәге иярчен хәл җөмлә белән аергыч җөмләгә бик охшаган әйләнмәләр (причастный һәм деепричастный оборотлар) исә, хәзерге рус грамматикаларында җөмлә итеп танылмыйлар. Алар гади җөмләнең аерымланган кисәге – әйләнмә дип саналалар. Мәсәлән: *Бу кеше кичә скамьяда утырган карт иде = Это был старик, сидевший вчера на скамейке; Ул, өстәлгә иелеп, нәрсәдер яза иде = Он, наклонившись на стол, что-то писал.*

Менә шушы охшаш моментлардан чыгып караганда, татар телендәге иярчен җөмләләр дип йөртелгән фактларның барсы да аерымланган кисәкләр – әйләнмәләр генә түгелме икән, дигән кызык бер уй башка килә. Бу күренешләр безнең иярчен җөмләләрнең җөмлә иканлекләрен шөбһә астында калдыралар.

– Татар телендә иярчен җөмләләр бармы? – дигән сорау әнә шуннан килеп чыга. Бу сорау – күптәнге инде. Ул Европа һәм рус тюркологлары тарафыннан куела. Ләкин ул әлегәчә чишелмәгән көе тора. Француз тюркологы профессор Жан-Денининың төрек телләрендәге бу иярчен җөмләләр турында гипотеза рәвешендә, – болар – җөмләсымак фактлар, фаразый җөмләләр; алар төбендә гади җөмләнең җәенкеләнгән кисәкләре генә булсалар кирәк, дигән мәгънәдә бер фикер әйткәнлеге мәгълүм.

Әлегә чаклы без бу сорауның үткенлеген сизеп бетерә алмаганбыз. Әлегә чаклы безгә фигыль тирәсенә оешып ияргән сүз тезмәләрен иярчен җөмлә дип үтеп китү уңайлысымак тоела иде. Хәзер алай җиңел генә котылып булмый башлады. Соңгы вакытларда грамматикаларыбызда «аерымланган кисәкләр» дигән яңа бер категориянең баш күтәрүе белән иярчен җөмләләрнең хәле авырайды. Аерымланган кисәкләрнең «әйләнмәләр» дигән бер бүлеге чыгып, иярчен җөмләләрне үз түгәрәгенә кертә башлады. Шуның нәтиҗәсендә бу фактларның чик араларын билгеләү мәсьәләсе тагын нечкәрде, тагын читенләшә төште. «Иярчен җөмләләр бармы?» дигән сорау бик үткенләште һәм татар грамматикасы өчен актуаль бер мәсьәләгә әйләнде.

Барлык тикшеренүләр, чагыштырулар иярчен җөмләләр белән

әйләнмәләрнең аналогик бер факт, грамматик бер категория күренешләре икәнлеген ачалар. Элгәреге рус грамматикаларында аергыч һәм хәл әйләнмәләре кыскартылган иярчен җөмләләр – сокращенные придаточные предложения дип йөртелгән булганнар. Бу да аларның грамматик бер үк күренешләр икәнлегенә дәлил була. Кыскасы, «иярчен җөмләләр», «әйләнмәләр» дигән терминнар бездә бер үк эчтәлекне белдерә торган сүзләр булып чыгалар. Шулай булгач, безгә бу терминнарның берсен генә кулланырга кирәк була. Соңгы синтаксис дәреслегендә без «әйләнмә» терминын эшкәртү тәҗрибәсен ясадык. Шуның белән бергә «иярчен җөмләләр»не дә калдырдык. Ләкин, күренеп тора, болар арасында аерма бик аз, ясалма аерма гына. Бу терминнар телнең бер категориягә керергә тиешле фактларын ясалма рәвештә икегә аералар, чуалталар дип уйлыйм. Менә шушы мәсьәләне чуалта торган параллель терминнардан котылу, бер фактны бер генә исем белән атау хәзер безгә беренче чираттагы бурыч булып тора. Я әйләнмәләр генә, я иярчен җөмләләр генә калырга тиеш.

– Ләкин боларның кайсын алырга?

Менә шул мәсьәләне дөрес чишә алсак, «иярчен җөмләләр бармы?–дигән баштагы сорауга да җавап табылган булачак.

Югарыда сөйләнгән охшату, чагыштыруларга караганда, шулай ук профессор Жан-Дени фикере буенча, безгә иярчен җөмләләрне ташлап, аның урынына әйләнмәләрне җәелдереп җибәрергә кирәк булыр төсле күренә.

Ләкин бу өстән караганда гына шулай.

Мәсьәләне ныклабрак тикшергәндә, татар теленең үзенчәлекләренә объектив рәвештә якынлашканда, киресенчә, әйләнмәләрне бетереп, иярчен җөмләләрне законлаштырырга тиеш булып чыга.

Эш менә нәрсәдә бит. Иң элгәре шуны әйтергә кирәк, һәр телнең социаль-тарихи шартлар нигезендә үскән, башка телләр белән уртак хасиятләре булганы кебек, азмы-күпме үзенә аерым үзенчәлекле яклары да бар. Үзенчәлекле күренешләр аларны өйрәнү өчен кулланылган методларның да үзенчәлекле булуын таләп итәләр. Шунлыктан бер телдәге теге яки бу фактларны билгеләү өчен кулланылган критерийләр башка телдәге аналогик фактларны билгеләү өчен яраксыз булуы мөмкин. Билгеле бер телдән априор рәвештә алынган теге я бу формаль билгеләргә карап кына, башка телдәге фактлар турында «бар я юк» дигән кискен бер хөкем чыгару, – гомумән, мәсьәләгә метафизик караштан башка нәрсә түгел.

Фактлар бар, алар үсеп җәелгән һәм үзенчәлекле бер категория булып торалар. Мәсьәлә – боларны нинди термин белән атап алуда, кайсы терминның гыйльми дөрес, практик уңай булуында. Минемчә, бу урында «иярчен җөмләләр» терминын куллану, гыйльми яктан дөрес булу белән бергә, практик яктан да уңай булачак.

Татар телендәге иярчен җөмләләр дип йөртелгән фактлар – аерым җөмлә белән җөмлә кисәге арасында ике уртадарак торган күренешләр. Алар бер кабыргалары белән аерым җөмләгә, икенче кабыргалары белән иярчен кисәккә якын торалар, формаль якларыннан иярчен кисәкләргә охшасалар, эчтәлекләре ягыннан җөмләләргә туры киләләр. Шуңа күрә аларда бөтенлек (җөмләлек) хасияте белән кисәклек хасияте каршылыклы рәвештә бергә җыелган була. Димәк, алар – үзләре иярчен кисәк, үзләре җөмлә булган фактлар.

Ләкин иярчен җөмләләрдә бу ике хасият бертигез түгел. Алар, тулаем алганда, җөмлә ягына якынрак торалар. Аларда җөмләлек хасияте көчлерәк. Бу хасиятне без иярчен җөмләнең үзләренә аерым актуаль белдермәлеккә ия булуларына карап беләбез. Кайбер сөйләмнәрдә аларның белдермәлек табигатьләре баш җөмләгә караганда да көчлерәк булырга мөмкин. Мәсәлән, билет алып куяр өчен алдан вокзалга киткән бер кешенең, иптәшләре килгәч: *«Мин әллә кайчан билет алып, монда сезне көтеп утырам»* дигән сөйләмендә аның көтеп утыруыннан бигрәк, билет алу турындагы белдермәсе әһәмиятлерәк, әлбәттә. Ә бу белдермә монда иярчен җөмлә формасында бирелгән.

Иярчен җөмләләрдә җөмләлек хасияте көчле булганлыктан, аларны һәрвакыт параллель функцияле теркәгечле я теркәгече ияртелмә җөмләләр белән чагыштырылуларына, бер-берсе белән алмаштырылуларына карап та аңларга мөмкин. Русчадан татарчага, һәм киресенчә, тәрҗемә иткәндә, бу җөмләләрнең бер формадагысы икенче формадагысы белән алмаштырып тәрҗемә ителгәнен без бик яхшы беләбез. Мәсәлән: *Мы с трудом разбирали дорогу, так как было очень темно = Төн бик караңгы булганга, без юлны көч-хәл белән генә аера идек. Иртән аяз булып, кичен яңгыр яуды = Утром погода была ясная, а вечером шел дождь.*

Шуңа күрә мондый грамматик фактларны элгәрегечә «иярчен җөмләләр» термины белән аерып йөртү гыйльми яктан дөрес, практик яктан да уңайлы булып чыга. Боларны иярчен кисәкләрдән санап йөрткәндә, ияртелмә җөмләләр белән чагыштыру, тәрҗемә итү мәгънәсез, бәйләнешсез бер эш булыр иде. «Әйләнмә» термины дөрес булган булса, без аларны тулы жөмләләргә түгел, бәлки иярчен кисәкләргә генә чагыштырыр идек.

Аннары шуңа игътибар итәргә кирәк: тарихи яктан иярчен җөмләләр гади кисәкләрнең җәенкеләнү юлы белән килеп чыкмаганнар, бәлки аерым җөмләләрне бергә бәйләп, кушып сөйләүдән килеп чыкканнар. Гадәттә, сөйләү телендә бу иярчен җөмләләр белән белдерелгән уй шул ук аудиториядә (әңгәмәләшү түгәрәгендә) бер кабат аерым җөмлә хәлендә сөйләнеп үткән була. Хәтта ул кушма җөмләдән алда гына әйтелгән булырга да мөмкин. Мәсәлән: *Ничектер, шунда мин барып кердем. Барып керсәм, анда Гали утыра икән. Төштән соң бозлы яңгыр яуды.*

*Бозлы яңгыр явып, игеннәрне харап итеп китте.* Бу мисаллардагы иярчен җөмләләр алдагы аерым җөмләләрнең кушып сөйләнгән формалары икәнлеге күренеп тора. Алар бер яктан, хәбәрнең әһәмиятен көчәйтү өчен кабатлап әйтелгән булсалар, икенче яктан, соңгы фикергә якын бәйләнешне белдерү өчен, аңа ияртеп оештырылганнар. Җөмләләрне тыгыз оештырып, фикерләрне бер-беренә органик бәйләп сөйләү – татар теленең үзенчәлекле бер табигате, үзенә күрә бер үзенчәлеге ул. Шулай булгач, бу иярчен җөмләләрне ничек итеп башка җөмләнең җәенкеләнгән кисәкләре дип әйтә алабыз.

Шунысы да бар, рус телендә иярчен формадагы фигыльләр причастный, деепричастный дигән ике генә формада очрасалар, татар телендә алар сәбәп, вакыт, шарт, кире, хәл, чагыштыру, аергыч һ.б. функцияләрдә, күп төрле формаларда киләләр. Аларны әйләнмәләр исеме белән каплап калдырырга мөмкин түгел. Алар үзләренә аерым, зур бер категория булып өйрәнелүне таләп итәләр. Бу категория, нинди генә термин белән атаганда да, иярчен кисәкләр ягында түгел, бәлки кушма җөмләләр ягында урын тотачак. Иярчен җөмләләр термины белән аерып өйрәнү аларның катлаулы, бай үзенчәлекләрен тулысынча ачылдыруга ярдәм итәчәк.

Дөрес, иярчен җөмләләрнең барында да җөмләлек хасияте бертигез түгел. Кайбер формаларда, кайбер мисалларда җөмләлек бик аз булырга да мөмкин. Чөнки, югарыда әйткәнебезчә, иярчен җөмләләр аерым җөмлә белән җөмләнең кисәкләре арасында өзлексез бәйләнешле фактлар булып торалар. Аларның аерымланган кисәкләргә якын торган кайбер формаларының рус телендәге әйләнмәләргә охшавы шуннан килә. Ләкин бу сирәк формалар да рус телендәге әйләнмәләр белән бөтенләй бер үк түгелләр. Рус телендәге әйләнмәләрнең үзләренә аерым ияләре була алмый. Мәсәлән, татарчада *бу юлы ул өйдә калып, мин эшкә киттем* формасында сөйләү – мөмкин дә, дөрес тә. Рус телендә исә На этот раз она дома оставаясь, я пошел на работу рәвешендә ияле әйләнмәләрне без очрата алмыйбыз. Хәзерге рус әдәби теле нормалары ноктасыннан караганда, болай сөйләү мөмкин дә түгел, дөрес тә түгел (кирәк: *на этот раз она осталась дома, я пошел на работу*). Әйләнмәләр причастие яки деепричастие тирәсендә оешып җәенкеләнгән иярчен кисәкләр төркеме генә булып калалар. Татар телендә кайбер хәл җөмләләрнең әйләнмәгә охшаулары – аларның уртак ияле булуларыннан килеп чыккан тышкы бер күренеш кенә.

Кыскасы, татар телендәге иярчен җөмләләр – татар теленең чын-чыннан үзләре җөмлә, үзләре иярчен булган диалектик табигатьле үзенчәлекле бер күренеше. Аларга «иярчен җөмләләр» дигән терминнан да тапкыр килгән бер исем табарга мөмкин түгел. Димәк, татар телендә иярчен җөмләләр бар, һәм аларның булуы зарурый бер факт.

## Иярчен җөмләләрне билгеләү мәсьәләсе

Иярчен җөмләләр бар булып чыкты. Ләкин моның белән әле бу фактлар тирәсендәге башваткыч мәсьәләләр чишелеп бетмиләр. Иярчен җөмләләрне башка янәшә фактлардан аерып билгеләргә, бу термин түгәрәгенә кергән фактларны ачык барлап күрсәтергә кирәк. Әлегә кадәр бездә бу мәсьәлә бик чуалчыклы булып килде. Иярчен җөмләләрне билгеләү өчен формаль яки функциональ бик күп төрле критерийлар күрсәтергә була. Ләкин боларның берсе дә бу термин түгәрәгенә кергән фактларны үз эчләренә алып бетерә алмыйлар. Мәсәлән, функциональ якны алсак, грамматик төзелеш ягыннан бөтенләй аерылып китәргә – теркәгечле, теркәгечсез җөмләләрне дә иярченгә кертергә туры килә. Сәбәп, шарт һ. б. конкрет функцияләр кайбер мисалларда билгеле бер форма белән бәйләнгән булсалар да, башка мисалларда ул форма белән бәйләнмәгән булып чыгалар. Шуның белән бергә кайбер җөмләләр берничә функциягә ия булып йөриләр, кайберләренең функцияләре бик томанлы була. Формаль билгеләрне генә алсак, иярчен җөмләләр түгәрәге бераз кечерәеп, ачыкланып кала калуын, ләкин конкрет билгеләрнең берсе дә ахырына кадәр эшкә ярамыйлар. Мәсәлән, пауза белән аерылуны билге итсәк, аергыч тәмамлык җөмләләр төшеп калалар. Ияле булуны шарт итсәк, хәл, максат һ.б. уртак ияле җөмләләр төшеп калалар. Бу хәл иярчен җөмләләрне тәгъриф итү – билгеләү мәсьәләсен бик читенләштерә.

Элгәрерәк мәсьәләнең бу ягы безне аптыраште калдырып килгән булса, инде ул, киресенчә, бездә кызыксынуны гына арттыра.

Тел үзенең бөтен хасиятләре, барлык катлаулы төзелеше белән – диалектик каршылыклы социаль бер күренеш. Аның һәр моментында без бу каршылыкларның чагылуын күрә алабыз, күрергә тиешлебез.

Югарыда әйткәнебезчә, иярчен җөмләләр үзләренең бер кабыргалары белән тулы җөмләләргә якын торсалар, икенче кабыргалары белән алар иярчен кисәкләргә якын торалар. Тулаем алганда, алар аерым җөмлә белән җөмлә кисәге арасында өзлексез һәм сөзәк бәйләнеш ясаган күпер яки баскыч булып торалар. Алар үзләренең функциональ төрләре белән генә түгел, формаль тулылыклары ягыннан да шушы ике арада тирбәлгән конкрет мисаллар бирәләр.

Бу өзлексез бәйләнеш тел фактларында бер юнәлештә генә түгел, башка юнәлешләрдәге башка фактлар белән бәйләнешләр дә шундый ук характерда була. Бу бер-берәнә әверелүчән фактларның бер өлешендә табылган хасиятләр икенче өлешендә табылмаска да мөмкин. Шуңа күрә аларның бер өлешендә эшкә яраган билгеләр икенче өлешендә эшкә ярамыйлар. Бу каршылыклы, катлаулы фактларга үз үлчәвебез белән якынлашырга, аларны бертигез, бертөсле кисәкләргә бүләргә мөмкин түгел. Диалектик төзелеш законы шулай. Ленин әйтә: «Без

өзелмәгәнне өзмичә, гадиләштермичә, тупаслandырмыйча, бүлмичә, җанлыны үлекләндермичә хәрәкәтне күз алдына китерә, кисә, үлчи, сурәтли алмыйбыз. Хәрәкәтне фикер белән сурәтләү һәрвакыт тупасландыру, үлекләндерү ул, һәм фикер белән генә дә түгел, бәлки сизү белән дә, һәм хәрәкәтне генә дә түгел, бәлки һәрбер төшенчәне дә. Диалектиканың чын асылы да шунда. Шушы чын асылны инде каршылыкларның берлеге, охшашуы дигән формула тәгъбир итә». (*Ленин җыентыгы*, XII том, 193 бит.)

Билгеле, Ленинның даһиларча әйткән бу фикере безгә тел фактларын өйрәнү өчен дә өлге була.

Безнең тел фактларын төркемләүләребез, бүлүләребез шулай өзлексез бәйләнешле булган күренешләрне бер-береннән аеру, тупасландыру, җанлы процесс хәлендәге фактларны үлекләндерү инде ул.

Ләкин без һаман да бер дә кискәләмичә, бүлмичә булдыра алмыйбыз. Чөнки без объектив барлыкны, фактларны, күренешләрне башкача таный, белә, аңлый алмыйбыз. Тел фактларын да шулай бер дә бүлгәләмичә өйрәнергә мөмкин түгел.

Бүлгәләү, төркемләүләрдә шуны хәтердә тотарга кирәк:

1. Һәрбер бүлү, төркемләү – нисби, шартлы һәм чикле.

2. Кагыйдә, категорияләр грамматик күпчелек хасил иткән нигез күренешләрне, төп моментларны үз эчләренә алсалар, шул җитә. Телнең барлык фактларын бер дә калдырмыйча, кагыйдә, категория астына алырга, системага кертеп бетерергә мөмкин түгел. Шуның өчен грамматикаларда күбесенчә дигән саклык сүзне еш кына очратырга туры килә.

3. Ике аралыктагы, сирәк очраган күренешләр, ялгызак фактлар нисби булган системаны бозмыйлар. Алар искәрмә я чыгарылма итеп күрсәтелә алалар.

4. Өйрәнелгән фактлар бу урында, әйтик, иярчен җөмләләр үзләренең нормаль тәртипләрендә, ялгыз һәм тулы формаларында алып тикшерелергә, төркемләнергә тиешләр. Очраклы формалар, катлауланган күренешләр, инверсияле хәлләр кагыйдә, норма була алмыйлар.

5. Аерым, ялгыз билгеләр, бер яклы гына критерийлар эшкә ярамыйлар. Берничә төрле билгеләр, хасиятләр комплекс хәлендә алынырга тиешләр. Бу вакыт анализ бер билгеләргә карап эшләнсә, синтез икенче билгеләргә карап эшләнергә мөмкин.

6. Тел фактларын ничаклы ваграк төркемнәргә бүлеп, һәрберсен үз хасиятләренә карап өйрәнсәк, шул чаклы дөреслеккә, чынлыкка якынрак килгән булабыз.

Инде без иярчен җөмләләрне, төрле хасиятләренә һәм билгеләренә карап, янәшә фактлардан аеру, алардан чикләү эшенә күчәбез. Иярчен җөмләләрне шушы түбәндә күрсәтелгән моментларга карап өйрәнергә, билгеләргә мөмкин.

## Җөмләлек хасияте ягыннан

«Тәмамланган уй белдерүче сүз яки сүзләр төркеме җөмлә дип атала». Гадәттә җөмләне менә шулай дип тәгъриф итәләр. Бу тәгъриф буенча, тулы тыныш белән тәмамланып әйтелгән, сорау, җавап, атау, өндәү, лозунг җөмләләре җөмлә булып саналсалар да, иярчен җөмләләр, тәмамланмый әйтелгәнлектән, җөмлә булып санала алмыйлар. Күренә ки, монда ниндидер аңлашылмау бар. Бу ябышмаганлык җөмлә тәгъриферндәге традицион садәләштерүдән килә.

Эш шунда: җөмлә бар, сөйләм бар.

Сөйләм рус тел галимнәре арасында высказывание, сказ, интонационное целое дигән атамалар белән аңлатыла. Карарланган – урнашкан термины юк. Социаль мөнәсәбәтләрдә, тел белән чыгыш вакытында тулы тыныш белән бүлеп сөйләнгән һәрбер сүз яки сүзләр төркеме, һәрбер җөмлә яки оештырылган җөмләләр төркеме аерым бер сөйләм була. Сөйләмне кыскача «тулы тынышлы интонацион бөтенлек» дип, яки «тел белән чыгыш берәмлеге» дип билгеләргә мөмкин.

Җөмлә – сөйләмнең бер төре генә. Җөмлә – сөйләмнең типик берәмлеге. Сөйләм, күбесенчә, җөмләләрдән тора ул. Без, башлыча, җөмләләр белән сөйләшәбез. Шуңа күрә җөмлә бик әһәмиятле дә.

Җөмлә – диалектик каршылыклар берлеге. Җөмләдә ике төшенчә бер-беренә каршы куела, һәм шуның белән бу төшенчәләрнең әлегәчә беленмәгән яңа мөнәсәбәтләре белдерелә, яңа берлекләре ачыла. Җөмләнең хасияте менә шушы каршылыклы берлек мөнәсәбәтенең ачыклыгы, актуальлеге белән билгеләнә.

Җөмләнең белдермәлек хасияте башлап хәбәр ителгәндә, беренче авыздан сөйләнгәндә көчле, үткен була. Татар телендә хәбәрнең икенче авыздан сөйләнеп массага таратылу формасы да бар (*гән, икән, ди* формалары белән).

Бу форманың да белдермәлек хасияте тегесеннән ким булмый, тик беренчелекне югалтуы гына сизелә. Ләкин беренче һәм икенче авыздан сөйләнеп массалаштырылганнан соң, алдагы сөйләнүләрдә инде безнең җөмләбез үзенең белдермәлек хасиятен һәм аның үткенлеген югалта. Элгәреге каршылыклы берлек мөнәсәбәте якын берлекле мөнәсәбәткә үзгәрә. Ул инде җөмлә формасында түгел, бәлки тыгызрак бәйләнешле кисәк тезмәләр формасында бирелә башлый. Мәсәлән,

беренче авыздан сөйләгәндә: «Калинин килде»,

ә икенче авыздан сөйләгәндә: «Калинин килгән».

Хәбәр массалашканнан соң:

«Калинин килүдән өч көн үткәч...»;

«Калинин килгәннең өченче көнендә...»;

«Калининның килүе безгә зур бәйрәм булды»;

«Безгә килгән Калинин...»

Бу соңгы мисалларда «Калинин» сүзе белән «килү» сүзе арасында каршылыклы мөнәсәбәт юк. Алар паузалы да, бетемле дә түгелләр. Аларда белдермәлек хасияте дә юк. Шуңа күрә без мондый тезмәләрне җөмлә дип таный алмыйбыз.

Тезмәле, теркәгечле, алмашлыклы, керешле кушма җөмләләрдә һәр җөмләнең белдермәлек хасияте тулы һәм ачык була. Шуңа күрә алар һичбер үзгәрешсез, турыдан-туры аерым җөмлә булып килә алалар. Иярчен җөмләләрдә инде белдермәлек хасияте байтак кимегән, үзенең үткенлеген югалткан була. Чөнки монда каршылыклы мөнәсәбәт белдерү теләге хәбәрнең-әһәмиятен көчәйтү, аның башка эшләргә бәйләнешен күрсәтү кебек өстәмә максатлар белән катлауланган була. Шулай да әле актуаль белдермәлек хасияте иярчен җөмләләрдә бөтенләй бетмәгән, төрлесендә төрле дәрәҗәдә сакланган була. Бу хасият, формаль яктан, аларның баш җөмләдән пауза белән аерымланып әйтелүләре, ия белән хәбәр арасындагы пауза һәм интонациянең саклануы рәвешендә тәгъбир ителә. Иярчен җөмләләрдәге каршылыклы мөнәсәбәт берлеге күп вакыт беренче башлап хәбәр ителәләр. Иярчен хәл җөмләләрнең яңа бер эш турында хәбәр белдерү өчен кулланылуларын еш кына очратырга була. Мәсәлән:

*Кояш баеп, караңгы төшә башлагач, колхозчылар эштән туктадылар.* Бу мисалда *Кояш баеп* җөмләсе хәл яки рәвеш белдерми, бәлки кояш баеды дигән хәбәр белдерә. Хәл һәм шарт фигыль формалары күп вакыт тиңдәш җөмләләрне тезеп бәйләү өчен дә кулланылалар. Мәсәлән:

*Артыма әйләнеп карасам, беркем дә күренми.*

*Иртәнчәк көн ифрат суык булып, төштән соң аз гына йомшартып җибәрде.* (Шәриф Камал.)

Бу мисаллардагы карасам, булып фигыльләре – карадым, булды мәгънәсендәләр. Бу әйтелгәннәр паузалы иярчен җөмләләрдә җөмләлек хасияте җитәрлек дәрәҗәдә барлыкны исбат итәләр.

Аергыч, тәмамлык җөмләләр дип йөртелгән фактларга килсәк, боларда актуаль белдермәлек хасияте бөтенләй алынган – җуелган була. Боларда элгәреге хәбәрне яңадан искә төшереп үтү максаты гына бар. Каршылыклы мөнәсәбәт белдерү алдан билгеле булган якын берлек мөнәсәбәтенә үзгәргән була. Алар инде җөмләлекләрен югалтып, иярчен кисәкләргә әверелгән булалар. Эчтәлек ягында булган бу аерма формаль яктан баш җөмлә белән ике арадагы паузаның алынуы, ия белән хәбәр арасындагы паузаның юклыгы белән тәгъбир ителә. Мәсәлән: *Вәли килгән көннән бирле эшләр рәтләнеп китте. Син кайтканны ишетмәгән идем әле мин.* Бу мисаллар да *Вәли килгән, Син кайтканны* тезмәләре актуаль грамматик рольләре ягыннан да, әйтелеш формалары ягыннан да гади иярчен кисәклərдән аермасызлар. Баш килештәге ия белән кайчакта хәбәр булып та килә торган

сыйфат фигыль – монда тик тышкы бер күренеш кенә. Аларны актуаль контексттан ясалма рәвештә аерып алып караганда гына җөмлә диярго мөмкин. Инде алар алынган – җуелган (снятое) җөмлә күренешләреннән башка нәрсә түгел.

Җөмләнең гади иярчен кисәкләрендә исә, теләсә алар аерымланган, теләсә аерымланмаган булсыннар, җөмләлек мөнәсәбәте, хәбәрлек хасияте булу турында сүз дә булырга мөмкин түгел.

Җөмләлек хасиятен күзәтү буенча, гомумән, җөмләләрне шушы төркемнәргә бүләргә була:

1) аерым җөмләләр,
2) тулы хәбәрле кушма җөмләләр,
3) иярчен хәбәрле җөмләләр,
4) алынган – җуелган (снятое) җөмләләр.

## Хәбәр табигате ягыннан

Хәбәр – җөмләнең иң әһәмиятле кисәге. Чөнки ул җөмләнең төп белдерүче, төп оештыручы кисәге. Җөмләдәге башка сүзләр шушы хәбәр тирәсендә оешкан булалар. Җөмлә анализы һәрвакыт хәбәрдән башлана. Хәбәрнең нинди элементтан, нинди формада килүе күп вакыт җөмләнең нинди характерда икәнлеген билгеләүгә ярдәм итә. Җөмләләрнең, хәбәрләренә карап, фигыль җөмлә, исем җөмлә дип аталганлыкларын без беләбез. Бу урында без аларның кайсылары нинди формаларда тәмамланган хәбәр булып, нинди формаларда иярчен хәбәр булып килүләрен күзәтәбез.

Саф фигыльләрдән боерык, үткән һәм хәзерге заман фигыльләре күбесенчә, теләсә нинди формалары белән җөмләнең тәмамланган хәбәре булалар. Бу фигыльләрнең иярчен хәбәр булып килүләре сирәк очрый.

Хәл фигыльләрдән шарт, рәвеш, вакыт, сәбәп, чагыштыру фигыльләре һәрвакыт җөмләнең иярчен хәбәре яки иярчен кисәге булып киләләр.

Сыйфат фигыльләр (*ган-гән, ар-әр, чак-чәк, макчы-мәкче, малы-мәле*) зат кушымчалары белән төрләнеп, иягә ярашып әйтелгәндә, җөмләнең тәмамланган хәбәре булып киләләр. Зат белән төрләнеп әйтелә алмаганда, күбесенчә, җөмләнең иярчен кисәге булалар.

Исем фигыльләр (*у, ү, ырга-ргә, ергә-ргә, мак-мәк, ыш-еш-ш*) баш килештә җөмләнең тәмамланган хәбәре булып килергә мөмкин, ләкин аергыч була алмыйлар. Болар, күбесенчә, ия яки тәмамлык ролендә йөриләр. (Фигыльләрнең кушма, катлаулы булуы – аларның эчке табигатьләре. Кушмалыкның хәбәрлек табигатенә йогынтысы юк.)

Исемнәр, сыйфатлар, саннар шулай ук баш килештә җөмләнең тәмамланган хәбәре була алалар. Ләкин исемнәр, күбесенчә, тәмамлык ролендә, ә сыйфатлар, саннар аергыч ролендә кулланылалар.

Димәк, фигыль җөмләләр, хәл фигыль төрләрендәге хәбәрләре белән, һәрвакыт башка бер җөмләгә бәйләнгән иярчен җөмлә булып килә алалар. Исем җөмләләр исә турыдан-туры иярчен җөмлә була алмыйлар, моның өчен алар иң элгәре ярдәмче фигыль аркылы фигыль җөмләгә әверелергә тиеш булалар. Исем җөмләләрнең хәбәрләренә бул ярдәм фигыле кушылып, аларны фигыль җөмләгә әверелдерә, һәм бу ярдәмче фигыль барлык хәл фигыль төрләрендә килеп, төрле функциядәге иярчен җөмләләр хасил итә. Шулай ук, *исә, икән, дип* ярдәм фигыльләре дә исем җөмләләрне иярчен җөмләләргә әверелдерәләр. Кайбер исем җөмләләр бул ярдәмче фигыленнән башка да, турыдан-туры хәл фигыль төрен алып, кыска формада иярчен җөмлә булып килә алалар. Мәсәлән: *Акча юкта, ярый ул. Йөгерә үрдәк, йөгерә каз, боты озынга күрә.*

Төп иярчен фигыль формалары шулар:

*са-сә* – (шарт фигыль, зат белән дә төрләнә), *гач-гәч, ышлый-эшли, мыйчы-миче, гачтын-гәчтен* – (вакыт), *а-ә, ый-и, арак-әрәк ып-еп-п, мый-ми, мыйча-мичә* – (хәл һәм рәвешләр), *мышлый-мешли* – (чагыштыру).

Ясалма иярчен фигыльләр дә бар. Сыйфат фигыль формасы ган–гән тәмамланган җөмләләрне иярченгә әверелдерүче универсаль бер чара булып хезмәт итә. Шуның белән бергә ул элгәре хәбәрлек мөнәсәбәтен дә саклый. Бу *ган-гән* формасы *чә, че, дә, дәй, гә, гәчә, лектән* кушымчалары белән ялганып, шулай ук *күрә, өчен, белән, кебек, шикелле, сымак, саен, элек, соң, көе, килеш* ярдәмлекләре белән кушылып, төрле функцияләрдәге иярчен фигыльләр, димәк иярчен җөмләләр хасил итә ала. Бул ярдәм фигыле белән фигыльгә әверелгән хәбәрләр дә шулай ук *ган* төре аша, югарыдагы кушымчаларны һәм ярдәмлекләрне алып, иярчен җөмләнең хәбәре була алалар. (29, 30 табл.)

*гән-ган* формасы *ның-нең, ны-не, ын-ен* килеш кушымчалары белән төрләнә ала. Ләкин, бердән, функцияләре үзгәрмәгәнлектән, икенчедән, *лык-лек* кушымчалары белән яңадан исемгә әверелгәнлектән, өченчедән, тартым һәм сан белән (*ым-ыбыз, ың-ыгыз, ы-лары*) төрләнгәнлектән, боларны иярчен җөмлә формаларыннан санап булмый. Алар иярчен кисәк булып кына саналырга тиешләр. Тагын шуңа да дикъкать итәргә кирәк: ны-ын, ның килешләре *ган-гән* белән генә түгел, исем фигыль төрләре *у-ү-ш* белән дә кушыла алалар. Аннары, исем җөмләләр төшем килешендә булганда, күбесенчә, аларга *ны-ын* кушымчалары икән ярдәм фигыле аша ялгана (*икәнне, икәнен, икәнегезне, икәнлеген, икәнлекләрен...*) Иярчен җәмләләр билгеле функцияләрдә, билгеле бер формаларда гына киләләр. Гади тәмамлыклар кебек күп төрләрдә очрамыйлар.

Хәбәрләрнең табигате турындагы эзләнүләргә йомгак ясап, шушы схеманы күрсәтергә була: (+була ала, – була алмый дигән сүз).

*29 таблица*

| | | Фигыль җөмләләрдән | Исем җөмләләрдән | |
|---|---|---|---|---|
| Төп иярчен формалар белән | са-сә | ул безгә килсә... | булса | көн яхшы булса... |
| | кач-гач... | кояш чыккач... | булгач | тамак тук булгач... |
| | ышлый | мин юлдан кайтышлый... | булмыйчы | үзең культуралы булмыйчы... |
| | миче | карангы төшмиче... | буларак | мин ударник буларак... |
| | а | китәргә ун минут кала... | булып | көн аяз булып... |
| | арак | үзе аңлаярак | | |
| | ып | элгәре өйгә кайтып... | булмый | |
| | мый | ул шауламый гына... | булмыйча | |
| | мичә | бер сүз дәшмичә... | | |
| | мешли | колхозчылар әйтмешли... | | |
| Кушымчалы, ясалма формалар белән | канча-ганча... | Ленин әйткәнчә... | булганча | |
| | ганчы | таң атканчы... | булганчы | |
| | ганда | кояш чыкканда... | булганда | көн аяз булганда... |
| | гандай | үзең әйткәндәй... | булгандай | эштә ударник булгандай... |
| | ганга | башым авыртканга... | булганга | тормыш күңелле булганга... |
| | ганлыктан | эш иртә беткәнлектән... | булганлык-тан | акча күп булганлыктан... |

*30 таблица*

| | Тәмам-ланган хәбәр | Иярчен җөмлә хәбәре | | | Аергыч булалар |
|---|---|---|---|---|---|
| | | үз төрендә | кушымча белән | ярдәмлек белән | |
| Саф фигыльләр | + | – | – | – | – |
| Хәл фигыльләр | – | + | – | – | – |
| Исем фигыльләр | + | – | – | + | – |
| Сыйфат фигыльләр | + | – | + | + | + |
| Исемнәр | + | – | – | + | + |
| Сыйфатлар | + | – | – | + | + |

Хәбәрләр өстендә тикшеренүләр безгә нәрсә бирәләр?

1) Әлегә чаклы иярчен җөмләләрдән санап, бергә бутап йөртелгән теркәгечле я теркәгечсез ияртелмә җөмләләр, үзләренең тәмамланган хәбәрләре белән, катгый рәвештә аерылып калалар. Аларны иярчен җөмләләр белән бер төркемдә йөртү грамматик яктан хата булып чыга.

2) Исем җөмләләрнең дә, фигыль җөмләләр кебек үк, тулы хокуклы иярчен җөмлә була алганлыклары ачыла. Чөнки фигыль җөмләләр

белән исем җөмләләр арасында синтаксик яктан бер төрле дә аерма юк. Иярчен җөмлә булганда, алар бер үк формаларда киләләр һәм бер үк функцияләрдә булалар. Аларны бер-береннән аерып йөртергә мөмкин түгел. Алар синтаксик бер категориягә керергә тиешле фактлар. Гомумән, бездә исем җөмләләргә игътибарсыз карау, фигыльләрне, киресенчә, кайда, нинди формада очрасалар да, җөмлә итәргә тырышу – фетишләндерү чире бар. Хәлбуки бездә фигыльләр грамматик дүрт төркемгә бүленәләр, җөмләнең дүрт төрле кисәге була алалар. Исем фигыль белән сыйфат фигыль – исем белән сыйфаттан аермасызлар. Бигрәк тә исем җөмләләрнең хәбәрләре алдан фигыль хәбәргә әверелгәнлектән, аларны иярчен җөмләләр арасыннан чыгарып калдырырга һичбер төрле юл калмый.

3) Мондагы хәл фигыль ясаучы *ча, чы, да, дай, дан* (лыктан), *га* кушымчаларын гади килеш кушымчалары белән чуалтырга мөмкин. Бу чуалту ихтималына каршы шушы чараларны күрсәтергә була: бердән, бу кушымчаларның җөмлә була алган тезмәнең хәбәренә ялганган булуын хәтердән чыгармаска кирәк. Икенчедән, алар башка функцияләргә әверелгән булалар. Без аларның килеш функциясендә булганнарын алмыйбыз. Өченчедән, бу хәл фигыль ясаучылар билгеле бер формада килгәндә генә, шушы яңа функциядә була алалар. Шуңа күрә алар бүтән формалар белән ясалмыйлар, сан, тартым белән төрләнә алмыйлар. Дүртенчедән, хәл фигыль функцияләрендә иярчен җөмлә булып килгәндә, үзләренең нормаль тәртипләрендә бу тезмәләр пауза белән аерымланып әйтеләләр. Килеш функциясендә гади тәмамлык булганда, алар аерымланмыйлар да. Менә шул шартларга туры килмәгәнлектән, иялек килеше *ның-нең* төшем килеше *ны-не, ын-ен* кушымчалары иярчен җөмлә формалары була алмыйлар. Ләкин функциясе үзгәргән һәм билгеле бер форма белән генә бәйләнгән *гәнлектән гән+гә,* (күрә), *гән+дә, мастан* кушымчалары иярчен җөмлә формаларыннан саналырга тиешләр.

# УН ЕЛ ЭЧЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕ[1]

Бу мәкаләдән теләк татар теленең гыйльми, гамәли эшләнүе юлында Октябрь Революциясеннән соң ун ел эчендәге хәрәкәтләр белән таныштыру, бу юлда ун ел эчендә булган хезмәтләргә бер йомгак ясау булганлыктан, Октябрьгә чаклы булган эшләргә бик кыска, өстән-өстән генә кагылып китәргә туры килә.

XIX йөзнең азагыннан башлап Октябрь революциясенә чаклы бер чорны безнең татар тарихында «капитализм чоры» (яки җәдитлек дәвере) дип йөртәбез. Бу чорда башланган милли, мәдәни уяну, яңару хәрәкәте татар теленең гыйльми, әдәби бер тел булып эшләнүе һәм танылуы ягыннан яхшы ук әһәмиятле эзләр калдырды. Бу юлда Каюм Насыйри тарафыннан башлап салынган нигезләргә яңадан-яңа хезмәтләр өстәлә барып, тел бинасы заманына күрә эшләнеп бетү дәрәҗәсенә килеп җитте. Бигрәк тә 1905 нче елгы революция хәрәкәтләренең бу юлдагы безнең эшләребез кызып китүгә зур йогынтысы булды. Капитализм чорының характеры бу чорда безнең мәдәни, гыйльми эшләребезнең дә анархия юлында үсүен китереп чыгара иде. Шуңа күрә бу вакыт безнең тел бабындагы эшләребез аерым иҗатчылар, язучылар, наширләр арасындагы уңышлар рәвешендә мәйданга чыга барды. Ул чорда нинди генә эшләрне булса да киңәшеп, үзара җыелышлар ясап, бер план белән оештырып алып баруга мөмкинлек юк иде. Шуңа күрә бу эшләрдә безгә 1905 елдан соң гына чыга башлаган гәзит, журналлар, андагы өзлексез алып барылган кампанияләр генә бераз томанлы маяк хезмәтен үтәп килде.

Имля мәсьәләсе матбугатта өзлексез тикшерелеп торды. Бу юлдагы эш туктаусыз бер революция хәрәкәте булып барды.

Бу юлда Һади Максуди, Шакирҗан Таһири, Гыймәд Нугайбәк, Галимҗан Ибраһимов, Ш.Әхмәдиев, Гыйбадулла Алпар, М.Корбангалиев, Г.Хисмәти, Хәсән Гали һәм башкалар мәсьәләне кыздырып, өзлексез эшләп килделәр. Октябрь революциясенә чаклы бу мәсьәлә гамәли яктан өзелеп, иске гарәплектән котылып, татар теле фонетикасына яраклашып бетәр дәрәҗәгә килеп җиткән иде инде. Бу мәсьәлә тирәсендәге тартышлар бездә байтак тел тикшерүчеләр туып чыгуга сәбәп булды.

Каюм Насыйридан соң телебезнең сарыф-нәхүләре ныклап эшләнә башлады. 1910 ел аерым искә алына торган бер тарих булып тора. Бу

---

[1] Мәгариф. – 1927. – № 10–11. – 60–66 б.

елдан башлап берсе артыннан берсе әллә ни чаклы сарыф-нәхү китаплары, ана теле дәреслекләре чыга торды. Бу юлда яңадан-яңа уңышлыклар туып, телебезнең байлыклары ачыла барып, татар теле гыйльми, гамәли эшләнеп бетәр дәрәҗәгә җитте. Тел өйрәнү бабында заманына күрә байтак гыйльми байлык җыйналды. Бу аралыкта сарыф-нәхү язу кампаниясенә Һ.Максуди, Ш.Иманаев, Гыймәд Нугайбәк, Галимҗан Ибраһимов, уфалы Фатих Сәйфи, Габдрахман Сәгъди, Җамал Вәлиди, М.Корбангалиев, Хуҗа Бәдигый иптәшләр катнашкан иде.

Лөгатьләр (сүзлекләр) төзү бабында Каюм бабаның «Ләһҗәи татари»сыннан, «Русча-татарча лөгать»еннән соң Солтан Рахманкулиның «Татарча-русча лөгать», шул ук Солтан Рахманкули, Г.Кәрәмнәрнең «Мөкәммәл русча-татарча лөгать»ләре һәм Җалтурин «Лөгать»е эшләнеп чыкты.

Татар теленең методикасын эшләү юлында М.Корбангалиев, Галимҗан Ибраһимовлар күп хезмәт күрсәттеләр. Шулар аркасында татар теле мәктәпләрдә рәсми бер дәрес булып укылырлык дәрәҗәгә килеп җитте.

Әдәби телдә Каюм бабай белән үк башланган татарлык агымы көннән-көн тирәнәя, көчәя барып, элгәреге гарәплек, чыгытайлык, төреклек агымнарын тәмам җиңеп чыкты. Татар әдәби теленең йөзе ачык күренә башлады (бу чордагы эшләр белән ныклап танышасы килгән иптәшләр Г.Ибраһимовның «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» дигән китабын карасыннар).

### Октябрь революциясеннән соң

Октябрь революциясеннән соң, башка сәяси, иҗтимагый һәм мәдәни эшләр белән бергә, тел бабындагы эшләрне дә киңәш, план белән оештырып алып баруга киң юл һәм зур мөмкинлек ачылды. Бу эшләрдә элгәреге анархиягә, аерымлыкларга чик куелып, күмәк эш бергә кушылып, туры юл белән тиз-тиз адымнар белән алга юнәлде.

Мәдәни-гыйльми эшләрнең барышы гомумән сәяси, икътисади эшләргә бәйләнгән булганлыктан, Октябрь революциясеннән соң ун ел эчендә тел бабындагы гыйльми, гамәли эшләребезне гомуми хәлләргә карап, ике дәвергә бүлеп күрсәтергә туры килә:

1. Ун елның беренче ярымы.
2. Ун елның икенче ярымы.

Октябрь революциясеннән соңгы ун еллык чорының беренче ярымы көчле революция хәрәкәтләре, гражданнар сугышы, авыр ачлык еллары сәбәпле, мәдәни, гыйльми эшләрдә яңа иҗатлар белән шөгыльләнергә артык мөмкинлекләр туып җитә алмаган була. Шуңа күрә бу дәвердә безнең тел бабындагы эшләребез элгәредән таркау хәлендә булган эшләрне оештыру, элгәреге казанылган белемнәрне туплау, үстерү, тулып җитә алмый калган эшләрне төгәлләү рәвешендәрәк уза.

Элгәреге анархия юлы белән барган, булып торган имля революциясе бу чорда төрле конференцияләр, съездларда бик кызу мөзәкәрә ителеп, хәл ителә (имля мәсьәләсе турында «Мәгариф»тә аерым мәкалә басылганга күрә, мин монда тукталырга теләмим).

Бу вакыт ана теле мәктәп программаларына ныклап кереп, гражданлык алган була. Шуңа күрә бу дәвердә күбрәк сарыф-нәхүдән гамәли дәреслекләр әзерләү ягына әһәмият бирелә. Элгәредә бу юлда эшләп килгән иптәшләрдән Г.Ибраһимовның «Тел сабаклары», уфалы Ф.Сәйфинең «Татар теле дәресләре», М.Корбангалиев, Х.Бәдигыйларның «Ана теле дәресләре» берничәшәр мәртәбә төзәтелеп басылып чыгалар. М.Корбангалиев, Х.Бәдигый иптәшләр «Ана теле сарыфы» һәм «Ана теле нәхүе» дигән китапларын байтак нәрсәләр, уңайлыклар арттырып, яңадан эшләп чыгаралар. 1920 елларга таба каширләр, язучылар ярышы бетерелгәннән соң, «Тел сабаклары» коллектив рәвештә төзелеп тарала башлый. Җ.Вәлидинең укытучылар, курслар өчен кулланма итеп төзелгән «Татар теленең грамматикасы» ике мәртәбә басылып чыга. Бу китап элгәредән казанылган белемнәргә бер йомгак булу белән бергә, фонетика, сарыф, нәхү бабында яңадан бик күп байлыкларны да эченә алган тирән гыйльми бер әсәр була. Ләкин шуның белән бергә, бу китап гыйлем дөньясында ташланган элгәреге мантыйкый методны яңадан көчәйтү белән дә үзенә аерым бер урын тота.

Бу дәвернең характеры булган эшләребездән тагын берсе итеп, әдәби татар телен чит сүзләрдән тазарту, матбугат телен массага якынлаштыру юлындагы көрәшләрне күрсәтергә була. Ул чакта безнең матбугатта элгәреге гарәплек, төреклек калдыклары булып, эшче, авыл аңламаслык бик күп чит сүзләр кулланыла, икенче яктан укымышлы яшьләрнең теле сугыш, революция китереп киткән бик күп яңа сүзләр белән чуарлана башлаганы күренә иде. Шуңа күрә бу дәвердә бер яктан иске гарәплек калдыкларына, икенче яктан, үз сүзләребез бар өстеннән артык күп урыс сүзләре куллануга каршы көрәшләр барды. Бу мәсьәлә тирәсендә әллә никадәр җыелышлар, киңәшләр, тартышлар булып узды. Шул көрәшләр нәтиҗәсендә бик күп яңа татар сүзләре дә ясалып, матбугат теле көннән-көн татарлаша, халыкка якынлаша барды. «Түгәрәк, оешма, укытучы, элемтә, уңышлы...» кебек байтак сүзләр шул чаклардан башлап әдәби телдә гражданлык алып киттеләр. Бу юлдагы көрәшләр, акрынлап булса да, әле дә дәвам итә.

Ун елның соңгы ярымы сугышлардан, ачлык авырлыкларыннан арынып, яңадан төзәлү, тыныч төзү эшләре башлану белән аерыла. Икътисади, иҗтимагый эшләрнең характеры гыйльми, мәдәни эшләргә дә бик зур йогынты ясый. Авыр еллар сәбәпле акрынлап, тукталып торган гыйльми, иҗади эшләр яңадан җанланып китә. Татар телен гыйльми һәм гамәли яктан эшләү мәсьәләләрендә элгәредән дәвам итеп килгән нәрсәләр белән тукталып калмыйча, элгәреге эшләргә ревизия ясау, андагы яңа капитал

хезмәтләргә нигез салу, шул юлдан киң колач, тирән тикшерү белән эшкә башланганлык күренә. Элгәредән эшләп килгән тел тикшерүчеләребез аерым бүлекләрдә тирәнәеп, хезмәтләрен дәвам иттерәләр. Яңадан көчле эшчеләр үсеп чыга башлыйлар. Бу дәвердәге иҗади эшләрдән берсе итеп тел күзәтүдә, грамматикаларда шәкли нигез мәсьәләсен күрсәтергә кирәк. Революциядән соң мәктәпләрдә үзгәреш ясалу белән урыс галимнәре арасында мәктәп грамматикаларын гыйльми грамматикалар белән берләштерү, сарыф-нәхүләрдән форма-шәкел ягын нигез итү күрәше башланган иде. Моның йогынтысы белән ачлык еллардан соң бездә дә шәкли нигез мәсьәләсе, матбугатта элгәреге сарыф-нәхүләребезгә революция ясау хәрәкәте башланды.

1922–1923 елларда үзбәк матбугатында проф. Поливанов белән Н.Хәким иптәшләр төрек теле грамматикаларын шәкли нигезгә карап төзергә кирәк дигән бәхәсне ачалар. Н.Хәким белән Габдрахман Сәгъди иптәшләр арасында бу турыда бәхәсләшүләр булып үтә. Мәсьәлә соңыннан татар матбугатына да күчеп, башкалар да шуңа катнаша. 1922 елны «Безнең юл» журналының 4 нче санында, 1923 ел «Безнең юл»ның 6 нчы санында, «Мәгариф» журналының 1924 елгы 3–4 саннарында, 1926 елгы 1–2 нче санында Нигъмәт Хәкимнең «Грамматика әсаслары», «Падеж мәсьәләсе», һәйәт тарафыннан төзелгән «Сарыф-нәхү хакында», «Грамматика эшләүдә мөһим моментлар» дигән мәкаләләре булып үтә. Нигъмәт иптәш бу мәкаләләрендә грамматикаларда шәкли якны нигез итү кирәклеген алга сөрә. Тәгърифләр сүзләрне төркемләү, бабларны билгеләү кебек берничә нәрсәгә шәкли яктан үзенең карашын да күрсәтеп уза.

1923 елларда М.Корбангалиев, Х.Бәдигый иптәшләрнең «Эш мәктәпләрендә ана теле программасы» китабында да тел күзәтүдә шәкли якны нигез итү кирәклеге күрсәтелеп үтелгән.

Габдрахман Сәгъди иптәш үзбәкчә «Инкыйлап» журналында төрек телләренең сарыф-нәхүләрендә саф шәкли нигезне алу мөмкин булмавын, телебездә мантыйкый якның көчле булуын куәтләп, берничә мәкалә язган иде. 1925 елгы «Мәгариф» журналының 4–5 саннарында «Сарыф-нәхү әсаслары» дигән мәкаләсендә шул карашларына йомгак ясап, тел өйрәнүдә нигез максат, мөндәриҗә һәм ысул хәсиятләренә изах биреп үтә.

Бу мәкаләне язучының «Белем» журналының 1925 елгы 4 нче санында, «Мәгариф» журналының шул елгы 10–11 санында «Бездә падеж бармы-юкмы мәсьәләсе», «Грамматика нигезләре турында» дигән мәкаләләре була. Бу ел «Вестник Н. об-ва татароведения» журналының 7 нче санында «Телебезнең ялганмалык табигате турында» дигән русча бер мәкалә чыга.

Бу мәкаләләрне язучы да грамматикаларда шәкелне нигез итү ягын куәтли, телебезне шәкли яктан карап тикшерә, шуның гамәли юлларын күрсәтә.

Төрек телләре грамматикаларында шәкелне нигез итү мөмкинме, түгелме дигән мәсьәләгә чик куйган нәрсә Г.Алпаровның 1925 елда чыккан «Татар грамматикасы» булды. Беренче тәҗрибә урынында төзелгән бу китапның безгә биргән яңа нәрсәсе татар теленең сарыф-нәхүен формаль метод, шәкли нигез буенча тулы рәвештә төзек бер системага салу, телебезнең тышкы фактларыннан ничек файдалану юлларын күрсәтү, шуны гамәли рәвештә исбат итү белән бергә, телебездәге кушымчаларны барлап, аларның ялгану тәртипләрен ачу, ялганмалык табигатен ачыклабрак өйрәтү булды. Шуның белән бергә без монда грамматиканы башка төрек телләренә чагыштырып өйрәнә баруның юлын да башлап күрәбез. Хәзерге көндә «Татар грамматикасы» тел укытучыларына, 2 нче баскыч эш мәктәпләрендә укучыларга кулланма итеп төзелә.

Шәкли грамматика ысулы бу ел Казанда булып үткән татар теле һәм әдәбият укытучыларының Бөтенсоюз күләмендәге конференцияләрендә кабул ителде. Хәзер мәктәпләр өчен шәкли нигез буенча тел дәреслекләре дә әзерләнеп чыга башлады. М.Корбангалиев, Х.Бәдигый иптәшләрнең «Тел сабаклары» шәкли нигезгә каратып яңадан эшләнеп чыкты.

Телебезне тикшерү юлында соңгы елларда безнең гыйльми үсүебез билгесе итеп югарыдагы эшләрдән башка тагы түбәндәге хезмәтләрне күрсәтеп үтәргә кирәк:

«Мәгариф» журналының 1923–1924 елгы 9–10 һәм 3–4 саннарында Г.Рәхим, Г.Гобәйдуллиннарның «Төрекчә бер сүз төбе турында төпчену» дигән мәкаләләре телебезне тарихи яктан өйрәнүчеләр өчен әһәмиятле, тирән гыйльми бер төпченү үрнәге булды. Уфалы Хангилдин иптәшнең «Башкорт аймагы» журналының 2 нче санында (1926) телебездәге кушымчаларны төркемләү турында бер тәҗрибәсе күренгән иде. «Вестник Татароведения» журналының 6 нчы санында Җ.Вәлидинең «Татар теленең шивәләре турында» мәкаләсе, 7 нче санында Г.Шәрәфнең тәҗрибәле фонетика кораллары буенча татар теленең авазларын тикшерү турындагы мәкаләсе дә бу дәвердәге тел бабында әһәмиятле гыйльми хезмәтләрдән саналырга тиеш.

Татар телен гыйльми тикшерү эшләренә урыс галимнәре дә актив рәвештә катнашып, безгә үзләренең белемнәре белән юл күрсәтеп баралар. Лингвистикада танылган зур галимнәрдән проф. Богородицкийның хезмәтләре аеруча дикъкатькә алынырлык эшләр. 1922 елның «Введение в татарское языкознание» дигән китабының фонетикадан бер кисәге басылып чыккан иде. «Вестник татароведения» журналының 3, 4, 6 нчы саннарында «Төрек телләрендә иялек килеше төренең эволюциясе», «Татар телендәге ике иҗекле сүзләрдә тон хәрәкәте», «Төрек телләрендәге сингармонизм турында» дигән мәкаләләре булды. Хәзерге көндә 70 яшьләренә җиткән бу карт профессорның, картлыгына бирешмичә, төрек-татар телләрен төпчеп ятуы безнең өчен аеруча өлге булырга тиешле.

Тюрколог проф. Ашмаринның да чокчынып ятканы күренә. 1923 елларда аның «Татарчада тыныш билгеләре» дигән китабы басылган иде. Соңгы 7 нче сан «Вестник» та «Татар телендә җөмлә кисәкләренең тәртибе мәсьәләсенә» дигән мәкаләсе чыкты.

Бу эшләр соңгы биш еллык төзү чорында татар теле гыйльми эшләр юлында безнең нинди зур адымнар белән алга баруыбызны күрсәтергә җитәрлек нәрсәләрдер.

Ана теленең методикасы мәсьәләсенә килсәк, бу яктан да без урыслар арасыннан калышмый, эре адымнар белән алга барабыз дияргә була. Бу яктан инде без элгәреге мәддия, саутия ысулларыннан үтеп, бөтен сүз ысулына килеп җиттек. Элгәреге карт педагогларыбызга ярдәмгә әллә никадәр яшь педагоглар җитешеп килә. Болар «Мәгариф» журналында үз тәҗрибәләрен өзлексез язып торалар.

Октябрь революциясе аркасында Татарстан җөмһүрияте төзелеп, татар теле дә рәсми дәүләт теле булып танылганнан соң, дәүләт хезмәтендәге урысларга да татар телен белү мәҗбүр ителгән иде. Шул уңай белән урысларга татар теле өйрәтү өчен берникадәр дәреслекләр, кулланмалар төзелеп таратылды. Һади Максудиның «Татарстан»ы, М.Корбангалиев, Х.Бәдигыйларның урыслар өчен «Татар теле» дәресләре, М.Корбангалиев һәм Риза Газиз иптәшләрнең 1926 елда басылып чыккан урыслар өчен «Татар грамматикасы» шул җөмләдән саналырга тиешле хезмәтләрдер. Сүз байлыгын җыю, лөгатьләр эшләү мәсьәләсенә килсәк, бу яктан да яхшы ук зур хезмәтләр ясалып ятканын күрәбез. Танылган тел белгечләребездән Җ.Вәлидинең бөтен күләме 80–100 табакларга җиткән «Татар теленең тулы сүзлеге»ннән бу ел 22 табаклык беренче кисәге басылып чыкты. Бу сүзлекләрдә татар шиваләрендә кулланылган бөтен сүзләр җыйналып, һәр сүзнең чыгышы, мәгънә яклары татарча изах ителә бара. Элгәре безгә моның кебек озак вакыт, күп акча, зур чыгым сораган хезмәтләргә керешү мөмкин түгел иде. Октябрь революциясе аркасында мондый керешүләргә алдан ярдәм күрсәтелеп, уңышлы тәгәлләнү чаралары да күрелеп тора.

Бу юлдагы эшләребездән тагын И.Кули, Р.Газиз, М.Корбангалиевләрнең яңа гына басылып чыккан «Татарча-русча сүзлек»ләрен, Алпаровның «Татар теленең имля сүзлеге»н дә әйтеп үтәргә кирәк. Төзелеп, басарга бирелеп яткан башка сүзлекләр дә бар: Фарис Юсуповның күптән җыелып килгән «Зоология, ботаника сүзлеге», Фазыл һәм Кәбир Туйкәләрнең «Үсемлекләр сүзлеге» бар. Шулар өстенә яңадан эшләнеп яткан «Русча-татарча тулы сүзлек» һәм «Авыл хуҗалыгы атамалары» бар дип ишетәбез.

Гыйльми үзәк янындагы гыйльми атамалар төзү комиссияләренең хезмәтләрен дә шуңа кушарга ярый. Бу хезмәтләр бергә тупланып, зур бер тел байлыгы булып басылып чыксалар кирәк.

Сүз азагында җанлы сөйләү теле белән матбугат, әдәбият теленең

барышы турындагы берничә сүз әйтеп китик. Сугыш, революция еллары, яңа тормыш агымы белән хезмәт өстендә булган егетләребезнең, яшьләрнең җанлы теле чит сүзләр хисабына баеп барганлыгы күренә. Бу турыда «Безнең юл» журналының бу елгы 4–5 санында М.Галинең тикшеренүләре җанлы татар теленең барышы белән кызыксынган иптәшләр өчен әһәмиятле бер материал булса кирәк. Ләкин язу, матбугат, әдәбият теле, баштарак, бер яктан, иске гарәплек калдыклары, икенче яктан, яңа кергән чит сүзләр белән чуарланыбырак барса да, көннән-көн алардан сафланып, төзек бер эзгә төшеп бара. Әдәби телне халыкка, эшче крестьян массасына якынлаштыру юлындагы көрәшләрнең бу эштә зур йогынтысы булганлыгын уйларга туры килә. Бу турыда «Безнең юл» журналының бу елгы 2–3 нче саннарында Гөлсем Мөхәммәднең «Татар телендә чит сүзләр» дигән бер мәкаләсе дәлил була ала. Бу мәкаләдәге тикшеренүләргә караганда, безнең әдәбият телендә чит сүзләрнең чамасы кайбер язучыларда күп булганда 18 процентларга җитеп, кайберәүләрдә аз булганда хәтта 3 процентларга чаклы төшә ала икән. Шуның белән бергә без бу мәкаләдә күрсәтелгән цифрларга карап, язучыларыбызның телендә чит сүзләр саны барган саен кими, азая барганлыгын да ачык күрә алабыз.

Татар телен эшләү юлында бу ел Казанда июнь аенда җыелган Бөтенсоюз күләмендәге тел, әдәбият укытучылары конференциясе аеруча әһәмиятле тарихи урын тота. Монда, балалар йортыннан алып югары мәктәпләргә чаклы, тел укыту, тел тикшерүгә бәйләнешле бөтен мәсьәләләр зур бердәмлек белән нечкәләп тикшерелеп чыкты. Әдәби, гыйльми үсеп барган татар теле ныклы нигезләргә салынып, алда барачак юлына маяклар куелды.

Кыскасы, әдәби татар теле хәзер саф, төзек аһәңле гыйльми бер тел булып урнашып бара. Октябрьнең ун елы тулганда, без моны шатлык белән билгеләп китә алабыз. Икътисади, мәдәни шартларның моннан соң да уңайлы килүенә карап, алда тагы да күбрәк, тагы да нәтиҗәлерәк уңышлыклар күтәргә була.

# ФОНЕТИК ТРАНСКРИПЦИЯМЕ, ГАМӘЛИ ЯЗУМЫ?[1]

«Идеалом было для меня всегда замена схоластики, механического разбора живой мыслью, наблюдением над живыми фактами языка, думанием над ними. Я знаю, что думать трудно и тем не менее думать надо и надо, и надо бояться схоластики, шаблона, которые подстерегают нас на каждом шагу, всякий раз как мысль наша слабеет. Поэтому не следует прельщаться легким, простым и удобным: оно приятно, так как позволяет нам не думать, но ложно, так как скрывает от нас жизнь; бесполезно, так как ни чему не учит, и вредно, так как ввергает мысль нашу в дремоту».

*Профессор Л.В.ЩЕРБА.*
*(Сборник «Русская речь» II кн. стр. 26)*

20–30 еллар буена тикшерелеп, бер туктамый төзәтелеп, үзгәртелеп килгән имля мәсьәләсе, Октябрь революциясеннән соң бераз карарлашып тукталып торганнан соң, латин әлифбасына күчү хәрәкәтләре уңае белән яңадан күтәрелеп китте, бу юлы ул, элгәрге традиция белән килгән имлябызга вак-төяк төзәтмәләр кертү рәвешендә генә бармыйча, бөтен нигезеннән, әлифбасыннан башлап, яңа баштан төзелергә тора. Аны төзү эшләренә якыннан катнашып, нигезеннән үк төпле, рациональ бер юлга салырга ярдәм итешү тел өстендә эшләүче, имля өстендә баш ватучыларның тарихи бурычлары булып калды. Шул уңай белән кайбер иптәшләр үзләренең бу мәсьәләгә карашларын, планнарын матбугатта язып үттеләр. Ләкин әле мәсьәлә ачылып, әтрафлы рәвештә каралып, өзелеп беткәне юк. Тикшерәсе яклар, үлчәп карыйсы урыннар, әйтәсе сүзләр күп кенә күренә әле.

Имля турында язучы иптәшләр мәсьәләгә бер яклырак карап уй йөртәләр. Иске имляне тәнкыйттән уткәрү белән бергә, имля мәсьәләсенә, гомумән язуга караштa әлегә чаклы мәдәният, гыйлем дөньясында гомуми рәвештә игътираф ителгән гыйльми әсәрләргә дә ревизия ясарга омтылалар. Үз фикерләрен үткәрү өчен агитация йөзеннән кызу кан белән сөйләнгән нәрсәләргә тукталып та тормыйк. «Гыйльми-фәнни» дип исбат итәргә тырышкан фикерләрендә дә фактка туры килеп бетмәгән байтак кына фәнни хаталар очратабыз.

---

[1] Мәгариф. – 1928. – № 9. – 77–89 б.

Бу хаталар башлыча түбәндәге нәрсәләргә кайтып кала:

1) гомумән тел, язу мәсьәләләренә диалектик караш юклыгы;

2) сөйләү, аңлау, уку, язу процессларының ничек үтәлүләренә дикъкать итмәү;

3) фонетик транскрипция белән гамәли язуны аермау;

4) тел, язу элементларына фәнни караш сайлыгы;

5) имля нигезләре, язу нормалары турындагы чын гыйльми карашлар белән исәпләшмәү, аларның фәннилеген танымау;

6) гамәли язуның әдәби телгә мөнәсәбәтен аңламау;

7) имляның идеалогик ягына бер катлы караш;

8) төзек язуның массалашуындагы гамәлне күрмәү һәм башкалар.

Мин макаләмдә мәсьәләнең менә шул якларына тукталмакчы булам. Хәзергә бездәге бу хаталануларның үзе кайдан килеп чыгуына марксизм яктысы белән әз генә күз ташлап киткәндә зарар булмас дип беләм.

Гасырлар буенча йоклап яткан караңгы бер дәвердән соң, уянып, мәдәни күтәрелә башлаган чагыбызда безнең беренче чиратта алдыбызда торган эшебез мәктәп, грамота мәсьәләсе булды. Уку-язу танытуда ысул саутия (аваз методы) иң җиңел, иң идеал бер юл булып танылды. Шул дәвердә әлифба китапларының, дәреслекләрнең дә, гомумән имлябызга ишетләгәнчә генә язылган булуы миләребезгә зур идеал булып урынлашып калган иде. Соңгы вакытта уку-язу танытуда әлифбасыз, авазга каршы хәреф күрсәтми укыту, бөтен сүз методлары чыгып, төрек телләре дәүләт теле булып танылгач, иҗтимагый шартлар үзгәргәч тә, башыбызга урнашып калган бу идея – иман үзгәрмичә калды.

Ул чакларда мәктәпнең тормышка әзерләүче, үткенче бер васита булуы артык тикшерелми, балаларга мөмкин кадәр тизрәк, бер дә көч сарыф итмичә укырга, язарга өйрәтү өчен генә ярыш бара иде. Гел ишетелгәнчә генә язылганда, аваз методы белән өйрәнүче балалар 1–2 ай эчендә үз-үзеннән шаулатып укый, шаулатып яза да китә, имля кагыйдәләре шуны буып тотарга гына сәбәп дип ышанылa иде. Карашлар, белемнәр, шартлар үзгәргәннән соң да мәктәпнең, авазның самоцель булып калуы шуннан килә. Имля мәсьәләсен куертучы, фонетикага артык мәхәббәт багышлаучыларның шушы ысул саутия дәверенең каһарманнары булуы да шуны күрсәтә торгандыр.

* * *

Язу да, тел кебек үк, кешеләрнең үзара иҗтимагый мөнәсәбәтләреннән туган, шул мөнәсәбәт коралы булып йөри торган нәрсә. (Надстройканың базиска тәэсире.) Язу – тел белән сөйләп аңлату урынына йөри торган шартлы билгеләр. Шуңа күрә язуның телгә муафыйк, аңлашуга яраклы булырга тиешлеге һәр кемгә билгеле. Соң ул ничек булганда телгә муафыйк, аңлашуга яраклы була? Бусы бераз авыррак мәсьәлә. Моның өчен

безгә телебезне тикшереп карарга, аның нинди элементлардан торганын, ничек уй, мәгънә аңлатканын белергә кирәк була.

Тел – тормыш кисәге, тормышта садә, бер катлы «ялгызы гына хөкем итә торган дисциплина» юк. Моны марксизмның әлифбасы белән таныш кешеләр дә белә. Тел – ялгыз бер генә катлы механик авазлар тезмәсендә генә тора торган нәрсә түгел. Без телебездә авазлар белән бергә, аерым мәгънәле сүзләр, ул сүзләрнең кечкенә мәгънәле кисәкләре, кушма сүзләр, сүз тезмәләре барлыгын, аларның чиксез катлаулы булганлыкларын беләбез. Тел менә шул элементларының, шул эреле-ваклы төрле кисәкләрнең катлаулы кануннар буенча бергә оештырылган комбинациясеннән тора.

* * *

Бу элементларның кайсы масса өчен уңайлы, сөйләүче халык тарафыннан кайсысы тизрәк, ачыграк сизелә?

Сөйләүче масса өчен болар арасыннан иң ачык сизелгәне, иң җиңел аерылганы тышкы тәсаувырлар, мәгънәләр белән бәйләнгән аерым сүзләр булуында шөбһә юк. Аерым сүзләребезнең телебездә аерым гармония белән әйтелүләре шәкли яктан да бик ачык аерылып торган элементлар. Аннан соң җиңел сизелү ягыннан аерым уй белдергән җөмләләр, вак тәсаувырлар белән бәйләнгән төп сүз, кушымча кисәкләр киләләр. Сөйләүче өчен сизем ягыннан аеруы авыррак булган элементлар – авазлар, болар арасыннан да авыррагы әгъзаларның зәгыйфь хәрәкәте белән чыгарылган сузык авазлар. Чөнки авазларны аеру сөйләү әгъзаларының хәрәкәтләренә дикъкать итү белән генә мөмкин була. Хәлбуки халык үзенең ничек сөйләгәнен сизми сөйли. Аның өчен ничек сөйләү түгел, нәрсә сөйләү мөһим, ул шул якка дикъкать итә.

Моны исбат итәр өчен язучылык тарихына күз салу җитә: кешеләр башта тоташ уйларны, аерым мәгънәле сүзләрне генә ишарәләр белән язып аңлашканнар. Борынгы мисыр иероглифлары, хәзерге кытай язулары, безнең көндәлек тормышыбызда кулланган цифрларыбыз, математика билгеләре шул аерым сүз, мәгънә ишарәләре, икенче урында сүз кисәкләренә ишарәләр белән язу тора. Хәзерге япон язулары шуңа нигезләнгән икән.

Кешеләр иң соңыннан гына, тел турында белемнәре үскәннән соң гына (әлбәттә иң алдынгылары гына), авазларга билге алып язуга килеп җиткәннәр. Ләкин монда да элгәре иң ачык сизелгән авазлар белән генә файдаланганнар. Финикиялеләр, яһүдләр һәм гарәпләрнең әлифбаларында бары 22 хәреф булып, сузык авазларны калдырып язулары, шул аваз сиземе тулы булмаудан килә. Борынгы төрекләрнең (орхон язулары) тартык авазларның калын, нечкәләренә дә аерым хәрефләр куеп да, язуларында сузыкларны төшереп калдырулары гарәп тәэсиреннән туган бер нәрсә түгел, әлбәттә. Гарәп язуында ас, өс, өтерләрнең, Европа әлифбаларында

төрткеләр я катлаулы хәрефләр белән күрсәткән кыска сузыкларның соңыннан билгеләнүе, рус әлифбасындагы фонетикага хилаф Е, Ю, Я «сузык»ларының әлегә кадәр сөйрәтелеп йөрүе бары да шул аларның танылмавыннан, сизелмәвеннән килә. Ниһаять, безнең үзебездә имля мәсьәләсендәге фаҗигабызның сәбәбе, « ـُ » (ы-е) авазының хәтта кайбер телчеләребез тарафыннан «калкалә» дип кенә каралуының, әлегә чаклы телебездә ничә сузык аваз барлыгын да төшенеп җитә алмавыбызның сере дә шунда.

* * *

Хәзерге көндә мәдәният дөньясында башлыча өч төрле язу бар:

1) ашыгыч язу – стенография,

2) аваз теркәү – фонетик транскрипция,

3) гамәли – практик язу.

Бу язулар ишарәләре, ысуллары, максатлары ягыннан бер-береннән бик нык аерылалар.

**Стенография** – авыздан сөйләнгән бөтен нәрсәне, сөйләп барган тәртибенчә, түкми-чәчми теркәп алып калу өчен кулланыла. Монда җитезлек, сөйләгәнне язып өлгерү мөһим. Шуның өчен монда бөтен сүз, сүз кисәге, хәтта мәгълүм бер шаблон буенча, бөтен җөмләләргә дә шартлы, кыска бер ишарә ясап алып калу да җитә. Соңыннан стенограф үзе аны тутырып, яңадан гамәли язуга күчерә алса, була. Бу язулар массага иҗтимагый мөнәсәбәт ролен уйнарга ярамыйлар, әлбәттә.

**Фонетик транскрипция** – лингвистларның гыйльми кабинетларында бер шивә яки сөйләшнең җанлы сөйләү формаларын тикшереп карау өчен кулланыла. Монда телнең мәгънә ягына, мәгънәле элементларына һич тә игътибар ителми. Ялгыз механик рәвештә нинди авазлар, интонация, басымнар белән әйтелүне теркәп алу гына күзәтелә. Монда авазлар нинди әгъза белән кай урыннан, ничек әйтелүдә генә түгел, калынлык, нечкәлек, аһәң, акустика, озын, кыска, ачык, тонык булу, экскурсия, рекурсияләре, йотылу, үзгәрү, тиз, әкрен сөйләү, сөйләүченең эчке настроениесендәге үзгәрешләр белән дә бер-береннән аерылалар.

Телдә мәгълүм бер хәреф белән генә точный (төгәл. – *А.Ш.*) күрсәтелгән, һәр җирдә бер төсле әйтелгән аваз юк; чиксез катлаулы, төрле авазлар тезмәсе генә бар. Сүз башындагы бер аваз, шул ук хәреф белән күрсәтелгән сүз ахырындагы аваз белән бер була алмый. (Бездәге «ا, و, وٗ, ـُ, ـِ» авазларын карагыз.) Бер сүздәге аваз, шул ук хәреф белән күрсәтелгән икенче сүздәге авазга охшамый.

Менә фонетик транскрипциядә шуларның барына да аерым хәрефләр, билгеләр алынган була. Монда ялгыз телнең шәкли ягы – ничек әйтеш ягы гына күзәтелеп, нәрсә сөйләү, нинди мәгънә аңлату ягына игътибар

ителмәгәнлектән, телнең мәгънә ташучы элементлары югалып, бер-беренә охшашып, үзгәреп бетәләр, бер сүз икенчесенә ялганып танымаслык, аңланмаслык бер хәлгә килгән була.

Менә «йөз процент фонетикага нигезләнгән» язу шушы инде. Ләкин бу массага кулланугa ярыймы? Юк әлбәттә, чөнки аның максаты да, юлы да башка. Ул аның өчен ирешә алмаслык кыен, артык черчекле (четерекле) бер нәрсә, ул зур, тирән белем сорый торган авыр бер язу. Ул кабинет имлясыдыр.

**Гамәли язу** – ул бөтенләй башка. Монда киң катлау халыкның бер төсле, уңай аңлавы, аңлаша алуы төп максат булып тора. Моңа нәрсә ярдәм итсә, тизрәк шуңа ирештерсә, шул юл тотыла. Монда бер катлы садә карашлар белән эш итәргә ярамый, бәлки телнең бөтен фактларын игътибарга алып, иҗтимагый якларын да күзәтеп, диалектик ысул белән эш итәргә мәҗбүрбез.

Тормыш өчен кирәкле, иҗтимагый мөнәсәбәт, үзара аңлашу коралы булган гамәли язуда тулы рәвештә фонетика нигезен генә үткәрү мөмкин дә түгел, кирәк тә түгел. Монда без фонетикага чик куярга, морфология, мантыйк әсасләре дигән башка нигезләргә дә игътибар итәргә мәҗбүр булабыз. Бу нигезләрне «татар укымышлыларының массага каршы чыгарган черек бер нәрсәләре» дип әйтү зур кыюлык, дөресе, гыйльми мәсьәләгә провокация кертү, демагогия ясау гына. Ул нигезләр бөтен мәдәният дөньясындагы тел галимнәре тарафыннан ачылган, фәнни яктан гомуми игътираф ителгән нәрсәләр. Телдә сүзләр, мәгънәле кисәкләр юкмыни? Алар язуда аерып күрсәтелмиләр дә укылмыйлармыни? Җөмләдә тыныш билгеләре куярга кирәкмимени? Аларны нинди нигезгә таянып язабыз соң?

Фонетикага артык кыйммәт биреп, башка нигезләрнең бәһасын җиткезмәү – фонетик транскрипцияне гамәли язудан аера белмәүдән генә килгән нәрсә.

* * *

Гамәли язуда бу нигезләр ничек аңлана? Аларның кайсына, күпмегә кадәр таянырга ярый? Хәзер мәсьәләнең менә шул якларына тукталып карыйк.

Масса язуында башта, авазларга хәрефләр билгеләгәндә үк, эш башкачарак корыла. Монда фонетика үзе шартлы бер мәгънәдә аңлана: монда алынган аваз, бер-береннән ничек булса да аерылган, үзенә башка бер төрле әйтелгән тавыш түгел, бәлки телнең сүз ясый торган, мәгънә аертуга ярый торган иң кечкенә кисәге. Моны фонетик язудагы аваздан аеру өчен «фонема – фанема» дигән атаманы йөртәләр. Фонема – аерым бер аваз түгел, ул мәгълүм бер чик арасында әйтелгән берничә аваз, шуларның барына да уртак бер атама. Аерым телдә сөйләүченең сиземендә (язы-

ковое сознаниедә) аерым аваз түгел, шушы фонемалар гына бар. Моны аңлар өчен берничә мисал алып карыйк:

Бездә یوق (юк) дигән бер сүз бар. Бу сүзнең икенче авазын төрле аваздан төрле хәлдә төрлечә ишетәбез: ерактагы кешегә кычкырганда, эреләнеп әйткәндә, урыс телендәге «о» авазы белән «йок», хәтта «а»га якынлатып یاق (як) дип әйтелә. Йомшак, иркәләп әйткәндә урысчаның «у» авазы белән «йук» дип әйтелә. Моның ике аралыкта әйтелгән хәлләре дә бар. Бу сүзнең башындагы авазны төрле хәлдә, төрле аваздан *җук, зук, дзук, жук, джук, зьок* төрләрендә ишетәбез. *Кил* дигән сүзнең икенче авазы тагы төрле хәлдә төрлечә – *кәл, кел, кил* рәвешләрендә әйтелә. Бу вариацияләргә карап, без бу сүзләрне башкача аңламыйбыз, һаман шул бер төп мәгънәне генә аңлыйбыз. Чөнки болар фонетика ягыннан башка-башка авазлар булса да, сүзнең мәгънәсен алмаштыра алмыйлар, яңа сүз ясамыйлар. Менә шушы ике чик эчендә (*о* белән *у, е* белән *и, җ* белән *й* арасында) әйтелеп бер мәгънәдә сүз ясауга гына яраган төрле авазлар барысы бергә бер фонема булалар. Гамәли язуда фонетика шарты мәгънәдә аңланып, әнә шул фонемаларга гына аерым хәрефләр билгеләнә. Гамәли язудагы хәреф һич бер вакытта чын авазны бирә алмый, ул әлеге авазларның барына уртак тәкъриби ишарә генә. Шуңа күрә аны фонетик язудагы чын авазны күрсәтүче хәрефтән аеру өчен лингвистикада «графема» дип атыйлар.

Гамәли язуда графема (безнеңчә хәреф) ничек укылуы (телгә, сөйләүгә яңадан кайтарылу – реставрациясе) укучының үз ирегендә. Аның телне белеп, җиткереп сөйли алуына кала. Монда «син бу хәрефне кайда гына күрсәң дә менә шул аваз белән генә әйт» дип өйрәтү телне бозу булачак. Шуңа күрә тел методикасы безгә грамота өйрәткәндә, әлифбасыз укытырга, бөтен сүз ысулы белән мисаллардан аваз аерттырырга куша да. Башкача өйрәткәндә дә барыбер шул баскычны үтми булмый. Юкса, без гомердә дә дөрес укырга өйрәнә алмас идек. Практикада бер өйрәнеп алганнан соң, без хәрефнең нинди урында нинди авазга йөргәнен үзебез сизмичә дә дөрес әйтә алабыз. Пешковскийның: «Всякий грамотный гораздо яснее и вернее представляет себе буквы своего языка, чем звуки его»[1] дигән сүзен дә шулай аңларга кирәк.

Кыскасы, гамәли язуда «һәр авазга бер хәреф» дигәнне аерым мәгънәле аерым сүз ясауга яраган һәр фонемага язуда үзенә махсус графема булырга тиеш, дип аңларга кирәк була. Яңа сүз ясауга ярамаган авазлар гамәли язуда игътибарга алынмыйлар, алына алмыйлар да.

Шуны да әйтеп китәргә кирәк, табигый, иҗтимагый хадисәләрнең бер кисәге булган телдә дә катгый, ачык чик аралары юк. Кайбер фонемалар үзара ачык чикләр белән бер-береннән аерылсалар да, кайберәүләре үзара бик аз аерылалар. Мәсәлән, сүз башындагы ا (а),

[1] Русский синтаксис в научном освещении. – 1928. – С. 20.

و (у), يـ (и), ۆ (о) фонемалары бездә сүз азагындагылар белән якын булсалар да, икесе бер түгелләр. Шулай да, боларның барына да аерым графема алып булмый. Бәлки, аларның урынына карап, төрлечә әйтелүеннән, ана телендә сөйләүчеләрнең аны саташтырмавыннан файдаланып (кагыйдәле булганга күрә), икәвенә бер билге алына. Шуңа күрә әлифба билгеләгәндә дә бер кадәр шартлылык, сонгыйлыклардан (ясалмалык.– *А.Ш.*) качып булмый.

Һәр телнең фонемалары, аларның чик аралары ул телнең үзенчә була. Бездә сүз ясамаган авазлар, башка телдә аерым сүз ясарга мөмкин (пил, коли, кули, пел кебекләр). Бездә татар теленең و (у) ، ـُ (и) сузыкларын урыс теленең «у», «и»ләре белән бер дип уйлау бар. Бу хата. Әлбәттә, татар теленең ا, ـه, و, ۆ, يـ, يـ, چـ, د, بـ, ک, گ... авазлары һичбер хәлдә башка телләрнең *а, я, у, о, и, ы, ч, г, к, б, д...* авазлары белән бер була алмыйлар.

Мәсьәләнең тагы башка ягы да бар. Гамәли язуда бер шивә, сөйләш фонемалары гына каралмый, монда төрле сөйләш һәм шивәләрне берләштергән, киң төркемгә уртак әдәби тел фонемалары күзәтеләргә, шуңа күрә якын кардәш телләргә дә күз салырга кирәк була.

Аваз ягыннан кардәш төрек телләре, аларның төрле шивәләре дә бер-береннән азмы-күпме аерылалар. Ләкин фонема ягыннан аларның аермалары юк диярлек, сөйләшләр бөтенләй аерылмыйлар. Төрек телләренең әлифбаларында уртак фонемаларга бер төсле графемалар алынганда, язма әдәби телләренең бер-берсенә якын, уртак булуына, бер-береннән мәдәни файдалануга киң юл ачылачагына шөбһә юк. Бер фонема билгесе булган бер хәрефне һәр кардәш төрек үз авазы белән укый, ләкин бер төсле язар иде. Чөнки бер төсле сөйләү тормышта юк, бер төсле язу гына бар. Әлифбада, язуда унификация фәкать шулай гына була ала. Ләкин, бу якка күз салынмаганлыктан, «яңа төрек әлифба»ларында язу рәвешләренең элгәргедән дә ераклаша төшкәнен күрәбез. Мәсәлән,

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| قول | – | үзбәк, | казакта | qol, | татарда | qul |
| كول | – | ” | ” | kөl | ” | kyl |
| قوُل | – | ” | ” | qul | ” | qol |
| كوُل | – | ” | ” | kyl | ” | kөl |
| كيل | – | ” | ” | kel | ” | kel |
| بل | – | ” | ” | bil | ” | bel сурәтендә языла. |

Хәлбуки болар арасында фонема ягыннан түгел, аваз ягыннан да аерма юк диярлек, ـُ авазында бөтенләй аерма юк. Болай булганда, бер төсле язу түгел, бер төсле аңлау, аңлашу да булачак түгел.

Яңа әлифбалар урынлашып киткәнче, бу хаталар төзәтелсә икән дип өмет итәбез.

* * *

Гамәли язуда, мантыйкый әсас буенча, җөмлә төрләренең, җөмлә кисәкләренең тыныш билгеләре белән аерылып, фикернең дөрес аңлавына ярдәм итүче бөтен шартларның күзәтелүе тиеш икәнлегендә шөбһә дә, тартыш та юк дип беләбез. Шуңа күрә ул турыда тукталып та тормыйм.

Килик морфология нигезләренә.

* * *

Гамәли язуда төп максат булган нәрсә аңлашу дигән идек. Имляда морфология нигезе телнең мәгънә ташучы элементларына әһәмият бирүдән, әнә шушы төп максат булган аңлату ягын күзәтүдән килеп чыккан нәрсә. Чөнки телнең аваз ягы, икенче төрле әйтсәк, әйтеш, сөйләнеш (шәкел) ягы гына бу максатны үтәп бетерә алмый. Әйтеш белән мәгънә арасында тарихи, иҗтимагый мөнәсәбәт аркасында, янәшәлек ассоциациясе белән туган якын бәйләнеш булса да, алар арасында чын мәгънәсе белән тулы берлек юк. Сөйләгәндә алар икәве бер-беренә тәңгәл килеп үк бара алмыйлар. Телнең мәгънә сиземе үзенең юлында конкрет фактлар эзе белән алар арасына ачык чикләр куеп, ачык төсләр белән аерып баскычлап, сыниклы сызыклар ясап бара. Шәкел – әйтеш андый сыныклар, сикермәләр ясый алмый. Ул почмакларда бөгәлҗәләр ясап, турыданрак сыпыртып китә. Ул мәгънәнең ялкау хезмәтчесе, ул үз эшен мәгънә кадәр үк төгәл, җиткереп үтәми, мәгънәдән калышмый, аны ерактанрак күрсәтеп, ничек итте алай ияреп барса, булды аңа. Чөнки ит кисәге булган телнең, баштагы тапкыр ми кебек җитез эшли алмавы билгеле инде, шуңа күрә аерым сүз, кисәк мәгънәләр тәсаувыры белән фонетика берләшеп җитә алмыйлар. Җанлы телдә сүзләрнең кайдан башланып, кайда бетүләре аерылмый, бер сүз икенчесенә кушылып, мәгънәләре аерым сүзләр бер-беренә охшашып, бер үк сүз берничә төрле әйтелеп чуалышып бетә.

Мәсәлән, *бар ал, бара ал* сүзләрен *барал* рәвешендә

| | | | |
|---|---|---|---|
| бар иде | ” | барыие | ” |
| ат дагасы | ” | аддагасы | ” |
| боз ява | ” | боҗҗава | ” |
| каз шурпасы | ” | кашшурпасы | ” |
| тоз сал | ” | тоссал | ” |
| кил әле әй | ” | киләләи | ” |
| кил, әзер ул | ” | киләзерул | ” |
| алып бар | ” | апар | ” |
| мин әйтәм | ” | мәйтәм | ” |
| минем эш бар әле | ” | минемж бар әле | ” |

әйтәләр.

Шулай ук төп сүз, кушымчаларны да тел психологиясе һәр җирдә бер төсле итәсе, аналогия эзе белән алып барасы килсә дә, фонетик як аңа ирешеп бетә алмый, өлгерә алмый. Аның тирәсендә төрле аумалар (уклоннар) ясап кына барырга мәҗбүр була. Шулай булса да, ул телнең грамматик сиземеннән артык ерак китеп, саф үзенчә генә дә ясап бетерә алмый. Үзгәргән авазлар ике якның да үзенә тартуы белән, ике аралыктарак торып калалар. Шуның белән бергә, көче җиткән кадәр тел мәгънәгә якын килергә дә тырыша, күп вакыт аның белән бөтенләй берләшә дә. Мәсәлән:

| Мәгънәле телдә | Әйтештә | Мәгънәле телдә | Әйтештә |
|---|---|---|---|
| килгәнләр | килгәннәр | азчылык | аччылык |
| кызса | кысса | унга, уңга | уңга |
| баскыч | бачкыч | синме? | симме? |
| борынгы | бороңгы | тунлык | тунnык |
| җенлән, җендән | җеннән | әйтегезче | әйтегечче |
| шундан | шунан | янына | җанна |

булып чыгалар.

Сүзнең беренче иҗегендә аерым мәгънә ясауга яраган ۏ (*о-ө*) фонемасы, иреннәрнең ялкаулыгы сәбәпле, соңгы иҗекләрдәге ـٰ (*ы-е*) фонемасын да өләндереп әйттерә, ләкин тел психологиясе, аналогия көче аның тәэсирен киметеп үзенә тартканлыктан, өләнү артык еракка китә алмый, 2–3 иҗектән соң ачылып «е»га әйләнергә мәҗбүр була. Аңа кадәргеләрендә дә ул чын *ө* түгел, ике уртадарак әйтелгән була. Шуңа күрә без «төрлесенеке, төзелешенең» кебек сүзләрнең тулы рәвештә азакка чаклы «ө» авазы белән «төрлөсөнөкө, төзөлөшөнөң» булып әйтелүне сизмибез. Әйтелештәге бу аерымлыклар төрле шивәләрдә, төрле сөйләшләрдә тагы башкачарак булганлыктан, аларның мәгънәне чуалтулары тагы да көчәя төшә.

Боларны барын да ишетелгәнчә генә язып бетәргә мөмкинме? Аваз – мәгънә коралы гына, ул безгә самоцель (үзмаксат.– *А.Ш.*) була алмый, аны аерып торуы да авыр. Шуңа күрә без аңа бер кадәр чикләр куярга мәҗбүр булабыз. Мәгънә аеру, бер мәгънәле элементны бер төсле итү теләге, грамматик төзеклек тойгысы – телдә көчле бер фактор. Мәгънә бер булганда аналогия буенча хәтта аерым кушымчаларның да, телдә бер-беренә охшашып киту фактлары бар.

Тел үзе дә ачык аңлатырга теләп, җиткереп сөйләгәндә, мәгънәле сүзләрне тутырып, берәмләп өзеп әйтә, төшеп калган авазны кушып, үзгәргән җирләрне, охшашкан урыннарны төзәтеп аңлатырлык, саташтырмаслык итеп әйтеп бирә, ике уртада әйтелгән авазларны мәгънә теләгәнчә, башка төрләр белән бер итеп чыгарып бирә. Ул аны өйрәнеп түгел, табигый бер сәвекъ белән эшли, чөнки телдә ул сүзләрнең үзгәрми, бозылмый әйтелгән нигез төрләре дә бар. Сөйләүче шул запастан файдалана.

Гамәли язуда морфология нигезе менә шушы мәгънәле элементларны грамматик җиткереп әйтүгә карап, телнең көче җитмәгән урыннарны тутырып, төзәтеп язуны күзәтү дигән сүз.

Ул фонетикага каршы куелмый, ул мәҗбүри, чарасыз кирәк булган бер нәрсә. Ул әлифбадан соң грамотага өйрәтүнең дәвамы гына. Шунсыз чынлап укымышлы, мәдәни кеше булырга мөмкин түгел. Имля кагыйдәләре – гамәли язуны массага якын итәр өчен, аны укынаклы, аңлаешлы (рациональ) эзгә салу өчен, фәнгә нигезләп, диалектикага муафыйк итеп алынган мәҗбүри нормалар алар. Безнең сүзләрне аерып, җиткереп әйткәнчә язуыбыз, кушма сүзләрне сызык аркылы язуыбыз, төп сүзне үзгәртмәвебез, җанлы кушымчаларда берлек күзәтүебез – бары да шушы морфология нигезенә таянып эшләнәләр. Бигрәк тә безнең телебез кебек низамлы, ачык ялганмалы телләр өчен бу нигез табигый, кирәкле һәм файдалы, имляның нәрсә икәнен белмәгән бер заманда ук бабаларыбызның (артык булмаса да) сүзләрне аерып, сүз кисәкләрен бер төсле итеп язулары моңа бер дәлил булырга ярый торгандыр.

Бездә «черек морфология нигезен җуеп, мәңге баш күтәрмәслек итеп күмеп, йөз проценты белән фонетика нигизенә салу кирәк» дип әйтүгә чаклы көче җиткән кешеләр табылса да, Европа теле галимнәре, юлбашчы әсәрләр биргән авторитетлар арасыннан берәүнең генә дә моңа батырлыгы барып җиткәнен ишеткәнебез юк. Киресенчә, алардан башкачарак акыл өйрәнәбез. Мәсәлән, профессор Томсон болай ди:

«Так как в звуковом языке представителями отдельных значений являются так же морфологические принадлежности слов, то для ассоциации письма с семантическими единицами речи и значениями их **крайне выгодно**[1], чтобы каждой отдельной морфологической принадлежности разных слов соответствовал по возможности отдельный, всегда одинаковый комплекс букв...»[2].

Болар бары да чит телләргә карап әйтелгән, безнең төрек халыклары өчен алар ярамый, дияр идек, аңа да юл юк. Чөнки төрек телләрен үзебездән артык белгән тюрколог галимнәрнең юлбашчылыгы белән үткәрелгән беренче тюркология съездының – «төрк телләренең имлялары морфология нигезе белән яраклашкан фонетикага нигезләнергә тиеш» дигән ачык карары бар. Моның белән дә хисаплашырга кирәк була.

* * *

Саф фонетик язу белән әдәби тел икәве берләшә алмыйлар. Әдәби тел – туган, якын сөйләшләрнең барын бергә җыя торган, барына да уртак булган тел. Ул тарихи, иҗтимагый традиция белән, тормышның үз кушуы белән килеп чыккан язу, имля, әдәбият аркылы мәдәни күтәрелү

[1] Бу сүзләрнең хәрефләрен калынайту минеке. – *Г.А.*

[2] *Томсон А.* Введение в общее языковедение.– Одесса, 1910.– С. 419.

аркасында туган була: аның үсәчәк юлын гамәли язу үзе билгеләде. Морфология нигезе, имля кагыйдәләре төрле әйтелешләргә, шивә аермалыкларына чикләр куеп, аны бер эзгә салуга ярдәм итәләр. Язуның оештыручы ролен аңлаган һәр кеше моны төшенергә тиеш. Ишеткәнчә язу, саф фонетика шивәләрне берләштерә алмый, ул аларны аера гына. Чөнки ишеткәнчә яз дигәч, һәркем үз ана телен, үз гаилә, үз авыл телен генә ала, шуны яза, нәтиҗәдә бары да үз-үзенә аерылып, чуалышып бетәргә мәҗбүр була. Бер сыйныфта утырган, төрле җирдән килгән балалар һәрбере үзе ишеткәнчә, биш укытучы үзләре тагы биш төрле язса, болама булачак. Нәтиҗәдә төрле шивәдән җыелган чуар, ботка кебек бер аңлашылмау килеп чыгачак. «Язуда әдәби телгә (фәлән җирнең) әйтешен нигез итәбез» дигән коры сүз белән генә монда канәгатьләнеп калырга ярамый. Ул барыбер кемнәрнедер кагыйдә өйрәнергә мәҗбүр итү дигән сүз. Ул бит, элгәре әдәби булырга дигән телне үз авызыңа күчереп, үзләштереп бетерергә кирәк дигән сүз. Бу мөмкин түгел. Шуңа күрә фонетика дип артыкка китү, әдәби телне үтерү, аны күмеп кую була. Күрәсез, безнең кайбер фонетикачылар: мишәрләр «й» язсын, казанлылар «җ» язсын (*җир, йир, җук, йук, җаз, йаз*... кебек сүзләрдә), һәркем иректе булсын, дип, үзләре үк моңа киң юл куеп торалар[1]. Әдәби тел шулай ясала ди микәнни?!

Мәсьәләгә педагогия ягыннан карап якынлашканда да без шул ук нәтиҗәләргә килеп чыгабыз. Язуда, укуда телне аваз сиземе түгел, мәгънә ассоциациясе белән бергә ныгып, урынлашып калган, карарлашкан шәкелләр роль уйный. Грамотный кеше язуны авазлап, хәрефләп язмый да, укымый да, ул мәгънәле кисәкләрне автомат рәвешендә бертоташ сизеп яза, бертоташ күреп укый. Язучы кул, укучы күз аңлаучы баш әйтергә теләгән мәгънәләрне эзәрлекләп, шуны тәсаувыр итеп бара, ничек сөйләүне, әйтешне ул дикъкатькә алып, сизеп бетерә алмый. Нигә без хата язылган язуларны да, формасы килгән булса, үзебез дә сизмичә, дөресләп укыйбыз? Нигә «латин әлифбасы белән һаман элгәрге имляга, я рус имлясына охшатып язалар» дигән зарлануларны ишетәбез? Чөнки күздә калган, карарлашкан язу рәвеше аваз сиземеннән көчлерәк бер гамил. Ишеткәнчә язу аның мәгънә берлек тойгысына җиңелә. Менә шуның өчен мәгънәләре бер булган элементларның, морфология нигезе буенча, бер төсле язылуы уку, язу тизлегенә бик зур ярдәм итә.

Әлифба өйрәткәндә, иң авыр авазларны аерырга өйрәтеп тә, иң уңай, иң кирәкле булган сүзләрне, төп сүз, кушымчаны аерырга өйрәтмәү, ул надан калдыру, тел бозарга юл кую гына була. Грамота өйрәткәндә без, уку, язу техникасы белән бергә, иң әһәмиятле булган аңлап уку, аңлап язуга да дикъкать итәргә, өйрәтергә мәҗбүрбез. Үткән тел, әдәбият укытучыларының конференциясендә, әлифба өйрәткәндә

[1] «Яңалиф» журналы (саны күрсәтелмәгән), Хәсән Гали мәкаләсеннән.

телебезнең ялганмалык табигатеннән бик нык файдаланырга тиешлеге әйтеп кителгәнен дә онытмаска кирәк. Аваз аерып язу, хәрефләп уку ул вакытлы, үткенче бернәрсә, ул югары автомат рәвештә мәгънә укуга илтә торган васита гына. Алифбадан, мәктәптән югары яккарак карый белергә вакыт инде.

Җиңеллек, тизлек, 2–3 айда селькорлар (хәбәрчеләр.– *А.Ш.*), язучылар чыгару дигән нәрсә шулай ук ялган бер хыял, үз-үзеңне алдау гына. Педагогия шартсыз-нисез җиңел дигән теләкне генә күзәтми, файдалы булу ягын да карарга кирәк. Ысул саутия белән хәреф таныту җиңел булса да, ул ярым грамота, беренче адым гына; икенче адымга киткәч, аның чие чыга башлый: аңларга, аерырга, белеп эшләргә өйрәтү җитмәгән булып кала. Бу якта «фәлән халык сөйләгәнчә яз» дип өйрәтү урынына «фәләнчә яз» дип күрсәтү конкретрак, уңайрак икәне күренә. Нигә соң мәдәниятtә, гыйлемдә иң алдагы америкалылар, европалылар үзләренең сөекле балаларына уку-язуны тиз өйрәтергә ашыкмыйлар? Чөнки алар аңламыйча, машина кебек укуга караганда, аңлап уку, төшенү ягына күбрәк әһәмият бирәләр. Шуңа күрә алар мәдәни булып җитешәләр дә. Алар язучы, хәбәрчеләр чыгару өчен аваз өйрәтү генә җитмәгәнлеген, байтак белем, байтак тәрбия, аң, дикъкать кирәклеген беләләр шул.

* * *

СССРның авторитетлы зур тел галиме профессор Щерба әйтә: «Гамәли язуда фонетика нигезе башка нигезләр белән катлауланырга мәҗбүр була. Язуда саф фонетикадан идеальный җиңеллек эзләү хата, ул мираж гына, анда ниндидер начарлык яшеренгән, сарфи нигез уйларга, уйланырга өйрәтә, телне аңлап, белеп язуга алып бара. Мәктәп тормышка әзерләргә тиеш, тормышта уйсыз бер нәрсә дә эшләнми.

«Саф фонетика аз төркем халыкка гына ярый. Ул да башта гына, соңыннан ул авырга килә. Ул уйландырмый, баш эшләтүгә каршы, уйсыз машиналар гына чыгара. Аннан язучы, телче чыкмый. Шуңа күрә саф фонетика дию үз-үзеңне алдау, арзан товар, демагогия генә, ул иренчәкләргә генә бара.

Тел – фикер тәгъбирчесе, фикер тәгъбирен күзәтү мөһим. Морфология нигезе шуңа юнәлтә, ул тел өстендә азрак тукталуга, уйлануга сәбәп, ул күзәтүчән, дикъкатьле мәдәни кеше җитештерә.

Саф фонетик язу һич вакытта да әдәби тел була алмый. Ул сөйләүгә, әйтүгә, әгъза хәрәкәтләренә дикъкать сорый. Сарфи төзелеше, кушымчалары ачык, низамлы телләр өчен сарфи нигез файдалы». (Профессор Щерба лекциясеннән).

Шундый ук фикерләрне без профессор Томсоннан да ишетәбез. Ул болай ди:

«Фонетик язу гомуми халык имлясы өчен кирәк тә түгел, уңай да түгел. Ул бер шивәне генә терки, башкаларны авырлаштыра. Һәр грамотный кеше уртак шивәне үзләштереп бетерә алмый, бу авыр эш.

Морфологиягә нигезләнгән язуны башлап өйрәнү авыр кебек булса да, соңыннан ул фонетик язуга караганда, әллә ничаклы җиңел (гораздо легче) була. Чөнки анда сарфи элементлар үскән була. Кулны автомат йөртүгә, үзләштерүгә уңайрак була. Сүз төрләнгәндә кисәкләрне төрлечә язуга караганда, бер төсле язу тизгәрәк килә. Грамоталы уку, язу өчен (аның кирәге дә шуның өчен бит) фонетик язу авырлыктан башка бер файда да китерми»[1].

* * *

Читләргә тел өйрәткәндә, тагы фонетик язуның әһәмияте чамалы, киресенчә, грамматик җиткереп язу уңайрак, тел белмәгән берәүгә «ишетелгәнчә язу» диясе урынга, «бу мәгънәне белдергән кисәкләр һәр вакыт болай языла» дип күрсәтү аңа аңлаешлырак. Әйтү, ишетелүне ул тормышта әкренләп өйрәнә. Аны өйрәнеп беткәнче язмый тора алмый ич ул. Русча дөрес яза белгән татарларның күпмесе генә дөрес әйтә белә икән? «Ишетелгәнчә яз» дип кенә өйрәткән булсалар, кайсыбыз русча дөрес язарга өйрәнә алыр идек икән? Хәсән Гали әйткәнчә: «рус студентына өйрәткәндә аптырап бетәбез. Нигә болай, әйтелгәнчә язылмый дисә, дәлилебез юк» дию – чепуха, әкият кенә ул. Рус үзе нигә ишетелгәнчә язмый соң? Рус, нимес, французларның берсендә дә фонетикага муафыйк язу юк. Инглиз, америкалыларның язуы фонетиканың «ф»сына да туры килми. «Язмаганны таз укыр» дигән кебек, бөтенләй язылганның киресен укып йөриләр, ләкин боларның берәрсеннән:

– Имлябыз телебезне боза... дигән зар елау ишетелгәне бармы?

Шуны да әйтеп китәргә кирәк, теләсә нинди имляның массалашып, карарлашып китүе аның кагыйдәсез, чыгымтасыз булуына түгел, иҗтимагый, икътисади сәбәпләргә бәйләнгән. Халыкның мәдәни дәрәҗәсе күтәрелү белән үлчәнә торган нәрсә ул, моңа еллар, чыдам кирәк.Шунсыз бер имля да карарлашачак та, канәгатьләндерәчәк тә түгел.

* * *

Озын сүзнең кыскасы, имля мәсьәләсен бер катлы карашлар белән генә хәл итәргә мөмкин түгел. Телдә абсолют бер закон гына хөкем сөрми. Телгә муафыйк язу тел кебек үк комбинацияле булмый чарасы юк. Гамәли язуда «йөз процент фонетика» я фарология (морфология булырга тиештер.– *А.Ш.*) дип кырт кисү үзе телгә җинаять, массага хыянәт булачак. Морфология нигезе дә телдә ачык сизелгән җанлы

[1] *Томсон А.* Введение в общее языкознание. – С. 424.

кисәкләрдән еракка китә алмый. Шуның өчен боларның икәвен дә үлчәп, рациональ, мантыйклы бер юл табарга тиеш булабыз. Агитация, дулату, кул күтәртүләр белән генә боларга ирешеп булмас. Көч берләштереп, киңәшеп, коллектив уй, салкын кан белән эш иткәндә генә туры юл таба алырбыз, дип беләм.

Мин монда гамәли имляның нигезләре белән таныштыруны гына максат итеп алганлыгымнан, аның кагыйдәләре, аерым матдәләре турында конкрет тәкъдимләр ясамадым. Кирәк булганда, ул турыларда киләчәктә язармын.

# ТАТАР ГРАМАТИКАСЫ ТУРЫНДАГЫ ТӘНКЫЙТЬЛӘРГӘ ҖАВАП[1]

«Шәкли нигездә татар граматикасы»ның 2 нче басмасы чыкканга да байтак вакытлар үтеп китсә дә, ни сәбәптәндер, Хуҗа Бәдигый иптәш әйткәнчә, «мәсьәлә артык яңа булгангамы, кирәк телебезнең формаль грамматикасын тикшерү юлында булсын, кирәк Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» турында булсын, матбугатта әле үзара фикер алышулар, бу юлдагы тәҗрибәләрне уртаклашулар күренми» иде. Чөнки озак тикшерүләр нәтиҗәсендә килеп чыккан яңа бер гыйльми хезмәтнең тиз генә популярлашып китүе мөмкин түгел. Моның өчен байтак эзләнергә, тикшеренергә, уйланырга туры киләчәк иде.

Ниһаять, шәкли грамматика мәсьәләсе, тел, әдәбият конференциясендә каралып, мәктәпләрендә, эш өстендә тәҗрибә ителеп үткәннән соң, тел тикшерүче иптәшләр кузгала башлады. Берсе артыннан берсе «Мәгариф» журналында «Татар граматикасы»на, шәкли методка карашларын язып, тәҗрибәләрен уртаклаша башладылар. Ничә ел көтеп алынган бу тәнкыйтьләрне мин бик зур дикъкать белән укып, тикшереп барам. Бу тәнкыйтьләрдә, чынлап та, дикъкать ителергә тиешле булган мәсьәләне аңлап туры әйтелгән фикерләр булган кебек, мәсьәләне төшенеп җитмәгәнлектән, элгәреге традицияләрдән котылып бетә алмаудан килеп чыккан хата карашлар да бар. Кайбер мәсьәләнең канәгатьләнерлек дәрәҗәдә чишелеп бетмәве нигез мәсьәләләр, принциплар ачылып җитмәүдән, гомумән телебезнең методологиясе эшләнмәүдән килеп чыкканлыгын аңларга кирәк. Моның өчен әллә ни кадәр хезмәтләр, тәҗрибә өстенә тәҗрибәләр кирәк булачак әле. Шуңа күрә, бердән, мәсьәләнең яңалыгы, икенчедән, китапның кыска бер конспект итеп кенә язылган булуы сәбәпле, тәнкыйтьче иптәшләрнең башкалар тәэсиренә бирелүе, ялгыш карашларга төшеп китүе, әлбәттә, гаҗәп түгел иде.

Бу хәлләр миңа, тәнкыйтьләргә җавап бирү белән бергә, нигез мәсьәләләргә дә артык җәелеп китәргә журнал битләре тар булганлыктан, икенчедән, нигез мәсьәләләр турында быел татар педагогия җәмгыятенең башлавы белән 5–7 октябрьдә татар мәдәнияте йортында ясалып үткән докладлар, дискуссияләр татар педагогия җәмгыяте тарафыннан аерым бер китап рәвешендә басылып чыгарылачак бул-

[1] Мәгариф. – 1928. – № 11. – 70–76 б.

ганлыктан, монда мин җавапларны бик кыскартырга мәҗбүр булдым. Мондагы җаваплар белән канәгатьләнмәгән иптәшләрнең шушы әйтелгән «Шәкли грамматика нигезләре» турындагы аерым китапка мөрәҗәгать итүләрен сорыйм.

### Башлыйк телебезнең тышкы фактларыннан

Бу мәсьәлә тоташы белән яңа, әлегә кадәр грамматикаларыбызда тикшерелмәгән бер нәрсә иде. Шуңа күрә телебезнең тышкы фактларын билгеләү мәсьәләсендә, бердән, тәнкыйтьче иптәшләр бик аз катнашсалар, икенчедән, күбрәк хата фикерләр бәян иттеләр.

Тышкы фактлардан «ялганмалык» дип йөртелгән нәрсәне «кушымчалар» дип алу фәкать атама мәсьәләсе генә булып, аның нигез мәсьәләне аңлауга бер төрле дә зарары булмаганга күрә, ул мәсьәләгә тукталып тормыйм. Бу яктан караганда бәлки «сингармонизм» дигән атаманы да «калынлык – нечкәлек» дип алу ачыграк булыр.

Бәдигый иптәшнең «кабатлау» белән «тәртип»не грамматикада тышкы факт – шәкел итеп алуга караганда, өслүбкә калдыру артыграк булыр иде», дигән фикере хата.

«Татар грамматикасы»ндагы кабатлауны өслүптәге «тәкрар» белән саташтырырга ярамый. Алар икәве бер-береннән шәкли дә, мәгънәви дә бик нык аерылып торган нәрсәләр. «Кабатлау» монда яңа мәгънә, яңа бер төр ясаучы тышкы бер факт булу ягыннан карап алына. Ул телебездә бер сүзне бары ике мәртәбә кабатлап әйтү төрендә генә килә. Өслүбтәге тәкрар бөтенләй башка нәрсә, ул яңа мәгънә ясамый, бер мәгънәне көчәйтү өчен генә һәм ике мәртәбә генә түгел, күбрәк тә әйтелә ала. Кабатлау төрендә ике арага башка сүз кертеп әйтү теләнгән мәгънәне боза. Тәкрарда исә арага башка сүз керүдән мәгънәгә зарар килми.

Мәсәлән, *килә* сүзе хәзерге заман фигыле иде. *Килә-килә* дигәч, ул мәгънәсен югалтып, дәвамлы хәл фигыль (рәвеш) булып китте. Әмма *сызла* сүзен *сызла, сызла, сызла* дип ничә кабат тәкрар итсәк тә, сызла күңелем, сызла дип арага башка сүз кертеп әйтсәң дә мәгънә үзгәрми.

Менә шуның өчен телебездә бер сүздән икенче сүз, бер төрдән икенче төр ясаучы бер шәкел булуын карап, кушымчалар рәтендә икенче катлы, рәвеш ясаучы «кабатлау» төрләрен дә тышкы бер факт итеп санарга, бер шәкел итеп алырга тиеш булабыз (боларны өслүбтәге тәкрар белән саташтырмас өчен, «куш сүз», «янәшәлек» атамасы белән йөртергә дә мөмкин).

«Тәртип»нең «Татар грамматикасы»нда ни мәгънә белән шәкел ителеп алынуы да аерып, ачык итеп күрсәтелгән иде. Ул монда, кайбер җөмлә кисәкләренең башка төрләр белән күрсәтелмәгән чагында, үзенең нинди кисәк булуын җөмләдә торган урыны белән күрсәтүе, кайда килүенә

карап үз төрен билгеләве мәгънәсендә аңланырга тиеш иде. Мондый мәгълүм бер җөмләнең сүзләре катыш урынлашкан бер тәртиптә генә килә, башкача һич тә килә алмый, дигән тупас бер мәгънәдә аңларга ярамый. Телебезнең гомуми нигез табигате буенча, гадәттә башкарылган сүз башкаручыдан алда килә һәм бәйләнү, башкарылу көчләренә, дәрәҗәләренә карап, якын да, еракка таба да бер тәртиптә тезелеп киләләр дигән бер канун бар. Фикер мәркәзенең үзгәрүе, теләнгән мәгънәнең әһәмияте алмашуына карап, җөмлә кисәкләре шул әйтелгән канун буенча урыннарын алмаштырып тезелергә мәҗбүр булалар. Шул мәгънә белән җөмлә кисәкләре мәгълүм бер фикерне аңлату өчен гадәт булып урнашкан мәгълүм бер тәртиптә тезелеп килергә тиеш булалар. Шул мәгънә белән «тәртип» фикер тәгъбиренең тышкы бер формасы, шәкеле булып чыга. Тәртипнең мәгънә үзгәртү өчен кирәге булмаса, ялгыз башка шәкелләр генә җитә торган булса, җөмлә кисәкләрендә теләсә нинди тәртип аермасыз булыр иде. Хәлбуки факт алай түгел. Мәсәлән, *ана бала ярата* дигәндә, яратучы (ия) кемдә яратылган объект (төшем) нәрсә? Әлбәттә, *ана* – ия, *бала* – төшем тәмамлыгы диячәкбез. Боларның урыннарын алмаштырып *бала ана ярата* дигән булсак, *бала* – ия, *ана* – төшем тәмамлыгы дияр идек. Моны кайдан белдек? Кушымчадан, басымнан я башка бер билгедәнме? Юк, әлбәттә тәртиптән. Ул сүзләрнең, кисәкләрнең урыныннан белдек. Әмма *ярата бала ана* дигән тезмәдән без бер нәрсә дә аңлый алмыйбыз. Ул безнең карашыбызда мәгънәсез бер сүз тезмәсе генә. Чөнки бу төрле тәртип бездә гадәт булып урнашкан күренеш түгел.

Димәк, тәртип безнең телебездә бар. Ул фикер тәгъбиренең бер формасы булып йөри. Шулай булгач, без аны чын мәгънәсе белән аңлаганда, грамматикаларыбызда тышкы бер факт, шәкел итеп санамый калдыра алмыйбыз. Бәдигый иптәш башта аны өслүбкә калдырырга димләсә дә, мәкаләсенең азагында: «монда мин грамматикада «ялганмалык» һәм «тәртип»не бөтенләй төшереп калдырырга дигән фикерне аңлатырга теләмим», дип баштагы фикереннән кире кайтырга мәҗбүр булган.

Басым белән сингармонизмның да безнең телебездә шәкел булуы ягыннан әһәмиятләре аз түгел. Күп иҗекле авазлаш сүзләрнең исемме, фигыльме икәнен без аларның фәкать басымнарына карап аера алабыз. Мәсәлән, «алма, батыр, каптырма, алмасын» кебек сүзләрдә басым беренче иҗектә әйтелгән булса – аларны фигыль дип, басым азакта булса – исем дип беләбез. Басым бер тышкы тәгъбир васитасы булмаса, без аларны аерып таный алмас идек. Сингармонизм грамматикада безгә бер сүзне икенче сүздән аерып белүгә, кушымчаны төп кисәктән аерып тануга, ярдәмлек белән кушымчаларны бер-бере белән бутамаска ярдәм итә. Шул ягы белән ул грамматикада тышкы бер шәкел ролен уйный. Аларның телебездә аз я күп урында эшкә яравы, күпме җирдә

шәкел булып йөрүе башка бер мәсьәлә. Хуҗа Бәдигый иптәшнең: «җөмлә төзелешендә бердәнбер бер тышкы факт (?), шәкел булган «ярашу»ны, ни өчендер, төшереп калдырган», дигән фикере дә урынсыз, бер хата булып чыккан:

1) «ярашу» сүзе «ялгау» кебек гам бер атама. Монда да грамматика хадисәләрендә шәкел итеп «ярашу» ның үзен атау белән аннан туган кушымча, тәртип...ләрне атауда зур аерма бар дияргә була.

2) Бәдигый иптәш үзе дә: «ярашу» дип мин монда җөмлә эченә кергән сүзләрнең нинди юл белән булса да, үзара теркәлүләрен – бәйләнүләрен атыйм» дип тора. «Татар грамматикасы»нда ул урында шушы «бәйләнү – бәйләнеш» дигән атама йөртелгәнгә күрә «төшереп калдырган» дип әйтергә юл юк.

3) «ярашу» – бәйләнү (башкару, ияру кебек) эчке мәгънә ягыннан чыгып әйтелгән сүзләр. Алар бар телдә дә табыла торган хәлләр. Безгә шәкли грамматикада аларның үз телебезгә хас булган нинди тышкы төрләр белән ничек күрсәтелүе генә кирәк. «Татар грамматикасы»нда бәйләнүнең нинди шәкелләр белән күрсәтелүе ачык әйтелгән (124–126 битләр). Бәдигый иптәш аларны бәйләнү (үзенчә «ярашу») нең тышкы төрләре дип танымаган ахыры.

4) «ярашу» сүзен ия белән хәбәрнең үзара бәйләнү төрләренә атама итеп алу уңышлырак. Китапта ул шул урында йөртелгән.

5) Мәгънәви бәйләнешне аңлаткан «ярашу»ны, рус грамматикаларына ияреп, һаман да мәгънәви булган «ияручелек» – управление (башкарылу) һәм «янәшәлек» – примыкание (теркәлү) дигән ике төргә бүлеп алу белән дә мәсьәлә үзгәрми. Чөнки болар үзләре төбендә барыбер әлеге кушымчалар, ярдәмлекләр һәм тәртип белән тәгъбир итүгә килеп терәләләр. Нәтиҗә һаман да «Татар грамматикасы» нда әйтелгән шәкелләргә кайтып кала. Шуңа күрә бу турыдагы сүзләр «ләфыз бәхәсе» генә булып чыга.

## Фонетика бүлеге турында

Эксперименталь фонетика үзенә бер фән төсенә кереп барган гыйлем булганлыктан, гомуми грамматикаларда фонетиканың эксперименталь була алмавы, булырга да тиеш түгеллеге әһленә мәгълүм бер мәсьәлә. Татар грамматикасының фонетика бүлегендә мин әлегә кадәр бездә ачылып бетмәгән байтак яңа фикерләр ташлаган идем. Мәсәлән, сингармонизмны тел галимнәренең гармония звуков в прогрессивном порядке дип аңлатуы, «ا – ۇ» авазларының иренләштерү табигатьләре, иҗек кануннары, бу турыларда яңа схемалар һәм башкалар минем карамагымда гыйльми әһәмиятле яңа нәрсәләр иде. Фонетика бүлегенең беренче басмада кай урынга кертелүенә хәтле әйтеп киткәндә, бу мәсьәләләргә өстән генә карап узуның хикмәте аңлашылмый.

Фазыл Туйкә иптәш: безнең телебездә («ۋ» авазын да кушып санаганда) барлыгы 31 аваз бар ди. Шулар җөмләсенә ул калынлы-нечкәле «ق, ع, ک, گ» авазларын дүртәвен дә кертеп исәпли. Мин грамматикада авазларны калын-нечкәгә аермыйча, икәвен бергә исәпләп алганмын. Чөнки бездә башка авазларның калын-нечкәләре бар. Аларның барын да аерып исәпләгәндә бездә 31 генә түгел, барлыгы 55 аваз булырга туры килә (сузык «ې» авазының калыны юк дип игътибар итәбез). Авазларның чыганаклары белән таныштырганда 32 аваз алып күрсәтүем аларның кайдан, ни урыннан, ничек әйтелеп чыгуларын күзәттерү өчен генә эшләнгән иде. Ялгыз «ه» («ә») кушып карау гына авазларның аерым аваз булуын лязим итми. «ص, ط» авазларына да «ه» кушып карап була ич. Мин авазларны билгеләгәндә, аларның тел сиземендә бар булган мөстәкыйль фонемалар булуына, морфологиябездәге берлек табигатенә карап алдым.

## Морфология элементлары һәм кушымчалар

Сүзләрнең морфология элементларын билгеләүдә мин сингармонизм табигатеннән файдаланып эш итәм һәм төркемләүдә гомумән дедукция юлын тотам. Икенче төрле әйткәндә, иң элгәре уртак табигате булган нәрсәләр бер төркемгә кертеп исемләнәләр дә, аннары, үз эчләрендәге аерымлыкларына карап, вак төркемчәгә бүленәләр. Сүз төркемнәрендә дә, фигыль төркемчәләрен билгеләгәндә дә без шушы урыннан вакка таба бару юлын тотабыз.

Шул ысул белән эш иткәндә безгә калынлык-нечкәлек тә төп кисәккә ияреп, аның артыннан ялганып йөргән бөтен вак кисәкләрне элгәре «кушымчалар» дигән бер төркемгә аерып алырга туры килә. Моның эченә ясаучы, төрләүче, өстәмә кушымчалар – бары да керә. Чөнки алар бары да шул сыйфатларда уртаклар. Соңыннан, төп кисәккә нинди тәртиптә кушылу ягыннан карап тикшергәндә генә, болар үзләренә аерым төркемчәләр булып чыгалар. Өстәмә кушымчалар шунда килеп аерылалар. Бәдигый иптәш өстәмә кушымчаларны төп кисәкләр белән беррәттән башта ук үзенә аерым бер элемент итеп аеру тарафында. Ул, өстәмәләрне тышкы фактлар ягыннан да, морфология функцияләре ягыннан да башкалардан бик нык аерылалар, ди. Әлбәттә, шул аерылган өчен дә алар татар грамматикасында үзләренә башка бер исем белән, үзләренә бер төркемчә итеп алынганнар инде. Аларны ялгыз басым үткәрмәүләренә карап аерганда, *ма-мә, дай-дәй, ча-чә* ләрне дә «من (*мын-мен*), بز (*быз-без*), سڭ (*сың-сең*), سز (*сыз-сез*)» кебек кисәкләрне дә шулардан санарга, кушымчалар дип танымаска туры килер иде. Бу мөмкин түгел. Шуңа күрә мин сүз элементларын билгеләгәндә, һичкемгә иярмәстән, саф үз телебезнең табигатенә карап дедукция юлы белән төркемләүне фәннирәк дип беләм.

Ясаучы, төрләүче кушымчаларны билгеләгәндә дә, аларның табигатен һәр яктан карап, ныклап, озак тикшереп эшләнгән иде. Ясаучы кушымчалар монда шартлы бер мәгънәдә, нигез ясаучы кушымчалар мәгънәсендә алыналар. Аңа саф сүз ясаучылар да дәрәҗә (баб, иркәлек, артыклык, кимлек) ясаучылар да керә. Дәрәҗә ясаучы кушымчаларны төрлекләр белән бергә кушып йөртү мөмкин түгел, аларның ясаучылар кебек, җанлылары булган кебек җансыз (сирәк сүздә йөргән) лары да бар. Төрлекләре белән исә алар телебездәге иң җанлы, иң ачык беленеп торган кушымчалар. Дәрәҗәлекләрнең ясаучылар белән бергә кушылганнары, яки берәрсе ике функцияне үтәгәннәре дә бар. Бу хәлләр аларны икәвен бер төркемдә күрсәтүгә, бергә йөртүгә мәҗбүр итә. Аннары ясаучылар белән дәрәҗәлекләрне түбән сыйныфларда укытмый узганда да зарар юк. Аларның җөмлә аертуга, грамматика үтүгә катнашлары бик аз һәм аерту, өйрәтү өчен авыр нәрсәләр. Төрлекләрне исә түбән сыйныфларда ук өйрәтеп, аертып йөртмичә мөмкин түгел. Аларны өйрәнү дә уңайлы. Аннары тел галимнәренең аваздан дәрәҗәлек кушымчалары ясаучы (словообразовательный) төрләрдән санап йөртүләрен дә игътибарга алырга кирәк.

Кыскасы, дәрәҗәлекләрне саф ясаучылардан башта ук аермыйча, алар белән бергә йөртү мәҗбүри һәм табигый килеп чыккан нәрсә ул. Аларны телебездәге иң җанлы төрлек кушымчалары арасында күрсәтү үзе мәсьәләне чуалтуга, авырлаштыруга сәбәп. Шуның белән бергә грамматиканың эше азмы-күпме гамьрәк булган җанлы кушымчаларны гына тикшерү булганлыктан, мин сирәк сүзләрдәге төрләрне искәрмә астында мисаллар белән генә күрсәтеп киттем. Аларны тикшерү этимология һәм лөгать эше.

Фигыль дәрәҗәләре (баблар) арасында кабатлык, сирәклек төрләре булган *галә*, شدر (*ышдыр-ешдер*) кебекләрне бер рәттән күрсәтү – бердән, аларның төркемнәрен күбәйтмәү, уңайлык өчен эшләнгән; икенчедән, аларның баб кушымчаларыннан алда, алар белән аралашып килүләре (мәсәлән, *угалану, кискәләнү* ... кебек) игътибарга алынган иде. Шуңа күрә монда «фигыль дәрәҗәләре» дигәнне шартлы рәвештә *ма-мә* гә кадәр булган бөтен кушымчалар дип аңларга була.

Сүз төрләүче кушымчаларны иреклe, ирексез килеп кушылуларына карап, «сарыф – нәху» дигән төркемчәләргә аерып йөртүнең шәкли яктан әһәмияте бик аз, мин аны беренче басмада тәҗрибә итеп караган идем. Алай булу кушымча тәртипләрен үзара чуалтуга сәбәп була. Мәгънә ягыннан караганда, аларның кайбер сарфый дигәннәре дә нәху булып чыга. Мәсәлән, баблар, ясаучыларны, мәгълүм тәмамлык теләүләренә карап, нәху дип әйтергә мөмкин. Заман кушымчалары да ирексез килеп кушылалар. Мәсәлән: *кичә ул килер, мин иртәгә килдем* дип булмый. Шәкли яктан карап төркемләгәндә, аларны ятык сызык буенча бары фигыль һәм исем төрлекләре дигән ике төркемгә текә (үрә) сызык буенча (тәртипләренә карап) һәр берен өчәр рәткә бүләргә генә туры килә.

Фигыль төрлекләренә «*ма-мә*, заман һәм хәбәрлекләр», исем төрлекләренә «*лар-ләр*, тартымнар һәм килешләр» керә. Килеш кушымчалары арасында *ча-чә, дай-дәй* төрләрен күрсәтү аларның башка килешләр кебек пассив (ирексез) булуына һәм башкалар кебек үк, шул ук тәртиптә исемнәргә кушылучы булуларына карап эшләнгән иде. Аларны ясаучы кушымчалардан санап йөртү дә мәсьәләләрне чуалтачак. Аннары килешләрнең һәрберсе исемнәрне фигыльгә бәйләү хезмәтен генә үтәве лязим нәрсә түгел. Ул вакыт *ның* кушымчасын да килешләр арасына күрсәтмәскә туры килер иде. Чөнки ул да исемнәрне исемнәргә бәйләүгә хезмәт итә ич. Дөрес, бу кушымчаларның тегеләрдән аермасы бар (килешләр бары да бер-берсеннән үзенә махсус табигатьләре белән аерылалар). Болар фигыльләргә бәйләнгән кебек исемнәргә дә бәйләнәләр. Ләкин аларның фигыльгә бәйләнүләре күбрәк. *Үзбәкчә китап* дияргә булса, *урысча өстәл, татарча кәтлит, суп по-польски* кебек төрләребездә килә алмый (*үзбәкчә китапта* төбендә *үзбәкчә язылган китап* булып чыга).

Һәрхәлдә бу *ча-чә, да-дәй* кушымчалары тегеләй дә, болай да куллана торган ике аралыктагы үзенә башкарак төрлекләр. Андый төрләрне, шартлы рәвештә, искәрмә белән күпчелек якларына кертеп йөртүдән башка чара юк. Татар грамматикасына ул шулай кертелгән дә. Аннары «бездә килешләр янәшә килә алмый» дигән канун да гам түгел. Баблар янәшә килгән кебек, алар да кайвакыт янәшә килергә мөмкин. Мәсәлән, «ашарганы белә, эшләргәне белми, юлдасын юлда ла. Күңеле уендага күрә, сабагын белми. Үзе өйдәнең эше рәтле ...» кебекләр телебездә очрый.

Казак теленең грамматикасын язучы, профессор Мелиоранский да *ча-чә, дай-дәй* төрләрен килешләрдән санаган. Тюрколог профессор А.Н. Самойлович та бу кушымчаларны аралык төрләрдән саный: «Алар турында төрек телләрен тикшерүчеләр арасында төрле карашлар бар. Аларны искәрмә белән кайда керткәндә дә зарар юк», ди. Менә бу фикерләргә дә игътибар итсәк, бу кушымчаларның килешләр арасында күрсәтелүләренә, аларның анда ипләнеп бетмәүләренә гаҗәпләнергә бер дә урын калмый.

# «ТАТАР ГРАММАТИКАСЫ» ТУРЫНДАГЫ ТӘНКЫЙТЬЛӘРГӘ ҖАВАП[1]

## Сүз төркемнәре турында

Сүзләрне төркемнәргә аеру эше бик катлаулы, авыр бер мәсьәлә. Бу мәсьәлә русларда да әле өзелеп бетмәгән. Сүз төркемләүдән максат – телдә азмы-күпме уртак табигатьләре, уртак төрләнешләре, үзенә башка бер төрлерәк кулланылулары булган категорияләрне аерып белү. Сүзләрне төркемләүдә без аларның нинди кушымчалар белән төрләнүләренә генә түгел, кирәк булган урыннарда башка шәкелләргә дә игътибар итәргә, сүзләрне ялгыз, аерым хәлләрендә генә түгел, башка сүзләр белән бергә бәйләнешле итеп әйтелгән хәлендә алып карарга тиеш булабыз.

Башка сүзләрне төрләнүче, төрләнмәүче дип караганда, төрләнүче сүзләрне исем, фигыльгә аерганда, әлбәттә, төрләүче кушымчаларга карап эш итәбез. Шулар өстәвенә күп иҗекле сүзләрнең исемме икәнен басымнарына карап та аера алабыз. Фигыльләрдә характерлы билге итеп иң гам булган «заман» кушымчаларын, исемнәрдә «килеш» кушымчаларын йөртергә кирәк була. (*ма-мә* кушымчаларын фигыльләргә хас билге итеп алу ярамаганлыгын мин тел, әдәбият конференциясендәге докладымда да әйткән идем.)

Фигыльләрне үзара төркемчәләргә бүлгәндә, аларның шушы «заман» төрлекләре хәбәрлек (нисбәт) төрләренә нинди мөнәсәбәттә булуларына карап бүләбез («заман» сүзе монда шартлы мәгънәдә, дүртенче рәттәге фигыль кушымчалары дип кенә аңланырга тиеш). Һәрвакыт заман белән хәбәрлек кушымчасы бергә килә торган фигыльләр саф фигыльләр (хәбәр фигыльләре) була. Болар һич вакытта да хәл яки аергыч булып килмиләр. Хәбәрлек (нисбәт) кушымчаларын бервакытта да алмый торган фигыльләр хәл фигыльләр була. Кайвакыт хәбәрлек ала, кайвакыт алмый торган (исем яки аергыч булып та килә ала торган) фигыльләрне исем фигыльләр дип аерабыз. Шулай итеп шәкли яктан фигыльләр өч төркемгә бүленгән булып чыга.

Саф фигыльләрне үз эчләрендә тагы бер кабат шәкли яктан төркемчәгә аеруга юл юк. Алар турыдан-туры боерык, шарт, үткән, хәзер дигән

[1] Мәгариф. – 1929. – № 1. – 94–99 б.

төрләргә генә аерылалар. Үткән белән хәзерге заман (вакыт) фигыльләрне үзләренә бер төркем – хәбәр фигыльләре итеп йөртү рус телендәге наклонениягә ияреп эш итү генә булыр иде. Хәбәрлек (нисбәт) төрләренә караганда, киресенчә, бездә шарт белән үткән фигыль бер-берсенә охшыйлар. Хәзерге заман фигыльләр нисбәтләренә караганда исем фигыльгә охшасалар да, алар кебек аергыч булып йөри алмыйлар. Кыскасы, безнең телебездә рус телендәге кебек наклонениягә бүленү юк. Моны аңларга кирәк.

Хәл фигыльләре үз эчләрендә вакыт, рәвеш дигән ике төркемчәгә бүленәләр. Боларның мәгънәләрендә дә, шәкелләрендә дә аерма бар. Вакыт фигыльләре «кайчан?» дигән сорауга, рәвеш фигыльләре «ничек?» дигән сорауга җавап булып киләләр. Мәсәлән «кайчан?» – укыгач, укылганчы (басым азакта).

Ничек? – укып, укый-укый, укыганчы (басым башта) хәзерге вакыт фигыле урынына «укыганда, укышлый» төрләре йөри (болар фигыль итеп саналмый). Хәзерге рәвеш фигыле ялгыз хәлендә күбрәк азаккы фигыль белән кушма булып килә (*укы әле, килә төш, егыла яздым* ... кебек). Сирәк аерым кулланyы да бар (*уйламый сөйләшкән, авырмый үләр, озата бардым* ... кебекләр). Югарыда күрсәтелгәнчә кабатлау урынында да килә.

Тәнкыйтьче иптәшләр исем фигыльләр турында күп тукталдылар. Исем фигыльләрне башка фигыльләрдән без аларның җөмлә хәбәре булып (нисбәт булып килә алуларына һәм урыны белән исемнәр алдыннан аергыч булып та, хәтта үзләре исем булып, исем кушымчалары (лар-ләр, тартымнар, килешләр) белән төрләнә алуларына карап аерабыз.

*Ар-әр* фигыльләрен ачак төрендәге исем фигыльләргә искәрмә итеп кенә йөртү мөмкин түгел, алар арасында аерма зур. *Ачак*, шартсыз, катгый фигыль. Ул, аергыч булганда да, киләчәк мәгънәсен аңлата («килер заман» диелми, «киләчәк» диелә).

*Ар-әр* – шартлы, шөбһәле фигыль, ул аергыч булганда хәзерге заман мәгънәсен аңлата – (*агар су, янар тау* диләр, *яначак тау* димиләр. *Килер шәт – килү ихтимал* була, *киләчәк ихтимал* булмый.)

*Учы* төрен исем фигыльгә кертмәү уйлап, нык тикшереп эшләнгән иде.

1. *Учы* төре хәзерге заман исем фигыле түгел. Ул урында бездә кушма төрдәге *ый торган* формасы йөри. Мәсәлән, *баланың укыган китабы, баланың укыячак китабы, баланың укый торган китабы* диләр (*баланың укучы китабы* димиләр).

2. *Учы* төрендә исемлек көчле, ул күберәк «кем?» соравына җавап була. Башкаларда сыйфатлык көчле: алар «нинди?» дигән сорауга җавап булалар. Шуңа күрә *укучы тормышы, язучы каләме (язучының каләме)* дип ияләк аергычы белән теркәп әйтә алсак та, *укыган тормыш, язачак каләм* дип теркәп изах белән әйтү телгә авыр. Аның урынына *укыган кеше тормышы* ... дип әйтү уңай.

3. *Учы* төре хәбәр булганда юклык төрендә *түгел* ярдәмлеге белән әйтелә. Башка фигыльләр *ма-мә* белән киләләр. *Мин укучы түгелмен, мин укымаганмын, мин укымаячакмын* була.

4. *Учы* төре кешегә генә аергыч була ала. Башка сүзләргә аергыч була алмый, *салынучы йорт, авыртучы баш, түгелүче кара* ... дип әйтмиләр.

5. *Учы* ике катлаулы *у+чы* кушымчаларыннан тора. Мондагы «чы», *тимерче, юлчы* сүзләрендәге кебек һөнәр, кәсеп иясенең исемнәрен ясаучы төр генә.

Менә шушы хәлләргә карап *учы* төрен фигыльләр арасында йөртмәскә туры килә. Әмма *асы, макчы* төрләрен искәрмә белән исем фигыльләр арасында йөртергә ярый.

Сирәк булса да, сыйфат (аергыч) булып йөри ала торган килеш төрлекләрен ала алган *ар-әр* төрендәге фигыльләрне саф фигыльләр арасына кертергә һичбер мөмкин түгел. Хәбәр булып килү генә саф фигыль булуга хаклы итми. Исемнәр дә хәбәр булып килә алалар һәм беренче, икенче затка нисбәт белән дә әйтелә алалар (*мин кешемен, син усалсың* ... кебек).

Әшрәф иптәшнең «яңа төрләр кәшеф итүдә сакланырга» димләве мәктәпләр өчен бик яхшы. Ләкин зурлар өчен телебездә нинди сүзләрнең аналогия буенча нинди кушымчалар алуга кабинияте (сәләтлелек, белү) барлыгын, телнең шул юл белән киңәя, байый алуын да истән чыгарырга ярамый. Телнең потенциаль табигате аркасында без октябрь революциясеннән соң гына *укытучы, башкарма, сөземтә, беркетмә, белешмә*... кебек әллә никадәр яңа атамаларга ия булдык түгелме?

Исемнәрне үз эчләреннән вак төркемнәргә бүлү мәсьәләсе байтак катлаулы һәм шартлы бер нәрсә, исемнәр үзара бер-беренә бик якыннар. Аларда аралык хәлләре бик күп очрый. Шуңа күрә монда азмы-күпме гам булган аермалар белән канәгатьләнергә туры килә. Минем фикеремчә, исемнәрне вак төркемнәргә аеруның мәктәпләр, түбән сыйныфлар өчен артык кирәге дә юк. Төп сыйфатлар башка исемнәрдән кып, ап кебек кабатлау кисәкләре, яисә башлаучы (көчәйтүче) ярдәмлекләр һәм азмы-күпме үзләренә махсус ясаучы кушымчалар алу белән аерылсалар да, ясалма сыйфатлар белән исемнәр арасында ул аермалар табылмый. Рак-рәк кушымчаларын сыйфатлык билгесе итеп күрсәтә алмыйбыз, алар исемнәргә дә, рәвешләргә дә, фигыльләргә дә, ярдәмлекләргә дә кушыла ала (*кышырак, языпак, кебегерәк, бигерәк, алыбырак, кызуырак* ... кебек).

Зат исемнәренең *чы, даш, сыз* белән аерылуларын мин аларны күпчелек хәлләренә карап алган идем. Бәдигый иптәш китаптагы күберәк дигән сүзгә игътибар итмәгән икән, ләкин Бәдигый иптәшнең исемнәрне дәрәҗәлек кушымчаларына карап төркемнәргә тырышуы да уңышсыз чыккан. Шуңа күрәдер, ул үзе дә аңа канәгатьләнмәгән, *кабиллек* дигән нәрсәгә таянырга мәҗбүр булган.

Бәдигый иптәш исемнәрне кечерәйтү (*чык-чек*) һәм иркәләү (*кай-кәй*) кушымчаларына карап аерырга тәкъдим итә. Хәлбуки вакыт-урын исемнәре бөтенләй диярлек *чык-чек* алмыйлар (*былтырчык, киччек...* диелми), әмма кайбер фигыльләр моны алалар (*кабарчык, бөркәнчек, өшәнчек, кыелчык, валчык, озынчык...*) шулай ук сыйфатлар, фигыльләр *дә кай-кәй* алалар (*каракай, матуркай, чибәркәй, картай-тукай, йөрүкәйләре...*)

Вакыт-урын сүзләре бездә ялгыз *кыгы* белән генә түгел *н-ән* кушымчаларын алу белән дә аерылалар. Шуңа күрә аларны башта ук исемнәрдән үзенә бер төркем итеп аерырга туры килер. *Кы-гы* кушымчалары фигыльләрдә очраса да бик сирәк, булганнары да үлек, тарихи төрләрдән һәм кайберләренең *гыч-геч* тәреннән үзгәргән булулары билгеле, әмма аларның вакыт-урын сүзләренә кушылулары гам бер күренеш. Исемнәргә алар васита белән генә кушыла алалар.

Аерым сүзләрдә исем, сыйфат билгеләренең бары да табылып бетүе лазым түгел. Минемчә, монда ул кадәр төгәллек, тулылык эзләргә ярамый. Табигый, тарихи, иҗтимагый хадисә булган телдә андый хәлләр күп була, булырга тиеш тә. Алынган шәкелләр җитмәгәндә башка шәкелләргә карап эш итәргә кирәк. Мәсәлән, сыйфатлар төрләнмичә аергыч булып килгәндә, исемнәр күбрәк иялек төрендәге аергыч булып киләләр. Аларның аергыч булып килүләре сирәк. Исемнәр башлаучы (көчәйтүче) ярдәмлекләрне алмыйлар, сыйфатлар алалар. Менә шуларның берсе булмаса берсен яки берничәсен алып һәръягын игътибар итеп карарга тиеш була.

Аннары шуны да әйтеп китәргә кирәк, бер үк сүз урынына, истигъмалына карап, исем дә, сыйфат та, фигыль дә була ала. Шуңа күрә, сүзләрне ялгыз көенчә, бер табышмак итеп түгел, башка сүзләр белән бәйләнешле көенчә, җөмлә эчендә очраганда алып карарга, шул урынында төркемен билгеләргә кирәк була. Мәсәлән, *кузгә ак төшкән* дигәндә *ак* сыйфат түгел, ул зат исеме. *Яшь, ат, кош...* кебек авараздаш сүзләрне дә без шулай бәйләнешле сүз тезмәләре арасында карап бик уңай аера алабыз.

Алмашлыклар башка исемнәрдән үз алларыннан сыйфат алмау белән аерылалар. Болар арасында: зат алмашлары – хәбәрлек төрләре белән ярашуда, күрсәтү алмашлары *ндый, лай, ләй* белән ясалуда, сорау алмашлары – беренче иҗек басым белән әйтелүдә һәм алдан *бер, һәр, һич, әллә* сүзләрен алып, азактан *дыр* кушымчасы алып ясалуда аерылалар (*боларның исем төрлекләре белән төрләнмәгәннәре исемнән саналмаска тиеш*);

рәвешләр мәгънә ягыннан сыйфатка бик якыннар. Аларның берсе урынына берсе йөрүләре дә бар. Шуңа күрә аермалары бик аз, шулай булса да, рәвешләрне без: 1) фигыльләргә тәртип белән янәшә килеп бәйләнүләре; 2) урын алмаштырганда да төрләнмәүләре; 3) сыйфат

белән аергаланмаулары; 4) күпчелегенең сыйфат кебек көчәйтү, кабатлау кисәген алмавы; 5) җөмләнең хәбәре булып килә алмаулары белән аера алабыз.

### Нәхү бүлеге турында

Нәхү бүлеге русларда да, хәтта Европада да тәмам эшләнеп бетмәгән бер бүлек булган өчен, грамматиканың бу ягы безнең өчен аеруча җаваплы бер мәсьәлә булып тора. Һәрхәлдә без нәхүне сүз тезмәләренең тышкы төрләрен, аларның үзара эчке бәйләнешләренә мөнәсәбәтләрен тикшерә торган бер гыйлем дип беләбез.

Сүзләрнең үзара эчке бәйләнешләре җөмләнең баш кисәкләрендә ярашу, тиңләшү (*иснад*) рәвешләрендә, ияргчен кисәкләрдә ияру (*башкарылу*) рәвешләрендә була. Җөмләдәге сүзләр үзара эчке яктан, теләсә ярашу рәвешендә, теләсә ияру рәвешендә бәйләнгән булсын, аларның бу бәйләнешләре, Бәдигый иптәшчә, «ярашу» булып чыга, тышкы яктан түбәндәге шәкелләрнең берсе я берничәсе белән күрсәтелгән булырга тиеш: 1) кушымчалар белән (монда хәбәрлек, килеш кушымчалары йөри); 2) ярдәмлек сүзләр белән; 3) төрсезлек (ул форма) белән (мәсәлән, ияләрдә килеш төре белән әйтелмәү); 4) сүзләрнең урыннары, тәртипләре белән; 5) мантыйкый басым белән; 6) интонация, тынышлар белән җөмләнең һәрбер кисәгендә бу шәкелләрнең бары да бер юлы табылып бетүе лязим түгел. Интонация белән күрсәтелгәндә, кушымча белән белдерелгәндә, мәсәлән, аларның тәртипләре үзгәрергә дә мөмкин була.

Иярчен кисәкләрнең бәйләнешләрендә шәкли билгеләр белән бергә, аларның нинди сүзгә ияреп, бәйләнеп килүләре дә бик әһәмиятле (без боларның нинди сүзгә бәйләнүләре, эчке сорауларга җавап булып төшүләренә карап, кушарлап тезеп караудан беләбез). Чөнки без әйтергә теләгән уйны, мәгънәне аларның нинди сүзләргә бәйләнүләреннән генә ачык аңлый алабыз. Җөмлә кисәкләрен шулай аерганда гына эчке мәгънә белән тышкы шәкел арасында тулы мөнәсәбәт күзәтелгән булачак. Җөмлә кисәкләрен, Бәдигый иптәш тәкъдим иткәнчә, ялгыз шәкелләренә генә карап (саф шәкли рәвештә) аерту, бердән мәгънә белән мөнәсәбәтне бозу булса, икенчедән, җөмлә кисәкләрен үзара чуалтуга сәбәп булачак. Мәсәлән, иярүләре ялгыз тәртип белән генә күрсәтелгән сүзләрне барын да хәл (рәвеш) исеме астында йөртү мөмкин түгел. Төрсез, тәртип белән бәйләнгән сүзләрнең кайвакыт ия дә, тәмамлык та була алуын онытмаска кирәк. Шулай ук исемгә бәйләнгән сүзләрне дә, тәмамлыклар бәйләнгән сүзләрне дә тәмамлыклар белән саташтырырга ярамый. Мәсәлән, *ның* кушымчасы белән исемнәргә бәйләнеп йөргән *иялек аергычы (изафә-теркәү тәртибе)* Бәдигый иптәш тарафыннан тәмамлыклар җөмләсеннән санала. Хәлбүки *ның* кушымчасының килешләр арасында күрсәтелүе үзе дә бик шартлы бер нәрсә. Аның башка килешләрдән шәкли яктан да, эчке фун-

кциясе ягыннан да аермасы бик зур. Аны тәмамлыклардан санау – икенче дәрәҗә иярченнәрне беренче дәрәҗәдәгеләр белән саташтыру, шәкел белән мәгънә мөнәсәбәтен күзәтмәү була. Фигыльгә ияргән кисәкләрнең дә, исемгә ияргән кисәкләрнең дә тышкы бәйләнешләре телебездә булган шәкелләрнең, формаларның һәр төрлесе белән күрсәтелә алуына дикъкать итәргә кирәк була. Бәдигый иптәш *ярашу*ның (*бәйләну*нең) төрләрен аңлатканда, руслардагы кебек эчке мәгънә ягына карап эш итсә, аларны җөмлә кисәкләренә аерганда артык шәкелгә бирелеп киткән. Шуңа күрә тышкы билгеләрендә дә кайбер аерымлыклар ясарга туры килгән.

Тәмамлыкларның тәгърифендә *фигыльдән алда килеп* дигән сүзне төп, *тамыр фигыль* дип аңларга кирәк. Китапта бу башта ук аңлатып кителгән. Шуңа күрә тәмамлыкларның фигыльдән ясалган исемнәргә дә ияреп килүе мөмкин булып чыга.

* * *

«Татар грамматикасы»ның басылып чыкканына инде берничә еллар үтеп китте. Мин үзем дә, тикшерү өстендә булганга күрә, шул аралыкта аң арттырырга, төзәткәләргә тиешле булган байтак кына яңа нәрсәләр җыйган идем. Алар китапның тагы бер басылуын көтеп торалар. Һәрхәлдә яңа гыйльми бер мәсьәләдә үзара аңлашу өчен иптәшләрнең чыгышлары, тәнкыйтьләре бик кирәкле, бик файдалы бер эш булды. Моның өчен иптәшләргә чын күңелдән рәхмәтләр әйтәм, мондагы җавапларга канәгатьләнеп бетмәгән иптәшләрнең якында басылып чыгачак **«Шәкли грамматика нигезләре»** турындагы аерым китапка (*докладларга*) мөрәҗәгать итүләрен үтенәм.

## ГЫЙБАДУЛЛА АЛПАРОВ ҺӘМ ГОМУМИ ТЕЛ ГЫЙЛЕМЕ

Г.Алпаровның 1945 елда басылгын «Сайланма хезмәтләре» тел-әдәбият факультеты студентлары һәм тел укытучылары өчен ярдәмчел материал буларак тәкъдим ителә. Әлеге җыентыкта, автор үзе искәрткәнчә, «... телебезне гыйльми тикшерү юлында бер тәҗрибә» итеп язылган, 1926, 1927 һәм 1945 елларда аерым китап булып дөнья күргән «Шәкли нигездә татар грамматикасы» дигән күләмле хезмәте һәм гомуми тел фәлсәфәсенә мөнәсәбәтле берничә мәкаләсе урын ала.

«Тел гыйлемендә марксизм хәрәкәте» дигән мәкалә 1929 елда «Мәгариф» журналының 5, 6–7 нче саннарында басылган була. «Тел гыйлеменең кыскача тарихы», «Тел гыйлемендә нигез мәсьәләләр», «Яфетик эзләнү юллары» дигән тикшеренүләр авторның 1929–1931 елларда укылган фәнни докладларына нигезләнеп языла һәм «Тел гыйлемендә марксизмга таба» дигән гомуми тема һәм махсус кереш белән берләштерелеп бирелә. Боларга тагын авторның 1933 елда «Яңалиф» журналында (№ 3) «Тел гыйлемендә диалектик материализм методологиясе нигезләре» дигән мәкаләсе дә кушыла; болары, җыентык өчен, Л.Җәләй тарафыннан редакцияләнә (Алпаров, 1945: 211–327).

Әлеге мәкаләләр, докладлар язылган вакытта, Гыйбадулла Алпаров һәм Хуҗа Бәдигый СССР Фәннәр Академиясенең Ленинградтагы шәрыкны өйрәнү институтында филолог һәм археолог Н.Я. Марр (1864–1934) җитәкчелегендә белем ала, нәтиҗәдә алар телне «яңача өйрәнү» дигән тәгълиматның төп нигезләрен үзләренең тикшеренүләрендә дә чагылдырырга тырышалар. «Сайланма хезмәтләр»гә кереш язучы Ш.Рамазанов бу хакта болай дип белдерә: «... Г.Алпаров, атаклы совет тел галиме, академик Маррның татарлар арасында иң күренекле һәм талантлы шәкерте буларак, тел турындагы яңа тәгълимат нигезләрен татар телендә популярлаштыру һәм татар теле материаллары өстендә ясаган тәҗрибәләре, эзләнү-тикшеренүләре белән совет тел белемен баету юлында әле бүген дә әһәмиятләрен югалтмаган хезмәтләр калдырды».

Н.Я.Маррның XX гасырның 30–50 нчы елларында совет тел белемендә, тел-идеологик өскорма, иҗтимагый формацияләрнең үсеш-үзгәрешенә бәйле һәр яңа формациядә телнең структур төзелеше дә кискен үзгәрә, яңара, ягъни тел дә сыйнфый күренеш ул, дигән карашы, телне өйрәнүдә әһәмиятле яңалык дип кабул ителә; илдә барган тулаем яңарышка-пафоска аваздаш буларак, бик активлаша; яфетизм дигән теория, марксизм-лени-

низм, диалектик материализм дигән төшенчәләр белән бергә, еш кабатланып кулланыла, әмма диалектиканың төп үзәге, ягъни үсеш-үзгәрештәге эзлеклелек, традицион-дәвамчанлык мәсьәләсе инкарь ителә, пролетариат диктатурасына кадәр булган чордагы әдәбият та, тел дә, бигрәк тә язма әдәби тел, шул исәптән телне өйрәнү-тикшерү методлары да «буржуаз» дип белдерелә.

Г.Алпаровның гомуми тел фәлсәфәсенә мөнәсәбәтле рәвештә язылган мәкаләләрендә, чыгышларында да, асылда, менә шушы мәсьәләләргә игътибар ителә. Мәкаләләрнең гомуми кереше итеп бирелгән өлешендә фәннең «... сыйнфый оештырылган белем» булуы, фәнни тикшеренүләрдә кулланыла торган метод һәм методологиянең дә шулай ук сыйнфый булуы , ягъни «... тикшерүченең сыйнфый аермасы, идеологиясе, дөньяга карашы белән бик нык бәйләнгән» булуы: «... Әлегә кадәр, башка күп гыйлемнәр кебек, тел гыйлеме дә буржуа белгечләре тарафыннан оештырылып, аларның идеологиясенә ятышлы методлар изах ителеп килде. Шуңа күрә аның буржуа сыйныфы мәнфәгатенә корал булып килүенә шөбһә юк. ...Безнең татарлар арасында әле тел гыйлемендә иске буржуа өйрәтүләре дәвам итә. ...Тел – иң көчле сыйнфый көрәш коралы. ... Бөек СССР илендә пролетариат идеологиясенә буйсынмаган бер фәннең дә яшәве мөмкин түгел. ... Революцияче пролетариат өчен фәнни тикшерүләрдә тик бер генә метод бар. Ул да – чын объектив барлыкны чагылдыручы диалектик материализм фәлсәфәсе, марксизм-ленинизм методы. Без үзебезнең гыйльми тикшерүләребездә шушы диалектик материализм методологиясен үзебезгә юлбашчы итеп алабыз, шуның өчен көрәшәбез», – дип белдерелә. Гомуми керештә тезис буларак күтәрелгән әлеге проблемалар һәр мәкаләдә кабатлана, киңәйтелә, үстерелә.

Сыйнфый каршылыкның бигрәк тә язма әдәби телдә ныграк чагылуына аеруча басым ясала: «Әдәби тел, гомумән, икътисади, сәяси хаким булган сыйныфның теленә нигезләнә. ... Хаким сыйныф әдәби телне үзенең сыйнфый мәнфәгатьләренә хезмәт иттерә, буржуазия аны эксплуатация коралы итеп файдалана. ... Капитализм тормышында төрле сыйныфның телендә аерма булмый хәле юк. Буржуа сыйныфы динле, милләтле, укымышлы әдәби бер телгә ия була. Алар шул тел белән үзара берегәләр, пролетариатка, хезмәт ияләренә өстен булып торалар»,– дип яза автор, телне «яңача өйрәнү» тәгълиматы таләп иткән ысулда. Буржуаз әдәби телгә күп шивәләргә аерылган крестьян һәм авылдан чыгып шәһәрләшә барган пролетариат теле каршы куела: «Алар арасында корычланган, үткен көрәш теле үсә. Формасы – милли, эчтәлеге – пролетар тел, бара-бара, үзенә бер юл алып үсә, өстен чыга»,– дип ышаныч белдерә. Һәм шундый нәтиҗә ясала: «Кыскасы, монолит милли бер тел юк. Милли телне монолит бер тел итеп уйлау – ул, асылда, сыйнфый аермаларны күрәсе килмәгән буржуа милләтчеләрнең фикере генә. Шуңа күрә телләрне, җиренә, халкына карап кына түгел, мәгълүм социаль коллектив теле һәм

аның эчендәге сыйнфый катлауның теле булу ягыннан карап өйрәнергә кирәк була».

Хәзерге гомуми тел гыйлеме күзлегеннән караганда, бу тәрдәге фикерләрнең барлыкка килүе, ул вакытта инде Ф. де Соссюр (1857–1913) тарафыннан фәнни нигезләнгән, телне Тел һәм Сөйләм итеп карап тикшерергә кирәк, дигән карашның киңәеп китә алмавы белән аңлатыла. Әлеге караш нигезендә, монолит бер милли тел бар, ләкин ул үзенең кулланылышында бер төрле генә була алмый; телнең структур төзелеше, кем тарафыннан, ни өчен, нинди максаттан файдаланылуына карап, аерымлана, менә шушы аерымлану, ягъни сөйләм нигезендә, «сыйнфыйлык» хасил була. Сөйләм дигән төшенчәне Г.Алпаров та куллана, тик ул монда тел дигән мәгънәдә файдаланыла: «Аерым бер милләтнең бөтен социаль катлаулары, андагы төрле сыйныф кешеләре бары да монолит бер тел белән сөйләмиләр. Аларның сыйныф булу ягыннана аерылулары телләрендә дә мәгълүм микъдарда аерманың булуын китереп чыгара. Масса теленә, эшче теленә элгәреге аристократиянең, бай сыйныфның, «урам теле», «гавам теле» дип, түбән күз белән каравы юкка гына түгел». Аңлашылганча, тел һәм сөйләм абсолют синонимнар буларак, берсе икенчесен алмаштырып кулланыла. Әмма шуның белән бергә, автор болай дип тә белдерә: «...Социаль мөнәсәбәт берәмлеге булу ягыннан, телдә иң нигез булган факт – сөйләм (фраза – высказывание). Шуңа күрә аерым сүзләр сөйләмнән, җөмләдән аерып каралмый, бәлки шул тулы бөтеннең бер кисәге итеп, бөтен бер комбинациядә, контекстта карап тикшерелә. Ялгыз сүз бөтен фикернең кисәге генә, шуңа күрә ул сөйләм эчендә генә аңлана ала. Шуның белән бергә, бирелү, саклану, төзелү өчен уңайлы булу ягыннан, телдә аерым сүз дә бик әһәмиятле бер бөтен саналырга тиеш». Сөйләм дигәндә авторның, асылда, җөмләне күз алдында тотуы күренә.

Әмма ничек кенә булса да, Г.Алпаровның татар филологиясендә беренче мәртәбә гомуми телгә нисбәтән күтәрелгән кайбер фикерләре аларның алга таба ничек итеп тикшерелүен күрергә мөмкинлек бирә. Аерым фикерләре исә хәзерге гомуми тел гыйлеме өчен актуаль булып яңгырый: мәсәлән, фонеманың мәгънә аерымлый торган аваз, авазның сөйләм берәмлеге булуы, тел берәмлекләрендә форма һәм мәгънә берлеге, тел берәмлекләренең үзара ныклы берлек хасил итүе, «...төрле кисәкләрнең бер-беренә бәйләнешләрен, бер-беренә тәэсирләрен бик нык күзәтергә, аларны да үзара бер-беренә бәйләп өйрәнергә кирәк булу» һ.б. Хәзерге гомуми тел гыйлемендә телнең структур төзелеше дигән теманы үткән вакытта, галимнең әлеге фикерләренә нигезләнә алабыз.

Шуның белән бергә, «Тел һәм җәмгыять», «Тел һәм аң, тел һәм фикерләү», «Тел һәм сөйләм» дигән, гомуми тел гыйлеменең үзәк мәсьәләләрен аңларга һәм аңлатырга тырышканда да татар халкының танылган телчесе Г.Алпаров хезмәтләренә мөрәҗәгать итә алабыз. Дөрес, болар бүгенге

көндәге кебек, ныклы бер эзлеклелектә бирелми, ләкин игътибарны җәлеп итәрлек дәрәҗәдә яңгырый. Мәсәлән, галимнең «Тел – табигатьтә булган күренешләрнең иң гаҗәп, иң тирән, иң катлаулы булганы» дигән тәкъбирен , теләсә кайсы теманы үткәндә дә, һәрдаим кабатлый алабыз. Гомуми тел гыйлеменең «Тел һәм аң» дигән темасын үткәндә, дәреслектә дә: «... язык выступает в роли орудия формирования самих актов сознания. ... язык есть средство его выражения. Сознание – условие и основная причина развертывания речи, т.е. речевого функционирования языка», – дип аңлатыла (Общее языкознание, 1979: 72–73 б.). Үз вакытында Г.Алпаров та нәкъ шушы фикерне әйтә: « ... Уй белән тел – болар икәве үз башына аерым нәрсәләр түгел, бәлки икәве бер үк мөнәсәбәт фактының ике ягы. Болар икәве диалектик берлек хасил итәләр. Аң да, тел дә – объектив барлыктагы күренешләр, алар шуны чагылдыралар. Тел үзара аңлашу коралы гына да түгел, ул җәмгыять әгъзаларының фикер чарасы, уйлау коралы да».

Гомуми тел гыйлеме курсында «Тел һәм җәмгыять» дигән тема аерып алып өйрәнелә. Анда телнең иҗтимагый-социаль табигате, телнең барлыкка килүе һәм үсеш-үзгәрешенең һәм әдәби тел һәм әдәби норма формалашуының социаль күренеш булуы, функциональ стильләр һәм җәмгыять һ.б. шундый катлаулы мәсьәләләр тикшерелә. Тел – ул җәмгыятьнең тумасы, аны яшәтү чарасы, әмма ләкин тел үзе дә реаль – объектив яши торган система. Әлеге темаларның барысы да диярлек, үз чоры дәрәҗәсендә, Г.Алпаров хезмәтләрендә чагылыш таба. Монда иң гаҗәбе шул: бүгенге көндәге гомуми тел гыйлемендә объектив дөрес һәм субъектив хата дип санала торган фикер, икесе бергә үрелеп, бер үк җөмләдә, бер үк абзацта бирелә. Мәсәлән: «Тел – иҗтимагый хадисә, иҗтимагый аңлашу ролен үйный торган шартлы уртак нәрсә. Ул – аңның тышкы – техник рәвештәге күренеше. ... Тормышның идеологиягә (өскормага) әйләнүен барыннан да элек телдә күрергә, тикшерергә була. Аваз телендә иҗтимагый тормышның чагылуы бик катлаулы, аның үткән юллары бик төрлечә. Тел – күп катлаулы, кеше тормышының тарихын, бөтен иҗади агымнарын эченә алган бер хәзинә ул. Шунлыктан монда садә, бер катлы карашлар белән түгел, бәлки бик күп белем белән эш итәргә генә мөмкин», – дигән язмадан «тормышның идеологиягә – өскормага әйләнүе иң элек телдә күренә» дигән өлешне сызып куйсак, авторның фикере нәкъ хәзерге фән таләбенчә яңгыраш ала. Яисә: «Хуҗалык төрләре, тормыш мөнәсәбәтләре үзгәрү, алмашу белән аң һәм тормышка караш үзгәргән кебек, аның тышкы чагылмасы булган тел дә үзгәрә, алмаша. Коры сүзләр генә түгел, төрләр дә, авазлар да, тормыш төренә охшашып, өзлексез үзгәрә баралар. Шуңа күрә тел, сүз кешелек дөньясындагы икътисади, иҗтимагый үзгәрешләрнең көзгесе була ала. Анда азлап-азлап бөтен иҗатлар, элгәреге үткән тормыш эзләре, элгәреге караш рәвешләре җыела, саклана килгән була», – дип яза автор. Бу өзектә сүзләрнең генә түгел, телдәге авазларның да, тормыш төрләренә охшаган-

ча, өзлексез үзгәрүе турындагы фикер генә чынбарлыкка туры килмәве расланган. Галимнең түбәндәге белдерүе дә бүген әйтелгәндәй актуаль яңгырый: «Телнең мәгънәсе дә, формасы да, кануннары да иҗтимагый. Ләкин, шуның белән бергә, тел үзенең эчке кануннары белән, берникадәр үзенчәлек белән яши. Аның үзенә генә хас булган, специфик хасиятләре дә бар. Шунлыктан телне, бәйләнеш ягыннан гына түгел, үзенчәлекләрен ачу ягыннан да ныклап өйрәнергә кирәк була». Әлеге фикер тел – ул җәмгыятьнең тумасы булуына карамастан, үз йөзе, үз табигате белән реаль яши торган система дигән мәгънәне аңлата.

Г.Алпаровның татар филологиясендә беренче мәртәбә гомуми тел гыйлеменә нисбәтән язылган мәкаләләрендә бүгенге фән өчен дә мөһим булган менә шундый һәм башка күп кенә фикерләрне ассызыклап күрсәтә алабыз.

*И.Бәширова*

# ЭЧТӘЛЕК

Г.Алпаровның тормышы һәм гыйльми эшчәнлеге. *Ш. Асылгәрәев* .......... 5
Төзүчеләрдән .......... 20

**Хәреф вә имлямыз** (әлифба тарихы, иске язулар, хәрефләребезнең күплеге, үз тавышыбызга хәрефләр, имлямыз...) .......... 22

**Грамматика нигезләре турысында** .......... 42

**Латин түгел, гарәп** .......... 52

**Шәкли нигездә татар грамматикасы** .......... 64

- Сүз башы .......... 65
- Беренче бүлек. Кереш.Тел һәм сөйләшү .......... 66
- Икенче бүлек. Телебезнең фонетикасы .......... 74
- Өченче бүлек. Телебезнең сарыфы .......... 98
- Дүртенче бүлек. Телебезнең нәхүе .......... 160

**Татар грамматикасына караган өстәмә материаллар** .......... 188

- Татар теленең ялганмалык табигате турында .......... 188
- Татар телендә кушма төрләр .......... 208
- Функциональ сүзләр (ярдәмлекләр) .......... 228
- Татар телендә иярчен җөмләләр бармы? .......... 235

**Ун ел эчендә татар теле** .......... 248

**Фонетик транскрипцияме, гамәли язумы?** .......... 255

**Татар грамматикасы турындагы тәнкыйтьләргә җавап** (1928) .......... 269

**Татар грамматикасы турындагы тәнкыйтьләргә җавап** (1929) .......... 276

Гыйбадулла Алпаров һәм гомуми тел гыйлеме. *И. Бәширова* .......... 282

Научное издание

**Алпаров** Гибадулла Хабибуллович

ИЗБРАННЫЕ НАУЧНЫЕ ТРУДЫ

ФОНЕТИКА. ГРАФИКА. ОРФОГРАФИЯ.
ВОПРОСЫ ГРАММАТИКИ

Казань. Издательство «Магариф». 2008

*На татарском языке*

Фәнни басма

**Алпаров** Гыйбадулла Хәбибулла улы

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

ФОНЕТИКА. ГРАФИКА. ОРФОГРАФИЯ.
ГРАММАТИКА МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Басма өчен җаваплы: *Ш. Н. Асылгәрәев*
Редакторлары *Я. М. Абдулкадыйрова, Л. Г. Шәрифуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Компьютерда биткә салучысы *Г. Г. Камалова*
Корректоры *Г. Ә. Гыйләҗиева*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 03.12.2008. Форматы 70×100 $^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Татар сувенир» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 24,05+ф.0,48. Нәшер-хисап табагы 18,09+ф.0,81.
Тиражы 500 д. Заказ Т-1551.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62
http:// www.magarif.com
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.